# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ

## ЯШЬ ЙӨРӘКЛӘР

Роман

1

Кояш тотылгандай булды... Бер секундта бөтен дөнья үзгәреп, яктылык ничектер бетте дә, тирә-якны әллә нинди куе вә куркыныч караңгылык каплады. Хәйрәттән[1] гакыллар эшләмәс, күзләр аермас булды... Адәмнәр гүя юлларыннан шаштылар, һәркем баскан җирендә[2*] катып калды... Берәүләр урамда сөйләшеп утырган урында истән язды; икенчеләр, бара торган юлларын яңлышып, киң вә тигез урам уртасында, кая барырга белмичә, багана кебек каттылар...

Ике карт, ачмак булып тоткан ишек тимереннән кулларын да ала алмый – алгамы, арткамы атларга белми, хәйранлыкта калдылар.

Һәркем шашты, һәркем аптырады... Һичбер бәндә кая барырын, ни кыйлырын белми...

Адәмнәр үзләре курыкмыйлар да, ләкин һичбер нәрсә аңламыйлар – гүя җан вә миләрен хәйрәт ташкыны басты, гүя ниндидер бер явыз кул анларның миләрен суырып алган да, анда ниһаясез[2] аптырау күәсеннән башка һичбер нәрсә калмаган...

Дөньяның караңгылыгы куәтләнә, куркыныч арта бара шикелле...

Менә, менә тагы бер... ике... күп булса, өч минут кына үтсен – кötелмәгән бер афәт чыгар да, бөтен дөнья җире, күге белән буталыр; һәммә нәрсәнең асты өсткә килеп, барлык җан ияләре артык дәрәҗәдә мөдһиш[3] булган гомуми үлем тарафыннан берьюлы йотылыр[**]; бер минутта бөтен кяинат[4] ниһаясе булмаган юклык караңгылыгы диңгезенә әверелер кеби тоела.

Шул вакыт ерактан, бик ерактан, әллә кайдан түбәннән, ниһаясез караңгы вә тирән һавиянең[5] нәкъ төбеннән килгәнгә охшап, бер тавыш ишетелә башлый.

Ул ят, ул шомлы; ул йөрәкләрне үтә кисеп төшәрлек мәртәбәдә куркыныч та. Ләкин адәмнәр бар да истән язганнармы, – ни өчендер һичкем бунардан[6]

---

[*]Авторда – *“җотылыр”*

[**] Авторда — *«йирендә»*.

[1]*Хәйрәт* – аптырап калу, ис китү [2*]

[2] *Ниһаясез* – очсыз кырыйсыз, чиксез.

[3] *Мөдһиш* – коточкыч, куркыныч.

[4] *Кяинат* – бөтен дөнья, галәм.

[5] *Һавия* – упкын, җәһәннәм.

[6] *Бунардан* - моңардан

курыкмый. Әүвәлге бер минутта баягы хәйрәт куәтләнә дә, шуның артыннан ук халык, һушын җыеп, җиңеллек хис итә – җан әсәре вә уянганлык әсәре күрсәтә башлый.

Теге тавыш якыная, куркыныч та кими бара. Тирә-якны чолгаган караңгылык та, гүя шул тавыштан мөтәәссир булып[1], бераз сыегая.

Җан әсәре арта; һәр нәрсә, җиңелеп, шул тавыш килгән якка карый. Ул як караңгы: күз. анда ни барын ачык аера алмый. Шулай да бераздан анда бик зур бинаның түбәсенә утыртылган озын вә калын багананың, шул куе караңгылыкны ярып, ерак күккә таба мөтәкәббиранә[2] күтәрелгәне күренә башлый. Бераздан соң, бу бинаның мәсҗед булып, теге күккә таба сузылган багананың манара икәне, теге тавышның да шул манараның башыннан кычкырылган азан тавышы икәнчелеге аңлашыла.

Караңгылык тагы бераз сыегая. Халык, җанланып, шул тавышка таба атлыйлар. Анда бик күп ирләр җыела. Йөзләр агарган, күзләр ниһаясез хәйрәт белән тулы. Халык кузгала, атлый, ләкин бу кузгалыш җанлы машинаның хәрәкәтенә охшап, теләк вә ирек белән түгелдер шикелле, һичкем авыз ачып бер сүз дә әйтми, гүя телләре дә тотылган. Күрмиләр дә бугай. Ләкин ничектер берсен-берсе бер дә таптамый. Манарада тавыш киселә, мөәзин төшә. Халык, сафларга тезелеп, сәҗдәгә китә. Кемдер куәтле тавыш белән: «Аллаһу әкбәр!» – ди. Күккә карап дога кыйла башлыйлар. Куллар амингә күтәрелә, – һәм шул секундта дөнья янәдән берьюлы үзгәреп, якты көндә әллә кайдан хасил булган куркыныч караңгылык югала. Көн төнгә әйләнеп, баягы куркыныч рәвештә тотылган кояш урынында матур ай заһир була[3].

Ул тулган; үзе бик зур, бик ерак, бик артык матур вә хыялый төстә нурлы, ләкин бу нурда вә бу югарылыкта мөлаямәт[4] вә иркәлектән бигрәк кибер[5] катыш салкынлык бардыр шикелле тоела. Ул, бер генә минутка суык вә һавалылыгын азайтып, сәҗдәдән калыккан адәмнәргә бер генә, тик бер генә мәртәбә, сөеп, иркәләп карый да калын катлаулы кара болыт артына кача.

Ләкин күңел ышанмый – бу чынлап та ай булдымы, әллә Тәңренең тәҗәллисе[6] идеме? Шуннан соң теге куркыныч тәмам югалып, дөнья үзенең табигый хәленә төшә, адәмнәр дә, гади төннәрдәге кебек, үз юлларына китәләр.

Кояшның тотыла башлавыннан бирле үз күзе алдында булып кичкән бу

---

[1] *Мөтәәссир булу* – тәэсирләнү.
[2] *Мөтәкәббиранә* – горур, масаюлы.
[3] *Заһир булу* – күренү, чыгу.
[4] *Мөлаямәт* – сөйкемлелек, ягымлылык.
[5] *Кибер* – горурлык, масаю.
[6] *Тәҗәлли* – нур чәчү, ялтырау.

әхвальдән[1] хәйрәткә чумган вә ни эшләргә белми аптырап калган Мәрьям туташ та, берьюлы айнып, һичбер нәрсә булмаган кеби, тар гына, озын гына тыкрыктан үзе белән бергә бармакта улган адәмгә карап:
– Соңга калмабызмы икән? Сәгать ничә? – диде.
Ул үз ирегеннән башка әйтелгән бу сүзгә тагы ныграк уяна төште. Ләкин эшнең чынын һаман аңлап җитә алмый: әле генә кояш тотылган иде; анда адәмнәр шашып калдылар. Бер караңгылык, бер яктылык булды. Нindидер мәсҗед, тагы нindидер манаралар, азаннар, гыйбадәтләр-фәләннәр булды. Ул вакытларда Мәрьям туташ ялгыз кебек иде. Кайдан соң бу адәм килеп чыкты? Ничек ул Мәрьямнең култыгыннан тотарлык мәртәбәдә якынлык алган? Кем соң ул үзе?
Ә!., белде.
Янында барган адәм үзенең ире Фәхри икән. Мәрьям туташны, үзе белгәннән бирле яратышып йөргән вә кабергәчә бергә булырга вәгъдә куешкан яры Зыяга бирмичә, икенче бер егеткә биргәннәр. Ул егет матур, шәп, ләкин аның һәрбер сүзендә, кыйланышында, бөтен торышында Мәрьям суыклык хис кыйла; гүя аңың эчендә боз диңгезе бар.
Шөбһә юк, Мәрьям аны яратмый. Ләкин ничек аңа биргәннәр? Ни өчен Зыядан аерылырга Мәрьям риза булган? Буны ул үзе дә белми, белергә дә теләми. Фәхри белән тору үтә кыен да түгел бугай. Ләкин бер уңгай чыкса, теләсә ничек кенә булса да, Мәрьям туташ аңардан аерылырга, аны мәңгегә ташлап, балалык дусты Зыяга барырга хәзер тора.
Көтелмәгән бу вакыйга кайчан булган вә кай вакыттан бирле ул Фәхригә хатын булып яши – Мәрьям буны ачык хәтерләми. Кем белә – былтыр бугай; юк, бу ел яз гына түгелме? Әллә тагы, шайтан хәтерләсенме үзен!
Аның Мәрьям өчен бер тиенгә дә кирәге юк. Булган, беткән: кайчан гына булса да, аны барыбер, кайтарып булмый инде.
Аһ, кичегәләр бугай, – шул уй кылт итеп Мәрьямнең башына килде дә, ул тагы, янындагы иптәшенә карап:
– Фәхри, кара әле! Сәгать ничә? Кичекмәсәк кенә ярар иде! – диде.
Мәрьям туташ шул сүзне әйтеп тә бетмәде, боларның каршыларында өч егет заһир булды. Ахрысы, башка авылныкылардыр, чөнки берсен дә танып булмый. Егетләр үзара берәр генә сүз алышалар да боларның яныннан юаш кына, песи генә кебек үтеп китәләр.
Ул арада булмый, тиз генә борылганнар да, арт яктан үзләренең куәтле куллары белән боларны эләктереп алганнар; икесе Фәхрине каядыр өстери, берсе

[1] *Әхваль* – хәлләр, вакыйгалар.

Мәрьямне тоткан да үзенең кесәсеннән нидер капшап ята. Мәрьям туташ кычкырырга уйлап баккан иде, никтер тавышы чыкмады – авызын каплаганнар бугай.

Ә, юк, башына капчык сыман бернәрсә кидергәннәр икән. Мәрьям аптырый, ләкин курыкмый. Егет тә, бик билгеле һәм гади бер эш кыйлган адәм кеби, туташның колагына нидер әйтә дә кулына бер нәрсә тоттыра. Ахрысы, тимердер: каты да, салкын да. Ләкин кызның буңа бер дә исе китми; бирергә вәгъдә кыйлынган вә бик зарур да булган бер әйбер сыман итеп кесәсенә яшерә дә ире Фәхри янына килә.

Аңа да бернәрсә булмаган; тик башын урап, Мәрьямгә таба каратмыйчы гына тотканнар.

Егетләр, ахрысы, шуның өчен генә килгәннәрдер: эшләрен бетерделәр дә, шул килгән якларына кире борылып, ындыр артына таба юнәлделәр.

Мәрьям туташ:

– Куркам, бармыйк, кайтыйк, – ди башлады.

Ире дә күнде; булар сүзсез генә борылдылар да өйләренә таба киттеләр.

Тирә-як тын. Авыл тирән сөкүнәт[1] вә караңгылык астында. Өйдә дә һәркем йоклаган, лампылар сүндерелгән; тик боларның бүлмәсендә генә тычкан уты шикелле зәгыйфь бер шәм ялтырый.

Кереп чишенәләр. Сәгать ун – ятырга вакыт.

Фәхри, йокымсырап, миңрәүләнеп тора. Ләкин Мәрьям бөтенләй үзгәргән: ул, йөрәгенең ашкынуына чыдый алмаган адәм кеби, урынына утыра алмый, күзләре яна, куллары калтырый; йөзендә башка һичбер вакыт булмаган каһарманлык куәте балкый. Фараз итегез, Тәңренең үзеннән әмер килде: сез хәзерге минутта бөтен дөньяның язмышын үзгәртәчәге ачык мәгълүм булган бер зур эшне башкарырга тиешлесез; менә бер бармагыңызны гына кыймылдатыңыз, хәзер теге зур эш эшләнер, теге мөдһиш нәтиҗә мәйданга килер...

Менә шундый зур нәтиҗә тудырачак бер эш алдында торган адәм ни нәрсә хис кыйлса, хәзерге минутта Мәрьям туташ та үзендә шуңа охшаш бер халәт тоя. Үзе туктаусыз Фәхринең күзләренә карый.

Теге аптырый, шикләнә башлый, ләкин ни диярге дә белми. Эш юктан эш булсын дигән төсле, җилкәсенә тунын сала да тышка чыга.

Мәрьям, тагы да куркынычрак халәткә кереп, баягы егетләр биргән әйберне кесәсеннән ала да, уңгайлап тотып, ире керәчәк ишек төбенә килә. Йөзе агарган, күзләрендә башка һичбер вакыт булмаган ут вә куәт яна, кулларының

---

[1] *Сөкүнәт* – тынлык.

калтыравы арта; бөтен торышына коточыргыч бер төс чыгып, таный алмаслык бер кыяфәт ала, ләкин үзе урыныннан кузгала алмый.

Тыш яктан ишеккә якынаеп килгән бер аяк тавышы ишетелә башлый.

Ә, бу – Фәхри: Мәрьям аның аяк тавышын таный.

Ул якыная, җитә, менә килеп тә керә.

Фәхри, ишекне ачып, бусагадан атлыйм гына дигәндә, Мәрьям, кочакларга омтылган адәм кеби ташланып, аны арткарак этәрә дә, нәкъ йөрәгенә таба төзәп, беррәттән өч мәртәбә ата.

Револьвер тавышы бер секундта, тын һаваны ярып, халыкны уята, ләкин атучы буны ишетми, гүя һичбер тавыш чыкмады. Ул үзе, куркуыннан хәлсезләнеп:

– Уһ!.. Бетте! – дип, артына таба чигә. Фәхри исә:

– Аһ... Мәрьям... беттем... бетердең!.. – дип, туташның муенына асылырга итә. Ләкин аның аяклары куәттән язып, гәүдәсе үзен-үзе тота алмыйча, бусагага чалкан төшә.

Фәхринең йөзеннән хәят[1] төсе китеп, кул-аяклары ташлана; күзләрендә куркыныч үлем ялтырап, тыны киселә.

Мәрьям, ни булганын яхшылап белмичә, үз ирегеннән башка:

– Әни!.. Әни!.. Фәхри атылды... Фәхри үзен-үзе үтерде... – дип, яман аваз белән акырып җибәрә...[*]

Һәм шул тавышка ул уянып та китә...

Бакса, боларның барысы да төш икән.

Кояш та тотылмаган, караңгылыклар да булмаган; теге адәмгә кияүгә дә бирмәгәннәр; аны атуы да юк эш.

Ходаем, өнеңдә шундый куркынычлар булса, нинди яман булыр иде; ару булган, әле дә төш икән. Ул шундый шатлык белән тирә-якка күзен сала башлады. Караса, өстәлләр, зур көзгеләр, урындыклар, китаплар ята, ләкин берсе дә таныш түгел; ул, ахрысы, бүген чит бер җирдә кунактадыр.

Кемдә булыр соң?.. Тукта, ул кичә кайларда булды, ниләр эшләде?.. Өендә иде бугай; ул, ниндидер бер кызганыч роман укып, күз яшьләре дә түкте шикелле; әллә боларның бере дә булмадымы? Алла белсен!..

Мәрьям шул уйлар эчендә кайнаганда, тирә-якта бер үзгәреш булгандай тоелды.

Чү, бу ни эш? Бүлмә азрак кузгала, әйберләр дә бик аз гына алмашалар. «Бу нихәл?» – дип, тагы бер мәртәбә тәрәзәгә таба караса, күз алдында Зыя тора.

---

[*] Авторда – *«йибәрә»*.

[1] *Хәят* – яшәү, тереклек.

А... а... менә нинди шатлык: Зыя солдатка алынган иде, Мәрьям аны бер күрү өчен җан атып йөри, артык сагына, зарыга иде. Менә бәхет!.. Бу ничек булды соң?.. Ничек ул монда кайткан да туры туташның бүлмәсенә керә алган? Аны күрмәгәнгә байтак көннәр булды... Шул арада Зыя бераз үзгәргән. Юк, бераз гына түгел, бик күп, хәтта бөтенләй алмашынган: башында яшел, зур читле, киң, кара түбәле фуражка; өстендә соры шинель; аягында ялтыравыклы итек; тагы шундый ят киемнәр. Ләкин болар  аны бер дә ямьсезләтмиләр. Тик бераз башкарак, уйчанрак вә җитдирәк төс бирәләр. Аның буе да бераз гына үскән бугай; йөзе, әүвәлгедән дә агарып, бераз озынайган, яңаклары суырыла төшкән. Нечкә коңгыр кашлары астындагы зур күзләр эчкәрәк батканнар, ләкин әүвәлгедән бик күп матурайганнар да, һичбер туймас шикелле булып, батырып, туктаусыз елмаеп карыйлар. Бер күзләре генә түгел, аның бөтен торышы, йөзе, авызы – барлык җире шатлыктан көлә түгел, бәлки яратып елмаялар шикелле.
Зыя һичбер вакыт Мәрьям туташның ятагында булганы юк иде. Шунлыктан ул тартынырга, кире чыгарга тиешле иде. Ләкин ул алай итми, йөзендәге нурын, күз вә иреннәрендәге елмаюларын бераз гына арттыра да, Мәрьямнең күзләренә йотылырдай[*] булып текәп карап, үзенең арык, нәзек, ләкин матур кулларын Мәрьямгә суза. Туташ кул бирә; Зыя исә, гомерендә
беренче мәртәбә бугай, аның кулларын үбеп, күзендәге яшьләрне күрсәтмәскә тырышкан адәм кебек, йөзе белән Мәрьямнең калку күкрәгенә егыла.
Ләкин шунысы гаҗәп: Мәрьямгә бундый эштән оялырга кирәк иде, ә ул, һичбер тартынмыйча, үзенең кичке күлмәктән генә булуына да карамыйча, акрын гына урыныннан торды да, үзенең бөтен тәгаҗҗебенә[1] каршы, бик сак кына, бик гади генә рәвештә кузгалып, Зыяның муенына асылды. Берничә минут шул хәлдә калалар.
Соңра Мәрьям тора да бик ашыгып кына киенә башлый. Зыя шунда тора. Аның зур күзләре тирә-якка нур чәчеп туктаусыз елмаялар. Ул әүвәлге Зыя, ләкин бүген аның матурлыгы арткан, бөтен торышы нурга чолгангандай тоела.
Мәрьям тагы оныта башлый. Бу ни хәл? Өнме, төшме? Әллә саташамы? Зыя белән култыклашып, кеше белмәсен дигәндәй, аяк очы белән генә басып тышка чыккач, аның хәйрәте тагы артты: көнме, төнме – аерыр хәл юк; дөнья башка һичбер вакытта булмаган хыялый төсле нур белән тулган. Күк аяз, ачык һәм бик ерак булып, анда карасаң, күз камашырлык, адәмнең йөрәген бер минутта илаһи куәт илә тутырып, рухыңны яндырган гыйшыкка чыдый алмый, сәҗдәгә

---

* Авторда – *“җотылырдай”*
[1] *Тәгаҗҗеб* – гаҗәпләнү,

китәрлек җәмал[1] балкый.

Ишектән чыкканда, йорт һәм авыл боларның үзләренеке төсле, таныш кебек иде. Хәзер ул да үзгәрде. Гүя илаһи бер кул белән җир йөзендәге һәммә биналар, ташлар каядыр алынды да, анларның урынында иге-чиге булмаган бакча хасил булды. Җир өстендә тупрак та, таш вә каралык та юк; һәр җирдә әллә нинди матур агачлар, күктән агылган нур белән гаҗәб бер матурлык алган аллы-гөлле чәчәкләр, дөньяның матурлыгы хакында эчтән зикер әйтешеп[2] утырган гүзәл үләннәр, белмим, тагы әллә ниләр, әллә нинди чибәрлекләр, әллә нинди хыялый нурга чумган чәчәкләр... чәчәкләр... чәчәкләр...

Зыя белән Мәрьям шуларның уртасыннан баралар. Аяклары җиргә әллә җитә, әллә юк; гәүдәләре җиңеләйгән; гүя һавада тора алалар кеби, гүя шул чәчәкләр өстеннән, шул нур диңгезендә йөзеп барган кеби йөриләр. Күңелләре әллә кая, әллә кая ашкына; телләр сөйләми, һәм аңа ихтыяҗ да юк. Чөнки бүген шул дәрәҗәдә якынлашканнар ки, бер-беренең йөрәкләрендә булган хиссиятне сүзсез үк аңлыйлар.

Менә каршыларында көмеш кебек ялтырап аккан гаҗәиб матур бер елга. Их, шунда җуыныргa, шуның буенда, чәчәкләр уртасында бераз утырырга!..

Елганың буенда зур бакча. Бу ничектер Мәрьямнәрнең үз бакчаларына бик охшый. Менә анлар бакчага керәләр. Анда да матур чәчәкләр, зур агачлар бар. Аның бер җирендә тирә-ягы чәчәкләр илә күмелгән кечкенә генә бер чатыр сыман нәрсә бар. Мәрьям буны күргәне бар да, юк та шикелле. Эчендә ни бар икән?... Күрәсе иде! Бу уй Мәрьямнең башына килеп тә җитте, Зыя, аны шундук аңлап:

– Керикме, ни бар икән? – диде. Керделәр.

Йа хуҗа!.. Бу ни... Бу ни хәл?!

Ул бундый нәрсәне күргәне булу түгел, әкиятләрдә дә укыганы юк иде. Чатыр тыштан кечек булса да, эче бөтен бер дөнья: анда бар ниһаясез зур диңгез; ул диңгезнең әллә кай бер җирендә канатларын каерган пароходлар йөри; җир йөзендәгегә бер дә охшамаган матур кошлар оча; әллә кай бер җирендә, матур агачлар уртасында, тәннәре нурдан яратылганга охшаш чибәр хатыннар су керәләр. Болар, әлбәттә, җир хатыны булмас, болар йә пәриләр, йә хурилар булыр. Чатырның бер ягында баягыдан да гаҗәи*брәк төсле нурга болганган чәчәкләр гөрләп утыра. Шулар уртасында тәхеткә охшаш бер урын бар.

Менә... бер... ике минут үтә дә, Мәрьям туташ үзен шул тәхетнең өстендә күрә; караса, ул үзе бөтенләй үзгәреп, өсте ялангачланган да, теге яратып укыган

[1] *Җәмал* – матурлык, күркәмлек.
[2] *Зикер әйтешү* – бер-берен макташу.

«Әлфе ләйлә вә ләйлә»[1*] дәге кызлардан да мең вә йөз мең мәртәбә матуррак кыяфәткә кергән.

Зыя исә аның каршысында тора. Ләкин якын килергә куәте җитми бугай. Мәрьямнең матурлыгы, анын шул нур эчендә шул хурилардан чибәр кыяфәт илә елмаюы аның чыдамын бетерә, – ул, кулларын күккә күтәреп, рухының әллә кай җиреннән кайнап чыккан бер аваз илә:

– Аһ, Мәрьям! Аһ, Мәрьям! – ди дә анын кашында сәҗдәгә китә.

Һәр икесе аңлыйлар: бу сәҗдә – гашыйк күңелнең гомер барынча мәгъбүд итеп[1] килгән җәмал алдында бер самими табынуыннан гыйбарәт иде.

Ләкин бу хәл озакка бармады: белмим, диңгез, дулкынлап, үкереп җибәрде, белмим, андагы пароходлар бик яман рәвештә акырдылар; ни дә булса, каяндыр мөһлик[2] бер тавыш килде дә, бөтен тирә-як кара пәрдә илә чолганып, чәчәкләр кара көйде; дөнья, теге хыялый төсле нурдан язып, кара корымдай бер сыйфатка керде, һәм шул минутта Мәрьям туташ, астындагы тәхетнең каядыр китеп, үзенең, зур куәт илә атылган таш рәвешендә, ниһаясез тирән вә карангы һавиянең төбенә таба ирексез төшеп барганын хис итте. Кычкырырга уйлый, ләкин тавышы чыкмый. Куркудан йөрәге ярылырга якын; тыны да кысылып бара, менә тагы бер-ике минут үтсен – ул, шул караңгылыкка чумып, мәңгегә югалыр, бетәр, дөньяда Мәрьям туташ калмас кебек тоела...

Ләкин бу куркынычның вакыты җитә алмады; туташ, йөрәгенең ярылып баруына чыдаша алмыйча, барлык көче белән бер акырырга уйлаган иде – тавыш чыкмады; ләкин үзе шул көчәнүдән уянып китте; караса, үзенең караватында ята имеш.

Янында Зыя да юк, бакча да, нур да, чәчәкләр дә, теге чатыр эчендәге диңгез дә – берсе дә юк.

Ул бу арада әллә нинди хыялый төшләр белән азап чигә иде. Бусы да шул төшләрнең берсе икән. Җитмәсә тагы, бу көн төшендә төш күргән. Ләкин чынлап уяндымы әле? Бусы да бер саташу гына түгелме?

Юк, бусы инде төштә уяну гына түгел, бусы чын уяну: әнә аның өстәле; әнә бар да матурлап тышланган, исемнәре алтын белән язылган ун җилд[3] «Әлфе ләйлә вә ләйлә»; әнә аналарыннан яшереп кенә саклый торган матур альбомы; әнә кичә кич укый-укый йокыга киткән теге һәйбәт романы – бар да үзенеке, бар да таныш. Димәк, аның чынлап уянуында шик юк инде.

Мәрьям шундый хыял эчендә йөзгәндә, теге яктан ишетелгән бер аяк тавышы

[1] *Мәгъбүд итеп* – табынып.
[2] *Мөһлик* – һәлакәт китерүче.
[3] *Җилд* – том.

аны бөтенләй айнытты.

Анда кемдер кечкенә генә аяклары белән йөгереп керде дә калтыраган тавыш белән, бик ашыгып, кычкырып җибәрде:

– Ахирәт апай! Ахирәт апай! Шәкерт абзыйга әллә ни булды... Әни сиңа тиз генә килсен әле дигән иде...

Мәрьям бу тавышны таный: ул Зыяның сеңлесенеке. Димәк, «ул» кайткан. «Аны» берничә көннән бирле көтәләр, Мәрьям дә көтә. Вәгъдәле көненнән кичегә төшкәч, бер-бер хәл булдымы икән әллә дип, куркышып та торалар иде. Мәрьям, бер яктан, аның кайту хәбәренә шатланса да, икенче яктан, теге: «Әллә ни булды!» – дигән сүзгә йөрәге «шу-у!» итеп китте; һәм шул минутта аның ишеге төбенә бер аяк якынлашты да таныш бер тавыш белән:

– Кызым! Мәрьям!.. Мәрьям, тор инде... Сәгать унбер. Син һаман йоклыймсың? – диде.

Мәрьям мөмкин кадәр йокылы һәм тыныч чыгарырга тырышкан тавыш илә җавап кайтарды:

– Торам, әни, торам... Хәзер торам... Кем бар, әни, анда?..

– Ахирәт апаңның кызы килгән... Мине чакыра... Монда бер кеше дә юк, торып киен дә бу якка чык... Кеше-кара кермәсен!

Тавыш тынды, аның артыннан аякларның тышка таба атлаганы, бераздан ишекнең ябылганы ишетелде.

Мәрьям ятагыннан калыкты. Аның йөрәге тибә, бөтен тәнендә артык каты эшләгәннән соң гына була торган бер арыганлык, хәлсезлек сизелә; башы кызып, хыялында теге төштә күргән гаҗаибаты[1], томан эчендәге гәүдәләр шикелле, буталып йөзәләр. Ул, күзләрен өстәлдәге китапның бер читенә юнәлдергән хәлдә, шул әхвальне җыйнарга, төшен хәтерләргә тырыша иде. Ләкин ничек кенә тырышса да, ул төшләрне ачык вә табигый булган бер күренешкә җыя алмады һәм җыюдан өмит өзеп, урыныннан торды да, өстенә юрган салып, Зыяларның йортына таба караган тәрәзәгә килде.

Анларның өйләре янәшә, арада тик бакча гына бар. Шөйлә ки[2], ул якка караган тәрәзә аркылы Зыяларның өйләрен дә, йорттагы хәлләрен дә күреп була. Ике йорт арасында булган бакча Мәрьямгә бик якын, бик таныш җир. Анда аның бик күп кыйммәтле хатирәләре саклана. Ул Мәрьямгә һәрвакыт бер дә бетми торган җуаныч та, дуст та. Ләкин хәзер ул хәятын җуйган – чәчәкләре сулган, үләннәре саргайган. Җәй көне куе яшеллекләргә күмелеп, гөрләп, мөтәкәббиранә утырган зур карт агачлар хәзер, яфракларын коеп, шыр ялангач

[1] *Гаҗаибат* – гаҗәеп, искиткеч хәлләр.
[2] *Шөйлә ки* – шулай ки.

калганнар, – димәк, көз.

Мәрьям туташ шул тәэсирдән айнып җитә алмады, күзенә бакчадагы агачлар үтәсеннән каршыдагы өйгә таба барган бер хатын илә кечкенә бер кыз чалынды. Анлар бик ашыгып баралар. Менә бер-ике атларлар да таштан ясалган биек болдырга җитәрләр. Аннан ары – ишек... Әнә шуңа барып та җиттеләр, кызу гына ачып, шул ишектән кереп тә югалдылар.

Бу өй – Зыяларныкы, аңа кереп киткән хатын исә Мәрьямнең анасы, вә аның янындагы кызчык та аны чакыра килгән бала иде.

Мәрьям, анлар кереп югалгач, бер генә минутка уйланып торды да көзгесе каршысына килеп киенә башлады.

2

Мәрьямнәр белән Зыяларның өйләре янәшә булган шикелле, гаиләләре дә бер-беренә бик якын вә бик дустанә мөнәсәбәт саклыйлар. Бу якынлык гаиләнең төрле әгъзасында төрле кыяфәттә булып, Зыя белән Мәрьям арасында бөтен дөньяга җиңелмәс мәртәбәдә күнел бәйләнеше булса да, анлар буны үзләренә генә хас бер кодсият[1] дип беләләр, шунлыктан бөтен дөньядан яшерәләр иде. Әмма анларның аналарында бөтенләй икенче хәл булып, Мәрьямнең анасы Фатыйма бикә белән Зыя анасы Зөләйха абыстай эчләрендәге якынлыкны бер дә яшерергә лөзүм[2] күрмиләр, – бөтен дөнья кашында бер-берен ахирәтлек дуст дип игълан кыйлып, бер-беренә «ахирәт» дип кенә, балалары «ахирәт апай» дип кенә эндәшәләр иде.

Бу ике ханым, нәсел, кан һәм мәртәбә игътибары белән башкалардан өстен булганга, үзләрен авыл хатыннарыннан югары тоталар, бөтен авылда бер-береннән башка эч серләрен яшермәслек адәм тапмыйлар, аз гына авырлык булса, бергә елашалар, бергә киңәшәләр, читен минутларда бер-беренең ярдәменә сарылалар иде.

3

Фатыйма бикә ахирәтенең булай кызулап чакыруыннан бик үк борчыла калды. Анларның ишекләреннән: «Ни генә булды икән, Илаһым?» – дип, атлап керү белән, дусты Зөләйханың агарган йөзен, күзләрендәге үлем куркусын күргәч, аның каушавы тагы артты:

– Чү... ахирәт... ни бар... ни булды?..

Фатыйма бикәнең бу сүзләренә каршы Зөләйха абыстай, чак кына тынып алып, хәзер генә бик зур һәлакәтне кичергән бер адәм кыяфәте белән:

– Юк... хәзер ару инде... үтте инде... Бая бик котым очкан иде, – дип җавап

---

[1] *Кодсият* – пакьлек, изгелек.
[2] *Лөзүм* – тиеш.

кайтарды да, кәнәфидә хәлсез төс белән яткан угылына карап: – Балам... хәлең булса тор, ахирәт апаң белән күреш! – диде.

Зыя урыныннан кузгала гына башлаган иде, Фатыйма бикә аның йөзенә кызганыч бер караш белән бакты да, җиңнәрен бармак очынача салындырып: «Кузгалма, Зыя!» – дип, үзе килеп күреште һәм, якындагы урындыкка утырып, сораша башлады:

– Нихәл, Зыя?.. Исән-сау кайттыңмы?.. Йөргән җирләреңдә иминчелекме? Уфада безнекеләрне күрдеңме?..

Сөальләргә берәм-берәм җавап бирелгәч, сүз Зыяның үзенә күчте.

Фатыйма бикә аның хәлсез йөзенә тагы бер мәртәбә кызганып күз салды да:

– Ай-һай, балам, Зыя... Бигрәк беткәнсең икән... Артык өзлекмәсәң ярар иде, – диде.

Зөләйха абыстай, угылының җавабын көтмичә үк, үзе сүз ялгады:

– Әйтмә инде, ахирәт кенәм, кайтып кергәч, үзем дә танымадым. Ул электән ябык булса да, бу чаклы түгел иде; әле кабердән чыккан кеше төсле булган... Илаһым!..

Ике ахирәт Зыяның ябыклыгы һәм танылмас мәртәбәдә үзгәргәнлеге хакында сөйләштеләр дә, Зөләйха абыстай аның кайтуы һәм теге куркыныч хәлнең ни рәвешле булуы тугрысында тәфсыйль[1] бирергә тотынды:

– Атасы, – ди, – каралырга өч көн калгач кайта, дип йөргән иде... Шимбә көттем – юк, якшәмбе көттем – юк, дүшәмбе көттем – юк; юк та юк... Илаһым, дим, бербер хәл булмаса гына ярар иде, дим; күңелем курка башлады... Әнә кайта, менә кайта ди-ди көннәр үтте, төннәр үтте... Урамда ат-арбалы адәм күргән саен, ул түгелме икән дип, чыгып карыйм. Самавырым һаман кайнап тора. Моннан ат җибәрсәң, дим, ерак җир, атасы да өйдә юк, ичмаса, ул булса, әллә берәр җаен табар иде, дим. Ни кыйлырга белми шулай аптырап торганда, бүген иртә белән сәгать сигез дигәндә кайтып керде. Каршы чыксам, исем дә китте, гакылым да бетте; әйтерсең, гомер барынча авырып яткан: күзләре эчтә, йөзе көл кебек... тавышы да әкрен... Балам, дим, сиңа ни булды, дим... Юк, әни, ди, ни булганын үзең беләсең бит, ди... Самавырым кайнаулы иде, зур өстәлгә чәемне әзерли башладым. Юк, әни, ди, миңа, ди, бернәрсә дә кирәкми, тик син минем сумкамнан куфины[2] ал да шуны кайнатып кына бир, ди. Куй, балам, дим, өйгә кайтып бер чынаяк чәй дә эчмәгәч, ул ниткән эш, дим. Ул һаман үзенекен сөйләп, мин ничаклы көчләсәм дә, бернәрсә дә капмады, бер чынаяк чәй дә эчмичә, кара кан кебек каты ясап куфи эчәргә тотынды. Үзе шикәр дә,

[1] *Тәфсыйль* – аңлатма.
[2] *Куфи* - кофе

сөт тә капмый. Балам, дия, йөрәгеңә тияр, син, дим, берәр нәрсә кабарга кирәк иде, дим. Юк, әни, ди, алай эчкәч, файдасы булмый аның, ди. Шуннан ары бераз сөйләшеп утырдык та, ул эчә калды, мин аш өенә чыктым; атасы: Зыя кайтса, аш яса да кияүләрне ал, старостаны да чакыртырсың, дигән иде. Шуңа дип кызуланып әзерләргә тотындым... Пичемә ягып, казанга итемне генә сала башлаган идем, кызым Фәридә дөнья җимерелгәндәй булып акырып җибәрде: «Әни! Әни! Шәкерт абзый үлә... Тизрәк мен!» – ди. Йөрәгем «шу-у!» итеп китте. Ходаем, ни генә булды икән, дим; үзем ни эшләгәнемне белмичә, кулымдагы итле табагымны җиргә ташлаганмын да, атылып монда кердем. Керсәм, ни күзем белән күрим: Зыя кулындагы стаканын идәнгә төшергән дә үзе утырган кәнәфинең буена үлек кебек сузылып төшкән, иреннәре күгәргән... бите көлдән яман... Күзләре йомык. Моны күргәч, куркудан йөрәгем куба язды. «Сиңа ни булды, балам!» – дип, муенына асылдым, Тавыш та юк, тын да юк... Илаһым... хуҗам... Газраил җаннарын гына алды күрәсең, Раббым, дип, һуштан яза яздым. Кая барырга, ни кыйларга белмим. Өйдә кызым Фәридәдән башка бер адәм дә юк... Шуннан соң...

Бу хикәя белән шашып калган Фатыйма бикә, ни дияргә белмичә, ахирәтенең сүзен тәкрар итә:

– Шуннан соң?

Зөләйха абыстай дәвам итә:

– Шуннан соң... Фәридә, Фәридә... бар, йөгер... тиз генә ахирәт апаңны чакыр, дип, сиңа җибәрдем. Үзем аптырадым, ни кыйлырга да белмим... Үлде, күрәсең, инде дип, котым очты... йөрәгем чыга язды. Шул вакыт, Ходай күңелемә салгандыр инде, баягы нәрсә йөрәгенә тимәдеме икән дип, авызына сөт салырга уйладым... Менә, ахирәткәем, Аллаһы Тәгаләнең кодрәте, бер генә йоткан иде, күзләрен ачып: «Аһ… аһ...» – ди башлады. Тагы бер-ике каптырган идем, керпекләре күтәрелеп, җан кергән шикелле булды. Аннан ары инде, иркен тын алып, үзе сөт сорап эчте... Менә шуның белән, Аллага шөкер... хәзер ару инде... Котым гына очкан иде... Илаһым, дим, җыясы ризыклары бетеп кенә кайттымы икәнни соң, дим...

Зыя хәятсыз күзләрен анасына таба юнәлдерә дә аның сүзен бүлә:

– Юк, әни... андый куркыныч нәрсә түгел ул. Миңа калада да бер булган иде; доктор: бер нәрсә дә булмас, тик вакытында сөт кенә эчәргә тиеш, диде...

Ханымнар икесе берьюлы Зыяга борчулы кыяфәт илә карап:

– Куй, балам, алай димә, Алла үзе генә сакласын диң, – диештеләр.

Сүз икенчегә күчте.

Ун минут чамасы сөйләшеп утырдылар да, Зыяның бераз хәл алганын, йөзенә

кызыллык вә күзенә хәят нуры калыкканын күреп, инде куркыныч үтте дигән кыяфәт илә, ханымнар икенче өйгә чыктылар.

4

Зыя быел никрут. Ул иртәгә таң белән каралырга китәчәк. Аның ябыклыгының һәм аз гына сәбәп белән һуштан язарлык мәртәбәдә хәлсезлегенең дә бөтен сере шунда. Бу хәл аның анасына тоз өстенә торма дигәндәй тәэсир итә. Зөләйха абыстайның угылының ябыклыгына, хәлсезлегенә кайгыруы вакытлы гына, болай өстән генә, әмма асыл мәсьәлә аның никрутлыгында. Менә шул аның йокысын качыра, шул аның бөтен диккатен үзенә алып, туктаусыз көенүләр тудыра.

Ул үзенең угылы Зыяны алты яшьтән үк шәкерт итеп күрергә, егермеләргә җиткәч, һәйбәт, әхлаклы хәлфә кыяфәтендә уйларга өйрәнгән; инде, озакламый мәхәллә иясе булып, мөнбәр өстенә менәргә якын итеп хыяллый башлаган иде. Ул Зыяның өстендә бик матур җилән дә чапан, башында чалма булуын, кулында китап «Корьән» генә йөрүен тели; авызыннан чыккан сүзнең дә аять, хәдис кенә булуын көтә, – ул шуларны тели, көтә һәм булыр дип ышана; шул ышану аңа Зыяны шулай булып беткән үк, анын башка бер халәттә булу ихтималы юк ук дип, хыялына урнаштырган. Шөйлә, аның хыялында Зыя – мәсҗедтә картларны елатып корьән укый торган шәкерт; аннан соң мәҗлесләрдә китап сүзе генә сөйләп йөрүче хәлфә; аннан соң шәригатьнең барлык, барлык эшләрен камил үтәп, халыкны да шул юлга өндәүче хәзрәт — мөнбәр иясе.

Ә язмыш аңа каршы барырга әйтә. Киләләр дә аның Зыясын башка мужик егетләре рәтеннән никрут ясамакчы, аннан ары, Алла үзе генә сакласын, солдат ясап, әллә нинди кара урыс арасына алып китмәкче, Ходай язмасын, чалма-чапан урынына әллә нинди картузлар, кара чикмәннәр кидермәкче, харам нәрсәләр ашатмакчы булалар... Никадәрле дәһшәт!.. Никадәрле авыр көннәр!!!

«Никрут»... «каралу»... «солдатка алыну»... кебек сүзләр борын аңа бертөрле дә мәгънә аңлатмыйлар, ул, боларны үзенә килми торган нәрсәләр кебек кенә уйлый иде. Ә хәзер алай түгел. Угылының каралачагы мәгълүм булган көннән башлап ул сүзләрнең мәгънәсе, тәэсире үзгәрде. Бу сүзләрне ишетү белән аның угылы хәтеренә килә дә, язмышында булачак авыр алмашыну күз алдына килеп баса. Ходаем, ниләр генә язган икән... Шулай ук аның Зыясын да алырлармы икәнни?.. Шулай ук Тәңре аның намазлык өстенә утырып түккән күз яшьләренә бер дә генә илтифат итмәсме икәнни?.. Илаһым, хуҗам!

Аның хәзерге кайгысы бервакытта да үтә зур куәт белән йөрәген телгәләп ташламый; ул, һәлакәт килеп баскандагы шикелле, башын кая куярга белмәслек

мәртәбәдә өзгәләнеп янмый, көйми; шуның илә бәрабәр һичбер вакыт тынмый да, йөрәге тыныч та булмый. Каралачак көннәр якынайган саен бу тынычсызлык арта, көчәя бара. Керә хатыннар, аналар. Анларның да җә угылы, җә кияве, җә башка бер якыны карала. Анлар да, башка һәрнәрсәдән бигрәк, йөрәкләрен тындырмый торган шул кайгылары хакында сөйләргә яраталар. Бу сүзләр Зөләйха абыстайның ярасына тоз булып төшә. Аның тынгысыз йөрәге тагы борчыла башлый.

Зыя сәхәрсез руза тоту илә мәшгуль булганга, халык серне аңламасын өчен, каралырга өч кенә көн калгач кайтачак иде. Аның вәгъдәле көннән кичегүе Зөләйха абыстайда әллә нинди катыш хиссият уятты. Ул, берәр эш булмадымы дип, бер яктан кайгыра, котылу хакында берәр юл эзләмиме, тапмасмы дип, икенче яктан шатлана да иде. Угылы кайтып та, аны кабердән чыккан адәм төсле күргәч, хиссиятендәге теге катышлык тагы артты. Ул Зыяның ул дәрәҗә ябыклыгына, куркыныч бер авыруга сәбәп булмасын-фәлән дип, бер яктан пошына; шул ябыклык аркасында теге бәладән котыла алмасмы дип, икенче яктан бераз шатлана да иде. Уйламаган җирдән андый куркыныч хәлгә, һушсызлыкка төшүе аның йөрәген бөтенләй үк урыныннан кузгаткан иде, җиңел генә терелә алгач, теге шатлык ягы күтәрелде. Ул тагы шул бер-беренә каршы булган ике тойгы тәэсирендә, диңгездәге кечек кимә кебек, дулкынлана башлады.

Зыяның язмышына Фатыйма бикә дә салкын карый алмый. Ул бит Зыялар гаиләсенең дусты, бигрәк тә Зөләйханың ахирәте. Эчке дустлык илә бәйләнгән бу ике гаилә гомер барынча бер-беренең кайгыларын уртаклашалар. Шулай булгач, Фатыйма бикә дә һәрвакыт матур вә гакыллы шәкерт итеп күрергә өйрәнгән шул чибәр егетнең әллә нинди ерак җиргә, каты хезмәткә алынып, анасына зур көек булуын теләми, бунардан котылуын эсти[1]; ләкин бу — әхвальнең тышкы ягы. Заһирдә[2], Фатыйма бикә Зыяның котылуын теләвен шул югарыда әйтелгән сәбәпләрдән дип тәэвилли[3]. Әмма мәсьәләнең төбендә буңа бөтенләй башка һәм чын сәбәп булган бер сер бар. Ул да шуннан гыйбарәт:

Фатыйма бикә Зыялар фамилиясен байлыгы, нәселе, игътибары белән бөтен тирә-якта үзләренә якыннан катыша алырлык бердәнбер гаилә дип таный. Ул Зыяның атасына салкын караса да, анасын чыннан тәкъдир итә; Зыяның үзен исә, чибәр, гакыллы, бигрәк тә бөтен тирә-як авылларда шәплек, яхшылык белән даны чыккан булучылыгы өчен, рухының иң төбеннән генә киләчәктә

[1] *Эсти* — тели.
[2] *Заһирдә* — чынлыкта.
[3] *Тәэвилләү* — аңлату.

аның үз гаиләсенә бәйләнешен — кызы Мәрьямгә кияү булырга ихтималлы бер мәхдүм[1] икәнен сизә. Ул буны һичбер вакыт телендә вә гакылында игътираф итмәсә[2] дә, йөрәгенең яшерен бер җирендә ул нык куәт белән саклана. Ул үзенең кызы Мәрьям туташның Зыяга ни дәрәҗәдә куәтле тойгы илә бәйләнгәнен, әгәр дә кияү сайлау хакы бирелсә, шуны әйтәчәген эчтән тоя – тышкы әхвальнең буңа каршы булмаячагын да ачык белә.

Мәхдүмнең алынуы бу эшләрнең һәммәсен пыран-заран китерүе ихтимал. Менә шул мәсьәлә өчен ул Зыяның калуын тели. Бу – эшнең төп сәбәбе, төп сере. Әмма, заһирдә, аның телендә һәм гакылында сәбәп иттереп теге гаиләчә якынлык һәм ахирәт дустлыклар тотыла. Бу сәбәпләр аның рәсми рәвештә кайгыра алуына юл да бирә. Шуңа күрә ул, юк-бар шөбһәләргә китүдән курыкмыйчы ук, Зөләйха абыстай белән бергә кайгырыша ала.

Зөләйха абыстай да бу серне бик аз гына сизенә. Шунлыктан ахирәтлек белән генә чишелә алмаслык серләрне дә бу тугрыда яшерергә лөзүм тапмый. Аның, башка һичбер кемгә әйтелүе мөмкин булмаган берничә мәсьәләсе бар: берсе – Зыяның сәхәрсез руза тотуы, икенчесе – мулласының шул Зыя эше белән бик өмитле бер җиргә киткән булучылыгы, өченчесе – теге явыз Хәйриләрнең, «бирербез әле кирәкләрен» дип, теш кайрап йөрүләре.

Боларның һәрбере аның кашында бик зур вакыйга. Боларның һәркаюсы аның йөрәген туктаусыз тырныйлар. Ул, боларны саклап йөри-йөри, канга сабышудан курка, болар аның эченә сыя алмый, атылып тышка чыгарга омтылалар. Шуның өчен ул бу көн ахирәтенә эчендәге бар нәрсәсен түгәсе килә. Бу көн бу аңа табигый бер ихтыяҗ хөкемендә.

Шунлыктан ул, Зыяның һушына килеп, йөзенә хәят төсе чыгуын күргәч, ахирәтен икенче өйгә алып чыкты.

Анда кайнаган самавыр, әзерләнгән өстәл тора иде. Зөләйха абыстай аш хәзерләүне икенче бер хатынга тапшырды да Фатыйма бикә илә чәйгә утырды. Бу ике хатын чәй яраталар, чәйдән дә бигрәк, зур самавырның суын икәүдән-икәү эчеп бетергәнче озын-озак сөйләшүне яраталар. Сүзләр башка вакытта күбрәк ил гайбәтеннән гыйбарәт була. Ләкин бу көн гайбәткә куәтләре җитми, бу көн икесенә уртак булган вә икесенең дә йөрәкләрен тынычсызлый торган хәсрәтләре бар. Зыя – никрут, Зыя карала, Зыяның алыну ихтималы якын – менә бу көн анларны башка һәрнәрсәдән бигрәк шул мәсьәлә ишгаль кыйла[3]. Бу көн сүзнең мәркәзе шул булачак иде һәм булды да. Фатыйма бикә ахирәтенең

---

[1] *Мәхдүм* — мулла малае.
[2] *Игътираф итү* — тану.
[3] *Ишгаль кыйлу* – биләп алу, борчу.

сүзен җөпләп тора. Зөләйха абыстай исә үзенең кайгысын түгә, төшләрен сөйли, шундый һәйбәт шәкерт өстеннән, Ходайдан курыкмыйча, шикаять итеп алдырырга йөргән теге явызларга ләгънәтләр яудыра, анларны каргый, кешегә казыган базга үзләренең төшүен тели.

Сүз бу тугрыга килсә, аның күзләреннән ирексез яшь коела башлап, ул үзен-үзе оныткан хәлдә каһәрләргә керешә:

– Ходай үзе генә сакласын инде, ахирәткәем, – ди, – булыр ул эттән, бар да булыр, йөзендә иман нуры юк... Мин, дип әйтеп әйтә имеш, ди, йортымдагы актык казыгым беткәнче тырышам. Мин... аның ул маңкасының өстенә солдат чикмәне кидертмәсәм, дөньяда тормыйм, хатыным талак булсын, дип әйтә, ди... Мин, дип әйтеп әйтә, ди, үзем җиде ел йөрдем, ике угылым солдат булды, өченчесе хезмәт итә, киявем дә уйнап кайтты... ә аныкылар аксөяк: киявен дә калдырды, аю кебек таза зур угылы да алынмады... Без генә дигәнмени падишаһка хезмәт итәргә! Барсын ул да... Без күргәнне ул да күрсен, дип әйтеп әйтә, ди...

Абыстайның сүзе шунда җиткәч, ике ахирәт мужикның кабахәтлеге, әшәкелеге хакында төрлечә мөхакәмә итәләр[1] дә, Зөләйха абыстай, күзендәге яшен сөртә-сөртә, тагы дәвам итә:

– Җә инде, ахирәт, үзең уйлап кара: имеш аныкылар хезмәт иткән, – итсә ни була ди, аны бит без иттермәгән... Нигә бездән үч алырга... Кеше бәхетенә касд кыйлганчы[2], Аллаһы Тәгаләдән үзенә сораса ни булыр иде... Төшләрем дә бик яман керә, Ходай үзе генә сакласын инде. Кичә башымны аз гына куеп торган идем, шул Хәйриләрнең зур кара этенең өстемә өреп килгәнен күреп, куркып уяндым...

Абыстайның сүзен теге өйдән килгән бер бала бүлдерде:

– Абыстай, сине Зыя абый чакыра!

Самавырда су да бетәргә якын иде. Фатыйма бикә, чынаягын каплап, кайтырга хәзерләнде; Зөләйха абыстай, аягүрә баскан хәлдә, угылының хәяты хакында тагы бер-ике кызганыч сүз әйтте дә, ахирәтен озатып, угылы янына китте.

## II

Зыяның бер бабасы (атасының агасы) бар. Исеме – Ярулла. Урам телендә аны Ярми карт дип йөртәләр.

Бу – чын мәгънәсе илә авыл карты: туры сүзле, рыясыз, простой; өст-башында вә бөтен торышында борынгыларча булуны сөя; үзе хәзерге халыкны «кылҗи-мылҗи»сы өчен сүгеп, әүвәлгеләрне сагына; кешедән оялуны, уйлаганын әйтми

---

[1] *Мөхакәмә иту* – фикер йөртү,
[2] *Касд кыйлу* – кул сузу.

калуны бер дә белми; халык кашында мәртәбәсе дә бар, сүзе тыңлана, җыеннарда аның тавышына нык колак салына; ул укымаган, гыйлемгә артык исе дә китми; аның һәр тугрыда үзенә махсус кануннары, галәмәтләре бар, болар бар да картлардан калма сүзләрдән, кагыйдәләрдән гыйбарәт булып, ул язның һавасыннан җәйнең ничек булуын, җәйдән көз вә кышның ни рәвешле килүен вә башка шундый үз тәҗрибәсе илә беленгән күп хәлләрнең алмашынуын алдан ук әйтә ала; ләкин болар гына түгел, аның бөтен картлардан ачык аерыла торган бер сыйфаты бар: ул бөтен авылның нәсел вә нәсәбен бик яхшы белә; ул, берәүнең тәгъбиренчә, авылның «аяклы тарихы».

Сез ничек тә булса, бер җаен тугры китереп, аның кылын тибрәтеңез, шуннан соң ул, үзе сизмичә үк, фәлән карт заманында авылга фәлән хәл вакыйг булган елда дип сөйләргә дә керешер.

Зыя яшьтән үк бу (үз тәгъбиренчә) «кара бабайны» бик ярата, аның борынгылар хакында сөйләгән кызыклы хәбәрләрен һәрвакыт рәхәтләнеп тыңлый иде. Шунлыктан аның хыялында үзләренең берничә буыннары бөтен мәнакыйбләре[1] илә тезелешеп торалар.

Картның сөйләвенә караганда, бу авыл моннан ике йөз ел элек утыра башлаган. Башлап нигез салучы Бөре ягыннан күчеп килгән Әлемгол атлы бер карт булган. Ул чакта әле авылның тирә-ягы әзәлдән бирле[2] балта, пычкы күрми, мөтәкәббиранә шаулап утырган зур кара урманнар белән чолганган булган. Шунлыктан буны Кара урман авылы дип атаганнар.

Әлемголның җиде угылы бар икән. Анларның исемнәре фәләнчә, фәләнчә булып, бөтен авыл шул җидедән таралган. Тик мирзалар гына килмешәк икән. Ярми карт ул җиденең һәрберен атый, авылдагы адәмнәр анларның кайсыннан таралганлыгына чаклы әйтә. Ул картның җиде угылыннан иң зурысы Шайбәк исемле булган. Ул галим дә, бай да, могтәбәр[3] дә булган. Заманында бөтен тирә-якны дер селкеткән. Аның угылларыннан, угылларының угылларыннан гел зур кешеләр җитешеп, ул нәселдән бер дә өзелмичә галимнәр, ишаннар, зур мөдәррисләр килгән.

Зыялар да шуның нәселеннән.

Ярми карт бу силсиләне[4] башкалардан да артык тәфсыйль белән белә.

Аның сүзенчә, Зыяның атасы, Җәләл мулла, җиде буын аркылы шул Әлемголның зур угылы Шайбәккә барып тоташа. Ул ике арадагы җиде затның һичбере буш кеше түгел: бар да ишан да әүлия. Карт анларны, үз алдында

---

[1] *Мәнакыйб* – булдыклылык, талант.
[2] *Әзәлдән бирле* –элек-электән.
[3] *Могтәбәр* – атаклы, күренекле.
[4] *Силсилә* – нәсел-нәсәп тарихы.

булып кичкән кебек, исемнәре, тәрҗемәи хәлләре, мәнакыйбләре илә санап бирә. Берничәсенең кәрамәтләре[1] дә бар. Берсенеке бигрәк тә ачык.

Ул җиденең күбесе рәсми ишан булып, ничә йөзләрчә мөритләр тәрбияли булганнар. Әмма Хозайдад атлы берсе, ничаклы ялынсалар да, мөрит алмаган. Халык аны, аталары юлын тота алмады дип, гаепли дә башлаган. Ләкин ул буш кеше булмаган. Бервакыт шуның хатыны, балага авырып, җирдән хәзер генә өзеп алынган яңа җир җиләге тели башлаган. Ә бу хәл үзе кышкы чилләдә, чатлама суык заманда булган.

Ни эшләргә? Мондый вакытта яңа җир җиләген кайдан табарга?

Хозайдад хатынын үзенә чакырган да:

– Серне кешегә әйтмәссеңме? – дигән. Хатын әйтмәскә сүз биргән.

– Ярый, бар, әйтмәс булсаң, тәлинкә ал да базга төш, шунда кирәгеңне табарсың! – дип әмер биргән.

Хатын төшә. Ни күрсен: базда үләннәр, чәчәкләр үскән, шулар арасында җәй көне июль аенда гына була торган эре җиләкләр сабакларын бөгеп утыралар. Үзе бик күп һәм бар да эре, бар да кып-кызыл булып пешкәннәр.

Хатын кирәген ала да, ашап, теләген тутыра.

Ләкин бу серне саклый алмый, берәүгә сөйли. Шуның җәзасыннан, туган ир баласы тәүфыйксыз булып, гомер буена эчеп, ахырда кабак алдында вафат булган...

Бу хикәяне Ярми карт бик тәмләп, баллап сөйли. Ул. хәзерге нәселдән канигъ[2] түгел; вакландыңыз, бабайлар кебек була алмадыңыз, ди, һәм һәрвакыт үз сүзенә куәт өчен шундый бер кәрамәт-фәлән китерә.

Зыя бу сүзләрнең, бу зурлыкларның чын икәнендә шөбһә итми. Анларны тирә-якта булган һәммә халык тәсдикъ кыйлган кебек, атасы Җәләл хәзрәтнең шүрлегендә өелеп яткан китаплар да аның растлыгына шәһадәт бирәләр.

Мулланың өч катлаулы бер шүрлеге бар. Анда аның үзе хәлфә булган заманда алып та, инде һичбер тотмас шарты илә, тузанга ташланган байтак мантыйк вә Кәлям хашияләре[3] белән бергә кулъязма китаплар бар. Болар, һәммәсе бик искеләр, һәммәсе бик калын яшькелт кәгазьгә бик пөхтәләп язылган. Күбенең читләрендә, эчләрендә шөххәләре[4] дә бар. Боларның һәммәсе диярлек теге Ярми карт сөйләгән җиде буын адәмнәре тарафыннан язылган улып, күбенең ахырында бик озын имзалар, язучының атасы һәм остазы ягыннан булган силсиләләр дә бар. Үзләре бармак калынлыгы такталар һәм жуан тиреләр илә

---

[1] *Кәрамәт* – изгеләр тарафыннан күрсәтелгән «хикмәтле» эш.
[2] *Канигъ* – канәгать.
[3] *Мантыйк вә Кәлям хашияләре* – логика һәм Коръән сүзләренә аңлатма.
[4] *Шөххә* – китап битенең, кырыена язылган язулар.

сыйраҗлаб[1] тышланганнар да. Араларында шундый зур һәм авыр булганнары бар ки, Зыя ун яшьләрендә чакта анларның кайберләрен күтәрә дә алмыйдыр иде. Болар һәммәсе гарәбчә язылганга, ул яшь чагында бернәрсә аңламаса да, читләрендә, баш вә азакларында булган кайбер төрки сүзләрне күреп, һәрвакыт укый иде. Мондыйлардан бигрәк тә кечерәк бер мәҗмуга аңа кызык тоела иде. Тарихына караганда, ул мәҗмуга теге Җәләлдән җиде буын югары булган Шайбәкнең угылыныкы булырга охшый. Аның «тарих мең дә сигез йөз дә хутның[2] икенче яумендә»[3] дип башлап язган үз куллары, аннан соң килгәннәрнең зур казалар, бәлалар, кайсы елны боз ни вакытта киткәнлекләре кебек вакыйгалар-фәләннәр хакындагы язулары да очрый. Арада бабаларның мәнакыйбләренә гаид[4] нәрсәләр дә була.

Менә шуларның һәммәсе теге Ярми картның сүзләренә Зыяны ышандырып, аның хыялында бабалары чыннан да дан һәм зурлыкта булып урнашалар.

2

Тәварис[5] бу урында үзен күрсәтми кала алмады.

Зыяның атасы Җәләш (Җәләлетдиннән үзгәртелгән) хәзрәт кыяфәте белән бабаларына охшый; ул озынрак буйлы, киң күкрәкле, зур вә тигез җилкәле, киңрәк һәм озынчарак йөзле. Аның куксу-соры күзләре һәрвакыт һәрнәрсәгә югарыдан һәм мәртәбә белән карарга яраталар. Ул үзе күп, кызыклы һәм югарыдан торып сөйли. Һәммә мөгамәләсендә үзен булган мәртәбәсеннән өстен тота, һәрвакыт бераз кабарырга, куык очырырга тырыша. Тырыша гына түгел, бу аңа гадәт тә, табигать тә булып киткән.

Менә бу хәлләрдә шул зур нәселнең кәраматле канының тәэсире юк түгел.

Аның канында зурлык, тирә-яктан өстенлек һәвәсе[6] кайный. Бу аңа бабадан калма мирас. Аның бабалары чынлап та заманының зурлары, ләкин алар хакындагы мәнакыйбләр бигрәк зур. Анларның даны бигрәк югары оча. Шул зур аталарның баласы Җәләлгә исә табигать андый зурлыкны, зур ясарлык куәтне бирмәгән; ләкин тәварис үзенең тәэсирен күрсәтми кала алмый: Җәләш хәзрәттә алай зур булырлык куәт булмаса да, канында зурлык нәтиҗәсе булган «данлылык» һәвәсе, рухында бабалар зурлыгының күләгәсе бар.

Шул һәвәс, шул күләгә аның табигатендә иң зур вә иң эшчән куәт булалар; аның хәяты гомер барынча шул һәвәс, шул күләгәнең күргәзгән юлыннан агып

---

[1] *Сыйраҗлаб* – төпләп.
[2] *Хут* – 22 февраль белән 22 март арасындагы вакыт.
[3] *Яум* – көн.
[4] *Гаид* – бәйләнешле.
[5] *Тәварис* – нәселдән килүчәнлек.
[6] *Һәвәс* – дәрт, теләк.

китә. Һәм шул хәлләр аның халык телендә җилкуар, мактанчык, куык вә кабаргач дип тә аталгалавына сәбәп булалар.

3

Сез, мөнбәрдә исемен әйттереп, дан чыгарырга теләгән башкорт агайның кыйссасын ишеткәнеңез бардыр. Булмаса, сөйлик.

Борын заманда булган, ди, бер башкорт. Аны «Байгура» дип атаганнар. Ул үзе бик бай да, юмарт та булган; ләкин үзе һәр җирдә макталуны, зур җирләрдә исеме әйтелеп, тирә-якка даны чәчелүне бик сөя икән. Ул юмартлыктан үз авылына башлап мәсҗедләр салдырган, татардан мулла китерткән; аны тәрбияли дә икән. Әмма шул үзе китергән мулланың һәрбер җомганың хотбәсендә[1], теге мәсҗед вә муллага файдасы тию түгел, үз баласының тамагын да туйдыра алмый торган хәерче Галиләр, карак Хәсән белән каравылчы Хөсәеннәр, тагы җыен ярлы Әбүбәкерләр[2*]-фәләннәрнең исемен зикер кыйлап[2] та, үзен бер дә авызга алмавына бик кәефе китә башлаган. Байга исә бу эш аның авылда базарын төшерер, дәрәҗәсен киметер кеби тоелган. Бераз сабыр итсә дә, ниһаять тыела алмаган: муллага үзенең үпкәсен сөйләп, башкача риза булмаса, тик бер генә хотбәдә үзенең исемен бер генә мәртәбә әйттерү өчен кырык баш мал (куй) бирәчәген белдергән.

Шук мулла беренче җомгада ук, яшел таягын алып, мәһабәт кыяфәттә мөнбәргә менә дә, сүз уңгаен-фәләнен карамыйча, хәмед вә салават[3] рәтеннән:

– Йа әйеһәлбайгура! Әнтә кәлбөн кәбира![4]

– Йа әйеһәлбайгура! Әнтә кәлбөн кәбира! – дип, сузып, мәкамләп ялгап җибәрә.

Хатиб[5] әфәнде авыл халкын үтә күрә, шунлыктан бик имин. Ләкин, гөнаһ шомлыкка каршы, җомга вакытында авылдан үтеп барып та, азанны ишеткәч, атын мәсҗед ихатасына бәйләп, намазга кергән бер татар шәкерте эшнең мөнәсәбәтсезлеген сизә дә шөбһәне аңлаткан рәвештә тамак кыра.

Мулла тиз арада аңлап ала да, бер дә каушамый гына, укып барган аяте артына:

– Ля тәнәхнох, йа әхи! Әрбәгунә ганәмөн, нисфы ләкә, нисфы ли,[6] – дип куша.

Шәкерт тына.

Мулла да, хотбәсен бетереп, Байгурадан, бер мәртәбә исемен мөнбәрдә зикер кыйлган өчен, кырык куйны алып, ярымын шәкерткә бирә...

---

[1] *Хотбә* – вәгазь.

[2] *Зикер кыйлу* – мактап телгә алу.

[3] *Хәмед вә салават* – мактау сүзләре, догалары.

[4] *Йа әйеһәлбайгура! Әнтә кәлбөн кәбира!* – Әй син, кара бай! Син бик зур эт шикелле!

[5] *Хатиб* – вәгазь сөйләүче, оратор.

[6] *Ля тәнәхнох, йә әхи! Әрбәгунә ганәмөн, нисфы ләкә, нисфы ли!* – Тамак кырма, энем! Кырык куй, яртысы сиңа, яртысы миңа.

Халык алдында бер мәртәбә исемен телгә алдыру өчен шунча маллар бирер мәртәбәдә данлылыкка һәвәскәр булган байгуралар була калса, Зыяның атасы Җәләш хәзрәт тә, һич шөбһәсез, шуларның берсе, бәлки беренчеседер.

Үз хакында әйтелгән яхшы сүздән һәркем азмы-күпме күңелләнә; үзе вә үзенең эшләре-фәләннәре хакында макталуны сөю – зәгыйфь йөрәкле бичара адәмнең бер кимчелеге. Ләкин сәламәт табигатьле адәмнәрдә бунның бер чиге була; анлар кеше сүзенә ул чаклы исермиләр, макталуга да ул чикле җиңелмиләр.

Жәләш хәзрәттә исә бу сыйфат һичбер төрле чикләнмәгән. Бу сыйфат аның гомерендә һәр тугрыда иң зур рольне уйнады, аның хәятындагы иң мөһим эшләрнең булу йә булмау якларыннан беренең җиңүе ул эшнең шул сыйфатка мөнәсәбәте рәвешеннән килде.

Ул үзе баладан ук бик кызу да, усал да, комсыз да иде. Һәрнәрсәне үзенә генә аласы килә. Һәр тугрыда аның кәефен карасыннар. Бер нәрсә булса, аңа зур да, күп тә, яхшысы да бирелсен. Анасы аштан кайтса, моңа өлешнең зурын, тәмлесен калдырсын. Кыш булса, шуа торган чапаның матурын ул алсын; кием теккәндә, аныкы башкаларныкыннан әйбәт, төймәләре ялтыравыклы булсын. Аш, чәй вә башка вакытларда ул унгай урынга, кунакка якында утырсын. Әгәр дә шуларның берсе генә ул дигәнчә булмаса, бер генә тугрыда анык мәртәбәсе икенчеләрдән югары кыйлынмаса, ул дөнья туздыра башлый: ни очраса, шуның белән бәрә; вата, бөтен дөньяга акырып елый, тилерә.

Бу вакыт аңа кагылма гына инде, кагылдың – бетте, ул тагы яман җүләрләнә башлый. Ләкин анасы угылы Җәләлнең табигатен яхшы аңлый. Мондый турыларда аның кайсы кылын басарга кирәклеген ачык белә. Ул иң әүвәл өйдә булганнарның һәммәсен берәмләп тирги, шелтәли башлый, соңра җенләнеп яткан Җәләлгә килеп, башыннан сыйпый, аны иркәли, мактый:

– Кил, гакыллым, кил, Җәләлем, син гакыллы бит, шул тилеләргә карама... фәлән, – дип, малайның хәкарәт күргән хөббе нәфсен[1] күтәрә һәм шуның белән аны җиңә дә.

Бер-ике минуттан соң карасаң, малай, күзләрен сөртеп, һавалы сыйфат илә йөри башлаган була.

Җәләлнең бу табигатен аңлаган адәмнәр аңа баладан ук: «Үскәч нинди булыр... дөньяны җотар, Илаһым, бу убыр...» – дип карыйлар, икенче яктан аның хакында «салам кыстыру» гыйбарәсен кулланалар иде.

Җәләл боларның һәр икесе дә чынлыктан бик ерак булмаганлыгын үзенең бөтен хәяты илә күрсәтеп бирде.

Бераз үсеп, мәдрәсә вә халык дөньясына чыккач та, ул һаман һәр тугрыда үзен,

---

[1] *Хәкарәт күргән хөббе нәфсен* – кимсетелгән горурлыгын.

тик үзен югары, тиңсез күрсәтәсе килә, шуны эзли, шуңа исерә; икенчедән, аның бу кылын белеп баса алган адәмнәргә, үзе сизмичә үк, һәр эштә җиңелә дә иде.

Ул үзе яхшы, зирәк кенә бала иде. Мәдрәсәдә шәрикләре эчендә башта беренче булды. Ләкин, гөнаһ шомлыкка каршы, өченче елда анларга кара күзле бер башкорт малае килеп кушылды да монының беләән беренчелектә ярыша башлады.

Бу шәриге, аңардан үзе генә беренче булып йөрү мәртәбәсен алган өчен, Җәләлгә мәңгелек-мәңгелек дошман булды. Ул, шуны узу өчен, шуны үзеннән артта итеп күрсәтү өчен, көннәр тырыша, төннәр тырыша, шуңа тырышып, тиреннән чыга яза иде.

Ләкин теге кара күз башкорт та бик тырыш, ул да бирешми.

Хәтем итеп[1] мәдрәсәдән чыкканчы, Җәләлгә аның белән узышырга, үзен шунардан шәп итеп күрсәтү өчен тырышырга тугры килде, һәм мантыйк моназаралары[2] заманында бер дәрәҗә муафыйк булгандай[3] күрә башлады.

Җәләл мәдрәсәнең беренче моназире[4] иде. Ул күп хашия дә карый, бәхәсләшергә кабилияте[5] дә бар. Ләкин аннан да бигрәк аның тавышы зур, оятсызлыгы чиксез иде.

Мәдрәсәдә теләсә ни генә хакында бер моназара чыгамы, хәзер аңа Җәләл барып тыгылган, аның тавышы һәммәнекеннән куәтлерәк тә, галәбәлерәк[6] тә ишетелә.

Бу турыда ул мәсьәләнең таныш булуын, үзенең аңа ничек каравын һичбер игътибарга алмый; буның аңа кирәге дә юк, кычкырырга, тавышын мәдрәсәгә ишеттерергә юл бармы – булса җитте. Бу хәл кайбер вакыт аның үзе исагуҗихан заманында «Тәүзыйх» мәсьәләләренә катышып[3*] көлкегә калуына яисә, бер генә сәгать әүвәл сөйләгән сүзенең хәзер киресен дәгъва итеп, оятлы булуына да сәбәп булгалый иде. Ләкин ул буңа илтифат итми, болар бит аның моназирлектә ифрат китүен генә күрсәтә. Бик яхшы, күрсәтсен – ул бит үзе дә һәр тугрыда ифратлыкны гына эзли.

Ул мәдрәсәдә заманында үзенең «зур куәтенә» ышана һәм шуның аркасында, бу мәдрәсәдә хәтем кыйлганнан соң, берничә ел мөкәррир[7], хәлфә булып ятырга да, соңра үзен ныграк күтәрү өчен, чит мәмләкәтләрдән берендә булырга уйлый

[1] *Хәтем итү* – бетерү, тәмамлау.
[2] *Моназара* – бәхәс, сүз көрәштерү.
[3] *Муафыйк булу* – ирешү.
[4] *Моназир* – бәхәсче, суз көрәштерүче.
[5] *Кабилият* – сәләт.
[6] *Галәбә* – өстенлек.
[7] *Мөкәррир* – репетитор, өйрәтүче (укытучы).

иде.

Аннан соң эш билгеле: «зур кеше» булып кайта да, аны зур шәһәрнең беренче мәхәлләсенә мөдәррислеккә[1] сорыйлар. Ул җирнең борынгы мөдәррисе үлеп, әзер мәдрәсә, әзер шәкерт буңа кала... Бу керә дә, зур һәвәс илә укытып, шәкерт әүвәлгедән күп арта; анлар башка мәдрәсәнең шәкертләрен авыз да ачтырмаслык моназир булалар.

Менә китә дан! Менә китә яшь мөдәрриснең шөһрәте!

Аңа, әлбәттә, зур байдан маллы кыз алырга да юл ачылган була. Озакламыйча, шәһәрнең беренче ахуны булу ихтималы да юк түгел. Юк, ихтимал гына түгел, булачак та. Шөбһәсез булачак...

Ләкин язмыш икенче төрле карады.

Җәләл–моназир шул хыяллар белән бәхетле булып йөргән заманда атасы үлде дә, моны бөтен җәмәгать исеменнән чакырып кайтарып, муллалыкка тамга җыйдылар.

Аңа авыр, ул теге хыялдан, теге зур шәһәрнең данлыклы мөдәррисе булудан бу караңгы авылга кайтуны бер дә эстәми. Ләкин җәмәгать тели, бөтен агай-эне ялыналар. Анасы сүз дә әйттерми.

Ни эшләсен, – ирексез, мулла була.

Ләкин ул үзенең тик ятмавын өмит итә. Шәһәрдә генә димәгән бит. Әнә Кышкарлар, Эстәрлебашлар[4*] бик кечкенә авыллар. Ә үзләрендә нинди зур мәдрәсәләр бар. Әнә Гыймад хәлфә кайтып мулла булган иде. Артыннан ничаклы шәкерте ияреп килде. Монда мәдрәсә ачты. Фәлән итте дә, ун ел эчендә тирә-якның беренче зур мөдәррисе булып китте...

Җәләлгә дә шундый эш мөмкин түгелмени? Әлбәттә, бик мөмкин. Мөмкин генә түгел, ул шулай булыр да...

Ләкин ул булмады. Җәләл муллалыгының беренче елында менә дигән шәп ахунның гыйлем вә җәмал белән тирә-якны шаулатып, бөтен авызларда: «Ышанырсызмы, Кәрим ахунның кызы «Шәрхе мулла»[5*] укый, ди, кафия мәтенен[2] яттан су кебек эчә имеш...» – дип сөйләнмәктә улган Зөләйха атлы кызына өйләнде дә акрын-акрын дөньяга жигелеп китте.

Кая мәдрәсә дә, кая шәкерт! Кая теге гөрләп моназара кыйлышкан шәкертләргә «Сөлләм», «Казый»ыннан [6*] дәрес әйтү!

Барына да вәссәлам!

Шуның белән аның теге бөтен рухын тутырган идеалына таба хәрәкәте тукталды, ләкин табигате үзгәрмәде. Аның канында теге зур бабаларының

---

[1] *Мөдәррис* – мәдрәсәдә өлкән укытучы, мөгаллим.
[2] *Кафия мәтене* – шигъри (рифмалы) текст.

мирасы булган зурлык һәвәсе һаман кайный, аның рухында теге нәсел буенча килгән данлылыкның күләгәсе һаман да бар, – бу ике нәрсә һаман аны югары очарга димлиләр; ул табигате белән шул күләгә вә шул һәвәскә мәелдән[1] туктый алмый.

Эш вә гамәл белән бу мәелне икънаг итәргә[2] җай калмаган. Шуның эчен хәзер теге табигатьтә булган орлык икенче яктан барып тишеп чыга.

4

Җәләш мулла ул сыйфатын үзе белми. Аның буенча эшләгән гамәлләрендә дә гаделлеккә хилаф һичбер нәрсә сизми; ләкин үзенең табигате аны шуңа өнди; үзен һәр җирдә югары күрсәтү, бөтен эшләрендә тирә-якны шаккатыру аңа мөтәгалликъ[3], һәрбер эштә ничек кенә булса да телгә алынып макталырлык бер имтияз[4] булу – менә аның бөтен тормышында җиңелмәс бер куәт илә хөкем сөргән табигый мәелләр.

Аның күренәсе, күрсәтәсе килә. Шунлыктан кеше күзенә күренерлек булган һәр нәрсәсендә бер буяу, бер куык, бер күтәрелү була. Кешенең өстендәге киеме иң әүвәл күзгә чалына. Ул буны ачык белә һәм бар көче белән тирә-як муллаларының «борынына сугарлык» киенергә тырыша. Аның башында һәрвакыт киң камалы бүрек булыр; эчке киемнәрдән җилән, чапан, казаки, читекләр әлбәттә ачык төстән, ис китәрерлектән; сәгать зур, матур; бавы әллә нинди ялтыравыклы ташлар илә тулып, тыштан салынып йөри. Җәй көне һәрнәрсәгә югарыдан карап, бүрекне бик аз гына кырын салу, арбада барганда аз гына ята төшеп, һаваланып утыру – аңа гадәт. Кыш ул, кая гына барса да, якасы әллә кайдан ук мөмтаз[5] сыйфат илә күренеп торырлык зур бүре толып, зуррак җирдә булса, кызыл якалы төлке тамак толып кия. Ул ничаклы саран, ничаклы акча дусты булса да, хатын вә балаларын да шуңа якынрак рәвештә киендерә. Әнә күрсеннәр: Җәләш мулланың угыллары нинди киенә! Байлык шул! Йорт-җир дә азбар-кура вә каралтылар хакында да шундый ук хәл.

Ул, бөтен авылда булмаганына һәм матди яктан уңгайсызлык биргәненә карамыйча, өйләрне ике кат эшләтте. Әлбәттә, буяп, бизәп, чибәрләп; йорттагы каралтыларның да адәм күзенә чалынырлык булганын мөмкин кадәрле зур, мөмтаз, менә диярлек ясый.

Өйнең эченә керсәң, гади авыл байларында, авыл хәзрәтләрендә булган зиннәтләр өстенә, башка һичкемдә булмаган яхшы кәнәфи, зур өстәлләр,

---

[1] *Мәел* – омтылыш, теләк.
[2] *Икънаг итү* – канәгатьләндерү.
[3] *Мөтәгалликъ* – бәйләнешле.
[4] *Имтияз* – өстен.
[5] *Мөмтаз* – яхшы, матур.

һәртөрле посуда[1] вә бизәкләр илә тулган зур пыяла шкафлар, шалдыратып суга торган зур дивар сәгатьләре, календарьлар һәм һәрбере керү белән күзгә чалынырлык урынга куелган әллә ничаклы киемнәр, байлыклар белән тутырылган була.

Авыл җирендә капканың зур әһәмияте бар. Җәләш мулла буны ачык белдегеннән, өйләре такта белән ябылган булса да, капканы тәмам шәһәр рәвешендә зур, чибәр, мөмтаз ясатып, башын, бөтен гадәткә хилаф рәвешендә, төрле төскә буяп, тимер белән яптырган.

Ул чит бер җирдә булганда бер адәмгә үзенең йортын өйрәтәчәк булса, тавышын тамак төбенәрәк китерә дә:

– Син, энем, авылга кер дә капкаларга гына карый бар. Авылда минеке төсле капка булмас... Зур да, биек тә, кала байларыныкы төсле эшләткән булыр... Башы тимер белән ябып буяган... – ди.

Һәм тирә-якта да аның капкалары мөмтаз сөйләнә. Мулла исә шуңа тагы бераз кабара төшә. йорт-жирдән кала иң зур дәрт белән караган нәрсәсе – ат, ызбруй[2] тирәсенә гаид булып, ул һәрвакыт кучер белән йөри, арба вә ызбруйларны, мөмкин кадәрле, якындагы Ушаков боярыныкы төсле ясарга тырыша.

Бер агасы аның хакында: «Безнең Җәләш «ат тилесе» булып бетте инде», – дип сөйли иде, һәм тугры да.

Ат дәрте аңарда – шифасы булмаган бер авыру кабиленнән[3]. Ул гомер буена ат җыя. Яхшы ат күрсә, һичнигә карамыйча ала, асрый.

Аның бу дәрте ике нәрсәдән туа. Берсе – ул үзе җигеп утырган атның юлда очраган һәркемнекеннән матур да, зур да, симез дә һәм «әһ» тә димичә узып китеп, бөтен адәмнең исен китәрерлек шәп тә булуын тели һәм шул максатына ярарлык атлар эзли.

Икенчесе – ул һәрбер сабан туенда, башка атларны икешәр чакрым артта калдырып, гел беренче килерлек булган бер чабышкы тотуны сөя, һәм шуның өчен, кайда чабышкы булуы өмитле бер тай, бер ат сатылса, ул ала, тәрбияли, шуны чабышкы ясарга хәзерли.

Ул беренче максатына гомерендә берничә мәртәбә иреште – чынлап та үзе теләгән шундый берничә шәп ат асрап, тирә-якка байтак дан чәчте. Әмма икенчесенә бервакытта да ирешә алмады.

Аның ат таныйм дигән дәгъвасе бар. Кайда бер җүнле ат күрсә, хәзер шуның тешен карый, тоякларын карый, буен-фәләнен үлчи башлый. Җитмәсә, бу хакта

---

[1] *Посуда* – савыт-саба
[2] *Ызбруй (сбруя)* – сбруй, дирбия
[3] *Кабил (къәбил)* – төр, рәвеш.

үзе ышанган берничә картның да ярдәменә мөрәҗәгать иткәли. Ләкин бере дә ярдәм итми.

Башта ару да кебек, өмитле дә кебек булалар. Ул көз алган таен кыш буена карый, тәрбияли, кешеләргә аның чабышкылыгы хакында галәмәтләр сөйли. Килә яз. Ул, кар эреп, бик аз гына җир ачылуга, үзенең берничә атына һәм теге «булачак чабышкы» тайга малайларны атландыра да яланга чабышып карарга җибәрә. Әгәр дә, бәхетенә каршы, теге чабышкысы башка атларны уза калса, менә мулланың башы күккә күтәрелә башлый. Аннан соң ул һәрбер очраган адәмгә үзенең шул чабышкысын мактарга тотына:

– Минем, – ди, – Хисамый карт, теге яшь көрән бик шәпкә чыкты бит әле, – ди. – Кичәгенәк, – ди, – халыкның атлары тездән бата, аякларын күтәреп атлый да алмыйлар. Мин шул вакыт Убалы күлдән башлап авыл киртәсенә чаклы – алты чакрым җирдән чаптырган идем. Көрәнем тегеләрне күз күреме җир калдырып килде... Атланган малайның исе киткән: «Хәзрәт, – ди, – мин биш елдан бирле чабышкылар өстендә йөрим, әмма моның кебеккә очраганым юк иде; җил кебек бара, кайда гына ыргытып бәрер икән дип, котым очып барам», – ди...

Бу сүзләрне тыңлаучы риялырак адәм яисә хәзрәттә берәр йомышлы кеше булса, керешә салам кыстырырга:

– Буласының башыннан ук билгеле инде, хәзрәт. Мин, ул көрәнеңне алып кайткач та, әмма соң безнең хәзрәт атны таный да дип, исем китеп агайларга сөйләгән идем... Алла бирсен инде... Быел язда зур сабан туе ясап, теге этәчләрнең борынына суктырыйк инде, хәзрәт.

Мулла берьюлы күтәрелеп китә дә сүзне атыннан үзенә, үзенең ат тану хакындагы талантына күчерә:

– Бервакыт, – ди, – Ушаков боярының бакчасында чәй эчеп утырабыз. Бояр үзе, җәмәгать, бала-чагалары, берничә кунагы бар. Мин юри мескенрәк булып утырам. Карт бояр, яныма килеп, аркамнан какты да: «Җә, мулла, – ди, – мин ике ат алдым, һөнәреңне күрсәт, шуларныш каюсы шәбрәк булыр?» – ди. Атларны китерделәр, мин урындыкка кырын яткан хәлемнән тормый гына карыйм: берсе бик зур, бик симез, матур, том-кара ат; икенчесе ябык кына, бөкре генә, ләкин зур ала күзле, зур авызлы акбүз бия. «Җә, мулла, күрсәт һөнәреңне», – ди. «Ярый», – дим. Һәм яткан җиремнән тормыйча: «Зур кара атың, – дим, – бер тиенгә дә тормый, бер калага барып кайтсаң, эштән чыгар; әмма бу акбүз бия, – дим, – син күрү түгел, ата-бабаңның да төшенә кергән мал түгел», – дим. Карт бояр мыек астыннан гына көлә. Эченнән: «Менә дурак мулла!» – ди бугай. Мин артык бер сүз дә әйтмәдем. Атларны алып киттеләр... Ә минем сүз дөрест булган. Бер көн Уфадан кайтып киләм. Тора тауны менеп

барамыз. Мин кырын ятканмын, атлар бар халыкны узып баралар. Каршыдан килеп чыкты теге бояр. Мин аңа, туктамыйча, ерактан бүрек алып китәргә генә уйлаган идем, ул фуражкасын алган да. «Тукта, тукта!» – дип кычкыра. Туктадым. Ул, минем янга килеп җитмәс борып, кычкыра башлады: «Ах, мошенник мулла икәнсең... Мин беркөн, ни белсен бу татар мулласы, дип калган идем. Сүзең чын булды бит: минем теге биш йөз сумга алынган зур кара атны кичә кырыкка сатып җибәрдем. Бер мәртәбә калага барып кайткан идем, бөтенләй бетте, аякларына да баса алмый, ашый да алмый. Ә теге алтмышка алган акбүз биягә хәзер өч йөз сум бирәләр дә, мин сатмыйм... Харап, харап икән, мулла, синең күзең... Моннан соң ат алсам, сиңа күрсәтмичә алмам», – ди...

Хәзрәтнең мохатабы[1] бундый сүзләрне берничә мәртәбә ишеткән булганга, әлбәттә, бер дә исе китми: «Булыр, хәзрәт, синең ат тануың дөньяга мәгълүм инде», – дип тора һәм шуның аркасында үзенең йомышы хәзрәт тарафыннан бер сүзсез үтәлә.

Халыкның күбе буны белә һәм файдалана да. Ләкин хәзрәткә ул кызганыч түгел, ул дөнья өстеннән ничек тә булса очынырга, кабарырга юл таба – аның табигате шуңа канигъ.

Ләкин чабышкы атлар хакында Җәләшнең бу кабарынуы тик сүздә генә кала иде. Ул, ничаклы тырышса да, бөтен тирә-якның атларын һәр сабан туенда икешәр чакрым артта калдырып килерлек бер чабышкы да күрә алмады. Алып-алып та уйлаганы чыкмагач, ул берничә ел туктап торган, күңеле сүрелә төшкән иде. Тик Идел буендагы бер боярда ике яшьлек бер айгыр сатылуын ишеткәч кенә, аның әүвәлге һәвәсе тагы уянды. Аны күреп кайткан Камали картның сөйләвенә караганда, айгыр яшь булса да, бик өмитле иде: буе озын, гәүдәсе нәзек, ләкин гади атлардан биегрәк, төсе чем-кара; ял, койрык бик шәп; үзе мәшһүр чабышкы нәселеннән булып, атасы – үз гомерендә һичкемгә алынны бирмәгән теге мәгълүм кара айгыр.

Моны ишетү белән, Җәләш мулланың йөрәге берьюлы кузгалып, тиз арада атларын җиктерде дә шуны карарга юнәлде.

Аның торган җире Кара урманнан йөз чакрым кадәрле булса да, мулла өчен бу бернәрсә дә түгел иде.

Өченче көнне ул өйлә вакытында «минә күреңез инде күрмәгәнеңезне!» дигән кыяфәт илә, сылу Кара айгырны чана артына бәйләп, авылга кайтып керде. Айгыр чынлап та бик матур һәм бик өмитле иде. Картлар чын күңелдән үк: «Кара урман бундый малны күргәне юк иде...» – диештеләр. Карарга бөтен

[1] *Мохатаб* – тыңлаучы (икенче зат).

авыл җыелды, малай-шалайның исәбе-саны юк иде. Анлар һәр көн айгырның, сарайдан эчерергә чыгаргач, аяк тибеп кешнәвен, һәрбер күренгән хайван өстенә атылып китеп, ялчының кулыннан китәргә тырышуын күреп, бер-берсенә хәйрәт белән карашалар да:

– Менә, ат, әй!! Вәт ичмаса, булгач шулай булсын, – диешәләр.

Халыкның карашы да шуңар якын булып, бу вакыйгадан мулланың башы күккә тиярлек мәртәбәдә күтәрелде һәм, тагы яңа дәрт, яңа һәвәс илә бирелеп, бөтен кыш буена шул айгырын тәрбияләү белән мәшгуль булды.

Буны ул артык яратты. Шунлыктан ялчылар каравына гына тапшырасы килми, һәр көн иртә намаздан кайта да, өстенә кыска тун, аягына зур пима киеп, билен буып, айгыры янына чыга. Аны үз күзе алдында кыргычлата, сылата, сыйпата да, каеш нуктага озын тезген куйдырып, айгырын шуның белән кулына ала һәм киң йорт уртасында пакь вә йомшак кар өстендә аны уйнатырга керешә.

Өйрәтү исә айгырны, ике алгы аягын югары күтәреп, арт аяклары белән генә басып тора алырга мәләкәләндерүдән[1] гыйбарәт. Бу ничен кирәктер, анысы мулланың үзенә генә мәгълүм. Ләкин ул озын тезгеннән тота да икенче кулына чыбыркы ала һәм, тезгенне югары кагып, чыбыркы илә айгырның тезләренә сугып, рус кучерлары шикелле, тамак төбеннән чыгарылган тавыш илә:

– Сложэ, сложэ, сложэ, – дип, аякларын күккә күтәрергә тәклиф итә[2].

Буның серен Зыялар аңламый; Зөләйха абыстай исә мулласының шундый килешмәгән эше өчен кеше алдында кызарып җаны чыга, аны ни дип тә акларга юл тапмый. Ләкин хәзрәт, боларның һичберенә карамыйча, кыш буенча шул уенны дәвам иттерә.

Килә хәзрәтнең сабырсызлык белән көткән язы һәм ат чабыштыру көннәре. Менә муллага бәйрәм. Менә ул бирә бу ел кирәген теге этәчләргә! һәм раст та. Авылда моңарчы чапкалап йөргән берничә ат белән мулланың айгырын сынап карадылар. Кайда тегеләр: мулланыкы, «эһ» дип алуга, тегеләрне уза да әллә ничаклы җир калдырып килә. Хәзрәт тагы күтәрелә. Ул бу язны үзенең бәйрәме дип таный. Шөбһә юк, аның аты барын узачак, шул сылу Кара айгыр һәм аның иясе бу ел бөтен тирә-якларга дан чәчеп, барын да аста калдырачак!

Көтелгән көн житте. Менә иртәгә сабан туе. Айгыр узе дә сизә бугай: бернәрсә капмый, әллә нәрсә көткән кебек, еракка карап, гел ашкынып, яраулапып тора. Мулла исә аннан да яман: аның йөрәгенең ашкынуына чик тә, чама да юк; ул инде түзми, таң атыр да үзенең аты, беренче килеп, халык алдында зур

---

[1] *Мәләкәләндерү* – күнектерү, өйрәтү.
[2] *Тәклиф итү* – көчләп кушу.

мөкяфәт[1] илә үтеп йөрер минутны җитмәс кебек хис итә.

Икенче көнне кояш чыгуга бөтен авыл аякка баса. Кара урманның кешеләре, алты яшьлек баласыннан алтмыш яшәр картларынача, сабан туе дәрте белән җилкенә. Авыл – ире, хатыны, баласы-чагасы – бары берлектә дуу килә. Чит авылдан кунаклар җыела. Авылның барлык егетләре, атка менеп, яшь килен төшкән йортлардан сөлгеләр-фәләннәр җыеп йөриләр. Урам кызыллы, чобарлы һәм туктаусыз хәрәкәт итеп торган халык белән тула.

Өйләгә таба авылнын кыйбла як башындагы зур чирәмгә сабан туе өчен мәйдан ясыйлар да, бөтен халык шунда агыла. Бер Ходай үзе генә белсен, кайдан бу чаклы халык чыккан да, ничек болар монда җыелып җиткәннәр, – әйтерсең, бертуктаусыз әле бер якка, әле икенче якка дулкынланып торган зур диңгез!

Бу ел байлык. Шунлыктан сабан туе гадәттәгедән зуррак, шәбрәк булачак. Чабарга килгән атлар да елдагы чикле ике бар. Җитмәсә, теге явыз – бөтен тирә-якны узып йөри торган Ала ат та килгән. Ләкин бу Кара урманнарны куркытмый. Анлар Җәләшнең чабышкысы һичкемгә алынны бирмәвенә ачык ышаналар. Бу бөтен авылның күңелендә булган иман Җәләштә бигрәк куәтле.

Чабачак атлар халык диңгезе буеннан йөрәкләренә чыдаша алмагандай йөриләр. Өстләренә, марҗа кызы төсле киенеп, малайлар утырган. Арада мулланың Кара айгыры да бар. Ул башкаларның барыннан сылу да, сөйкемле дә һәм алдан килере мәгълүм үк шикелле.

Атлар каядыр югалалар. Менә ике сәгать инде аларның берсе дә күренми. Ахрысы, чабарга киткәннәрдер. Халык буңа игътибар итми. Анлар мәйдандагы көрәшүчеләр белән мәшгуль. Ләкин ат хуҗаларының йөрәге бер дә урынында түгел: анлар, атларның кайчан киткәнен, ун чакрым җиргә бару өчен күпме вакыт кирәген һәм ничә минуттан монда килеп җитә алачагын чамалап, туктаусыз сәгатьләренә карый торалар.

Вакыт якынлаша. Ат ияләре бер сәгатькә, бер атларның киләчәк ягына карап торалар. Җәләш мулла да кая басканын, ни булганын белми, гүя тиз арада әллә ниләр килеп кичәчәк.

Менә бервакыт кемдер ачы тавыш белән: «Атлар килә... атлар!.. Бер якка! Бер якка!» – дип акырып җибәрде. Карасалар, бер-ике чакрым җирдә бер карачкыл һавада очкан кебек атылып килә. Халык башын күтәреп кузгалырга өлгерә алмый, кемдер:

– Ала ат килә, Ала ат!.. – дип кычкыра башлый.

Халык диңгезе икегә аерыла, һәм арадагы ачыклыкка әллә нинди, матур да, кызганыч та һәм сөйкемле дә төс алган нәзек, озын булган Ала ат килеп керә.

[1] *Мөкяфәт* – макталу, бүләк, премия.

Муенына сөлге ташлыйлар да, ул, халыкның уртасыннан ярып, ун якка үтә. Бу атның кыяфәте, бунын шул беренче килгәндәге төсе күңелгә әллә нинди тәэсир бирә. Ул хәзер һәр нәрсәне аңлыйдыр кебек, барып тәбрик итсәң, белер кебек, тик рухында булган җавапны әйтеп бирергә теле генә юктыр шикелле.
«Ала ат килде» тавышын ишетү, аның муенына зур сөлгенең ташланганын күрү белән Җәләшнең тәненә суык су коелгандай булып китте; ул һичбер бундый хәл булыр дип уйламаган иде. Кара урманлылар да бу көн Кара айгырны беренче күрүләренә ышаналар иде, шунлыктан Ала атны күрү анларга да начар тәэсир итте. Ала атның куәте хәйран икән. Менә ун минут үтте, әле һаман башка атлар күренмиләр дә. Ә, әнә берсе күренде, әнә икенчесе, өченчесе...
Җәләш, үз айгыры беренче булмагач, аның икенчедә булуына шөбһә итми иде; халык та шулай карый иде.
Ләкин бар да алдандылар.
Нәзек, суырылган, танылмас мәртәбәдә тиргә баткан юртаклар* берәм-берәм килә тора, сөлгене ала торалар – мулланыкы исә һаман юк. Моны күреп торган Җәләш, үз эчендәге ялкын вә дәртнең, баягы ашкынуларның акрынлап сүнә, бетә барганын сизеп тора...
Инде килсә дә, хәере юк... Әнә, бәхетсезнең, иң арткы ат булып килеп тә чыкты. Ходаем, моннан да авыр алдану булырмы!.. Җитмәсә, явыз халкы да шунда ук:
– Менә ике йөзлек айгыр!.. Менә чабышкы!.. – дип көлә башлыйлар.
Кайбер этләре:
– Ник көләсез, ярамыймыни?.. Ул да бит, арт яктан санаганда, беренче килде!.. – дип тә мәсхәрәгә алалар.
Ахырдан мәгълүм булды: Кара айгыр, теге чаба башлый торган чиктән кузгалу белән, малайга баш бирмичә, әллә кая, чит якка таба бәреп алып кереп киткән дә, яңадан башка атлар юлына төшкәнче, байтак вакытлар үткән, шунлыктан артта килгән... Юкса, Ала атка беренчелекне бирүе бик шөбһәле икән. Ләкин бу гозер Җәләш мулланың изелгән гыйззәтен[1] кайтармый; шул вакыйга аның «чабышкы асрау» һәвәсен мәңгегә сүндереп, ул хурлыгыннан сабан туйларына да, чабышкыларга да гомергә кул селти.
Инде аның яше дә байтакка килгән. Ничә бала атасы; үзе тирә-якның игътибарлы гына хәзрәте; олыгаеп та бара; һәрхәлдә, болай да чабышкы атлар артыннан йөрү аның шанына[2] бик үк якышмый да – Кара айгыр вакыйгасы аны менә шул фикергә китерде, һәм шул фикер аның табигатендә булган теге

---

* Авторда – “журтаклар”
[1] *Гыйззәт* – дан, мәртәбә.
[2] *Шан* – дәрәҗә, авторитет.

орлыкны тагы икенче җирдән тишеп чыгарга мәҗбүр итте.

5

Бу вакыт хәзрәтнең яше кырыклар эчендә булып, аның җитеп килгән кызы, аңардан кечек дүрт угылы бар иде. Гомер буенча зурлык күрсәтергә генә тырышкан, хәятында булган һәрбер эшне шуның белә генә үлчи торган Җәләш мулла кызына күп әһәмият бирмәде. Аның укытуын, тәрбия дигәнен хатыны Зөләйха абыстай ирегенә ташлап, үзе тик булачак кияүгә бирнә хәзерләү өчен әйбер алырга акча бирүне генә белә иде. Чөнки ул кызларның бер эш кыйлып дөнья яңгырата алуларын, Җәләл мулланың кызы фәлән эшләр кыйлган дип тирә-якта мактасып сөйләнерлек бер хәлнең булырын һичбер хәлдә ихтимал тотмый; шуңа күрә аңа күп игътибар да итми иде. Аның кызы хакындагы иң зур иҗтиһады – аңа: «Җәләш мулланың кияве фәләндәй адәм, фәлән мәртәбәле!» – дип сөйләнерлек, мөмкин булса, тирә-якта ахун була алырлык бер кияү табу иде. Шундый кияүне тапканның соңында ул, әлбәттә, кызының аңа мөнәсәбәтен, кызының ул адәмгә хатынлыкта булачак тормышын һич вә һич бер игътибарга алмастан, үз тарафыннан сүз белән бирде дә, һәр ике якның алыш-бирештә бик зур тотынуына, тирә-якта аныкы шикелле туй булганы юк дип сөйләнерлек мәртәбәдә кибари[1] корылуына гына иһтимам кыйлды[2], – болар, әлбәттә, аның дигәненчә барды, һәм шуның белән Җәләл мулланың үз кызы хакында хезмәте тәмам булды. Ул хакта шуннан башка булган һәрбер эш язмыш ирегенә бирелде.

Ләкин ул угылларына бөтенләй икенче күз белән карый иде. Дүрт угылыннан икесе бик яшьләр әле. Шунлыктан анларны өйдә генә укытмый хәл юк. Әмма Зыя белән Сабир инде кайда гына куйсаң да яшәрлек – анларны чит җиргә илтми ярамый.

Мулла бу ике угылына бик зур өмит белән карый. Аның зурысы артык гакыллылык һәм куәт белән мөмтаз. Кечерәге исә зирәк һәм тырыш күренә. Хәзрәт үзе хыял кыйлып та ирешә алмый калган теге зур мәртәбәгә болар, әлбәттә, ирешергә тиеш. Кем белә, замана баласы аңардан арттырса да ихтимал. Бу яктан өмит тә, ихтимал да зур. Тик шуңа барып ирештерерлек юлга гына салырга кирәк. Асыл мәсьәлә шунда. Хәзрәт бу хакта һәммә эшкә әзер. Ул ярлы түгел; дөрест, акчаны бик яра:а, бик кызгана; шулай да булса: «Җәләш мулланың угыллары!» – дип һәр җирдә яңгырап торырлык бер хәл тудыру өчен ул мал кызганмаска әзер. Эшнең мәгънәви ягында да алданмаслык булырга тырыша. Ул Русиядәге мәдрәсәләрнең мәртәбәсен, дәрәҗәсен белә. Үз

[1] *Кибари* – зурдан кубып.
[2] *Иһтимам кыйлу* – кайгырту.

фикеренчә, иң беренче саналганнардан ике җирнең атаклы мәдрәсәсенә ул ике угылын тәгаен итте: ул анларны бергә куймый: «Берсендә булмаса, берсендә булыр», – ди.

Халык телендә мөмтаз вә макталып сөйләнүгә артык дәрәҗәдә мәел итүе бу хакта файда булып чыкты. Тирә-як муллалары угылларын, октябрь-ноябрь айларында мәдрәсәгә илтеп, яз башында ук кайтаралар. Ләкин Җәләш бу хакта да үзен теге Сафа муллалар, Галикәй ахуннар мәртәбәсендә калдырасы килми; шунлыктан әүвәлге елны ул, кызу эш өсте булучылыкка карамыйча, угылларын август башында ук мәдрәсәгә җибәреп, май беткәч кенә кайтарды.

Бу, бер яктан, аның хезмәт кулларын азайта, икенчедән, мәдрәсәдә озак яту сәбәпле, мәсарифне[1] ике өлеш арттыра – бу хәл аны бераз тыгызлап, киреләтүгә дә якынлаткан; ул да, теге акча сөю хисенә җиңелеп, эш беткәч җибәрергә, яз көне сабанга кайтарырга уйлап куйган иде, тик бер хәл аның бу уена каршы килде.

Мөфтидә мәҗлес булды. Тирә-якның «менә мин!» дип йөргән ахуннары, зур муллалары, могтәбәрләрдән[2] һәммәсе дә бар иде. Шунда гыйлем, мәдрәсә вә балалар укыту хакында сүз чыкты. Җәләштән бурычка акча сорарга уйлап йөри торган бер хәйләкәр карт мулла, сүзгә катышып, тирә-яктагы муллаларны берәм-берәм сүгеп чыкты да, ахырдан китереп, Җәләшне истисна кыйлды[3].

– Менә, – ди, – безнең тирәдә балаларын тәрбия итә белгән тик Җәләл хәзрәт кенә бар. Бездә бер кеше дә аның чикле эш кыйла алмый. Без сараннар; безгә угылларымызның эшләве кирәк; ә ул моны уйга да алмый. Үткән ел кызу урак өсте, көнлек илле тиен; безнең угыллар муеннан эштә; ә Җәләл шул вакытта, басудагы игененең шул көенчә ятканына карамыйча, угылларын мәдрәсәгә җибәрде. Яз көне без, әз генә кар эрүне карап торабыз да, тизрәк алып кайтып сабанга кушабыз. Ә аныкылар май беткәнче мәдрәсәдә яталар. Менә, егетләр, бу. эшне Җәләлдән башка кайсыбыз кыйла ала?..

Бу сөальгә мәҗлестәгеләр: «Әлбәттә, юк! Беремез дә кыйла алмый!» – дип җавап бирделәр. Мөфти исә Җәләшкә рәхмәт укыды, аны мактады, бөтен тирә-як муллаларына аны күчергеч булырга ярарлык, диде.

Мәҗлестәгеләр, бер генә минутка булса да, Җәләшкә кызыккан караш илә бактылар. Ул да, үзенең имтиязын[4], һәммә кешенең аңа шаккатуын хис кыйлып утырган хәлендә, бөтен дөнья башына менгәндәгегә охшаш бер кабарыну тойды. Бу вакыйга аңа гомер буенча сөйләп, мактанып йөрерлек бер материал

---

[1] *Мәсариф* – чыгым, расход
[2] *Могтәбәр* - хөрмәтле
[3] *Истисна кыйлу* – аерып алу, күрсәтү.
[4] *Имтияз* - өстенлек

булу илә бәрабәр; ул шундый имтиязлы эшендә дәвам кыйлып, угылларын мәдрәсәгә җибәрү, кайтаруда шул, августтан май беткәнче, гадәтен куймады; чөнки ул мөмтаз эш; ул аның бөтен тирә-якта макталуына, һәммә муллаларга югарыдан карый алуына хокук бирде, бирә һәм бирәчәк! Җәләлгә исә монардан артык бер нәрсә дә кирәкми.

Хәзрәт үз гомерендә сүзгә, бәхәс вә моназарага бик зур әһәмият бирә торган адәмнәрдән. Ул үзе гомер буенча шуңа тырышты, галәбәне шунда дип белде. Максатына ирешүдә моны иң туры юл дип ышана иде.

Шуңа күрә угылларыннан да, анлар аз гына кычкырыша алырлык яшькә килү белән, шуны таләп итә башлады. Ул, мәдрәсәдән кайткач, азмы-күпме мөнәсәбәт илә, балаларын төрле җирләргә йөртә, зурларга катыштыра, мәҗлесләрдән калдырмый һәм һәрбер барган җирендә угылларының һөнәрен күрсәтергә дә тырыша иде.

Була мәҗлесләр, анда муллалар, мөдәррисләр, могътәбәрләр, шәкерт вә хәлфәләр дә җыела.

Бундый җирне Җәләш бик ганимәт белеп[1], берәр хәзрәткә үз угылларыннан сүз сорап карарга куша. Хәзрәтләр арасында очраган бер шәкерттән «сүз сорап», «чамасын тартып карау» бик гомуми бер гадәт булганга, Җәләшнең үтенүе, әлбәттә, җирдә калдырылмый. Хәзрәт ни дә булса сорый. Китә җаваплар, шаяртулар. Мондый моназаралар кайбер вакыт мәҗлестә булган шәкертләрнең үз арасында да булып ала. Хәзрәт ничек тә балаларын тик тотмый, аның ан*ларны кычкыртасы, бөтен мәҗлестә анларның тавышын хөкем сөрдерәсе килә. Әгәр дә мәхдүмнәре җавап бирмәсә, моназара итешмәсә, бигрәк тә, аны белмибез, дигән кыяфәт күрсәтсәләр, хәзер мулланың төсе үзгәрә, йөзе ачудан кара-кызылга бүртеп, угылларына кул селкә дә үз һөнәрен чәчәргә тотына.

Бу хәлне күрү белән мәхдүмнәрнең йөрәге суга башлый. Чөнки анлар аталарының холкын яхшы беләләр: бу көн өйгә кайтуга анлар өстенә аталары тарафыннан куәтле буран булачак, һәм яңлышмыйлар да. Ул юлда һичбер сүз дәшмичә, ачуына батып өйгә кайта да ишектән керү белән угылларын сүгәргә тотына:

– Мин, – ди, – укытам, дөнья күрсәтәм; сезнең өчен чал сакалымны селкетеп, әллә кайларга керәм, күренәм... Дөньяда һичкем һичбер заманда кыйлмаганны мин кыйлам... Ә сез, этләр, бөтен мәҗлес алдында шул Сафа мулланың маңка малайларына каршы авыз йомып утырасыз. Сез адәм булсаңыз, атаңыздан гыйбрәт алыр идеңез... Менә мин – кем? Мине кем болай ясаган? Мине кем мөфтиләр кашында таныткан?.. Укыту әрәм, йөрүең әрәм, акчаң әрәм сез

[1] *Ганимәт белеп* – кулай, уңайлы күреп.

бозаулар өчен! Имеш, шунда, «мин белмим!» дигәндәй, авыз йомып утыр! Адәмнән оят бит! Анда белү нигә? Бел, белмә: син аңа карама, сүз чыккач, түлке давай, кычкырыша бир... Шунда сине танырлар, шунда гына адәм эрәтенә керә алырсың... Ә сез, ишәкләр, авыз йомып утырасыз...

Бер җирдә сүз чыгып та, белмәсәләр йә, башка бер сәбәп илә, тавыш беткәнче кычкырыша алмасалар, өстләренә ява торган бу буранга мәхдүмнәр бер сүз дә каршы әйтә алмыйлар, чөнки каршы әйтелгән сүз аталарының ачуын арттырып, буранны гына көчәйтәчәк.

Әмма шундый мәҗлесләрдә угыллары туктаусыз сөйләсә, анларнын тавышы туктаусыз чыгып торып, бераз галәбә төсе дә булса, Җәләшкә гомер буена мактанырлык бер материал була. Ул һәр җирдә бик аз мөнәсәбәтләр белән дә моны тәкрар итеп йөри:

– Беркөн, – ди, – муллалар мәҗлесе булып, бөтен тирә-якның әкәләре җыелган иде. Минем Сабирым шунда бер сүз чыгарды. Моны ишетү белән бөтен мәҗлес тын булды. Берсе дә керешә алмый, мактанчык Хатыйп мулла әле аннан, әле моннан тартып карый башлаган иде, – юк, бара алмый. Минем Зыя кызып китте дә берне «Сөлләм»нән, берне «Казый»дан, берне «Тәһзиб», «Мирза»дан[7*] атарга тотынды. Ни булсын, һәммәсенең кимәсе комга терәлеп, бар да шаккатып калды. Мин эчемнән кызганып торам. Чөнки гомердә ишетмәгән, төшләренә кермәгән хәзинәләр муллаларның борыннарына керә... Анлар шуны икенче җирләрдә сөйләп, гыйлем чәчә башлыйлар... Шул көн Хатыйпның исе дә, гакылы да киткән. «Җәләл хәзрәт, – ди, – мин, – ди, – күп йөрдем, күп адәм күрдем, әмма бундый егетләргә очраганым юк иде... Харап икән угылларың», – ди...

Бу сүзләргә Җәләш мулла үзе дә ышана башлап, шул вакыйгалардан соң ул балаларына карашын югарылата, өмитен зурайта. Ул үз гомерендә бик күп зурлыкларны эстәгән адәм. Ләкин күбенә җитә алмады. Буны үзе дә сизә. Ләкин үзе теләп тә ирешә алмаган олуг мәртәбәгә угыллары ирешсә, аның өчен барыбер. Чөнки барыбер анлар Җәләлнең угыллары, барыбер Җәләлгә угыллары аша зурлык килә.

Угыллары мәдрәсәләрендә дә мактаулы. Бик моназирлар дә бугай. Остазлары да мактап сөйли, һәрхәлдә, өмит зур. Ул үзе шәкерт вә хәлфә заманында хыял итеп тә ирешә алмаган нәрсәләргә боларның ирешүе бик матлуб[1] та, якын да эш. Угылларының һәрбер эше шуңа таба корылган. Ул үзе буңа нык ышана; ничек тә булса балалары, берничә елда хәтме көтеб[2] итеп, хәлфә, мөкәррир

[1] *Матлуб* – теләнгән, кирәкле.
[2] *Хәтме көтеп итеп* – укып бетереп (мәдрәсәне) тәмамлап.

булып, зур бер җиргә, әлбәттә шәһәргә, зур мөдәррис, аннан соң даны белән тирә-якны шаулаткан ахун булырлар.

Бу бер дә ят эш түгел. Әнә Шакир ахун авылның бер хәерче баласы иде. Тырышкач, ахырдан нинди зур мәртәбәгә иреште. Әнә Галим шәкерт мәдрәсәдә кешегә самавыр куеп тамак туйдыра иде. Күрәсеңме хәзер: биш-алты йөз шәкертле мәдрәсәнең мөдәррисе. Байлык дисәң – нинди, шөһрәт дисәң – аннан да яман! Хәтта мөфти дә зур эшләрдә аңа киңәш итми эшли алмый икән.

Мондый мисаллар дәхи бик күп. Хәерче малайлары шундый мәртәбәгә ирешә алгач, мәшһүр зур нәселдән килеп, һәрнәрсәдә халыкның исен китәрерлек эшләр кыйла торган, булдыклы, эшлекле Җәләлнең угыллары шундый бер дәрәҗә ала алмасלармыни? Әлбәттә, алырлар! Ул буңа нык ышана һәм бөтен куәте илә шуңа тырышып, балалары хакындагы һәрбер хәрәкәтен шул өмитенә каратып, шуңа якынайтырлык рәвештә эшли.

Менә бер зур шәһәр. Әнә аның беренче мәхәлләсенең мәдрәсәсендә арыслан кебек акырышмакта улган биш йөзләп усал, дәһри, моназир шәкертләр. Әнә шуларга мөдәррислек дигән, дөньяда иң олуг саналган мәртәбә! Җәләлнең угыллары хәятларында шуны максат итәргә, шул мәртәбәне алу өчен, бар куәтләрен сарыф итеп, туктаусыз шуңа таба барырга, шуңа, тик шуңа гына тәвәжжеһ итәргә[1], ул нокта, ул мәртәбә – анларның гамәлләрендә кәгъбә[2] кыйлынырга тиешле!!

Ата шулай уйлый иде.

7

Ләкин угыллар икенче төрле җавап бирде. Заман вә табигать тәэсиреннәндерме, атаның әмәле[3] белән балаларның гамәле[4] кара-каршы килеп бәрелештеләр...

Баланы ата-анадан беренә яисә икесенә дә охшату гадәт хөкеменә кергән. Бу һәм шулайрак була да. Ләкин Җәләл хәзрәт һәм Зөләйха абыстай илә ике зур угылы арасында бу хакта истисна[5] кебек бер хәл булды.

Бу хәл зур угыллары Сабирда бигрәк ачык иде. Бу һичбер сыйфаты – нә җаны, нә кыяфәт вә табигате белән атасына да, анасына да охшамады. Әмма урта буйлы, калынрак гәүдәле, киңрәк, кара һәм караңгырак, өстәвенә катырак та йөзле бер адәм. Аның бөтен торышында юк-барга илтифат итмәү, сентименталистлыкка асла бирелмәү төсе күренеп торган кебек, күзләре дә куәт вә җиңелмәслек белән карыйлар. Ул гомумән сабыр вә авыр табигатьле. Юк-

---

[1] *Тәвәҗҗеһ итү* – йөз юнәлтү, бөтен игътибарны шуңа бирү.
[2] *Кәгъбә* – монда: тоткан юл мәгънәсендә.
[3] *Әмәл* – максат, идеал.
[4] *Гамәл* – эш, практика.
[5] *Истисна* – аерылып тору

барга селкенеп тә, очынып та бармый. Аз сөйли, бер дә мактанмый, үз эшләре хакында хикәя кыйлырга бик аз ярата; ләкин күп уйлый, күп эшли.

Кешенең табигатен тәгъйин[1] итүдә азмы-күпме куәсе булган адәмнәр аны бик яшьтән үк «авыр, сабыр, төпле, гакыллы» дип йөртәләр иде. Моның өстенә «көчле» дигәнне дә кушарга кирәк. Ул юк-бар өчен җилкенеп, кыйналып бармый, пычрак вә ачы иттереп сүгенә дә алмый; шулай булса да, бала чагыннан ук бергә уйнаган малайлар, хәтта дустлары да аңардан, эчке бер куәт сизгән кебек, куркалар, ул дигәнгә җиңелеп, буйсынып баралар иде. Бу хәл мәдрәсәдә дә дәвам итте. Шәрикләре генә түгел, бер төрлерәк хәлфәләре дә аңа бераз шикләнеп карыйлар; гүя бер-бер сәбәп белән шул кузгалыр да эчендә яшеренеп йөргән теге усал куәте белән бер эш кыйлып ташлар кебек тоялар иде.

Ничә гасырлар буенча тын вә тыныч кына йоклап килгән мәдрәсә галәме уянып, шәкертләр әллә нинди ислахат[2] өмитләре белән дулый башлаган заманнарда Сабир да тик ятмады. Ул башкалар кебек ысул җәдидә[3] файдасына, милләт тәрәкъкыйсе[4] намына әллә нинди фәлсәфәләр сатмый, ул хакта туктаусыз моназара дә кылып йөрми; ләкин ничек тә булса мәсьәлә җитдиләшеп, аны кузгата алса, ул, санап сөйләгәндәй, аз, акрын сүзләре илә, мәсьәләгә кагылып, усал, яшерүсез һәм куркусыз гыйбарәләрдә үз фикерен әйтә дә, күп кычкырып тормыйча, моназараны ташлый иде. Аңа мөсәлләм булмыйлар[5], һаман җавап бирәләр, ләкин аның шул сүзләреннән күп тыңлаучының рухында теге иске якка каршы бер салкынлык уяна; ахырдан шул сүзләр аны бик озак уйлата, күп вакыт эчтән җиңә дә иде.

Шәкерт дулкыны, үз куәтенең ниһаясенә җитеп, үзен дөньяга күрсәтерлек мәртәбәдә җитлеккән кебек тоя башлагач, мәдрәсәләрдә үзара җыеннар була башлады. Анда әллә ниләр киңәшәләр, әллә нинди зур үзгәрешләр ясарга уйлыйлар иде. Сабир исә, мәдрәсәне яратмау ноктасында иптәшләре белән бер фикердә булса да, бу хәлдән котылу өчен ярдәм бирер дип уйланган ул шау-шулы җыеннарга, ул киңәшләргә ни өчендер күп якын бармый, бәлки көннәр, төннәр югалгалап, әллә канларга бара, әллә нинди ят адәмнәргә катыша иде. Иттифакый[6] тугры килеп, ул бер җыенда булган иде.

– Син ник бер дә авызыңны ачмыйсың? – дигәч:

---

[1] *Тәгъйин итү* – билгеләү.
[2] *Ислахат* – реформа, яңарту.
[3] *Ысул җәдидә* – укытуда яңа метод.
[4] *Тәрәкъкыйсе* – үсеше, прогрессы.
[5] *Мөсәлләм булу* – риза булу, фикердә килешү.
[6] *Иттифакый* – очраклы рәвештә.

– Мин сезнең иманнарыгызга хәләл[1] китерәсем килми... Мин бу киңәшләрдән күп нәрсә көтмим... Минемчә, моннан китеп, мондагыга караганда яхшырак нәтиҗә бирүе мәгълүм булган бер эш, бер иштигаль[2] таба алуына ышанган егетләр бу мәдрәсәдән таралырга гына кирәк. Ләкин юкка чыктым, мине котырттылар дип, ахырдан еларлык булган шәкертләргә һәр җирдә дә дөнья бер, – дип җавап бирде.

Ялкынлы иптәшләре, әлбәттә, моңа кул куймадылар, үзләренең җыеннарын, киңәшләрен әүвәлгечә бардырдылар. Сабир исә, мәдрәсәгә дә, дәресләргә дә, иптәшләренә дә кул селкеп, үзенең көннәр, төннәр әллә канларга китеп югалуында дәвам итте. Бу югалу, бара торгач, атналарга, ун көннәргә сузылып, ахырдан ул бөтенләй гаиб булды[3].

Фараз итеңез; дөньяның барлык бәхетләре илә тулган хыялый бер алтын сарай булсын. Ул зурлыкта, матурлыкта, тоткан мәртәбәсенең бөеклегендә дөньяда миселсез[4] дә булсын. Язмыш шул сарайны сезгә бирергә, сезне шуның белән дөньяда тиңе булмаган зур мәртәбәгә күтәрергә вәгъдә кыйлды. Менә бер көн, ике, өч көн... Бик күп булса, биш, алты көн генә үтсен, вәгъдәле сәгать җитәр дә, язмыш үз сүзен үтәп, сезне шул сарайга кертер, шундагы бәхетләргә чумырыр, – сез буңа хәзердән бик нык ышанасыз һәм, тиз арада шул зур мәртәбәгә ирешүеңезне уйлап, хыялый бәхет эчендә, өмит диңгезендә йөзәсез. Алгы көнеңез сезгә ниһаясез сәгадәттә[5], җәннәт бакчаларында күренә.

Менә шул вакытта ниндидер бер явыз куәт эшкә керešте дә, сезнең күз алдыңызда дөньяга афәт килеп, теге сезгә биреләчәк алтын сарайны җир йотты[*], берничә көннән соң ирешергә өмит итеп йөргән теге бәхетләр, теге сәгадәтләр бер минутта әллә кая югалды. Сез авыр, мәзлум[6] вә изгеч бер хәлдә калдыңыз. Шул минутта, шул сәгадәтне мәңгегә югалтуыңызны ачык белгән секундта, сез ни нәрсә хис итсәңез, зур өмит баглаган, аның аркылы бик вә бик кабарынулар көткән зур угылы Сабирның югалуы хакындагы хәбәрне алгач, Җәләл хәзрәт тә шуңа охшаш, бәлки шунардан мең мәртәбә авыр вә изгеч булган бер зыягъ вөҗүдкә килгәнен[7] тойды, гүя аны яшен сукты яисә хәятындагы зур бер сәгадәте явыз куллар тарафыннан мәңгегә югалтылды.

Бу хәбәрне аның бер хәлфәсе язган иде. Хәлфә үзенең хатында, Сабирның

---

[1] *Хәләл* – кимчелек, зыян.
[2] *Иштигаль* – эш, һөнәр, шөгыль.
[3] *Гаиб булу* – югалу.
[4] *Миселсез* – мисалы, тиңе булмаган.
[5] *Ниһаясез сәгадәттә* – чиксез бәхеттә.
[*] Авторда – “*җотты*”
[6] *Мәзлум* – җәберләнгән, кыерсытылган.
[7] *Зыягъ вөҗүдкә килгәнен* – югалту, һәлакәт килгәнен.

хәятын әллә нинди куркыныч караңгылыклар эчендә тасвир итеп, аның мөбһәм[1] бер галәм эченә китеп югалуын бәян илә бергә, аның соңгы еллардагы барлык эшләрен: остазларга әллә нинди кискен вә авыр сүзләр ычкындыруын, зурлар вә мәдрәсәләр хакында үзе генә белә торган усал вә куркусыз гыйбарәләр кулланганын да берәм-берәм сөйләп биргән.

Бунардан хәзрәтнең баштагы тәэсире ниһаясез ачу катыш хәйрәт иде: «Җә инде, исең китмәсме, гакылыңнан шашмассыңмы?.. Нинди зур мәдрәсә!.. Нинди остазлар, нинди хәлфәләр! Торган җире нинди! Акча дисәң, тоткар юк... Тагы бераз укырга да, хәлфә булырга да, менә, Алла бирсә, зур бер урынга утырырга гына иде... Тагы шуны кара: без остазлар алдында калтырап тора идек... Кушсалар, аякларын яларга да хәзер идек. Ә ул... ә ул анларга каршы шундый сүзләр әйтә... Йа Хуҗа!.. Оят кайда... Остазлык хакы кайда?..һич булмаса, атасын уйларга иде...»

Җәләл башта шулай хәйрәт белән килә дә усал, куәтле ачуга күчә. «Мин анлар өчен көн йөрим, төн йөрим... Укысыннар, адәм булсыннар дим... Ә ул этләр, ә ул чучка бәрәннәре, маңкалар, үз белдекләре белән эш итәләр... Атайга язу юк, атайдан сорау юк... Тот та шундый эшләр кыйл!.. Әйтмичә югал!.. Югалсын... бетсен... мәңгегә кадалсын... Мин аны йортыма аяк бастырмам!.. Йөзенә төкерермен... кяфернең!..»

Һәрбере миен ярып, агулап барган бу уйлар белән хәзрәт идән буена йөри-йөри дә үзенең артык хәкарәтләнгән гыйззәте нәфсен[2] ни белән күтәрергә, шул мальчишканың[3], атасы шикелле зур адәмнең рөхсәтеннән башка, аяк атлап, читкә басуына каршы нинди зур дәһшәт күрсәтергә белмичә, аптырап, йөзләре кара көя; күзенә явыз вә усал бер куәт чыга да, эченнән ташып барган бөтен ачу дулкыннарын бер сулышта чыгарыр рәвештә: «у-у-ф-ф-ф!» дип, урынына йөзтүбән каплана. Ләкин теге агулы уйлар, теге эченнән ташып барган ниһаясез ачулар туктамыйлар.

Өйдәгеләр бар да, моны сизеп, куркудан җаннарын кая куярга белмиләр. Аның яткан өенә абыстайдан башкасы керми; кергәннәре дә, аяк очы белә генә басып, һичбер тавыш чыгармыйча, күләгә кебек кенә йөриләр.

Ләкин бар да беләләр: эш моның илә генә бетмәячәк әле. Менә бер-ике сәгать үтәр дә, Җәләшнең үз алдына җенләнгән ачу дулкыны чигеннән чыгып, бөтен өйдәгеләр өстенә һичбер сәбәпсез куәтле буран күтәрелеп, дөньянын астын-өсткә китерер; барын да, Сабир өчен болар гаепле булган кебек итеп, эттән

---

[1] *Мөбһәм* – билгесез.
[2] *Гыйззәте нәфес* – үз-үзен сөю хисе.
[3] *Мальчишка* – биредә “малай актыгы” мәгънәсендә

алып эткә салганчы тиргәр, сүгәр, дөнья туздырыр.
Һәм яңлышмыйлар да.
Бунын иң башы, иң авыры, әлбәттә, Зөләйха абыстайга төшә. Ул үзе дә Сабир хакында ни дияргә белми. Ул үзе дә аның һичбер кемгә мәгълүм булмаган теге караңгы дөньяга китеп югалуын аңлый алмый. Бу аңа бик зур изтыйраб[1] та бирә. Ләкин хәзрәт моны игътибарга алмый. Юк бер сәбәп табып, ачулы сүз башлый да, тиз арада аның үзенә, аның балаларына, «аның Сабирына» күчеп, «син үзең шулай, синең балаларың мондый» дип, дөньяда булган һәрбер ачы, әрнүле һәм агулы сүзләр белән абыстайны әрләргә тотына.
Зөләйха иренең холкын белә. Шуңа күрә бер сүз дә дәшмичә, үз эше юлында, бөтен дөнья залимнәренә башы уйлап җитә алмаслык, зур газапларны күтәрергә хәзер булган, илаһи бер каһарман кыяфәте белән, күзләрен мөтәкәббиранә бер ноктага терәп, йөзләре агара төшкән хәлдә, озын буен тагы да күтәреп, шкафка яны белән сөялгән көйдә тора бирә, авыз ачып, яңлыш та бер сүз әйтми. Ул иренә каршы эчендә, тик йөрәгенең яшерен бер җирендә куәтле бер кибер[2] саклый. Теле, гакылы белән тәгъбир итеп җиткерә алмаса да, эчке бер сизенү белән, ире Җәләлне хаксыз рәвештә үзенә гомер буенча хуҗалык итмәктә булган бер залим, бер җәббар[3] кебек тоя; шул аңа авыр минутларда үз идеясе юлында явыз куллар тарафыннан газап кыйлынмакта улган шәһитләрнекенә охшаш бер җуаныч, бер ләззәт бирә; Мәсьәлә үз балалары хакында булса, бу җуаныч аңа бигрәк арта. Шунлыктан иренең бу ачы тиргәүләре аңа газап катыш бер сәгадәт кебек тоелалар.
Көннәр, төннәр, айлар, атналар үтте. Хәзрәт һаман үзенең карасына көеп йөри. Һаман юк-бар сәбәпләр белән дөнья туздырып сүгенә. Зөләйха абыстай иренең ырылдавына күп кайгырмаса да, Сабирдан һаман хат юклыгы аны артык борчый. Ул аз сөйли, аз көлә. Үзе байтак ябыга да төште. Көндезләр тагы бер хәл. Әмма озын, караңгы төннәрне үткәрү аңа бик авыр була. Ул һәр көн угылыннан хат көтә. Булмагач, төн буенча аның язмышы хакында уйлап чыгып, әллә нинди авыр, куркыныч хыялларга чума. Соң кайда булыр ул? Кая китәр, ни эшләп йөрер? Караклык-фәләнлек кебек алама эшләргә китү ихтималы, әлбәттә, юк. Буламы соң? Зөләйханың угылы шундый эшкә катышамы? Мөхаль[4], мең мәртәбә мөхаль!
Сабир хакында озын колактан ишетелгән бер хәбәр бар. Гүя көзнең караңгы

[1] *Изтыйраб* – борчылу, әрнү.
[2] *Кибер* - горурлык
[3] *Җәббар* – деспот, җәберләүче, изүче.
[4] *Мөхаль* – булмый торган, мөмкин булмаган хәл.

төнендә мәдрәсә урамының бер чатында, зур кара кимәгә[1] зур өч ат җигеп, кемдер көтеп торган була. Сабир, мәдрәсәдән бер әйберен дә алмыйча чыгып, як-ягына каранып, теге кара көймәгә килгән дә тиз генә менгән. Атлар кузгалган. Шуның белән вәссәлам. Шул юктан юк та юк... Ичмаса, исәнлегеннән бер хәбәр генә язса ни булыр иде, балам...

Бу ноктада абыстай артык йомшара да, тыела алмыйча, елап җибәрә. Ләкин хыял туктамый, аңа күз яше арасыннан караңгы төннәр, зур кара көймәгә җигелгән зур кара атлар, Сабирнын, аның гакыллы угылы Сабирнын, шул көймәгә курыкмыйча утырып, әллә нинди караңгы, билгесез дөньяга кереп китеп югалулары берәм-берәм күз алдына килә...

Ул шуннан соң ни булырын дә ачык итеп уйлый алмый. Соң ул кара көймә аны кая алып китәр? Нигә алып китәр?.. Моны Алла гына белсен. Бигрәк гаҗәбе – Зөләйха абыстайның гакыллы угылы Сабир ни эшләп андый куркыныч юлларга керә?..

Зөләйха абыстай бу елларда әллә нинди бер халык була башлавын, шуларның әллә нинди зур фетнәләр чыгаруларын ишеткәләгән иде. Сабирның китеше дә дөньяда борыннан һичбер адәм ишетмәгән, артык мөстәсна[2] вә артык гаҗәп бер эш булганга, ул яшьлек белән шул «әллә нинди» халыкка иярмәдеме, шул куәтле дулкын аны да тартмадымы, дип уйлап та куя. Ләкин бу хакта бертөрле дә хәбәре булмаганга, хыялы белән дә бер ачык нәрсә күрә алмый – шулай итеп, тик авыр изтыйраблар[3], йокысыз төннәр белән газап чигә иде.

Җәләл мулланың исә теге халыкта да, фетнәләрдә дә кайгысы юк. Ул теге кара көймә хәбәренә дә ышанмый. Аны халык алдында тышкы ялтырау илә мактану урынында сөйләштерсә дә, эченнән аңа бертөрле дә илтифат итми иде. Теләсә, кара көймә алып китсен теләсә, кызыл көймә белән качсын – аңа боларның әһәмияте дә, кирәге дә юк. Аның хәзер нихәлдә булуы да хәзрәтне кайгыртмый. Ул теләсә зинданда булсын, теләсә ач йөрсен – боларның бере дә мөһим түгел. Сабир мәдрәсәне ташлаган, остазлар кашында абруен югалтып, теге хәят юлында кәгъбә итеп тотарга тиеш булган ахунлык вә мөдәррислек кебек мәртәбәгә ирештерә торган мөкаддәс юлдан тәмам чыккан – менә Җәләл хәзрәт өчен мәсьәләнең бөтен дәһшәте, барлык һәлакәте шунда, шул ноктада!

Зөләйха абыстайның бу изтыйрабы, Җәләш мулланың бу, тиресенә сыя алмый йөргән ачулары байтак дәвам итте. Тик ул авыр хәбәр ирешкән көннән ике ел үтеп, дөньялар басыла башлагач кына, анлар Сабирның «...» шәһәрендә икәнен

---

[1] *Кимә* – экипаж (дүрт тәгәрмәчле, рессорларга утыртылган ябык арба)

[2] *Мөстәсна* – гадәттән тыш.

[3] *Изтыйраб* - борчылу

белеп, бераз тәэсирләрен үзгәрттеләр. Аңардан исәнлеге хакында кыска гына бер мәктүб тә бар иде. Ләкин теге көннәр, теге ике ел хакында һичбер сүз язмавы йорттагыларның барын да аптыратты.

Җәләл угылына кул селеккән иде. Үзе хат язмады. Хәтта сәлам әйтергә дә кушмый иде. Зөләйха абыстай исә, аның адресын белгән көннән башлап, атна саен диярлек, баштан-аяк ялынулар, күз яшьләре, сагыну тойгылары белән тулган озын-озын мәктүбләр күндерә башлады. Ләкин Сабир һаман да кыска яза, һаман да теге хакта авыз да ачмый иде.

Җәләл буңа илтифатын белдермәсә дә, бу сөкүт[1] ана йөрәге өчен әүвәлге «караңгы дөньяга кереп югалу» изтыйрабыннан да авыр, аннан да газаплырак иде. Бу бәлки авыр бер нәтиҗәгә алып барыр иде, тик шул көзне Сабирның бер җирдә тәгълим[2] эшенә тотынуын һәм язга авылына кайту хәбәрен ишетү белән генә, ул-бу булмый калды. Зөләйха абыстайның да йөрәге урынына утыра башлады.

Сабир, тирә-яктагы әйберләргә үз күзе илә карый ала башларлык яшькә кергәннән бирле, атасына җылылык, якынлык хис итми иде. Ул гомумән табигате белән артык назик, артык ялкынлы хиссияткә таныш түгел. Ул гакыл, салкын мөхакәмә[3] колы, шуларның күргәзүенчә бара. Ул адәмнәрнең язмышын тәгъйиндә кабилиятсез үк түгел. Анасын да, атасын да, араларындагы мөгамәлә вә мөнәсәбәтне дә яхшы аңлый. Ул анасының бөтен голү җәнабе[4], бөтен бай табигатьлелеге илә бәрабәр, Җәләл мулланың тимер куллары эченә аяусыз рәвештә кысылып, гомере буенча газап чикмәктә икәнен, өстәвенә үзе буны ачы вә үткер бер хәлдә хис кыйлып, дөньядан яшерергә, белдермәскә, эчке ыңгырашуларын кешегә ишеттермәскә бар көче илә тырышмакта идекен бик ачык күрә, һәм шул аңа хәссас[5] һәм бөек җанлы анасының хәятын башыннан аяк трагедия, артык авыр трагедияләр белән генә тулы кебек күрсәтә; менә шул хәлләр аның йөрәгендә анасына каршы үтә ялкынлы бер кызгану тойгысы уятмаса да, аның гакылы... салкын, ләкин ачык һәм якты мөхакәмәсе һәрхәлдә анасының сүзләрен илтифатсыз калдырмауны вөҗдани бер бурыч дип таныта иде.

Атасының караңгы торачагын белгән хәлдә, анасының күз яшьләрен игътибарга алып, аз көнгә булса да, өйгә кайтып китүне тиеш таптырган нәрсә – иштә, анага булган шул мөнәсәбәт иде.

---

[1] *Сөкүт* – эндәшмәү, җавап бирмәү.
[2] *Тәгълим* – белем алу, уку.
[3] *Мөхкамә* - фикерләү
[4] *Голу җәнабе* – бөек җанлы.
[5] Хәссас – сизгер күңелле

Ул өендә күп тормады. Теге көннәр хакында ачык бернәрсә сөйләмәгән кебек, алда ни эшләячәге тугрысында да билгеле бернәрсә әйтмәде. Атасы салкын иде, шулай да куып чыгармады. Ләкин аңардан мәңгегә кул селеккәнен ачык аңлата иде: чөнки бу Сабирда Җәләлнең көткәне, булачак мөдәррисенең исе дә калмаган иде.

Ана исә һаман ана, бәлки әүвәлгедән якынрак, әүвәлгедән дә мәхәббәтлерәк иде. Тик аны Сабирның үз хәяты хакында ачык бәян бирмәве генә борчый иде. Ләкин ни эшләмәк кирәк: бер хикмәте бардыр, вакыты белән бар да беленер әле...

Бу ике ел Сабирның хәятында, бигрәк тә хәятка карашларында байтак үзгәрешләр ясаган иде. Борын фикердәш булган иптәшләре хәзер аны ничек тә аңлый алмыйлар: ул элгәре, уку кирәк, рәсми мәктәпләр кирәк, заманның мәдәниятен танып, һәрхәлдә шуңа сыгынырга, үзеңнең тормышыңны шуңа корырга кирәк, дип йөри, үзе һәм шуларга тырышкан кебек күренә иде. Хәзер боларга бик салкын карый. Әгәр дә бу хакта сүз чыгып, иптәшләре аңардан: «Мәктәпкә хәзерләнүне ни өчен ташладың?» – дип сорасалар, ул, әүвәл йөзен салкынайтып, кулларын селкә дә бер-ике сүз белән фикерен бәян кыйла:

– Мин, – ди, – ул зәһәрдән котыла алдым инде. Нинди генә булса да укулар, анларның тудырган нәтиҗәләре һәм дә авыз суы корытып макталынган мәдәни тормышлар, шәһәрнең баштанаяк мода вә бизәк эченә чумган мөтәкалләф хәятлары[1], бигрәк тә боларның һәрбер адәмнең эчке хәятына, җан вә күңел рәхәтенә мөнәсәбәтләре-фәләннәре кебек хәлләре бармы – мин боларның һәммәсен дә үтә күрерлек, үземә бирәчәкләрен аерырлык мәртәбәдә генә үстем инде... Шуңа күрә бере дә тартмый, бере дә җылылык бирми, – ди.

Ләкин үзе әле һаман шәһәрнең мәдәни тормышында яши иде. Моның сәбәбен сорагач: «Тагы бераз сыныйм әле, эстәгәнем табылмасмы дип бераз эзлим әле...» – дип җавап бирә иде. Һәм берничә еллар шуны эзләп, төрле урыннарда мөгаллимлекләр итте, мәдрәсә кисәкләрендә мөдирлек сыйфаты илә дә яшәде; дәхи зур гына байларда контор вә сату эшләре белән дә чуалып карады. Ләкин берсе дә аны канәгатьләндермәде, үз тәгъбиренчә, ул һичкайда үзенә ярашлы, табигатенә килешле тормыш таба алмады.

Кешенең җан вә табигате илә тормышы арасында ачыктан-ачык тәзад[2] булса, ирекле йөрәк аны күтәрә алмый. Сабир да шуңа якын бер нәрсә тоя иде.

Кайда гына җирләшсә дә, үзе дигәнне тәмамынча кыйла алмый. Планнарының да берничәсе муаффәкыятьсыз чыкты. Аннан да бигрәк, кая гына барсаң, нинди

[1] *Мөтәкалләф хәят* – зур расходлы тормыш.
[2] *Тәзад* – каршылык.

генә эшне алсаң да, әллә кемнәргә баш ияргә, муаффәкыять табу өчен бик күп түбәнчелекләр күтәрергә мәҗбүр булына... Һәр адымда диярлек сатылырга да, нифак[1] сатарга да кирәк... Әлла нинди фәлсәфи вә әхлакый ноктадан карап түгел, тик үзенең табигате, хилкате[2] белән үк Сабир боларның берен дә булдыра алмый... Яратмый гына түгел, булдыра алмый; болар аңа авыр бер тәклиф[3], зур мәшәкать кебек тоелалар. Дәхи мәдәни тормышның иге-чиге булмаган тәклифатын[4], адәмнең җаны, рәхәте өчен авыр йөктән башка файдасы тимәгән хисапсыз модаларын, гадәтләрен, тар рамкаларын күтәрергә, шуларны ригая итәргә[5] дә ул үзендә, бердән – чыдам, икенчедән кабилият[6] үк тапмый.

Болар ана һичбер хәлдә үзең өчен файдасы булмаган һәм булмаячак мәшәкатьләр, хәтта газаплар булып күренәләр. Шуңа күрә дә ул мәдәни тормыштан, каланың баштанаяк зиннәт вә мода эченә күмелгән ялтыравыклы хәятыннан гомергә кул селкеп, ничек кенә булса да, үз табигатенә ягышлы бер дөнья табарга тәбган[7] мәҗбүрият хис итеп, моның өчен дә тын, караңгы авылга китеп югалырга карар бирде. Бу карарга килүе хакында ул гомуми булган байтак нәзарияләр[8] сөйләсә, дәлилләр китерсә дә, аның төп сере – Сабирның табигате белән мохитында һәм кичергән гомерендә иде.

Ул үзенең бу карарын белдергәч, Җәләл мулланың хәйрәте[9] һәм ачуы чигеннән, чамасыннан бөтенләй үк чыгып китте. Хәзрәт, Сабирның югалып йөрүләренә, соңгы еллардагы хәрәкәтенә начар караса да, ахыргы елларда мөгаллим-фәлән булып, мәктәп, мәдрәсә тирәсендә әйләнә башлагач, аның рухында тагы бераз өмит кузгалган иде. Ул, суга батып барганда саламга тотынучы кебек, угылына бераз өмит илә карап: «Кем белә, бәлки тагы рәтләнер... Әүвәлгесе яшьлек җүләрлеге генә булса, әллә яңадан гакылга утырыр да, атасы угылы булыр-фәлән», – дип уйлый башлаган иде.

Сабирның соңгы карары исә бу өмитләрне бөтенләй җимереп ташлады. Мулла бертөрле дә аңлый алмый; имеш, мөдәррислеккә, ахунлыкка якынаеп барганда, шул мәртәбәне ташлап, әллә нинди мәгънәсез юлларга кереп китүе генә җитмәгән кебек, инде тагы авылга кайтып, еллыгы егерме сум торган ялчылар белән беррәттән сабан сөреп йөрсен!.. Бу ни эш... бу ни хурлык?.. Адәм

---

[1] *Нифак* – икейөзлелек.
[2] *Хилкать* – яратылыш.
[3] *Тәклиф* – көчләп кушу.
[4] *Тәклифат* – көчләүләр.
[5] *Ригая итү* – кайгырту, карау
[6] *Кабилият* - сәләтлелек
[7] *Тәбган* – табигый рәвештә.
[8] *Нәзария* – караш, фикер.
[9] *Хәйрәт* – аптырап калу

авылдан котыла алмый... ә ул шул чаклы укыганнан, йөргәннән соң тагы авыл мужигы булмакчы!.. Ул тәкъдирдә уку нигә, мәдрәсә нигә?.. Моның ояты да нинди зур. Дошманнарның барлыгы: «Җәләл мулла угылларын мактап, шапырынып йөргән булган иде... Ничә ел йөреп, адәм рәтле урынга да керә алмадылар...» – дип көләчәк.

Сабирның карары Җәләл хәзрәткә бер адәмнең: «Мин падишаһ булмыйм, мин көтүчелекне яратам... Мин, тәхеттән төшеп, озын чыбыркы белән сыер көтәргә китәм!» – дигәненә охшап күренә. Ул бу хактагы хәйрәтен, ачуын тәгъбир итәргә сүз тапмый... Аптырагач, тагы эттән алып, эткә салып сүгәргә керешә. Гамәли бер нәтиҗә итеп ошбу карарга килә дә угылына шуны белдерергә куша:

– Крәстиән булмагае, кадалып китсен... Мин укыттым... Егермегәчә тәрбияләдем... Ахырдан миңа үпкәләмәс... Мин аны, балам булмагае, Аллам булса да, үз ирегем белән авылга кайтарып, үз күз алдымда чабаталы крәстиән-мужик булып йөргәнен күрер хәлем юк... Кайтмасын... күземә күренмәсен! – ди.

Сабирның буңа исе китми. Ул, мәүкут[1] уларак хәзерге эшләрен дәвам иттереп, бераз акча ясарга да, атасы белән килешә алмаса, башка урыннан җир алып, авыл тормышына чумарга уйлый. Бу мәсьәләләр хакында аның энесе белән дә бераз моназарасы булды. Зыя авылга кайтып мужик булуга, әлбәттә, атасы күзе белән карамый. Авылны ул үзе дә ярата. Җәй көннәре аны шәһәрдән күп алда күрә. Шулай да агасының фикеренә кушыла алмый:

– Мин, – ди, – синең крәстиән булуыңа әсасән[2] каршы бармыйм. Үзең теләгәч, булды. Артык бернәрсә дә кирәкми. Ләкин мәсьәләнең шул ягы бар: син гыйлемле вә мәдәниятле тормышның зәһәре белән бер мәртәбә агулангансың. Син бу зәһәрне чыгарып бетерә алмазсың... Дөрест, башта берничә елга ару да, рәхәт тә булыр. Аннан сон син авылдан туеп, тагы мәдәни тормышка таба омтыла башларсың... Шәһәрнең шул тәзйинаты[3], шул шау-шулы театрлары, шул матур музыкалы опералары, концертлары, шул бай көтебханәләре – кыскасы, мәдәнияте сине тагы тартыр, син тагы болар ны сагына башларсың... Бервакыт сиңа корган ояңны бозып, бик күп уңгайсызлыклар чыгарырга яисә гомер буенча шул «тын, караңгы авыл»ыңнан бизеп, мужиклыгыңа нәфрәт чигеп, газапланырга тугры килер. Менә мин шуны уйлап, синең ул фикереңне мактап бетә алмыйм... – ди.

Ләкин Сабир үз сүзендә дәвам итә:

---

[1] *Мәүкут* – вакытлы.
[2] *Әсасән* – нигездә.
[3] *Тәзйинат* – зиннәтлелек.

– Юк, туган, – ди, – ул мәгънәдәге мәдәниятеңездән дә, театр вә музыкаларыңыздан да туйдым... Гыйлем хәзинәсе булган көтебханәләреңезгә дә ихтирамым бик аз; мәдәниятнең бирдеке башка бик күп “сәгадәтләре”нең дә һичберен сагынырмын дип уйлый алмыйм. Барыннан туйдым, барыннан биздем. Мин сүзем, гакылым белән генә түгел, үземнең инстинктым белән үк авыл ягына карыйм. Дөрест, синең санаган нәрсәләреңнең анда бере дә булмас, ләкин минем җанымның теләгәне булыр. Анда булыр минем үземнең бер колач кына булса да җирем, булыр үземнең сукам, үземнең атым. Мин үземнең таза кулларым белән, үз сукама үз атымны җигеп, үз җиремне сөрермен дә, үз орлыгымны чәчеп, үземә генә караган икмәк җитештерермен. Бәлки бай булмам, ләкин ачка да үлмәм дим. Мин ул тормышны табигатем белән яратам. Дөрест, минем тормышым түбән, тупас һәм простой булыр. Тирә-ягымны да тышлары бик артык ялтырамый торган чабаталы адәмнәр – мужиклар чорнар. Ләкин шулар илә бәрабәр минем үз малым, үз дөньям булыр. Минем алдар хыялым тараер. Мин үз эшемне эшләп, үземә һәм үземнең ирегемә үзем хуҗа булырмын. Азат булырмын. Миңа шул җитә дә.

Хәзрәт, угылының шул карарында һич кайтмаслык мәртәбәдә сәбат[1] иткәнен күргәч, сүздән дә, сүгенүдән дә арып, Сабирга кул селкә дә бөтен өмитен, барлык хыялларын икенче угылына баглый...

8

Зыя үзенең агасы Сабир кебек мөмтаз[2] куәтле бер адәм түгел. Ул бервакытта да яшерен бер усаллык белән тирә-ягындагыларны куркыта да, җиңә дә, буйсындыра да алмый. Ул, агасы шикелле, үзенең тоткан юлында таш яуса да барырга, тукталмаска тырышып, бетен мохиткa каршы ачыктан-ачык көрәшүне дә сөйми.

Сабир бөтен табигате белән ир, чын мәгънәсе белән ирлекле булса, Зыяның йөрәгендә, җан вә яратылышында анасы Зөләйхадан, – гомумән хатынлыктан бераз өлеш бар кебек. Аның төсе, буе, кыяфәте дә шуны белдереп тора.

Ул, анасына тартымрак булып, озынрак буйлы, нечкәрәк гәүдәле; бөтен әгъзаларында хатыннарга махсус назиклек сизелә; аның таррак һәм озынчарак, аксыл-алсу йөзе һәрвакыт һәркемгә йомшаклык вә якынлык теләгән кебек күренә; төз вә нечкә каш астындагы күк төсле күзләре бөтен дөньяга көлеп, яратып карыйлар.

Шул сыйфатлары сәбәпле гомерендә бер генә очраган адәмнәр дә аны илтифатсыз үтә алмыйлар, назик вә хәссас адәмнәрнең хәтерендә аның бер

---

[1] *Сәбат* – ныклык, үз сүзендә торучанлык.
[2] *Мөмтаз* – башкалардан аерылып торган.

очрашудан гына алынган сурәте дә бик озакка кала. Кыяфәтеннән аңлашылган шул йомшаклык, шул мөлаемәт аның һәрбер сүзендә, мөгамәләсендә дә бар. Ул назик хәтерле, бик аз нәрсәләргә дә кәефе китә. Ләкин бу кәеф китүчелек эчке вә самими бер үпкәдән гыйбарәт булып, һичбер тәкъдирдә дөнья җимереп үч алырлык мәртәбәдә дошманлыкка җитә алмый. Ул, кызурак табигатьле булса да, бервакытта да усал вә агулы сүзләр белән сүгешми. Кешегә каты йөз бирү, салкын мөгамәлә күрсәтү дә аның табигатенә хилаф. Аның бу сыйфатларын башка һәркемнән бигрәк Зөләйха абыстай белә, – юк, белә түгел, эче вә йөрәге белән сизә; һәм шуның өчен дә ул, һәммә балаларын Тәңренең үз кулы аркылы җанына салынган илаһи бер мәхәббәт белән сөйсә дә, икенче угылы Зыяга үз йөрәгендә башкалардан артык бер якынлык, берлек – җан берлеге тоя.

Бер Зөләйха абыстай гына түгел, гомумән хатын-кыз аның алдында үзләрен рәхәт, шат хис кыйлалар. Сабир ирлеге, куәте белән ирләр алдында тәкъдир ителсә дә, хатыннар аңардан бераз шикләнәләр, эчке бер тартынуларын сизенәләр. Әмма Зыяда алай түгел. Агасы Сабирдан качкан хатыннарның да күбе аңардан качмый. Аны гүя үзләре, якыннары кебек тоялар. Халык та аңа яхшы күз белән карый. Гомумән аны яраталар, аңа якынлык хис итәләр, аны һәр җирдә нәмунә[1] булырлык бер егет кебек тоталар.

Бу шулай.

Ләкин бер, тик бер генә нәрсә, Зыянын баштанаяк яратылып, пакь фәрештәдәй, мәгъсум[2] тотылып килгәч нурлы хәяты өстендә кара тап булып тора. Шул тап аны каралый, шул, тик шул телгә алынган тәкъдирдә күп күңелләрне хәйрәткә төшерә[3], бигрәк артык пакь булганнарның күңеленә салкын йөгертә.

Бу да – аның тумышыннан ук ибтиля[4] мәртәбәсендә музыкага бәйләнеше!

## 9

Якын бер иптәше Зыяны «музыка тилесе» дип атый; аның бу гыйшкын төбе белән аңлаган, кадими бер хәлфә исә һәрвакыт: «Егетләр, менә Зыя белән музыка арасында нинди нисбәт?., нинди галәка?[5].. Минемчә, бу икесе мөтәлязиман[6] булып, арадагы галәка дә галәкаи ләзүм[7] булырга кирәк!» – дип көлә иде.

Һәм вакыйгда да шуңа охшаш бер хәл бар иде. Бу аңарда бала чагыннан ук

---

[1] *Нәмунә* – үрнәк.
[2] *Мәгъсум* – пакь, гөнаһсыз.
[3] *Хәйрәткә төшерә* – гаҗәпләндерә.
[4] *Ибтиля* – авыру дәрәҗәсендә артык бирелү.
[5] *Галәка* – бәйләнеш.
[6] *Мөтәлязиман* – берсе икенчесенә кирәкле булган, аерылмас ике әйбер.
[7] *Галәкаи ләзүм* – табигый, мәҗбүри бәйләнеш.

сизелә башлады. Аның алты яшьлек чагы булыр. Бервакыт аталары каядыр китте дә, ул анасының куенында йоклады. Төндә бер заман анасы, уянып, тирә-ягын капшап караса, янында угылы юк:

– Чү, бу ни эш?.. Зыя, син кая?..

Зөләйха абыстай бер дәшә, ике дәшә, – һаман җавап юк. Соң кая булыр ул мондый караңгы төндә?!

Тагы катырак тавыш белән кычкырган иде, урам буендагы тәрәзә яныннан Зыяның җавабы да ишетелде. Анасы аптырый калды:

– Ни кирәк, Зыя, нәрсә эзлисең анда?

Бала әллә нинди ят вә тирәннән килгән кебек тавыш белән җавап бирә:

– Юк, бернәрсә дә эзләмим... болай гына..,

– Су кирәкме әллә?

– Юк.

Бала үзенең ничөн, торып, анда барганын әйтеп җиткерә алмады, һәм ул үзе буны ачык тәгъйин[1] дә итә алмый иде, ләкин анын сәбәбе шунда иде: хәзер никрутлар заманы... шулар гармун уйнап йөриләр... Моң, музыка тирән йокыга бирелгән тын авыл өстендә бәйрәм итә... Бала исә йокы арасында шуны ишеткән дә, үзе сизмичә үк, урыныннан торып, урам як тәрәзә яңагына килеп сөялгән...

Яше зурая барган саен, җан вә табигатенең, тәкямеленә мөтәнасиб[2] рәвештә анын бу мәйле, бу хәлкый[3] һәвәсе дә куәтләнә барды.

Җиде яшендә аны күрше авылга мәктәпкә илттеләр.

Мәктәп тормышы башта аңа бик авыр кебек иде. Анда тыгыз да, тузан, пычрак та, иртә белән җуынырга да кар кебек салкын су гына була. Шуңа күрә ул, чынлап авырып та, ясамадан авырулар чыгарып та, еш-еш өйгә кайта иде. Кем белә, бу «мәктәптән качу» бәлки озак ук дәвам итәр, ул бәлки Зыяда руханый бер начарлык та тудырыр иде; ләкин бер хәл аңа шул ямьсез күренгән мәктәп тормышын матур итеп җибәрде. Гыйнвар числалары булса кирәк. Мәктәпнең хуҗасы Зариф мулла үзенең шәкерт вә хәлфә булып торган шәһәрендәге банларга кунакка, бигрәк тә зәкят[4] алырга китте. Мәктәптә башка зур хәлфә юк иде, барлык ирек зуррак шәкертләр кулында калды.

Борын хәзрәтнең кысынкы кагыйдәләре эчендә яшәгән шәкертләр, ул китү белән, берәүнең тәгъбиренчә, бәйләүдән ычкынган этләр кебек, дулый, тилерә,

---

[1] *Тәгъйин итү* – билгеләү.

[2] *Тәкямеленә мөтәнасиб* – үсешенә ярашлы, пропорциональ.

[3] *Хәлкый* – табигый, тумыштан килгән.

[4] *Зәкят* – ислам дине буенча сәүдәгәрләргә еллык кеременең кырыктан бере күләмендә салынган еллык налог.

башларына килгән һәрбер эшләрне кыйла башладылар. Мәктәп бөтенләй җанланды. Бик күп кызыклар, уеннар корыла башлады.

Зыя өчен артык мөмтаз булган яңалыклардан бере, бәлки беренчесе, һәр көн кич була торган җырлашулар, курай, кубыз, кайбер вакыт гармун белән музыка тартулар иде.

Бундый кичәләр башлангач, ул үз хәятында әллә нинди бер байлык, моңарчы татылмаган рәхәтлек булгандай тоя башлады.

Менә кич килә. Ишекләр бикләнә. Тәрәзәләргә һичбер нәрсә күренмәслек итеп юрганнар, киезләр корыла да, Зыяның зур бер бәхет кебек көткән музыка тавышы мәктәптә хөкем сөрергә тотына; ул биюне яратмый, такмаклар да аңа бер дә ошамый. Әмма, әмма дөнья туздырып, котырып йөргән маланларны да җиңеп, туктатып, тирә-якны үзенең моңлы сөкүнәтенә чумдырган озын көйләр башланса, ул дөньясын оныта, үзен югалта да, кечек хыялы эшли алган әллә нинди әкият галәмнәренә кереп китә.

Үлә бала. Ул башка вакытларда тере генә, сүзчән генә. Әмма музыка башланса, ул уйнаучының күзенә күзен тегәп, яңагына таяна да һичбер кузгалмый, катып кала; сүзе дә, терелеге дә югала; яисә бөтен халыкның артына, караңгы бер почмакка сөялеп, музыканың лэтафэтенә[1] бата.

Ул бик яшь әле. Шунлыктан бу эшләрнең һичбере аның иреге вә гакылының теләве белән түгел, бәлки табигатенең сөрешеннән генә туа. Шулай ук ул мохитның музыка хакында гасырлардан бирле саклап килгән игътикадыннан[2] да нәзари[3] рәвештә хәбәре юк. Ул аның хакында «гөнаһ, ярамый, хәрам» дигән сүзләрне дә әйтә белми. Шулай да эчке бер сизенү аңа бу музыканың да, мәктәптә булган башка тилерүләр, әдәпсез уеннар, карталар, эчү вә тартулар кебек, хәзрәт булмаганда гына, бөтен дөньядан яшереп кенә эшләргә ярый торган бер нәрсә икәнен тәлкыйн итә[4]. Ләкин бу тәлкыйннең куәте аңарда булган музыка һәвәсеннән, табигый мәелдән зәгыйфьрәк. Шуңа күрә ул үзен музыкадан тыя алмый. Күңелендә андый бер ният тә юк.

Менә шул вакыйга аны мәктәпнең барлык авырлыгына күндерде; ул инде, әлбәттә, кайтырга тиеш булган атна кичләрдә дә кайтмый башлады. Кайтса да, анда әллә нинди кыйммәт бер нәрсәсе калган кебек, тизрәк мәктәпкә китәргә ашкына иде.

## 10

Зыяда булган бу табигый мәел аның хәятында «музыка бәласе» дип аталырга

---

[1] *Ләтафәт* – матурлык, гүзәллек, күңеллелек.
[2] *Игътикад* – ышаныч.
[3] *Нәзари* – теоретик.
[4] *Тәлкыйн итү* – күңелгә салу.

тиеш булган бик күп кыенлыклар да тудырды.

Ул Зариф мулла китү сәбәпле азатлык бирелгән көннәрдә бик аз гына кубыз да өйрәнә башлаган иде. Иптәшләреннән кайберләре: «Сиңа иртәрәк әле!» – дип көләләр, музыка белгәннәре исә: «Кара монауны! үзе бармак буе гына булса да, куллары бик җиңел килә...» – дип хәйран калалар иде.

Ул, кубызларның дөньядан яшереп кенә уйналырга тиеш әйбер икәнен сиздегеннән, әлбәттә, оят килерлек җирдә үз кубызын уйнамый да, күрсәтми дә, әмма аз гына җае, уңгае чыкса, хәзер, яшеренгән коралны алып сыза башлый иде. Бу эше өчен аңа байтак таяклар ашарга, халык тарафыннан мыскыл ителергә дә тугры килгәләде.

Ул, мәктәптән кайткач, ындырдагы кибәннәр арасына качып, яисә кешегә күренмичә генә, мунчага бикләнеп, кубызын тарта башлый. Башта, кеше ишетә күрмәсен дип, әлбәттә, бик акрын гына уйный. Ләкин бара-бара, музыкасына бирелеп, үз хәлен онытa да, үзе сизмичә үк, бар куәтенә сыздырырга тотынган була.

Бу тавышны башлап анасы ишетсә, тагы бер хәл. Ул, тыштан бик каты ачуланган кебек: «Күрмим икенче шул эшеңне!.. Атаңа әйтеп, тиреңне тунаттырырмын!» – дип орышса да, эченнән баласын кызганганлыгы, һәрвакыт очрый башлаган шул аламалыктан үзенең мәхдүм угылын ничек тыярга икән дип аптыраганлыгы һәм сүзеннән, һәм йөзеннән ачык күренеп тора. Шуңа күрә артык авыр да булмый, әмма, әмма атасы ишетсә, бер Ходай үзе генә сакласын, – ул сак кына мунчага килеп керә дә, иң әүвәл яңаклап, тибеп ега, аннан соң колагыннан өстерәп өйгә китерә дә, анасы, туганнары алдында:

– Икенче андый эшкә катышма! Катышма! Катышма! – дип, эт урынына кыйнап ташлый.

Кайбер вакыт аның кесәсеннән кубызын малайлар эләктерәләр дә, әллә нәрсә тапкан кебек: – Караңыз, егетләр... караңыз... Зыя, мәхдүм башы белән, кубыз уйнап йөри икән! – дип мәсхәрәгә калдыралар.

Зыя мохит белән ачыктан-ачык көрәшә алмый. Шунлыктан бундый дәресләр аның хәтерендә бик озаккача сакланып, ул кубызын һичкем тапмаслык җиргә яшереп куя. Ләкин мәңгегә тыела алмый, мәсхәрә онытыла, атасыннан ашаган таякларның калдырган авыртулары бетә башлый. Шуннан соң ул тагы, бик сакланып, бик яшеренеп кенә, гомерлек дустының янына бара.

11

Авыл җирендә җәй көне малайлар, егетләр ат белән ерак тугайга куна йөриләр. Монда, авылның барлык шаяннары, үткер вә уенчак егетләре белән бергә, иң мөмтаз талантлары – шәп җырчы вә атаклы музыкантлары да җыела. Егетләр,

көн буена каты эштә йөреп арыганлыкларына карамыйча, бунда ярты төннәр узганчы җырлашалар, гармун уйныйлар, бииләр.

Зыя буны бик яшьтән үк белә, анда булган маланларның иртән кайткач, шәп җырчыларга, шәп гармунчыларга исе китеп сөйләүләрен ул әллә кайчаннан ук эчке бер кызыгу белән тыңлый да иде. Ләкин үзе шунда барырга ата-аналарыннан сорау түгел, аны уена да китерә алмый иде. Чөнки анда җыен азгыннар, тәүфыйксызлар җыелып, гел эштән чыккан адәмнәргә генә ярый торган эшләр эшлиләр – гармун кычкыртамы, бииме, җырлашамы... тагы шундый җыен ярамаган нәрсәләр.

Мондый бер җиргә баруны сорау түгел, авызга да алу куркыныч. Ул бит мужик малае түгел, ул – мәхдүм, ул – шәкерт. Аңа андый азгыннар җыенына бару, әлбәттә, әлбәттә, килешми.

Ләкин көтелмәгән бер эш аның ярдәменә җитеште.

Бер җәйне анларның карт ялчылары эш өстендә бик каты авырый башлады. Кызу урак чагы; ашлык коелып бара. Һәр көн хатын-кызны көнлеккә чыгарырга кирәк. Ә анларны уракка алып бару өчен атлар кирәк. Ялчы йөри алмый. Инде ни эшләргә? Беркөн уракка җигеп барачак атларны Сафа карт малаена куна алып барырга биреп җибәрелгән иде. Ул начар тышаулаган да, атлар, төн буенча китеп, әллә кая игенгә барып тотылганнар. Анларны эзләп тапканчы, өйлә җитеп калды. Ә монда яллаган көнлекчеләр төшкәчә, ат көтеп, өйдә яттылар. Инде ни эшләргә? Башкаларга бирсәң, тагы шундый бер эш булырга мөмкин... Менә шул мәҗбүрият Зыя өчен көтелмәгән бер бәхет ачып, аның комсыз һәм саран атасы, үзенең бөтен теләгенә каршы, мәхдүм угылын уракка җигеп барылачак атлар белән теге малайлар, егетләр арасына кунарга җибәрде.

Ләкин аның бу бәхете озак дәвам итмәде. Берничә көннән соң, базардан бер малай яллап, Зыяны куна йөрүдән туктаттылар. Ләкин берничә төннән генә гыйбарәт булган ул аз заман аның хыялында һәрвакыт сагынып искә алырлык күренешләр, күңелле хатирәләр калдырды.

Карачәле[*], ничек онытырсың, нинди матур кичәләр бит. Кояш байый. Җир өстеннән бик аз гына караңгылык күтәрелеп, һәммә нәрсәне чолгый башлый. Җәйнең аяз вә ачык күк астындагы тын, латыйф[1] вә йомшак кичәсе, бөтен дөньяны үзенең кочагына алып, табигый рәвештә иркәли. Шул вакыт төннең салкынча һавасын яшел үләннәрдән, һәртөрле чәчәкләрдән күтәрелгән тәмле исләре белән тутырып, чиксез рәвештә җәелеп киткән зур тугайга малайлар белән егетләр җыела. Болар бар да көндезгедән җанлы да, дәртлерәк тә кебек

---

[*] *Карачәле* – карачы әле.
[1] *Латыйф* – матур.

тоелалар. Анлар ачык күк астына табын булып утырышалар да, җырларга, музыка уйнарга тотыналар. Тирә-як тын. Һәммә нәрсә гүя шул музыканың тавышы алдында сәҗдә иткән бер кыяфәт илән мөлаеманә сөкүт итә[1].

Бу вакыт Зыя, үзен бөтенләй онытып, башка һичбер заманда булмаган хыялый, серри[2], әллә нинди йомшак бер ләззәт эченә чумып китә.

Шул хәлдә төн үтсен, таң беленеп, кайтыр вакыткача уен дәвам итсен – ул урыныннан кузгалмаячак һәм, йоклый алмадым бит дип, бик аз гына да хәтеренә китермәячәк: йокылар, ашлар аның каршында музыка өчен мең мәртәбә корбан ителергә ярый.

Туганыннан башлап, аны тик бер генә мәртәбә ирешкән бу зур сәгадәттән аталары мәхрүм кыйлган сәгать – аның өчен чыннан да тәмсез бер сәгать булды. Ләкин ни эшләргә? Әллә ни кыйлып булмый иде. Данлыклы Җәләл мулла белән зур остазбнкә саналган Зөләйха абыстайның угылы Зыя мәхдүмнең андый вак эшкә, азгыннар җыенына барып йөрүе гадәткә дә сыймый. Моны мохит та күтәрми, һәрхәлдә «ата баласы»на ягыша торган эш түгел иде...

12

Ерак шәһәрнең зур мәдрәсәсенә барып кергәч, эшләр тагы да үзгәрде; әлбәттә, Зыя өчен матлуб булмаган[3] якка таба!

Бу мәдрәсә үзенең баштанаяк сәләф[4] гадәте өстенә корылган ничә йөз еллык тарихы һәм дә гасырлар буенча заман вә мохитның куәте белән үсә, зурая килгән карт тәгассыбның[5], ниһаять, тәкямелгә ирешеп[6], үзендә хаким мотлак[7] уларак патшалык кыйлуы белән бөтен дөньяга каршы мактана алырга хакы бар.

Ул үзе бер дөнья, бер патшалык. Аның үзенә махсус тарихы, үзгәрергә ярамый торган хәяты һәм бик күп остазларның, бик күп мөдәррисләрнең тырышуы аркасында дәхи дә бер мәртәбә ныгый төшкән канун вә гадәтләре бар. Ул гасырлар буенча шул гадәтләр, шул кануннар эзеннән агып бара. Анларның беренә генә карышу да зур гөнаһ. Анда һәрнәрсә бар, аның һәммә җире мөкәммәл санала. Хәтта анда кыш буена берничә мәртәбә мәдрәсәнең теге явыз казыйсы белән усал карт хәлфәне, хәйләләп булса да, берәр җиргә җибәрә алсалар, асткы катка бикләнеп, уен, көлке, чәй мәҗлесләре дә ясала. Монда җыр, әлбәттә, туктаусыз була. Биш йөз шәкертле мәдрәсә эчендә бер генә данә

[1] *Мөлаеманә сөкүт итү* – ягымлы; рәхәт тынычлыкта тору.
[2] *Серри* – серле,- яшерен.
[3] *Матлуб булмаган* – бу урында «уңайлы булмаган» мәгънәсендә.
[4] *Сәләф* – борыннан, электән килгән.
[5] *Тәгассыб* – консерватизм, кирелек, искелек.
[6] *Ниһаять тәкямелгә ирешү* – иң югары ноктасына җитү.
[7] *Хаким мотлак* – хокукы чикләнмәгән хаким.

дә гармун яки кыллы музыкалардан берен белүче булмаганга, андый нәрсә булмый, булса – кубыз да курай яисә авыз музыканы! Ләкин аңа да рәхмәт диң! Ул да булмаса, ни эшләр идең?!

Болар, бердән, бик артык сирәк, икенчедән, теге егетләрдән, теге никрутлардан ишетә килгән музыкага караганда, әллә ничә мәртәбә түбән булганга, әлбәттә, әлбәттә, Зыяны канәгатьләндерә алмый. Шулай итеп, аның эчендәге музыка дөньясы, музыкадан ләззәт алу өчен яратылган тойгылары күп елларгача, шәкерт вә мәдрәсә галәменең куәтле рамкалары эченә кысылып, әллә кайда, төптә, рухының әллә нинди эчке катлауларында бикләнеп ятырга мәҗбүр булалар.

13

Зыяның хәяты, бигрәк тә эчке дөньясында, хыялында булган вакыйгаларның тәэссераты белән бай. Аның диккате күп вакыт башындагы планнары, фараз вә хыяллары белән мәшгуль булып, тышкы вә матди дөньяда килеп кичкән, гомумичә бик кызыклы, бик шау-шулы вакыйгалар дә аның тарафыннан һичбер илтифатсыз үтә алалар.

Килә яз. Март вә апрель айлары керә. Пасха бәйрәме башлана. Шул вакыт «Югары мәйдан» дигән бер җирдә һәр елны балаганнар корыла. Мәдрәсә гадәте буенча, монда йөрүдән манигъ[1] булмаганга, шәкерт дөньясы, бары бергә кузгалып, шул мәйданга таба агыла. Анда әллә ничаклы халык җыела, әйберләр сатыла, матур марҗалар да бик күп була имеш; җен төсле булып киенгән дураклар (клоуннар), шундагы балаганнарның башына чыгып, әллә нинди, дөньяда булмаган кызыклар, тилелекләр күрсәтәләр имеш, – буны һәр көн кич шунда барып кайткан иптәшләре сөйлиләр, мактыйлар; ләкин Зыя, боларны тыңларга яратса да, кызыгып, иртәнгесен үзе дә барырга хәзерләнми иде.

Беркөн шунда барган һәммә иптәшләре зур сакаллы, тирән шадралы бер сукыр урысның шундагы балаганнар алдында бик шәп итеп гармун белән татар көйләре уйнаганын хикәя кыйлдылар. Әйтүләренә караганда, ул «Тәфтиләү», «Зиләйлүк» кебек иске көйләрне дә, хәзерге такмакларны да бик яхшы чыгара икән. Һәммәсенең аңа исе киткән: «Ул, урыс башы белән, мөселман көйләрен ничек белә икән? Әллә чукынчыкмы икән?» – дип аптырашалар.

Бу хәбәр Зыяга тәэсирсез калмады. Ул иртән торды да, һәммә шәкерт дәрес белән мәшгуль чакта, өйләгәчә барып кайтмак уе белән, ялгызы гына шунда юнәлде.

Вакыйган[2], сукыр татар көйләрен уйный икән. Болай дөрест тә, җиңел дә

[1] *Манигъ* – тоткарлык.
[2] *Вакыйган* – чыннан да.

чыгарган кебек. Ләкин Зыяга теге үз авылларында азгын, тәүфыйксыз татар егетләренең простой гармуннары белән һичкемнән өйрәнмичә уйнаган музыкалары кебек куәтле бер тәэсир бирә алмый.

Сукырны гаепләү мөмкин түгел. Аның көе нәкъ татардагыча. Уйнавы да бик шәп, бик оста күренә. Шулай да нәрсәседер җитми, ниндидер яшерен вә илаһи булган, ләкин музыканың тәэсирендә бернәрсәнең рухый мәртәбәсендә зур урын тоткан бер хасият аңарда юк кебек.

Зыя буны сизә, ләкин сәбәп вә хикмәтен бертөрле дә белә алмый.

Шулай да, юктан бар яхшы кануны буенча, ул байтак вакытлар, сукырның кулларында мотыйганә[1] елаган гармунга карап, катып торды. Зур сакаллы, бөрмә киемле урыс, зур көмеш тәресе киеменең тышкы ягындарак салынып тора, ә шул үзе иске, бабалардан калган мөселман көйләрен уйный – эче намаз әһеле белән тулган мөкаддәс мәсҗеднең мөнбәрендә, башына картуз киеп, хотә укымакта булган адәмне күрү мөэмин калебле бәндәгә нинди тәэсир бирсә, бу гармунчы да ахырдан уйнаганда Зыяда шуңа охшаш бер тойгы уята иде.

Балаганнар беткәнче, Зыя берничә мәртәбә сукыр музыкантны зыярәт итте. Ләкин, ничә генә ишетсә дә, һаман да нидер җитешми, теге яшерен хасият һаман да табылмый иде. Шул вакыйга тәэсире белән ул, тышкы дөньяга бераз ияләшеп, үзе кер юдыра[*] торган марҗаның зур угылының димләве һәм күрсәтүе буенча, шәкерт вә мәдрәсә галәменнән генә түгел, бәлки бөтен дөньядан яшеренеп, музыка хөрмәте өчен рус кинематографларына, бара-бара концертларга да йөри башлады. Ниһаять, операларга чаклы барып иреште.

Ул үзе русчадан бернәрсә дә белми. Шунлыктан бу җирләрдә куелган, күрсәтелгән нәрсәләрнең мөндәриҗәсеннән[2] бөтенләй хәбәрсез кала. Затән[3] бунын Зыяга кирәге дә юк; анда бар музыка, шул аңа җитә. Һәм йөри-йөри үзендә тәбган булган икенче бер сыйфат – матурлыктан ләззәт алу тойгысы да уяна башлый. Бу соңгы тойгы әле бик зәгыйфь. Зыяның аңардан хәбәре дә юк. Шунлыктан ул, беленгән тәкъдирдә зур авырлыклар чыгачагын һәм яшеренү өчен әллә ничаклы кыенлыклар күтәрергә, ялганнар уйларга мәҗбүр булуын игътибарга алмыйча, һәрбер форсатны ганимәт белеп[4], рус музыкасы алдында теләп баш июендә дәвам итте. Бу театруларда, бу концерт вә операларда мөселман көйләренең һичберен, әҗәлгә дару булачагы беленгән тәкъдирдә дә, ул ишетә алмый, – монда гел читләр, читләр! читләр! Боларның яхшы

---

[1] *Мотыйганә* – буйсынган, тынлаучан рәвештә.

* Авторда – “*җудыра*”

[2] *Мөндәриҗә* – эчтәлек.

[3] *Затән* – асылда.

[4] *Форсаты ганимәт белеп* – вакыттан файдаланып.

уйнаулары хакында ул, әлбәттә, шөбһә итми. Болар инде мөкәммәл дә, оста да, матур да, мөәссир[1] дә уйныйлар. Ләкин ни генә булмасын, һаман да аның теге зур тугайларда, ачык күк астында, тын төнне ярып, авыл малаеның кулында елаган гармун вә шундый тәэсир монда юк инде. Гүя анда музыка уенчының йөрәгеннән күтәрелеп, моның йөрәгенә туры ага, рухының әллә нинди эчке катлауларына үтә китә иде. Ә монда никтер ул хәтле үк түгел, никтер монда аның эчендә булган музыка кыллары сценадан килгән музыкага үз итеп җавап бирмиләр, – монда гүя эчке бернәрсә җитми, гүя монда һөнәр беләнрәк уйныйлар. Әллә юкса уйнаучы белән моның йөрәгендә булган кыллар башкамы?

14

Бу елларда Зыя мәдрәсәнең пишкадәмнәреннән[2] булган бер моназир илә бик чынлап якынлашты. Ул яман телле, усал сүзле бер егет булып, шәкерт арасында аны дәһри Садыйк дип йөртәләр иде. Ул, дәрес вә моназарада каршы килгән вә ярышырга уйлаган һәрбер иптәшен андый фараздан мәңгегә тәүбә иттерерлек мәртәбәдә изеп ташлаучылык белән мөмтаз булган өчен мәдрәсә кашында да, остазлары алдында да зур игътибарлы булса да, дошманнары һәрвакыт аның тәүфыйксызлыгыннан бәхәс итәләр, шул хакта хәбәрләр таратып, аны каралыйлар иде. Аның тәмәке тартуы бөтен мәдрәсәгә җәелгән, хәтта берничә мәртәбә мунчада тартып утырганын да күргәннәр. Эчүе, яман җирләргә йөрүе хакында да әллә нинди хикәяләр бар. Ул гына да түгел, аны «теге дөньяга» – »кызыл фонарь»ларга да йөри[3] имеш дип сөйлиләр.

Шул пишкадәм беркөнне ничектер бик ачылып китте дә бөтен дөньядан яшереп йөргән эч серен яңа дусты Зыяга сөйләп ташлады:

– Әй, иптәш, күрсәң исең китәр, анда бөтенләй, бөтенләй икенче дөнья... – дип башлап, андагы хәлләрне, ничек барып керүләрен, үзенең андагы мәхбүбәсен[4], аның белән мөгамәләләрен, аның елавын, музыкага катышып җырлауларын берәм-берәм тасвир кыйлды. Егет ул галәмне бик яратып сөйли; һәрбер сүзе аның өчен »кызыл фонарьга» йөрү җан вә табигате илә кирәксенә торган бер ихтыяҗ, бер зарурият кабиленнән икәнен белдереп тора; шуңа күрә ул галәм Садыйкның авызыннан матур сүзләр вә җазибәле[5] тәгъбирләр белән чыга иде.

Зыя ул дөньяны баштанаяк авырулар, пычраклар, гөнаһлар белән тулган бер

---

[1] *Мөәссир* – тәэсир итә торган рәвештә.
[2] *Пишкадәм* – карт шәкерт.
[3] *«теге дөньяга» – »кызыл фонарь»ларга да йөри...* – фәхешханәләргә йөрү күз алдында тотыла.
[4] *Мәхбүбә* – сөйгән кыз, сөяркә.
[5] *Җазибәле* – мавыктыргыч, соклангыч.

җәһәннәм сыйфатында хыяллап йөргәнгә, элгәре ул аңа аяк басудан җаны-тәне белән чиркана иде. Ләкин иптәше аның хыялындагы күренешне берьюлы үзгәртеп җибәрде. Бу үзгәреш аның күңелендә шул галәмгә якынлык һәм мәел тудырып, ул берничә көннән соң, тугры килгән бер форсатны ганимәт белеп, һичбер кемгә, хәтта дусты Садыйкка да сиздермичә, шул дөньяга сәфәр итте.

Кайбер адәмнәр җан вә табигатьләренең сөрешләре, асыл яратылышлары белән үк үзләрен хыялый вә мәгънәви булган хәлләрнең хөкеменә тапшыра вә гомер буенча шуңа буйсыналар. Бундый затларның йөрәкләрендә табигать илһамы белән урнаштырылган мөкаддәс кануннар, гали әмәлләр вә бөтен матди хәятның ләззәтләрен шуның юлында үзе теләп корбан итә торган вә гомер буенча шуңа табындыра торган изге ниятләр була.

Бөтенләй үк булмаса да, кайбер җәһәтләре белән Зыя да шундый вөҗүдләрдән[1]. Яшьтән үк хыял белән ерак әмәл аның хәятында бик зур рольләр уйный килде. Бу хыял вә бу әмәлләр заман вә мохитның һәм дә аның мәртәбәи фикриясенең[2] тәэсире белән үзгәрә, төрле кыяфәткә керә килсә дә, ул һәрхәлдә бар иде, һәм аны Зыя тышкы дөньяга вә матди хәятының гади, хәтта табигый булган эшләренә дә җиңелмәслек рәвештә идарә кыйла иде.

Табигать танучылар аның бу сыйфатын күзләренә тик бер генә мәртәбә карау илә дә белеп алачаклар: чөнки рухның көзгесе булган ул хыялый күзләрдә бунның галәмәте бик ачык ялтырый иде. Бөтен мәдрәсә галәме «кызыл фонарь» сүзе белән үк үзен икенче төрле хис кыйла башладыгы, һәммә шәкерт ул йортлар вә андагы кызлар хакында авызыннан сулар китерерлек мәртәбәдә кызышып, яратып сөйләдеге, мөмкин булса, дөньяда оятка калудан яисә җәһәннәмдә утта янудан курыкмаса, башы-аягы белән чумарга хәзер тордыгы хәлдә, Зыяның ул дөньядан, ул фонарьлы йортлардан җаны вә йөрәге белән чиркануы –囲штә башлыча шул табигатенең тәэсиреннән иде.

Дәһри Садыйкның тик бер мәртәбә генә сөйләве аркасында, беренче форсат белән шунда атылырлык мәртәбәдә авышып китүендә дә бердәнбер мөәссир булган нәрсә шул табигать иде. Чөнки юлдашының тасвир кыйлган галәме белән үзе хыял кыйлган вә табигате белән мәел итмәктә булган дөньясы арасында нииндидер бер мөнәсәбәт, бер охшашу бар кебек тойган иде.

Һәм яңлышмады да.

Ул, кимәле извозчикны яллап, ерактан ялтыраган кызыл фонарьларга якынлаша башлагач, эчендә, белмим, куркугамы, шик вә икеләнүгәме охшаш бер халәт тойган иде. Кимә йортларга тәмам җитеп, ачык тәрәзәдән татар музыкасы, нәкъ

---

[1] *Шундый вөҗүдләрдән* – «шундый кешеләрдән» мәгънәсендә.
[2] *Мәртәбәи фикрия* – фикер дәрәҗәсе.

теге тын кичәләрдә тәүфыйксыз Бәдринең уйнаганы кебек мөәссир музыка ишетелә башлау белән, икеләнү дә очты, куркудан да әсәр калмады. Каяндыр кыюлык, нииндидер батырлык килеп, ул, һичбер нәрсәгә илтифат итмичә, кимәсеннән сикереп чыкты да, аякларын каты басып, башын югары күтәреп, үз өенә кергәндәй, биек клидурдан[1] менеп китте.

Анда умарта корты кебек гүлиләр иде. Әллә нинди ирләр бар, калын-калын хатыннар бар. Берәү керә, берәү чыга. Кайбер җирләрдән җырлар, музыкалар, шаркылдап көлүләр ишетелә. Ул, беркемгә дә карамыйча, иптәшенең тасвир иттеге рәвеш белән, экономканы күрде дә, тыныч бер бүлмә алып, пиво китерергә, ике кыз чакырырга, иң шәп татар музыкантын кертергә кушты:

– Музыкантның шәбе булсын, татар булсын. Башкалар тарафыннан алынган булса, мин хак өстәп алдырачакмын, – дип тә гыйлавә кыйлды[2].

Аның хыялында әллә НИНДИ ерак галәмнәрнең күренеше бар. Аны монда китергән берничә мәелләр бар. Ул үзе, пиво янында, фахишәләр уртасында булдыгы хәлдә, шул хыяллары, шул мәелләре белән бу дөнья арасында мөнәсәбәтнең кай нокталарда икәнен, ераклап, чуалчык рәвештә булса да, сизенергә тырышты... Ул бүлмәсенә кергән кызларны күп карамады, җентекләмәде. Тик аз буянган, күзләре яшьрәк вә мәгъсумрак[3] карый торган Хәнифәне янына алды да, бүлмәне бикләтеп, гомерендә беренче мәртәбә, үз иреге, үз хуҗалыгы, үз боерыгы белән, үзе өчен уйналганын яшермичә, татар музыкасының аһәңнәренә йөрәген ачты. Һәм шул минутта гына ул, теге иптәшенең сүзләре аңа ни өчен ул чаклы нык тәэсир итеп, үзенең шундый тиз арада бу сәфәргә батырлык итәр мәртәбәдә аңа җиңелүенең вә аның тасвираты эчендә иң артык җазибәлесе кай нокта булганын ачык рәвештә аңлый алды.

Аның мондый сәфәрләре байтак мәртәбәләр тәкрар ителеп, соңра эчендә яшәгән мохитның тимер куллары арасында җаны кысылган, йөрәгенең тын алырлык та тәкате калмаган, һәммә нәрсәгә төкереп, дөньясын чүплеккә ташлап, күңеле әллә кая ашкынган, үзенә бик аз бер җуаныч өчен бөтен җирен, күгэн бирерлек мәртәбәдә борчылган минутларда, үзеннән меңе мәртәбә көчле булган бер куәт аны кимәле извозчикны яллап, шунда таба юнәлә иде.

15

Ул никадәрле сак йөрсә дә, йөргән эзен яшерү өчен ничаклы чараларга керешсә дә, «без капчыкта ятып кала алмады» – аның әллә нинди рус уеннарына,

---

[1] *Клидур* – биредә "баскыч" мәгънәсендә
[2] *Гыйлавә кыйлды* – өстәде.
[3] *Мәгъсум* – гөнаһсыз.

шәригатьтә хәрам булган ләгу вә ләһәбләр[1] күрсәтелә торган кяфер йортларына, бигрәк тә мөэмин адәм аяк басарга ярамаган яман йортларга, “һәрбер баскан җирләрендә үлән корый бара” торган гөнаһлы хатыннар янына баргалавы юкбарны казып йөрүче адәмнәр тарафыннан хәзрәткә җиткерелде.

Бу хәбәр башка бер шәкерт хакында булса, күп тикшереп тә тормыйча, әүвәл, теге бичараны тотып, бөтен шәкерт алдында эт урынына кыйнарлар, соңра, суктырып, мәдрәсәдән генә куарлар иде. Ләкин Зыя хакында алай җиңел генә бетерү мөмкин булмады. Аның бабасы бу мәдрәсә мөдәррисенең шәриге булган. Бохарада да бергә яшәгәннәр. Атасы Җәләш хәзрәт тә, бабасы мөнәсәбәте белән катышып, мөдәрриснең якын дустлары зөмрәсенә[2] кертелгән. Менә шулар хөрмәте өчен, Зыя хакындагы ул хәбәрне эчтән тынарга әмер кыйлып, мөдәррис әфәнде мөттәһәмнең[3] үзен чакыртты да, шундый хәбәр ишеткәнлеген, ләкин үзенең ана ышанып бетә алмавын, дошманлыктан сөйләмиләрме дип уйлавын, әгәр дә яшьлек белән була калган булса, тәүбәи нәсух[4] кыйлып, яңадан якын бармаска тиешлеген атаклы хәзрәткә махсус тел белән бәян итте һәм дә шундый эш тагы бер мәртәбә булса, аңарга моннан аерылырга тугры киләчәген белдерде.

Зыя инде бу вәгазьләргә мөтәәссир булырлык мәртәбәдән үткән иде. Шуңа күрә буңа үз тарафыннан күп әһәмият бирмәде. Ләкин, агасы мәдрәсә ташлаганның соңында, атасы ни дәрәҗәдә тилереп, анасына ничаклы авыр көннәр күрергә туры килгәнен ачык белдегеннән, бунын да «уйнаш сәбәпле мәдрәсәдән куылу» хәбәре ирешсә, анасының баштанаяк авыр газаплар илә тулган хәяты тагы да бик авыр көннәр эченә ташланачагын ачык аңлаганга, ул, остазына мотыйганә җавап биреп, үзен акларга тырышты, андый эшнең булмаганлыгын һәм булмаячагын сөйләде.

Ул туктады, ләкин гомергә түгел.

Башка бер җирдә ишетү мөмкин булмаган шул җырлар, шул музыкалар, шул – татарның гасырлардан бирле җыелып килгән барлык моңнарын йөрәгеңә ачып сала торган мөәссир аһәңнәр аны тагы да тартты; ул тагы да, бик яшеренеп кенә, шул йортларга зыярәт кыйла башлады. Ләкин бер көн бер дә көтелмәгән эш булды.

Ул, гадәтенчә, тын гына бер бүлмәдә иде. Өстәл тирәсендә берничә кызлар булып, анлар туктаусыз эчә торалар, анларга, кергәләп, экономка да, иптәш кызлары да ярдәм иткәли; бутылкалар бушатыла, стаканнар туктаусыз йөри

---

[1] *Ләгу вә ләһәбләр* – уен-көлкеләр.
[2] *Зөмрә* – төркем, группа.
[3] *Мөттәһәм* – гаепле дип саналган, яла ягылган кеше.
[4] *Тәүбәи нәсух* – чын күңелдән гаепне тану, тәүбә итү.

торалар.

Зыя исә, боларның һичберенә илтифат итмичә, гүя икенче дөньядан килеп, тирән хәйрәт эчендә калган адәм кебек, мәгъсум Хәнифәнең калку күкрәгенә бер як яңагын куйган хәлдә, дәртле татар егетенең кулында татарның бөтен кайгыларын еламакта, әллә нинди озын көйләр белән моңланмакта улган музыканың куәтенә җиңелеп, хыялы белән әллә нинди ерак вә музыкальный галәмгә китеп югалган хәлдә утырмакта иде...

Шул вакыт кемдер ишек шакылдатты да, аңсыздан бер кызның ачуы белән, ике егет басып керделәр.

Караса, дәһри Садыйкның дошман шәрикләреннән Гали белән Сафа икән! Ахырдан мәгълүм булды: бу ике, кемнәндер Садыйкның мондалыгын ишетеп, эләктерү өчен кергән булганнар икән... Ләкин барыбер – анлар Садыйк аша Зыяга дошманнар...

Бу эшләрдән туачак нәтиҗә ачык билгеле булганга, Зыя, үзе хакында «бәйләп алып кайту» сүзен ычкындырып ташлаган ул ике шәкертне политсә белән чыгартты да, аларга: «Хәзрәткә сәлам сөйләңез, аның үзе белән дә, мәдрәсәсе белән дә минем хәзер һичбер төрле галәкам калмады!» – дип әйтергә кушты. Үз-үзенә яңа гына хуҗалык алган адәм кебек, төн буена музыка уйнатып, иртә белән бер номерга килде вә шунда торырга карар бирде. Икенче көнне аның бер дусты, һәммә нәрсәләрен китереп, хәзрәт тарафыннан рәсми тапшырылган ошбу игъланны ирештерде:

– Җәләл мулла угылы Зыя Сабитов тәүфыйксызлыгы сәбәпле мәдрәсәмездән сөрелде...

Бу вакыт Зыяга унсигез яшь тулып килмәктә иде.

16

Ул мәдрәсәдән сөрелде. Шуның илә бергә аның эчендә булган музыка дөньясын чолгап, басып вә кысып торган зур, калын, кызганычсыз крепостьлар да берьюлы җимерелеп юкка чыкты вә тузанга әйләнделәр.

Бөекләрдән берсе: “Назик җанлы вә хассас йөрәкле адәмнең табигате вә табигый мәелләр белән эчендә яшәдеге мохит арасында башкалык, дошманлык булса, аның хәяты мәңгелек трагедия эченә ташланмыштыр!” – ди. Һәм тугры да сүз.

Зыя да язмышның шундый колларыннан берсе иде.

Явыз куллар белән аяусыз читлек эченә бикләнеп куелган асыл кош, үзенең кошлык табигате белән гашыйк булган ниһаясез фәзада[1], киң дөньяда, ачык һавада вә матур җирләрдә туктаусыз очарга теләп тә, әллә кемнәр тарафыннан

[1] *Фәза* – күк киңлеге.

ясалган тимер рәшәткәләр аның бу теләгенә, бу табигый өмитенә каршы барып, азатлык бәндәсен мәңге тоткынлык трагедиясендә яшәткән кебек, Зыяның эчендәге, Тәңренең үз кулы, үз ирадәсе[1] белән куелган музыка таланты, музыка дәрте ничаклы омтылса, ничаклы тырышса да, куәтле мохит аңа дөньяны күрсәтми, хаким мохит аны һаман да ирекккә җибәрүдән тимер куллары белән тыя иде. Шунлыктан аның хәятында, теле вә гакылы белән тәгъбир итеәлә алмаган, ләкин бик куәтле булган трагедия хөкем сөрә иде.

Бар табигый, хәлкый булган бер ихтыяҗ, бер мәел; шул үтәлми. Шуннан туа трагедия.

Зыя бик яшьтән үк, киләчәк бәлаләргә дә карамыйча, бер кубыз саклап, шуны өйрәнергә тырышып йөрсә дә, мәдрәсәдән котылу заманынача, аның мәеленең бу ягы икенче мәртәбәдә тоелып, иң куәтле теләк аны ишетүгә, аның белән рухында булган бушлыкны тутырырга, җанының табигый азыгын бирергәдән гыйбарәт иде. Теге мәсьәләләрнең ачыктан-ачык фаш булуы белән, ихтыяҗның әүвәлге сурәтен, беренче ягын үтәү җиңеләйде, мохитның бунардан тыйган куллары берьюлы сынып, кысып торган таш диварлары бар да ватылды, юк булды. Ләкин асыл кош һаман да үз гыйшкының бөтенләй үк канәгать табып җитмәвен хис кыйла иде.

Ул инде бала түгел. Үзенең ирекенә генә түгел, дөньяга карашында, фикер вә игътихатында да үзенә үзе хуҗа икәнен ачык аңлар мәртәбәдә үсә алган. Музыкага кемнәр ничек карыйдыр, кемнәрнең ясаган кануннары аны, ярыйгамы, ярамыйгамы кертә – аның бер тиенлек әһәмияте калмаган.

Бер мәртәбә пәрдә ачылгач, мохитның да куәте бетте. Ул як шулай. Ләкин ничек итеп, мәйданга китерергә аптыралган, бөтенләй яңа да һәм юлы да салынмаган бер хәрәкәт булганга, аның алгы көнен тәгъйин кыйлу бик читен хәлдә күрелгән икенче бер як бар. Ул аны ачык итеп уйлый да алмый, хыял да кыйла алмый.

Менә ул бала чакта кубыз белә иде. Ул анда ярый да, канәгатьләндерә дә иде. Ә хәзер аңа кубыз тавышы очкан чебен канатының безелдәве сынлы гына тоела. Ул үскән; үзе белән бергә тәмйиз[2] дә үскән. Ихтыяҗының куәте дә зурайган. Ул кулына бернәрсә тотып, йөрәген канәгатьләндерә алырлык дәрәҗәдә уйнау өчен, бер Ходай белә, никадәрле эш кирәк. Шуның илә бәрәбәр буны ул тели дә. Үзенә бик нык ышана да. Менә Тәңре бер юлын күрсәтсен, андый-мондый гына түгел, аны чыннан канәгатьләндерерлек бер уңгае чыксын да, ул өйрәнсен, белсен! Аңа башка бернәрсә кирәкми, тик табигатендә булган

---

[1] *Ирадә* – теләк.
[2] *Тәмйиз* – аера белү.

кылларны аңлап, шуңа мөтәнасиб[1] юлы гына табылсын. Ул, хәзер зур дәрт белән тотынып, тиз арада белер дә шул дәрәҗәдә уйный башлар ки, аның куллары кылга кагылу белән музыка елый башлар. Шуның беренче тавышын ишетү белән үк, бөтен дөнья да аңа кушылып еларга тотыныр. Бу бер хыял вә фараз түгел, бәлки аның табигатенең вә йөрәк төбенең сизенүедер. Ул үзе һәрвакыт шуны хис кыйлып йөри. Гүя аның эчендә менә хәзер түгелергә торган бер дәрья бар, менә вакыты килсен, табигый бернәрсә шуңа юлы белән кагылсын – ул дәрья ташып чыгар да дөньяны басып китәр кебек була.

Ләкин буның өчен табигатьнең үзе билгеләгән, моның үзенә генә махсус кебек булган әллә нинди юлы бар шикелле тоела. Гөнаһ шомлыкка каршы, шул табигый юл белән барылмаса, аның барлык таланты тискәреләнер дә, барлык өмите кирегә китеп, ул кулындагы музыкасын ачу вә әрнүдән ваткалап ыргытыр, кем белә, үзенә дә әллә ниләр булыр.

Ләкин боларның берсе дә булмады. Ул, үзенең кулларының йөрәге чаклы музыкант булып яратылмавыңа, скрипкәнең карышкалавына җаны әрнеп, берничә мәртәбә атып бәргәләсә, хәтта өзгәләсә дә, әллә нинди зур авырлык чыкмады; шулай ук, белмим, табигый юлы табыла алмагангамы, кай ноктадан, кай рәвешчә керешергә идеге беленеп җитмәгәнгәме, теге, эчтәге зур дәрья ташып чыгып, дөньяны басып та ташламады, – ул өйрәтүчеләр кашында гадиләрдән байтак өстенлек вә тизлек белән музыка сәнгатен дәвам иттерде. Үзе бәгъзан яна, көя, өмитсезлеккә төшә, кайбер чакта бик зур дәрт вә һәвәс илә дә керешеп, өмитенең якынаюын да хис итә башлый иде.

17

Язмыш кайбер вакытта бичара адәмнең өстеннән, үзенә дә сиздермичә, үтә кызганычсыз көлеп куя.

Мунчада кубыз тарткан өчен сабый баласын эт урынына кыйнап ташлаган Җәләш мулла белән дә язмыш шундый бер уен уйнады.

Зыяның мәдрәсәдән куылу хәбәре атасына, әлбәттә, көне белән ирешкән иде. Аның буңа карашы билгеле: ул моның белән бергә җиһанда актык өмитенең югалганын ачык аңлап, ни дияргә белмичә, көннәр, төннәр җенләнде, тилерде. Дөньяның һәммә адәмен эттән алып, эткә салып сүкте дә арыганның соңында Зөләйха абыстай аркылы аңа хат яздырды:

«Хәбәреңне, – ди, – ишеттем. Җүләрсең. Малайсың. Егермегә җитеп, башыңа гакыл кермәгән. Ата дип белсәң, миннән сүз шул: бар! Мөдәрриснең ишеге алдына егыл! Аягын үп! Сәҗдә кыйл да, тәүбә итеп, гафу сора. Үзем дә хат язарым. Кичерер. Әгәр дә сүземне тыңламасаң, мине ата дип белмә, күземә

---

[1] *Мөтәнасиб* – туры килүче, җайлы.

күренмә, йортыма аяк басма. Дүрт ягың кыйбла: теләсәң, чукынып, тәре тагып, кадалып кит... Чукын, кяфер бул! Мөшрик[1] булып җаның чыксын! Миннән фатиха шул!»

Бу мәктүб Зыя өчен бик табигый нәрсә булып күренде. Чөнки ул теге хәбәрнең атасына ирешәчәген һәм атасының аңа ничек караячагын ачык белә, язачак хатының гыйбарәләрен тәгъйин итә алмаса да, мәфһүмен[2] көн кебек аңлап тора иде, – шунлыктан ул аңа бик гади күз белән карады һәм, аңа илтифатсыз, үз эшендә дәвам итеп, көлкеле тәгъбиренчә, дүрт ягын кыйбла ясап йөри бирде.

Ул бәлки Кара урманга мәңгегә кул селеккән дә булыр иде, ләкин, ләкин ике нәрсә аны аяктан екты; ул, үзе өчен кирәк дип белмәсә дә, илаһи бер мәхәббәт илән багланган анасының һәм дә балалык җан дусты Мәрьям туташның бертуктаусыз ялынулары, күз яшьләре өчен, тик шуларга булган мөнәсәбәт мәҗбүр кыйлганлык өчен, атасы белән яңадан килешергә уйлады.

Бу бер дә кыен эш түгел. Тотарга да бик зур шөһрәт чыгарган бер мөдәрриснең данлыклы мәдрәсәсенә барып керергә; «Әти, мин укыйм, дәресләрем-фәләннәр, алда фәлән төрле планнарым бар», – дип язарга кирәк, ничек тә яңадан гакылга утырып, ахунлык, мөдәррислек кәгъбәләренә юнәлә башлавың хакында өмит кенә бирергә кирәк. Шуның белән Җәләл хәзрәт ал да гөл булыр. «Угылым, ни хәл, кирәксә акча сора, син болай да ябыксын, ашау-эчүдән кызганма – сәламәтлегеңне саклый күр!» – дип хатлар яза башлар.

Һәм шулай булды да.

Ул яңа мәдрәсәле бер шәһәргә барды да, үзе шунда торып, «читтән тыңлаучы» сыйфаты илә дәресләргә йөргәләргә кереште һәм атасына монда берничә ел торып, Мисыр вә Гарәбстан ягына китү фаразы барлыгын язды.

Зыяның солдатка каралыр елы да якынаеп килә, шул чорларда бәлки уңгайлырак, гаиләнең күз яшен түкмичәрәк өзелергә чарасы табылуы ихтимал. Шунлыктан, кыен булса да, бер-ике елга түзәргә булды.

«Чукын, мөшрик булып җаның чыксын!» – дигән Җәләш мулла исә, тимер балавызга әйләнгән кебек, угылының бу акыллылыгын күргәч, бөтенләй йомшап китте.

Өйдәгеләр берьюлы җиңел тын алдылар. Зөләйха абыстай да хәзрәтнең әрләреннән беразга тынды. Җәләш мулла исә тагы матур хыяллар белән җуана башлады.

Ул борын кадим иде. Зыя бундый мәдрәсәгә кергәч, җәдиткә ауды: ник ис китәргә? – заманасы шул бит инде, ди; җәдитләр мантыйк, кәлямдә сайрак

[1] *Мөшрик* – динсез, мәҗүси.
[2] *Мәфһүм* – төп мәгънә, эчтәлек.

булалар[1] булуын да, барыбер инде... Хәзер халык шуны ярата. Әнә Садыйк хәлфә элгәре җәдитләрнең башлыгы кебек йөри иде, ә Мысыр, Ыстамбул йөреп кайтты да шәһәрнең нинди зур мәхәлләсенә мулла булды. Әнә Кәримне дәһри дип сүгәләр иде, инде зур мәдрәсә салдылар да үзен беренче мөдәррис ясап куйдылар. Күрсәң, исең китәр. Бу губернатормы дип торырсың. Хәзер бөтен шәһәрне кулында уйната, башка муллалар аның алдында сүз дә ачалмыйлар, имеш...

Зыяга да шундый бер насыйб чыкмасмыни? Иншалла, чыгар, әлбәттә чыгар... Менә шул үзгәрешнең икенче елында иде, Зыя, атасына хат язып, хәзерге остаз киңәше буенча, Уфа Духовный собраниесенә[2] имтиханга кермәк булам, аннан соң, бәлки, авылга да кайтып килермен, дип хәбәр итте.

Бу хәбәр хәзрәтне ничә еллык яшәртеп, аның шатлыгының иге-чиге дә юк иде. Бу фаразның чынлап ук вөҗүдкә чыкканын күргәч, аның аяклары җиргә тими, башы күккәчә күтәрелеп, ул бу вакыт үзен, хәзер генә бөтен дөньяның башына менгән дә, һәммәнең күзенә карап мактанырга, кабарынырга хак алган бер адәм кебек хис кыйла иде.

Имтихан тоткан соң өенә кайтканда Зыяның янында бер иптәше дә бар иде. Ул, аңа атасының барлык табигатен сөйләп, бер дә аптырамаслык рәвештә таныштырса да, теге егет хәзрәт өчен бәгъзан колакларынача кызаргалый иде. Бу вакыт күбрәк мәсьәлә мәхдүмнең имтиханына гаид булды.

Җәләл кәнәфигә кырын ята да мең дә беренче катка янәдән сорый башлый:

– Собраниегә барып кердең? Шуннан соң кем очрады?

– Бер татар шунда.

– Ни ди, нигә килдең диме? Кай якныкы, кем угылы диме?

– Әйе.

– Соң, син нәрсә дидең? Җәләлетдин хәзрәт мәхдүме дидеңме?

– Мин тәфсыйльле адресымны әйтеп бирдем.

– Ни ди, ә мин беләм аны, әйдә алайса, мөфти хәзрәтенә керегез димәдеме?.. Миңа бит андагылар бар да таныш. Барсам, бар да: «Мулла абзый да мулла, абзый?» – дип, тирә-ягымны сырып алалар, кайсы аягымны, кайсы тунымны салдыра башлый... Казыйлар да бары: «Әйдүк, мулла Җәләлетдин, түрдән, мөфти хәзрәтенең яныннан утыр!» – дип, бил баглап торалар... Соң, энкә, имтиханга кергәч, сине таныдыларммы?

– Юк, мине кем танысын анда?

– Соң, син кем угылы дип сорамадылармыни?..

---

[1] *Кәлямдә сайрак булу* – сөйли белмәү.

[2] *Духовный собрание* – (Духовное собрание) – Диния назарәте

– Аны сорадылар.
– Син ни диден?..
– Мин әйттем, мин Җәләл мулланың угылымын, дидем. Шуннан соң бер казый: «Кара урман Җәләлнекеме?» – дип сорады.
– Соң син ни диден?
– Әйе, дидем.
– Соң мөфти сорамадымы мине? Ни ди, атаң исәнме, сәлам әйт диме?..

Бу сөальләр ниһаясез дәвам итә. Хәзрәт төрле яктан уратып китерә дә тагы мөфтинең сорауларына тери:

– Мөфти ни ди, ә, беләм, бик беләм, Җәләл минем бик дуст кеше ул диме? Син Җәләл мулла угылымыни, ә, беләм алайса, беләм дип әйтәме? Соң, чыкканда, атаңа сәлам әйт, угылы бик шәп икән, рәхмәт, тырыштырган-фәлән дип әйтмәдеме?

Ике ягы да бәрабәр булганга, Зыя бу сөальләрнең һәммәсенә иҗаб[1] белән җавап бирә дә, хәзрәт, анларны тәкрардан арып, мөдәррислекнең имтиязлы мәртәбәсенә, үз кашында дөньяда аңардан зур дәрәҗә юклыгына даир[2] сөйли башлый:

– Менә, – ди, – мулла Әхмәди, минем бер ягыма зур алтын тавы куйсыннар, икенче ягымда әле яңа гына Собраниедән Зыяга бирелгән «Зыя бине Җәләлетдин Сабитовка имам хатиб вә мөдәррислек рөтбәсе игъта кыйлынды[3]» дип язулы шаһәдәтнамә булсын, – шул икенең каюсын аласың дисәләр, алтын тавына әйләнеп тә карамас, валлаһ, әйләнеп тә карамас... мөдәррислекне алыр идем... Әлхәмделилла, әлхәмделилла, Хода бу мәртәбәне бирде инде... Зур эш, бик зур эш... Тирә-якның бу төшенә дә кермәгән эш.

Шул егет Зыяларда бер сумка әйберләрен калдырган иде. Анда бер гитара да бар икән. Моның нинди нәрсә икәнен берсе дә аңлый алмады. Зыядан сорыйлар, ул шаярган кебек кенә көлә дә «белмим» дип җавап бирә. Шулай итеп гитара байтак көннәр диварда асылып торды.

Инде бу вакыт бөтен тирә-якка «Җәләшнең икенче угылы мөдәррислек алган имеш...» хәбәре тәмам таралып җиткән иде.

Беркөнне боларга становой килеп төште. Ул, Җәләш белән якын мөнәсәбәттә булып, аның табигатен бик яхшы аңлый иде. Урыс бит – нәрсәне таный. Өйгә кереп, чишенеп тә җитмәде, күзе диварда асылып торган гитара төшеп, зур хәйрәт белән кычкырып җибәрде;

---

[1] *Иҗаб* – уңай.
[2] *Даир* – турысында.
[3] *Рөтбә игъта кыйлынды* – дәрәҗәсе бирелде.

– Бу нәрсә, мулла? Кем уйный моны?

Бу урыс соңгы елларда Зыя белән дә якыннан таныш булганга, аның хәятын белә, зарларын аңлый, музыка дәртенә мохитының ничек җавап биргәненнән дә хәбәре бар иде. Шуны игътибарга алып, хәзрәтне җиңәрлек яктан тилертә башлады:

– Бу ни эш, мулла?.. Син харап икәнсең!.. Син безнең барыбыздан уздыргансың икән... Кайдан төшердең буны?

Хәзрәт, ни дияргә белмичә, бераз гына торганнан соң:

– Ә, алаймы?.. Сабитовларда булмаган ни нәрсә бар дип беләсең? – ди.

Становой тагы дәвам итә:

– Беләмсең, мулла? Бу бит заграницада гына була торган нәрсә... Безнең Русиядә ул юк та, аны белмиләр дә. Бездә гармун белән скрипка дигән музыкалар була, ләкин анларны җүнле әдәм тотмый. Тотса, мужиклар тота. Ә бу бит бөтенләй икенче нәрсә... Бу – губернатор, министр угылларының кулында гына булгалый торган кадерле әйбер...

Хәзрәт кабарынып куярга уйлый, ләкин яңлыш бернәрсә ычкындырып, оятка калу ихтималыннан курку аны тагы туктата.

Урыс дәвам итеп:

– Ну, Зыя, беләсеңме, Җәләл мулла угылы була торып, шуны да белмәсәң, ул нигә ярый, – дип, гитараны тоттыра да уйнарга тәклиф итә.

Балалар, бигрәк тә мулла, хәйрәт белән тулган күзләрен Зыяга юнәлдерәләр. Ул, берәүгә дә карамыйча, гитараны ала да, санын арткарак ташлап, аякларын чалып, чын музыкант кыяфәте белән берничә мәртәбә тартып куя...

Шулай итеп, кәрамәтле нәселдән килгән данлыклы Җәләлетдин мулланың намаз урынында, үз күзе алдында, әзәлдән бирле беренче мәртәбә музыка тавышы ишетелә.

Становойның тәклифе илә Зыя дәвам иттерә. Өйдәгеләр бар да шакката, Җәләл ни дияргә белми, ләкин аның йөзендә ачу юк, күзләре дә ачу белән түгел, мактанып карыйлар, бөтен торышында бер кабарыну әсәре күренә. Зыя уйный, становой аны мактый, хәзрәт исә бер угылына, бер урыска туктаусыз «ә, алаймы?» дигән кыяфәт илә күзләрен йөртә...

Бераздан соң теге сумкадан ноталар да алынды. Инде шаккатулар азая төшкән иде. Теге якта балалар вә хатыннар ярыктан хәйрәт белән карауда дәвам итсәләр дә, Җәләл мулла, артык исе киткәнлеген становойдан яшерү өчен, икенче эш белән мәшгуль була башлады.

Зыя исә, барын онытып, музыка тавышы илә бергә әллә кая агып китте.

Бу көн хәзрәт тә, абыстай да гомерләрендә тик бер генә мәртәбә очраган гаҗәб

аптыраш вә хәйрәт эчендә калдылар. Бу ни эш, бу ни хәл? Бу ярыймы, юкмы, буннан ни нәтиҗә чыгар? Зыяны туктатыргамы, әллә уйнасынмы? Соң нәрсә икән бу?.. Бу сөальләр анларның гакылына килми, анлар буңа җавап та эзләмиләр, бәлки шул сөаль вә шуларга җавап эзләү хәлендә була торган хәйрәтне генә тоялар.

Җәләш кубыз тарткан өчен Зыяны эт урынына яра иде. Ләкин бу җәза угылының гамәле шәригатькә сыймаганлык өчен генә түгел, бәлки Җәләлнең, әлбәттә, зур ахун, атаклы мөдәррис булачак мөмтаз угылын шул эштән чыккан мужик балалары рәтенә төшерүе, мохитның начар каравына сәбәп булуы хәзрәтне бигрәк кузгата иде. Ә хәзер соң? Бу да барыбер түгелмени?

Бер дә кебек, түгел дә кебек... Бит Зыяда тәүфыйксыз, егетләрнең, азгын кызларның уйный торган гармуны да түгел, теге, базарга килгән урыс малайларында күренә торган скрипкә дә түгел; аныкы – заграничный, аныкы губернатор, министр угылларында гына була торган әллә нинди кыйммәтле әйбер. Җитмәсә, ул әллә нинди кәгазьләр буенча уйный. Соң ни эшләргә инде? Борынгы заман булса, ул үзе мондый шөбһәләргә бирелмәс, күңеленә аз гына шик килсә, угылына аяк тибен кычкырыр, туктатыр да, бик карышса, теге нәрсәсен дә ваткалап ташлар иде. Хәзер алай итү кыенрак. Ул ачы тәҗрибәләр кичерде. Аның зур угылы әллә ни хәлгә төште. Бусы да өзелгән иде, ярый, ничектер гакылга утырды... Артык катылык күрсәтсәң, аны атасына бәйләгән нечкә җеп өзелер дә, ул угылыннан колак кагар... Тагы шул да бар: Зыя бит хәзер мөдәррис инде. Аның белән ничек артык усал булырга.

Ә абыстайның хәйрәте тагы авыр.

Аның кашында музыка тарту – барыбер уйнаш итеп тотылу, ат урлап кыйналу, урамда җырлап йөрү кебек үк. Музыканы инде һичбер вакыт адәм рәтле кеше уйнамый. Анлар бар да азгыннар, тәүфыйксызлар була. Әнә егетләр белән тотылып, аты-чабы чыккан Бәдрелхәят, әнә, атасын ач тотып, тапкан акчасын эчеп бетерә торган Тимеркәй, тагы шундый эштән чыккан, тәүфыйкларыннан язган егетләр – менә бит музыканың әһелләре кем.

Ә соң тирә-якта гыйлеме вә әхлагы белән беренче урын тоткан Зөләйха остазбикәнең тәрбияле мәхдүменә, мулла булырга якынлашкан угылына бу килешәме? Алай дисәң, Зыя бит теге Бәдрелхәятлар, Тимеркәйләр кебек скрипкә уйнамый, – аныкы әллә нәрсә... Җитмәсә, үзе китаптан карап уйный...

Халык исә аның китаптан каравын да, гармун түгеллеген дә уйламады. Мулладан музыка ишеткәч, хәйрәт белән тыңлаштырдылар да, бөтен авыл буена: «Безнең мулланың малае бигрәк шәбәеп кайткан икән, сыза гына, Тимеркәйләрең бер якта торсын», – дип чәйни башладылар. Хәбәр Кара

урманнан чит авылларга таралып, тиз арада «Җәләшнең малае» хакында әллә нинди сүзләр чыкты. Дошманнар: «Вәт сиңа имам хатиб мөдәррис! Буны мулла ясасаң, михрабта гармун тарта башлар», – дип көләләр. Хәбәр, ерак киткән саен, зурая барып, читрәк авылларда: «Җәләлнең угылы теге йортларда музыка уйнап йөргән имеш... Атасы «уйнама» дисә, мин ансыз тора алмыйм, ди имеш... Зыя уйный, янындагы бер урыс егете бии имеш...» кебек сүзләр дә ясалды.

Ул көнне Җәләл становой белән, ике көннән кайтачак булып, каядыр киткән иде. Зыя исә, бернәрсәгә дә карамыйча, эшен дәвам иттерде. Зөләйха абыстай ни дияргә дә белми иде. Кояш баеп, караңгы төшү белән, Зыя гитарасын ала да бакчага чыга. Анда зур имән төбендә, яшь үләнгә кырын ятып, уйный башлый. Менә шул вакыт абыстай тагы хәйрәт диңгезенә башы, гакылы белән чума.

Аның хыялында бер-беренә охшамаслык ике Зыя йөри. Менә анын йомшак табигатьле, көләч йөзле шәкерт угылы. Ул инде хәзер мөдәррис тә. Ул һәйбәт киенә. Кечкенә җир фәрештәсе төсле булып, матур гына кыяфәт илә чалма, чапаннан мәсҗедкә бара. Кешеләргә сәлам бирә. Аксакалларгача аңа юл биреп, бил баглап торалар. Ул Коръән укый. Кайбер вакыт аның мәкаменнән бөтен мәсҗед еглый да имеш. Менә яңарак кына, өченче көн, хәтта кичә генә дә шулай иде... Ә бүген бакчада, кырын ятып, музыка тарта. Бу вакыт инде абыстай аның теге карап уйный торган китабын да, аләтенең [1]гитара булуын да хәтерли алмый. Хәзер аңа Зыя бөтенләй икенче адәм, гүя аның чалма, чапан киярлек җүне дә калмый, кисә дә, килешми, очраган картлар да аның сәламен алмый, аның мәсҗед әһелен елата торган тавышы да әллә кая оча, – юк, Зыя урынына әллә нинди, кулына скрипкә тоткан бер урыс малае гына кала... Бу аңа «әни!» дип әйтә белерлек тә түгел кебек...

Абыстай бу шөбһәләрне Зыяга әйтә алмый. Ничектер кыен тоела. Аның кәефе китәр шикелле була.

---

Ләкин боларның барына да бик тиз хатимә бирелде[2].

Хәзрәт киткән җирендә бер голәма мәҗлесенә туры килгән дә, анда Зыя хакында сүз ачып, берәүсе аны: «Бертуктамый гармун гына уйнап ята имеш!» – дип сөйли башлаган.

Сүздән сүз китеп, бер карт мулла Җәләлгә бик бәйләнгән:

– Сине без, мулла Җәләл, тирә-якның котбы[3] кебек тота идек, – ди икән мулла, – ә син бер балаңны да шундый эштән тыя алмыйсын, икән... Синең атаң кем

[1] *Аләт* – корал, уен коралы.
[2] *Хатимә бирелде* – монда «чик куелды» мәгънәсендә.
[3] *Котб* – иң зур кеше, үзәк фигура.

иде, бабаларың кемнәр булган? Анлар синең бу эшеңә ни дияр?.. Анларның рухлары сиңа рәнҗемәсме?.. Ата-бабадан тирә-якта шундый бер эш булганы, ишетелгәне бармы?!. Җитмәсә тагы, угылыңны мөдәррис дип мактыйсың... Мөдәррис булмагае әллә кем булсын, иблис бик галим дә бит, аның гыйлеменнән ни файда?.. Соң синең гайрәтең кая булды?! Ничек үз алдыңда шуңа рөхсәт бирәсең?!. Менә мин, авылның никрутлары, гармун уйнап, урамнан үтә башласалар, йөгереп чыгам да таяк белән эт урынына ярам. Икенче вакыт малайларның эзләре дә булмый.

Җәлал мулла бу мәҗлестә: «Сезнең ни эшегез бар?.. Ул инде балигъ... теләсә, марҗа белән торсын, минем анда эшем юк-фәлән!» – дип, махы бирмәскә тырышса да, кайткач икенче төрле кыйланды.

Атны малайга биреп, өйгә кергән чакта анда бер адәм дә юк иде. Ул, чишенмичә-нитмичә, бик гади эш кыйлган адәм кебек, ләкин ниһаясез ачу белән дивардагы гитараны сугып төшерде дә, бер минут кичексә, дөньяны харап кыйлачак бер һәлакәткә каршы сугыш ачкан адәм кебек, идәндә яткан гитараны аягы белән таптарга, изәргә тотынды. Бер минуттан соң гитараның тик сынган такталары илә өзелгәләп беткән кыллары гына калган иде. Мулла боларның барын кулы белән җыеп алды да, менә сиңа музыка дигән сыман, барын берьюлы янып торган пичкә атты.

Шуның артыннан ук өстәлдә яткан ноталарны да ут җотты. Башкалар кергәндә, өйдә әллә нинди көек исе, май исе чыккан иде. Пичкә карасалар, анда мәрхүм гитараның актык сыныгы янып бетмәктә иде.

Шуның белән музыка тавышы тынды, вә ул хакта һичкем, һичбер вакыт «ләм-мим» дип авыз ачарга да батырлык итә алмады. Анасының ниһаясез зур бәхетенә каршы, Зыя да моңа аслан илтифат итмәгән, һичбер мөтәэссир булмаган кыяфәт белән җавап бирде.

18

Җәлал мулланың Зыяга багланган өмитен бераз ныгайта төшкән бу вакыйга май числосында булып, шул ук елның октябрендә мәхдүм әфәнде каралачак та иде. Ике арада галәка өзелгән чак булса, Җәләш угылының солдатка каралуына бертөрле дә илтифат итмәс, китте ни, калды ни, барыбер, миңа кирәге калмады, китмәгәе, кадалсын, дип карар иде.

Ләкин хәзер эшләр бөтенләй башкача һәм табигый да. Хәзер бит Зыя азгын шәкерт, җүләр малай түгел. Ул гакылга утырды. Ул, Җәлал тарафыннан тәгаен кыйлынган кәгъбәне кыйбла танып, яңадан голәма юлына, ахунлык вә мөдәррислек өмитенә төште. Эш бу мәртәбәгә бик якын да. Ул мөдәррислеккә имтихан кыйлынды, ул теге музыкасын утка якканда бер сүз әйтмәде; менә,

Алла биреп, хезмәттән калсын да, аны читкә җибәрер. Ул һәр ике баласыннан өмит өзгәч, хаҗга китәргә җыена башлаган иде. Инде аны да куйды, чөнки Зыя, Гарәбстан вә Мысырга барачакмын, дип язган иде. Ул хәзер аны бер дә кузгатмаса да, әлбәттә, барачактыр. Шуңа бит акча хәзерләргә кирәк.

Караласы бар. Анда да акча тотмый булмас. Чөнки теге Хәйриләр барлык көчләре белән мәхдүмне җибәрергә тырышачаклар. Анлар шикаять тә кыйлыр, акча да бирер; Җәләл анларны җиңәргә тиеш. Бу эшкә ул берничә айлар элек үк хәзерләнә башлап, угылына да шул хакта йокламаска, чаралар эзләргә кушып, әллә ничә мәртәбә хатлар язды.

Ул, анаң бик сагына, елый дип, Зыяны каралырдан бер ай әүвәл үк кайтармакчы иде. Угылының: «Әти, миңа бик әзләп кенә сакланырга, докторга да күренә торырга кирәк... Кайтсам, ул да булмый, халык та белә башлый, мин каралырга өч көн генә калгач кайтырым» – дигән хатын алгач: «Син үзең артык беләсең, үзеңә тапшырдым, бер үк тырыша күр!» – диде. Көннәр якынайган саен, мөгамәлә йомшара, хәзрәтнең, дә иҗтиһаты арта бара иде. Ул угылын алу өчен стансага да үзе бармак булган иде, Хәйринең, ат җигеп, көн-төн чапканын күргәч, йөрәгенә чыдаша алмады. «Мин шул Хәйрүктән җиңелсәм, дөньяда тормыйм!» – дип, шул өмитен эзләргә китте. Мәсьәлә исә Зыяның язмышын үзгәртерлек, аның өстенә киелергә торган солдат чикмәнен кире кайтарырлык бер кул, шул эштә бер таяныч табудан гыйбарәт иде.

Берничә җирдә шундый куллар барлыгы сизелә дә, тик шуларга үз файдаңа эшләтә торган куәтне өрү өчен уңгайлы бер мөнәсәбәт чыгарырга гына кирәк.

Менә байтак заманнар инде Җәләл мулла шуның эзеннән йөри. Шуны табарга тырыша. Зыя каралачак булып өенә кайтканда да, Җәләл мулла, ат җиктереп, шуның артыннан каядыр чапкан иде.

Зөләйха абыстай, ахирәте Фатыйма бикәне озатып, «абыстай, сине Зыя абый чакыра» дигән баланың сүзе буенча, кәнәфидә авыру хәлдә ятмакта улган угылы янына кермәк өчен ишеккә килгәндә, мулласы Җәләлгә очрады. Ул: «Кайттымы?» – дип кенә сорады да, икәү берлектә өйгә керделәр.

Бу вакыт Зыя, кәнәфисеннән торып, китаплар шкафы янында нидер актара иде. Атасы аның белән бик дустанә генә күреште дә, Зөләйхага карап:

– Малайга әйт, минем атны тугарып, зур җирәнне җиксен дә әле кайтканын ышыкка бәйләп куйсын! Бик тирләгән, кичсез кушарга ярамас, – диде. Кайнаган самавыр, ашарлык бер җылы нәрсә булса, китерергә кушып, үзе тәһарәт алды да иртә намазын каза кыйлырга[1] кереште.

Ул арада өстәлгә чәй дә, кыздырылган ит тә килгән иде.

[1] *Каза кыйлу* – вакытында укылмый калган фарыз (мәҗбүри) өлешен уку.

Хәзрәт бик ашыгып эчте, угылыннан хәл-әхваль сорашты, абыстай исә бөтен тәфсыйлаты белән әле бер сәгать әүвәл генә Зыяга килгән теге куркыныч һушсызлык вакыйгасын өзелә-өзелә сөйләп алды.

Җәләлнең йөрүләре бушка булмаган. Ул Ушаковка барган. Анда, бик зурлап кабул кыйлып, аңа сый-хөрмәт күрсәткәннәр. Теге турыда өмит зур. Ушаков, үз кулы белән登 становойга хат язып, Җәләлгә дә бер дә курыкмыйча серне ачарга әйткән. Аның энесе карау комиссиясендә икән. Шунлыктан теге кирәкле кулны становой аркылы табу бик җиңел булачак. Хәзрәтнең яңадан ат җиктерүе дә шуңа бару өчен икән.

Чәйдән соң Зөләйха абыстай иренең өстенә тунын кидерде дә:

– Аллага тапшырдым инде, бер Ходай үзе уң кыйлсын инде, Илаһым! – дип, яшьле күзләре белән Җәләлне озатырга чыкты.

Ат кузгалды. Җәләл дә, теге атын кояш баемаенча ашарга кушмаска тагы әйтеп, үзенең төнге сәгать икедән кичекми кайтачагын, ике-өч сәгать йоклагач, таң беленгәндә, Зыя белән теге каралачак авылга китәчәкләрен сөйләп, юлына юнәлде. Ахыр сүз итеп:

– Зыя, анда бөтен тирә-як җыела. Муллалар да, шәкертләр дә күп булыр. Өс-башыңны алыштырып, һәммә яхшы киемнәреңне үзең белән алырсың... Хәзерләп куй! – дип кычкырды.

19

Җәләлне озатып, өйгә керүгә, аллы-артлы ике бала килде.

Боларның берсе Зөләйха абыстайны ашка чакыра, икенчесе Фатыйма бикәләрнең малае булып, Мәрьям туташтан, «безнең машинабыз ватылган. Мин бер генә минутка кереп, сезнең машинаңыз белән башлаган эшемне генә бетереп чыга алырмынмы?» дигән сөаль белән килгән иде.

Угылыннан аерылырга теләмәгәнгә, Зөләйха абыстай әүвәлге малайга рәд[1] җавабы бирде, икенчесенә эчтән генә көлде дә:

– Ярый, килсен, безнең машинабыз хәзергә буш әле, – диде.

Зыя, кәнәфигә кырын яткан хәлдә, кулындагы китапны актармакта иде. Теге як ишектән кемдер бик сак кына керде дә, аяк очлары илә генә басып, күләгә сыман гына, түргә таба узды. Зыя моны танымады. Шулай да, аның йөрәге нидер сизенеп, бөтен рухына әллә нинди бер куәт вә ялкын йөгерде...

Һәм шул ук минутта ул яктан бер тавыш та килде. Ул бик сак чыгарырга тырышылганга охшый; ләкин ничаклы тырышылса да, аның самими, тойгы катыш күз яше аша килгәнлеге бер хәрефеннән үк сизелә иде.

Тавыш тәкрар итте:

---

[1] *Рәд* – кире кагу.

– Ахирәт апай...

Зөләйха абыстай урыныннан кузгалды. Зыяның китабы ирексез кулларыннан төшеп, ул үзе әллә нинди бер дулкынлы хәлдә калды. Гүя теге сүз тел белән әйтелмәде... гүя ул Зөләйхага, абыстайга да түгел… ул берәүнең мәхәббәтенең тавышы... ул гүя караңгы төннәрдә үз алдына бикләнеп еглый торган, сагынучы яшь йөрәкнең авазы иде... Ул гүя Зыя өчен, үзенең күп заманнардан бирле җыелып килгән барлык тойгыларын Зыяга бер сүз илә аңлату өчен әйтелгән иде... Тагы берничә гади сүз ишетелде дә, машина текерди башлады.

Бу – Мәрьям туташ иде.

Ул, анасыннан Зыяның кайтуын ишеткәч, бер хәйлә булсын өчен үзе машинасын юри бозып, боларга кергән иде. Ул, бәлки, монда утырыр, Зыя белән бер өйдә булыр да күрешә алмый чыгып китәргә мәҗбүр булыр иде... Мондый хәлләр аңа еш кына очрый да иде... Ләкин бу көн бик гади бер эш аның ярдәменә җитеште.

Зыя урынында ята иде. Алты почмаклы, арадан ишекле өйнең икенче ягында исә Мәрьям туташ машина тирәсендә теккән булып маташа, Зөләйха абыстай исә аның белән сөйләшеп утыра иде. Шул вакыт аш өеннән бер хатын атлыгып керде дә, изелгән, харап булган тавыш белән: «Абыстай, тиз бул: әтәч харап булды... янып торган пичкә керде дә, берничек тә алып булмый!» – дип кычкырып җибәрде. Зөләйха кызулап шунда китте, Мәрьям исә, һичбер нәрсәгә карамыйча, яшендәй тизлек белән Зыя ягына атылды һәм, тиз арада аның кәнәфисе янында булып, кулларыннан кысты да, нә карарга, нә бер хәреф сөйләшергә өлгерә алмыйча, тар, озын канвертны аның янына салды. Үзе кире машинасы янына ташланды.

Ул арада абыстай килеп керде дә анда күргәнен хикәя кыйлырга тотынды:

– Менә, Илаһым, – ди, – баягынак бик бөрешеп утыргач, туңа башлаган, күрәсең, дип, бер әтәчне өйгә керткән идем... Шул гөрләп торган пичкә кергән дә янып эштән чыккан... Мәхлүкъның тәнендә бер бөртек җоны да калмаган... Үләр инде...

Ләкин Мәрьям буны тыңламый да, аңламый да, җаны артык дулкынланганга, куллары дер-дер калтырыйлар, машина белән дә берни кыйла алмый. Тагы бераз торса, абыстайның сизенүе ихтимал булганга, ул: «Хәзергә ярар инде!» – диде дә кайтырга җыенды һәм, абыстайның калырга кыставына карамыйча, чыгып ук китте.

## 20

Төн. Сәгать уннар чамасы булыр. Зыя зур толыпны киде дә, анасына йорт буенда йөриячәген сөйләп, тышка чыкты.

Дөнья караңгы. Язу укырга мөмкинлек юк. Шуның өчен ул, кесәсендәге хатын кулына алып, тәрәзәдән тышкы якка төшкән яктыга килде дә укый башлады:
«Зыя!
Мин төн йокламый көтәрмен. Азрак хәлең булса, кичәнең кайсы гына вакытында булса да, минем тәрәзәмне шыкылдат. Чиртсәң дә җитә. Әни өйдә юк. Бер нәрсәдән дә курыкма».
Егет мәктүбчекне берничә кат укыды да, тирә-ягына җитди рәвештә каранып, һичкем күрмәвенә ышангач, ике арадагы бакча ашасыннан Мәрьямнәрнең йортына таба юнәлде.

III

1

Аның мулла кушкан исеме – Мәрьям.
Ләкин авыл халкы болай гына дип атауны азсына, түбәнсетү булыр шикелле тоя, шуңа күрә аны, башка кызлардан, башка Мәрьямнәрдән аерып, Мәрьям туташ дип йөртәләр.
Бу һәм табигый дә кебек.
Әнә авыл кызлары – Гөлгенәләр, Сылулар, Миңҗамаллар, Зөләйхалар, Зәйнәпләр, фәләннәр ничек: яз булса, булачак кияүләренә бирнә өчен ничә айлар буена киндер сугып утыралар. Җәй көне үзләре кебек ирләр, егетләр белән кыр эшенә китәләр; урманга йөриләр, тырма, сәнәк күтәреп, кибән салалар, таза куллы ирләр белән ярышып, җиде-сигез адәм арасында ашлык сугалар; көз килсә, таза, көчле беләкләрен сызганып, җырлаша-җырлаша тула басып йөриләр...
Ләкин Мәрьям бу эшләрнең һәммәсенә чит. Ул боларны кыйлу түгел, җүнләп исемнәрен дә белми.
Дөрест, Мәрьям дә болай авыл кызы: авылда туды, авылда үсте, әле дә авылда яши. Ләкин бу хәлләр аны чын мәгънәсе белән авылныкы ясап бетерергә җитә алмады, – ул шул тормыш эчендә, ләкин аның тупаслыгыннан, матдилегеннән әллә кая югары тора. Буңа әллә ничә нәрсә сәбәп булды. Кыскарак әйткәндә, язмыш аны авылга ташласа да, аның җаны, аның хәяты, бигрәк тә эчке дөньясы бөтенләй икенче галәмнең, икенче куәтләрнең тәэсиренә бирелде, вә шул хәлләр Мәрьям белән мохитны бер-беренә каршы куйды.

2

...Мохит вә табигать!
Болар һәркемнең хәятында иң зур рольләрне үзләренә алалар. Без яхшы булу, тырышу, тәрбия ителү, теләк вә ирадә хакында сөйлибез. Ләкин бик күп тугрыда, бик күп бәндәләр хакында болар буш сүзләр генә булып кала. Бер

адәмнәр мохитка җиңелү, язмыш агымына буйсыну түгел, мохитның үзен җиңәләр, язмышны үзләре теләгән якка борып җибәрәләр. Ләкин болар Тәңренең артык мөстәсна[1] коллары. Анлар меңгә, миллионга түгел, ничә йөз миллионнарга бер генә, ничә гасырларда бер мәртәбә бичара адәмнең артык буш хәятына бер яңалык, бер байлык бирү өчен генә җибәреләләр...

Әмма калганнары, шул мөстәсна даһилардан башкалары, гомер буена мохит вә язмышның колы булалар. Язмыш ни куша – анлар шуны кыйла; мохит ни сөйли – шул канун була; мохитның биргән тәэсире анларга табигать булып китә.

Мәрьям дә шундый колларның берсе.

3

Аның эчендә яшәгән мохиты ике катлаулы: берсе, өстке вә ераграк катлавы – авыл тормышы, икенчесе һәм аңа тәмам якын булганы – Гәрәй мирзаның хәрәме[2].

Бу ике катлау бер-беренә тәмам башкалар, һәм Мәрьямгә тәэсирләре, мөнәсәбәт вә якынлыклары да төрлечә.

Ул бик яшьтән үк мохитның шул ике катлавы арасындагы аерманы күрә килде, һәм күрмәскә мөмкин дә түгел иде.

Менә ике биек тау арасына салынган зур гына авыл! Әнә шул авылның баштанаяк иске вә черегән, саламга күмелгән, мискиннәрчә иелеп, җиргә сеңгән, аяныч биналары! Әнә шул аяныч өйләрнең, бөтен дөньяга кул селкеп, хәяттан өмит өзгән бичара мәзлумның үлек вә томанлы күзләре шикелле карый торган караңгы тәрәзәләре... Әнә, үзенең шул хәленә исергән кебек, бүрекне кырын салып, җыртык бишмәтнең кесәсеннән кызыл яулыкның очын тышка салындырып йөри торган көяз вә мөтәкәллиф[3] егетләр... Әнә, он иләргә иләк биреп тормаган өчен, өч көн, өч төн әрләшергә, талашырга хәзер торган гайбәтче хатыннар...

Әнә иннек, кершән белән кызыл читле шәлдән башканы кайгырта белмәс шикелле тоелган кызлар... Тагы шундый бик түбән вә бик артык матди булган, күрер күзгә тупаслык вә прастуйлык диңгезе шикелле күренгән ямьсезлекләр, ямьсез нәрсәләр... Менә аның мохитының тышкы кабыгы, беренче катлавы шундый.

Ләкин Гәрәй мирзаның хәрәменә керсәң, эшләр бөтенләй икенче төрле күренә.

Гәрәй мирза! Бу исем үзе үк аны белгәннәр кашында да бик куәтле ишетелә вә бик күп зурлыкларны аңлата. Ул – мирза; өстәвенә бай да; тумыштан ук куәтле,

---

[1] *Мөстәсна* – башка кешеләргә охшамаган.
[2] *Хәрәм* – чит кешеләр кереп-чыгып йөрми торган йорт.
[3] *Мөтәкәллиф* – кирәксезгә кыйланып йөрүче,

мөтәкәббир һәм тирә-ягыннан өстен булырга дип яратылган шикелле, мөмтаз кыяфәттә бер адәм.

Ул гомерендә дәүләт хезмәтләреннән һичберен алмады, ил тарафыннан сайланып куелган урыннарны да рәд кыйлды; шулай булса да, тирә-якның зур эшләре Гәрәй мирзага киңәштән, аның ишарәсеннән башка эшләнми иде. Ул үзен малдан, акчадан югары тота – шуңа күрә бик юмарт та. Халык юмартлыкка мисал урынында «Гәрәй мирза кебек һиммәтле» дип сөйлиләр. Бу хәл аны тагы берничә мәртәбә күтәрә. Аның халыктан югарылыгын бигрәк тә ныгыта төшә.

Тирә-якның түрәсе, мулласы – бар да аның җиле искән якка авалар. Могтәбәр дигәннәре дә аңардан уза алмый, бөтен тирә-якның үз алдына утар тотып яткан алпавытларын халык, көлеп, «бөлгән баяр» дип атадыгы хәлдә, Гәрәй карт хакында һәр җирдә «зур тора» дип сөйлиләр. Шул ике сүз белән ул озын буйлы, калын гәүдәле, чал сакаллы карт мирза арасында бер мөнәсәбәт бар шикелле тоелган кебек, «зур тора» дигәч, аның тормышының халыкныкыннан өстенлеге, нмтиязы да бөтен тәфсыйлаты белән күз алдына килә.

Һәм, вакыйган да, ул, авылларга караганда, әллә ничә мәртәбә «зур тора».

Аның әллә нинди буяп, чибәрләп салынган зур өйләре – авылның җиргә сеңеп, юк булырга торган кебек, мескен вә аяныч биналары уртасында, падишаһ сарайлары шикелле, үзләренә тиң тапмыйча, башларын мөтә-кәббиранә күккә күтәреп утыралар. Аның йортындагы каралтылары да бөтен авылга, монда безгә тиң булырлык нәрсә юк дигән шикелле, өстән, мактанып карыйлар.

Картның бик зур мәшәкать белән камиллеккә ирештергән зур, бай, матур бакчасы, андагы зур агачлары, гөл вә җимешләре* генә дә аны башка һәммә адәмнән әллә ничаклы аера вә югары куя.

Аның атлары, арба, чаналары, ызбруйлары да бөтенләй башка – яхшы һәм мөмтаз[1].

Авылның бер төрлерәк адәме, аның өйләренә керсә, бер яктан, каушап, юлын яза, икенчедән, анда булган «ят, матур әйберләр»гә карап, исе китә, һәм шулай булырлык та.

Авылның баеракларыннан саналган Гыйлаҗилар, Шәмсиләр белән чагыштырсаң, бу өйдә ниләр генә юк! Иң элек күзгә чалына торган зур-зур көзгеләр, авыл халкы төшендә дә күрми торган матур урындыклар, өстәлләр, кәнәфиләр дисеңме, мең төрле әйберләр белән тутырылган пыяла капкачлы зур шкафлар, әллә нинди ят вә мәһабәт тавыш чыгара торган зур сәгатьләр, диварда тезелгән ят күренешләр, нигә икәне бер дә аңлашылмаган вак-вак бүлмәләр

---

* Авторда – «*йимешләре»*.

[1] *Мөмтаз* – менә дигән, шәп, аерылып тора торган.

дисеңме, – белмәм, тагы шундый, берсе дә караңгы авылда ияләшелмәгән әйберләр, әллә ниләр, әллә ниләр, әллә ниләр...

Мәрьям исә шул зиннәт, шул бай тормыш эчендә туды, күзе ачылып, иң әүвәл дөньяга карау белән шуларны күрде, шулар белән булды, шуларга ияләшеп, шуларга өйрәнде, үзләнде. Һәм шул аның рухына, тирә-як дөньяга карашына, мөнәсәбәтенә зур тәэсир бирде.

Атасының бөтен тирә-якта дан тоткан Гәрәй мирза булуы, эчендә яшәгән гаилә тормышының башкаларныкы белән чагыштырылмас мәртәбәдә югары вә мөмтаз торуы аны Мәрьям генә түгел, Мәрьям туташ ясыйлар вә, үзенә белдермәслек юллар белән тәэсир итеп, аны мохитның киң вә ерак катлавыннан суыта, ераклата вә, башка дөньядан биздереп, шул икенче мохитның даирәсеннән читкә чыгуны бөтен табигате белән үк теләмәслек бер хәлгә якынлаталар. Бу хакта Фатыйма бикәнең тәэсире бигрәк тә зур иде.

Ул үзе – кала кызы. Калада туып, калада үсте. Ул бөтен табигате белән каланы ярата, – шул дәрәҗәдә ки, Гәрәй мирзага иргә килеп, утыз еллар торса да, авыллаша, авыл тормышын үз итә алмады. Монда аңа һәммә нәрсә кара, караңгы, ямьсез, артык прастуй вә артык тупас күренә. Ул ирен гомер буенча калага күчәргә димләде. Ләкин, дөньяга ачык күз белән карап, һәрнәрсәдән бик тиз гыйбрәт алырга кабилияте булган карт мирза бикәсенең бу сүзенә каршы күп бәхәскә керешми, тик, мәсьәләнең бөтен рухын аңлатып бетәрлек бер җөмлә тапкан адәм сыман:

– Шәһәрне макта, авылда тор! – дип җавап бирә, шуның белән моназара да туктый иде.

Фатыйма бикәнең шул бикәлеге Мәрьямнең хәятында бик мөһим роль уйнады. Ул болай да, авыл тормышыннан суынып, үз гаиләсе эченә бикләнү ягына ауган кызы Мәрьямне бар көче белән шул тупас мужик кызлары белән катыштырмаска, уйнатмаска тырышты, мөмкин кадәр анларны китермәскә, Мәрьямне анда җибәрмәскә юллар карады.

Аның өст-башын тәмам калача, каланың да мирзаларынча ясый, юк-бар балаларга катышып пычранмасын, тупаслыкка өйрәнмәсен, әдәпсез сүзләр ишетмәсен өчен, аның тирә-ягын мең төрле уенчыклар белән тутырып ташлый иде.

Мохит шуңа таба юнәлдергәне шикелле, табигать тә бикәнең ярдәменә, теләгенә каршы бармады. Мәрьям тумыштан ук артык шау-шуны, көтү-көтү балалар белән җенләнеп уйнап йөрүне яратмый. Ул, тынрак, рәхәтрәк бер кызык булса, шуңа канәгатьләнә иде.

Һәм шул саядә[1] бикә үзенең Мәрьямен, Мәрьям туташлыкка хәзерләп, авыл тормышының «тупаслыгыннан һәм ямьсезлегеннән» тәмам, тәмам аера алды. Вә шул саядә Мәрьям туташ, мохитның тышкы катлавыннан тәмам эчкә тартылып, Гәрәй мирза хәрәменә бикләнеп калды.

4

Аның рухына дәхи бер хәлнең зур тәэсире булды: Фатыйма бикәнең туган-үскән каласы «...» болардан илле генә чакрым җирдә. Анда аның кардәшләре, якыннары бик күп. Елында берничә мәртәбә анлар килә. Мәрьям исә, анларга барып, һәр ел айга якын гомер үткәзә. Ул анда, әлбәттә, кунак. Кунак булгач, аңа шәһәрнең гел кунаклык яклары, сый-хөрмәтләре, бизәк вә матурлыклары, ялтыравыклары күренә.

Яшь үскән саен боларның тәэсире тагы көчәя бара..,

Ул бара калага. Күрә: караңгы авылга караганда бөтенләй икенче дөнья. Нинди йортлар, нинди кешеләр... Һәммәсе матур, һәммәсе чибәр. Бар да яхшы киенгәннәр... Өй эчләренә керсәң дә, бөтенләй башка. Аш-су дигәнең, кунаклашулар дигәнең, бакча-фәлән дигәнең, – хасыйл бар да күрер күзгә үк чибәр торалар... Тагы нинди уеннар, нинди кызыклар...

Ул русча артык аңламаса да, кардәшләре белән ёлкаларга, балалар спектакльләренә, театрларга бара... йа Ходай, нинди матурлык, нинди кызык!.. Авылда бит боларның берсен күрергә зар булырсың... Шәһәрнең шул ялтыравыклары эчендә ничә атналар яшәп, авылга кайткач, аңа дөнья тарайган төсле була. Хәятында бушлык, тарлык сизелеп, үзен әллә кая җепсез бәйләп ташланган адәм кебек тоя. Бу хәл аны авыл тормышыннан тагы да ераклата; анларның үз хәрәмнәре теге шәһәрдә күреп кайткан шәп дөньяның күләгәсе шикелле хис ителеп, ул тагы ныграк шуның эченә бикләнә.

5

Зыялар байлык ягыннан, Гәрәй мирзадан кала, авылда беренче булып, нәселенең, бигрәк тә Зөләйха абыстайның тәэсире сәбәпле, дөнья көтүдә, яшәүдә, нәзакәт вә тәрбиядә башка халыктан байтак югары торганга, Фатыйма бикә өчен якыннан катышырлык һәм кызын анларга катышудан тыймаслык бер гаилә бар исә, һич шөбһәсез, шул Җәләл мулла гаиләсе иде.

Һәр ике гаилә күптән үк бик дустанә яшәп килә. Бикә белән остазбикә күптән үк ахирәтләр. Табигый, бу ике гаиләнен балалары да бергә булачаклар. Фатыйма бикә кызының авыл баласына катышмавын күрсә, узе шуна тәэсир итсә дә, муллалардан тыярга һичбер лөзүм тапмады.

---

[1] *Шул саядә* – шуның аркасында, нәтиҗәсендә»

Вакыйган, бала бит, аны мәңге бикләп булмый. Аңа, һич будмаса, бер иптәш кирәк.

Менә шул иптәшлек тә Зыяда табылды.

Җәләл мулланың өлкән угылы, Сабир, яшькә дә зуррак; аннан соң, ул бөтен табигате белән бала төсле үк түгел; ул, ахры, уйный да белми, уйнаса да, кызларга, үзе кебек малайларга катышмый, гел зурлар арасында чуала. Шунлыктан Мәрьям һичбер хәлдә аңа якынлаша, аның белән уйный алмый, хәтта бераз курка да иде. Зыя исә бөтенләй башка. Ул бервакытта да шаулашып, көтү-көтү булып уйнаган малайларга катышмый, гел бер үзе яисә үзе сыман бер иптәше белән тын гына үткәрелә торган бер уен артында утыра. Ул юаш, ул йомшак; үзе һичбер авыл малаена чагыштырылмас мәртәбәдә пакь кенә, чибәр генә киенә; яше дә Мәрьямнән ике елга гына зур булып, бөтен табигате белән инсафлы кызлар шикелле күренә: йомшак сөйли, йомшак мөгамәлә кыйла... Тагы үзе әллә нинди сөйкемле, аны кызлардан да болай яратырлык, аны гел яратасы, дус итәсе килерлек. Ул гүя йөрәгеңә кереп бара, бер очрашуда ук күңелең аңа якынлашуны теләп тора. Шуның өчен дә Мәрьямгә бу мохитта Зыядан башка иптәш булырга мөмкин түгел иде. Шуның өчен дә ул уен дигән, бергә уйнау дигән нәрсәне белә башлаганнан бирле, үзен Зыяга бәйләнгән кебек хис итә башлады.

Зыя белән бергә булу аның нәзакәтенә тими, аны үзенең хәрәменнән теге тупас дөньяга чыгарга мәҗбүр итми, Фатыйма бикә дә аны Зыя белән күрүгә бик шат. Шунлыктан ул, башка дөньядан тагы бер мәртәбә өзелеп, барлык гомерен йә үзләрендә, бакчаларының агачлары, гөлләре арасында, йә үзләренең икенче басмасы шикелле булган Җәләл муллаларда, ләкин һәр хәлдә Зыя белән бергә вә һәрвакыт аның белән икәү генә үткәрә башлый. Бу вакытлар анларны берничә айга аеру, йә башка бертөрле дустлыкларын җимерү – бу Тәңренең әзәлдә һәдия иткән[1] бер кодсиятен[2] явыз кул белән юк итүгә охшар иде, һәм һәр ике мәгъсумне[3], белмәм, нинди зур вә нинди мөкаддәс бер сәгадәттән мәхрүм кыйлу булып чыгар иде.

Саф вә мәгьсум балалык, фәрештәдәй ике вөҗүднең шул мәсәлсез кыйммәтдар сабыйлык дәвере, пакь вә голүви[4] мөнәсәбәт белән, илаһи бер күренеш шикелле узып китә.

Якынлаша бәлагать. Шул һәм Тәңренең бу кодсиятенең дөньяга күренүенә пәрдә була.

---

[1] *Әзәлдә һәдия иткән* – элек-электән бүләк иткән.
[2] *Кодсият* – изгелек, яхшылык.
[3] *Мәгъсум* - гөнаһсыз
[4] *Голүви* – бөек.

6

Бәлагать[1] килде. Шуның белән бергә мохит анларга: сез «нәмәхрәмнәрсез» дип игълан итте. Буның әүвәлге күренеше байтак ук мөәссир[2] дә.

Зыяның, унөче тулып, яңа ундүрткә чыккан заманы булыр. Ул теге, ахун вә мөдәррис ясый торган мәдрәсәгә китеп, анда тугыз ай үткәргәч, майда өенә кайткан иде.

Мәрьям бу хәбәрне ишетү белән, әүвәлге елларда атна кич күрше авыл мәктәбеннән кайткандагы шикелле, бер нәрсәгә карамыйча, атылып барып керергә дә, аның муенына асылырга-фәлән итәргә фаразы белән анларга чапмак булды, ләкин шул ук минутта әллә нинди бер тойгы аңа бу эшнең ярыймы, юкмы икәнен шөбһәле сыман күрсәтте...

Аның теге дәрт ялкынына салкын су тамган кебек булды, шулай да ул тукталмады, үзе аңлап җитә алмаган бер тойгы тәэсире белән, өст-башын бик аз гына ыспайлады да, азрак оят та, гөнаһ та булыр төсле күренгән бер эшкә ният кыйлган адәм сыман, нидәндер, кемнәндер бераз тартына төшеп, бакча ашасыннан Җәләл муллалар йортына юнәлде...

Туры зур яктан керергә базмыйча, хатыннар ягы ишегеннән барып, өйгә керде. Зур якта байтак кешеләр: Зөләйха абыстай, Сабир, Фатыйма бикә, Бәдри карчык, белмәм, тагы әллә нинди затлар бар иде. Зыя идәндәге паласка сумкасын ачып ташлаган да каладан алып кайткан нәрсәләрен, бүләкләрен актара; һәйбәт, йомшак тавышы белән көлә-көлә нидер сөйли. Мәрьямнең ят кеше шикелле тартыныбрак кына килгәнен күргәч, Зөләйха абыстай эченнән генә көлде дә аңа кыюлык бирер тавыш белән:

– Мәрьям туташ, синме? Ник анда торасың, монда кил, ул синен абыең ич! – диде.

Зөләйха абыстай сүзен бетерергә дә өлгермәде, башта бераз аптырап, икеләнеп торган Фатыйма бикә, берьюлы карарга килеп, кискен рәвештә:

– Куй, ахирәт, ярамас: ул – зур кыз ич инде! – диде.

Фатыйма бикә – мирза хатыны, ул үзе авылның мулла-мәзине белән берничә могтәбәр аксакалыннан башка адәмнән качмый; ләкин үзенең бу эшен әллә ничә катлы нәзариянең[3] үзе дә яхшы аңлап җитә алмаган бер ноктасы белән тәэвилләп[4], шул гадәтен куймаса да, мәсьәлә кызына килгәч, аның мирзалыгы каядыр югала да, утыз ел гомернең биргән авыллашуы, мөселманлыгы җиңеп, Мәрьямгә Зыядан качуны тиеш таба.

[1] *Бәлагать* – җитлегү, буйга җитү.
[2] *Мөәссир* – тәэсирле.
[3] *Нәзария* – дөньяга караш.
[4] *Тәэвилләү* – аңлату.

Шунлыктан ул: «Ярамас!» – ди.
Мәрьям туташ, үзе хакында әйтелгән гыйбарәнең чын мәгънәсен аңламаса да, эченең әллә кай җире белән анасының сүзе кая барганлыгын, «син – зур кыз ич инде!» дигән җөмләнең төбе, нәтиҗәсе нидән гыйбарәт була икәнен сизенде, һәм хәзер баягы «ярыймы, юкмы» хакындагы икеләнүе берьюлы «ярамый»га әйләнгәндәй тоелды. Шундый эчке оялу белән кызарынды да, ни эшләгәнен белмичә, тиз генә йөзен каплап, һичкемгә бер сүз дәшми, атылып, кире чыгып китте.

7

Шул көннән башлап берничә елларгача Зыя белән Мәрьям туташның араларындагы мөнәсәбәтнең фитрәт[1] заманы дип аталырлык бер дәвере керде.
Анлар хәзер бала түгел. Анларның, әүвәлге шикелле, ике дуст рәвешендә бергә уйнавы, бергә йөрүе, хәтта күрешү, сөйләшүе дә мохит тарафыннан зур гөнаһка санала – анлар бер-береннән качарга, хәтта карашмаска да тиеш, чөнки гөнаһ. Анлар яшь. Анларда язмышның бу агымына каршы барырлык куәт юк. Анлар мохитның сөйләгәненә буйсыналар, язмышның шул агымына ятып, бер-береннән тәмам, тәмам өзеләләр, ераклашалар.
Бу өзелү, бу ераклашу, әлбәттә, тыштан гына, тышкы күренештә генә. Әмма анларның эчләрендә бала чакта ук Тәңренең үз кулы белән йөрәкләренә салынган саф вә пакь дустлык әүвәлгедән дә артык куәт белән дәвам итә, дәвам итә генә түгел, тамырларын йөрәкнең әллә нинди эчке вә яшерен нокталарына җибәреп, куәтен арттыра, аз гына җае килсә, хәзер җитешеп, хәят йөзенә матур чәчәкләрен чыгарырга якынлап килә. Анлар һәр икесе, бигрәк тә Мәрьям, буны сизәләр, ләкин бу тойгының теләдеге рәвешчә, шул мөнәсәбәт вә шул дустлыкны бер-беренә белдерергә юлын да, имкянын[2] да белмиләр.
Эчләрендә мөбһәм[3] бер тойгы бар. Ул бер-беренә якынлыкны тели. Ләкин мохит ана: «Ярамый», – ди. Шундый вакытларда адәмнәр яшерен рәвештә мөнәсәбәттә булалар икән, халык күзеннән сакланып катышырга да мөмкин икән, безгә дә шулай эшләргә кирәк, дигән уй анларның башына төшә алмый, чөнки аңа җитә алмаганнар әле. Дәхи төшсә дә, ул эшне башкару рәвешен белә дә алмаслар, яшерен мөнәсәбәтне дөньяга тудыра да алмаслар иде. Чөнки ул мәртәбәдән яшьрәкләр дә, андый нәрсәдән хәбәрләре дә юк. Ике ел шул хәлдә үтеп китте.

---

[1] *Фитрәт* (фәтрәт) – хәрәкәтсезлек, торгынлык.
[2] *Имкян* – мөмкинлек.
[3] *Мөбһәм* – яшерен, билгесез.

Бу, бәлки, артык та дәвам иткән булыр иде, тик Мәрьям туташ өчен яңа галәмнәр ачкан бер хәл – аның «...»дагы кызлар мәктәбенә баруы гына бу авыр вә мөбһәм тәэсирле көннәргә хатимә бирде.

8

Карт мирзаның укуга артык исе китмәсә дә, Фатыйма бикә, бар көче белән, бердәнбер баласы булган Мәрьямне укытырга, уку дөньясына кертергә тырышты. Ул үзе гимназиягә хәзерләнеп тә, атасы вафат булу, соңра ярлылану сәбәпле генә анда керә алмаган, шулай да бөтенләй мәхрүм түгел, русча һәм мөселманча язуларны, халык тәгъбиренчә, «су кебек эчә» иде. Авылның караңгылыгын, тупаслыгын күргән саен Мәрьямне укыту дәрте көчәеп китә, шунлыктан ул үзе шикелле зирәк булуына ачык ышанган кызын бала чагыннан ук теге каладагы мирза балаларынча тәрбия итәргә хыяллый, укытырмын, әлбәттә, укытырмын, шуның аркасында аны, ничек кенә булса да, бу ямьсез һәм кара авылдан коткарырмын, калага бирермен, дип өмит итә иде. Һәм шул хыял, шул өмит белән ул, кызы уннарга якынлашкач та, карт мирзага баланы кыш көне шәһәргә җибәрү, укыту хакында сөйли башлады. Ул эченнән кызын бервакыт гимназистка итеп күрүне хыялласа да, иренә буны әйтергә батырлык кыйла алмый, башта калага барсын, аннан соң башкалары үз җае белән булыр дип җуана иде. Ләкин карт боларның беренә дә якын килмәде. Эчендә ни булгандыр, әмма тышыннан хатынына кыска рәвештә: «Юкны сөйләмә!» – ди дә, теге дәлилләре, күз яшьләре белән аптырата башлагач, үз фикеренә куәт булырлык нәрсәләрен китерә иде.

Ул Фатыйма бикәнең кардәшләре белән бу елларда бик җитди рәвештә үпкәләшкән иде. Шунлыктан анларга бармый, катышмый; Мәрьям – бала, аны укырга дип калага җибәргәндә, әлбәттә, анлардан башка җирдә тоту мөмкин түгел; ләкин карт күңел бу ихтималны аслан якын китерми: булмас, анда ул кызын жибәрмәс!

Бикә буңа каршы елап, игътиразлар кыйлса[1] да, ире, теге Сәлах мирза кызының, алтынчы класс гимназиядә чагында берәүгә алданып, чукынуын, тагы әллә кем кызларының, укып-укып та, ни урынга керә алмый, ни кияүгә бара алмый, гомергә карт кыз булып йөрүләрен-фәләннәрен сөйли башлагач, ирексез җиңелә һәм туктый иде. Ләкин бу туктау, бу җиңелү коры сүздә җиңелүдән гыйбарәт улып, ул эченнән һаман теге фикерендә кала иде; әллә кемнәрнең карт кыз булып гомер итүләре, әллә нинди Раузаның бер урыска алданып чукынулары аны асла куркытмыйлар, читләргә теләсә нинди хәл булсын, Мәрьямгә андый куркынычның асла вә асла килү ихтималы юк, – ана, Фатыйма

---

[1] *Игътираз кыйлу* – каршылык күрсәтү, протест белдерү

бикә, буңа үзенең мәхәббәт илә тулган аналык йөрәге белән бик чыннан ышана; шуңа күрә картының киреләнүен урынсыз саный иде.

Ләкин ни эшләмәк кирәк, ир булгач ир инде, аңардан узып, аның дигәненә каршы барып берни дә кыйла алмыйсың!

Айлар, еллар елап та сүзе алынмагач, ул каладагы кардәшләреннән берәүнең бик мактавы, гимназиялардән бер дә генә ким түгел ичмаса дип сөйләве буенча, Мәрьямне шул заманда кызлар өчен булган татар мәктәпләреннән иң яхшысы саналган «...»дагы мәктәпкә җибәрергә уйлады. Мирза да буңа карышмады.

Бу вакыткача Мәрьям русча вә татарчаны Зөләйха абыстайдан, авылның учителеннән һәм анасыннан өйрәнеп, яхшы гына укый да, яза да белә иде.

9

Кызлар мәктәбенең аңа тәэсире зур булды.

Ул анда, аңлы, ачык карашлы кызлар, китаплар, сөйләнгән яңалыклар эчендә, үзенең кызлыгын, кыз йөрәклелеген сизә башлады. Шуның аркасында, балалыкның соңгы елларында була торган дәвердән чыгып, ачыктан-ачык кызлар ягына аерылды, һәм шуның илән бергә, аның Зыяга мөнәсәбәтендә булган фитрәт заманы бетеп, ул гомерендә беренче мәртәбә үзенең аңа мөнәсәбәте бер кызның бер егеткә булган багланышы рәвешенә керә башлаганын сизенде.

Ул табигате белән үк үзе белмәгән караңгы вә яшерен дөньяларга, хыял галәмнәренә тартым. Шунлыктан үзләрендә бала караучы булып торган Бәдри әбинең шома вә килешле рәвештә сөйләгән әкиятләрен бала чагында бик яратып тыңлый, анда ничаклы куркынычлар-фәләннәр сөйләнсә дә, бер дә бизенми иде. Укырга өйрәнеп, китаплар аңлый башлагач, өйләрендә ничаклы тарих вә хикәя рәвешендә язылган әсәр булса, барын кат-кат укый иде. Зөләйха абыстанлардан алган «Таһир-Зөһрә», «Бүз егет»[8*], «Йосыф китабы»ннан[9*] башлап «Алты бармак»ларга[10*], «Рабгузи»ларгача[11*] – һәммәсе аның күзеннән әллә ничә мәртәбә кичкән иде.

Кызлар мәктәбенә баргач, аңа китаплар бабында бөтенләй икенче дөнья кәшеф ителде[1]. Анда татарча эт бетергесез хикәяләр, кыйссалар өстенә, бик тәмләп вә бик баллап язылган төрек романнарының да исәбе-хисабы юк иде. Мәрьям, килүе белән, шуларнын эченә чумды да китте.

Әйтәләр: ул дәресләрен, зирәклеге аркасында, бер кат укып чыгу белән, сыйныфта җавап бирерлек хәзерле иде дә, аннан соң, үзе ала-чола аңлаган төрек романнарыннан көннәр, төннәр башын ала алмый утыра иде, дип. Һәм вакыйган, бунда килеп, бер мәртәбә тәмнәрен татыганнан соң, шул баллап

[1] *Кәшеф ителү* – ачылу.

язылган төрек романнарын уку төзәлмәс бер чир хәленә яки рухының бертуктаусыз теләп тора торган бер ризыгы (азыгы) рәвешенә әйләнеп китте.

Менә болар аның йөрәгендә уянган теге кызлык тойгысын куәтләттеләр генә түгел, Мәрьямне шул барлык гомерләрен гыйшык белән уздыра торган кыз-каһарманнарның берсе, беренчесе кебек хис иттерә башладылар – теге балалыктагы дустлык икенче сыйфатка керде.

Ул кайсы романны укыса, шуның кыз-каһарманын үзенә охшата вә үзе дә шуның кебек булырга уйлый: Халид Зыяның[12*] «Нәмидә»сен укыганда ул, әлбәттә, Нәмидә була; «Фәрди вә шөрәкя»сен укыса, әлбәттә, Һаҗәр була, ләкин аның кебек бәхетсезлеккә очрамый, бәлки сөюенә каршы сөелә һәм барлык гомерен бәхет белән, романнардагы кебек матурлыкта үткәрә.

Аның каршысында исә теге романнардагы Наилләр, Исмәгыйль Тайфурлар-фәләннәр урынына Зыя тора. Ләкин ул теге каһарманнардан башка. Анлар кебек, бераз сөйгәннең соңында моны ташлап, күңелен икенчеләргә бagламый; анлар кебек ялындырып яисә үпкәләп тә йөрми. Ул аның мәңгелек дусты, гомерлек юлдашы. Ул бертуктаусыз үзенең матур күзләре белән Мәрьямгә карый да, бик аз гына елмая төшеп, йөрәгенең әллә кай җиреннән кайнап килгән бер тойгысын сөйли – матур тавышы белән, Мәрьямне дөньядагы һәммә кешеләрдән артык сөйгәнен, аның эчендәге гыйшык диңгезе тик Мәрьямгә генә гаид, аңа гына махсус икәнен сайрый: «Аһ, Мәрьям, белсәң, мин сине ничек сөям!» – ди.

Бу аңа даими булган тәсбих; бу аңа сөйгән йөрәкнең лазем иттеге вирд вә зикер!![1]

Шунын өчен ул буны туктаусыз тәкрар итә.

Менә Мәрьямнең яшь йөрәге теге бала чактан ук яратып килгән, йөрәгеңә керергә барган, бер күренү белән күңелеңә мәхәббәт салган теге матур йөзле, йомшак тавышлы, йомшак вә сөйкемле мөгамәләле Зыя хакында шундый яңа бер тойгы саклый, хыялы аны шундый күренешләр белән чолгый иде. Шуның тәэсире уларак, Мәрьям, тәмам бер кыз-каһарман кыяфәтен алып, дусты Зыяга хат язды... Илаһи, бу беренче адымда беренче мәктүбне язуда, җибәрүдә, теґеннән җавап килгәнче үткән озын төннәрдә яшь йөрәкнең кичергән шөбһәләрен, тойган тәрәддетләрен[2], дулкыннарын, бертуктаусыз алмашып торган ышану, шатлану һәм көенүләрнең ни мәртәбәгә җиткәнен, бер Ходай, үзең генә белерсең...

Зыядан дустлык җавабы килгәннең соңында, назик җанлы, гашыйк күңелле вә

---

[1] *Вирд вә зикер* – догалар һәм изге теләкләр.
[2] *Тәрәддет* – шик-шөбһә.

хыялый табигатьле туташны әллә канларга, әллә нинди җәннәтләргә, җиденче кат күк илә гарше көрсиләргә[1] алып очкан ниһаясез сәгадәт ташкыннарын аның башы да сыйдыра алмый; чикләп вә тәгъбирләп уйларга зиһене дә тәкать китерә алмый иде.

10

Кызлар мәктәбендә Мәрьям туташ ике ел булды. Әлбәттә, дәрес вә фән исеменнән әһәмият биреп укыган нәрсәсе юк иде. Ул монда гомерен йә башындагы, йә әдәбияттагы хыялят[2] белән уздыра иде. Ул, әлбәттә, тагы берничә ел йөриячәк, киләчәк иде, чөнки аңа монда үз иреге үзенә бирелә, хыялы, табигате үз теләгәнен һәрвакыт таба ала иде дияргә мөмкин, ул монда үзе теләгән хәятта иде. Ләкин, аның да, башкаларның да зур бәхетсезлегенә каршы, көтелмәгән бервакытта бу мәктәпне хөкүмәт ябып ташлады.

Буңа бик аптырадылар; хикмәтенә төшенә алмый интегеп беттеләр. Тышкы якта сәбәп булып күренгән нәрсә исә шул иде:

Бу мәктәпне вөҗүткә китерүче имам – Сафый мәхдүм Төркия вә Мысырда йөреп кайткан адәм. Ул үзенең башын шул яктан килгән тәрәккыяте фикрия агымына бирә. Хатынын төрек вә гарәб матбугаты белән тәрбия итеп, бер мәктәпне тәрбия кыйлырлык хәлгә китерде, һәм аның янына Төркиядән, анда туып, анда мөгаллимәлек мәртәбәсенә укыган бер татар кызы алдырып, шул икенең кулына мәктәпне тапшырды. Мәрьям туташ мәктәпне роман вә әдәбият дөньясы итеп күрсә дә, күбрәкләр, бигрәк тә яшь вә нык кызлар, монда андый гыйшык романнары барын да җүнләп белми; күбе бу мәктәпне вә ул мөгаллимәләрне күктән төшкән бер хәзинә кебек белеп, зур әһәмият илә дәресләрендә булалар иде. Мөрәббиләр[3] Төркиядән килгән яисә шуның тәэсиренә бирелгән адәмнәр булса да, монда, әлбәттә, Кара диңгез арты белән бертөрле дә якынлык, мөнәсәбәт белдерелми, тик аның мәгълүмате бирелә иде. Ләкин дошманнар буны аңламаганга салышты. Сафый мәхдүмнең, читтән кайтып мулла булганның соңында, борыннан тирә-якны кулларында тоткан данлыклы муллаларның өстләренә чыгуы, халык аның ягына авышып баруы күпләрнең эчен яндырды, күпләрне аның зарарына торгызды. Шуның нәтиҗәсе уларак, хөкүмәт колагына Сафый мулланың үзе дә, кызлар өчен булган мәктәбе дә падишаһлыкка каршы нигезләр өстенә корылган дип ирештерелгән. Шул эш тентүләргә, тикшерүләргә сәбәп булып, ахырда мәктәпнең ябылуы, мөгаллимәнең куылуы белән тәмам кылынды.

---

[1] *Гарше көрси* – динчеләр фикеренчә: күктәге тәхет.

[2] *Хыялят* – буш хыяллар, фантазия.

[3] *Мөрәбби* – тәрбияче.

Кызлар, туташлар, күтелмәгән бу афәттән кан аглар мәртәбәдә[1] мөтәәссир булып, кышкы чилләдә илләренә таралыштылар. Мәрьям дә, башка һәр нәрсәдән бигрәк теге матур күзле, гүзәл мөгамәләле, әллә нинди нечкә хисләр сөйли торган төрек мөгаллимәсеннән һәм дә үзенең хыялятен бик иркәләп тәрбияли торган роман вә әдәбият дөньясыннан аерылуына тәәссеф итеп[2], өенә китте.

Әлбәттә, башка җиргә, башка мәктәпкә бармады, шуның белән укуын тәмам кыйлды. Бу вакыт Мәрьям туташ җитү кыз булып килмәктә иде.

11

Шуннан соң башлана Мәрьям өчен авыр һәм борчулы көннәр! Ул бикәнең бердәнбер туташы. Назлы, кадерле. Ул кыр вә иген эшләренә түгел, өй эчендәге хезмәтләргә дә күп катышмый. Аның «эш вә шөгыль» намына бары бик аз гына тегү-чигүе бар. Вакыт күп; көннәр дә, төннәр дә озын. Ә мәҗбүри булган яисә күңел кызык тапкан даими бер хезмәт юк. Ул шәһәрдә булса яисә үзе күңел биреп, кызык табып катышырлык, йөрешерлек адәмнәр белән торса, әлбәттә, бу бушлыкны сизмәс; уены булыр, җыены булыр; берәүгә барыр, берәве килер, – шулай итеп гомер кичерер иде. Ә монда кемгә барасың да кемне чакырасың... Өйдә тик анасы бар. Авылда бердәнбер якын күрә торган Җәләл мулла гаиләсенә керсәң, Зөләйха абыстай бар. Ашын ашаган, яшен яшәгән бу ике карчык белән ни сөйләшәсең дә, ни кызык табасың. Анларның нинди сүзе, нинди эше яшь йөрәккә бернәрсә бирер! Башкаларын әйтмисең дә инде...

Авылның һәммә егетләре Мәрьям туташны күргән саен: «Ах, туташ... сине!» – дип, дәртләренә чыдый алмый калсалар да, һичбере, яңлыш кына да, аңа бер мөнәсәбәт бәйләргә уена китерә алмый. Анлар кашында Мәрьям әллә кая югары: ул гүя җиргә төшеп, адәм сурәтенә кергән фәрештә; әгәр дә бер җүләре, моны аңламыйча, үзенең байлыгына, йә матурлыгына мәгърур булып, Мәрьямгә мөнәсәбәт гарыз итсә[3], туташ, ни эшләгәнен белмичә, януыннан чыдый алмый, зур ялкын белән: «Кит, падлец![4]» – дип кычкырыр иде дә хурлыгыннан, әрнүеннән ничә көннәр аглар иде.

Ләкин, әлбәттә, мондый эш булмады.

Авылның кызлары белән ике ара да шуңа охшашлы бер хәлдә иде. Мәрьям туташ үзенең табигате: әчке мохите, анасы, мәктәп, әдәбият, мөгаллимә, тагын шундый бик күп нәрсәләр тәэсире белән үзен болардан әллә кая югары

[1] *Аглар мәртәбәдә* – елар дәрәҗәдә.
[2] *Тәэссеф итү* – үкенү.
[3] *Гарыз итү* – белдерү, сиздерү.
[4] *Падлец (подлец)* – адәм актыгы, хәсис.

мендергән, боларның барыннан читләшкән, ераклашкан, хәтта, теләсә дә, эчке бер мөнәсәбәт, җылылык булмаслык мәртәбәгә килгән. Ул үзен шуңа мөнасиб[1] тоткан кебек, авыл кызлары да буны бик яхшы сизәләр; шуңа күрә аны үзләренә тиң итәргә батырлык кыйла алмыйлар; бик байлары, бик мәгърурлары гына туташны кызлар мәҗлесенә-фәләнгә чакырырга җөрьәт итә алса да, күп гомерен ата-анасының боерыгында, дүрт дивар эчендә уздыра торган авыл кызының көтеп ала торган бәйрәмнәренә – каз өмәләренә, кыр эше өмәләренә, аулак өйдәге җыелышларга, тула басу җыеннарына, әлбәттә, чакыра алмыйлар. Чөнки ничектер бу эшләр белән Мәрьям туташ арасында бик аз гына да мөнәсәбәт юк төсле тоела.

Шулай итеп, ул авылда кайнап торган халык эчендә ялгыз яши, ялгызлык тоя.

Көндез тагы бер хәл. Әмма соң көзнең озын төннәрен үткәрү – ах, тик бер Ходай белә, – аңа ничаклы авыр! Зур өйләр, катлаулы-катлаулы бүлмәләр; кич белән анларның күбесендә ут та яндырылмый. Тәңре үзе генә белсен, ул караңгы бүлмәнең тын, куе караңгылыгы эчендә озын төннәрдә нинди серләр, нинди яшеренекләр сакланадыр... Көндез Фатыйма бикәгә берәү керә, берәү чыга. Шулай итеп аның күзе җанлы әйберләр, кузгалышлар күрә; шулар аз булса да аны ишгаль кыйлалар. Әмма төндә, әмма төндә! Ходай өчен берсе генә дә керми! Ялчы үзенең хатыны белән, караңгы төшеп, арлы-бирле итүгә, тышкы ишеккә якын бүлмәдә йокыга китә. Бераздан Бәдри карчык та тына. Ястүдән соң, бер парә Коръәнен тәмам итеп, Фатыйма бикә дә рәхәт йокыга бирелә, – менә шуннан соң, әллә нинди караңгы бүлмәләр белән тулган, зур караңгы өйдә Мәрьям туташ бер үзе, тик бер үзе кала.

Төн. Караңгы. Бөтен дөньяда тынлык. Өйдә шылт иткән бер тавыш юк.

Үзен ничаклы көчләсә дә, мондый төннәр аның күзенә йокы китерми. Ул, бүлмәсенә бикләнгән хәлдә, бер яктан, төннең шул серле караңгысына, шул тирән мәгънәле тынлыгына күмелеп; икенчедән, бер авыр, бер борчулы, бер мәсгудиятле[2] булган тирән хыяляткә чумып утыра.

Йөрәк туктаусыз суга. Күңел каядыр ашкына. Хыял бертуктаусыз эшләп, туташны җирдән күккә, күктән гарешкә, аннан тагы, белмәм, әллә канларга алып китә. Каядыр оча, каядыр йөзә; ләкин һичбер хәлдә күз алдыннан бер күренеш китми: ул ни генә хыял кыйлса да, әллә нинди томаннар, караңгылыклар аша матур гына елмаеп торган Зыяны күрә.

## 12

Мәктәптә чагында Зыяга хат язу һәм аңардан килгән хатларны йөзәр, меңәр кат

---

[1] *Мөнасиб* – яраклы, муафыйк.

[2] *Мәсгудият* – бәхетлелек, рәхәтлек.

уку белән җуана торган иде. Зыя – мәдрәсәдә, бу мәктәптә булгач, адреслары билгеле; хатның җибәрелүендә, тапшырылуында һичбер төрле уңгайсызлык чыкмый иде. Ул елларны Зыя өенә дә һәр җәйдә диярлек кайта; бер авылда янәшә йортларда торгач, кеше алдында күрешеп сөйләшү-фәлән мөмкин булмаса да, караңгы төннәр анларны кавыштыра, зур бакчаның куе куаклары, карт имәннәре аларны явыз күздән саклый иде. Бакчаның суга караган башындагы, эче куыш зур имән дә боларның бөтен дөньядан яшерелгән мөкаддәс серләрен саклый, әманәтләрен тапшыручы хезмәтен кыйла иде: кеше аркылы йөртергә теләмәгәнгә, бу бик шөбһәле дә булганга, анлар җәй көне бер-беренә язган хатларын шул карт имәннең эченә куялар һәм шуннан һәрвакыт карап ала торалар иде.

Шулай итеп, ул елларны җәйләр бик хозур үтә иде. Кыш көне дә ул чаклы авыр булмый, чөнки хатлашу кызык бирә иде. Ә хәзер бөтенләй башка. Мәрьям өендә тора. Аның үз адресы белән хат җибәрү һичбер мөмкин түгел, – чөнки мәктүб бикәнең кулына, ихтимал, башка берәүнекенә төшәчәк тә, бөтен дөньядан яшереп килгән мөкатдәс дустлык дөньяга фаш булачак, барлык ләтафәте җуялачак; ихтимал, төрле күңелсезлекләр дә туачак. Шуның өчен аңа Уфадагы кардәшләреннән бер якын дусты аркылы гына җибәрергә мөмкин, һәм шулай итәләр дә. Ләкин бу нинди кыенлы, нинди озакка тартыла. Кайбер чакта, Ходай үзе саклый күрсен, югалып калуы да ихтимал.

Икенче яктан, Мәрьям үзе язган хатларын да авылдан җибәрүдән бик зур кыенлык күрә. Бу авылда почта кантуры, ящигы юк, волостьлы авылга җибәрергә кирәк; анда кем артыннан җибәрәсең, белсәләр – нинди зур хәтәр! Җитмәсә тагы Зыя мәдрәсәдән чыккан да: «Дүрт ягым кыйбла!» – дип, әллә кайларга йөри тора, күчә тора, адресы алмашына, кайбер хатлар югалып та кала...

Һәр нә төрле яктан кыенлыклар, кыенлыклар, кыенлыклар тулы. Бер Ходай үзе генә ярдәм бирсен!

Айлар, еллар шул хәлдәгечә тора.

Зыяның каралачак көзенең алдынгы елы, бигрәк тә көзе Мәрьям өчен тагы күңелсезрәк булды.

Ул кыштан артык курыкмый. Аның ак, саф кары, таза вә куәтле суыгы Мәрьямгә бераз матди хәятны аңдыра, дөнья барын, анда Мәрьямнең хыялына башка эшләр булмакта икәнен хис кыйлдыра – хыялны тарайта, тышкы дөнья белән бераз бәйли. Әмма көз дигәнең бигрәк яман.

Җәйге матурлык бетә. Үләннәр корый. Агачлар кара, ялангач калып, актык яфракларын коярга хәзерләнәләр. Җире, күге – барлык нәрсәләре сиңа ачулы,

чытык йөз белән карыйлар. Иртән торып, алай-болай итәргә өлгерә алмыйсың, көнең үткән була – төн килә. Менә авыр, менә борчулы, менә, илаһи, эч пошыргач заманнар!

Тышкы дөнья вә мохит белән бәйләнеше бик аз булган Мәрьямгә елның бу дәвере аерым бер күңелсез тәэсир бирә. Ул, әллә нәрсә эзләгән кебек, зур өйнең аулак, караңгы бүлмәләрендә йөри-йөри дә, җуанырлык бер нәрсә дә тапмагач, башын кая куярга белмичә, бүлмәсенә кереп бикләнә...

Ашыйсы килми, эчәсе килми; кул һичбер эшкә бармый, хәтта әдәбият та биздергән... Баштанаяк гыйшык сайрый торган теге матур, тәмле романнар да туйдырган... Әнә ята «Әлфе ләйлә вә ләйлә»ләре, әнә Әхмәд Рәсимнәре [13*], Кәмаллары[14*] Гошшакый-задәләре[15*]… Әнә диварда асылып тора нинди матур күренешләр... Әнә айлы кичәдә ике гашыйкның бер-беренә сарылышкан хәлләрен күрсәтә торган тирән, серле, кадерле рәсемнәре... Әнә тагы шундый бик матур рәсемнәр белән тулы һәйбәт альбомы – бары да бар, ләкин һәммәсе туйдырган, һәммәсеннән бизелгән... Берсен кулга аласы, тотасы килми...

Йөрәк суга, күңел каядыр ашкына... Эч поша, поша, поша... Әллә нәрсә җитми, нидер тулмый... Хәятның әллә кай җирендә бик зур бушлык бар... Мөмкин булса да, җан эстәгән нәрсә табылып, шул бушлык тулса, бәлки бераз җиңеләер, тынар иде... Юк шул, юк!

Мөмкин булып та, балаларча бик әрнеп, бик өзелеп, бик озак еласа, бәлки, бераз ару булыр, эче бушар иде, ләкин ул да булмый, ул бәхет тә килми.

Шулай итеп, шул тойгылар, шул тәэсирләр эчендә, шул диңгезнең туктаусыз дулкынына охшаш шөбһәләр, әрнүләр эчендә, уяулы-йокылы бер хәлдә, төрле саташулар белән төн үтеп китә.

Ул иртән ватылып, изелеп тора.

Баш талган, томанланган; йөрәк хәлсезләнгән; эчтә кичәге борчылуларның тик ачы калдыклары гына бар. Бөтен тән кыйнап ташланган кебек бер халәттә. Буны бар да беләләр: һәм бикә дә, башкалар да:

– Сиңа ни булган? Әллә авырыймсың? – дип җанын алалар.

– Башым авырый, – ди, ләкин тагы аптырый; сораучыларга ачудан әрни башлый. Эченнән сызланып: «Җә инде, Илаһым, боларның миндә ни эше бар икән?!» – дип, кан йота.

Кайбер вакыт, шул аз сорауга да түзә алмыйча, күзенә яшь килә, бугазына нидер тыгыла да, бу хәлне сиздермәү өчен, кулына комган алып, тиз генә тышка таба чыгып китә. Көзнең кыска көне үтә, тагы төн килә. Тагы шундый тынлык була яисә әллә кайдан ачы, җан өзгеч җилләр исеп, кемдер кызганыч та, куркыныч та рәвештә улый башлый... Бакчадагы карт агачлар да әллә нинди

шомлы тавыш белән караңгы төндә шауларга тотыналар.

Күңел куркына, эч нидәндер шикләнә; башыңа ирексез рәвештә:

– Илаһи кәрим[1], тагы ниләр күрермен икән... Хәерлегә генә булса ярар иде, – дигән бер-бер хәтәр килә.

Бераздан җил тына. Агачлар да шауламый башлый. Ләкин боларның калдырган тәэсирләре йөрәктән һаман китми, ул инде, хәзерге тынлыкка кушылып, әллә нинди авыр тойгылар бирә. Башка төннәрдәгедән артык тәэсир калдырып, теге борчулар, теге бертуктаусыз пошынулар тагы башлана. Күңел нидер тели. Йөрәк кайдадыр бер бушлык сизә. Менә шул вакыт Мәрьям башын кая куярга аптырый; күңелен ни белән җуатудан гаҗиз була. Китапларын, альбомнарын актара, чигүен алып карый, – юк, юк та юк. Берсенә дә кул бармый, берсе дә җуатмый... Менә шул вакыт аның җаны бернәрсә, тели, йөрәге, шул эш булса, рәхәт табар шикелле тоя.

Менә, мөмкин булып та, Мәрьям үзенең бөтен йөрәге аңа мәхәббәт илә тулган дустына, шул сөйкемлесенә, эчендә булган барлык тойгыларын сөйләсә; эчке ялкыны тышка чыгып, йөзе саргайган, йөрәге туктаусыз яну-көюдән көлгә әйләнгән тәкъдирдә дә, башка һичкемгә белдертмәячәк, мөкаддәс дустлыкны, мөкаддәс мөнәсәбәтне ул мәгъбүденә[2] тасвир кыйлып бирсә; шул озын төннәрдә, тын кичәләрнең берендә үзенең яңагын аның күкрәгенә куйган хәлдә, еллар буенча эченә җыя, җота килгән барлык кайгыларын, барлык хәсрәтләрен, бөтен хәятын, йөрәген ачып, кызу ялкын илә муенына сарылса, бәлки, җиңеләер, бәлки, кодрәт кулы белән бу авыр көннәргә хатимә бирелер иде.

Ләкин, ләкин «ул» ерак, «ул» әллә кайда, хыял галәмендә!!

13

Шул хәлнең, бәлки, иң көчәйгән заманы булгандыр, Зыя, кымыздан кайтышлый, башка һичкемгә белдертмичә, Фатыйма бикәләр каласына төшәчәк булды һәм, буны Мәрьямгә хәбәр итеп, мөмкин булса, җае чыкса, аның да шунда килүен үтенде.

Бу вакыт Мәрьямнәр гаиләсендә күптән авырып та шифаханәдә вафат булган Гәрәй мирзаның үлеменә матәм тоту көннәре иде. Фатыйма бикә, хөрмәтсезлек булыр дип, матәм көнендә кунакка йөрүне килештермәсә дә, кызы бик ялынып сорагач, туктатырга кыймады, җибәрде, – әлбәттә, туташның асыл серен белеп түгел, кардәшләренә кунакка бара, дип иде.

Мәрьям белән Зыя бу юлы каланың бакчаларыннан берендә ястү вакытында очраштылар, һәм берничә көннәр, төннәр буена гел бергә диярлек булдылар.

---

[1] *Кәрим* – бәек, рәхимле;  Аллаһның эпитеты.

[2] *Мәгъбүд* – табынырлык дәрәҗәдәге кадерле зат.

Пакь вә саф балалык дәвереннән соң мондый азатлыкта, иркенлектә беренче кавышулары булгангамы, артык вә бик үтә сагынылгангамы; әллә һәр икесе дә бу кавышуда тәмам вә тәмам пешеп җитеп, җан вә тәннең барлык куәләре тәкямелгә[1] ирешкән дәвере башлангангамы, – белмим, нидәндер, бу юлыгышуда әүвәлгеләргә бөтенләй башка бер хәл тойдылар. Инде хәзер, балалыктагы мәгъсум дустлык яисә соңгы еллардагы бер-беренә егет белән кыз арасындагыга охшаш мөнәсәбәт кенә түгел, моңардан бик күп башка, бик күп югары һәм җанны бертуктаусыз дулкынлата, йөрәкне кузгата торган, һәрхәлдә, аерым бер мөәссирлек вә җанлылык белән мөмтаз бер халәт иде. Күрешүләр, сөйләшүләрнең бере дә гади вә табигый рәвештә була алмады, анлар гүя үзләрен бер бик мөдһиш[2] вә бик куәтле драма алдында кебек яисә шуны үткәзеп кенә җибәргәнгә охшаш бернәрсә хис иттеләр. Гүя каза вә кадәрнең[3] әзәлдә язып куйган бик зур бер эше хәл кыйлына яисә бу кавышуда шундый бер нәтиҗә чыга кебек сизенделәр.

Тышкы дөньяда андый бер хәл күренмәде, шулай да бу очрашу анларның арасында булган мөнәсәбәтне чын мәгънәсе белән «романга» әйләндерде; һәм һәр ике якның йөрәгендә әүвәлгегә бөтенләй башка булган эзләр калдырды.

Моңарчы Мәрьям иге-чиге булмаган хыял дәрьясында йөзә, шул хыялның тудырган пошынулары, шуның шөбһә вә изтираблары аны озын төннәрдә йокыдан мәхрүм кыйла, аны борчый, аны сызландыра иде. Диңгезнең куәтле дулкыннары кечек кимәне уйнатуы кебек, ул да шатлык белән көенечнең, өмит белән шөбһә вә үкенүнең әле бер яктан, әле икенче яктан туктаусыз агымына ятып, матди хәяттан аерыла, эзләгәнен мәңге таба алмас шикелле бер тойгы сизә иде. Бу очрашу исә Мәрьямнең эчендәге дулкыннарын бераз басты; йөрәкнең бертуктаусыз сугуына, эчнең пошынуына, күңелнең туктаусыз ашкынуына беркадәр талгынлык бирде.

Гүя аның җаны теләгәннәрнең беразы булды; калганнарының булачагына кемдер бик нык иман иттерде. Гүя Тәңре үз кулы белән Зыяны аңа, аны Зыяга баглап куйды; шуларның тәэсире белән аның йөрәге бераз ныгыды; беркадәр гакылга утырды да, тойгылары табигый юлга төшеп, теге туктаусыз борчый торган хыял да бераз инсафланды шикелле сизә башлады.

Әмма Зыяга бөтенләй икенче төрле тәэсир кыйлды.

Үзенең борынгы дусты – дәһри Садыйкка язган бер мәктүбендә ул бу очрашудан алган тәэсseratын шәйлә тасвир кыла:

---

[1] *Тәкямел* – өлгереп җитү.

[2] *Мөдһиш* – куркыныч, коточкыч.

[3] *Каза вә кадәр* – язмыш, тәкъдир.

«Иптәш!
Көлсәң көл, ләкин мин хәзерге минутта, йөрәгемә сыеша алмый, диңгез кебек ташып барган бер тойгыны сиңа сөйләми кичә алмыйм.
Башта ук шуны әйтим: без пессимист буламыз: дөнья сүгәмез, хәятта ямь юк, кызык юк димез, – бар да җүләрлек, бар да сукырлык икән. Хәятта ямь юк түгел, анда ямь дә бар, кызык та бар; үзеңне кашында табындырырлык мәгънәләр дә бар. Тик аны табарга, үзеңдә хәятның бөек бәхетләреннән файдалана белү кабилияте булырга кирәк. Мин, туган, шуны таптым; шуның эченә баш-аягым белән чумдым, һәм әйтә алам: хәзер мин – мәсгут, мин бәхетле, моңарчы хәятны аңламаганмын; аның яшь йөрәкне мәңгелек сәгадәт илә тутырып, дөнья вә кяинаткә[1] бөтенләй икенче төс бирә торган ноктасы кайда икәнен белә алмаганмын икән.
«Әллә азрак җүләрләнә башладыңмы?» – дияргә ашыкма; тыңла, баштан сөйлим.
Син бит Мәрьям туташны беләсең. Мин аны гелән сөйлидер идем. Ул минем балалыктан бирле якын дустым. Без бергә үстек, бергә уйнадык. Безне, унөч-ундүрт яшьләр тирәсендә булса кирәк, «сез нәмәхрәмнәрсез» дип, аердылар. Ләкин без бер-ике елдан соң, яшерен мөнәсәбәт башлап, хатлар языштык. Мин авылга кайткач, караңгы төннәрдә зур бакчаның куе куаклары арасында кавышадыр идек. Ул миңа чын күңелдән багланган кебек, мин дә аны бик ярата идем, – чөнки аны яратмау асла мөмкин түгел, – ләкин гашыйк түгел идем.
Аның белән чынлап күрешә алмауга ике ел тулып, өченчегә китте дигәндә, бу ел тагы очраштык. Бусында инде качынып, посынып түгел, тәмам, тәмам азат уларак.
Менә, иптәш, исем дә китте, гакылым да бетте. Белмим, ул шул чаклы үзгәргән, белмим, миндә матурлыкны тәкъдир – аны сизү куәсе тәрәккый иткән, – ни дә булса бар, – әмма, әмма мин аңардан тәмам хәйранмын.
Әүвәлге очрашуымыз бакчада булды. Аяз, матур, тын, айлы кичә иде. Көтелмәгәнрәк җирдән каршыма килеп чыгып:
– А... Зыя абый, синме? – дигәч, шаша калдым. Өнме, дим, төшме? Каршымда бер фәрештә тора. Миңа матур, кечек кулларын сузган. Таныйм да, танымыйм да. Әгъзаларының барысы зиһенемдәге Мәрьямгә килә. Ләкин аның бөтен вөҗүден, йөзен илаһи бер пәрдә каплаган. Шул минем йөрәгемә сугып, «Мәрьям!» дип, берьюлы батырлык итүгә каушата.
Син ул туташның рәсемен күргәнең бар: ул озынрак, нечкә һәм зифа буйлы; гәүдә вә әгъзалары табигый һәм килешле. Аның бөтен тәнендә хатыннарга

[1] *Кяинат* - галәм

аерым бер лэтафэт бирэ торган назиклек бар. Бите озынчарак; тавышы назлы кызларныкыча. Үзе һичбер вакыт тыштан сөйли белми, һәммә сүзе тик йөрәгеннән чыгадыр төсле. Авыз, борын уртача; башка әгъзалары да гади – һәр күргәннең сынын катырырлык үтә матур да, ямьсез диярлек тә түгел. Шөйлә, аның тышкы әгъзаларыннан бер рәссам нәмунә алачак булып та, ул, адәмнең йөзендәге бөтен рухани дөньясын, рухан матурлыгын күрсәтә алырлык мәртәбәдә даһи булмаса, һич шөбһәсез, Мәрьямнең тышкы копиясе белән бик гади бер кыз сурәтенә башка нәрсә чыгара алмас иде.

Әмма... әмма... Тәңре бер адәмне үтә хәссас итеп яратсын; үз сәнгате вә үз кодрәтенең ниһаять җәмал[1] белән хәлык кыйлынган[2] ноктасы кайда икәнен аңларлык куәт, дәһа[3] бирсен дә, шул бәхетле адәм язгы таңнарда, айлы кичәләрдә, тын, серле вә хыялый төннәрдә Мәрьямнең йөзенә, сер, илаһият, нур вә ялкын илә тулган ул зур кара күзләренә тик бер генә мәртәбә карасын, – ант итәм, ул даһи ихтыярын югалтыр, дөньясын онытыр да, Тәңренең бу мөмтаз сәнгате – рухан матурлыкның ниһаясен аңлаткан, йөрәктә булган барлык голүвият вә җәмалне ингыйкас иттергән[4] ул йөз, ул кара күзләр алдында гали бер коллык белән сәҗдә итәр.

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Хатыннарга «түшәк өчен» дип караган бәндәләр Мәрьямгә, бәлки, табынмас, аны гади табар, һәр җирдә аңардан артыкларны күрер. Ләкин адәм, табигате белән ул мәртәбәдән югарырак булсын, хәссас күңел белән яратылсын — әнә шулар гына Мәрьямне тәкъдир итәр, шулар гына аны аңлар; шулар гына аның матурлыгы битендә түгел икәнен, аның рухы — җәмал, нур вә голүвият диңгезеннән гыйбарәт идекен һәм болар аның йөзен каплаган илаһи пәрдә белән кара күзләр аша дөньяның мөмтаз табигатьләренә лотфән[5] күренә алганын йөрәге белән сизәр.

Мин үзем шулай дип аңлыйм. Вакыйган, гаҗиеб тә бер хәл. Дөньяда матур күзләр күп, ялтыр каралар да әз түгел. Ләкин Мәрьямнең күзе, аның күзендәге матурлык, аның күзендәге тирән серләр,— Ходай белә, ни диим, очраганым юк, болар мине тәмам, тәмам сихерлиләр дә куялар.

Күзе генә дә түгел, хәзер аның һәр җире миңа эчке вә рухани матурлыкны күрсәтеп торалар шикелле тоела. Ярым караңгы вә ярым нурлы булган айлы кичәләрдә, зур суга караган бакчаның аулак бер җирендә, аның белән икәү генә

---

[1] *Ниһаять җәмал* – чиксез матурлык.
[2] *Хәлык кыйлыну* – яратылу, барлыкка китерелү.
[3] *Дәһа* – даһилык, талант.
[4] *Ингыйкас иттерү* – чагылдыру.
[5] *Лотфән* — ягымлы, килбәтле,

күзгә-күз карашып утырган чакларда, шул дәрәҗәдә сихерләнәм ки, өнме, төшме, әллә юкса, бу каршымдагы бер сурәт яисә шигырь вә хыялдан гәүдәләнгән бер фәрештәме дип, бер секундка шөбһәдә калам... Шул вакыт аның бер көлүе, бик гади бер сүзе, матур, зур хыялый кара күзләре белән синең күзеңә бер мәртәбә каравы рухыңа үтә китеп, тәкатеңне бетерә; ни эшләргә белмәстән, күңел ашкынуыңа чыдый алмастан:

— Аһ... Мәрьям, белмисең... Валлаһ, белмисең,— дип, йөзең белән күкрәгенә егылып, муенына сарыласың... Менә шул минут сиңа җир, күк бәрабәренә алыштырылмаслык мәртәбәдә гали булган бер сәгадәт бирә.

...Садыйк, син теләсәң ни әйт, әмма мин бу очрашудан соң үземә хөсне занымны[1] арттырдым. Мин әле рухан кипмәгәнмен — минем йөрәгем үлүдән ерак икән әле: мин гашыйк булырга, шуның белән мәсгудият табарга мөстәгыйд[2] икәнмен. Мин хәзер гыйшык тотам:

Урамнан узып бара,
Кашыннан күзе кара;
Керфегеннән гөлләр тама,
Күрсәм йөрәгем яна.

Менә, иптәш, мин шул назик мәгънәле җырны чыгарган халыкның угылымын. Бундый шигырьне чыгара алучы — хәссас йөрәкле бәхтияр[3] халык булган кебек, моны илһам итүчесе дә шул халыкның, туташлары, минем Мәрьямем кебиләр улмалы. Мин моны үзем өчен үземнең йөрәгемнән алып чыгарылгандай тоям. Бу — минем даими зикерем. Бу минем фәрештәмне тасвир кыйлып биргән шикелле, ул туташның минем йөрәгемдә нинди урын тотканын да әйтеп җиткерергә якынлаша. Дөрестән дә:

Урамнан узып бара,
Кашыннан күзе кара;
Керфегеннән гөлләр тама,
Күрсәм йөрәгем яна.

.........»

## 14

Бу очрашуның соңында килгән байтак көннәр Мәрьям өчен бер-бер артлы тезелеп киткән шатлыклы сәгатьләрдән гыйбарәт булды. Ул башта, бөтен дөнья бәхетен кулына алгандай, шат, уенчак, җиңел табигатьле, күтәренке рухлы булып, бертуктаусыз шаярып, көлеп йөрде; соңра көннән-көн бик аз гына

---

[1] *Хөсне зан* — үзе турындагы яхшы фикер.
[2] *Мөстәгыйд* — булдыклы.
[3] *Бәхтияр* — бәхетле.

басыла, акрыная барып, аның өчен тыныч кына, рәхәт кенә агып утырган, бәхетлегә якын бер заман килде.

Әйтерлек зур бәхетләр, сәгадәтле минутлар да юк. Бер секундта хәятыңны җәһәннәм газабына әйләндереп җибәрә торган зур кайгылар да юк. Шулай бертөрлерәк кенә, рәхәт-тынычрак кына үтә бирә.

Җәй шул халәт дәвам итте. Көзнең башы да зарарсыз иде. Тик көннәр ямьсезләнеп, хатыннар Фатыйма бикә янына гайбәткә кергәли башлагач, ул тагы эчендә бер дулкын сизә башлады.

Гайбәтләр эченә катыштырып, никрутлар, әллә нинди каралулар сөйлиләр. Кем кала, кем китә; киткәннәрнең кайсылары бигрәк кызганыч — менә шуны гелән тикшерәләр. Зыя иң әүвәл телгә алына да, һәммәдән артык аны кызгана башлыйлар. Шул сүзләр белән бергә Мәрьямнең эченә бик аз гына тәэсир йөгерә.

Чынлап та, ул — быел никрут бит... ул караласы...

Аның уе шуннан күп үтми... Зыяның алынулары, солдат булулары — коры бер сүз генәдер кебек тоела.

Әмма төн килсә, эшләр башкара. Тагы шул эч пошыргыч, озын, ямьсез, мәгънәсез көзге төннәр! Кайбер көннәрне тын, сакин[1] була. Анда авыр, борчулы, кайбер вакыт теге ачы җил сызгыра, кемдер улый, карт имәннәр шаулаша башлый – бу вакыт исә бераз куркыныч та, шомлы да була, әүвәлге еллардагы кебек эч поша, күңел тынгысызлана, кул һичбер эшкә бармый. Ни эшләргә? Бу таңы атмас озын төннәрне ничек үткәрергә?

Дөнья тын һәм караңгы. Авыл тирән йокыда. Мәрьям җанын кая куярга белми, интегеп утыра – менә шул вакыт урам буйлап җырлап, музыка уйнап никрутлар үтә. Бу бер яктан аны бик аз гына җуатса да, икенчедән, шул тын кичәдә уйналган музыка аңа әллә кемнәрнең китүен, әллә кемнәрнең калуын сөйли. Ул шулар эчендә үзе белән Зыяны да күрә. Үзләренең язмышы да шул егетләр һәм анларның сөйгән ярлары Фатыймалар, Зәйнәпләр, Гөлсылулар кебек икәнен хәтерли дә гомерендә бер мәртәбә һәммәсенә бер якынлык сизә.

Мәрьямнең рухындагы бу халәт көннән-көн арта, караласы көн якынайган саен никрутларның йөрүе күбәя, гүя җырлары моңая төшеп, музыкалары да күбрәк «Аерылу-аерылышу» көйләрен уйный башлый, – шуларның бары аның төннәрен тагы да озайталар, пошынуларны тагы да арттыралар...

Зыяның вәгъдәле көндә кайтып җитә алмавы – аңа тагы яман тәэсир итте. Октябрьнең егерме бишендә, шимбә көн, кайтачакмын дигән хәбәре Мәрьямгә сәгате белән ирешкән иде. Ул бу көнне секунды, минуты белән көтә башлады.

---

[1] *Сакин* – тыныч.

Бер ел чаклы тоелган шимбә үтте – юк. Һәрбер атлыны, ул кайтмадымы дип, аерым диккать белән уздырып, бер капкадан, бер тәрәзәдән карый-карый, якшәмбе дә үтте; аның бик зур бәхетсезлегенә каршы, дүшәмбедә дә кайта алмады...

Бу өч тәүлектә аңа заман туктаган кебек, көн үтмидер кебек тоелды. Көндезләр тагы бер хәл, әмма төннәр бик яман, бик авыр, бик борчулы. Караласы көннәре тәмам җитеп калганга, бу арада никрутлар бер дә йокламый, төнозын урам буена йөреп кенә чыгалар. Җырлары әллә нинди кайгылы кебек; музыкалары әүвәлгедән дә артыграк моңланадыр кебек.

Аңа Зыя хакында әллә нинди куркыныч уйлар килә башлый:

«Илаһым, хуҗам! Ни генә булды икән?.. Авырыймы икән?.. Әллә ашамаганын сизеп, карамый-нитми, бер җирдә тотып, солдатка алдылармы икән?!»

Бу өч төндә ул бер дә тыныч йокы күрмәде, башын мендәргә куеп, күзен йомуга, зиһененә әллә ниләр, әллә нинди ят галәмнәр, әкият дөньялары килеп, төнозын куркыныч төшләр, мәгънәсез саташулар белән бәлаләнеп бетте.

Сишәмбе көн иртән шундый төшләрдән, әллә нинди кояш тотылу, кеше үтерү кебек куркыныч эшләрдән куркып уянуга, теге яктан яшь баланың:

– Зыя абзыйга әллә ни булды! – дигән тавышын ишеткәч, бу хәлләргә берьюлы хатимә бирелеп, ул күрешү өмитенә төште вә, шуның чарасына кереп, Зыяга теге мәктүбчекне бирергә муафыйк та булды.

Озын көн шул кичке кавышуны көтү белән үтеп китте.

Кич сәгать ун булып, бакча ашасыннан килеп, аның тәрәзәсен чирткәндә, ул, йөрәк сугуына чыдый алмый, минутны минутка ялгар мәртәбәдә сабырсызланып көтмәктә иде.

Бүген анасы өйдә юк. Бүлмәсенә кертеп, бикләнә алганда, бер дә куркырлык эш калмас иде. Ләкин тышкы ишеккә якын бүлмәләрнең берсендә – ике карчык, берсендә хатыны белән ялчы ята. Гөнаһ-шомлыкка, шулар күреп калса, бөтен дөнья харап булыр. Әүвәлге еллардагы кебек, бүлмәсенең бакчага караган тәрәзәсен алып, шуннан кертергә дә мөмкин булыр иде; юк шул, тәрәзәләр, кышка каршы ике каты да куелып, кадакланган, сыланган. Аны ала башласаң, тавыштан бөтен авыл уяныр, икенчедән, аны иртәгә һәммә кеше беләчәк тә. Юк инде, юк, ни генә кыйлсаң да, Зыяны бүлмәгә кертә алырлык җай чыкмый. Ахрысы, бәхетсезең, булмас, анларга шундый кыйммәтле минутларны кайда булса да тышта, теге шаулашып утырган агачлар арасында үткәрергә тугры килер.

Мәрьям көн буена, бу уйлар, бу планнар белән ватылып, җәфа чигеп, шул

соңгы мадәгә[1] карар бирелгән булганга, Зыяның шыкылдатуына каршы, лампасын тәрәзәгә китереп, бөтен өмитләрен белдергән хәлдә, һәм күзе, һәм йөзе белән аңа бер генә мәртәбә елмайды да ишарә белән:

– Шунда көт, хәзер, хәзер чыгып җитәм! – диде. Бер минуттан ул инде карт имәннең төбендә, үзенең җилкәсенә генә салып чыккан пальтосын ташлап, Зыяның куенына, зур толыбы эченә атылган иде.

Көзнең ачы, салкын җилен, агачларның туктаусыз шаулавын сизмичә, анлар төннең өч сәгатен шунда бергә, бер тун эчендә, тәэсирләрен, баштан кичергәннәрен сөйләшеп үткәрделәр.

Арада һичбер көтелмәгән бер эш тә булып алды.

Мәрьям, үзенең тышкы киемнәрен тәмам ташлап, кечкенә бала шикелле Зыяның алдына утырып, икесе бер тун эчендә улдыгы хәлдә, яңакларын Зыяның йөзенә куеп, үзенең бу өч көнне үткәрүдә күргән газапларын сөйләмәктә иде.

– Белсәң, әй, бу берничә көннең авырлыгын... Көндезләре тәрәзәдән тәрәзәгә йөреп, аннан капкага чыгып үтә инде... Ләкин төннәр ничектер бик борчулы була... Халык йоклап беткәч, җырлап, музыка уйнап никрутлар йөри... Шулар да әллә ничек күңелне кузгата... Зөләйха абыстай да, көненә берничә мәртәбә кереп, безнең әни белән: «Илаһым, ни генә булды икән, ник бу чаклы кичекте икән», – дип кайгырынып чыга... Шуннан мин дә курка башлыйм, әллә, дим, бер җирдә тотып, карамыйча ук алдылармы икән, дим...

– Алай алмыйлар алуын аны... бервакытта да. Шулай да мин үзем дә, сез хафаланырсыз дип, икенчедән, каралу көненә кайтып өлгерә алмыйм күрәсең инде дип, бик каушадым.

– Соң ни эшләп алай кичектең?.. Зыя, ни әйтергә икән дип, бераз уйлаган соң, ялганларга зарурәт күрмәде.

– Мин бит больницада булдым.

Мәрьям шаша калды. Берьюлы йөзен Зыяга таба борып, тәгаҗҗеб вә хәйрәт белән тулган күзләрен аның күзенә текәгән хәлдә:

– Ни дисең?.. Больницада?! Анда ни эшләп кердең?! – диде.

Зыя тагы бераз аптырады, дөресен әйтергәме, әллә аны куркытмаслык бернәрсә оештырыргамы дигән сөаль башына килде.

Ул шул сөальне аңлап та бетә алмады, күзенә бакчаның суга якын җирендә бер шәүлә – карачкыл күренеп, диккатен алды. Ул карачкыл адәмгә охшый. Кулында зур бер таяк сыман нәрсәсе дә бар. Ул качамы, юри яшеренәме – ни дә булса бар, күренмәскә тырышкан адәм кебек, куак араларына, агач

---

[1] *Мадә* – чара.

ышыкларына посына-посына гына атлый. Үзе болар га таба килгән дә кебек. Зыя буны ачык күрсә дә, бәлки үз зше белән йөридер, бәлки үз юлына китәр дип, курыкмасын өчен Мәрьямгә әйтми үткәрергә теләгән иде. Боларны күзәтеп йөргән адәм булу ихтималы күңеленә килеп, теге дә боларга якыная башлагач, чыдамады, мөмкин кадәрле салкын канлылык саклап:

– Мәрьям, Мәрьям, син өстеңә киенмимсең?.. Әнә тегендә кемдер йөри бугай! – диде.

Туташ сискәнеп китте:

– Ни дисең?!. Ни дисең?!

Мәрьям, сүзен әйтеп, Зыя куеныннан чыгарга да өлгерә алмады, теге шәүлә якынайды, тагы бер-ике атлады да кулындагы ботаклы агачы белән Зыяның уң ягына селтәп үк җибәрде. Җитмәсә, әллә кай җиреннән чыгарырга азапланган авазы белән, бик авыр көчәнеп, акыра башлады:

– Әй, җәмәгатьләр!.. Әй, хәлаикъ...[1] Харап булдык!.. Тиз... Уйнашчылар!.. Уйнашчылар!..

Мәрьям, дөнья җимерелеп беткән вә хәзер актык минут килеп җиткәндәгегә охшаш бер каушау белән, ни эшләгәнен, ни булганын белмичә: «Уф... харап булдык!..» – дип, өй ягына таба йөгерде. Зыя исә, көтелмәгән бу эштән артык кайнап китеп, актык көчен җыйды да, янында яткан бер күсәкне алып, адәмгә селтәде, ләкин ул тимәде. Адәм, үзенең карлыккан тамагы белән бугаз төбеннән нидер гырылдап, кулындагы агачы белән тагы кизәнде; Зыя, ни эшләгәнен белмичә, аның сугарга селтәгән таягына ябышты да, үзе, арткарак чигенеп, рәттән дүрт мәртәбә ни беләндер адәмнең күкрәгенә таба төзәде.

Ул арада Мәрьям, тагы кире йөгереп килеп: «Илаһым, бу кем соң?.. Харап кына булдык... Ни эшлисең син, абый?.. Мин кая гына барыйм?!» – дип, Зыяның муенына асылмак булганда, адәм: «Үһ!.. үһ!..» – диде дә бөтәрләнеп җиргә төште.

Егет, бер минутта гакылын җыеп, үзенең ни нәрсә кыйлып ташлаганын аңлады; күрмәсен, күрсә дә хәзергә аңламасын дип, Мәрьямне өйләр ягына таба алып китте. Үзе арыган, эштән чыккан иде. Җүнләп тынын ала алмый, җүтәлдән үлә башлаган авыру кебек, тыгылып, ахылдап, өйгә якын бер эскәмиягә чак килеп егылды...

Зыя гомерендә кеше белән сугышкан адәм түгел. Кан түгү, кеше үтерү дигәнне авызга да аласы юк. Ул, адәм кыйнауны түгел, йөккә җигелгән атларның сугылганын күргәндә дә мөтәэссир була. Әмма бүген шул үзе үләргә йөргән, хәлсез Зыядан адәмнең әҗәленә сәбәп булырлык куәт чыкты.

---

[1] *Хәлаикъ* – кешеләр (халык).

Ул үзе кызурак адәм. Бу – бер. Икенчедән, бүген анын фәрештәдәй мәгъсум дусты Мәрьямнең пакь намусы шул юкны күзәтеп йөргән адәм тарафыннан уйнашчылык пычрагына батырылу ихтималы бик якынаеп калды. Кем белә, моннан нинди афәтләр чыгар иде. Ярый, анын тавышы булмады да, ишетеп, халык килмәде; әгәр дә ирек бирелсә, ул бу көенчә калмас, боларны өстерәп урамга чыгарыр да сельский старостага барыр, аксакаллар чакырыр иде. Мондый эшләр булмады түгел. Әле берничә ел элек кенә Вәли белән Сабираны тотып, битләрен корымга буяп, урам буенча йөрткәннәр иде...
Адәм: «Уйнашчылар, уйнашчылар!..» – дип акыра башлагач, шул уйлар вә шул куркынычларның бары берьюлы, бер күренештә күз алдына килде дә, ул, үзенә хуҗалыгын югалтып, ни кыйлганын да яхшылап белмичә, кесәсендәге револьверга ирек бирде.
Эшне аңлагач, Мәрьям чак калды һушыннан язмыйча...
Тик Зыя аңа югарыдагы мәсьәләләрне тәфсыйль итеп биргәч кенә, ул бераз хәлгә килә төште. Шулай да куркуыннан йөрәге ярылырга бара, күзләре атылып чыгарга тора шикелле иде. Ул ни дияргә белми, аптырагач:
– Юк ла инде... безне алай йөретә алмаслар иде, – ди.
– Әлбәттә, аны булдыра алмаслар иде... Ләкин бөтен тирә-якта сине «уйнаш белән тотылган» дип гомер буена чәйнәрләр, намусың тапланыр, дөньяга чыгарлыгың калмас иде.
– Әй, Ходаем, мин мондый эшне бер дә генә уйламадым шул... Куй инде, авызыңнан җил алсын... Андый эш булса, Ходаем, үзең сакла, дөньяда тораммы соң... Сәгате белән су төбенә китәр идем. Шулай да бик куркам шул... Кара әле син йөрәкнең сугуын...
– Куйыйк, Мәрьям, аны сөйләмик. Безгә бит аерылырга да вакыт. Сәгать бер булып килә. Беренче әтәч бая ук кычкырды инде...
– Ай, Ходаем, бик куркам шул... Төшемә генә кермәсә ярар иде, Илаһым...
Мәрьям бераз тынычлана төшкәч, Зыя аны бакчаның анларга караган ишегенә чаклы озатып килде. Ләкин туташ бик бетеренгән, бик йомшарган иде. Кулларын егетнең явырына салды да йөрәгенең әллә кай җиреннән елап, тәэсирләнеп, өзелеп килгән бер тавыш белән:
– Зыя... Зыя... Зыя абый... син... син аннан, каралган җиреңнән... миңа хат язарсыңмы?.. Миңа бик авыр бит... – диде.
Зыя аның кулларыннан тотты да:
– Белмим шул, Мәрьям... Кем артыннан гына җибәрсәм дә, уңгайсызлыклар чыгарга мөмкин бит... Син тыныч бул. Без анда озак тормыйбыз. Ике-өч, күп булса, дүрт көн булырмыз... Мин бит бик ябык. Докторлар миңа, әлбәттә

калырсың, диделәр...

Ул сүзен бетерә алмады, хәлсезлектән аварга хәзерләнгән рәвештә торган туташ анның күкрәгенә башын салды, егет тә, җавап уларак, аны үзенең толыбы эченә алып, озак, ялкынлы үбеп, өйнең ишегеннән кертеп җибәрде.

Егет, шул пакь, гали вөҗданның, хәзер бүлмәсенә кереп бикләнү белән, мендәргә йөзтүбән капланып, бик әрнеп вә бик зур трагедия алдында кебек бер хәл тоеп, төн буена елап чыгачагын күз алдына китергән хәлдә, тегендә яткан адәмгә таба юнәлде.

Бу адәм – алтмыш яшьлек бер карт. Исеме – Хаҗи. Анның ата-анасы Гәрәй мирзаның атасы Һибәтулла мирзада гомерлек ялчы булып торган иде. Бу шунда туды, шунда үсте. Карт байлар вафат булып, дөнья Гәрәй мирзага калгач та, Хаҗи анларны ташламады – гомерен шуларда ялчы булып үткәрә башлады.

Ул юаш кына, суфый һәм беркатлы гына адәм булып, баен яратуы һәм аңа ярарга тырышуы да чиксез иде. Гәрәй ни куша – ул, әлбәттә, эшләнергә тиеш. Гәрәй ни сөйли – ул хак кына. Ул канун. Ул кайбер вакыт, көлдерергә уйласа: «Минем беренче – Аллам; икенче – Гәрәй мирзам», – ди торган иде.

Илле яшьләренәчә хезмәт иткәч, мирза, анның хәлсезләнә башлаганын күреп, даими хезмәттән азат кыйлу уе белән, ындырлар буена корылган кечек урамга бер өй салдырып бирде, бераз мал да кушты, – шулай итеп, ул үз йортлы булды. Ләкин Хаҗи моның белән Гәрәйләрдән аерылмады, «Шунда тудым, шунда үстем, карт көнемдә бу йортны ташлар хәлем юк, икмәк, тоз хакы да бар бит», – дип, үз эше шикелле, Гәрәйнең хезмәтендә йөри бирде.

Мирза аңа еллыклап жалунья бирүне туктатса да, арышыннан, тарысыннан гошерен[1] чыгара, иске киемнәрен дә садака кыйла, саламын, утынын, кирәк булса, җигәргә атын да аямый иде.

Гәрәй карт үлгәч, Фатыйма бикә, артык тугрылыгына ышанганга, аны билгеле мәгаш[2] белән, йорт-җиренә төнлек каравылчы итмәкче булган иде. Хаҗи баба тәклиф кыйлынган хезмәтне алса да, айлыклап бирелә торган жалуньяны рәд кыйлды:

– Юк, бикә, юк, – анам сезнең икмәгеңезне ашап, сезнең кул астыңызда кабер күрде. Үзем дә менә, Аллага шөкер... сакалым агара... бар гомеремне сезнең икмәгеңез белән үткәрдем. Жалунья-фәлән кирәкми, бикә... Ач үтермәссез әле... – дип, үз тәгъбиренчә, йортка күз-колак булуында дәвам итте.

Бүген бикә өйдә булмаганга, ул, әлбәттә, йокламаячак, йөреп, карап үткәрәчәк иде.

---

[1] *Гошер* – уңышның, уннан бере күләмендә дини. налог.
[2] *Мәгаш* – хезмәт хакы.

Ул Мәрьям белән Зыяның мөнәсәбәтен, әлбәттә, белми, белсә дә, һичбер нәрсә аңламас иде. Шулай ук Зыяның кайтуыннан да хәбәре юк иде.

Эскәмиядә бик аз гына селкенгәләп утырмакта булган ят киемле, калын гәүдәле адәм күренгәч, тугры ялчы шаша калды. Имеш, байның йортында, бакчасында җиде төн уртасында ят кеше йөрсен! Ул кем булыр?.. Әлбәттә, хәерлегә түгел!

Теге калын адәмнең эченнән күлмәкчән хатын чыкканын күргәч, аның башы әйләнде, күзен кан басты да, ни эшләгәнен белмичә, акырып та җибәрде, таягы белән дә омтылды. Ләкин ул, өченче көн салкын тидереп, тавышын бетергән иде, кычкыруы авыз эчендә калды; үзе хәлсез үк карт булганга, таяк белән дә һичбер эш кыйла алмады... .

Зыя Мәрьямне озатып килгәндә ул инде җан тәслим кыйлмыш иде. Егеткә авыр да, мәгънәсез һәм гөнаһлы да кебек тоелды. Ләкин үзен шуңа мәҗбүр һәм бу эшендә мәгъзүр[1] дә кебек хис итте. Әгәр дә бу авыр вә көтелмәгән фаҗиганең тәэсиренә бирелсә, аңа картның суынган гәүдәсенә бик озак карап торырга тугры килер, кем белә, нинди нәтиҗә белән барып бетәр иде. Ләкин ул гакылын җыйды да, сәгатьнең бер булганын, тиздән атасы кайтуын, дүрт-биш сәгатьтән соң каралуга китүләрен уйлап, ничек кенә булса да бу эшкә хатимә бирергә[2] карар итте. Башка юл, әлбәттә, юк иде.

Картны билбавыннан өстерәп бакча кырыеннан аккан суның ярына китерде дә:

– Миңа рәнҗемә... Тавышсыз картка тавышсыз мылтыктан әҗәл... Алла урыныңны җәннәттә кыйлсын!.. – дип, текә ярдан тирән ятуга этәреп төшерде... Шуның артыннан ук кесәсендәге револьверын да су төбенә җибәрде.

Авыр, могаззәб.[3] Ләкин ни эшләмәк кирәк?

Иртән бик аяусыз салкыннар булып, су өсләре бер төндә адәм йөрерлек мәртәбәдә боз белән түшәлде. Хаҗи карт та шуның астында кыш чыкты.

Бөтен тирә-якны ду китереп эзләүләр бар да буш булып, аның кая киткәнен, ничек югалганын бертөрле дә белә алмадылар. Хәбәре дә булмады, үтереп ташлаганнардыр дип уйлатырга гәүдәсе дә чыкмады. Тик яз килеп, елгалар таша башлагач кына, моннан өч чакрым түбәндә, боз белән килеп тә, күпернең баганасына кысылып калган бер мәет таптылар.

Аның ике аягы тәмам өзелгән; гәүдәсе күгәреп, череп эштән чыккан; баш сөякләре тәмам изелеп, авызы, борыны җимерелгән; гомумән, адәм рәвешеннән чыгып, Ходай белсен, нинди куркыныч бер черегән ит кисәгенә әверелгән иде. Аның кем үләксәсе икәнен ачык белә алмадылар. Кыш көне шул авылның бер

---

[1] *Мәгъзүр* – гафу ителергә тиешле.
[2] *Хатимә бирү* – тәмамлау, ахырына җиткерү.
[3] *Могаззәб* – газаплы.

егет югалган иде. Шуның гәүдәседер дип алып, кардәшләре җеназа укып күмделәр.

Менә шул гәүдә – теге кичәнең корбаны булган Хаҗи картныкы иде.

Карт тугрылыгына корбан булды, бетте. Аны якыннары, белешләре дә тиз оныттылар... Тик бикә генә: «Кая инде ул Хаҗи бабай кебек тугры кеше!» – дип, хыянәтләргә, алдануларга дучар булганда гына аны сагынгалый иде... Ләкин Зыя белән Мәрьям аны гомергә күз алдыларыннан югалта алмадылар... Баштарак анларга ялгыз калу шикләндерә иде... Хосусән[1] төннәрдә, тын, караңгы кичәләрдә! Гүя әнә шул таш өйнең бер почмагы ачылыр да, кәфеннәрен өстерәп Хаҗи карт килеп керер... яисә аның, белмим, каяндыр авыр ыңгырашулары ишетелер кебек тоела иде. Төшләрдә дә бик борчыды. Мәрьям аны ничә мәртәбә кәфене белән килгәнен күреп, куркып уянды. Мондый вакытта ничә көннәр авырып та йөри иде. Зыя бервакыт шундый төш күрде.

Зур бер су. Шунда бик калын баганалар өстендә зур күпер. Ләкин һичкем йөрми дә, йөргәнгә охшамый да. Шул күпернең астына караса, ниндидер бер мәет ята. Хаҗи картка охшый кебек, юк та кебек... Ул, ни эшләргә белмичә, арткамы, алгамы атларга аптыраган минутта, Хода белсен, кайдан, әллә тирә-якның караңгылыгыннан оешып, шунда бер күләгә ясалды... Менә шул күләгә ката бара, калыная бара. Менә ул куе караңгылык эчендә һич селкенми торган бер сурәткә әйләнде.,. Үзе кап-кара... Ялтыр күзләре гел моңа карап торалар... Менә аның бер кулы күтәрелде да әүвәл теге мәеткә таба ишарә кыйлды, соңра мөдһиш вә куркыныч күзләрен әйләндереп, Зыяга бармак белән яный башлады...

Уянганда, Зыя манма суга баткан, йөрәге бетен тәнен дерелдәтә иде... Тәүлекләр буенча ялгыз калса, шул сурәт алдына килеп, бер кабым нәрсә ашый алмый йөрде...

Айлар, еллар үтсә дә, Хаҗи карт үлеменең шул мөдһиш күләгәсе үзенең куркыныч кара сурәте белән болар артыннан йөрүдән тукталмады... Төннәр, ялгызлыклар аны хәзер чакырып, Зыя илә Мәрьямнең күз алдына китереп чыгаралар иде...

## 15

Боларның барлыгын тудырган теге фаҗигале кичәдә исә, таң беленеп, Зыялар каралырга киткәнгәчә, Мәрьям күзен дә йома алмады...

Ул, бүлмәсенә кереп, берәр сәгать торгач, Җәләл мулланың бик талган ат белән кайтып керүе; берничә сәгатькә йорт тынып та, соңра тагы ялчыларның атлар, чаналар белән кайнаша башлаулары; ниһаять, ул өйдә ут яндырылып, пич

[1] *Хосусән* – бигрәк тә.

ягылып, бераздан соң зур чанага җигелгән һәйбәт атның урам як койма ашасыннан башын салып торуы; Зыя белән Җәләлнең, зур толыплар кигән хәлдә, шул чанага утырып, әллә нинди тирән уйга баткан рәвештә, тын гына китүләре – һәммәсе Мәрьямнең күз алдыннан, томан арасында күренгән кебек кенә, берәм-берәм килеп кичтеләр.

Йорт тагын тынды. Мәрьям тагы ялгыз калды. Аның алдында тик ниндидер бер кара сурәт тә башында ихтыярсыз килгән бер сөаль бар иде: «Ул китәрме, калырмы? Калыр, әлбәттә калыр... Ходай үзе күрсәтмәсен, китеп барса, ни эшләрем?.. Илаһи, үзең сакла: синнән башка беркем дә белми!»

IV

1

Ходаныкын белмәссең.

Кичә көз иде. Кичә күк кара, караңгы һәм ачулы, авыр болытлы булып, туктаусыз карлы-бозлы яңгыр ява иде. Һава, диңгезгә тыгып алгандай, дымлы вә юеш, аяк асты тездән су һәм пычрак иде. Ә бүген бөтенләй икенче дөнья: төсе дә икенче, тәэсире дә икенче.

Көн аяз, матур, күк йөзе ачык; кичәге болытларның эзе дә калмаган. Дөнья якты һәм киң. Кичә җанга авырлык бирә торган төс белән каралып яткан җир йөзе, бүген күкнең иңдердеге ак вә саф кары белән түшәлеп, кичәгегә караганда шул дәрәҗәдә ямьләнгән ки, күзне кай якка юнәлдерсәң дә, чите офыкка барып терәлгән вә өсте ак мәрҗәннән гыйбарәт күбекләр илә бизәлгән, пакь вә ялтыравыклы кар диңгезе генә күрәчәксең.

Болар, шөбһәсез, матур да, күңелле дә. Ләкин бу матурлыкны, җәйнеке кебек, һичбер хәлдә җан вә йөрәк сизми. Буны күз күрә – тик шулкадәр.

Киңәеп, җәелеп баргандай торган авыллар, биналар бар да берьюлы саннарын җыйды, станнарында катты. Үз алдына үзе суланып, җәелеп барган һава да бу көн берьюлы куеланган, туктаусыз ката һәм ыклана тора. Морҗалардан чыккан төтеннәр, һаваның бу хәлен ганимәт белеп, саннарын күтәрә алмый, җиргә таба агарга бер дә мәҗбүрият күрмиләр, күкнең нәкъ йөрәгенә карап, туры вә мөтәкәббир рәвештә югары ашалар.

Кичә шаулап аккан елгалар бүген әллә кая, боз астына качты. Хәзер анлардан тавыш та, тын да чыкмый. Ахрысы, дөньяның салкынлыгына үпкәләп, асттан, яшеренеп, каядыр туктаусыз китеп утыралар. Инде анларның өстеннән атлы һәм җәяүлеләр үтә.

Кичә, актык яфрагын селкетеп, мескен кыяфәтендә утырган агачлар, бүген беренче суыкның китергән ак киемнәрен киеп, бәс белән уранып, тирә-якларына ясанган мөтәкәббир егет сыман карыйлар: гүя мыеклар куелган,

кашлары, керфекләре дә озайган. Гүя җәйнең яшел хөлләләре урынына асылларга уранганнар.

Ләкин боларның һәммәсен күз генә күрә. Әмма йөрәкләр, кяиннаттан җан вә хәят алынып, аның урынына әллә нинди олы аклык, олы яктылык белән олы ялтыравыклык кына калганын сизәләр.

Бүгенге көннең кичәгеләрдән артык имтиязы шунда: суык, суык, үтә суык! Шул дәрәҗәдә ки, кошлар оча алмый; маллар, йөрәк бәгырьләренә ярып төшкән бу салкыннан кайда әман[1] табарга аптырап, азбар ышыкларына сыеналар. Боларның баш-күзләре бәсләнгән, һәммә әгъзалары дерелди, һәрбер җан иясенең эчендәге казаны кайнап, шуннан куәтле бу чыккан сыман, һәрбер сулышы, суык һаваның арасына керә алмыйча, борылып-борылып югары менә.

Бу көн – кыш башы. Бу көн дөнья беренче кар белән беренче суыкны күрде. Әмма боларның тәэсире кышкы челләнекеннән дә яманрак. Әле аңа күнегеп җителмәгән: шул суык үзәккә үтеп, тәннәр дер-дер калтырый; тешләр шак-шок бәрелә; ачы шималь[2] җиле һәм зәһәр кара суыкның куәте җилекләреңә үтә китә.

Зур мәйданны каплап алган халык диңгезе исә, гүя суыкның шул ниһаясез куәтенә чыдаша алмаудан, туктаусыз кайный, туктаусыз дулкынлана тора. Тын күлләрнең иртән кояш чыгар вакытындагы хәле кебек, бу диңгезнең өстеннән күккә туктаусыз бу күтәрелә. Ул селкенә, дулкынлана һәм, туктаусыз гүләп, үзенең белемсез теле, аңлашылмас тавышы белән нидер сөйләп тора.

Карамалы – Зәңгәр чишмә белән Зирекле атлы елгаларның буена утырган, гомумән шул тирәдә булган авылларның иң зурысы, иң бае һәм иң мактаулысы. Анда зур-зур мәсҗедләр бар. Байлар да күп, сәүдәгәрләр дә байтак. Атна саен базар була. Борын һәр ел сентябрь аенда ярминкә дә ясала торган иде, соңгы елларда исә аны ни өчендер бетерделәр. Бу авыл һәр яктан да тирә-якка мәркәз: анда зур мәдрәсә дәвам итә; волостьның идарәсе дә шунда тора; һәр сайлауда диярлек старшиналыкка да бу авылның байларыннан берсе эләгә (тик писерләре генә чуаштан). Менә унынчы ел инде солдатка каралуны да өязлек каладан монда күчерделәр.

Бу авыл үзе зур вә киң яланнарның уртасында булган бер үргә утырган. Авылның нәкъ уртасында базар өчен дип хәзерләнгән бик зур мәйдан бар. Волостьның идарәханәсе дә шул мәйданга салынган. Идарәханә – иңе киң, буе озын, түбәсе карсак, тәрәзәләре зур вә караңгы күренгән бер бина булып, моның һәммә җире кызылга буялган. Шунлыктан тирә-якта моны «кызыл өй» дип йөртәләр. Халык телендә солдатка каралуны аңлатканда: «Сикермә, малай,

---

[1] *Әман* – куркынычсыз урын.
[2] *Шималь* – төньяк.

кызыл өйдән үтәсең бар әле!» – дип әйтү дә гомумләшеп бара. Чөнки никрутлар шунда каралалар.

Бу өйнең ике ишеге бар: берсе төнгә, берсе кыйблага карый. Каралучылар шуның кыйбла яктагысыннан кереп, төн ягыннан барып чыгалар. Шуңа күрә гавам авызында моны «дөнья сираты» дип охшату да гадәт хөкеменә кергән.

Һәр ел меңнәрчә егетләр шул сиратны кичәләр.

Зур мәйданны каплап алган теге халык диңгезе дә шул сиратны кичү өчен җыелган никрутлар белән анларның якыннарыннан – аталарыннан, ага-энеләреннән гыйбарәт иде. Меңләп никрутның һәрбере белән диярлек шундый якыннарыннан ике-өч адәм килгәнгә, монда башка һичбер җирдә – нә җыеннарда, нә сабан туйларында була алмаслык мәртәбәдә халык күп җыелган иде.

Үз алдына кайнашып, гүләп торган шул халык диңгезе эчендә һәм кыяфәте, һәм йөреше илә шул күмәк адәм уртасында ялгызга охшап бер егет йөри. Ул озынчарак буйлы, арык йөзле, башына каракүл бүрек, өстенә утырма якалы зур кара толып, аягына сары бурка белән резинка калуш кигән. Үзе талган күзләре белән тирә-ягындагы чобар адәм җыенын, хәйрәткә якын бер хәлдә, тамаша иткәнгә охшый.

Ул – ялгыз. Ахрысы, юри, теләп, ялгыз йөри; аңа кайбер егетләр, мөэмин сыйфатлы картлар ихтирам илә:

– Ә... Зыя мәхдүм, син икәнсең? Нихәл, исәнлекме? Каралырга килдегезме?.. Хәерле булсын, хәерле булсын, Алла котылырга насыйб итсен, – дип, дустанә генә сүз башласалар да, ул кыска вә өзек җөмләләр белән бик коры гына җавап бирә дә үз юлына китә.

2

Бүген никрутларны барлыйлар, жирәбә өләшәләр. Өлгерсәләр, яшелләрне[1] кертүләре дә ихтимал. Шунлыктан бу ел каралачак егетләр, якыннары – аталары, ага-энеләре белән, кичә үк Карамалыга җыелып беткәннәр иде. Зыяларның авылы Кара урман белән Карамалы арасы утыз биш чакрым. Бертөрлерәк атлылар өчен таңда чыгып, чакырылган вакытка, сәгать җидегә, килеп җитү авыррак та, атны да бик әйләндерә, халыкның кичтән үк монда килеп догуы да шуның өчен. Әмма Җәләлгә бу бернәрсә дә түгел. Ул кичәге көнне: «Хәзрәт, сез ни эшләп авылда? Халык китеп бетте бит», – дип бәхәс кыйлган адәмнәргә югарыдан карап, кискен рәвештә: «Соң чыксак та, җитәрбез без: Җәләл мулланың атлары бара ул!» – дип кенә җавап бирә иде.

---

[1] *Яшелләр* – буе, үлчәве җитмәү яисә сәламәтлеге начар булу сәбәпле узган елны алынмый калган никрутлар.

Һәм җитте дә.
Таңда авылдан чыгып, Карамалыга килеп җиткәндә, мәйдан халык белән тәмам тулган булса да, һичбер эш башланмаган иде әле.
Зыяның иң элек диккатен алган нәрсә – зур мәйданга җыелган халыкның шул дәрәҗәдә күплеге һәм аның, сарылы, аклы вә каралы төстә булып, бертуктаусыз селкенеп, бер яктан бер якка чайкалып һәм тавышлап торуы булды.
Җәләл, атларын бер егеткә биреп, Хәлил мулла йортына итәргә кушты да, үзе, «бик кирәк һәм бик ашыгыч кирәк булган» кешесен күрү өчен, теге кызыл өйгә таба китте. Зыя да картларның, бик ерактан белеш яисә бер дә таныш булмаган адәмнәрнең күрешүләреннән: «Ә, мәхдүм!.. исәнме, саумы?..» – дип сорашуларыннан, бигрәк тә, күзенә туры карап: «Ай-һай... мәхдүм... уразаны бик каты тоткансың бугай!» – диюләреннән качу өчен шул кайнап торган адәм диңгезе эченә кереп югалды.

3

Зыя бик күптән үк җыеннарда, мондый җыелышларда булганы юк. Ул, кыр, иген эшләрен ташлаганнан бирле, болай да авыл халкыннан аерылган, ераклаган иде. Шунлыктан бу чобар адәм җыены аның өчен бик мәшгаль[1] бер тамаша иде.
Ул шунда тышкы күренешләрне, төс вә кыяфәтләрне карый, үзләренчә сираттан кичәргә яисә якынын кичерергә торган шул халыкның сүзләрен тыңлый – монда кызык та бар, мәгънә дә бар. Халык исә чыннан чобар иде.
Монда кем генә юк! Иң әүвәл күзгә чалына татар никрутлары. Арада төрле кием, төрле кыяфәт булса да, болар көязлектә һәммәсе уртак иде. Болардан һичбере гади киемдә түгел. Бар да ясанган, чибәрләнергә тырышкан. Арада бигрәк купшылары да бар: бүгенге һаваның зәһәр суыгына карамыйча, бу купшы егетләр, эш өчен тегелгән, җылы, ләкин прастуй туннарын, тула чикмәннәрен ташлап, өстләренә бишбилле җылтыр кара бишмәт киеп, никрутлык хөрмәте өчен генә алынган кырык тиенлек бәйләм бүрекне маңгайга кырын салганнар. Такыр баш өши, колак ут кебек яна, ләкин аңа илтифат итми, чөнки көяз. Җылтыр кара бишмәтнең бер кесәсеннән кызыл өстенә ак дебет белән эшләнгән, икенчесеннән көрән өстенә сары белән чигелгән ике кульяулыкның салынып торуы егеткә тагы бер аерым көязлек бирә. Аякта, әүвәлге чабата урынына, өр-яңа җәйге резинка булуы дәртле никрутның башын тагы югарырак күтәртә. Тик, гөнаһ шомлыкка, калуш эчендә ак тула оек булуы гына азрак кәефне җибәрә, – шул, ничектер, прастуй сыман. Ләкин егет аңа да аптырамый. Бишмәте төсле үк җылтыр кара чалбарны бик озын итеп

[1] *Мәшгаль* – кызыклы, мавыктыргыч.

салындыра да, оекның әсәре дә күренми. Хәтта читтән караган һәркем: «А... бу егет итек белән яңа резинка кигән!» – дип искитәрлек ыспай тора. Билдә, әлбәттә, бик киң итеп уралган бурлат билбау. Муенда ак шарф. Аның бер очын алга, икенчесен артка салса, менә сезгә тирә-якны шаккатырырлык купшы егет, ыспай никрут! Ул сират кичәргә тора. Шунлыктан аңа ни эшләсә дә ярый, ул яшереп тарткан махоркасы урынына, каралырга килгәч, егермесе биш тиенлек папирос алган. Шуны, һичкемнән шикләнмичә, ике бармак арасына кыстыра да, төтенен вә барлык тартуын «госпадаларча» чыгарырга тырышып, бик һавалы вә эре кыйлана; аның бөтен торышы дөньяга югарыдан карап:

– Күрәмсез? Мин – кем? – дип тора.

Әгәр дә кулында гармуны да булса, бетте инде дөнья: шуның белән авыл никрутының башы күккә тия! Шулар янында ук тышсыз ак тун, түбәсе җыртылган иске бүрек, оек, чабата киеп, бу егетләрнең агалары йөри. Болар дөньяга авыр карый; болар никрут энеләре кебек башларын күккә күтәрми; мактанырга, купшылык күрсәтергә дәртләре дә калмаган. Болар дөнья белән, эш белән басылган. Хәзер дә шул кайнаган халык эчендә дә очынып китә алмыйлар. Йөзләренә карасаң, башларында: «Энем китсә, бер эш кулы югала... Тагы акча тотарга кирәк була – шул начар!» – дигән уйдан башка бернәрсә дә юктыр кебек тоела.

Арада бик күп аталар – ир уртасы татарлар, мәгъсум мәсҗед картлары да бар. Бу икенең әүвәлгесе туп-туры: «Угылым китсә, дөнья көтү үз өстемә кала, баеп булмый!» – дип тордыгы хәлдә, теге җеп кебек кенә калдырып кырылган мыеклы, көрәктәй ак сакаллы булып, өстенә тышы буй-буй телгәләнгән намаз туны белән, башларына калыбы бозылып, ямьшәеп беткән чалма бүреге кигән мәсҗед картлары, үзләренең бөкре саннарын турайта төшеп, әллә кайлардан кысылып чыкканга охшаш бер тавыш белән кайгырып, шулай да һәр эшне Тәңренең үзенә тапшырып йөриләр:

– Бәндә сагышлый, Хода багышлый, дигән картлар. Аллаһы Тәгаләнең үз ирке инде... Ул ни дисә, шул булыр... Безнең кайгырган белән булмый, балалар. Аллаһы Тәгалә ризыкларын чәчкән булмасын... Ризыкта эш, ризыкта, балам... Безнең хәзрәт мәрхүм бар иде, шул мәрхүмкәең әйтә торган иде: кеше Себергә китте, фәлән итте дип сөйлиләр, ди торган иде. Кеше үзе китми ул, аны ризык тарта, ризык, ди торган иде, һәр бәндәнең, ди торган иде, үзе тумас борын йиәчәк[1] ризыгы билгеләнеп куела... Аллаһы Тәгалә шул ризыкны кайда чәчсә, шул ризык бәндәне тарта, ди торган иде. Бик яхшы кеше иде мәрхүмкәең... Менә, балалар, шулай ул...

[1] *Йиәчәк* – ашаячак.

Бу сүзләр никрутларга, бер яктан, тынычлык биргән сыман булса да, икенчедән, эчләренә әллә нинди бер дулкын да җибәрә иде. Кайгырыргамы, шатланыргамы?– ризыгың читтә булса, ни генә кыйлсаң да, китәсең...

Русларның бик гади кыяфәттә булулары да Зыяның диккатен алды. Чынлап та, боларның никрутлары да һичбер көязлек күрсәтми: авылында, гади вакытта ничек булса, монда да шулай: шул фуражка, шул кара чикмән, шул күн итек яисә ыштыр белән зур чабата.

Боларга карасаң, монда җыелу сираттан кичү өчен икәнен дә онытасың; «ризык тартса, китми хәлең юк»ны да хәтердән чыгарасың: бар да гади һәм бик тыныч бер сыйфатталар.

Ләкин чуаш белән мукшы халкы тагы икенче төрле тәэсир итә. Баштанаяк кара сарык йонына уранган, кысык күзле, үлек йөзле, кыска буйлы вә бетен тирә-ягына, булса да ярый, булмаса да ярый – безгә барыбер, дип йөргәндәй вә, шуның илә бәрабәр, бөтен торышлары илә кемнәндер куркып иелгән; мең ел коллыкта ятып, әле дә шуның авырлыгыннан котылып, башларын күккә күтәрерлек хәл җыя алмаган мәзлум, бичара шикелле тоелган бу басынкы бәндәләргә карасаң, тагы башка бер халык күргәнеңне сизәсең. Болар шауламый, тилерми, башка халыкка күп катышмый. Тик бичаралар җиргә сеңәргә торалар.

Татарлар эчендә дәхи икенче бер төрнең дә хәле ярыйсы ук кызык. Болар – никрутлар өстеннән карау, тәртип саклау-фәлән өчен һәр авылдан, волостьтан килгән сотский, десятник, староста, старшина кебек «әфәнделәр»дер.

Болардан берсе яңлыш кына күзеңә чалынса да, хәзер моның гади бәндә түгел икәнен, бу ни белән булса да халыктан берәр илле югары мәртәбәдә идекен сизеп аласың. Чөнки бөтен торышлары, кыйланышлары моны ачык күрсәтә. Бигрәк тә Кара урман старостасы.

Болар авылда да, ягъни мәсәлән, прастуй мужик түгел, монда инде әйтергә дә юк. Баштагы мискин бүрекне кырынрак сала; мыекны, мәһабәтрәк булсын дип, бөтереп җибәрә; аякта чабата, Өсттә иске тун булу аңа бер дә зарар бирми; чөнки тунның тышкы ягында киң тасма белән асылган зур калай медальме, мәртәбә галәмәтеме аның күкрәген бизәп, бөтен дөньяга каршы аның кем икәнен кычкырып тора: ул – баш булырга жибәрелгән!

Һәм баш булырга белә дә: ул үзен һавалы тота; кызыл өйгә еш-еш кереп китә дә, аннан моңа бик мөһим эш, вазыйфа тапшырылган адәм сынлы чыгып һәм халыкка эре вә югарыдан карап:

– Әй, минем никрутлар! Таралмаңыз, китмәңез! Менә хәзер жирәбә алырга кертәбез! Порядканы бозмаңыз! – дип кычкыра.

Гөнаһ шомлыкка, берәр егет аңардан каралуга тәгаллыклы[1] бер нәрсә сорап куйса, ул сынын турылата, башын күтәрә дә, тамагын кыра төшеп:

– Әйе! Ул, мәсәлән, болай булырга мөмкин инде! – дип, ярылырга керешә.

Бундый сүзләрдә ул инде, әлбәттә, гади генә сөйләшми; җитди, түрәләрчә, үзе көлми дә; тавышын үзгәртеп, тамагының әллә кай җиреннән, төптән, тәмам начальникларча чыгарырга тырыша.

Зыяның шунда каралырга килгән бер шәкерт иптәше болар ны чабаталы түрәләр дип атаган иде. Шул исем, каралучы шәкертләр эченә таралып, призыв көннәре үткәнче анларны чабаталы түрә дип атап йөрделәр.

Әйе! Болар – түрә. Һәм чабаталы түрә иде.

4

Зыя шул чобар дөньяны тамаша итеп йөридер иде. Яшь мөтәрәккый[2] мулла кыяфәтендә булган бер адәм таныр-танымас кына рәвеш белән аңа таба килде дә, якынына җиткәч, зур кәшефкә ирешкәндәй күтәрелү белән:

– Ә... туган, Зыя! Синме? Танымый да торам... Килгәнеңне ишеткәч, эзли-эзли арып беттем, – дип кул бирде, һәм, кулын ычкындырмыйча, сүзендә дәвам итте:

– Ә, иптәш, сине бик, бик күрәсе килгән иде. Исемең Зәңгәр чишмә буйларын яңгыратты. Синең турыда әллә ниләр сөйлиләр: берәү яманлый, берәү мактый... Мин синең өчен талашып, муллалар белән дошманлашып та беттем...

Зыя, дустанә көлә төшеп, мулланың кулын кысып, яклашуы өчен рәхмәт укыды; соңгы исә аңа сөйләргә дә ирек бирми иде:

– Син кайткалагансың бугай... Үзең килмисең, ә мин барсам, киткән буласың, йә киткәч кенә ишетәм. Беләсең, без бит мәдрәсәдә бик кызык яшәгән идек. Мин берсен дә онытмыйм... Сагынып бетәм шуларны... Соң нихәл, иптәш? Каралыргамы?.. Бик ябыксын,... Әлбәттә, калырсың...

– Белмим, әй! Шулай дип дога кыйл инде.

– Соң, иптәш, син атаң белән ничек килештең? Өзелгән идең түгелме?

– Госман агай, ул бик озын мәсьәлә. Аны икенче бервакыт сөйләшербез... Син хәзер шуны әйт: фатирың кемдә? Ерак булмаса, кичкә сиңа барыйк, җә син миңа кил! Синең белән бик күп сөйләшәсе бар.

Госман бер генә секунд уйлап торды да җавап бирде:

– Сез үзегез кемдә? Хәлил мулладамы? Анда булса, баруның кызыгы юк; анда җыен карт муллалар, аксакАллар җыела да, сүз китә, талаш китә... Мин анлардан туйдым инде; минем фатир бик якын түгел. Шулай да миңа барыйк, мин сине моннан үзем алып китәрем. Ярыймы?

---

[1] *Тәгаллыклы* – бәйләнешле.

[2] *Мөтәрәккый* – прогресс яклы, фән һәм культура өлкәсендә алга баруны яклаучы кеше.

– Ярый, бик ярый!

Госман кызыл өйнең төн ягына бераз карап торды да, Зыяга шул якны күрсәтеп:

– Кара әле, ул – кемнәр?.. Синең картмы берсе?

– Әйе, шулар шул: атай, Сафа мулла, Бәдри ахун, белмәм, тагы әллә кемнәр!

Дөресте дә, кызыл өй буйлап боларга таба бер көтү адәм килә иде. Болар эчендә үзенең зур буе, мөмтаз кыяфәте белән иң элек Җәләл мулла күзгә чалына; аның башында яңа камалы бүрек; өстендә зур якалы, яхшы тышлы төлке тамак толып; аягында шәһәр эше яхшы калуш пима. Аның өст ягыннан американ читекнең кунычы ялтырап тора. Мулла, һәммә киеме белән аерылган шикелле, үзен тотуы, аяк атлавы белән үк тирә-ягына: «Күреңез, Җәләл мулла килә!» – дигәндәй күренә иде. Янында ак пима, ак бәрән толып, мискин бүрек кигән берничә мулла белән урта сәүдәгәрләрчә киенгән ике адәм; дәхи чиертсәң битеннән кан чәчрәп чыгарлык мәртәбәдә кызыл вә симез йөзле, зур буйлы, җуан корсаклы бер старшина да бар иде.

Шул җуан адәм килеп җитәр-җитмәс сүз башлады:

– Ә!.. Бу кем икән, бу нинди урыс баяры икән! дип торсам, Зыя мәхдүм, син икәнсең!.. Нихәл, исән-сау кайттыңмы?..

Зыя һәммәсе белән күреште, старшина, аның бер башына, бер аягына карап, дәвам итте:

– Ай, аяй! Мәхдүм! Үзеңдә бер дә генә мөселман сыйфаты калмаган: тун дисәң, нинди! Бүрек дисәң, нинди! Аягыңа кигәнең аннан да яман... Җәгез инде, хәзрәтләр, сезнең үз балаларыңыз, мәхдүмнәр шулай йөргәч, безнең мужикка ни сан инде... Безгә бит чәчне пумала кебек җиткереп йөрисе генә кала...

Зыя, старшинаның бу сүзләрне шаярып әйткәнен белмәгәнгә, янындагы көлемсерәп торган муллаларга бер кат күз йөртте дә, сүзенә көлү сыйфаты биреп:

– Нурмөхәммәт агай, син мине алай бөтенләй үк урыска сатып җибәрмә әле: менә бит минем бүрегем мөселманлыкның йөрәге булган Казан халкыныкы... Анда мөселманнар шуны кия, – диде.

Старшина, аның җилкәсенә уң кулын куеп, йөзенә вә тавышына ныграк иркәләгәнен чыгарып:

– Юк, мәхдүм, юк, шаярып кына сөйлим, авыр алма... Без кара кеше. Сез үзеңез китап, Коръән күргәнсез, бездән артык беләсез, үзеңез юлын тапкансыздыр инде, – диде.

Сүз икенчегә күчеп, голәмалар Зыядан берәм-берәм сораша башлыйлар.

Тирә-якның иң карт, ләкин иң надан һәм иң иске мулласы саналган Галим хәзрәт, бөтенләй исе киткән бер мәсьәлә төсле итеп, Салих атлы бер егетне

сораша. Бу – Галим мулланың авылдашы булып, яшь вакытында аңарда укыган да, ятимлеге сәбәпле, икмәк-тозыннан да файдаланган икән, хәзрәт шуның хәзерге хәленә артык аптырый:
– Җә, мәхдүм, дөресен сөйлә, – ди, – растмы? Шул Салих, чәч җиткереп, биленә каеш бәйләп, әллә нинди марҗалардан урыс кенәгәләре укып йөри имеш, ди...
Яшь, мөтәрәккый мулла түзә алмый, бәхәс итә:
– Соң, хәзрәт, укыса ни булган, – ди. – Гыйлем бит барыбер: марҗадан укыдың ни, хәзрәттән укыдың ни!.. Пәйгамбәребез бит, кытайдан булса да гыйлем алыңыз, дигән...
Старшина, Госманның күзенә карап, тагы, тагы дигәндәй күлә дә кулы белән аркасына төртә. Галим хәзрәт исә берьюлы кызып китә:
– Куй, ахмак! сөйләмә! Сәб голәма кыйласың[1], голәма белән марҗаны бергә куясың... ахмак... Яшь кеше син, тыгылмаска, тыңлап торырга кирәк иде... Син үзең дә шулардан... Тик бездән оялганга гына каешыңны яшерәсең... ахмак... Гыйлем алу дисең... Марҗада нинди гыйлем булсын?!
Сүз кызып китте. Галим хәзрәт, йөзенә барлык ачуын, кызулыгын җыеп, аягын тибә-тибә Госманны сүгә; башкалар берсе берәүне, берсе икенчене яклый. Талаш, моназара.
Бу, бәлки, озак та дәвам итәр иде. Тик, старшина, җаен табып, сүзне икенчегәрәк борды:
– Галим хәзрәт, анысы-анысы әле... Син ишеттеңме? Ул бит әллә нинди китаплар чыгара, ди... Менә, хәзрәт, аның китапларын күрәсе иде...
Мулла исә, берьюлы ачуын басып, сүзнең телгә алырга түгел, өстенә төкереп тә ташламаслык бер нәрсәгә күчкәнен белдерер рәвештә, уң кулы белән сөйләүчегә таба селки дә шелтәгә керешә:
– Сөйләмә шул юкны! Күрдем мин аның ул лыгырдыкларын... Кайчандыр Сабир кибетче йөгереп килгән дә, алтын тапкан адәм кебек: «Хәзрәт, хәзрәт, кара әле, – ди, – синең шәкертең, теге ятим Салих, зур мәртәбәгә ашкан икән... Менә әллә нинди гыйбрәтле нәрсәләр язган... Калада бар халык мактый!» – дип очына. Карасам, Сабирның керткәне әкиятләр, җырлар икән. Өстенә аяк тибеп кычкырдым да, син мине мыскыл итәргә кергәнсең икән, дип, эт урынына тиргәп чыгардым. Үзе ахырдан тәүбә итә, юк, ди, хәзрәт, ди, кешеләр мактагач, мин яхшы нәрсә дип белгән идем, ди... Мин, Нурмөхәммәт, сине ару дип торсам, син дә шуларны телгә аласың!.. Ни дип беләсең син анларны?! Ул әкиятне кем язмас?.. Имеш, бер кыз булган, кияүгә барган... Ире кыйнаган... Бер шәкерт булган... мәдрәсәдә укыган... кызлар артыннан йөргән... Шуны язалар да

[1] *Сәб голәма кыйласың* – галимнәрне сүгәсең.

китап дип чыгаралар. Җитмәсә, җырлар да кушалар. Ай, җыен эт авыз... Адәм калдыклары... Шуларны тагы акча биреп алалар. Язганына да акча түлиләр имеш, ди. Салих бер китабын утызга, берсен илле сумгамы саттым, дип яза икән... Менә замана, менә һәлакәт... Имеш, җыр яз, әкият яз да, китап диң, шуңа акча ал... Андый маләягъни[1] кирәк булса, әнә безнең җүләр Хафизга гына килсеннәр: ул акчасыз ук бер көндә биш әкият язып бирер... Җырын да ким куймас!.. Былтыр Садыйк бай, шуңа биш сум садака биреп, теге Гыйльманнарны яманлап бәет чыгарырга кушкан икән, тетеп кенә салган. Кай җирең кычыта... Теге Гыйльманнар, ярылса, җир тишегенә керердәй булганнар...

Хәзрәт дәвам итте, халыктан, муллалардан бәхәс кылучы булмады. Зыя белән Госман исә, бунардан читкәрәк китеп, шул Салих хакында сөйләшәләр иде... Галим мулла, ничектер, Госманның: «Салихның шигырьләрен, язуларын гәзитәләрдә мактыйлар икән. Мин шуларны укыдым!» – дигәнен ишетеп калды да тагы чәпчеп китте:

– Гәзиттәме?? Гәзиттәме? Ул гәзитне кем чыгара соң?.. Сезнең кебек кыска койрыклар бит. Әллә анда җүнле адәм бар димсең?.. Ашарга тапмыйлар да, дөньяның гайбәтен сатып, акча җыялар... Мин менә падишаһ булсам, барын җыяр идем дә, сырт буйларын тунатып, тәүбә иттерер, барлык китапларын утка ягар идем... Тагы тыңламасалар, көлләрен күккә очырыр идем мин ул эт авызларның...

Муллаларның каюсы яна, каюлары иске булса да, гәзиткә яманлап яздырудан куркалар. Шунлыктан Зыя алдында Галим хәзрәт ягыннан сүзгә керешмәделәр.

Мәсьәләне боларга хәзер генә кушылган икенче бер яшь мулла бүлде:

– Нихәл. Зыя әфәнде, исәнлекме? Иң әүвәл шуны әйтәм, собраниегә кереп чыккансыз дип ишеттем. Аңа бик шатмыз... Юкса менә бу муллалар безнең колак итемезне ашыйлар... Әнә, диләр, сезнең иптәшегез Зыя да ничә ел укып йөргән булды, үзе бер эш тә чыгара алмады, диләр... Соң нәрсәләр сорадылар? Ни бирделәр?..

Галим мулла тиз генә җавап бирде:

– Ни булсын, имам хатибтыр...

Баштан бирле угылы Зыяның муллалар арасында үзен зур тота белүе һәм аңа тирә-яктагы халыкның илтифаты өчен эченнән бәйрәм итен, шуның кызыгы белән күп сөйләшми торган Җәләл мулла Галим хәзрәтнең бер күзенә, бер селкенеп торган ак сакалына карады да бик кискен тавыш белән угылы өчен җавап кайтарды:

---

[1] *Маләягъни* – мәгънәсез, кирәксез эш.

– Ни сөйлисең син, Галим абзый! Җәләл мулланың угылы булсын да, хатиблык белән калсын! Ул бит, синең Җәгъфәрең кебек, Карамалы мәдрәсәсендә арыш икмәге кимереп ятмаган: Уфа күргән, Оренбур күргән, Казан күргән – ничә җирдә хәтме көтеб кыйлган... Аңа да мөдәррислек бирмәгәч, дөньяда кем мөдәррис булыр?..

Ярым көлеп, ярым мактанганлыгын белдереп әйтелгән бу сүзгә бер шаян мулла бәхәс итә:

– Юк ла, хәзрәт, азрак арттырасың инде, хатиб кына бугай?

Бу муллага Җәләл күптән ачулы иде. Аны тыштан белдермәсә дә, голәма мәҗлесендәге бер сүзе өчен аны кайчан да булса бер согындырырга уйлап йөри иде. Тегенең бәхәсе форсат булды:

– Энем, син чамаңны белеп ырылда. Бик күп өрсәң, эте бар диярләр... Мин гомеремдә алдаганым юк...

Һичкем моны көтмәгән иде. Алай ачуланырлык урын да юк кебек иде. Шунлыктан халык гаҗәпләнеп калды, мулла исә, йөзенә ачу катыш кибер чыгарып, сүзендә дәвам итте:

– Безнең ата-бабадан шулай килә инде... Әле ул көн Гыйнаят казыйны күргән идем: ну, мулла, ди, угылың укыган икән! – ди... Күпме еллар имтихан кыйлып, аның кебеккә очраганым юк иде, ди; сүзеңне сорап бетмисең, ул ут кебек чәчрәтеп, әллә кайчан җавабын аткан була...

Зыя, Госманга карап, көлә төшеп, читкә борылды; Җәләл дә сүзен бетерде:

– Без, ди, шуннан соң җүнләп имтихан да кыйлмадык, ди. Мөфти үзе дә, рәхмәт укып, үз кулы белән: «имам... х... а... т... и... б… вә м… ө... дә... р... р... и... с» дип куйган. Хода ул якларын биргән иде инде. Исән-сау котылырга гына язсын дип торам... Бүген калса, иртәгә Ыстамбулга җибәрәм... Мал бар, байлык бар, әлхәмделиллаһи шөкер! Ыстамбул күрсен, Мысыр, Бәйрут күрсен, Мәккә, Мәдинәдә булсын... Адәм булсын, кеше кыйла алмаганны ул кыйлсын...

Җәләлнең бу сүзләреннән һәммә кешенең эченә бер салкын йөгерде, һичкем нә сүз кушарга, нә җавап бирергә җай тапмады, бу җыелышның артык дәвам итәргә мөмкин түгеллеге һәркемгә сизелгән кебек булды, һәрбере, сәбәп табып, таралыштылар.

Зыя да, кичкә Госманга барырга тагы бер мәртәбә вәгъдә кыйлып, әле һаман да кайнамакта булган халык диңгезе эченә кереп югалды.

5

Картлар, муллалар вә шәкертләрнең һәрбере, үз ишен табып, шундый үзе өчен кызыгы булган әңгәмәләрне коралар; гавам, никрутлар исә, җыелып-җыелып, шаяралар, көрәшәләр, гармун уйныйлар, биииләр. Шөйлә ки, кара болыт

шикелле булып зур мәйданны каплап алган ул күп халык туктаусыз кузгала, туктаусыз агып, дулкынланып тора; аның һәр ягында төрле тавышлар, уеннар ишетелә... Хәрәкәт, хәрәкәт, хәрәкәт...

Зыяның бу көне исә мулла, шәкерт, никрутлар илә сөйләшеп, бигрәк тә шул хәрәкәтне тамаша итеп үтеп китте.

Бу көн никрутларны бер мәртәбә барлау (паверка кыйлу), икенче мәртәбә жирәбә өләшү өчен теге кызыл өйгә кертеп чыгарудан башка эш булмады. Яшелләрне бәлки карарлар да дигәннәр иде; кайсы елны, башка эш иртәрәк бетсә, шулай була да торган иде; ләкин бу ел, карау комиссиясенең башлыгы бераз кәефсез булу сәбәпле, шул ике белән бүгенгә эшне тәмам иттеләр.

Кояш вә аның артыннан шәфәкъ тә батып, җир йөзен караңгылык алгач, халык та фатирларына тарала башлады.

Зыя, баягы иптәше Госман белән тагы очрашып, аның фатирына бару өчен чанага утырырга гына хәзерләнгәннәр иде; бик арып, ахылдап беткән бер малай килде дә, тыгыла-тыгыла:

– Көчкә-көчкә таптым, атай... Зыя абзый, сине Җәләл мулла бабай, кайтсын, диде, менә запискасы да, – дип, бер кәгазь кисәге чыгарды.

Зыя ачты да, бер өйнең тәрәзәсеннән төшкән яктыга китереп, укый башлады:

«Зыя!

Олуг күлнең Камал мулла угылы Салих сиңа ат җибәргән; вакыты булса, бүген кич безгә килсен иде, дигән. Барамсың? Барсаң, кайт фатирга».

Укып чыкты да, Госманга карап:

– Иптәш, Олуг күлгә чакырганнар. Ничә чакрым моннан, әйдә бергә барабызмы? – дип сорады.

Ул да, һичбер уйлап тормыйча ук:

– Ник бармаска, ул моннан биш кенә чакрым, әйдә киттек, – диде.

Атларны бордылар да Хәлил муллага юнәлделәр. Никрутлар Салихтан килгән ат белән генә бармакчылар иде, Җәләл бер дә якын килмәде:

– Шундый киемнәр, шундый кыяфәтләр белән монавы кәҗә тәкәседәй атка утырып йөрергә ярыймы соң? – ди.

Һәм үз сүзен итте: үзенең зур чанасына пар атын кыңгыраулар тагып җиктерде дә, кучер утыртып, тәмам тантана белән озатты.

– Бар, йөргәч зур йөрегез инде, – ди.

6

Зыялар, иртә белән караңгылы-яктылыда кайтып, кызыл әй янына килгәндә, мәйдан тагы шул халык белән капланган иде. Ләкин халыкта кичәге нәшат[1],

[1] *Нәшат* – шатлык, күңеллелек.

кичәге җан калмаган иде: бүген тын, басынкы, авыр.
Жирәбә алу төрлечә тәэсир иткән. Күпләр, бигрәк тә якын номер чыкканнар, кулларына жирәбә бирелүне, фатирларына кайтып, үз Алларына калгач, яртылый эләккән яисә әләгергә бер генә адым калган кебек итеп хис иткәннәр. Күбесе әллә нинди яман төшләр, солдатлар, иске мылтыклар күргәннәр... Аны хәзер бер-беренә сөйләшәләр. Гармуннар уйнамый. Биючеләрнең эзе дә юк. Башкача да шаярмыйлар. Уенчак егетләрне яман төшме, киләчәкне сизенүме баскан.
Сәгать җиде булганда яшелләрне (былтыр каралып та паправкага калганнарны) кертә башладылар. Болар бик күп түгел иде, – барлыгы утызмы, кырыкмы егет, шуның да берничәсе генә алынды.
Кызыл өй тирәсен умарта корты кебек сырып алган халык, үзенең иртәнге басынкылыгы астында чакта, бик авыр сүз кебек итеп:
– Менә хәзер кыра башлыйлар! – ди иде.
Шул сүз аны тагы ныграк баса, шул «кыралар»ның бер башы үзенә төшәчәген белеп, тагы авырая, тына иде. Яшелләр кереп тә, күбе котылып чыккач, халыкта бер үзгәрү башланды, гүя теге «кыралар» каядыр югалып, аның урынына «әллә калырмыз да» җирләште; вә шул бераз йөзләрне ача, яктырта. Шуның белән бергә әллә нинди өмитле хәбәрләр дә сөйләнә башлады:
– Бу ел Казаннан шәп доктор килгән имеш... Бик аз гына ярамаса да алмый имеш... Каралучы бик күп, ә алынасылар аз, фәлән имеш, төгән имеш...
Халык шуларны сөйләү белән бераз җиңеллек тоя, мәйдан тагы бераз җанлана төшә.
Ләкин бу хәл озак дәвам итмәде. Менә яшелләр каралып, бер ун минут кына үткән иде, кызыл өйнең кыйбла як ишегендә бер адәм күренде, – кыска, кара киемле, ялтыр итекле, озын чәчле бер егет.
Бу – волостьның писере булып, уң кулында озынча бер дәфтәре дә бар иде. Шул арада теге «чабаталы түрәләр»дән берсе писернең янынарак килде дә: – Әй... никрутлар! Җыелыңыз! Карарга кертә башлыймыз! – дип кычкырды...
«Кыралар» тагы халыкның башына якынлашты, бу сүз гүя шуның югарыда асылып торган җиреннән монда таба кузгалуын белдерде. Никрутлар, берьюлы вә бик тиз агара төшеп, шул ишек тирәсенә кысылып, тыгызланып, җыелыша башладылар. Писер дә халыкка бер мәртәбә карады да йомшак тавышы белән:
– Яхшы тыңлаңыз, туганнар!! – дип, дәфтәрендә язылган исемнәрне кычкырып укый башлады:
– Владимир Алексеевич Петров?
– Монда!

– Гыйльман Насыйр угылы Кәримов?
– Монда!
– Кәрәм Җәгъфәр угылы Бәширов?
– Монда!
Писер берәмләп сорый тора, егетләр «монда!» дип кычкыралар да, башлары белән диңгезгә чумган адәм .кебек, ни эшләгәннәрен дә ачык белмичә, шул ишектән кызыл өй эченә атылып кереп китәләр...
Утыз егетне исемләп чакырды да писер: «Хәзергә җитте!» – дип, эчкә кереп китте. Халык исә, үз күзе .алдында, тәгъбирләреңчә, сиратка кереп киткән егетләрнең шуннан ничек кичүен, ягъни «кырылыпмы», калыпмы чыгуын белми калмас өчен, тиз генә кызыл өйнең аргы башына барып, шундагы ишек тирәсенә җыелды.
– Йа Ходай, ни була?
– Каламы, китәме?
Мәйдан тәмам үлде, җан бирде; һәммә кеше, бигрәк тә хәзер кызыл өйнең эченә кереп киткән егетләрнең якыннары, җанын, йөрәген шул ишеккә баглап, шул ике сөальнең тәэсире астында сабырсызлыкта тора...
Менә көткән минут җитте. Кызыл өйнең төньяк ишеге ачылып, анда бер егет заһир булды. Йөзе үлем төсле агарган, кыяфәте бозылган, караңгы һәм кайгы белән капланган... Моны күрү белән, бөтен мәйдан берьюлы телгә килеп, төрле аваз белән кычкырып җибәрде:
– Нихәл, егет?.. Калдыңмы?
Егет йомшарган, теле белән җавап бирә алмый, тик халыкка карап, өмитсезчә башын селекте, вә шуның артыннан ук күзләреннән ике бөртек яшь чыкты.
Иштә, сиңа җавап: димәк, «китте».
Зыя бу егетне таный. Ул – аның авылдашы, үткер, кыю, шәп никрут кебек иде. Ул каралырга язылганнан бирле, үзенең никрутлыгы белән мактанып: «Курыкмыйбыз без, китәбез, патша безне дә алмагач, кемне алыр?!» – дип йөри диләр иде. Монда килеп, өченче номер жирәбәне алгач та: «Ах, булмады бит... Беренче номер чыксын иде дип йөргән идем... Без бит барыбер китәбез... Киткәч, киткәч беренче булып китәргә иде!.. Өч сум акча бирәләр, имеш, беренчегә – шуны да алырга иде!» – дип йөргәнен Зыя үзе дә ишеткән иде, шунлыктан ул бик тәгаҗҗеб итте...
Аның артыннан икенчеләр, өченчеләр чыга башлады...
Монда да ишектә егет күренү белән бөтен мәйданны:
– Нихәл? Калдыңмы, малай?! – тавышы яңгырата. Монда да егетнең йә теленнән, йә кыяфәт вә йөзеннән:

– Киттем!
– Киттем!
– Киттем! – җаваплары бирелгәч, бөтен халык, теге «кыралар»ның мәгънәсен тагы төплерәк аңлаган кебек, өстләренә салкын су сибелгән кебек бер хәл тоя.
«Кырып салу» байтак дәвам итте. Беренче чакыруда кертелгән утыз никруттан тик икесе калган. Анларның берсе аксак, берсе тегермәнче урыс баеның угылы икән. Болар чыгып бетәр алдыннан баягы озын чәчле писер тагы ишек төбендә күренде; “чабаталы түрәләр”дән берсе тагы тәмам начальникларга охшаш бер тавыш белән:
– Әй, никрутлар! Тизрәк җыелыңыз: каралырга кертәмез! – дип кычкырды да, халык тагы, кысыла-кысыла, кызыл өйнең кыйбла як ишеге төбенә җыелды.
Писер берәм-берәм атап тора, егетләр, исемнәрен ишетү белән, кызыл өй эченә атылып торалар. Ул берничә мәртәбә шулай чакырды. Халык та кызыл өйнең бер төн ягына, бер кыйбла башына килеп, бер яктан никрутны кертеп, икенчедән каршы алуда дәвам иттеләр. Төньяк ишектә бер егет күренгән саен әле һаман да бөтен мәйданны:
– Нихәл? Калдыңмы? – тавышлары яңгырата иде. Егетләрдән исә «китте», «киттем», «китте», «киттем» авазлары туктаусыз чыга тора иде.
Халык шаша калды; инде аптыраудан, ис китүдән дә арый башлады. Чыккан егетләр: «Харап, туганнар... Җүнләп карамый да, сыдырып кына сала...» – дип сөйләүләре бөтен халыкның йөрәген кузгата, табигатьләрен басып, йөзләренә курку вә нindidер томанлы кайгы чыгара.
Шулар илә бергә әллә нинди куркыныч вә шомлы хәбәрләр дә тарала башлый:
– Имеш, Бурлыда солдат җитмәгән... Шунда җитмәгәнне монда тутыралар имеш... Бу ел былтыргыдан әллә ничаклы артык алырга имеш... Шунлыктан чирутныйлардан[1] аксак-туксактан башка беркем дә калмый имеш... Ыфтаруй рәзрәтләр[2] дә бетә имеш...
Өйләгә таба сирәкләп кенә «калды», «калдым»нар да ишетелә башлады.
Ләкин болар гына халыкның баягы басынкылыгын, баягы авыр караңгылыгын ача алмый. Җитмәсә, кызык кына бер вакыйга да булып алды:
Ишектә күренде бер егет. Ул – шат, ачык; үзе туктаусыз көлеп чыга... Моны күрүгә халык гүя үзен тәхкыйрь кыйлган[3] бер адәмгә каршы кычкыргандай тавыш белән:
– Ни бар? Ни эшләдең?! – дип акырып җибәрде. Егет исә, тагы ныграк көлә

---

[1] *Чирутный* (очередной) – чираттагы.
[2] *Ыфтаруй рәзрәтләр* – (второй разряд) – икенче дәрәҗәдәгеләр
[3] *Тәхкыйрь кыйлу* – мәсхәрәләү, хурлау.

төшеп:

– Ни эшлим, калдым! – дип җавап биреп, халык эченә керергә өлгерә дә алмады, кемдер таза, куәтле куллары белән егетне селтәп җибәрде. Егетнең аптыравына каршы, икенчеләр дә берәм-берәм кундыра, үзләренчә, «кабырга буйларын каезлый» башлап, тиз, кызу һәм сакитанә[1] теге «калдым»ны нык кына кыйнап ташладылар. Ләкин егет калу белән исергән иде, аркасына төшкән йозрыкларны җүнләп тоймыйча, юлына омтылды...

Бундый өлешне «калдым»нарның байтагы шулай ашаштыргалый иде. Каралучы шәкертләрдән дә өчесе кереп, икесе алынды, берсе калып чыкты. Ләкин буңа теге «өлеш», ни өчендер, бирелмәде.

Теге ике шәкертнең алынуы Зыяга үзенең эләгү ихтималын бик якынайтты: әнә бит Зыядан да ябык, Зыядан нечкәләр алынган. Ничек калуны өмит итәргә? Дөрест, атасы зур ышаныч белән:

– Мин кыйлачакны кыйлдым, кайгырма! – ди. Ләкин ул «кыйлулар» кайбер вакыт алдыйлар да шул.

Өченче мәртәбә чакыруда Госманның (теге яшь мөтәрәккый мулланың) энесе Шакир да кергән иде. Аны яшелгә калдырганнар. Шул ярым шатлык, ярым көенеч белән чыкты да, икәве бергә сөйләшеп тормакта булган Зыя белән Госманга килеп:

– Чукынсыннар ла, каһәр төшкерләре! Ахрысы, мине өч ел азапларга итәләрдер, – дип, боларны читкәрәк алып барды да, анда күреп чыккан гаҗаибатын[2] тасвир итәргә тотынды: – Ну, Зыя агай, синең анда күрәселәрең бар икән әле... Менә күрәмсең ишекне? Әнә шуннан кереп китәсең дә барып чыгасың зур гына бер бүлмәгә. Анда тузан, төтен. Анысы тагы бер хәл. Шул бүлмәнең урамга караган тәрәзәсе буенда бик простой бер өстәл бар. Шуның тирәсендә теге «чабаталы түрәләр”дән берничә адәм тора... Мин барып керүгә берсе таныды да: «Ә, мәхдүм, син икәнсең... Китер киемнәреңне, монда, безнең янга куй!» – диде. Бүлмә тыгыз, һава начар, һәрбер никрут шунда керә дә чишенә. Анда мин кергәндә, башка киемнәрен салып, тик кыска күлмәктән генә калган утызлап егет бар иде... Ис китте... Мин дә, чишенеп, шулар рәтенә тезелдем. Менә бервакыт шул бүлмәнең залга караган ишеге төбендә бер адәм күренде дә берәм-берәм безне эчкә, залга кертә башлады... Менә нәүбәт миңа да җитте. Атылып барып, залга кердем... Йа Ходай, күрсәң исең китәр: залның түрендә өсте яшел постау белән ябылган бик озын өстәл тора. Анда кәгазьләр, каралар, каләм вә гәзитәләр ята. Тирә-ягында әллә нинди зәңгәрле, сорылы

[1] *Сакитанә* – эндәшмичә, бер сүз дә әйтмичә.
[2] *Гаҗаибат* – искиткеч хәлләр.

киемнәр киенеп, медальле күкрәкләрен киереп, сары төймәле, кайсылары кылычлы, бик мәһабәт тугыз адәм утыра. Ә залның бу алгы бүлмәгә караган ишеге янында егермеләп егет тора. Күрсәң, төшме, өнме дип аптырарсың, валлаһи, күз ышанмый: һәммәсе озын, таза, куәтле егетләр, үзләре егермесе беррәттән тезелеп, шыр ялангач калганнар... Ичмаса, теге кыска күлмәкләре дә юк... Менә син шул картинаны күз алдыңа китереп бак. Кызыкмы булыр?..

Зыя, Госманга карап, көлә төшеп:

– Менә, иптәш, каралу искә төшкән саен, мине шул ялангачлык мәсьәләсе бик борчый, – диде дә Шакирдан: – Соң, үтенсәң дә күлмәк белән кертмиләрмени? – дип сорады.

Хикәяче Зыяның бик юкка исе киткәнен белдерер рәвештә:

– Әй, агай, син юктан курыккансың икән... Анда бит гаҗәиб бер хәл: зал тулы халык; өйнең тәрәзәләре аркылы тагы ничә йөзләп кеше тыштан да карап тора; син – шулар каршысында шыр ялангачсың... Ә оялу, тартыну дигәннең исе дә килми. Менә шул ишектән аягыңны атлау белән оят та бетә, гаүрәт тә бетә – берсе дә калмый. Бу һәммә никрутларда шулай... Искиткеч бер эш, әй... Аннан тагы шунысы бик гаҗәб: менә монда бит һәрбер никрут, куркып, китәм ахры дип, кайгырып йөри. Ә каралырга кергәч, бер дә алай түгел... Каралырга керү якынлашкан саен, йөрәк суга, күңел курка; ах, китәм инде, дисең; баскан урыныңда торып булмый... Писер синең исемеңне кычкыргандагы эчеңнең кайнавын, шул чактагы каушау вә калтыравыңны әйтеп бетерергә дә имкян юк...[1] Ә менә шул ишекне атлап кердеңме – бар да бетә, гүя өстеңә тынычлык суы сипкәннәр... Чишенәсең, әйберләреңне куясың – бернәрсә юк, хәтта кулың да калтырамый... Аннан соң залга керәсең, анда тагы тынычрак була... Бервакыт ыстанга чакыралар, буеңны, иңеңне үлчиләр – анда да бернәрсә юк, гүя сиңа яңа бишмәт тегү өчен үлчәү алалар... Аннан соң озын буйлы, куркыныч йөзле духтыр[2] янына, барасың... Ул тик кенә, туры гына торырга куша да, усал күзләре белән баштанаяк карап чыга... Менә җитте минут: шул усал адәм, тегендә утырган тугыз кешегә карап, ике-өч хәрефлек бер генә сүз әйтә, һәм шул синең язмышыңны тәгъйин итә. Син шуны ачык аңлыйсың, шулай икәнен беләсең, ләкин эчеңдә бик аз гына да каушау юк, гүя калдың ни, киттең ни – икесе дә бер кебек, калуда шатлык, китүдә кайгы дигәннең исеме дә юк шикелле тоела... Җитә актык секунд: духтыр авызыннан теге сүз чыга... Менә, шул вакыт син айныйсың. Шул вакыт алынганнар, күз Аллары караңгыланып, аяк астларыңдагы идән каядыр кузгалган, дөнья әйләнеп алган кебек бер хәл

[1] *Имкян юк* – мөмкин түгел
[2] *Духтыр* – доктор, врач

тоялар... Калучы егет тә, шул вакыт кына сизенеп, шатлыгыннан кая басканын белми, залдан чыгарга омтыла... Күпләре, артык куанудан залның ишеге төбендә калдырылган күлмәк-ыштанын да онытып, теге бүлмәгә ялангач көенчә барып чыга... Ә алынган бичараның йөзе агара, куллары калтырый, күбенең тәне дерелдәп, шунда эләккәннәрне язып торучы писернең өстәле янында катып кала... Бу өстәл янына килде димәк – эләкте димәктер, шунлыктан никрут бунда килсә, аның алыну хәбәре тыштагы якыннарына да ирешкән була. Теге чишенә торган бүлмәдә аның берәр якыны булса, көлүне мәңгегә оныткан адәм сыман аңа бер мәртәбә карый да: «Атайга әйт: минем баш китте, туган!» – ди. Ләкин бу җирдә елау-фәлән бер дә булмый әле... Менә кайчан ул кием бүлмәсенә чыга; аны киендерәләр; ул бу вакыт һичбер сүз дәшми, астка карап, һушсыз адәм кебек тик киенә... Соңра, тышка чыккач, халыкны, иректә йөргән адәмнәрне күрә, якыннары белән сөйләшә, кызгану сүзләре ишетә, – менә шуннан соң инде ул хәлне тәмам аңлап җитә, шуннан соң йомшара... тәмам йомшара... Менә, агайлар, нинди эшләр бар анда...

Шакир сүзен бетерде. Зыя да, аның күзләренә карап, ышанмаган адәм сыман:

– Дөрестен әйт, Шакир, бу тасвиратка үзеңнән күпме буяу куштың? – ди.

Теге көлә, үзенең ике мәртәбә бунда булганын, шунлыктан боларның бары да тәҗрибә белән беленгәнен әйтеп куя.

Шакирның каралып чыкканын күреп, аның тирәсенә якыннары, танышлары җыела башлый; сорашалар, сиңа тагы бер ел сәхәрсез руза тотарга кирәк булыр ахры, дип мыскыл итәләр...

Арадан берсе Зыя белән сүз башлады:

– Нихәл, мәхдүм!.. Жирәбәң ничәнче? Бик якын түгелме?

Ул номерын әйткәч, тагы сөальләр башлана:

– Нихәл соң, мәхдүм хәзрәт! Берәр авыруың-фәләнең юкмы? Калырга өмит бармы?..

– Болай күренеп торган авыру юк... Китү, калуны Алла үзе генә белә инде.

– Анысы шулай да шулаен...

Картның тынычсызлануына таза, симез бер адәм бәхәс итә:

– Бабай, син юкка хафаланасың... Үләргә торган, күләгә кебек мәхдүмеңне ни эшләп алсыннар, ди... Бетмәгәндер әле, бәрәңге ашап, арыш икмәге ашап, тазарган мыштым малайлары...

Карт, буңа җавап бирүне кирәксенмәдеме, үз сүзендә дәвам итте:

– Әйе, Аллаһы Тәгалә үзе ярдәмен кыйлыр әле... Ризыгы чәчелмәгән булса, калыр, Аллаһы боерса! Яхшы атаның, яхшы нәселнең баласы... Анлар ата-бабадан фатыйхалы кеше, догалы кеше...

Ул арада сүз икенчегә китеп, алынганнарның кызганыч булуы, кемнәрнеңдер яшь хатыны, ничә баласы калуы хакында кайгырыша башлаганнар иде. Баядан бирле шул таифә[1] эчендә булып та, бер дә сөйләшми, тик ачуланган сыман тыңлап торган бер адәм сүзгә кереште. Бу озын буйлы, калын гәүдәле, ярым русча киемле, карт йөзле, кырма сакаллы, зур чал мыеклы бер татар булып, рус тегермәнендә осталык хезмәтендә торучы икән. Ашыкмый, ләкин куәт вә ачу белән сөйли:

– Лыгырдыйсыз шунда, – ди, – дөнья күрмәгәннән: имеш, солдатка китә... харап була... Китте ни, калды ни бу заманда! Менә безнең заманда хезмәт иде ичмасам! Без киткәндә тумый калган малайлар, хезмәт тутырып кайтканда, үзе никрут булырлык үскән була... Калган егетләр, хатын алып, балаларына туй ясый башлаган булалар иде. Ә хәзер нәрсә! Китеп, бер-ике ел йөрмиләр, кайта башлыйлар... Җитмәсә, кайберләре шул өч елга да түзми, кунакка да кайткан була... Шуңа хезмәт дип, уф, китә дип кайгырып йөргән буласыз тагы... Ә менә безнең заманда хезмәт иде ичмасам... Анда еласаң да ярарлык иде... Ә хәзер нәрсә!..

Халык эченнән кемдер көлә дә үчекләүгә охшаш бер тавыш белән картның сүзен бүлә:

– Кәрим бабай, ул заманнарда солдатларны җир читенә җибәргәннәр имеш, диләр... Сез дә шунда бардыңызмы? Җирнең чите нинди?..

Карт, бу шаян егеткә бик агулы берәр сүз әйтер өчен, аңа таба карап, авызын ача башлый да, ни өчендер, тагы туктый һәм җавап та бирми, сүзен дә дәвам иттерми: ул үзенә һәм сүзенә һәр җирдә ихтирамны тели торган адәмнәрдән; егетнең мыскыл итүе исә аның кәефен җибәрә, шунлыктан сөкүт[2]белән кайтара. Карт бу хилкадан[3] бөтенләй китте, монда калганнар исә теге шаян егет кузгаткан мәүзуг[4] хакында хәзинәләрендә булган нәрсәләрне чәчә башладылар.

– Имеш, хатыны белән бер яшьлек кызы калган бер солдат егерме биш ел йөргән икән дә, ди, бер заман хезмәтен тутырып өенә кайткан икән, ди; аның каршысына бер хатын чыккан, ди. Солдат – шап! үз хатыным дип шуны кочаклап алган, ди... Ә ул аның үзеннән бер яшьлек калган кызы икән, ди. Анасына бик охшаган булганга, солдат шул дип белгән, ди... Ә аның үз хатыны, тәмам картаеп, тешсез карчык булып, пич башында ятмакта икән, ди...

Икенче берәүсе тагы ялгап алып китә:

– Без бала чакларда, – ди,- – кайталар иде солдатлар... Боларны күрергә бөтен

---

[1] *Таифә* – төркем.
[2] *Сөкүт* – эндәшмәү.
[3] *Хилка* – җыелышып, сөйләшеп торучы кешеләр.
[4] *Мәүзуг* – тема.

авыл җыела иде; анлар кая барса, урам тулы малайлар артларыннан ияреп йөри торган иде... Шулардан сораша торганнар иде: кайларда, нинди дөньяларда булдыңыз дип, ерак җирләрне күрдеңезме дип... Шуңа теге солдатлар, әллә кайларны күрсәтеп, кулларын селкә торганнар иде дә: «Сөйләмә инде, туган, без йөргән җирләргә очар кош та барып җитә алмас; без җирнең чигендә булдык, җирнең читенә барып җитеп, аяк салындырып утырдык; күрсәгез, исеңез китәр менә: шул җир бара-бара да, читенә җиткәч, теп-текә яр шикелле булып төшә дә китә, аннан ары бернәрсә дә юк... – дип сөйли башлый. – Җитмәсә тагы, шул җирләрдә болыт бик түбән була, болытка элеп мундирлар киптерәбез. Кояшны җыйнаулап тартып чыгарабыз...» – ди торган иде.

Әңгәмә куерды; шундый хикәяләр төрле авыздан бер-бер артлы ява башлады.

Зыя исә, теге ишектә озын чәчле писернең заһир булуын күреп, иптәшләре белән шунда таба китте.

7

Кичкә таба «кырып салу» бик аз гына акрынайган кебек булды. «Киттемнәр» рәтендә еш-еш «калдымнар» да чыга башлады. Тагы ике шәкерт, кереп, берсе алынды, берсе яшелгә калды. Зыя үз эченнән китү ихтималын бик якынайтып куйды. Ләкин бу халык эчендә күп нәрсә уйларга җай юк иде. Никрутлар эчендә исерекләр кичәдән үк бик күп булса да, бүген тагы артты. Алынганнар: «Киттек!» – дип, керәчәкләр: «Барыбер китәбез!» – дип, нык кына кага башладылар. Бу, бер яктан, авыр вә кызганыч күренеш бирсә дә, икенчедән, кызыгы да бар: халыкны җанландыра, мәйданга, асты ачы кайгы белән тулган булса да, заһири[1] шатлык бирә, хәрәкәт вә кузгалыш тудыра иде.

Чабаталы түрәләрдән бере тагы бик олуг тавыш белән:

– Әй, никрутлар! Тизрәк җыелыңыз, карарга кертәмез! – дип, бөтен мәйданга акырды.

Халык тагы кызыл өйнең кыйбла як башына тыгызлана-тыгызлана җыела башлады.

Писер маңлаена төшкән чәчен артка таба кайтарды да, озын дәфтәрен ачып, исемнәр кычкырырга тотынды:

– Дмитрий Николаевич Иванов?

– Монда!

– Михаил Алексеевич Савин?

– Монда!

«Мондамы?» – «Монда!»лар шулай әйтелеп тора; исеме чыккан бер егет кызыл өйгә атылып кереп тора...

---

[1] *Заһири* – тышкы яктан.

Шул кереп киткәннәрнең береннән Зыя сорап баккан иде:
– Номерың ничәнче?
– Йөз дә ике.
Берничә кеше аша дәхи сорады:
– Йөз дә тугыз.
Буны ишеткәч, Зыя үз жирәбәсен алып карады:
– Йөз дә унбиш.
Димәк, алты гына кеше калган. Аның берничәсе льгот булыр, әнә берничәсе кереп тә китте...
Алайса, Зыяга да керергә якынаеп калган, – ул шулай дип уйлап, бетәргә өлгерә дә алм.ады, теге писер ачы һәм куәтле тавышы белән кычкырып та җибәрде:
– Зыятдин Җәләлетдин угылы Сабитов?
Аның өчен Госман: «Монда!» – дип җавап бирде. Зыя: «Догада булыңыз!» – дип, кызыл өй эченә атылып кереп тә китте.

8

Сәгать ярым үткәч, карау тукталып, халык фатирларына таралды. Мәйдан буш, кызыл өй ялгыз калды.
Зыя, атасына эшнең чамасын, кая барачагын белдерде дә, иптәше Госман белән аның фатирына таба юнәлде. Аның язмышы бүген билгеләнә алмады: кереп чишенгәч, менә карыйлар инде дип кенә торганда: «Вакыт бетте», – диделәр дә ун егет белән Зыяны кире чыгардылар. Инде ни булса да иртәгә күрәчәк!
– Иптәш, мин синең бүген каралмый кире чыгуыңа бер яктан шатланам да: син бит, каралсаң, өеңә китә идең. Ә менә бүгенге төнне бергә үткәрәбез, ичмаса... Шулай түгелме?
– Әлбәттә, мин алынсам да, калсам да, чыккан минуты белән өйгә китәчәк идем. Анда бит минем әни ут йотып көтәдер; беләм, ул бичара бу өч көндә бер мәртәбә күз йоммады, ничә еллык картайды инде, бичара. Ул, дөньясын онытып, Илаһым, нинди генә хәбәр килер икән дип яна да тора инде...
– Соң, шулай ук кайгырамыни ул?
– Һич әйтергә түгел, әй... Мин өйдә чакта шул хакта бер сүз чыгарга ярамый, хәзер күзләре яшәрә, йөзенә кара болыт заһир була да, тавышы үзгәреп, бугазына күз яше килеп тыгыладыр иде. Бер көн эчендә әллә ничә мәртәбә елады... Ул үзе бик динле хатын, язмышка да бик нык ышана, ләкин болар ничектер аңа тынычлык бирә алмыйлар. Китәсе көнне шулай мин үземезнең язу өстәле янында ниндидер урыс журналлары, сурәтле язулар карап утыра идем; аякта итек, өстә кара күлмәк, билдә киң пояс, баш ялангач иде. Минем мондый кыяфәтемә анлар күптән өйрәнгәннәр иде. Баштарак бик шелтә кыйлсалар да,

теге йортны ташлап, анлардан галәкаләрне[1] өзеп йөрүләрдән соң, андый нәрсәгә һичбер бәйләнми башлаганнар – ни кисәң дә, барыбер күргән кебек тоелалар иде. Ә ул көн әни, яңа гына очраган адәм кебек, билдәге каешны да, салынып төшкән чәчне дә, алдагы сурәтләрнең дә һәммәсен берьюлы күреп, сизеп алды. Ишектән керде дә, иркәләгән дә, бик зур афәттән сакларга тырышкан да кебек бер тавыш белән:
– Ай, балам, ташласаңчы шул сурәтләреңне! – дип, тәнбиһ ясады[2] да, якындагы кәләпүшемне башыма кидертеп, сүзен дәвам иттерде: – Куй инде, балам, куй шул килешмәгән эшне. Иртәгә каралырга китәргә торасың, үзең шундый юк-бар нәрсәгә күз нурың түгеп утырасың... – ди.
Мин аңа: «Ни эшлим соң?» – дип, бик йомшак кына игътираз иткән[3] идем, ул тагы, йомшарып, сүзен бетерде:
– Мәсҗедкә барыр идең, картлардан дога алыр идең, зияратка менәр идең; кайтасың да китәсең, ике елдан бирле әрвахларга Коръән укыганың да юк.. Синең кебек шәкертләр коръән чыгып калалар... Әнә Юныс мулланың угылы җиде коръән чыгып калдым, дип әйтә, ди... Насыйр мәхдүм, өч хәтем коръән, кырык «Ясин» чыгып калдым, дип әйтә, ди... Син дә шулай итәр идең, балам. Ходай үзе сакласын, шундый чакта, урыс малае кебек киенеп, юк-бар белән утырырга ярыймы соң?.. Китеп барсаң, мин нишләрем тагы... Илаһым, – диде дә, баядаи җыелып, ташып барган яшьләргә тәмам җиңелеп калды...
Госманга авыр мөтәэссир кебек иде, иптәшенең күзенә карады да сөаль бирде:
– Ә син нишләдең?
– Ни эшлим, чәчне кәләпүш эченә тыктым да, өсткә җөббә киеп, «урыс кенәгә»ләренең барын җыеп, әни хөрмәте өчен, ышкаф башына аттым.
Госман үзенекен ялгап алып китте:
– Шуңа охшаш бернәрсәне мин монда никрутларда да , күрдем. Кичә сез килеп җитәр алдыннан, теге «чабаталы түрәләр»дән берсе бөтен мәйданны яңгыратып: «Әй, мөселман никрутлары! мәсҗедкә!» – дип акыра башлады. Бу ни эш? Әллә тәүбә иттерәләрме икән дип, аптырабрак мин дә бардым. Барсам, никрутлар, мәсҗеднең ихатасын тәмам тутырып, бер хилка рәвешендә тезелешкәннәр. Бар да ни була дигән кебек торалар. Менә бервакыт мәсҗеднең икенче ягыннан бер адәм килеп чыкты. Хозыр Ильяс диярсең: ап-ак сакал, яшел чапан, яшел читек, кулда бик озын яшел таяк, башта саргылт чалма, аның да түбәсеннән очлаеп, яшел тышлы бүрек күренеп тора. Үзе башын түбән салган,

[1] *Галәка* – бәйләнеш, мөнәсәбәт.
[2] *Тәнбиһ ясау* – кисәтү.
[3] *Игътираз итү* – каршы килү, әйтү.

астка караган, бик акрын гына атлый. Кулында бик калын тышлы зур бер китабы да бар. Никрутларга якын ук килгәч, бик аз гына күтәрелеп карап: «Әссәламегаләйкем!» – диде дә никрутларның тирә-якны яңгыраткан «мәгаләйкемәссәлам»нары туктагач, тамагының әллә кай җиреннән кысылып чыккан тавыш белән сүзгә кереште: «Менә инде, егетләр, никрутлар, китап һәркемгә, һәрбер адәм баласына яхшы булырга кушкан... Яхшы булыңыз, яхшы... Яхшы булганны Аллаһы Тәгалә дә яхшы күрермен, дигән... Бүтән елның никрутлары азалар, тузалар иде... эчеп-исереп, дошманнар алдында йөз карасы ясыйлар иде... Быелгылар ару күренәсез, ару... Шулай яхшы булыңыз, яхшы...» – ди. Хәзрәтнең ярым сәгать дәвам иткән вәгазе тәмам булгач, теге «чабаталы түрәләр»нең бере, югары яктан бирелгән бер сумны вагыйзьгә[1] төртте дә, сәдакасы бар кеше салсын, дип, мулланың янына кызыл яулык җәеп куйды. Хәзрәт, таягына таяна төшеп, бераз бөкрәйгән хәлдә, туктаусыз: «Рәхмәт! Рәхмәт! Алла кабул итсен! Алла кабул итсен!» – дип тормакта; никрутлар исә, янчыкларын актарып, зур бакырларны, ваграк көмешләрне яудыралар гына... Мин, исем китеп, ахырынача карап тордым; Алла беләә, мулланың яулыгына сәдака салмаган бер генә никрут калдымы икән... Минем артык диккать иткән нәрсәм – шул биш тиен бакырны яулыкка салып, хәзрәтнең рәхмәтен, догасын ишеткән минутта никрутларның йөзләренә чыккан үзгәрүләре иде. Аның йөзе, күзе вә һәммә торышы әйтеп тора ки: бичара никрут, муллага шул сәдакасын бирү белән эче җылынып, өмите артып китә, гүя шул сәдака аны каршыларында торган зур бәладән алып кала, шул киләчәк сиратта ярдәм бирә – котылдыра; менә шул өмит һәммәсенең йөзендә бик ачык ялтырый иде. Хәтта анлар сәдака биргәч, байтак сабырланып, уйланып ук та баралар иде. Менә, иптәш, бу да бик кызык бер хәл. А-а... без сүз белән килеп җиткәнне тоймый да калганбыз... Менә минем фатир шунда бит, – диде дә, Госман, Зыяның култыгыннан алып, капкадан кертте.

Уртача хәлле адәмнең йорты: чибәр генә капка, яңарагы урам ягына, искерәге эчке таба салынган янәшә ике өй; йортның арткы ягында саламны бер дә кызганмый ябылган келәтләр, азбарлар-фәләннәр тора. Бер читтә сиртмәләре әллә кая күтәрелгән кое бар. Кемдер шул коеның сиртмәсен шыгырдата-шыгырдата су чыгара; тигәнә тирәсендә байтак мАллар бар, бер егет шуларны эчәргә кыстап, сызгырып тора. Атлар, сыерлар берсе килә, икенчеләре эчеп китә тора...

Шуларны күздән кичереп, теге янәшә салынган ике өйнең уртасындагы болдырга җитеп, керергә аяк атлаганда, өй эченнән өч адәм килеп чыкты:

---

[1] *Вагыйзь* – вәгазьләүче, үгетләүче.

Госманның энесе Шакир, атасы Заһир мулла, шул йортның хуҗасы Талип карт. Хуҗа намаз толыбыннан, теге ике – юл киемендәләр. Боларның өчесе берьюлы сүз башлады:

– А... Зыя мәхдүм... Синең дә безнең йортка тәшриф итәр[1] көнең бар икән!.. Исәнме, саумы?.. Менә рәхмәт, күптән шулай кирәк иде. Без бит Җәләл хәзрәткә бик дус кеше...

– Ә, Зыя мәхдүм, синме? Шакирдан сораган идем, ул, Госман белән калдылар, диде. Күрә алмый китәм ахры дигән идем, ару булды әле...

– Әйе, Зыя абзый, синең киләчәкне белмәдем. Бераз кичеккән булыр идек...

Зыя һәммәсе белән яңадан күреште дә, сөальләренә каршы, кереп тә кире чыкканын әйтте...

Ул арада арты чыпталы чанага, аллы-артлы җигелгән ике ат болар янына йортның аргы ягыннан чаптырып килеп тә туктады... Чана әллә нинди мендәрләр, юрганнар белән тулы иде. Госман, калам, диде. Шакир, Зыяның кулларын кысып: «Пажалуста[2], безгә кунакка рәхим итеңез!» – дип, атасы янына чанага утырды. Заһир мулла, Зыяның исән-сау котылуы өчен дога итеп, кунакка чакыру хакында углының сүзләрен тәкрар итте.

Кучер сикереп утыруга атлар кузгалды; бик озын чыбыркы, зур җылан шикелле, чана артыннан бөтәрләнә-бөтәрләнә китте; мулла да калучыларга: «Әссәламегаләйкем», – дип, зур толыбының якалары эченә күмелде. Өйнең хуҗасы Талип карт исә:

– Мәхдүм, мин хәзер кайтам... Тиз китмәңез. Күршедә бер карчык авырый икән, шуңа «Ясин» чыгарга әйткәннәр... Хәзер кайтам... – дип, капкадан чыкты.

Госман, беркемнән дә сорамыйча, урам яктагы өйгә Зыяны алып керде. Өйнең тышы шикелле, эче дә урта хәлле адәмнәрнекенә охшаш, ләкин бик җыйнак, бик пөхтә иде: диварлар сап-сары булып ялтырап тора; күп өйләрдә булган кебек, төтен вә каралудан әсәр дә юк; дүрт тәрәзәнең һәммәсе бик пакь, нәфис итеп җуылган, урам яктагыларына авыл кызының эшеннән пәрдәләр дә корылган; тәрәзәләрнең араларында бик озын, бик киң һәм иң соңгы мода белән эшләнгән зур кызыл сөлгеләр асылып, өйнең өчтән берен алган зур сәке, ап-ак киез вә аның өстеннән юрганнар илә түшәлеп, дивар буена таба бик пөхтәләп түшәк-ястык һәм чибәр мендәрләр өелгән булуы да аерым бер тулылык бирә; ишектән кергәч тә, уң якта ап-ак итеп агартылган зур пич бар, шуның алды чобарлап эшләнгән бик зур һәм яңа чаршау илә бүленгән; болар өстенә чалт-

[1] *Тәшриф итү* – олылап килү.

[2]*Пожалуста (* пожалуйста) – биредә чакыруны куәтли торган кисәкчә урынына кулланылган. “Рәхим итегез” мәгънәсен белдерә (ихтирамлы мөрәҗәгать, әдәплелек йөзеннән әйтелә).

чалт йөрмәктә булган сәгать белән кечерәк көзге, әллә нинди күгәрченнәр төшергән яңа календарь, берничә шәмаил белән Ыстамбул, Мәккә, Кәгъбә рәсемнәре өйнең зиннәтен тагы бер кат арттыралар.

– Кереп, өстен салу белән, бу пөхтәлек Зыяның күзенә чалынды:

– Иптәш, синең бабаларың бик чибәр яшиләр икән. Кунак өедер ахры, бик пакь та, кадерле дә...

– А... Зыя, мөмкин булса, мин сиңа аннан да шәбрәк бернәрсә күрсәтер идем. Тукта, миңа шакылдыйлар бугай.

Ул чыкты да, бер биш минуттан соң самавырлар, поднослар кертеп, сәкегә җәелгән ашъяулыкка куйды. Үзе, шундагы лампаны яндыра-яндыра, сөйли башлады:

– Беләмсең нәрсә? Бу, кунак өе булганнан гына түгел, кызлы өй булганга бигрәк пөхтә. Безнең кызлар һәрнәрсәне ал да гөл итәселәре килә бит.

– Нинди кыз?.. Синең балдызлар да бармыни әле?

– Булмаган кая, бар гына түгел – икәү. Әйдә, өйләнәмсең? Берсенә башкода булам.

Ишекне тагы шакылдаттылар. Госман: «Хәзер!» – дип чыгып, бик куе каймак, яңа язган май, хәзер табадан гына төшкән коймак алып кереп, ашъяулыкка куйды да сүзен дәвам иттерде:

– Иптәш, минем ике балдыз бар. Әмма соң шуларның кечесе! Гаҗәб инде, әй; матурлыгын әйтәсе дә юк, анлар нәселләре белән матурлар... Минем бигрәк исем киткән җир – аның табигате, йөрәгедер... Ул әле яңа унбишенчедә. Үзе буйга җитү кыз, төскә, мөгамәләгә бөтенләй бала... Ул шаянлыгы, ул терелеге, ул туктаусыз уйнап, көлеп торуы, – искиткеч, әй... Үзе сүзгә дә бик елгыр, бик чапак[1]. Эчеңә кереп, йөрәгеңә үтә төшеп бара. Дәртлелеген әйтсәк, тагы искиткеч. Бу турыда апасы белән бөтенләй башкалар. Аның апасы басынкы, инсафлы кыз. Аз уйный, аз шаяра, егетләр белән дә әңгәмәсе юк. Әмма бусы инде, гакылың да китәр, шундый дәртле, шундый дәртле, шундый дәртле! Ул булган җирдә кеше күңелсезләнергә, пошынырга түгел, бик аз гына уйланырга да җай тапмый, һәммә кеше аның сүзе, шатлыгы, көлүе белән сихерләнә дә кала... Ул сине күптән ишетеп йөри икән. Каралырга килгәнеңне белгәч, минем җанымны алды: җизни, ди, кайчан килә шул Зыяң, ди... Мин әйтәм: нишлисең аның белән? Эшләмим, Казан шәкерте нинди була икән – күрәсем килә, ди. Син күрмәгәнсеңдер, бая без йорт алдында атанларны озатып торган чакта, ул әллә кайчан тәрәзәгә атланган иде... Син монда кергәч, мин аның янына чыктым да, җә, дим, Камилә, Казан шәкертен алып килдем инде... Анаң да өйдә юк, безнең

---

[1] *Чапак* – оста, зирәк

янга чәй эчәргә чыгасыңмы, дим. Болай дигәч, тилереп китте: «Абау, әллә син мине гакылдан язган дисеңме? Килешмәгәнне, ни сөйли бит», – ди. Апасы, кызара төшеп, безнең сүзләрне ишетмәгәнгә салышып тора, мин һаман Камиләне шаяртам: – Җә, дим, белмәгән кеше булып кына шул өйгә кер; җә, булмаса, дим, менә безнең чәйгә дигән әйберләрнең берсен үзең чыгар, дим. Ул, тагы да ныграк тилереп: «Булмас, атакай гынам! Мин соң, анда әллә нинди егетләр янына чыгып, сынымны күрсәтеп йөримме!» – ди дә миңа арты белән кызу гына борылып китә. Актык мәртәбә кергәнемдә мине бармак ишарәсе белән генә чакырып алды да колагыма гына әйтә:

«Җизни, – ди, – син, – ди, – әйт ул мәхдүмгә: бездә кызлар үзләре егетләргә барып, буй күрсәтеп йөрмиләр, бик кирәк булса, егет үзе кызны күзли ул», – диң... Мин, сүзен тыңлап бетәр-бетмәс, кузгалдым да: «Ярый алайса, шулай диярем», – дип чыга башладым. Менә бервакыт Камиләм, еларга җитешеп, артымнан ябышкан: «Җизни, – ди, – син тилердеңме әллә шул сүзне аңа әйтергә! Мин бит уйнап кына әйтәм», – ди. Мин бер дә илтифатсыз гына чыгып барам: «Мин, – дим, – синең уйнау, шаяруыңны белмим. Үзең әйттең, мин дә, – дим, – шуны аңа әйтәм». Менә шуннан бервакыт буран купты... Камиләм чынлап еларга якын: «Җизни дим, – ди, – әйтмә, валлаһи әйтмә, мин, әйтсәң, дөнья туздырып елыйм...» – ди...

Баядан бирле көлеп тыңлап торган Зыя Госманның сүзен бүлде:

– Да, иптәш, чынлап та замечательный[1] кыз икән. Чыкса, безгә кызык бирер иде. Вакыйган да, ничәдә дисең, унбишенчедәме?

– Әйе! Әллә алырга фараз бармы? Булса, мулла үзебезнеке: яшен тиз җиткерербез.

Зыяга, төштә кебек кенә булып, Мәрьям туташ сурәте ялтырап калды, һәм шул аны хәзер Талип карт өеннән Кара урманга, Мәрьямгә таба өстерәгәндәй булды, ләкин ул тойгыга бирелергә вакыт юк иде.

– Ә соң синең үз кәләшең балдызларыңның каюсына охшаган?

Госман, бик үк үзе теләгәнчә булып бетмәгән бер эш хакында әйткән сыман, башын кыйшайтты да җавап бирде:

– Минем кәләшме? Ул, иптәш, мәгаттәәссеф, [2] зур балдызга охшаган шул! Белмәдем, егет, белмәдем, Талип картның кызлары эчендә ул Камилә барлыгын белсәм, мин биш ел көтеп булса да, аны алыр идем... Җә, Зыя, ул юк-барны куйыйк әле. Син менә, сәкенең нәкъ түренә аягыңны бәкләп утырып, арканы ястыкка терә дә җылы коймактан авыз ит әле...

---

[1] *Замечательный* – искиткеч, бик шәп

[2] *Мәгаттәәссеф* – үкенечкә каршы.

– Мәгаттәәссеф, ярамый шул, күпкә түзгәнне азына түзим инде.

– Көчләмим алайса. Чәен эч... Безнең балдызлар: «Әбәү, бу Казан шәкерте бигрәк бер дә ашамый икән!» – дип калсыннар... Вакыйган, бездә бит шәкерт халкы гомумән аз ашау белән мәшһүр. Бичара, болай да ачлыктан киселгән шәкертне, бер җиргә барса: «Шәкерт кеше күп ашамый инде ул!» – дип яртылай ач калдыралар...

Ул арада ишекне тагы бер мәртәбә шакылдаттылар. Госман чыкты да тиз үк әйләнеп керде. Кулында бер конверт.

– Менә, иптәш, гакыллының гакыллы бит: минем зур балдызым Фатыйма сиңа минем аркылы бер сөаль бирә, бер әманәт тапшыра: син Садыйк баеңызның килене Зарифәне беләмсең? Белсәң, шул бит бу авылдан киткән кыз, һәм ул минем зур балдызның бик якын дусты булган икән. Фатыйма: «Шуның балага авырлы икәнен ишеткән идем, ни хәле бар икән, исән-сау котылдымы икән?..» – дип сорый. Ни диим?..

Зыя бер генә минут уйланып торды да:

– Ә, белдем, мин каралырга чыгар көндә генә бала тапты, үзе исән, бик матур угылы бар дип сөйләделәр, – диде.

Госман, тагы сүз алып, кулындагы конвертын Зыяга биреп:

– Менә бусы әманәт: минем балдыз сезнең авылның теге, Гәрәй мирза кызы Мәрьям туташ белән бер ел теге «...» дә кызлар мәктәбендә укыганнар икән... Дус та булганнар бугай; ахирәтеңнән дип аңарга тапшырылуын үтенә; сез, әлбәттә, әниеңез аркылы тапшыра алсаңыз кирәк! Булдырырсыз бит?! – диде.

Зыя, урыныннан тора төшеп:

– Бик мөмкин, баш өсте! – дип җавап биргәч, Госман чыгып китте дә, бер-ике минуттан соң, аңа Фатыйманың рәхмәте белән яңадан керде.

Госман бик сызганып чәй эчә, ансыз да мае агып торган коймакларны, эченә кисәкле ак май кыстырып, бөтәрләп-бөтәрләп тутыра башлады. Зыя исә, тәрәзәгә карап, дөньяда моңардан да зур сәгадәт бармы икән дигән төсле, иптәшенең ашавына кызыгып утыра бирде. Бераздан соң сүз тагы хатын-кыз тирәсенә күчте.

– Алай булгач, син хатыныңнан бик мәмнүн[1] түгелсең?

– Нидән «алай булгач» дисең?

– Соң үзең: белмәдем, белсәм, Камиләне көткән булыр идем, дисең ич! «Алай булгач» дип шуны әйтәм.

– Юк, иптәш, мин ул сүзне Камиләнең артык уенчак, артык тере һәм шат табигате белән сихерләнгән чакта гына әйтә алам. Юкса, гомумән, мин

[1] *Мәмнүн* – канәгать.

хатынымнан бик ризамын. Аның да бик гаҗәб сыйфатлары бар. Аның гакыллылыгын, аның минем кәефем өчен ни дәрәҗәдә тырышуын әйтергә дә юк. Ул бик эшчән, бик җыйнак. Мине бик ярата: «Дөньяда әүвәл – Аллам, икенче – ирем», – дигәндәй күрә. Аның миңа усаллык уйлавын, хыянәтен-фәләнен телгә алырга да мөмкин түгел. Ул, Алла белә, миннән башка адәмгә, ир сыйфаты белән, күтәрелеп карыймы икән... булмастыр... Шундый хатыннан ничек мәмнүн булмыйсың... Иптәш, минем синең белән, гомумән, адәмнәр белән рәтле вә ачык катышыр мәртәбәдә төзәлүемә хатыным иң зур сәбәпче булды... Беләсең бит, бу авылга кайтып, дөнья көтә башлау миңа күктән җәһәннәмгә чуму шикелле авыр күренде; шул вә гомумән тормыш агымы мине бик изгән, бик эштән чыгарып, йөрәгем әллә нинди ачу, ләгънәт белән тулган, соң дәрәҗәдә гасабиланган[1] идем. Уйнау, шаяру түгел, җүнләп сөйләшәсе, кешегә якты йөз бирәсе дә килми иде... Хәзер генә аңлыйм: хатыным, үзе дә белмичә, хәтта теләмичә, миңа да белдермичә, мине үзенең табигате, холкы, мөгамәләсе белән дәвалады. Мин бу үзгәрешне хәзер бик ачык сизәм... Иптәш, сиңа гына әйтергә ярый: минем бит бер уем бар!.. Ә хатыным шуңа...

Зыя иптәшенең күзләренә карады.

– Нинди уй ул? Әллә качарга уйлыймсың?

– Шуңа якын бер эш. Беләсең: минем башымда үлчәүсез хыял булган шикелле, эчемдә дә «тик тормас» дип аталырлык бер җен, бер шайтан бар. Алданмадым түгел, бик күп алдандым: бервакыт, татар мәдрәсәсеннән чыгып, русча укый башлагач, кесәмдәге акчаның бер-ике айлык кына икәненә, башка килер җир юклыгына карамыйча, өч-дүрт ел тоташ укырга да, аттестат зрелостига имтихан тотып, дарелфөнүнгә[2] керергә, ялтыр төймәләр тагарга уйлый идем... Эшли башлагач, ул мөхальнең янында ук төсле күренеп, мин университетны институтка әйләндердем. Монда керү дә, дим, артык кыен түгел, кергәч, земстводан стипендия, ярдәм дә алырга мөмкин. Аны бетергәч, дарелфөнүнгә керү дә, дим, җиңел була. Вакыйган, мөгаллимлектән алган акчам белән, бер ел хәзерләнеп, институтка керү өчен имтихан башладым. Баштагы бер-ике нәрсә зарарсыз үтте бугай. Менә бервакыт керде риязыят[3] дәресләре. Бирделәр нindидер задачалар[4]. Шул задачага бер мәртәбә күз салу белән башым катты, күз Алларым караңгыланды; үзем һичбер нәрсә аңламас хәлгә килеп, чыгара алудан тәмам өмит өздем. Белмим, ничек башка шул фикер килгәндер, урынымнан тордым да, шунда ук һәммә документларымны алып, имтиханга

---

[1] *Гасабилану* – нервлар какшау.
[2] *Дарелфөнүн* – университет.
[3] *Риязыят* – математика.
[4] *Задача* - мәсьәлә

бөтенләй кул селкеп, институттан сыздым... Шуннан, тагы түбәнрәк китеп, двухклассныйга учительлеккә имтихан тотып карадым[16*]... Аннан да ике мәртәбә сөрелдем... Менә шуннан соң, иптәш, башымны кая куярга, ачуымны кемнән алырга белмичә, укуына, дөньясына, Алласына ләгънәт укып, татарлыгым, язмышым өчен кан йотып, «уф... беттем! беттем!» дигән хәлдә, авылга кайтып егылдым... Атай, мулла бул, ди. Һәммәсе шуңа көчлиләр. Башта җавап та бирмәдем, кул гына селектем. Берничә ай үтте... Менә көз көне бер җыенда, халык алдында: «Ярар, булам», – дип ничек әйткәнемне үзем дә белмим. Ләкин һичбер хәлдә гомерлек бер эш дип белми идем. Башка уем да юк. Үзем һаман бөтен дөньясына ләгънәт укып, әрнеп йөрим... Өйләндем... фәлән иттем... Иң әүвәл хатынымны яраттым. Аның янында җылылык сизә башладым – аның тәэсиренә 'бирелдем. Менә ике елда ул мине шулай эшләп чыгарды, төзәтте... теге га-сабилекләр, әрнүләр, ләгънәтләр бетте... Мин теге вакыт артык арганмын, талганмын, ахры. Ике еллык авыл хәяты миңа файда иткән, иман вә куәт арттырган. Инде хәзер шул файда миңа икенче яктан афәт чыгарырга тора. Аңлыймсың, ни булыр? Мин, иптәш, тагы бер мәртәбә талпынып карарга итәм! Мондый хыяллар миндә күп булды, күп алдандым. Ләкин һаман да тыелып булмый...

– Неужели яңадан укуны уйлыйсың?!

– Уйлыйм гына түгел, шуның белән җенләнәм, шул төшемә керә.

– Ни дияргә дә авыр, синең ул инкыйлабың[1] бик күп көч тели, иптәш.

– Мин аны үзем дә сизәм. Китеп тә әллә ни кыйла алмам кебек, ләкин ятып калганчы атып кал дип, тагы бер талпынасым килә.

– Ә соң акча кайдан табарсың? Хатыныңны ни кыйлырсың?

– Акча мәсьәләсе кыен түгел: минем хәзер үземә караган йортым-җирем, малым бар, барын сатсам, мең ярым акча чыга, сатудан манигъ да юк... Тик менә хатын мәсьәләсе генә бик кыен. Аны аеру – миңа бик зур вөҗдани газап бирә. Әйтергә җиңел: ул бит мине яңадан тудыргандай ясады, үзе дөньяда миңа башка ир затына күз салырга хәрам дип ышана... Менә шул мине газаплый; шуны елатасым, кан-яшь түктерәсем килми...

Авызыннан чыккан сүзләре уңаена агып утырган Госманны тыштан ишеккә таба якынаеп килгән бер аяк тавышы бүлде. Кемдер бу өйгә керергә килә, әнә җитте дә:

– Әссәламегаләйкем! Бичараң үләр ахры, бик беткән...

– Вәгаләйкемәссәлам!.. Кемне әйтәсез, бабай? Фәхрелниса әбинеме?

Карт, ашъяулык янына утырып, Зыя белән тагы бер мәртәбә исәнләште. Ана

[1] *Инкыйлаб* – революция.

тагы рәхмәт укыды да сүзен дәвам иттерде:

– Әйе, шуны әйтәм шул... Әле бит мин аңа «Ясин» чыгарга барган идем, бик беткән, бик беткән бичаракаең... Болай үзенең теле бик яхшы, барын да белә, барын сөйли: үләм инде, үләм, балакаем, ди. Ходай Тәгаләм дөньядан иман белән генә кичерсә икән; Газраил җанымны җиңеллек белән алса икән; гамәл дәфтәрләрем уң кулларыма бирелеп, рәсүлнең шәфәгатеннән мәхрүм булмасам икән, Илаһым, ди... Теге Бәдри карчык белән гомерлек дошман булып, һичбер сөйләшми йөргәннәр икән. Шуны чакырып китертте дә, бик озак елаштылар бичаракайларың... Бәхил бул инде, Бәдри, бәхил бул, дип кочаклашып, үзен җуарга аңа тапшырды. Аның алдында васыятләрен дә әйтте: сыеры белән кәҗәсен ике мөәзин белән ике муллага фидия[1] итәргә, ди, әллә ничә елдан бирле җыйган акчасы бар икән, аны чәчүенә[2], ди, кәфенлеге күптән хәзер икән. Бер сарыгы белән ике тавыгын гүр садакасына, тунын тәлкыйнгә[3] калган кешегә, ди. Бар тагы шундый бик күп нәрсәләре... – Карт, сүзен бүлеп, Зыяга карады да: – Мин әллә ниләр сөйлән киттем, ни хәл соң, мәхдүм әфәнде? – дип сорашырга тотынды.

Болар шул хәлдә утырганда, кайдадыр берәү гармун кузгата башлады. Ахрысы, бик еракта түгел, әнә бер мәртәбә, ике, өч, дүрт мәртәбә тартып карады да, тәмам эзенә төшкән шикелле, моңлатып та җибәрде. Талип карт моңарчы юаш кына, суфый гына утыра иде, музыканың беренче аһәңе килү белән, ул колакларын торгызды, башын күтәрде дә, үзе белән бергә бөтен дөньяны да агызып алып киткәнгә охшаш бер куәт белән сыза башлагач, бөтенләй чыдамын җуеп:

– Ай, дошманнар, шул никрутлардыр, дуңгызлар! – дип, сикереп торды да өстенә кияргә тунын эзли башлады. Аның йөзе ачу белән каралган, күзләрендә дә бик зур гөнаһны күргәндәгегә охшаш бер төс ялтырый иде.

Зыя аптырап калды, Госман исә, тиз генә аңлап алып, картны тынычландырырга тырыша башлады:

– Бабай, бабай! Сез юкка борчылмаңыз, никрутлар түгелдер.... Теге, ни бугай...

– Миңа дисә, теләсә кем булсын, теләсә падишаһ булсын, чыгып таяклыйм... Имеш, көн юк, төн юк, авызларын күтәрәләр дә урам буена лыгырдатып йөриләр... Монда күршедә бер бичара үләргә ята, ә анлар анда шайтан чакырып йөри... җыен мәлгуньнәр...

Карт, сүгенә-сүгенә, толыбын кигәнче, Госман тиз генә тәрәзәгә карап алды да

[1] *Фидия* – үлгән кешенең, генаһсын ярлыкау өчен бирелгән мал.
[2] *Чәчү* – дини йола: үлгән кешене искә алу мәҗлесендә өләшенгән акча
[3] *Тәлкыйн* – дини йола; мәетне күмеп, күмүчеләр киткәч, кабер янында ялгыз калган кешенең мәрхүм өчен иман укуы.

бабасын тагы туктарга димләде:
– Бабай, сез юкка йөрмәңез, никрутлар түгел... Теге җүләр хатын уйный бугай... Нигә юкка йөрергә, гөнаһсы булса, уйнаучыга булыр, сезгә ни...
Карт карарсыз бер хәлдә ишек төбендә туктаган иде, аптыраганлыгы йөзеннән билгеле булган Зыя мәхдүмнең янына ук килеп, үзен акларга тотынды:
– Менә, мәхдүм, – ди, – теңкәмне корттылар инде. Иртә юк, кич юк – туктаусыз лыгырдаталар да йөриләр... Кич укырга утырсам, коръәнемне яңлышып бетәм, намазларымны яңлышып бетәм. Кичә шулай, ястүнең фарызын укыганда, урта эттәхиятка утыргач[18], шулар уйный башлады. Менә, Ходай, җен бит, сихер бит явызың, үземне җиңгән дә алып киткән, – бервакыт карасам, намазымны ташлап, торып киткәнмен дә шуларны карау өчен тәрәзә төбенә барганмын. Гармун диләрме, нидер, шул шайтан авазы туктагач, йокыдан уянган шикелле булып киттем... Менә, мәхдүм, нинди афәтләргә төшерә: намаз боздыра бит, әйтергә җиңел, намаз боздыра... Шуның өчен дә Аллаһы Тәгалә аны хәрам иткән, белеп хәрам иткән... Ә ул этләр, көн дими, төн дими, лыгырдаталар да йөриләр. Минем өчен теләсә никрут булсын, теләсә башка уйнасын – шәйтан авазы булгач шәйтан авазы инде... Ул, җүләр хатын, ичмаса, намаз вакытларында, һич булмаса, ят кешеләр бар чакта тыелып тору кирәк иде... Адәмнән оят бит: олуг башыңыз белән шуны да тыймыйсыз, диярләр...
Карт, бердән, сүзенә, икенчедән, музыкага бирелеп, чыгуын онытты. Зыя исә караңгы, тын кичәдә ерак күктән килгәнгә охшап ишетелгән ул гаҗәб аһәңгә секунды белән җиңелгән, алдындагы картны да күрми, сүзен дә тыңламый иде...
Музыка дәвам итте.
Өй тынды. Карт та, тунының бер җиңен салган, берсен кигән килеш, артындагы урындыкка чүгеп, гүя каядыр чумды, яисә сеңеп калды. Телеме бәйләнгән: бер сүз әйтә алмый, күзләре мөбһәм[1] бер ноктага карап, кадакланган кебек торалар. Зыя үзенең кайда – кеше өендә, кешеләр алдында икәнен онытып, тирән бер һушсызлыкка батты, аның йөзенә әллә нинди хыялый төс вә каядыр мәҗзуб[2] булучылык төсе чыкты. Китабы кулыннан төшеп, үзен-үзе белмәс бер хәлдә, артына таба сөялеп, катып калды.
Гүя музыка үзенең ниһаясез куәте белән аның йөрәгенә үтә китте; гүя музыканың моң, үткен вә илаһи аһәңе аның җанын тәненнән вә бу дөньядан аерып, әллә кая, әллә нинди рәхәт, латиф, йомшак вә мәсгудиятле бер дөньяга, илаһи галәмгә алып китте.

---

[1] *Мөбһәм* – билгесез.
[2] *Мәҗзуб* – бу очракта, уз-үзен онытып, музыка ихтыярына бирелү.

Тик Госман гына артык бирелмәгән иде. Ул, бер картка, бер Зыяга карап, аптырап торды-торды да ахырдан сүз башларга мәҗбүрият тойды:
– Нихәл, Зыя, ару уйныйлармы?
Ләкин Зыя моны җүнләп ишетмәде дә, кемнән вә ни мәгънәдә икәнен дә белмәде. Шулай да бу сүз аңа тәэсирсез калмады, аның рухы бераз айнып, хыялы җир йөзенә төште, һәм шул ук минутта кайчандыр бер театрдамы, төшендәме күргән бер күренеш хәтеренә килде.
Бик матур бер бакча. Айлы кичә. Дөнья матур. Йолдызлар адәмгә бетмәс бәхет телиләр. Бакчаның бер ягында бик матур бер елга бар. Шунда көймәләр күренә; башка җирләре исә асыл агачлар, яшел үләннәр, матур чәчәкләр белән түшәлгән. Шул чәчәкләр уртасында, шуларның бере, ләкин матуррагы шикелле булып, озын эскәмиядә бер кыз утыра. Аның йөзендә хыялый бер күркәмлек. Күзләре ерак күккә, андагы ай вә йолдызларга карап, нидер сорыймы, нидер эзлиме, әллә шуларның җәмале, тәэсире белән ниһаясез тирән уйга, мәсәлсез сәгадәткәме чумган. Башы артка таба җибәрелеп, озын кара чәчләренең ике иңенә төшеп торуы аңа гашыйкларга Тәңре булмак өчен җир йөзенә җибәрелгән бер пәри яки бер хур сыйфатын бирәләр.
Кыз шул хәлдә.
Менә бервакыт арттан, әллә кайдан, бик еракта, теге елга буйларыннан, бик елап, бик моңланып уйналган бер музыка тавышы килә...
Туташ, шуны ишетүгә, йөрәгенең әллә кай җиреннән ярып җибәрелгән кебек, уң кулының учы белән «уф!» дип тик бер генә мәртәбә маңлаена суга да, «аһ» дигән тавышы белән бергә, һушыннан язып, чәчәкләр өстенә йөзтүбән егыла...
Зыя буны бик күптән күргән иде, ләкин, нинди дер куәт белән, шул күренеш аның хатирәсенә сеңдерелгән, беркетелгән ки, бер-бер артлы килеп кичкән күп еллар аны оныттыра алмый – теләсә кайда гына булсын, йөрәгенә үтәрлек бер музыка ишетү белән шул күренеш аның хыялында заһир була иде.
Ул бунардан айнып җитмәде, Госман үзенең сөален тәкрар итте:
– Нихәл, Зыя, ару уйныйлармы?
Зыя, хәйрәтеннән башын селкә-селкә, җавап бирде:
– Гаҗәб, иптәш, чыннан гаҗәб бу! Бу просто могҗиза! – Музыка дәвам итте; Зыя да төш белән өн арасындагыга охшаш бер хәлдә сүзен бетерде: – Әйт, зинһар, кем уйный моны?.. Бу уйнау түгел... Гармун булсын, теләсә башкасы булсын – адәм кулы моны бирә алмый... Монда рух аглый... Бу аһәң йөрәкнең, Ходай белсен, нинди нечкә вә хәссас җирләреннән чыга да, нинди куәтле моңнарын, нинди серләрен сөйли... нинди аһларын егълый...
Тагы бераз торып:

– Никрутлар соң шулай ук уйный алырмыни?.. Әйдә чыгабызмы шунда таба?..
Карт аптырый төште. Ул башта Зыяның «шунда таба»сыннан «гармунчыларга таба»ны аңламакчы булса да, ул аңлавыннан тиз кайтылды: мәхдүм кеше анлар артыннан нишләп йөрсен!
Госман карышмады.
Киенеп чыктылар да урам буйлап үргә таба менеп киттеләр.
– Ну, Зыя әфәнде, кайда барамыз?
– Безме? Без, бик ерак булмаса, әйдә шул могҗизаның, һич булмаса, чыккан җирен күрик, ярыймы?
– Миңа барыбер – теләсәң, барабыз!
– Кем дисең, бер җүләр хатын димсең?.. Авылның читендә үкмени?
– Читендә читендәсен, ләкин ерак түгел ул – менә өч йорт үтеп, дүртенче анықы... Әнә күренеп тә тора.
Госман әйткәнчә, өч йортны үткәч, дүртенчесе бик кечкенә генә бер өй иде. Бу өй – кечкенәлеге өстенә үзе бик иске дә һәм бик ялгыз да: аның янында һичбер каралты-фәлән юк; ул Госманнарга караган өч йорттан утыз сажин кадәрле читтә утыра; ул авылның иң чите, иң кырыендагы бинасы. Аның аргы ягында әллә нинди яланнар китә; бераздан биек таулар күтәрелә; зур агачлы урманнар шаулый башлый.
Бүтән нәрсәсен уйга алмаганда, өйнең тик шул торышы, тик аның шул бөтен авылдан, бөтен көчлеләр, туклар дөньясыннан читкә кагып чыгарылганга охшаш мәзлум кыяфәте һәм авылдан читтә, караңгы төндә бер ялгызының торуы да әллә нинди авыр тәэсир бирмәктәдер. Аның бик кечкенә булган бер тәрәзәсеннән күренгән яктының шул куе караңгылык эчендә «бетәм, бетәм!» дигән төсле калтырап торуы ул гомуми күренешнең биргән авыр тәэсирен дәхи арттырмактадыр.
Зыялар шул өйгә якынайгач, музыка бер генә минутка туктап торды да, тагы еларга, тагы моңланырга тотынды.
Төн караңгы. Бөтен дөнья авыр бер тынлыкта. Авыл тирән йокыда. Башка һичбер җирдә тавыш вә кузгалыш юк. Зыя аптырый: бу бер тәсадефме[1], әллә төш яки саташумы? Юкса, бөтен дөнья шул авылдан, җәмг ыятьтән читкә ташланган, кечек ялгыз өйдә, бәлки, ялгызы утырып, әллә нинди бер дәрт илә уйналган шул музыканың куәтенә җиңелде, шуның тәэсире илә мондый тирән, мондый моңлы тынлыкка чумдымы?
Музыка ныграк ашкына, гүя уенчының йөрәгендә әллә нинди куәтле ялкын бар да, шул, минут саен арта, көчәя барып, җанга яңа дәрт, яңа илһам бирә, куллар

[1] *Тәсадеф* – очраклылык.

да шуның тәэсире илә үлеккә җан бирерлек, таш күңелләрне эретерлек, яшь йөрәкләрне икенче дөньяга ашырып, бөтен табигать өстендә хөкем сөрерлек мәртәбәдә булган илаһи бер осталык күрсәтәләр...

Зыя түзә алмый, иптәшеннән сорап, бу йөрәкнең кичергәннәрен беләсе килә:

– Иптәш, әйтче, зинһар, бу кем? Бу нинди адәм?.. Бу бит кул белән, һөнәр белән уйнамый... Моның музыкасында әллә нинди хәссас йөрәк атлый... Моның һәрбер авазында хәят трагедиясе, бетмәс күз яше, ачы күз яше белән тирән аһлар, тирән зарлар аңкый... Әйт, пажалуста, «җүләр хатын» дисең, ул моңа ничек ирешкән?..

Госман хатынның тәрҗемәи хәлен сөйләп бирә.

Ул – Гайшә исемле икән. Үзе бер карчыкның бердәнбер кызы булган. Яшь чагыннан ук бик моңаючан һәм бик җырчан булган. Авылда җырга, биергә, кубыз вә курай уйнарга, үсә төшкәч, гармун уйнарга һичбер кыз аның тикле булдыра алмаган. Ул бик дәртле, чамасыннан артык дәртле булган. Матур егет, дәртле уенчылар күргәндә, үзен-үзе онытырлык мәртәбәдә ашкынып китә торган булган. Шул егетләр арасында гармунга һәм уенга осталыкта иң беренче булган бер егетне сөйгән дә шуңа ябышып чыккан. Ата-аналары риза булмаганнар, – каргаганнар, явыз дога кыйлганнар. Ләкин, болар аңа карамыйча, күрше авылның мулласына барып, никах укытканнар да икәү тора башлаганнар. Аңлар бер-берсен бик яратышканнар. Хәтта әүвәл вакытларда көн буена икәү кара-каршы, күзмә-күз карашып утыралар да икән, берсе уйнап, берсе җырлап, гомер үткәрәләр, җүнләп эшләмиләр дә икән... Бөтен авыл анлардан көлгән. Хатыннар гайбәтләренә төшеп, картлар хәзрәттән вәгазь дә кыйлдырганнар... Ләкин берсе дә тәэсир итмәгән...

Менә шулай гомер кичергәндә, Гайшәнең ире, Сәлахи, арыш тарттырырга барган икән; ничектер, яза басып[1], аягы тегермән ташына эләккән дә, барлык гәүдәсе тетелеп, эштән чыккан – үлгән. Гайшә, мондый зур һәлакәтне ишетү белән, тегермәнгә йөгереп барган икән, – сөйгәненең гәүдәсеннән кан кисәкләре һәм дә тетелгән иттән башка бернәрсә дә калмавын күреп, ни эшләргә белмичә, шул каннар вә ит кисәкләре өстенә атылып егылган да һушыннан язган.

Аны исенә китергәннәр, имләгәннәр. Ләкин ул табигый хәленә кайта алмаган.

Шуннан сон ул, саташа башлап, җиде төн урталарында: «Син! син!» – дип, урамнарга чыгып китә торган булган. Бернәрсә эшләми, кеше белән дә җүнләп сөйләшми икән. Үзе бик еш елый һәм арлы-бирле итә дә тагы шул музыкасына ябыша икән.

Менә шул, уйный торгач, үзенә башка бер көй чыгарган. Аны ишетеп алып, бик

[1] *Яза басып* – ялгыш басып

яратканнар да һәр җирдә уйный башлаганнар. Ул көйне дә, чыгаручысына нисбәт белән, «Моңлы Гайшә» дип атаганнар. Аны, ирләрдән бигрәк, хатыннар, киленнәр ярата икән. Бер җирдә аулак өй булып, кызлар җыелса, җырда да, уенда да: «Куйчы шуны, җырла «Моңлы Гайшәне!» – дип, һәрвакыт аны алда тоталар икән. Хәзер ул бөтен тирә-якка таралып барадыр, ди.

Гайшә үзе исә, берничә ай үткәч, теге саташуларын куйса да, һаман табигый хәлгә килми; һаман кара, караңгы, ачулы сыман йөреп, һәр көн диярлек, дөнья тынгач, авыл йоклагач, шулай музыка уйный башлый икән... Күп төннәре шуның белән үтәдер, ди.

Госман Гайшә белән «Моңлы Гайшә»нең тарихын сөйләп бетергәч, Зыя бик озак сүзсез барды. Гүя аның телләре бәйләнгән, яхуд һәммә сүзләр аның хәтереннән чыгып беткәннәр иде. Гади күренешләрдә булып, бик гади тәгъбирләр илә хикәя кыйлынган ул авыр фаҗига анда бик авыр тәэсир калдырган иде. Ул сүз тапмый; ул авыр фаҗиганың чын рәвешен ясап, хәят эчендә тотачак урынын тәгъйин итеп җиткерә алмый. Музыка исә һаман дәвам итә, һаман елый; аның бу елавы теге фаҗиганың тәэсирен тагы арттыра, гүя ул «Моңлы Гайшә» көен дөньяга ядкяр иткән Гайшәнең йөрәгендә булган барлык моңнарын, барлык сызлануларын әллә нинди назик гыйбарәләр, хәссас телләр белән хикәя кыйлып бирә иде.

Гайшә кинәт тынды, шуның артыннан ук кечек өйнең тәрәзәсендәге бетәргә хәзерләнеп калтырап торган шәм дә сүнде. Кемдер кычкырды, кайдадыр бер ат кешнәде, бер эт өрде. Ялгыз кечек өй куе караңгылык эчендә юк булды.

Зыя, шул секундта зур бер нәрсәсен югалткан адәм сыман булып, берьюлы сүзгә килде:

– Ну, Госман, кая барамыз? – Бераз туктап торып: – Менә, иптәш, мин хәзер ул халыкның «Җүләр хатын» дип йөрткән Гайшәсен аңлыйм инде... Аның ничек ул мәртәбәдә зур куәт, тирән тәэсир калдырып уйный алуының сәбәбен дә йөрәк сизә башлады... Ну, кая барамыз?

– Хәзер кая барырга? Синең йокы килмиме?

– Юк, килми. Килсә дә, мин бу төнне йокламый уздырырга мәҗбүрмен... беләсең бит...

– Алайса, Сафыйларга барыйк. Анда бит бүген шәкертләр, яшь муллалар җыела... Әңгәмә зурдан булыр...

– Ә мин болай уйлаган идем: ялан якын бит, әйдә шунда, таулар арасына чыгыйк!

Госман аптырый төште:

– Син ни сөйлисең? Җиде төн уртасында тау араларына чыгып ни бар?

– Андамы? Анда, иптәш, менә ни бар: җәйнең матур яшеллегеннән соң, каралып, корып, тәмуг идәне төсенә әйләнгән кара, пычрак җир йөзе яңа яуган кырпак кар белән ак җефәккә чолгангандай матур сыйфат алган... Мин шуны карарга бик яратам: әллә каян кая ап-ак булып җәелеп ята, гүя ак, пакь саф бер диңгез... Үзе нинди киң дә, матур да...
Ләкин ул бер минуттан үзе үк киреләп:
– Юк, алайса бармыйк, бик арыганмын да, – диде. Сафыйларга бармак булып, кире борылдылар.

9

Болар барып кергәндә мәҗлес камил кызып җиткән, ниндидер бер яшь мулла, кулларын бутый-бутый, гаюр моназир[1] сыман сөйләмәктә, нидер исбат кыйлмакта иде:
– Юк дим, менә мин әйтәм, булдыра алмыйлар дим! Сезнең башыңыздан юрган асты хыялы китеп бетмәгән, сезне шул гына азаплый; теләсәңез, сакалыңыз агарганчы йөреңез, – ахырдан барып, җә мулла булырсыз, җә әнә теге Шәрифләр кебек каңгырып китәрсез...
Ишек ачылып, Госман белән Зыя килеп кергәч, мулла сүзен бүлде дә боларга каршы сикереп торды. Башкалар да урыннарыннан кузгалыштылар.
– Әйдүк, Зыя әфәнде, әйдүк, Госман абзый... түрдән узыңыз...
– Юк, кузгалышмаңыз, без утырыр җир табарбыз... Берәм-берәм күрештеләр дә тагын урыннарына утырдылар. Госманга теге яктан урындык чыгардылар. Зыя, кырын ята төшеп, караватка җирләште. – Бу ничек бу, егетләр, нинди җыелыш бу? Өй хуҗасының угылы Сафый шәкерт шул сөальне биргән Зыя каршысына килде дә, шатлык белән көлеп:
– Бумы, Зыя әфәнде? Мин бит бүген каралдым. Бөтенләй калдым... Шуның шатлыгыннан бәйрәм ясарга уйладым... Ә болар, беләсез, кайсы каралырга килгән, кайсы энесен-фәләнен китергән, – диде.
Госман теге муллага карап:
– Җаббар абзый, әйдә син сүзеңне бүлмә, нидер бик кызып ярыла идең бит әле... – дигән иде, мулла җиңел, ашыгыч вә бераз хиффәтчә[2] тавыш белән сүз башлады:
– Сүз бетмәс, мулла Госман, син аңа кайгырма, ләкин шул җире яман: сез менә соңга калдыңыз, бәлеш беткәч кенә килденез...
– Җә, юкка кайгырма: Зыя ашамый, ә мине балдызлар бик яман сыйлады.
– Сыйлар, сыйлар синең ул Камиләң... аңардан булыр...

---

[1] *Гаюр моназир* – гайрәтле бәхәсче
[2] *Хиффәтчә* – җиңел акыллы кешечә.

– Әй, Госман, Җаббар агайлар, сез балдызларыңызны да, бәлешеңезне дә икенче вакытта сөйләрсез. Монда бит...
– Соң, балдыз да сөйләмәгәч, ни сөйләргә?
– Әйдә баягы сүзеңне бетер!
– Җә, алайса, аңа барыйк. Минем сүз шул: юкка чабата туздырып йөрүдә мәгънә юк. Яшеңез өлкәнәйгән, акчаңыз юк, башыңыз ватылган, ата-анаңыз елый. Шул хәлдә җил куып, һавадагы торнаны тотарга йөргәнче, андый хыялларны ташларга да урынлаша башларга...
– Җаббар агай, син юкка «фараз» да «хыял» гына дисең. Аның хариждә[1] мисаллары бар бит: әнә Зөфәр егерме биштә мәдрәсә ташлады. Артык зирәк тә түгел, акчасы да, ярдәмчесе дә юк иде. Шулай да юлында калмады. Тырышкач, тырмашкач, мәсләгендә дәвам итеп, былтыр алты класс гимназиядән имтихан бирде. Киләсе елга сигездән бирмәкче... Аннан соң дарелфөнүн..
– Әй, егет, егет, беләбез Зөфәрнең ниләр кыйлганын! Фараз итик, ул шулай да булсын, – бит ул меңнән бер, ягъни мәсәлән, гарәбчә әйтсәк, шаз кабиленнән...[2] Ә башкалары?..
– Башкаларына ни булган?.. Бик һәйбәт тырышып укып йөриләр. Бервакыт барын ирешерләр дә.
– Ирештеләр ди! Әнә безнең мәдрәсәдән чыккан бик күп шәкертләр: «Русча укыйбыз!» – дип, ничә еллар өстерәлеп йөрделәр-йөрделәр дә, каңгырып эштән чыккач, кайтып, мулла булдылар. Көлке, валлаһи: чәч җиткән, билдә каеш, башта фуражка, кулда таяк була. «Ниләр бетерәсең, иптәш?» – дисәң, бик эре генә итеп: «Русча укыйм!» – ди. Тагы тәфсыйль итеп китә: «Хода насыйб итсә, – ди, – дарелфөнүнгә кадәрле бармак булам!» – ди. Ә шул егетне ике елдан соң күрсәң, җә, указ алып, бәлеш ашый башлаган була; җә шуңа ирешер өчен, бер мәхәлләне икегә аерып, мулла булу өчен, мужикка ришвәт бирә-бирә, тамга җыеп йөри. Менә сиңа русча, менә сиңа дарелфөнүн! Мин хыялдан сөйләмим. Шундыйлар һәр җирдә тулып ята... Хариждә мисдакы[3] кирәк булса, ерак барырга түгел, әнә Госман каршыңызда тора... Без аның белән шәрик идек. Мин мулла булам дигәч, әй, фәлсәфә сатты, әй, фәлсәфә сатты, – исең дә китәр, гакылың да бетәр: «Әфәндем, – ди, – «һиммәтерриҗаль тәкътагыль җибаль»[4] дигәннәр, сез, яшь үткән, акча юк дип, юкка берәр мәктәпкә керү өмитеннән ваз кичәсез, тырышмалы иде, җай табылыр иде, менә минем үземнең дә хәлем сезнеке кебек, шулай да барам бит әле», – ди... Ә соң кая кадәрле барды? Әнә

---

[1] *Хариҗдә* – читтә.
[2] *Шаз кабиленнән* – кагыйдәдән тыш (кеше).
[3] *Мисдак* – дәлил, раслау.
[4] *Һиммәтерриҗаль тәкътагыль җибаль* – ирләрнең, булдыклысы тау кисә.

үзеннән сораңыз, минем сүзем дөрес түгелме?.. Госман, минем туры әйтүемә, әлбәттә, ачуланмыйсың бит?

– Әлбәттә, юк! Ләкин мәсьәләнең шул ягы бар: бер Госманга, хәтта биш, ун Госманнарга карап та, бөтен шәкертләргә гам[1] булган хөкем чыгарырга ярамый. Госман бара алмый егылган икән, һәммәнең егылуы лазем түгел... Арада баручылары, барып җитүчеләре дә булыр...

Бу сүзне Зыя да яклап китте:

– Җаббар агай, син бигрәк кыска тотасың... Имеш, яшьләре үткән дисеннәр дә, борынгы хәлфәләр кебек, муллалыкка, сезнеңчә, урынлашырга җай карасыннар. Ник алай кырт кисәргә? Дәрте, өмите бар икән, барсын, тырышсын, – мулла булу качмый, эш чыгара алмаса, башка җай тапмаса, кайтыр да булыр. Сез торасыз да: «Булмый, булмый!» – дип гомуми хөкем бирәсез; дөрест, булмаганнары да бик күп, уннан, бәлки, җидесе, сигезе, шулай дарелфөнүн дип йөри-йөри аптырагач, укырга җай да, акча да тапмагач, әхваль агымына җиңелеп, ул юлны бөтенләй үк ташлый, мулла була, фәлән итә; ләкин арада теләгенә барып ирешүчеләре дә юк түгел... Мисдакларын бая да зикер иттеләр...

– Юк, Зыя, мин анларның үзләрен кызганып әйтәм бит. Йөриләр юкка чабата туздырып... Җил куалар да, тота алмагач, кайберләре бөтенләй үк эштән, рәттән чыга... Әнә син теге безнең мәдрәсәнең Закир белән Галине беләмсең: мәдрәсәдә вакытта ару гына, юаш кына егетләр иде, 190... нчы елдамы, мәдрәсәдән чыктылар да, каеш тагып, «русча укыйбыз!» дип йөри башладылар. Ә менә шул ике елда анлар кай мәртәбәгә ирешкән? Барыңыз да беләсез, имеш, «тырыштык инде, булмады!» дип, кабактан кабакка кереп эчеп йөриләр. Икесе' дә хәзер настоящий хулиганнар, жуликлар... Закиры, атасыннан калган барлык малны бер ел эчендә сатып бетереп, үзе хәзер ялангач калган. Ә тегесе әллә ничә мәртәбә анасыннан, укыйм дип, фәлән эшкә эләктем дип, акчалар алдырып, өеннән җигеп барган атларны сатып, һәммәсен эчеп бетергән... Бөтен кала зарлана, һәммә пивнойларны алдаганнар, кибетләргә бурычка чумганнар, иптәшләрен алдап бетергәннәр... «Ни эшлисез?» – дигәч, һаман: «Укыйбыз!» дип хат язалар, ди. Үзләре бернәрсә дә эшләми, акча да тапмый. Өст-башларын да сатып бетергәннәр... Ахырдан, аптырагач, мал табу өчен башка җүн беткәч, адәм башына килмәслек этлекләр уйлый башлаганнар. Галие үткән ел кыш буена, әллә нинди мошенникларга катышып, ялган акча ясау, вексельләр ясау юлын өйрәнеп йөри, ди. Ул гына да түгел, язга каршы адәм йоклата торган, агулый торган дарулар җыйган да үзе кебек бер эт белән Казанга киткән. «Анда шундый нәрсәләр бирмәкче булганнар иде», – дип әйтә, ди... Инде хәзер һичбер

[1] *Гам* – уртак, хас.

хәбәре юк, Алла белсен, әллә адәм суеп, каторгага китте, әллә җәһәннәм төбенә чумды... Монда бай гына ата-анасы бар, хатыны бар, һәммәсе кан-яшь түгеп торалар. Үзеннән һичбер хәбәре юк, ди. Тик Ташкентта бер фәхешханәдә пиво ташучы малай сыйфатында йөри имеш, дигән генә бер сүз бар... Менә бит, андый вакытсыз җилкенүләрнең, мәгънәсезгә җил кууларның нәтиҗәсе ни булырга мөмкин!..

Мәҗлестәгеләр, бу сүзләргә каршы кул селкеп, һәммәсе берьюлы авыз ачтылар:

– Ну, Җаббар агай, син бигрәк юлыңнан чыктың инде... Дөнья булгач, андый Закирлар да, Галиләр дә булыр... Әмма, артык йомшак, артык көчсез булган бер-ике малайга карап, бөтен яшьләр хакында андый хөкем чыгару – бу бер дә мантыйкка сыймый... Муллалар арасында кемнәр юк? Борынгы шәкертләр эчендә нинди адәмнәр булмый иде? Аңа карап гомумны пычратырга ярамый...

Кемдер урам яктан тәрәзә шакылдатты. Шуның белән моназара берьюлы киселде. Өй хуҗасы Сафый тиз генә атылып чыкты да үзе белән бергә урта гына буйлы бер шәкерт алып керде. Аның өстендә бәрхет якалы кышкы пальто, аякта штиблет белән сай резинка калуш, башында җәйге каракүл бүрек өстеннән ука чуклы сары башлык, кулында нечкә генә йон* перчатка иде. Ул, килеп кереп, сәлам бирү белән, һичкем урыныннан кузгалмаса да, мәҗлестәгеләр берьюлы ачык сүз белән каршыладылар:

– Ә, Кәрим мәхдүм, синме?.. Әйдүк, югарыдан уз... Бу ни хәл, сине каралды, калды дигәннәр иде. Суга баткан кебек югалдың, күреп тә булмады...

Шәкерт үзенең озынча ак йөзенә һәм хыялый төслерәк күренгән күзләренә аерым бер мәгънә арттырган рәвеш белән бик аз гына елмайды да җавап бирде:

– Әйе! Мин каралдым, калдым.

– Бөтенләйме?

– Бөтенләй.

– Ансы шәп булган, тәбрик итәм...

Кәримне һәммәсе тәбрик иттеләр. Ул, үзенең баягы мәгънәле елмаюын тагы арттыра төшеп, сүзендә дәвам итте:

– Минем әни бик авырый иде. Шуңа күрә мин, монда килеп, никрутларны барлаганда булдым, җирәбә алдым да тагы авылга киттем. Тик бүген, каралырга вакыт җиткәч кенә килдем дә, кереп, калып, чыккан минуты белән тагы авылга чаптым, – әни шулай кушкан иде.

– Соң хәзер ничек тагы килә алдың, әниеңне теге дөньяга озаттыңмы әллә?

– Куйчы, Җаббар агай, шундый каты сүзләреңне!.. Терелә төште, хәле аруланды. Мин, йомышым барлаганда бар иде, дип сорагач, ярар, барырсың,

* Авторда –*“җон”*.

диде дә монда җибәрде. Мин инде әллә кайчан ук килгән идем. Карамалы урамнарында чаба-чаба атымны яндырып бетердем: иң әүвәл Хәлил муллага барган идем: «Зыя әфәнде мондамы?» – дим. «Юк, юк, ул иртәдән бирле кайтканы юк», – диләр. Аннан соң чаптым Талип картка; чыкты бер кыз: «Сезгә кем кирәк?» – ди. Мин әйтәм: «Зыя мәхдүм монда юкмы?» – дим. Кызкаең бик үткен генә икән: «Ә, теге кара толыплы ябык Казан шәкертен әйтәсеңме, ул бездә иде, җизни белән бая ук чыгып киттеләр», – ди. Шуннан соң Җаббар агай фатирына бардым, ул да өйдә юк... Ахырдан урамда Сафыйның атасын очраттым: «Ни хәл, – дим, – сездә кешеләр юкмы, кемнәр бар?» – дим. Көлеп, кулын селекте дә: «Бар шунда, бик күмәкләр, кемнәр икәнен белмим; мин, бу кызыл авызлардан ерак качыйм дип, тиз генә сыздым», – ди. Шуннан сон монда чаптым. Килгәч керә алмый аптырадым: ат белән керергә зур капка бикле, кечкенәсеннән керсәм, бер көтү эт бар, «һам!» дип өзеп алырга торалар... Ахрысы, мәсьәлә бик кызган иде. Кемнәрдер кулларын селкә-селкә моназара итешәләр иде: биш-алты мәртәбә шакылдатмый торып ишетмәдегез дә... – Кинәт кенә сүзен бүлде дә Зыяга карап сөаль бирде:

– Зыя әфәнде, сез минем соңгы хатымны алдыңызмы?

– Алдым, иптәш, алдым, ләкин син җавап язмаганга ачулана күрмә инде...

– А, ни сөйлисез, мин ничек сезгә ачулана алыйм, әлбәттә юк.

Мәҗлестә икенче сүз башланды.

Кәрим исә, Зыяның караватына килеп, якын ук утырды да, башкаларга ишетелер-ишетелмәс кенә рәвештә, аның белән нидер сөйләшергә, киңәшергә тотынды.

Бу ике егет яшьтәш булсалар да, Кәрим Зыяда үзенең мәгънәви остазын, ярым мөәссирен[1] күрә иде. Буңа берничә бик табигый сәбәп тә: анлар бер мәдрәсәдә укыган заманнарында Зыя Кәримнән берничә дәрәҗә алда булып, аның һәммә сабакларын өйрәтә; төрле низагларда үз итә, яклаша иде.

Бу – бер. Икенчедән, Кәрим уналты-унҗиде яшьләрендә чакта, бер дулкынга ияреп, шәкерт ихтилялына[2] катышкан иде. Кемнәрнең котыртуы сәбәпле, анасы аның бу эшенә ачуланды да: «Өйгә кайт, юкса бер тиен акча бирмим!» – дип язды, һәм сүзендә торды да. Кәрим ни кыйлсын – тиз генә бирелмәде, бурычка алып, әйберләрен сатып, бераз яшәде дә, ниһаять, анасы тарафыннан аны алып кайту өчен җибәрелгән җизнәсе белән авылына кайтты. Ләкин күп тора алмады, бер дүрт йөз сум акча эләктерде дә, һичкемгә әйтмичә, Ыстамбулга укырга китү

[1] *Мөәссир* – йогынты ясаучы.
[2] *Ихтилял* – баш күтәрү.

уе белән Одессага качты. Кесәсендә еллык билеты[1] бар иде. Заграничный паспортны әллә кемнәр аркылы Одессада табарга уйлый иде. Язмыш кире сукты; ул, Ыстамбулга китә алмыйча, Идел буе шәһәрләреннән беренә кайтып, русча укырга тотынды. Ләкин кесә тиз арада такырайды, ач йөрергә тугры килә башлады. Ул моңа өйрәнмәгән дә, мәгънә дә күрми: чөнки барыбер укып булмый. Менә шул вакыт ул, Зыяның киңәше буенча, авылына «һәйбәт шәкерт кыяфәтендә» булып кайтты да анасы белән килешү җаена төште.

Анасы: «Укытмыйм, укыган кеше бозыла бу заманда!» – ди иде. Теләсә кем ни генә әйтсә дә, колагына алмый иде. Бунда да Зыя аның ярдәменә җитеште: ул элек Зәйнәп карчыкка үзе сөйләп, соңра атасын җибәреп, аны Кәримнең бер мәдрәсәгә барып укуына рөхсәт һәм акча бирергә күндерде. Болар өстенә Зыя кадим чагында[2] үзенең моназаралары белән зур ук муллаларны элеп алып, селкеп салуы, аннан соң үзенең «көфрияты»[3], әллә нинди тарихлары-вакыйгалары белән дә тирә-якны бик күп шаулатуы чыннан талант гашыйкы гына булган Кәримне аның куәте алдында баш ияргә мәҗбүр итәләр; аның хыялында Зыяны ниндидер бер каһарман сыман итеп күрсәтәләр иде. Шунлыктан ул Зыяга мөгамәләдә һәрвакыт кечедән олыга бирелгәндәй бер ихтирам саклый иде. Ул аңа киңәшче дә, сердәш тә иде. Аның һәммә уйлары, планнары Зыя мәгъкуле, эшләве аркылы кичә иде.

Ул тик ике эшен аңардан яшерде. Берсе – ул өч елдан бирле үзен шагыйрь яратылган дип уйлап йөри һәм вакыт-вакыт, илһам килеп, дөньядагы һичбер адәмнекенә охшамаган шикелле тоелган шигырьләр дә чыгарып куя, ләкин буны һичкемгә белдерми, тик үзенең яшерен дәфтәренә генә яза бара иде. Ул үзен яшерен шагыйрь дип таныса да, ул, шул шигырьләре бервакыт басылып, яхшылыклары белән дөньяны хәйран итәчәк, моны татарның иң алгы шагыйрьләреннән дә югары мендерәчәк дип уйласа да, хәзергә берсен дә чыгармый, хәтта якын сердәше Зыядан да буны бик нык яшерә иде.

Икенчесе исә үзенең мәхәббәте иде. Менә икенче ел инде Кәрим күршеләрендәге бер унбер, унике яшьлек кызны яратып йөри, шуны төшендә күрә, китсә – сагына. Ләкин тегеңә белдерми. Аның белән һичбер вакыт сөйләшми дә.

Бу да аның бөтен дөньядан яшереп сакланган бер сере иде.

Ләкин бүген ничектер ачылып китте дә, Зыя үзенең Мәрьям туташ белән булган мөнәсәбәтләрен сөйләвенә каршы, ул да үзенең шул бала белән башы

---

[1] *Билет* – паспорт.
[2] *Кадим чагында* – элек, кадим мәдрәсәдә укыган чагында.
[3] *«Көфрият»* – «динсезлек».

әйләнмәктә икәнен әйтеп ташлады.
Җаббар һаман ярыла иде. Сүз беткәннәнме, урыныннан торды да болар янына караватка килеп утырып, бәйләнә башлады:
– Җә, сез нишләдегез? Мәҗлестән аерылып, икәү «пыш-пыш» кына сөйләшеп утырасыз... Зыя туган, минем колакка гына әйт әле: бу Кәрим мәхдүм дигән егет нишләмәк була? Аның атасы урыны буш тора бит. Халык, мәхдүмне күтәбез, ди.
Зыя Җаббарның күзенә карап көлде дә:
– Мин аны кайдан белим, үзеннән сора! – диде.
– Сорадым да, әйтми ул миңа. Сүзгә Госман да катышты:
– Вакыйган, Кәрим туган, атаңның урыны һаман буш тора бит: халык сине күтәбез ди; әллә син: «Үзем булырмын!» – дип сүз бирдеңме?
– Юк, мин нишләп сүз бирим. Мин мулла булуны уйлаганым да юк әле.
– Соң син бу ел актык сыйныфта түгелме?.. Аннан соң нишләргә уйлыйсын?
– Аннан соңмы? Аннан соң русча укырга тотынам. Минем бит...
Кәримнең авызыннан бу сүз чыгып җитә алмады, Җаббар, сыртына без белән чәнечкән кебек, урыныннан сикереп торды да, шаркылдап көлеп, ике кулы белән янбашларына суга-суга:
– Әй Ходаем, әй Раббым!.. Кәрим, сиңа да ул чир йоккан икән... Син тагы шул хыял белән авырый башлагансың икән! – дип кычкырып җибәрде.
Моназара дәхи кызды. Инде бусында башкалар күп катышмады; Җаббарга каршы туктамый кычкыручы тик Кәрим мәхдүм генә иде.
Моназараның нәкъ кызган чагы булыр, урамда кемдер бик каты сызгырып җибәрде, һәм шуның артыннан «Баламишкин» көен дә бик күтәренке тавыш белән музыкада уйный башлады. Ул болай таба килә бугай, һаман якыная бара. Якынайган саен, аның канатлары җиңеләеп, күккә очарга ашкына, дәртен дә арттыра бара кебек. Бу ашкыну, бу дәрт мәҗлестәгеләргә дә йокты. Иң әүвәл кузгалучы Җаббар иде. Ул, музыка якынаюга, урыныннан сикереп торды да шундый ук күтәренке тавыш белән, теге никрутлар музыкасына кушылып, җырлап ук җибәрде:

Әйттер, җаный, әйттер, җаный,
Әйттерүләрең калыр.
Мин алмасам, башка алыр,
Безнең йөрүләр калыр...

Аның артыннан башкалар да кузгалышып, урам як тәрәзәгә өелештеләр. Тыңлыйлар, карыйлар. Урамның нәкъ уртасыннан зур чанага төялеп никрутлар үтеп бара икән. Кулларында ике гармун бар. Үзләре исерек, шулай булса да

туры уйныйлар. Берсе музыка уңаена авыл ярып сызгыра. Икесе җырлый. Берсе янәшә җигелгән ике атны туктаусыз кыйный бара. Хайваннар бар көчләренә чабалар. Шунлыктан, Җаббарлар тәрәзәгә җыелып, карап бетәргә дә өлгерә алмадылар, чана күздән югалды. Акрыная-акрыная барып, бераздан музыка да ишетелмәс булды.

– Менә, егетләр, шәкертлек бәласе бит, ул булмаса, без дә шулар кебек уйнап, җырлап йөри алыр идек! – диде берсе.

Икенчеләр төрле яктан аңа сүз каттылар:

– Чынлап шулай, әй! Авылда мин унбиш көн тордым, никрутлар тибәләр генә; һәр төндә авыл буйлап, уйнап, җырлап йөриләр... Мин дә никрут, ләкин миңа үз иптәшләремә катышып йөрергә ярамый... Имеш, шәкерт!

Җаббар тагы бәйләнде:

– Әй, иптәш, иптәш! Сез читтә йөреп кайтасыз да урамда йөргән уенчыларга кызыгасыз, «никрут без» дип шуларга катышмак буласыз... Беләсезме, анлар халыкка нинди кыйммәт төшәләр? Ул никрутлык бер бәла бит. Берәүнең угылы каралса, шул елының ярым дәүләте никрутына китеп бетә: аңа әллә нинди киемнәр кирәк, эчәргә, сыйларга кирәк. Шулар өчен ул гаиләсен бөлдерә: анасыннан ала, агасыннан ала, атасыннан, хәтта сеңелләреннән ала. Имеш, ул никрут, ул китәсе кеше. Ярлы адәмнеке булса, бичара гаиләсен ташлый да яз башыннан ук читкә, кәсепкә китә. Чөнки аңа никрутлык өчен акча кирәк... Күз керсә, шул этләрдән колагың тонып бетә: бүген берсен кыз белән тотканнар, кыйнап, муллага алып киләләр: «Җә, хәзрәт, хөкем ит», – диләр. Аңа нинди хөкем?.. Икенче көн тагы шундый бер хәл: җә, кызга керәм дип, тәрәзә ваткан; җә берәүнең өсәгеннән игенен, абзарыннан сарыгын урлап, кулга эләккән... Менә шундыйлар бетәсе түгел... Ә сез анларга кызыгасыз...

– Җаббар абзый, син бүген сул ягың белән торгансың, ахры: һәрбер сүзгә тискәре барасың. Имеш, никрутлар урлыйлар, бөлдерәләр, – мин бит анларга кушылып урлашырга иде димәдем. Тик шулар белән йөрисе иде дидем... Ә син...

– Җә, егетләр, куегыз юк моназараны! Сәгать ике бит, безгә таралырга вакыт!

Сафый урыныннан сикереп торды да бу сүзгә каршы авыз ачты:

– Юк, иптәшләр, таралуны авызга да алмагыз, мин хәзер самавыр яңарттырам... Сәгать ике булса ни, өч булса ни? Сатып алган вакыт түгел бит!

Самавыр яңарттыру мәсьәләсенә берсе, көлә төшеп, бәхәс итте:

– Сафый, утырсак болай гына утырырмыз, тагы самавыр яңарттырсак, адәмнән оят була башлар: беләмсең, без бит бер чиләк су сыешлыгы өч самавырны түнтәрдек!

Зыя, көлә төшеп, үз тарафыннан протест ясады:

– Егетләр, күпме эчкәнсездер, ансын белмим; ләкин гөнаһка мине катыштырмаңыз: мин бары бер генә чынаяк эчтем...

Кем күп, кем аз эчкәнен тикшереп, бераз мыскыллаштылар да, ахырда, Җаббар мулланың: «Җә, юк сүзгә карама, Сафый, бар, гөнаһсың үзем алырым, дүртенче булмагае, бишенче булса да, яңарттыра бир: мөселман кешегә чәй бара ул!» – дигән сүзенә җиңелеп, тагы бер самавыр эчәргә карар бирделәр.

Тиздән самавыр килде. Аның пары белән мәҗлес тагы җанланды. Тагы әңгәмә куерды. Ләкин бусы инде баягы кебек кызу кычкырышу рәвешенә кереп китә алмый иде: миләр арыган, телләр дә тала төшкән. Сүз теге Галим хәзрәтнең: «Биленә каеш бәйләп, марҗалардан урыс кенәгәсе укып йөри имеш!» дип сүккән Салихыннан башланды. Күбесе аны яраталар, шигырьләрен дә укыганнар. Аннан соң шагыйрьләргә, мөхәррирләргә күчеп, ахырдан милләт кайгырту белән тәмам булды.

Башта ару да кебек, милләт тәрәккый итә дә кебек иде. Гүя аның эшләре төзәлә башлаган да кебек, киләчәк көне өмитле дә кебек иде. Мәҗлескә ниндидер бер җил исте дә, арадан бер шәкертнең мәдрәсәләрне яманлап, шәкертләрнең авыр көннәреннән, мөгаллимнәрнең начарлыгыннан зарланып сөйләве белән, милләт тагы үзгәрде; инде аның хәле авыр, эшләрендә өмит азайды. Аның мәдрәсәсе дә начар, мөгаллиме дә надан, шагыйрьләре дә лыгырдый гына, мөхәррирләрендә дә күп рәт юк, – кая карасаң да, авыр күренешләр очрый торган булып калды...

Бу сүзләр астында йоклап китәргә якынлап утырган Зыя яткан җиреннән бик озак иснәде дә:

– Мин китим инде, иптәшләр! – дип, урыныннан кузгалды.

Аның белән башкалар да кузгалыштылар! Госман Зыяның кия башлаган бер җиңеннән тотты да ярым көлке белән сүз башлады. Башкалар, аягүрә басып, болар янына җыелдылар.

– Ник син, Зыя, безнең милләт кайгыртуымызга бер дә катышмадың?

– Минме? Чынын әйтсәм, мин ул сез кайгырткан нәрсәләр өчен артык пошынмыйм... Начаррак булса да, мөхәррире дә, үзенә күрә шагыйре дә-фәләне дә бар, язган да булып маташалар, алда, бәлки, төзәлерләр дә...

– Ә соң сиңа нәрсә кирәк иде?

– Миңамы? Миңа татарның җанын, йөрәген тәрбияли торган, чын мәгънәсе белән тергезә торган нәрсәләр кирәк иде... Бездә, егетләр, тупаслык зур, туңлык зур. Безнең йөрәкләр күгәргән... Яшь мәдәниятемез бу хакта берни дә кыйла алганы юк әле...

Җаббар, ачу беләнме, әллә юриме, аны бик кырт кисте:

– Юк, Зыя, син мөкаддәмәләреңне[1] куй! Сүзеңне генә әйт! Син үзеңчә ни димәк, ни теләмәк буласың?

Зыя җиңен Госман кулыннан ычкындырды да, тунын тәмам киеп, янындагы урындыкка утырды һәм сүзен дәвам иттерде:

– Минме? Менә нәрсә: Тәңре мине үз каршысына чакырып та: «Җә, колым Зыя, ни максудың бар, ни телисен, сөйлә – бу көн ни сорасаң шуны бирәм», – дисә, мин аңа: «Татар угылы татардан чын мәгънәсе белән даһи булган бер рәссам һәм дә татар рухында булган барлык гармонияләрне вә барлык тирән серләрне, хәзинәләрне тәмамы белән ачып бирерлек мәртәбәдә куәтле булган бер композитор җитешсен! Мин шуны сорыйм!!» – дияр идем.

Халык аптыраганга якын бер халәттә калды; шагыйрь исә, һәммәдән әүвәл уянып, Зыяны алкышларга тотынды.

Хатиб[2] дәвам итте:

– Мин моны матур сүз итеп кенә сөйләмим. Ул – минем даими теләгем, мин үз гомеремдә татардан шул ике куәтнең җитешкәнен күрсәм, үлсәм дә кайгырмам шикелле була...

Шагыйрь, тагы ныграк канатланып, кул чапты да, Зыяның сүзен бүлеп:

– Валлаһи, егетләр, моны гомеремдә уйлаганым юк иде; Зыя әфәнде әйткән соң, тәмам үз ихтирагым[3] шикелле булып китте. Караңыз, валлаһи, татар рәссамы, татар композиторы!! Болар нинди куәтле ишетелә бит... Исемнәре үк җанга җылы бирә... – ди башлаган иде, хатибның алгы сүзләре аны бераз баса төште:

– Кеше теләсә ни дисен! Әмма мин халыкның вә бер кавемнең җанын тергезү, йөрәгенә җан бирү бу икедән башка мөмкин була дип ышанмыйм... Шуңа күрә дә, җае чыкса, мин ун мөхәрриребез белән ун шагыйребезне бер чын композитор белән даһи бер рәссам бәрабәренә бер дә кызганмый сатып җибәрер идем...

Зыя ахыргы сүзен ярым көлке беләнрәк әйткән иде. Шагыйрь исә, моны күрмәдеме, ничектер, бу сүзләр белән үзен әллә кая югалган, аяк астына ташланган кебек тойды; ни дияргә белмәде, тик авыз эченнән: «Зыя әфәнде, бусын арттырыбрак җибәрәсең лә инде...» – дип мыгырдады да эчендә ут сүнгәнгә охшаш бер халәттә калды. Ләкин бу озакка бармады: ник авыр алырга? – һичкем аның шагыйрьлеген белми бит! Җаббар тагы бәйләнде:

– Зыя иптәш, карап торам-торам да, ач тору сәбәпле бераз җиңеләя башламагансыңмы икән дип уйлап китәм?..

---

[1] *Мөкаддәмә* – кереш сүз.
[2] *Хатиб* – оратор, сөйләүче.
[3] *Ихтираг* – уйлап табу.

– Ансы да бик ихтимал. Нидән аны кәшеф итәсең?..

– Соң, нидән ди, үзең бераз уйлап кара: ул музыкаң, ул рәсемең белән ни чыгарасың? Ул татарның корсагын туйдырамы, әллә миен нурландырамы?

– Юк, берсен дә эшләми. Бу ике нәрсә музыка белән рәсемнең биргән тәэсиреннән мең мәртәбә түбән торалар. Тагы әйтәм: корсагын да туйдырмый, миендә нурландырмый, ләкин...

– Ә соң ни генә эшли? Нинди «ләкин»?

– Улмы? Җан бирә! Җан бирә! Үлгән йөрәкне тергезә! Халыкка үзлеген, үзенең дөньяда барлыгын исенә төшерә, ул безне канатландыра... Ләкин болар аптыраганнан гына китерелгән тәгъбирләрдер. Музыка белән рәсемнең бирә алачак тәэсирен бөтен хәвасы[1], тулылыгы белән әйтеп җиткерергә адәм телендә сүз юк әле. Телнең безем тойгыларымыздан түбән һәм ярлы булуы менә шунда бик ачык күренә...

Җаббар каршы әйтмәде, тик:

– Чынын әйтсәм, Зыя туган, мин синең бу сүзләреңне җүнләп аңлап та бетмим! – диде дә өстенә киенә башлады.

Башкалар да, киемнәрен алып, чыгу хәзерлеген карарга тотындылар.

Сафыйның бер агасы бар. Исеме – Сәлим. Ул моннан берничә еллар элек бу шәкертләр белән мәдрәсәдәш тә, иптәш тә иде. Үзе батыр һәм зирәк булып, бунын өстенә бик каудыр[2] һәм кискен табигатьле дә адәм иде. Ул бер вакытлар, кызылларга катышып, халык эше белән дз йөрде. Зинданда да яткан имеш, дип сөйлиләр. Ләкин үзе бу хакта бернәрсәдә әйтми: «Булды инде анда!» – ди дә куя.

Ул ничә еллар атасы белән бозылышып йөргән иде. Бу ел кайтты да, килешеп, авылда тора башлады.

Ул хәзер бик үзгәргән. Үзе бик яман эчә. Алдында «халык», «милләт», «хезмәт» дигән сүзләрне ычкындырсалар, күп вакыт йөзен чыта, кашларын җыера да, кул селкеп, икенче якка борыла яисә «тфү!» дип чыгып ук китә иде. Бу көн нидер гадәттән тыш бер чыдам белән бу мәҗлестә утырды. Вакыт-вакыт, шәкертләр артык чөчетеп[3] җибәргәндә, кулын селкеп, агулы яман сүзләр ычкындыргаласа да, бөтенләй үк чыгып китмәде.

Шәкертләр киенә башлагач, ул урыныннан торып, теге якка чыккан иде. Ахыргы моназараны ишеткәч, түзмәде, җуылган кулларын ак сөлгегә сөртә-сөртә килеп, бераз карап торды да иң әүвәл бик агулы бер тавыш белән:

---

[1] *Хәва* – тулылык, хасият.

[2] *Каудыр* - кабаланучан

[3] *Чөчетеп* - төчеләндереп

– Әмма соң егетләр, гомергә балалыктан чыга алмассыз икән! – диде, соңра, тагы бераз тынлап, сүзгә кереште: – Сез шуңа кайгырасыз, господа! Ә мин болай уйлыйм: бер адәмнең табигый хәяты булган шикелле, бер милләтнеке дә була. Гомер табигый узу белән әҗәле табигый[1] килә. Бу табигатьнең кануны – моңарга, бер-бер адәмнәр буйсынган кебек, олуг милләтләр дә каршы бара алмыйлар... Татар дисезме, төрек дисезме? – ул милләт туган, үскән, яшәгән. Буның артыннан картлык килү, аннан соң әҗәле табигыйнең җитүе дә канун илаһидән; ачыграк әйтсәм, татар ашын ашаган, яшен яшәгән; инде, картаеп, хәле беткән; хәзер ул әҗәле табигыйсен көтә. Һәм аның килүе табигый, катгый... Шунлыктан табигать канунын аңларга да шуңа буйсынырга, юк-бар хыял артыннан чапмаска кирәк... Чапсаң чап, – ләкин бел ки, син табигатьнең җиңелмәс канунын үзгәртергә уйлыйсың. Ә ул – мөхаль! Ул бичараны, гаярь егет, Европа артыннан җиткерәмез, дип юкка азаплаганчы, аңа тыныч кына үләргә ирек бирергә кирәк. Аны тәрәккый иттерү дип шаулаулар – әҗәле табигыйне кичектерә алмас, тик бичара картны борчыр гына...

Бу сүздән мәҗлес берьюлы кызып китте, һәркем, кулын бутап, җавап бирергә тотынды. Ләкин егетнең тавышы һәммәнекеннән көчле иде:

– Хәзер, – ди, – яшәү юллары бик авыр, бик күп талант, бик күп көч, бик күп гайрәт тели. Боларның һичбере татарда булганы да, буласы да юк... Бәс...

Ул дәвам итәчәк иде, яшерен шагыйрь Кәрим эченә сыеша алмаган бер кызулык белән аны бүлде:

– Әйтче, зинһар, буны ни йөзең белән сөйлисең: имеш, татарда куәт булганы һәм булачагы юк, дисең. Моңа кем ышаныр? Татарда башка һичнәрсә булмасын – аңа кул куям, әмма «куәт, гайрәт» булмады дигәнең бу адәм ышана торган суз түгел ...

Артык кызып киткән шагыйрьне Җаббар мулла көлеп бүлде:

– Аба, харап икәнсең син, мәхдүм! Юаш кына булсаң да, бер кызсаң, авызыңнан ут чыга икән.

Зыя, бераз җылмаеп, Кәрим ягыннан төште:

– Менә... менә, әйт шуны ешрак... Мондый матур сүзләрне мин дә бик яратам...

Зыя ахырдан берьюлы көлкегә әйләндереп:

– Шулай булса да, минем өч сәгатьтән соң караласым бар әле... Догада булыңыз! – дип, күрешә башлады.

Шагыйрь шатлыгыннан кая басканын белми: «Яшә, вАллаһи, мең ел яшә, Зыя абзый!» – дип, аның кулларын кыса иде. Башкалар аптырап калдылар ...

Госман белән Зыя чыгып китте. Анлар артыннан бүтәннәр дә таралыштылар.

[1] *Әҗәле табигый* – табигый үлем.

Дөнья бераз караңгылана. Күктәге болытлар түбәнәя төшеп, бияләй-бияләй кар да ява башлаган иде. Авыл һаман үзенең тирән вә тыныч йокысында; тик бик сирәк кенә кайдадыр берәү ачы сызгырып җибәрә, кемдер өзек кенә бер җыр көйли дә музыка тартып куя иде.
Зыя белән Госман, култыклашкан хәлдә, урам буйлап бик акрын гына теге кызыл өйгә таба юнәлделәр. Яшь мулла сүз башлады:
– Иптәш, син музыканы бик яратасың, ахры?
– Нидән әйтәсең?
– «Нидән» дип, ни, үзеңнең сүзеңнән шул аңлана: бая бит аны һәрнәрсәдән югары куйдың.
Зыя бик тиз җавап бирмәде:
– «Ярату» дигән сүз генә минем музыкага мөнәсәбәтемне әйтеп җиткерә алмый, иптәш... Мин аны яратам гына түгел, аңа табынам. Юк, бу да түгел, ничек тә минем җаным белән музыка арасында шундый бер галәка бар ки, мин аны ни генә дисәм дә, дерест вә тулы итеп тәгъбир кыйла алмаячакмын... Мин башка һәрбер нәрсәгә үзем нинди мөнәсәбәт саклаганымны ачык аңлыйм да, әйтә дә алам, ләкин музыкада гаҗизмен. Ул ничектер минем кашымда сүздән, тәгъбирдән әллә кая югары һәм ерак тора... Ул шул дәрәҗәдә башка, үзенчә һәм киң тоела ки, тел рамкасына һичбер хәлдә сыйдырып булмый...
– Мин дә яратам яратуын, ләкин безнең көйләр гел бертөсле... Аннан соң, һәммәсенең дә әллә нинди гел озын булулары да миңа охшап бетми. Әллә ничек адәмне гел кайгыга, хәсрәткә алып китәләр, үтерәләр...
Зыя, йөрәгенә артык якын булган бер мәсьәләгә килеп кагылган кебек бер хәлдә, Госманның сүзен бүлде:
– А... иптәш! Минемчә, ул бик артык табигый, хәтта мәҗбүри үк булган бер хәлдер. Безнең көйләремезнең, безнең музыкамызның андый булуы иттифакый гына вөҗүдкә килгән бер эш түгел, аны тарих агымы тудырган... Чын татар йөрәгеннән чыгып, гомум тарафыннан сөеп, үз итеп кабул кыйлына алырлык көйләр – тик шулай гына булырга мөмкиндер дә...
Госман аптырый төште:
– Ник алай булсын, ди? Башка халыкларда төрлесе була ич...
– Халыклар бит әллә ничә төрле: табигатьләре дә, язмыш вә тарихлары да башка... Татарның табигате бүтән һичбер халыкныкына охшамаган кебек, ул тарихы, язмышы белә дә бөтенләй башка рәвештә тора. Шуңа күрә аның музыкасы да, бәлки, башка һичбер кавемнекенә охшамас, һәм охшамавы табигый дә... Бер халыкның язмышы вә табигате белән аның музыкасы арасында нинди дә булса бер якынлык, мөнәсәбәт булмавы мөмкин түгел. Чын

милли музыка – халыкның йөрәгендә булган тойгыларының тудырган җимеше, җанының аһы, зарларыдыр. Татарның асыл табигате бөек, җаны мәртәбәле, йөрәге бик хәссас булып, икенче яктан, язмышы бик агыр, тарихының соңгы сәхифәләре баштанаяк көенеч вә хәсрәт илә тулыдыр. Язмыштан мөтәәссир булмавы мөмкин булмаган музыкасы да шуның өчен гел җылый, гел моңлана... Һәм халык та, үзе белмичә үк, тик шундый көйләрне, шундый музыканы гына йөрәгенә алып, гасырлар буенча саклап килә... Мин үземне дә ул тугрыда халыкның угылы саныйм һәм йөрәгемнең музыкага мөнәсәбәтендә шул язмышның катышы бар дип беләм. Татар кыска көй уйнарга, такмакларга тотынса, миңа ялган сыман, ясама сыман тоела... Гүя татар йөрәге аңардан мөтәәссир булмаска тиеш шикелле була... Ә халыкның ул гасырлар буенча саклап, үз итеп, шуның тәэсиренә җиңелеп килгән табигый моңнары башланса, Хода белә, ниләр хис кыйлам да, нинди хыял диңгезләренә чумам!..

Госман бер сүз дә әйтмәде. Зыя бераз туктап барды да тагы сөйләргә тотынды:

– Халыкта «көй чыгару» дигән бернәрсә бар. Әнә теге Гайшә «Моңлы Гайшә» көен чыгарган дип сөйлиләр. Мин гакыл вә нәзариям белә аңлыйм түгел, йөрәгем белән сизәм, аның хакында «чыгарган» дию табигый халәтне туры тәгъбир итә алмый, – минемчә, «ул чыгарган» түгел, аңардан чыккан. Чөнки адәм «Моңлы Гайшә» кебек бер көйне, үзе теләп, үз ирege белән вөҗүдкә китерергә һичбер имкян юк... Ул артык мөмтаз вә артык мөстәсна булган бер илһам илә генә туа ала... Гүя мин хәзер күрәм: Гайшә җаны, табигате илә музыканы сөя иде. Аның курае, гармуны һәм хәсрәт, һәм шатлык минутларында да барын бергә уртаклаша торган дусты, җан дусты иде... Музыка аның йөрәгендәге шатлыгы белә шатлана, бәхет сайрый; кайгысы белә кайгыра, моңлана һәм елый иде... Бер көн килде дә, ул үзенең җан сөйгән ярын, гомерлек газиз мәгъшукын тегермән ташы белән өзгәләнгән хәлдә тапты... Аның оста итеп гармун уйный һәм Гайшәнең биленнән кыса торган куллары тәненнән аерылган; ул, һәрвакыт матур бер елмаю саклый торган сылу йөзе, изелеп эштән чыккан, кисәкле ит белән тамчылы канга әйләнгән; ул сөекле күзләрнең урыны да калмаган иде... Бу коточкыч һәлакәттән Гайшәнең йөрәге парә-парә була. Ул башын кая орырга, җанын кая куярга белми. Аның көне төнгә, хәяты уты сүнмәс җәһәннәмгә әйләнә, йөрәгендә һични белән тәгъбир итәргә мөмкин булмаслык бер изтыйраб[1], ниһаясез[2] газап вә хәсрәт башлана. Менә шул хәсрәт, шул газап тәэсире илә ул, үзе белмичә үк, мәңгелек дусты

---

[1] *Изтыйраб* • – газап.

[2] *Ниһаясез* – чиксез.

музыкага килә... җырлый моңнар... уйный көйләр... Ләкин һичбер җыр, һичбер көй җанының әрнегәнен әйтеп җиткерә алмый; нинди генә көйне уйнаса да, йөрәгендәге авыр кайгы илә ачы хәсрәтне тәгъбир итеп бетерә алмый, – башка вакытта җуаныч биргән, җанына җиңеллек вә рәхәтлек китергән, ул әүвәлдән белеп килгән музыка бу минутта аны канәгатьләндерә вә җуата алмый. Ничек тә кулының уйнаган көе – музыкасы йөрәктәге тойгыны тулы тәгъбир иткән булып җитә алмый... Менә шул вакыт аның кулы әүвәл белгән көйләр рамкасыннан чыга да анларга иярмичә, үз рухында булган сызлануларның гармониясенә җиңелә башлый... Ул ни эшләгәнен белми, яңа бер көй чыгару дигән ният аңарда асла юк. Тик аның кулы йөрәгенә иярә, музыкасы шул секунд рухында кайнаган газапның гармониясе буенча китеп бара... Эчке хәсрәт үз юлына төшкән, хариҗдә муафыйк тәгъбирен тапкан сыман була, һәм куллар шуңа буйсына... Ул, елап арыган бала кебек, үзен белмичә, табигый сәвекъ[1] илә шул хәлдә байтак дәвам итә вә шуны тәкрар кыйла... Уйный... уйный... уйный... сәгатьләр, көннәр уйный... Аны кешеләр ишетәләр... Яна кебек тоела... Әүвәлге көйләргә ничектер бер дә охшамый. Арадан үтә сизгеч бер музыка җанлысы килеп чыга да: «А, менә яңа көй!» – дип, каршы ала. Шуннан китә яңа көй... Шуннан соң Гайшәнең «Моңлы Гайшә»се телгә керә, колакка ишетелә, бервакыт аны йөрәкләр ала... Менә шулай итеп яңа көй чыга, ләкин чыгарылмый. Аерым бер көйнең хосусый бер адәмгә нисбәте шул рәвешле булган кебек, бөтен бер кавемнең музыкасының, аның табигате илә язмышына мөнәсәбәте дә шундый ук бер рәвештә буладыр... Шуңа күрә синең баягы сөалеңә мин: «Ул бик табигый...» – дияргә мөмкин табам...

Госман, миен басып киткән авырлыкны селкеп ташларга теләгән адәм сыман, башын як-якка чайкады да:

– Белмим, иптәш, чынын әйткәндә, мин синең бу сүзләреңне җүнләп аңламыйм, – диде.

– Мин үзем дә гакылым вә нәзарияләрем белән исбат итә алачак түгелмен, ләкин йөрәгем шулай ди...

## II

Болар килеп җиткәндә кызыл өй тирәсенә халык җыела башлаган иде. Авыр, басынкы адымнар илә төрле яктан монда килүчеләр дә күренмәктә иде. Кемдер: «Таң беленеп җитми, монда халык җыя башлыйлар!» – дип сукрана иде. Халыкның йөзендә гомумән караңгы пәрдә бар, таң караңгылыгы исә моны дәхи дә карарак һом серлерәк күрсәтә иде... Талип карт ягыннан, салмак кына атлап, дүрт никрут килә, һәммәсе бераз гына исерекләр. Зыя боларның берсен

[1] *Сәвекъ* – инстинкт.

таныды: ул кичә моның белән бергә кереп тә, нәүбәт җитмәү сәбәпле кире чыккан иде. Шул егет кара каеш белән иптәшенең муенына асылган зур гармунны алды да, кызыл өйнең кыйбла як башына таба барып, шунда аяк астында тәгәрәп яткан калын бүрәнәгә утырды һәм бик җай гына, бик акрын гына уйный башлады.

Көн яктыра бара. Халык арта тора, мәйдан тулганнан-тула иде. Зыя белән Госман да, теге җай гына, йокыда сыман гына уйнамакта булган егеттән ике сажин читкәрәк туктап, шундагы бер баганага сөялделәр. Бераз сөкүттән соң, Госман сүз башлады:

– Иптәш, син моннан соң нишләргә уйлыйсың?

– Исән-сау котылсам, минем алгы көн өчен корып куйган планымның иң тышкы, иң тупас һәм иң алдынгы маддәсе – музыка мәктәбенә керүдер...

– Ә соң атайлар ни дияр?

– Менә шул бер мәсьәлә инде... Язмышлары илә миңа азмы-күпме багланган өч зат бар: әти, әни, Мәрьям. Планымның беренче маддәсендә үк миңа бу өч зат белән хисаплашырга туры киләчәк... Мәрьям белән эшемез, әлбәттә, бик җиңел юлга салыначак. Беләсең, мин аның кулындамын. Башка нәрсәдә булган кебек, бу тугрыда да эшне аңа тапшырам... Ул теләсә, тотабыз да бу көннән өйләнеп, моннан күчәбез, теләмәсә – юк. Бераз кичегик дисә, ул монда кала, мин юлыма китәм... Өйләнү беразга торып тора... Һәрхәлдә ул миңа иман китергән, эшемдә ярдәмчедән башка һичбер нәрсә түгел. Чынын әйткәндә, ул миңа килеп тә хатыным булмаячак, бәлки илһамчым булачак... Мин аның тәэсирендә бөтенләй икенче төрлегә әвереләм. Әти хакында да кыенлык юк. Дөрест, ул мине көтә... Ахунмы, мөдәррисме ясыйм дип тора. Ләкин бер көн аңа тугрыдан-тугры сүз ачмый мөмкин түгел. Ул, әлбәттә, сүгенер, каргар, җәһәннәмгә җибәрер. Ләкин мин аңа: «Ләкем динекем, вәлия дин»[1], – генә дияргә дә артык сүз озайтмаска, шуның белән эшне өзәргә уйлыйм... Болар шулай, боларга минем ни кыйлачагым ап-ачык. Ләкин мәсьәләнең авыр ягы әни хакындадыр. Ул, бердән, минем музыка юлына рәсми рәвештә кереп китүемне һичбер төрле аңлый алмаячак. Буңа ул: «Бетте, харап булды...» – дип караячак... Икенчедән, безнең әти бик каты, бик җәббар[2] һәм бик артык кызу адәм. Ул миңа булган ачуын гаиләдән, әнидән ала... Шунлыктан минем музыка мәктәбем – әнинең ансыз да авыр булган хәятын артык зур газапка каплаячак... Менә шул тугрыда мин ни эшләргә дә аптырыйм инде. Әнине кызганмаска, аны язмыш ихтыярына ташларга минем һичбер хәлдә куәтем җитмәячәк. Теге әмәл исә аңардан да

---

[1] *Ләкем динекем, вәлия дин* – синең динең үзеңә, минем динем үземә.

[2] *Җәббар* – тиран.

көчлерәк. Менә миңа шул ике куәтнең арасыннан юл ярып чыгарга!..
Шул арада кызыл өйнең ишеге ачылды да, әлеге озын чәчле писер:
– Кичә каралмый чыккан никрутлар, хәзер кереңез! – дип кычкырды...
Зыя сүзен бетерә алмады, янындагы иптәше Госманга:
– Догада бул, – диде дә кызыл өйнең ишеге артына гаиб булды.

12

Сәгать ярымнан соң Җәләл мулланың шатлыгына чик тә, чама да юк иде. Кемдер кызыл өйнең төньяк ишегеннән чыкты да тирә-якны сырып алган халык өстеннән бераз читтәрәк торган Җәләлгә:
– Зыя мәхдүм котылды! – дип кычкырды.
Мулла, берьюлы күккә күтәрелеп, куллары йомшарды, кычкыручыга мул гына сөенче биреп, алынган никрутларга, тагы әллә кемнәргә дә бераз төшерде һәм, Зыяның киенеп чыкканын көтмичә үк, Кара урман ягына таба кайтырга чыккан бер адәмне тапты да:
– Бар, абыстаңнан барып сөенче ал, Фатыйма бикәгә дә хәбәр ит: Зыя бөтенләй калды! – дип әйтергә кушып җибәрде.
Ләкин бу шатлыклар озакка бармады. Зөләйха абыстай белән Мәрьям туташка бу мәсгудиятле хәбәр барып ирешкәндә, Зыя мәхдүм хакында: «Яңадан кырганнар!» – дигән хәбәр бөтен мәйданда авыздан-авызга тарала башлаган иде. Хәзрәт ачудан тиресенә сыя алмый йөри, халык, бигрәк тә картлар, мәхдүм хакында: «Ул ач торды», – дип шикаять биреп, шуңа шаһитлар дә хәзерләгән һәм шул эше белән аның яңадан кереп каралуына сәбәп булган дошман Хәйрине сүгәләр; мөэмингә касд кыйла, явыз, диләр иде. Ләкин моның илә мәхдүмнең язмышы үзгәрмәде: Зыя алынган, «мәхдүмне яңадан кырганнар» иде.

V

1

Көне-төне кар ява, җил ажгыра, туктаусыз буран уйный... Ноябрь чыгып җиткәне юк әле, шулай да дөнья кар туфаны астында калып, җир йөзен тирән көрт басты; җан чыраглары сүнде, тышкы күренештә хәяттан әсәр бетеп, кяинат[1] ак кар кәфененә уралып, каберсез күмелгән бер шәкелгә керде...
Менә, кыш дисәң, чын мәгънәсе белән кыш инде. Заманының аяклы тарихы Ярми карт та, Тәңренең бу эшләренә хәйран булып:
– Менә, балалар, сиксән ел тереклек иттем. Мондый кышны үз гомеремдә икенче күрәм, – дип сөйли.
Һәм шулайдыр да...

[1] *Кяинат* – дөнья, галәм

Күк йөзе әллә нинди карасу, соры болытлар белән капланып, дөнья тарайды. Көндез кояш чыкмый, кичен ай калыкмый, йолдызлардан әсәр дә юк. Иртәне кичтән, көнне төннән аерып булмый.

Туктаусыз кар ява; һәммә нәрсә аның белән күмелеп, җир йөзеннән югала. Өзлексез буран уйнап, иң яшерен вә иң эчке җирләргә дә үтә китә – карны тутыра. Бу эшендә ул шул дәрәҗәдә тырыш ки, бу гүя аңа лазем ителгән бер хезмәт.

Авыллар, бигрәк тә Кара урман кебек ике тау арасына утырганнар, тагы бераз булса, бөтенләй кар астында калып, югалыр мәртәбәгә якынлашканнар. Хәтта бүтән вакытларда башларын күккә күтәреп, биегәеп утырган Гәрәй мирза, Җәләл мулла өйләре дә быелгы кар белән кап-карсак бер нәрсә булып калганнар. Урамны кар басты, коймалар әллә кайчан аста калды. Капкадан йөрергә мөмкин түгел, җә икенче җирдән юл салалар, жә аның башын алып ташлыйлар. Зур йортларда һәркөн берничә адәм, кар көрәп, өйдән келәткә, келәттән азбарга-фәләнгә сукмак салудан, ишек төпләрен көрәүдән бушамый. Авылның кырыйдагы өйләре бигрәк харап: анларга көрәп өлгерергә һич имкян юк; анларның өй башлары әллә кайчан урам уртасы белән тигезләнгән; капка, читән дигәннең эзе дә калмаган. Бәлки, йортларны ташлап чыгарга да мәҗбүр булыныр иде, ләкин, нинди хикмәт буенчадыр, буран өйнең тирәсенә сылап салмый, бәлки, кар дивары белән өй бүрәнәсе арасында ярты аршын чаклы ачыклык калдыра. Менә шуннан тәрәзәләргә яктылык төшә, вә шуның аркасында өйдә торып була. Ләкин ишекне бик кызганычсыз күмә инде. Күп көннәр иртә белән чыгарга җай беткән, ишекне тәмам кар каплап киткән була. Бу инде ялкау ирләргә бер бәла. Хатын, уяну белән, аның кабыргасына төртә башлый:

– Әй, син, бар, – ди, – ишекне көрәп ач әле... Анда чыгарга рәт юк...

Картлар кайгырмаска куша:

– Кышын кар күп булса, җәен иген уңа, дигән борынгылар, – диләр.

Ләкин эш кешеләре бу хәлдән, бу кар туфаныннан бик уңайсызланалар.

Бу ел иген бик уңган иде. Ләкин көз бик иртә килде. Өзлексез яңгыр яуды, пычраклар булды. Шуңа күрә ашлыкны чак-чак ындырга кертеп бетә алдылар. Ашарлыктан башка бер көлтә сугып булмады. Печән дә яланда калды, урман ташырга да вакыт булмады.

Инде чана юлы гына төшсен, барын дәррәү эшләп алырмыз дип торалар иде. Менә туңдырып, кар төшеп, бер-ике көн генә үтте дә, китте бураннар, башлады кар явулар! Ноябрьның атналары үтте, әле һаман туктаган юк, арттыра бара, котыра бара...

Ярми карт, гомеремдә икенче күрәм, дисә дә, эш кешеләре, дөнья яратылганнан бирле беренчедер, дип уйлыйлар.

Адәм әйтеп, адәм ышанмас: тигез яланнарда, киң сахраларда салынган зур печән кибәннәрен табып булмый – көрт астында калганнар. Зур, тирән мәмерҗәләр[1] кар белән тигез җиргә әйләнгән. Ничә адәмнәр, адашып, атлары-ниләре белән шундый чокырларга очкаладылар. Урманда кар агач башыннан. Бу көн иртә юл салынган булса, төштә аны кар басып китә. Тагы зур бәласе: аяз көннәр, каты суыклар булмаганга, кар бер дә катмый, яңа яугандай көпшәк хәлендә тора. Ат бик аз гына юлыннан чыкса да, карга чума да китә, тик колаклары гына күренеп кала... Аны инде, күп кеше җыелып, арканнар белән генә чыгару мөмкин була.

Кайбер ялгыз юлчылар, атын чыгарам дип, туңып та калдылар. Адашып, авылга кайтам дип, бөтенләй кире якка китеп баручылар, йөреп һәлак булучылар да юк түгел.

Менә әле кышның бер ае үткән юк, ике адәмне шул бураннар шәһит җибәрде. Ничәләрнең җаннары кыл өстендә калып, бик зур бәхет илә генә котыла алдылар.

Ел да бу вакыт юл йөреп байтак акча ясый торганнар иде. Ә быел тугайдагы печәнең белән урмандагы утыныңны ташырга да имкян юк.

Һәркемнең үзенә күрә бер эше бар. Кар-буран исә һәммәсен туктата.

Җәнлек һәвәскәрләре әле һаман сунарга дип аяк атлый да алганнары юк. Дәртле атлар бүре сугып шәплек күрсәтә алмый, бурзайлар да куян, төлке тотып, дәртен басарга җай таба алмый, чөнки авылдан чыгып ике адым атларга да мөмкин түгел. Тик чаңгы һәм ау белән эш итүче сунарчылар гына рәхәт йөргән җәнлекләрне борчыгалыйлар.

Башка елларда бу вакыт ашлык сугылып, өсәкләр тутырылган була иде. Инде ул игеннең беразын сатып, кунак чакырышырга, туйлар ясарга да тотыналар иде. Ә бу ел берсе дә юк әле.

Мондый көннәрдә ничек япма корырга да ничек кибән туздырырга, ничек бүтән якларын башкарырга! Ә авыл кешесе болардан башка ничек акча ясасын! Шунлыктан бар да кичегеп торалар. Кызлар да бирелми, киленнәр дә ярәшелми, кунаклар да чакырылмый.

Шуңа күрә башкодалар да тигрәк торалар. Муллалар да исәпләнгән килерләрнең кичегүенә пошыналар, һәм хаклары да бар: бу ел байлык шәп, кунак-төшем күп буласы иде. Муллалар үз мәхәлләсендә ничә кыз биреләчәген, ничә килен ярәшеләчәген күптән санап куеп, ничаклы никах вә сәдака акчасы

[1] *Мәмерҗә* – җир убылып конус формасында ясалган чокыр

кererен әллә кайчаннан хисаплап, тумаган балага бишекләр корып беткәннәр иде. Хәлбуки, көннәрнең мондый булуы барын да артка калдырды.

Бу хәл, башка һәркемнән бигрәк, хезмәткә алынган никрутларга яман булды. Башка елларда берәр ай торалар иде, ә бу ел бары унсигез көнгә кайтардылар. Чүп өстенә чүмәлә дигән кебек, шул санаулы көннәрне дә башка елның алынганнары шикелле үткәрергә җай юк. Төн буена җәяү дә, чаналарга төялешеп тә урам буена йөрергә кирәк иде, ә мондый буранда ничек йөрисең, йөрүеңдә ни кызык бар?

Аннан да бигрәк акча мәсьәләсе авыр.

Алынган никрутның бу мөддәте[1] бөтен авыл тарафыннан кунаклык санала. Аталары аның һәр теләген кабул итәләр. Ул әхлак вә гадәт кагыйдәләрен җиренә җиткерергә дә мәҗбүр түгел, чөнки – «киткән баш». Аңа ни җитте урында бәйләнә дә алмыйлар. Чөнки ул хәзер – «падишаһ кешесе». Ул үзенең бу хаклары белән бик нык файдалана белә. Кайберәүләре, арттырып җибәреп, әүвәлге үчләрен дә алгалыйлар; без падишаһ кешесе дип, кулларына чамадан артык ирек тә биргәлиләр.

Боларның һәммәсеннән бигрәк, анлар сыйланалар, сыйлашалар.. Бу бер лазем булган гадәт иде.

Ә аның өчен акча кирәк. Иген сугылса, атасы да бирер, анасы да актык бер тиеннәрен аямас иде. Болар белән генә җитмәсә, өсәктән арткы юл белән кибетчегә илткәләргә дә булыр иде. Ә хәзер берсе дә мөмкин түгел: сукмаган көлтәне сатып булмый; келәткә керсәң, өсәкләрдә тычкан башы ярылыр.

Халыкныкы тагын бер хәл: анлар китәсе кеше түгел. Мәңге буран булмас, бер аязыр. Шунда игенен дә сугар, кызын да бирер, киленен дә ярәшер. Туйларын корып, кунакка да йөри башлар, – ул китми, ул өлгерер. Ә менә никрутныкы авыр. Син – «киткән баш». Синең көнең санаулы... Ә шунда да теләгәнчә бәйрәм итеп булмый.

Менә җыелырга, сыйлашырга кирәк иде. Менә сөйгән ярларга сагынмалык бүләкләр калдырырга иде. Иген сугылмагач – акча юк; акча булмагач – берни дә кыйлып булмый.

«Киткән башлар» моңа чыннан авырсыналар, «без өйләнгәч, тән кыскарды», диешәләр.

Көннәр болай булып торса, үзләре белән алып китәр өчен акча ясап булмау мәсьәләсе анларны тагы ныграк борчый.

2

Ләкин табигать безем теләккә һәрвакыт каршы бармый.

[1] *Мөддәт* – вакыт, ара.

Китәргә биш көн калды дигәндә, күк берьюлы инсафка килеп, карын туктатты, җил дә басылды; бураннар бетеп, аяз көннәр, ачык һавалар, кышкы чилләдәге кебек чатлама суыклар башланды, һәм шул арада игеннәр сугылып, никрутлар әүвәлгеләрне каза кыйлырга тотындылар.

Көндезләрдә бик көяз киенгән биш-ун егетнең ава-түнә урам буйлап йөргәннәре, чанага төялешеп чапканнары күренгән кебек, озын төннәрдә, оста уйналган гармунга кушылып, никрутларның кайгы катыш моңланулары, кемнеңдер йөрәге тыныч түгел икәнен белдереп, күңелгә бер дәрт, бер тәэсир бирәләр. Аталар угылын озатырга хәзерләнә: атын, чанасын, акчасын кайгырта. Аналар, бергә жыелып-жыелып, елашалар. Сөйгән ярлар, авыр вә борчулы төшләр күреп, берничә көннән озатачак егете белән очрашырга, туйганчы сөйләшеп калырга бер җай эзли; аңа бер сагынмалык бирергә, аны көтәчәген әйтергә, вәгъдә бирергә дип кан җота.

3

Санаулы көн тиз үтә, диләр.

Әле кайчан гына, каралырга вакыт җитә, дип йөриләр иде. Дулашып Карамалыга киткәннәре дә кичә, өченче көн генә булып үткән бер эш шикелле хәтердә тора. Әле менә яңа гына каралып, «кырылдык», «китте баш» дип авыр сулап кайтканнар иде. Таң ата да кич була. Сизелми дә калды, унсигез көн гомер үтеп тә киткән.

Бүген чәһаршәмбе. Димәк, «кырылганнар»ның авылда торачак мөддәте тулды: иртәгә сәгать унда калага җитеп, начальникка күренергә тиеш. Шуңа күрә озатачак никруты булган йортларда бу көн аерым бер хәзерлек, аерым бер хәрәкәт бара. Китәчәк егетләрнең күбе аягына баса алмаслык дәрәҗәдә исерек. Берничәсенең елаганын да сөйлиләр. Аналар бу төнне күзен дә йоммады. Имеш, угылың әллә кая, җир чигенә китәргә торсын, син йоклап ят! Бу һичбер мөмкин түгел. Аңа күлмәк-ыштанын, чолгавын, сөлгесен хәзерләргә кирәк. Аны буш кул белән җибәрергә ярыймы? һәйбәтләп май күмәче пешерергә, бавырсагын ясарга, һәйбәт кенә җиреннән ит тә пешереп, шуларның барын юлга бирергә кирәк...

4

Башкалар бүген өйлә укыгач та сәфәргә чыкмакчылар. Җәләл мулла исә атларына ышана; шуңа күрә ашыгырга теләми:

– Анда барып, урыс өендә кунганчы, төнне авылда үткәреп, иртә намазыннан соң юлга чыксак та, вакытына барып өлгерербез, – ди.

Зөләйха абыстай җүнләп аңламаса да, ярар, ярар, бик яхшы, бер көн булса да күз алдымда торсын, ди. Боларның өендә дә иртәдән үк туктаусыз хәзерләнү

дәвам итә.
Китәчәк никрутларның күбе хәзрәт һәм абыстай белән күрешергә килә, садакалар китерәләр. Җәләл анлар белән гел уенга тартып сөйләшә:
– Җә, юкка кайгырмаңыз!.. Мин хатыннар елавыннан да туеп беттем. Адәм йөрмәгән җир түгел, барырсыз да кайтырсыз. Анда берәүне дә ашамыйлар. Дөнья күрерсез, – ди.
Үзе, бер өйгә кереп, бер тышка чыгып, нинди киемнәрен алу, кайсы атны, нинди чананы җигү хакында каты-каты сүзләр белән кискен рәвештә боерыклар кыйлып йөри.
Зыяның күбрәк әйберләре калада калган иде. Шуларны бу көн генә китерделәр. Ул, шул нәрсәләрен актарып, калдырачагын ипләп, үзе белә алачакларын сумкасына тутырып вә башка юл яракларын карап маташа.
Атасы керә дә, тәэсирнең ни икәнен дә белмәгән бер йөрәк белән:
– Зыя, толыбыңны киеп утырырсың, җилән, җөббәң кирәкмәс; нәрсәң калмасын, анаңа ышанма, ул хафалы кеше... Үз кирәгеңне үзең кара, – дип чыгып китә.
Зыя шул эшләре белән чобалганда[1], аңа берничә карчык кереп чыкты, һәммәсе кайгырышалар, язмыштыр инде, Ходай Тәгалә исән-сау йөреп кайтырга язсын, дип дога әйтәләр.
Аның кендек әбисе булган Бәдри карчык мең дә беренче мәртәбә үзенең зарын, хәйрәтен[2] сөйли:
– Әй, балакаем, – ди, – бәндә сагышлый, Хода багышлый, дигәннәр борынгылар, балам. Без дигәнчә генә булмый шул... Көн теләдем, төн теләдем... Әй Раббым, шул балакаемны кяфер кулына бирмә... Ата-анасының ничаклы изгелеген күрдем. Үзенең сәдакасын алдым. Шулар хакына аны коткар, Илаһым, дип, намаз арты саен теләдем...
Зыя рәхмәт укый; карчык, күз яшен сөртә-сөртә, сүзендә дәвам итә:
– Ризыкларың читкә чәчелгәндер инде, балам. Ризыкларың кеше кулындадыр... Атаң – хәзрәт, бабаларың ишан да әүлия... Анаң дисәң, хәзрәте Асия белән хәзрәте Гайшә[17*] яхшылыгын җыйган кеше. Ул бичара көн еглый, төн еглый... Балам, ди-ди бичараның йөзе саргайды, үзе кипте... Син калсаң, балакаем, өч ай руза тотарга нәзерем бар иде; бер күлмәгемне садака итәрмен дигән идем; мәптектәге Садыйк хәлфәгә әйтеп, бер коръән чыгартырмын дигән идем... Без дигәнчә булмый шул, балам. Маңлайга язылганны җуеп булмый, дигән борынгылар...

---

[1] *Чобалганда* - чуалганда
[2] *Хәйрәтен* – аптыравын, хәйран булуын сөйли.

Карчык артыннан берничә карт килеп, бераз әңгәмәдән соң:
– Сау бул, мәхдүм. Исән-сау кайтырга насыйб булсын. Безне онытма, хат язганда безгә дә сәлам куй! – дип чыгып киттеләр.
Аяклы тарих Ярми карт та килеп, бераз утырып китте. Ул гүя Зыяның китәчәген белми дә иде. Сәлам яз да дими, дога да сорамый, үзенә генә махсус бер тынычлык белән боларның бабаларыннан Зөфәр ишанның кәрамәтләрен сөйләп утыра бирә.
Сәгать икеләр чамасында урамда арлы-бирле йөргән кешеләр күбәя башлады. Берәү атта, берәү чанада; зур чанага аллы-артлы ике ат җигеп, шәп кыңгырау тагып, күп кенә егетләр урамны әйләнеп тә алдылар.
Авыл җанланды; җырдан, гармуннан әсәр булмаса да, ат әйдәгән тавышлар, кыңгырау тавышлары бик еш ишетелә башлады...
Менә урам малайлар, егетләр белән тулды. Өй буйларын, капка төпләрен хатын-кыз сырып алды.
Менә тагы кыңгырау тавышы, менә чана тавышлары...
Шуның артыннан ук кемдер:
– Әни, китәләр!! Китәләр!! Никрутлар китә!! – дип кычкырды.
Зыя урам як тәрәзәгә таба килде.
Малайлар, егетләр, берьюлы кузгалып, куәтле җил белән әйдәлгән диңгез дулкыны сыман, авылның югары очына таба агыла башладылар. Өй вә капка буйларын сырып алган хатын-кыз дөньясы да кузгалды. Урамның нәкъ уртасыннан, кәрван кебек тезелеп, бик күп чаналар бара. Кучерларда берәр егет, түрдә – картраклар.
Атлар салмак кына атлый. Халык диңгезе аның уңгаена кузгала бара.
Никрутлардан берсе дә чанага утырмаган, һәммәсенең диярлек йөзләре авыр, мөтәэссир; күзләре яшьтән кызарган. Бөтен кыяфәтләре басынкы вә кайгылы тоела. Алар берәүгә сәлам бирә, берәүнекен ала, күпләре белән күрешеп, бәхилләшеп китә.
Бала җанлы аналарны газиз угылыннан, гашыйк күңелләрне сөйгән ярыннан аерган сыман тоелган бу хәрәкәт Зыяга авыр ук тәэсир итте. Ул шул халык диңгезе таралып, кәрван күздән гаиб булганчы карап торды да башына әллә ничек килеп төшкән: «Менә киттеләр дә, бичаралар», – дигән уй белән өенә керде.
Анда һичкем юк иде. Сәгать тиздән өч була. Димәк, аның үзенә китәргә дә унбиш кенә сәгать калган. Бу аңа бик аз тоелды.
Ничаклы, ничаклы эш бар! Ничек кенә булса да, Мәрьямне дә күрергә кирәк. Атай белән дә бер сөйләшми ярамый. Әнине дә ничек кенә булса да җуатырга,

моның мәдрәсәгә китү мәртәбәсендә гади бер эш икәненә канәгатьләндерергә кирәк... Тагы... әллә ниләр... Ә вакыт бик аз... Җитмәсә тагы, Госманнар, Кәрим мәхдүмнәр киләбез дигәннәр... Анлар ничаклы вакытны ала...

Ул шулай дип кенә торганда, аның кечкенә сеңелесе атылып килеп керде дә, күзләре чыгарга җитешкән хәлдә, буыла-буыла сөйләргә тотынды:

– Менә, – ди, – шәкерт абзыкай гынам, куркып үлә яздым... Теге Җамалиларга барган идем. Беләсеңме, аның угылы Камалине... теге... теге сары чалма киеп йөри торган шәкерт... Шуны чанага күтәреп алып чыгып салдылар. Үзе менә, Илаһым, чыра кебек кипкән. Бите көл кебек... Күзләре әллә нинди куркыныч, бертөрле тиле кешенеке кебек...

Зыя: «Ни булган соң аңа?» дип бүлмәкче булган иде, кызкай аңа карамый дәвам итте:

– Мин карарга барган идем... Киенеп беткәч, утырып бик озак дога кыйлдылар да, шуннан сон, никрут, теге шәкерт, Камали, өйдәге кешеләр белән күрешә башлады... Карарга куркыныч менә, шәкерт абзый, бите әллә нинди булган... Үзе, аска карап, бертуктаусыз елый... хәлләре беткән. Чак басып тора... Теге якка чыгып, хатыны белән күреште. Тагы башка кешеләр белән күреште дә анасына килде. Ул инде, Ходаем, угылыннан яман иде... Йөзен пичкә тери дә капланып үкерә генә бирә. Камали аңа барып, елаган тавыш белән: «Җә, әни, бәхил бул инде...» – дип, кул бирә башлаган иде, анасы тагы яман, ачы тавыш белән үкереп: «Балам, Камалым, мине кемгә калдырасың?» – дип, йөзе белән угылының күкрәгенә егылды. Менә шуннан елау купты, елау купты, теге яктан Камалинең хатыны кычкырып елап җибәрде, монда аның кечкенә сеңелесе, нишләгәнен белмичә, агасының кулына барып ябышты да: «Абзый, абзый, син нигә китәсең?!.» – дип, әллә нинди тавыш белән елап җибәрде... Менә, Илаһым, бер елау купты, елау купты... Шуннан сон, менә, абзый, теге шәкерт, хәлдән таеп, егыла башлады. Әллә һушы китте инде, үзе елый, үзе үкерә, ә үзе: «Юк, юк, мин бармыйм... Мин, бәйләмәсәләр, бармыйм», – дип акырырга тотынды.

– Шуннан соң?

– Шуннан соңмы?.. Шуннан соң теге җуан Зариф белән батыр Гәрәй аның ике култыгыннан алдылар да, күтәреп, чанага чыгарып салдылар... Шуннан соң... елый-елый китте...

Зыя бу никрутны якыннан ук таный иде. Ул юаш кына, инсафлы гына бер егет. Артык мөэмин, артык саф күңел. Ул уналты яшькәчә авыл мәктәбендә укыды да, атасы үлү сәбәпле, тәхсилен[1] туктатырга мәҗбүр булды. Ләкин моның белән генә ул мужик егете була алмады. Ул, мәктәпкә йөрмәсә дә, һаман шәкерт иде,

---

[1] *Тәхсил* – уку, белем алу.

гомеренең нәфес вә иштиһа[1] илә кайнарлык дәвере булганына карамыйча, үзе суфый вә тәкъва иде. Таза бер мужик чаклы эш эшли – урак ура, печән чаба, урман кисә; чын бер заһид[2] кадәрле динен, гыйбадәтен үти иде. Аның ялан эшендә, төшкә туктагач, су янына төшеп, таһарәт алып, өйлә укуларын, кайткач, вакытның тарлыгына карамыйча, ахшам вә ястүләр үтәп йөрүен, буш вакытында биш вакыт намазны илаһи бер куәт белән тәмам вә мөрәттәб[3] рәвештә мәсҗеддә әда кыйлуларын[4], җомгаларда матур мәкамнәр белән коръән укуларын бөтен авыл белә; халыкның яше-карты бу ихласка эчке бер хөрмәт илә карый иде.

Ул, анага бер булганга, үзен льгот[5] дип тора. Аның солдатка алынуы һичкемнең башына килми иде.

Ләкин эшләр ул уйлаганча булмады.

Аның атасы Җамали хәлфә үзе тәхсилдә булган, укытып торган җирендә бер хатынга өйләнгән дә шуннан ике угылы булган икән. Хәлфә ул хатынны аерган булса да, дәфтәрдә угыллары моның исемендә күренгән. Шул сәбәпле Камалигә льгот бирелмәде. Аны көтелмәгән җирдән чакырып карадылар да алып ук куйдылар.

Моның алынуы бөтен авылга бик кызганыч булды. Шундый суфый, шундый тәкъва, шундый намазчыл, хәтта заһид булган бер бәндәне картуз кидертеп, мылтык күтәртеп, «шагом марш» дип биетеп йөртү, әллә нинди урыс ашлары, чучка итләре ашату, ничектер, халык кашында бик үк табигый булып бетмәгән бер эш сыман тоела. Ничек тә бу анларның мантыйгына сыймый иде. Шуңа күрә дә Камалинең, солдатка алынгач, үзенең хәсрәтен бәян хакында чыгарган озын бәете бик тиз арада бөтен авылга таралып, күп адәмнәр тарафыннан ятланылды; күп аналар, шуны укытып, озак-озак ятладылар. Ул бик күп заманнаргача халык эчендә «Шәкерт солдат бәете» исеме белән сакланып килде.

Сеңелесеннән соң дәхи берничә адәм килеп, Камали шәкертнең ул мөәссир аерылуын хикәят кыйлдылар.

Бу Ярми картка да тәэсир иткән:

– Менә, мәхдүм, – ди, – сезнеке тагы бер хәл: син узең болай да ярты урыс кебексең. Син анда баргач та, урысның үзен өйрәтерсең әле... Ә бит ул бик суфый адәм иде... Мәсҗед белән намазыннан башканы белми иде. Җитмәсә, бер

---

[1] *Иштиһа* – теләк.
[2] *Заһид* – дингә бирелгән кеше.
[3] *Мөрәттәб* – тәртипле.
[4] *Әда кыйлу* – үтәү.
[5] *Льгот* – льгота, биредә: армиягә алынмас өчен өстенлекле хокукы бар мәгънәсендә

авыз урысча да белми. Ә монда анасы белән хатыны бер кулсыз калдылар. Бичаралар, бар да истән таеп елыйлар. Мәхдүм, үзеңә генә әйтим, атаңнан хәер булмас, син анаңа, килен бикәгә әйтсәң, ару булыр иде: ул шул бичара ятимнәрне ташламасын иде...

Зыя вәгъдә бирде. Карт, тагы ниндидер бер тарих сөйләгәч, чыгып китте.

5

Сәгать җидедә, бары бер чанага төялеп, Госманнар, Җаббар мулла, Кәрим мәхдүм һәм Сафыйның агасы Сәлимнәр килеп төште.

Боларның киләчәге алдан билгеле булганга, Зөләйха абыстайның сыйлары мөкәммәл рәвештә хәзерләнгән – ашы пешкән, бәлеше өлгергән иде.

Болар, табынга утырып, бик иплэп ашый башлагач кына, Җәләл мулла кайтып керде. Ләкин аның тагы бер җиргә никах мәҗлесенә барасы бар икән. Кунакларның һәммәсенә, эчендәге салкынлыгын яшерергә тырышкан бер кыяфәт белән, берәм-берәм көлкеләр сөйләде, бераз шаярды, Госманның кечкенә балдызы Камиләне берәүгә димләде, Кәримнән анасының сәламәтлеген сорады да, иң ахырдан Сәлимгә бәйләнеп:

– Менә, туган, дөнья шулай бит ул. Ул бар кешене дә җиңә. Баш бирми йөрсәң дә, сине дә ахырдан бөгеп салды, – дип, чыгарга хәзерләнде.

Сәлим җавап бирмәде, тик:

– Җә, хәзрәт, аны куй әле... Икенче бервакыт сөйләшербез! – генә диде.

Хәзрәтнең чыгып китүе белән, һәммәсенең күзе Зыяга таба юнәлде: таңда солдатка китәчәк угылына мулланың бу дәрәҗәдә салкынлыгы – аңа бер сүз әйтмәве, аның китәчәген телгә дә алмавы кунакларның барын гаҗәпләндергән иде. Моны һәрберсе ачык тойсалар да, аның астында, бәлки, Зыяга авыр булган берәр яра бардыр, дип дәшми кичәргә уйлаганнар иде. Җаббар мулла теленә баш була алмады:

– Зыя иптәш! Карап-карап торам да, бер нәрсәгә бик исем китә.

– Искитәрлек ни бар?

– Менә нәрсә: атаң карт сиңа ни өчен бик салкын? Әллә ике араңызга кара мәче кердеме?

Сүз бер мәртәбә башлангач, Госман да тыела алмады:

– Вакыйган, мин дә шундый бер хәл тоям. Беркөн базарда очрашкан идек, анда да бер сүз әйтмәде, әле дә,; угылым китә бит, фәлән-төгән дип, авыз да ачмый!

Яшерен шагыйрь күзләрен бер муллаларга, бер Зыяга йөртә башлады.

Зыя теләр-теләмәс бер хәлдә җавап бирде:

– Белмим, нидер бар, ахрысы... Алынганнан бирле миңа мөгамәләсе үзгәрде. Кирәкле бер йомыш булмаганда сөйләшми. Үзе гел карасына батып йөри...

Нидән икән, белмим, белергә теләгәнем дә, уйлаганым да юк.
Бу мәсьәләнең мәҗлескә муафыйк булып бетмәвен сизенеп, Җаббар мулла, сүзне икенчегә борып, берничә көлке сөйләде дә ахырдан тагы Зыяга килеп бәрелде:
– Иптәш, син үзең дә бик кайгырасың, ахры: бу арада кызарып ябыга башладың...
Зыя, ышаныр-ышанмас, аның күзләренә карады:
– Чынмы?
– Ышанмасаң, әнә көзгегә кара: беркөн чыра кебек идең... Хәзер инде, тагы берике ай ашатсаң, сугымга ярарлык булып киләсең. Ашказаның да начар эшли бугай: алдыңдагы тәрилкәләр еш-еш бушый тора.
Көлә төшеп, Госман да буны тасдыйк итте[1]:
– Вакыйган, мин дә күреп утырам, бик нык төшерәсең...
Бер-ике минут көлкедән соң, Зыя, каршысьшда утырган Кәрим мәхдүмгә карады да:
– Иптәш, боларга инабәт[2] юк, әйтсәң дөресен син әйтерсең: мин шулай ук симергәнмени? – диде.
Шагыйрь җитди рәвештә җавап бирде:
– Алай ук түгел түгелен. Шунда да сезгә хәзер төс кергән, беркөнгедән соң байтак тазаргансыз...
Бераз чәйнәшкәннән соң, Сәлим дә катышты:
– Зыя әфәнде, беркөн сезне күргәч, минем бик исем киткән иде... Ул чакта сездә бөтенләй канның әсәре үк калмаган иде. Мин: «Юктан куркып, нигә сәламәтлегеңезне харап итәсез?» – дияргә уйлаган идем. Каралырга кирәргә бик аз вакыт калган булганга, файдасыз санадым да дәшмәдем. Мин, терелә алмазсыз, дип уйлаган идем. Сез бигрәк бетеренгән идеңез...
Җаббар тагы бәйләнде:
– Шәкерт шул, шәкерт! Безнең шәкертнең яртысы шуның белән чери бит. Зыя да шуннан котыла алмады.
Кәрим мәхдүм белән Госман мулла берьюлы Зыяга карадылар. Анлар һәр икесе дә, Зыя бер секундта кызарып бүртенер дә, Җаббарга ни дә булса агулы яисә үтә ачулы бер сүз атар, дип уйлаганнар иде. Ләкин яңлыштылар. Ул, мулланың сүзе бетәр-бетмәс, күзләрен төшереп, йөзен җитдиләндерде дә, берәр минут уйлаган соң, Җаббарның күзенә шелтәле бер караш ташлады:
– Мулла Җаббар агай, сез һәрвакыт «тисә – тияккә, тимәсә – ботакка» дигән

---

[1] *Тасдыйк итте* – дөреслеген раслады
[2] *Инабәт* – ышаныч,

кебек сөйлисез... Сез минем хәлне яхшылап аңлаңыз, минем тормышымның эченә, иң эчке катлауларына кереңез, шуннан соң эшләрем хакында хөкем итәрсез... Читтән торып бирелгән хөкемнәр һәрвакыт хаксыз була ул...
Госман, сүзгә катышып:
– Юк инде, безнең Җаббар агай һәрвакыт шаярып сөйләргә ярата... Зыя, син авырга алмаска тиеш аны! – дип караса да, Зыя аңа илтифат итмичә, мәсьәләне ачып ташлады:
– Җаббар әфәнде, сез юкка алай уйлыйсыз... Тагы әйтәм: иң элек минем тормышымны, мохитымны аңларга тиеш, аннан соң хөкем итсәңез дә ярый. Минем алынып кайтканга унсигез көн булды. Шул аз көннәр эчендә минем әнием тәмугдан сугарып алып чыккан төсле булып калды. Аңа рәхәт бетте генә түгел, дөнья бетте, хәят бетте... Берәрегез кергәндә, чыкканда аның йөзен күрә алмадымы?.. Күргән булса, ул кеше минем ябыгуларның, минем бетеренүләрнең төп сәбәбен берьюлы аңлар... Бер әни генә түгел, минем алынуым өчен, әни мәртәбәсендә, бәлки артыграк та яна торган дәхи икенче бер җан, икенче бер йөрәк тә бар. Мин үземне туган көнемнән алып шул ике вөҗүднең йөрәгендә итеп хис кыйлам. Аларның йөрәгендәге газаплар белән мин дә могаззәб[1] булам... Моны гомеремдә сөйләмәм дигәв идем. Бер ачылгач, китте инде. Мәсьәләнең эчендә дәхи икенче бер катлау да. бар: мин ач торырга теләмәдем. Бер таныш фельдшерым бар иде. Шул миңа, зур белек сатып, бераз акча алып, бер дару бирде. Ач та торма, йокыңны да калдырма, каралырга керер алдан менә шул даруны гына эч тә җибәр, – шуннан соң сине шәйтан да алмас, куарлар да чыгарырлар, ди. Ләкин ул төрле кешегә төрлечә тәэсир итә, күпмесе файда биререн белү өчен, син алдан бер мәртәбә эчеп кара, ди, һичбер зарар булмас, ди. Мин ул җүләргә ышандым. Ышанмый ни эшлисең, ул бит тыйбби мәктәп[2] бетергән. Ярый, бер көн төндә эчеп яттым... Иртән торсам, дөньялар бөтенләй икенче төстә, торып тышка чыгарга барсам, аяк буыннарым әллә ни эшләгән кебек булды, берничә мәртәбә егылып киттем, торып, тагы атладым, тагы егылдым; дүртенчедә инде дөнья әйләнде, мин һуштан яздым... Күпмедән соңдыр, күземне ачсам, диванда ятам. Марҗа авызыма сөт салып маташа. Яныма байтак кеше җыелган. Шул һуш китү көн буена дүрт мәртәбә булган. Доктор да китертелде. Ул бик начар сөйләгән, хәтта: «Мин аптырыйм, ничек үлми ята бу?» – дигән. Ахры, әҗәл җитмәгәндер инде, кичкә таба бераз хәл алдым, бальницага илттеләр, өч көн шунда ятып чыктым... Менә шул мине эштән чыгарды...

---

[1] *Могаззаәб* - газаплы
[2] *Тыйбби мәктәп* – медицина мәктәбе.

Башкалар ни әйтергә белмәде, Җаббар мулла исә, бөтенләй җитди төс белән, Зыя янына килде дә аның кулыннан алып гафу үтенде:

– Беләсең минем телнең бәйләмәгәнлеген, мин шаярып әйткән идем...

– Юк, зарар юк... Мин, чынлап караганда, синең ул сүзеңне авырга алмаска да тиеш идем...

Шуның белән сүзләр сирәгәйде, һәркем үз эченә батты... Озатырга дип килеп, мондый әңгәмә чыгуын бере дә көтмәгән иде. Дөрест, һәммәсе авырга алырлык һичбер сүз юклыгын күрәләр, шуның илә бәрабәр мәҗлескә ниндидер бер бик зур авырлык төшкәнен дә хис итәләр иде.

Сүз яңадан кызмады. Җаббар үзенең барлык талантын җыеп караса да, теге тәэсирне югалта алмый, – сүзе көлке чыкмый, көлке булса да, көлдерә алмый иде. Хода белә, бу ни белән беткән булыр иде, әле дә ярый, хәзрәт кайтып керде:

– Аба, харап икән бу кунаклар... Әле һаман утыралар...

Иң әүвәл Җаббар күтәрелде:

– Менә кирәк булса, хәзрәт безне куа да инде, егетләр!

– Кумыйни, шулчаклы утыргач... Кәрим мәхдүм урыныннан тора төште:

– Хәзрәт, уеныңмы, чыныңмы? Алайса, мин атны җигәргә әйтәм...

Мулланың тавышы берьюлы үзгәреп китте:

– Ай, шәкерт! Бигрәк сабыйсың! Кеше чын сүзне шулай әйтәмени?.. Уйнап әйтәм, уйнап: Җәләл мулланың өе зур, ашы күп. Теләсәңез, таңгача утырыңыз...

Җаббар белән Җәләл арасында туктаусыз әңгәмә китте. Боларга, сирәкләп, Госман да катышкалый иде.

Зыя белән Кәрим исә, пич буендагы диванга кырын ятып, икәү гәпләшергә тотындылар. Бераздан соң хәзрәтне тагы ашка чакырдылар. Ул башта: «Бик туйган идем... кай җиремә ашармын икән», – дип; соңра: «Бу каһәр төшкән мужик, дошман, рәт белми, вакыт карамый; түшәгеңнән алып, пешмәгән итенә өстерәр», – дип сукранса да, кире җавап бирмәде. Тәһарәтен яңартып керде дә, күрешмәеәк, исән булыңыз, дип, мәҗлескә китте.

Ул киткәч, безгә кайтырга вакыт, дип, кунаклар да кузгалган иде, теге як бүлмәгә чыга торган ишекне кемдер шакылдатты. Зыя да, яткан җиреннән торып, тиз генә ул якка чыгып керде.

– Егетләр, кузгалмаңыз! Әни кайнаган самавырым да бар, эчми китмәсеннәр, ди. Менә мин хәзерлим, эчәбез...

– Белмим, туган! Хәзрәт әйтмешли, кай җиребезгә эчәрбез икән?..

Ул арада теге яктан чәй хәзерлекләре чыга да башлады.

– Җә, кайгырмаңыз, егетләр, чәйдән олы түгелдерсез. Утырыңыз... Аш ашка,

урыны башка дигән; абыстай әйткәч, эчәбез, – дип, иң әүвәл Җаббар табынга килде. Аның артыннан башкалар да тезелделәр.

Кунаклар чәйдән соң күп утырмады, атларын җиктерделәр дә, Зыяга бик күп җиңеллекләр теләп, планнар өйрәтеп, хат язышырга вәгъдәләр алып, килгән юлларыннан кире сыздылар.

Бу вакыт сәгать ун иде.

6

Зыя корулы алтатарын алды да, зур толыпны җилкәсенә салып, тышка чыкты. Анда ачык вә якты кышкы төн иде: күк аяз, һава салкын, дөнья тын, – җил, бураннан әсәр дә юк; ерак фәза[1] үзенең якты күзләре – ниһаясез күп йолдызлары һәм тулган ае белән һәркемнең күзенә тугры карап тора. Авыл тирән йокыда. Ул, гүя мөтәәссир, ул гүя бүген түгелгән вә түгеләчәк күз яшьләреннән мөтәәссир[2], – шул тәэсир гүя аның тавышын каплаган, телен баглаган. Ара-тнрә Галимәләр йортыннан музыка тавышы ишетелә. Бу да гүя бүген озатылган Садыйкның китүе өчен аглаган йөрәкнең бер «аһ» итеп куюы кебек тоела иде.

Бөтен җир йөзе әллә нинди бер тынлык саклый; җир гүя үзенең ак кәфененә уралган да салкыннан бөтәрләнеп яткан.

Табигатьнең башка вакыттагы күренешләре һәрбер адәмнең йөрәгенә үзләренә башка бер тел белән ниндидер бер сер, ниндидер бер дәрт сөйлиләр. Анлар җанга керә, эчкә үтә. Ә бу аяз, якты кышкы төн, бу ерак күкнең яктылыгын ингыйкас иттергән[3] ниһаясез кар диңгезе алан түгел, – бу якты, бу матур; ләкин мондагы матурлыктан йөрәк мөтәәссир булмый, буны тик күз генә күрә. Табигатьнең хәзерге хәле хәятлы түгел; гүя ул бу минутларда үз алдына, үз башына тора, гүя ул үзенең башка вакыттагы колларына Киберле[4] бер салкынлык саклый; гүя аның һичкемгә илтифаты юк, гүя ул хәзер үзен ялгыз вә ерак тота, – шуның өчен гүя җаны да беленми, теле дә сөйләми...

Сәгать унберенче ярты булганда, Мәрьям белән күрешергә тәгъйин кыйлынмыш иде. Өйдән чыгып, ерак фәзаны, бу тирән тынлыклы авыл белән аяз вә якты тәнне бераз тамаша кыйлды да Зыя, сәгатен карап, салмак адымнар белән бакча аша Гәрәй мирзаларга таба юнәлде.

Бу ел кар ничаклы куп булса да, бакча аша ике йортның береннән-береиә йөрү өчен тар гына сукмак салынган иде. Бакчаның бикәләргә караган ягында

---

[1] *Фәза* – күк йөзе.
[2] *Мөтәәссир* – кайгы-хәсрәткә чумган.
[3] *Ингыйкас иттерү* – чагылдыру.
[4] *Киберле* - горур

кечкенә генә капка бар. Мәрьям белән Зыя шунда очрашачаклар иде.
Мәрьямнең бүлмәсендә ут күренә. Пәрдәсе бөтенләй күтәрелгән. Зыя, йөрәгенең еш вә куәтле сугуын тыңлый-тыңлый, өйгә якынрак килде дә тәрәзәгә диккатьләп карый башлады.
Анда кемдер бар. Ул бөтен гәүдәсе белән тәрәзәгә капланган да бакчага таба карап тора. Ул башта җансыз сын кебек катып тора иде. Зыя якыная башлагач, тиз генә кузгалып, лампасын басты да тагы ныграк тәрәзәгә капланды... Бүлмә тагы яктыртылды, шул ук минутта теге гәүдә югалды. «Димәк, ул! Димәк, таныды!»
Зыя кечкенә капкага таба бер-ике атларга өлгермәде, зур өйнең кояш чыгышы ягына караган ишеге төбендә – болдырда бер карачкыл заһир булды.
Егетнең йөрәге суга, аяклары кызулый башлады. Ишекнең янындагы тәрәзәдән төшкән якты белән теге шәүләнең бер хатын икәнлеге ачык танылгач, бу хәл дәхи арта төште. Зыя, хатлардагы сүзләр буенча, бик акрын гына вә бик сак кына сызгырды. Моңа җавап уларак, теге хатын бик ачык рәвештә кулбауларын чылдырдатты.
«Димәк, ул!» «Димәк, ул!»
Бер секундта шул уй һәр икесенең башыннан кичеп, үзләре сизмичә үк, берьюлы кечкенә капкага таба атылдылар.
– Кем бар?.. Кем бар, дим?
Егет белән кыз, бер-ике атласак, күрешәмез дип, атылып килгәндә, койма буеннан бик каһәрле кәйфият илә чыккан шундый бер тавыш ишетелде. Ул арада булмый, койма белән кар дивары арасыннан бик калын киенгән, кулына ниндидер күсәк тоткан җуан вә озын бер адәм килеп чыкты да ачу, усаллык һәм каһарманлык тулган калын тавышы белән каты вә кызганычсыз рәвештә тагы кычкырды:
– Кем бар, дим?! Кем бу?!. кем йөри бу вакытта. Мәрьям, ни эшләгәнен белмичә, кире чигелде; Зыя, бер минутта эшне аңлап, башын җыйды, ләкин берни кыйла алмый катып калды... Шулай да үзен югалтмады, тунын киеп, уң кулы белән револьверын иплəп тотты.
Каравылчы якынрак килде. Зыя һаман урынында иде:
– Кем дип торам! Гали бабай, син икәнсең!
Батырның баягы каты, кызганычсыз тавышы тәкрар ителде:
– Мин! Мин! Җә, Мин булсам, ни эшләтәсең?!
– Тукта син, бабай! Ник ул чаклы җикеренәсең? Мин синең малыңны урламаган ич!
– Кем, мәхдүм Зыя, синме? Бар, димен, бар, кире юнәл! Атаң-анаң хөрмәтенә

җибәрәм; башка берәү булса, бер сугуда иңсәсен җимергән булыр идем...
Зыя бераз сүзсез торды да, картның янынарак килеп, тагы башлады:
– Кара әле, Гали бабай! Барыбер сер ачылды инде, мин синнән егетлек сорыйм, син минем юлыма койма булма!
– Сөйләмә, егет! Мин синең ни өчен йөргәнеңне беләм... Мине монда бикә куйды... Күп карышсаң, тотып, урамга чыгарырмын!..
Зыя револьверын ипли төшеп, икенче кулы белән сул кесәсендәге янчыгын карады.
«Ни эшләргә? Уң кулга ирек бирергәме, әллә картны майлап карыргамы?»
Ул бу икенең берсен эшләячәк иде. Башта, яхшылык ягы белән сынап карау өчен, сул кулы белән кесәсен актарып, өч сумлык кәгазь дә тапкан иде. Ләкин Мәрьям түзә алмады, Зыя дустлык кыяфәте белән картка якын ук килгән секундта, баягы ишек янында теге шәүлә заһир булып, ачы рәвештә кулбавы чылтырдады да: «юк, булмый, өмит бетте!!» дигән мәгънәне аңлатырлык кәйфияттә, яулык селкенгәне күренде...
Инде көрәштә мәгънә калмады, егет тә, суынып, китәр юлын карый башлады.
Карт:
– Бар, мәхдүм, бар! – диде.
Зыя исә аңа кире килеп сөаль бирде:
– Әйт дерестен: бу серне фаш кыйлачаксыңмы, юкмы?
Каравылчы каһарман аңа якын ук килде дә, уң кулы белән үзенең зур сакалын тотып:
– Менә шул сакалым белән әйтәм, моны Алла белән бикәдән башка һичкем белмәс... Мин әләкче түгел... Атаң-анаң хөрмәтенә җибәрәм, бар, тыныч бул! – диде.
Зыя, авыр вә үтерелгән бер хәлдә, өйләренә керде. Мәрьямнең тавыш вә хәрефсез, тик яулык ишарәсе белән әйтә алган сүзе әллә нинди мәгънәви бер тавыш белән аңа тәкрар ителгән кебек тоела иде:
«Юк, булмый, өмит бетте!»
«Юк, булмый, өмит бетте!»
«Юк, булмый, өмит бетте!»

7

«Менә тормыш! Менә сиңа хөррияте шәхсия![1] Яшәргә уйлыйсың, бәхет эзлисең! Бар да әрәмгә! Бар да юкка!.. Имеш, музыка хәрам! Җыр хәрам! Матурлык гөнаһ! Матурлык белән тәләззез[2] хәрам! Матурлык алдында сәҗдә

[1] *Хөррияте шәхсия* – шәхес азатлыгы.
[2] *Тәләззез* – ләззәтләнү.

итү көферлек! Соң, Илаһым, алай булгач, безгә ник мондый җан бирдең? Ник безне туң йөрәк, тупас күңел итеп яратмадың?

Олуг Тәңре, син кайда, син кайда? Күрәсеңме, без нинди хәлдә? Син безне хәят өчен яратмагансың, син безне туган көнебездән алып авыр трагедия эченә ташлагансың! Синең үзеңнән бер чаткы булган җаннары-мыз бер нәрсә тели; безнең йөрәгемез табигатьтән тәэсир ала; музыканы гашыйкларның зикере кебек тоя; безгә хәят кирәк, безгә ирек кирәк; безнең күңелләре-мез син үзең җир йөзенә тараткан надир мәгъбүдләр[1] – матурлар, матур җаннар, гали күңелләр каршысында сәҗдә итәргә тели, – бу теләкләрнең барын син үзең биргәнсең. Ләкин мохит буңа каршы бара. Тормыш безне кыса, безнең пакь вә гали теләкләремезгә, мәгъсум тойгыларымызга гөнаһ дип карый...

Минем ни гөнаһым: йөрәгемә мәхәббәт орлыгы салгансың, аны да шулай яраткансың, без аякка баскан көнемездән бирле бер-беребезне син үзең биргән мәхәббәт белән, чын, саф, илаһи гыйшык белән сөеп киләмез! Ул адәм түгел, ул фәрештә! Аның күңеле күкнең, гарешнең голүвиятенә турыдан-туры ачык, – мин моны хис кыйлам, мин моның алдында баш иясем, аягы астында туфрак буласым килә... Ләкин безгә ирек юк... Ничек аңлыйм, ничек аңлыйм: миңа аның йөзенә карау хәрам, диләр, аның белән сөйләшү хәрам, диләр, күрешү, бергә булу олуг азгынлык, диләр... Әйт, Тәңре, моны ничек аңлыйм, моны ничек башыма сыйдырыйм?.. Олуг Тәңре, мине кызган! Мин бүген аңардан аерылам; кем белә, ничә елсыз күрә алмам, – бәлки, үзең күрсәтмә, гомергә күрә алмам... Ә шул вакыт, шул кыйммәтле сәгатьтә миңа аның ул илаһи күзләренә бер мәртәбә карарга, аның ул мәләкнең[2] гыйбадәтенә охшаш тавышын актык мәртәбә ишетергә, үземнең йөрәгемдәге тойгыны актык мәртәбә аңа гарыз итәргә ирек бирмиләр... Үләм, Ходаем, үләм, бу тормышның тарлыгыннан, кысуыннан үләм. Моның тупаслыгыннан, моның сасы вә тар һавасына тончыгып үләм!

Әй, Ходаем! Түзем бир! Чыдам бир! Юк, яңлыш әйтәм, түзем кирәкми, чыдам да бирмә: син безгә талантлар бир; син безгә бу тормышның тар рамкаларын ватып, җимереп ташларлык куәтләр бир! Тормыш киңәйсен, һәркем ирекле булсын, дөньяңда матурлык белән ирек кенә солтанлык итсен...»

Шул фикерләр Зыяның башыннан диңгез кузгалышына охшаш бер хәрәкәт белән әле бер якка, әле бер якка кичтеләр. Ул үзе зур залның идәне буйлап кызу-кызу атлап йөри; хәзер генә булып кичкән гади вакыйга сәбәпле

[1] *Надир мәгъбүдләр* – сирәк очрый торган табыну сыны (бу очракта матур, гүзәл кызлар мәгънәсендә)

[2] *Мәләк* – фәрештә.

дулкынлана башлаган рухы бөтенләй табигый хәлен җуеп, бу фикерләр аны тилертәләр; ул уйлый, тагы кызып китеп, сөйли дә башлый, хәтта, әллә кемгә исбат итәргә теләгән сыман, куллары белән дә селтәнеп куя иде...

Бөя, бер эз салынмаса, ничә айлар буенча һәркөн артмакта булган суның һөҗүменә каршы тора бирә. Ләкин аның бер чамасы бар, шуңардан үтеп, бер җирдән бик аз гына артык куәт кушылса, ул чыдамый, ул җимерелә, су да ташып китә...

Зыяга да бүген шундый хәл булды. Аның теләгенә генә каршы төшмәделәр, ул әллә кайчаннан бирле мохитнең мәгънәсез рамкаларын күрә килә, анлар көннән-көн арта бара иде. Бүген чамасыннан үтте дә шул эш белән бары берьюлы бәреп чыкты. Бүген аның чыдамы югалды. Бүген ул эчендә яшәгән тормышының артык тарлыгы, артык кысанлыгы, анда тончыгып үләрлек мәртәбәдә сасылыгын бигрәк ачык тойды – шул гади вакыйга сабыр савытын таштырды.

Теге якта күптән утлар сүндерелгән иде. Йөри-йөри арыды да, бераз тын алу өчен дип, тышка чыкты. Дөнья баягыча тын булып, ерак ай болыт астына кереп бара иде. Кайдадыр бер ат кешнәде, һам-һам дип, кызу гына этләр өреп алды да, авыл тынды. Мәрьямнең бүлмәсендә ут һаман бар иде.

«Димәк, йоклый алмый!»

Тәрәзәләр ике катлы, аның да тышкысы карланган. Шуңа күрә ачык бернәрсә күреп булмый. Шулай да анда бер адәм барлыгы, аның, идән буена бераз йөргәч, бу як тәрәзәгә бөтенләй капланып, бик озак җансыз сын шикелле катып торуы беленмәктә иде.

Зыя йортны бер-ике әйләнде дә тагы өйгә керде.

Йоклап беткәннәрме-юкмы икәнен белү өчен, теге якның ишеге янына килеп колак салды. Атасы гырылдап йоклый иде. Анасы исә әллә акрын гына елый, дога кыйла, әллә бик акрын тавыш белән Коръән укый иде, – ул бу икене аера алмады, ләкин күңеле әүвәлгесенә китте.

«Гадәтенчә, ястүне соң гына укыгандыр да, намазлыкка утырган хәлдә, кулына тәсбих тотып, дога кыйладыр, аглыйдыр... Аһ, бичара йөрәк!!.»

8

Зыя тагы Мәрьям хакында уйларга тотынды:

«Нишләргә? Тагы бер мәртәбә сынап карargaмы? Ләкин ни файда? Картны бикә үзе куйган; мәсьәләне дә аңлаткан; шулай булгач, ул, көн яктырганчы, беркая нитми саклар. Бу көенчә калдыру тагы ярамый. Юк, ярамый гына түгел, мөмкин үк түгел...»

Ул мең төрле план төзеде, мең төрле хәйлә корды, ләкин һичбере теләккә илтеп

җиткерерлек булып чыкмады. Ниһаять, башын талдырып, зиһенен арытып, рухы хәлдән тайгач, бер мәктүб язудан башка бертөрле эш кыйла алудан өмит өзеп, кулына кәгазь, кара алды.

Лампалар сүндерелгән – өй караңгы иде. Үзенең хәзерге халәтенә бик охшаганга, яңадан шәм-фәлән ягып, өйнең ай яктысына катыш хыялый караңгылыгын бозасы килмәде, калын тышлы бер китап алды да, айга капма-каршы булган бер тәрәзәнең янына утырып, күктән килгән яктылыкта яза башлады.

«Ничек язарга? Диңгез ташкынынннан куәтле ашкынган рухның хәзерге халәтен ничек тәгъбир итеп җиткерә алырга да, адәм теленең гади, ярлы һәм коры сүзләре белән йөрәкнең хәзерге тойгыларын ничек аңа әйтеп бирергә? Бу – мөмкинме?»

Ләкин Зыя бу сөальне дә уйламады, аңа җавап та эзләмәде, кулына каләмен алды да әллә нинди бер куәт, бер ташкын белән берничә минутта табакларча кәгазьне тутырып ташлады. Аның кулы фикеренә иярә алмый, каләме язып өлгерә алмый иде.

Аз вакыт эчендә язып ыргытылган бу мәктүбтә һәрнәрсә бар иде: иге-чиге булмаган мәхәббәт тә, фөрьяд-фәган[1] дә; әллә кемнәргә ләгънәт тә, алям вә изтыйраб[2] та, – белмим, тагы әллә ниләр, әллә ниләр, әллә ниләр! Ул үзе башта канигъ[3] иде, хәзерге сәгатьтә язылган мәктүб, әлбәттә, шулай булырга тиеш дип белә иде. Ләкин идән буенда бераз йөреп, яңадан укыгач, артык тапты: Мәрьямгә бик авыр тәэсир итәр, аның ансыз да парчаланган йөрәгенә артык зур газап булыр, газабын арттырыр кебек тоела башлады...

Утырып, яңадан төзәтте, берничә җирен калдырды, сүзләрен алыштырды, ләкин нәтиҗәдә һаман канәгатьләнмәде.

«Юк, – ди, – бүген аңа ялкыннар тасвир итәргә кирәкми. Бәлки, аның йөрәгендәге утын бераз игътидалга китерерлек рәвештә язылырга тиеш!..»

Һәм шулай эшләде дә.

Гади генә бер кәгазь алды да мөмкин кадәр сабырлы сүзләр белән, ялкын вә тойгыдан бигрәк, гакыл вә уй кертергә тырышып, кыска гына бер хат язды:

«Мәрьям!

Моннан язачак актык сүзем. Хәзер сәгать унике. Без җидедә китәбез. Димәк, минем монда җиде генә сәгать гомерем калган. Сиңа әллә ниләр язасы, рухымның хәзерге минуттагы халәтен әллә ничек, ләкин бик гади сүзләр белән

---

1 *Фөрьяд-фәган* – елау, сыктау.
2 *Алям вә изтыйраб* – әрнү һәм борчылу.
3 *Канигъ* – канәгать.

ачып бирәсе иде, – булмый инде. Актык мәртәбә үзеңне күрермен дигән идем, булмады, булмады. Моның өчен кемгә ләгънәт укырга, Тәңре кашында кемнең битенә төкереп, кемне аяк астына салып таптарга?

– Белмим, белмим. Бернәрсә дә белмим. Син түзә алмадың, юкса мин ул карт белән бер эш кыйла идем...

Хәерле булсын инде!

Минем бар өмитем синдә, газизем! Син түз, син чыда! Безне аерачак заман алты, җиде ай булыр. Иң күпкә киткәндә, бер елга сузылыр. Бөтен рухым илә ышанам, шул мөддәттә мин ни генә булса да кыйлырым: йә котылып кайтырмын, йә солдат булганым хәлдә бергә, бер-беребезнең кочагында яши алуның чарасын табармын. Беләм, газизем, беләм, сине бик күп кыенлыклар көтә. Сиңа үзеңнең иң якын адәмнәрең белән көрәшергә тугры киләчәк. Анаң үзгәрде; беләмсең, теге явызны ул куйган бит. Ул эт, анаңа бүгенге вакыйганы әйтәчәк, – үзе шулай диде.

Теге җансыз, теге таш йөрәк Фәхри дә искәнүендә дәвам итә. Анаң борын аны миннән түбән тота торган иде; кичә исем, гакылым китте. Ул илтифат, ул тәрилкә, тик киявем дип әйтеп кенә бетерми...

Мин боларның барын күрәм, беләм. Ләкин һичбереннән курыкмыйм: мин сиңа ышанам, мин синең куәтеңә иман китерәм. Бөтен дөнья миңа каршы барып та, син минем якта булсаң, без җиңәрбез, дим; синең куәтең, синең ул бөек йөрәгеңдә булган мәхәббәтең каршысында ташлар эрергә, тормыш үзе сәҗдә итәргә, күкләр баш иярга тиеш. Сау бул! Актык мәртәбә күзләреңнән үбеп, каршыңда сәҗдә итәм; мин китәм, без аерылышабыз, ләкин мәңгегә түгел: Тәңре үзе берләштергән җаннарны заман да, мөсафә[1] дә, кызганыч адәмнәр дә аера алмас.

Минем йөрәгем шулай ди.

Мәхәббәтең утында янып: Зыяң.

19... нче ел, ноябрь.

Зыя хатны язып бетереп, канвертка салды да, өстенә толыбын киеп, тышка чыкты.

Иң әүвәл аның дикъкатен җәлеп иткән нәрсә – бик өздереп кенә уйналган татар музыкасы булды. Егетләр бер чанага төялгәннәр дә урам буйлап чаптыртып киләләр. Берсе уйный, берничәсе сызгырып җибәрәләр. Берсе бик көр, ләкин музыкальный тавыш белән бик дәртләнеп җырлый.

«Кемнәр булыр? Никрутлар китте!.. Ә, Зариф старшинаның угылыдыр. Ул да, халыктан калып, бу көн таңда гына китмәкче иде бугай».

---

[1] *Мөсафә* – ара ераклыгы.

Чана якынайгач, Зыя җырлаучыны тавышыннан таныды, – вакыйган, шул старшина угылы Гыйльман икән.

Боларның турысына җиткәндә, чананы бераз акрынайттылар. Берсе төшмәкче дә булган иде; ахрысы, капка төбендәге Зыяны күреп, үзләренең иптәшләреннән берәрсе түгелме дип уйлаганнардыр. Ләкин, Зыя толыбының якасын күтәреп ипли башлагач, кем икәнен таныпмыдыр, тагы кызулап чаба башладылар.

Таңда китәчәк егет исә бигрәк артык дәртләнгән сыман җырлавында дәвам итте:

Сау булыгыз, дуслар, диеп,
Без урамнан үтәбез;
Без җырламай, кем җырласын?
Без иртәгә китәбез,..
Җилбер-җилбер җил ала,
Илтеп дәрьяга сала;
Башкасына кайгырмыймын,
Өзелеп сөйгән яр кала...

Атлар бик кызу чабалар иде; Шунлыктан егетләр бик тиз ераклаштылар да, ни җырлаганнарын аерып булмый башлады, бара торгач бөтенләй ишетелмәс булды.

Зыя, бакчага таба килеп, Мәрьямгә язылган мәктүбне ике араларында йөрмәс почта хезмәтен үти торган зур карт имәннең үзләре генә беләторган бер җиренә кыстырды.

«Бу – сиңа әманәт; иясенә тапшыр!..»

Мәрьямнең бүлмәсендә һаман ут бар, анда һаман бер җанның, тирән һәм бик авыр уйга баткан шикелле, идән буена акрын вә салмак адымнар белән туктаусыз йөрүе, йөреп-йөреп арыгачтан, бакчага караган тәрәзәгә бөтен гәүдәсе белән капланып, бик вә бик озак, ләкин бер дә кузгалмый катып торуы күренмәктә иде.

Зыя, буңа карап, бик озак, аптыраган бер хәлдә торды-торды да өенә керде. Инде ни эшләргә? Әлбәттә, йоклап булмый.

Кечкенә бер шәм яндырып, кесәсеннән хатирә дәфтәрен чыгарды да андагы хатларны, рәсемнәрне карый башлады. Монда егетнең үзенчә артык газиз вә артык кыйммәтле булган мәктүбләр генә җыелган – һәммәсе, әлбәттә, Мәрьямнекеләр генә иде. Ул кайсыларын күздән кичерде, берсен берничә кат укып чыкты да бердәнбер булган рәсемне алды. Анда Мәрьям иде. Ул тар, озын, нәзек күлмәк кигән, озын кара чәчен ике иңенә салып, асыл чәчәк төсле

кечкенә генә калфакны маңгайга якын гына кадаган. Йөзендә, бөтен торышында әллә нинди бер трагедия катыш матурлык балкый. Үзе зур бер агачка сөялгән дә, авыр вә мөтәәссир бер рәвеш белән, күзләрен батып барган кояшка юнәлдергән. Зыя озак, бик озак бу рәсемне карады да, яңадан дәфтәре белән күкрәгенә куеп, шәмен сүндерде. Инде ул бик арыган, хәлдән тайган иде. Толыбын ташлады да, дивандагы юрганнардан беренә уралып, кәнәфигә килеп ятты.

Аның яткан җире – кәнәфие кыйбла як тәрәзәнең буенда булып, анда ерак фәза бөтен торышы илә күренмәктә, тулган ай Зыяның йөзенә, күзе аша җанындагын укырга теләгән кебек, карап тормакта иде. Егет шуңа карап катты.

Мәгълүм түгел, аңа әллә авыр иде, әллә ул күңеле белән фәзага, күкнең аргы якларына китеп, дөньяның кайгы дигән, хәсрәт вә кыенлык дигән кебек вак нәрсәләрен хис итәрлек мәртәбәләрдән әллә кая, бик вә бик югары ашкан иде...

9

– Кызым! Кызым! Сиңа әйтәм, ят инде, ят! Бу ниткән эш: сәгать бер булган, син һаман утырасың! Төндә йокың кала да, аннан ары көн буена, кәефем юк-фәлән, дип йөрисең!..

Фатыйма бикә берничә мәртәбә, кызының ишегенә килеп, шундый сүзләрне тәкрар итте; ләкин Мәрьям, ни әйткәнен белмичә үк:

– Ярар, әни, ярар, хәзер ятам! – дип җавап бирсә дә, аның күңеле йоклаудан, тын вә тыныч йокыдан бик вә бик ерак иде.

Зыяның алынган көненнән хәзерге сәгатькәчә үткән унсигез көннән гыйбарәт аз бер заман ана белән бала арасындагы мөнәсәбәтне үзгәртеп, ул көнгәчә йөрәкләрендә бер-беренә чын дустлык, чын сөюдән башка һичбер нәрсә тоймаган бу ике вөҗүд бу араларда бер алмашыну хис кыйла башладылар. Мәрьям, буйга җиткән булса да, адәмнәргә карашында бала, бик бала, бик мәгъсум иде.

Ул үзе ачык хәтерли алмаган бер заманнан бирле җаны-тәне белән берәүгә багланган. Ул «берәү»не анасы да белә, анасы да ярата; хәтта кайбер вакыт киләчәк көндә шул «берәү»нең тагы ныграк якынаю ихтималы да аның тел төбеннән аңланып кала иде. Мәрьям эченнән бу хәлләрне сизеп йөри иде. Шулай булса да, һичбер вакыт нә ачыктан-ачык вә нә ишарә белән дә ул үзенең рухын тутырган куәтле ялкынны аңа белдерергә теләмәде: мәхәббәт ничаклы яшерен булса, шулчаклы кадерле, шулчаклы мөкаддәс һәм кыйммәтле була шикелле тоя, шуңа күрә бөтен дөньядан яшерә иде. Ләкин бу хәл гомергә дәвам итмәячәк иде. Ул үзенең йөрәгендәге тойгысын мәхәббәт дип, билгеле бер адәмгә мәхәббәттән гыйбарәт дип таныган сәгатьтән башлап, хыялында бу

мәхәббәтнең алгы көне хакында, аның дөньяга ачылуы тугрысында, үзенчә, бик шигъри, бик матур булган бер күренеш саклый иде.

Килер бер вакыт: боларның тойгылары йөрәкләрендә яшеренеп ята алырлык мәртәбәдән үтәр, боларның мәхәббәте дөньяга бәреп чыгарга, үзенең нуры белән хәятны яктыртырга теләр. Ул эчкә сыймас, ул ташып барыр. Менә шул вакыт анлар, Зыя белән караңгы кичәдә, бик аулак вә бик тын булган бер җирдә бик озак вә бик җитди киңәшкәннең соңында, бер карарга килерләр. Шуннан соң Мәрьям бик уңгай вакытны табар да, моның хакында яхшылыктан башканы уйлавы мөхаль булган газиз әнкәсенә мөкаддәс серне ачар:

– Әни, әни, әнкәм, җаным! Ачуланмыйсың бит, ачуланмыйсың бит! Мин аны бишектән бирле яратам, бала чагымнан бирле сөям... Аны уйлау, аның сурәте белән ләззәтләнү, аны сөю – минем йөрәгем белән бергә кан булып, ит булып үскән. Аңа мәхәббәт – минем җанымның бер кисәге. Бер кисәге генә түгел, бөтен торышы, барлык куәте... Ул да шулай, ул да сөя... Җаным, әнкәм, ачуланмыйсын, бит, без инде артык яшерә алмыйбыз, – дияр.

Анасы, әлбәттә, кызын сөя. Әлбәттә, кызның бәхетен, сәгадәтен тели. Шулай булгач, каршы бер сүз дә әйтмәс, моңарчы яшерелеп килгән бу хәлдән бик мөтәәссир булыр, йомшар; бәлки, кызын янына чакырыр да, аркасыннан кагып, маңлаеннан үбәр...

Шулай итеп, анлар Зыя белән бергә тора башларлар. Әй, бәхетле булырлар, әй, мәсгуд торырлар, әй, хәятнең иге-чиге булмаган ләззәтләре, кызыклары эчендә гомер сөрерләр! Ал да гөл, кадер дә түр, оҗмах та нур булыр. Яз килер, дөнья яшәрер, чәчәкләр атар, матур сулар агар, сандугач сайрар, – болар шул җәннәттә гомер итәрләр...

Ул борын шулай уйлый иде. Зыяның каралу мәсьәләсе аның җәннәт рәвешендә күренмәктә булган киләчәк көне күгенә авыр һәм катлаулы кара болытлар чыгарса да, ул, шул болытлар яман күкрәп, афәтле яшеннәр яшьнәү ихтималын хыялында күрә башласа да, моны вакытлы эш дип белә, теге җәннәт кайчан да булса бер насыйб була дип ышана иде. Ул үзенең бу өмитенә, бу ышанычына, башка һәркемнән бигрәк, анасыннан, йөрәк бәгыре газиз әнкәсеннән ярдәм эзли, аны егылмаска бер терәк итеп сизенә иде, – моның киресен уйлау, ул Зыяны сөя торып та, газиз әнкәнең аңа каршы бер кыл кыймылдатуы – мәгъсум кызның башына кереп тә чыкмый иде.

Ләкин үзен, каласын, мәртәбәсен башка һәр нәрсәдән алда тотучы тәҗрибәле бикә икенче төрле җавап бирде.

Моннан унсигез көн борын Гәрәй мирзаның зур залында берничә хатын аягүрә сөйләшеп торалар иде. Арада Зыяның кендек әбисе Бәдри карчык, Фатыйма

бикә, Мәрьям туташ, тагы берничә «кыска аяк» бар иде. Ишектән күрше килене Гайниҗамал атлыгып керде дә:

– Ишеттеңезме, ишеттеңезме? Зыя мәхдүм алынган, ди, алынган, ди... Бер сәгать әүвәл генә Ситдыйк кайтып, абыстайдан, угылың калды, дип, сөенчегә өч сум алган иде. Хәзер икенче кеше кайткан да, яңадан алдылар, дигән. Абыстай һушсыз, ди... – дип кычкырды.

Килен сүзен бетерергә өлгермәде, Бәдри карчык:

– Ай, бичаракай гынам, ай Зөләйхакай гынам, – дип чыгып китә башлады.

Мәрьям исә, баскан урынында катып калып, тыны киселде, йөзенә үлем аклыгы чыгып, күзләреннән хәят әсәре югалды. Тагы бер минут булса, ул, җә «уһ... уһ» дип, йөзен каплап, кычкырып, каршы бүлмәгә атылачак иде, җә шунда гадәттән тыш бер эш булачак иде. Килен сөйли башлау белән, кызының йөзеннән күзен алмый карап торган мөтәкәббир Фатыйма бикә аның ул үзгәрүен күрде дә, йөзенә катылык чыгарып, күкрәге белән күтәрелеп, Мәрьямнең күзенә шелтә вә дошманлык белән тулган усал һәм каты бер караш ташлады. Бу караш каты иде, кызганычсыз иде, монда кызгану белән мәхәббәттән башка һәр нәрсә бар иде.

Үзе бер сүз димәде, берни кыйлмады. Туташ шул каткан хәлендә калды. Бикә исә, кызына «мин синнән моны көтмәгән идем!» дигән мәгънәне аңлаткан бер рәвеш белән кырт кына артына әйләнде дә, өстенә тунын салып, Бәдри карчык артыннан, ахирәтен юатырга китте.

Шул минут бөтен тәфсыйле белән әле дә Мәрьямнең хәтерендә, дөньяда дустлык вә йомшаклыктан башканы белмәс кебек тоелган ананың шул явыз карашы, шул артык каты, артык кызганычсыз карашы хәзер дә күз алдында.

Мәрьям буны аслан вә аслан көтмәгән иде. Ул «әни» ди иде. «Әни» дигән сүзе моның һәрбер кайгысына, шатлыгына кушыла торган бер җанны аңлата кебек тоя иде. Зыяның алынганын белгәч, аңардан кызының мөтәәссир булганын аңласа, бик йомшак мөгамәлә кыйдыр, зур кайгылы адәмне җуаткан шикелле тотар, ихтимал: «Беләм, кызым, беләм, йөрәк бәгырем, мин барын да беләм; кайгырма, анаң бар чакта һичбер авырлык мәңге булмас... Анда китеп мәңге тормыйлар, менә кайтып килер-фәлән...» – дип тәсәлла[1] бирер шикелле тоелган иде... Шуңа күрә дә анасының ул имансыз карашы Мәрьямгә яшен сукканнан да яман тәэсир итте. Аннан соңгы мөгамәләләр дәхи шул юлдан актылар.

Бикә Зыяны кызганса да, бу тыштан гына шикелле, рәсми генә кебек, ул хәзер эченнән аңа бертөрле дә якынлык сакламыйдыр шикелле тоела башлады.

Ул әллә ниләр сөйли. Солдаттагы начарлыкларны, казармаларны телгә ала.

---

[1] *Тәсәлла* – юаныч, тынычлану.

Фәхрине дә бик еш зикер итә... Ни өчендер бөтен сүзләре «солдатка китте, – димәк, бетте димәктер...» дигән мәгънәне аңлатырга тырышкан була иде. Кызына ул хакта һичбер ачык сүз әйтмәсә дә, Мәрьям анасының үзе түгеллеген, анлар икесе ике нәрсә уйлый торган ике җан, икесе ике төрле нәрсә эсти торган ике күңел икәнен шул көннәрдән соң бик нык сизенде.

Бу аңа авыр иде. Бик авыр иде. Шуның илә бәрабәр анасының һәрбер адымы, һәрбер сүзе шул ачы хакыйкатьне ача бара иде.

Бу ничөн? Бикә ник алай Зыяга мөнәсәбәтен үзгәртте?

Мәрьям моны белми дә, уйламый да. Тик көтелмәгән, үзенең мантыйгына сыйдыра алмаган бу катылыкка, бу таш йөрәклеккә аптыраганнан-аптырый гына бара иде.

Бу хәл аны, анасыннан каядыр читкәрәк, ераккарак җибәргән кебек, теге «берәү»гә тагы ныграк баглый, аның белән араны тагы ныграк якынайта бара иде.

Димәк, ул ялгыз! Димәк, ананың күңелендә дә аңа ачылмаган пәрдәләр, катлаулар бар. Әүвәлге зарбәнең[1] тәэсиреннән айный башлагач, аның иң беренче теләге – тизрәк «аны» күрмәк тә, бик озаклап, бик тирәннән үзенең бар хәсрәтен, анасының шундый үзгәрешләрен энәсеннән җебенәчә «аңа» бәян кыйлмак, дөньяда «аңа» башка һичкеме калмаганлыгын, авыр көннәрен, йокысыз төннәрен, борчулы төшләрен – барын, барын «аңа» сөйләп бирмәк, шуның белән бер җуанмак иде. Ул һәр көн, һәр иртә шуны уйлап тора, планнар төзи, хәйләләр кора; ләкин сәгатьләр атлый, көннәр үтә, ул бәхет һаман насыйб булмый иде.

Бикә мәхдүмне берничә мәртәбә ашка, чәйгә алды. Ул, килеп, берәр уңае чыкмасмы дигән сыман, бик озак утыргалады. Шул йөрүләрдә бер-ике очраштылар да. Ләкин бу да йә баскычтан менгәндә, ишектән чыкканда бик хәвефле бер кул кысышу, якты җир булса, күзгә-күз карашып калудан үтми; нә сөйләшергә, нә башкага имкян булмый иде. Бикә башка вакытларда кунакка-фәләнгә китеп, озак ук торгалый, кайбер чак төннәрдә дә өйдә булмый иде. Ә хәзер һичкая атлап чыкмый; малга бүре тия, салам вә игенне бик урлыйлар, дип, йортка каравылчы да куя; җитмәсә, үзе кичләрдә бик озак утыра иде. Шунлыктан, әүвәлге вакытлардагы кебек, төнге күрешүләргә һичбер төрле имкян табып булмый иде.

Мәрьям, нинди дә булса бик табигый йомышлар табып, ахирәт апасына һәр көн диярлек керә, моңа анасы да һичбер сүз әйтми иде. Ләкин керүдә ни файда? Булса, ерактан бер күз карашуда, бик үтсә, бер күрешү белән калына иде.

---

[1] *Зарбә* – бәрү, удар.

Анда керүнең дәхи икенче бер авырлыгы да бар иде.

Зөләйха абыстай әллә бер галәмәтеннән-фәләненнән белгән, әллә тик йөрәге белән генә сизә – ни дә булса бар, ул гүя Мәрьямне үтә күрә, гүя бу назик табигатьле, хәссас йөрәкле туташның эчендә нинди ут янганын тоя һәм гүя һәр көн кереп тә, җитди йөз, талган күз, кайгылы бер кыяфәт вә мөтәәссир тавыш белән бер-ике сүз генә сөйләп, кире чыгарга ашкынуының серләрен аңлый иде.

Хәзер аңа ахирәт апасы әүвәлгедән әллә ничә өлеш якынайган кебек күренә; аның туташка мөгамәләсе дә йомшак, сүзләре дә гел: «Елама, бәгырем, елама, күз нурым, менә мин дә синең кайгың, синең хәсрәтең белән янам», – дигән шикелле чыгалар иде. Ул гүя бу яшь йөрәкнең үзенеке белән бер утта янганын күрә дә кайгыда уртаклык күрсәтә иде...

Мөгамәләсеннән, сүзеннән бигрәк, абыстайның күз карашлары бу халәтне Мәрьямгә бигрәк ачык белдерәләр иде; Ахирәт апасы гүя аңа һәрвакыт кызганып карый, гүя: «Беләм, бәгырем, беләм; ләкин ни эшлик соң?» – ди иде.

Бу Мәрьямгә зур җуаныч, авыр газап эчендә куәтле бер күңел рәхәте сыман иде. Абыстасының алай каравыннан ул курка да, оялган шикелле дә була, шуның илә бәрабәр аңа якынлык тоя, күңеленә бер җиңеллек килгәндәй була иде.

Менә бу хәл аны һәр көн Җәләл мулланың өенә тартса да, Зөләйханы күрү белән, аның йомшак вә кызганычлы күз карашын очрату белән, ул монда тагы бер минут калуның мөмкин түгеллеген тоя, тагы бераз шул ана янында калса, түзә алмас: «Җаным, абыстай! белсәң, мин ни чаклы бәхетсез!» – дип елап, аның кочагына атылудан яки шуңа охшаш бер хәл булуыннан курка; шуңа күрә, юктан ясап кергән йомышын үти дә тизрәк бу авыр хәлдән, бу кызганучы күздән котылу ягын карый иде. Шунлыктан һәр көн, хәтта кай көннәрдә берничә мәртәбә керсә дә, Зыяны күрергә, аңа эчендәге җәһәннәмне ачып, алдында күз яше түгәргә имкян чыкмый иде.

Ләкин күрешү, бик озаклап сөйләшү лазем иде, фарыз иде. Буны күңел генә теләми, бу – йөрәкнең, мәхәббәтнең эстәге[1] генә дә түгел, монда җитдият тә бар, зарурат[2] та бар иде. Кем белә, ни хәлләр булмас, Зыядан соң нинди алмашынулар килмәс – шуларның барына каршы хәзерлек кирәк, план кирәк, һәр көн диярлек язылган хатлар да буны әйтеп бетә алмый; йөрмәс почта – карт имән дә бу хактагы сүзләрне ташып җитә алмый иде.

Башкача юл булмагач, Зыя да хәйлә кормакчы булган иде: Мәрьям нинди дә

---

[1] *Эстәк* – теләк.
[2] *Зарурат* – үтә кирәклек.

булса бик табигый бер бәһанә[1] табарга да калага кардәшләренә китәргә, шул көннәрдә Зыя да, кая булса да барам дип, шәһәргә барырга һәм шунда күрешергә!

Менә нинди яхшы план; нинди зур иркенлек, нинди бөек азатлык!

Ләкин кызының җанындагы һәрбер үзгәрешне үтә күрә башлаган Фатыйма бикә, бер-ике сүздән үк мәсьәләнең төбен сизеп алып, башта бик кырт кына: «Булмас, нинди вакытсыз йөрү ул!» – дияргә уйласа да, яхшылык белән тыю мөмкин булган урында, кызына явыз күренәсе килмәде; Мәрьямнекеләрдән дә мантыйкыйрак сылтаулар чыгарды да: «Һичбер, һичбер мөмкин түгел», – итеп калдырды...

Шуның белән вәссәлам.

Яшь күңел шулай булса да өмит өзми иде әле. Бәлки, бер җае чыгар, бәлки, Ходай бер юлын күргәзер, дип уйлый иде.

Ләкин кечек капка янындагы фаҗига бу өмитләрнең вә ул планнарның һәммәсенә, һәммәсенә берьюлы хатимә бирде:

«Юк, булмый; өмит бетте!»

«Юк, булмый; өмит бетте!»

«Юк, булмый... өмит бетте!»

Анларның беренче аерылышулары түгел. Бер вакытлар Мәрьям кызлар мәктәбендә булды, Зыя мәдрәсәдә торды, хәтта әллә кайларда йөреп, берничә ел кайтмый торырга да туры килде. Айлар, еллар үтте, анлар күрешә алмадылар, тик бетмәс-төкәнмәс хатлар белә генә җуаныштылар. Ул вакыттагы аерылышулар да, әлбәттә, җиңел түгел, ул чакларда да бер күрү өчен зар булган минутлар бик күп була иде. Ләкин, ләкин һичбере, һичбере ни өчендер хәзерге аерылышу кебек авыр тоелмый, хәзергесе кебек йөрәкне парә-парә кыйлмый иде. Мәрьям буның хикмәтен, әлбәттә, уйламый, ләкин кызларның үзләренә генә хас булган бер сизгерлек белән ничөн артык хафаланганын бераз тоя иде.

Баладан ук куркып киләләр; халык телендә, ул эшне телгә алганда, «Ходай үзе сакласын» дип сыгына башлыйлар; анларга «киткән баш» диләр; анларны әллә кайларга, әллә нинди сугышларга, мөдһиш туп астларына җибәрәләр; күпләр аннан кайтмый да, кайтса да, әллә ничек үзгәреп, икенче адәм булып кайта, – Мәрьям шуларны эче белән сизә дә, «аның» бу китүен мәңгегә аерылудыр сыман тоя. Гүя ул китә дә югала, бетә; бетмәсә, югалмаса да, Мәрьямгә сөйгән яр була алмый.

Бер Ходай үзе генә белә, тагы нинди хәлләр булыр, нинди көннәр килер! Теге Фәхри, Зыя алынгач, бу тирәдә иснәнеп йөренгәләвен бигрәк арттырды; бикә дә

[1] *Бәһанә* – сәбәп, сылтау.

аның янында гадәттәгедән артыграк әйләнә башлады. Боларның һәрбере алгы көннәрнең күгендә, аерым-аерым кара болытлар ясап, өмит кояшын каплый баралар.

«Ходаем, үзең сакла, тагы ниләр булыр, ниләр булыр!»

Аның күңеле әллә нигә бик үк курка шул. Көндез дә башында әллә нинди авыр вә хафалы уйлар йөри; кич булса, йокыга ятса, яман төшләр күреп газаплана, үткән төн дә бик куркып уянды.

Имеш, бер зур су. Шуның буенда агачлар, таллар, нindидер куышлар бар. Яр буенда зур-зур көймәләр тора... Йа Ходай, көймәләр түгел имеш, – кулларына әллә нинди нәрсәләр тоткан адәмнәр имеш... Ходаем, нинди куркыныч йөзләре: җеннәр, пәриләрмени! Абау, Илаһым, бу ни эш, бу ни эш? Шул куркынычлардан берсе үзенең зур, куркыныч, усал һәм кара күзләре белән бертуктамый Мәрьямгә карап тора... йа Ходай, бусы ни тагы? Шул куркыныч адәм һаман күзләрен алмый, гүя карашы белән аны ташка әйләндермәкче; ә үзе үзгәрә бара, үзгәрә бара, үзгәрә бара. Бу ни бу, төшме, өнме? Үзгәрә торгач, шул адәм таныш бер кыяфәткә әйләнде. Гүя Мәрьям аны таный, ләкин кем икәне хәтеренә генә килми. Шулай дип уйларга өлгермәде, ул адәм Фәхри булды да, кулындагы зур пычагын ялтыратып, боларга таба атлый башлады. Болар икәү имеш, якындагысы Зыя имеш... Мәрьям, теге пычаклардан куркып, Зыяга таба: «Абау, харап булдык, безне үтерә...» – дип ташланырга өлгермәде, Зыя урыныннан сикереп торды да, кунычыннан зур пычак чыгарып, Фәхригә каршы килде.

Тегеннән адәмнәр кузгалды, Мәрьям исә: «Абау, һәлакәт!» – дип кычкырырга уйлады, ләкин тавышы беткән иде бугай, беркем дә ишетмәде... Гүя Зыя белән Фәхри пычакка пычак килешкән хәлдә торганда, агач арасыннан әллә нинди күк шинельле, сары төймәле, кылычлы бер адәм килеп чыкты да: «Сабитов!» – дип кычкырды, һәм шул секундта Зыяның кулыннан пычагы төшеп, ул картузлы, шинельле бер солдатка әйләнде дә, теге афитсәр[1] алдында, аякларын турылап, олуглау урынында уң кулын маңлаена куйды – хөрмәт күрсәтте.

Шуннан соң аны алып киттеләр, Мәрьям калды. Ул, актык мәртәбә күз карашты, Мәрьямгә өмитсезчә кул селекте:

– Юк, булмый; өмит бетте!

Бу төш Мәрьямгә бик яман тәэсир итте. Берәүгә сөйләп юратса, бәлки бераз җиңеләер дә иде. Ләкин «аңардан» башка кемгә сөйләргә мөмкин? Ә аны ничек күрәсең?

«Каһәр төшкеренең «Тәгъбирнамә»се[18*] дә әллә кая бит!»

[1] *Афитсәр* - офицер

«Ходаем, ни эшләргә? Әллә башны ташка орыргамы?»
Ичмаса янында берәр кеше дә юк. Романнар да укыйсы килми... Хатлар, портретлар актарып та күз талып беткән... Эшкә кул бармый!
Бала чагындагы кебек, битеңне, башыңны тырнап, чәчләреңне туздырып, бөтен дөньяның астын өскә китерерлек, эчеңдәге барлык-барлык көенечләреңне чыгарып түгәрлек итеп, туйганчы елап, акырып булса, үзеңне өзгәләсәң, яисә явыз язмышны үзәгенә үткәргәнче тиргәп., ләгънәтләп ташласаң, бәлки, бераз ару булыр, бәлки, бераз җиңеләер иде. Яисә, менә хәзер бер могҗиза була да, шул тәрәзә үзеннән-үзе ачылып, аннан көлә-көлә Зыя килеп керсә! – нинди хозур, нинди бәхет булыр иде!
Ләкин елап та булмый, могҗиза да заһир булмый. Сәгать бик акрын атлый, йөрәк сызлана. Бөтен авыл тыныч йокыда. Әнә икенче этәч тә кычкыра. Ләкин ул, авыр вә тирән уйга баткан хәлдә, идән буйлап акрын гына йөри. Арыгач, бакчага караган тәрәзәгә каплана да, җансыз сын шикелле, озак, бик озак катып кала.
Шул вакыт аның башына, бик табигый агымнар белән, бер дә дулкынсыз, ташкынсыз гына, мең төрле уй килеп кичә. Ул Зыяга кыенлык булыр, ул газап күрер, авыр яшәр дип уйламый, ничектер бу бер дә аның башына килми, һәм кайгысы да ул ноктадан түгел. Зыя аңа дуст иде, сөйгән яр иде. Анлар бишектән алып бик чын рәвештә дустлык җебе белән бәйләнгән; анларның җаннары берләшкән, һәр икесе бер-берләренең йөрәгенә баладан ук кереп утырганнар. Яратышалар, берен-бере күрү белән, бер сүз алышу, бер карашу белән шатлык хис итәләр, бераздан бөтенләй берегеп, бик бәхетле, бик мәсгут гомер итәчәкләр иде.
Инде ул әллә нинди, кайтмас, котыла алмас кебек тоелган бер җиргә китә... Аны бер күрергә зар булыр, ләкин мөмкин булмас, сагыныр, хәятында ямь вә тәм калмас. Кем белә, тагы niләр булыр!
Бер кеше китә, беразга аерылышалар гына түгел, гүя аның хәятында бердәнбер сәгадәт булып хис кыйлынган кадерле нәрсәсе мәңгегә югала; аның хәятына нур биргән шәм сүнә; гүя һәммә шатлыкларының, һәммә бәхетләренең чишмәсе гомергә, гомергә корый... Зыя китә, Зыя солдат була түгел, бәлки Мәрьямнең үз хәяты, үз күңеле бик кыйммәт вә бик кадерле булган җәүһәреннән аерыла.
Гүя әллә нинди явыз кул ул матур егетне, ул гашыйк ярны назлы туташның кочагыннан тартып ала да, аны гыйшык сәгадәтеннән, хәят нигъмәтеннән мәңгегә мәхрүм итә...
Моны мөхакәмә сөйләми, гакылы да белми, бәлки җаны сизә, йөрәге әйтә...

Тәсбихе белән «Коръән»ен артындагы мендәргә куйды да, мулласына йокларга тынычсызлык итмәсен өчен баса төшкән лампасын яңадан чыгарып, Зөләйха абыстай урыныннан калыкты.
Җәләл һаман гырылдап йоклый. Теге якта ут юк, тавыш-тын да килми: димәк, Зыя йоклаган!
Хафалы анага бу бераз җуаныч төсле булды: йоклый, димәк, артык кайгырмый! Ул, угылы уянмасын дип, аяк очы белән генә басып, зур якка, өстенә кияргә чыкты. Үзе әрвах вә күләгә кебек кенә, сак кына йөри. Бер дә тавыш чыгармаска тырыша иде, ләкин пич буендагы комганны алганда, ниндидер бер тимер шалтырап идәнгә төште;
– Кем бар?.. Әни, синме?..
– Мин, балам, мин!
Зөләйха абыстай кулындагы лампасы белән Зыяның, кәнәфиенә таба килде:
– Балам, син һаман йокламагансыңмыни? Йоклау кирәк иде, сәгать өч тә булып килә... Атаң, алтыдан калмый торырбыз, диде...
– Юк, әни, мин йоклап уяндым...
Абыстай, угылының янынарак килеп, бер. урындыкка утырды да авыр кыяфәт, салмак тел һәм йөрәкнең әллә кай җиреннән, әллә нинди авыр тойгылар аркылы үтеп чыккан тавыш белән, гәүдәсен бер дә кузгатмый, сөйләшә башлады.
Зыя исә анасының бөтен торышында, бигрәк тә йөзендә булган зур үзгәрешне бу минутта, бу кечек лампа яктысы, төн караңгысы, тонык ай шәүләсе илә чолганган бер секундта, артык ачык вә артык мөәссир күреп хәйран калды.
Бу – тәгаҗҗебле ис китү түгел, бәлки кызгану илә кайгы дәрьясының төбеннән күтәрелгән авыр хәйрәт иде.
Зыя үзенең алынуы анасына ни дәрәҗәдә авыр тәэсир итәчәген әүвәлдән үк бик ачык белә иде, һәм алынып кайткан көннән алып, ул гали йөрәкнең ни дәрәҗәдә мөтәэссир булганлыгы[1] аның һәрбер сүзеннән, һәрбер хәрәкәтеннән сизелеп тора иде. Бу хәтта Зыяның көткәненнән дә артык иде: ул беленерлек мәртәбәдә ябыга башлады; зур күзләре, әллә кая төпкә батып, һәр нәрсәгә авыр, җитди, өмитсез карый торган булды; анлар гүя җәһәннәм газабын тәгъбир итәләр иде. Дуст хатыннар керәләр дә, остазбикәләренең бу хәлен күреп:
– Илаһым, ана күңеле балада, бала күңеле далада, дигәннәр, угылына тагы бер хәл иде, исән булса, бер кайтыр иде, әмма абыстай бик кызганыч; бичара, болай да юк-бардан янып, көеп, балаларым, балаларым дип җан өзелеп йөри торган кеше, артык сөйгән Зыясы алынгач, бигрәк артык хафалана инде... Атна-ун көн эчендә берничә еллык картайды, йөзе саргайды, үзе кипте, – дип аптырашалар,

[1] *Мөтәәссир булганлыгы* – кайгыдан иза чигүе

кызганышалар.
Ләкин бу кызганудан аңа бертөрле дә җиңеллек булмый. Ул аз сөйли, аз ашый, төне буенча тәрәзәсендә ут була, – димәк, йоклый алмый. Өйдәге эшләрен дә күп вакыт үзе карамый, бер хатынга тапшыра... Башында артык куәтле бер уй булгангамы, кайбер чакта көннәрне, вакытларны да саташтыра, кайбер вакыт көненә берничә мәртәбә: «Бүген кайсы көн әле?» – дип сорый... Гүя аның хәтере югалган.
Үткәннәр дә, ничектер, бер сыек, аксыл томан эчендә, яисә бер дә булмаган кебек күренәләр.
Дөньясы тузылган, эшләрендә тәртип беткән... Намазларын гадәттәгедән күп һәм озак укый. Һәр намаз соңында вирдләре, догалары җөмләсенә берничә сүз дә куша, хосусән ястүләрне бик ихлас вә бик озак үти. Дөнья тын, авыл йокыга чума, өйләрдә ут сүндерелеп, һәркем онытыла, икенче дөньяга китә – менә шул вакыт ул намазлыгын җәя, янына басып кына кечкенә шәмен куя да тын вә ярым караңгы өйдә, пакь намазлык өстендә кулында тәсбих, алдында «Коръән» улдыгы хәлдә, сынган күңелдән илаһи бер хөлус[1] белән Тәңрегә тәүбәсен, догасын, теләген гарыз итә – ялына, ялвара...
Бәгъзан шул хәлдә таңнар атып китә...
Ул үзе бик хәссас һәм бик мөтәәссир вә бик бай хыяллы хатын. Шул пакь, саф вә сөйкемле угылы, шул йөрәк парәсе Зыяның әллә кемнең азгыннары белән, әллә нинди начар җиргә китүе аңа бер дә тәгъбир итеп җиткерә алмый торган бер авырлык, бер кайгы бирә.
Ул угылы аркылы бәхет көтми иде; шулай ук, күп аналар кебек, аңа кәләш алып, килен хезмәте күрү, кодагый булып түрдә утыру сәгадәтләре дә аны ул чаклы тартмыйлар, кызыктырмыйлар иде. Юк, ул боларны уйлап, угылы аркылы бер рәхәтлек көтеп тә, инде шул көткәненә ирешә алмаячак булганга кайгырмый, бәлки угылының язмышында булган бу авыр үзгәреш шул йөрәк парәсе баласын бик авыр хәлгә төшерә, аны харап итә, аны әллә нинди газапка ташлый сыман тоя, вә шул тойгы аны газаплый иде.
Гүя ул китә дә әллә ни хәлләргә төшә, икенче дөньяга чумып, әллә ниндигә әверелә. Ул, аны асарлар, кисәрләр дигән кебек, билгеле бер нәрсә уйламый, ләкин үзенә беленмәгән бер авыр хәл, авыр кайгы килгән кебек тоя... Гүя аны иртәгә озаталар да, ул әллә нинди ятмы, караңгымы, гөнаһлымы булган бер дөньяга кереп китә; шуннан аның йөзе дә урыс төсле буламы; күзләре дә әллә ниндигә әвереләме; картларны елатып коръән укый торган матур тавышы да бетеп, ул инде анасына элеккеге шикелле һәйбәт вә тәмле сүзләр дә әйтә белми

[1] *Хөлус* – чын күңеллелек, ихласлылык.

башлыймы; тагы мыжгырдап торган чәчде, тәреле адәмнәр арасында, башында картус булган хәлдә, бисмилласыз, сул кулы белән тотып чучка ите ашап утырамы; тагы шундый әллә ниләр, әллә ниләр буламы, булмыймы, – аны гакылына китерми; ләкин йөрәге шундый мең нәрсә сизенә. Әллә андый һичбер нәрсәне сизми, уйламый, тик баласына мәхәббәт вә шәфкать илә тулган ана йөрәге тик «ул алынды» дигән бер сүз белә генә шул хәлгә төшәме?.. Мең тойгы, мең шөбһә...

Әгәр дә аңардан: «Абыстай, адәм башы югала торган жир түгел бит, ник ул чаклы кайгырасыз?» – дип сорасалар, ул, шелтәне аңлаткан бер рәвештә, башын селкер дә: «Менә, Илаһым, аны сорап торырга ярыймы соң!» – дип кенә җавап бирер вә шул җавапны үзенең эчендә булган барлык тойгыларын тәмам әйтеп житкергән санар иде.

«Менә, Илаһым, аны сорап торырга ярыймы сон?»

Зыя, боларның һәммәсен белеп, һәммәсен йөрәге белән сизеп, анасын үтә күргәндәй булып йөри иде.

Боларның бере дә яңа түгел, шуңа күрә берсе дә аңарда хәйрәт тудырмаска тиеш иде...

Ләкин җиде төн уртасында, бөтен дөнья йокыда чакта, намазлыгыннан торып, аның янына килеп утырган, төннең ярым караңгылыгы һәм тонык, хыялый ай шәүләсе илә чолганган бу авыр кыяфәт, җитди вә мәтәәссир булган бу йөз һәм эчкә баткан бу зур күзләр белән суырылган яңак – үзләренең авыр сөкүтләре белән Зөләйха абыстайның йөрәгендә башка һичбер вакыт булмаган олуг кайгы илә тирән фөрьяд барлыгын сөйлиләр иде.

Бераз утырганнан соң, абыстай әллә кай җиреннән, җанның төбеннән килгән тавыш белән:

– Ходайның язмышы шулайдыр инде, балам, мин күрәсене кем күрсен! – диде дә урыныннан кузгалды, дәхи шул ук тавыш белән: – Йокла инде, балам, йокла! – дип, комганын кулына алды да чыгып китте.

Ул яңадан кергәнче, Зыя, чишенеп, пич буендагы караватка ауган иде. Абыстай һичбер сүз димәде, туны белән комганын урыннарына куйды да теге якка, ире янына чыкты.

Хәзрәт бик җәелеп, бер дә кайгысыз төсле ята иде.

Ана бу хәлгә тәгаҗҗеб итте:

«Әй, Раббым! Бу чаклы таш йөрәк була алыр икән бәндә!»

11

Әнә биш, ун мәхәлләле зур шәһәр... Әнә шуның биек манаралы, беренче

дәрәҗәдә олуг вә шанлы мәсҗеде... Әнә аның айлы, челтәрле, мөзәйян[1] мөнбәре... Әнә шул мөнбәрдә Җәләл мулланың угылы вәкар вә кибер катыш һавалы кыяфәт белән мәсҗедкә шыгрым тулган зур байлар һәм могътәбәр[2] җәмәгать алдында могҗиз[3] бер аваз илә хотбә укый... Бөтен халык хәйран кала...

Яисә үзенең даны, шөһрәте илә дөньяны яңгыраткан бик олуг вә бик могътәбәр мәдрәсә... Анда ничәмә йөзләгән шәкерт... Дәресханәдә көрәк кебек сакаллы, зур вә мәһабәт хәлфәләр, явыз телле, дәһри башлы, сүз бирмәс табигатьле имансыз пишкадәмнәр... дөньяда үзенә тиң тапмый күккә ыргыган арысландай бер ашкыну белән моназара итешәләр... Түрдә, дәрес көрсисендә[4], Җәләлнең хәким[5] күзле, риязый[6] кыяфәтле угылы күзлегенең өст ягыннан каршысындагыларны диккать итә... Арадан кемдер дәреснең шәэненә якышып[7] бетмәгән бер сүз ычкындыра... Җәләлнең угылы, күкрәге белән калка төшеп, куәтләренә чыдаша алмый утырган арысланнарга күзлек өстеннән шелтәгә охшаш бер караш ташлый, – тегеләр шым булалар...

Диңгезнең куәтле дулкыны, үзенең кочагына алган корбанын бер батырып, бер чыгарып уйнаткан кебек, угылларының киләчәк көне хакында бик күп еллар хыялында ясап йөргән менә шул күренеш, шул идеал Җәләлне бер батырды, бер күтәрде, өмит белән шөбһә арасында бик күп шаяртты да, ниһаять, тагы китереп төпкә бәрде.

«Мәхдүм алынды!»

Шуның белән бергә мулланың башы томаланды, хыялындагы шәһәр дә югалды, мәсҗед тә җимерелде, теге мәдрәсә дә юкка чыгып, имансыз пишкадәмнәр дә әллә кая очты; анда башка һич бер нәрсә калмады, – тик томан да караңгылык! Башка аталарның, угыллары алынган хәбәрне ишеткәч, иң әүвәл хис иткән нәрсәләре – кызгану була; мулла булыр, имамәтлек кыйлыр дип йөргән шәкерт угылы алынган кешеләр дә берьюлы өмит өзмиләр: «Анда, – диләр, – кеше мәнге тормый. Менә тоймый да калырсың, өч ел үтәр дә китәр... йөрер, дөнья күрер; дөрест, гомере әрәм була, гыйлеме артмас, ләкин китап караса, моталәгадә[8] булса, кимемәс тә...»

«Менә тоймый да калырсың, хезмәте тулып кайтып килер... Аннан соң

[1] *Мөзәйян* – зиннәтле,
[2] *Могътәбәр* - хөрмәтле
[3] *Могҗиз* – матурлыгы белән кешеләрне таң калдыручы, сокландыручы.
[4] *Көрси* – кафедра.
[5] *Хәким.* – акыллы, философ.
[6] *Риязый* – укымышлы.
[7] *Шәэненә якышып* – үзенчәлегенә, эчтәлегенә туры килеп
[8] *Моталәга* – уку, белем алу.

нөфүзле[1] генә мәдрәсәләрнең берсенә барып, берәр ел гыйлемен яңартыр да, насыйб булса, мулла да булып куяр...»

Ләкин Җәләл мондый җуанычтан бик вә бик ерак.

Аның зур угылы юлдан язды, бусы да, гакылдан шашып, берничә еллар атасы теләгенә каршы киткән иде. Нindидер бер могҗиза гына аны яңадан гакылга утырткан иде... Шулай да мулла үз рухының төбендә бу гакыллылыкта ничектер бер шөбһә тоя иде: гүя ул бер вакытлы гына эш; гүя аның Зыясын атасына бәйләгән җеп бик артык нечкә; шул дәрәҗәдә ки, нинди генә булса да бер гади көч аңа кагылсын, – теге нечкә җеп бөтенләй өзелер дә, Зыя ычкынып китәр, һәм аннан соң инде аны асла вә асла тотып булмас...

«Мәхдүм алынды!»

Шуның белән теге җеп өзелде, Зыя да хәзрәтнең кулыннан мәңгегә ычкынды...

Мулла шулай дип хис кыйла, һәм инде әллә нинди могҗиза да угылын яңадан гакылга утыртып, мөдәррислек юлына сала алмас төсле тоя... Шуңа күрә, солдаттан кайтып укыр да ахун булыр дигән өмитне, үзе көчләнсә дә, башына китерә алмый...

Ул бу эшләрнең бары да, тыштан Зыя өчен күңелсезлек булса да, асылда аның теләгенә таба барып чыкты дип уйлый; гүя ата белән угылның көрәшүендә соңгының тәмамән җиңә алуы өчен солдатлык ярдәм итте, гүя Зыя моны аңлый да, шул ягын уйлап, бераз шатлана да...

Шуңа күрә дә хәзрәт угылының алынуы өчен кайгырмый, бәлки ачулана; эчтән, йөрәгенең әллә кай җиреннән ләгънәт кенә хис итә.

«Мәхдүм алынды!» – дигән хәбәрне ишеткәч, аның беренче тойгысы – кызгану түгел, бәлки угылына ачу, дошманлык катыш ачу булды.

Гүя алынуда Зыя гаепле иде. Ул буны ачыктан-ачык әйтмәсә дә, яшерергә дә лөзүм күрми иде. Аңа җылы сүз әйтми, ул хакта бергә кайгырышмый, хәтта әүвәлгечә уен сүзләр дә сөйләми иде.

Китәр көнгәчә шул хәл дәвам итте; кайгы вә кызгану урынына йөзенә ачу вә салкынлык чыгарып, угылына җылышмады, тик мәҗбүри булган бер бурычны үтәгән сыман, аның кирәк-яракларын, юл хәҗәтләрен хәзерләтте.

12

Зыя исә тагы үзенчәрәк уйлый иде.

Ул үзенең эләгүенә, үз хәяты вә үз көне ягыннан гына караганда, бик артык исе китми: «Ну, алындың. Ни булды? Алынмау, әлбәттә, яхшы иде. Анда өч-дүрт ел гомер үтә. Гыйлем вә сәнгать артта кала. Корылган планнар юлда тора. Ләкин ни эшләргә? Аның өчен елап булмый бит инде», – ди.

[1] *Нөфүзле* – авторитетлы, дәрәҗәле.

Бу эш аны бик авыр булган бер бәрелешүдән дә коткара. Ул бит барыбер атасы теләгән адәм булмаячак. Бүген, йә иртәгә, булмаса, бер айдан, бер елдан соң булса да, ана бит атасы белән хисапны өзәргә туры киләчәк, кайчан да булса бер атасының тәклифатына[1] каршы: «Атай, син юкка көчләнмә: мин ахун да булмыйм, мөдәррислегең дә кирәкми! Син ул фаразны башыңнан чыгар», – дип әйтергә кирәк булачак иде.

Табигый, атасы аның бу сүзенә рәхмәт әйтмәс, бер минутта эченә ут кабынып, ачуына чыдаша алмый урыныннан сикереп торыр да кара көйгән йөз, акайган күз белән моның өстенә кычкырыр: «Алайса, кем буласың?! Алайса, кем буласың?! Көтү көтәмсең?! Бар, күземә күренмә!! Әнә урыс авылына бар да дуңгыз көт!! Чучка бәрәне асра!!»

Шуннан тотынып сүгәргә, тотынып бөтен дөньяны эттән алып эткә салырга!

Анасын сүгәр, Сабирны эт итәр, кияве белән кызын тизәккә ташлар, үзенең болар өчен тырышуын, дөньяда һичкем кыйлмаганны кыйлганлыгын, гайрәтен, шәплеген сөйләп, үзен күккә күгәреп мактаныр, мактаныр да, Зыя шуннан соң да гакылга килмәсә: «Күземә күренмә! йортыма аяк басма!!» – дип куып чыгарыр.

Зыя өчен бунда да зур кыенлык юк. Җиләнен, җөббәсен кияр дә чыгып китәр, – шуның белән вәссәлам! Ләкин ана ни эшләр? Бу хәл аңа ничек тәэсир итәр?

Зыя бик ачык күрә ки: бу бәрелешү Зөләйха абыстайның ансыз да бәхетсез башына артык авыр вә мәңге бетмәс трагедия булачак, аны җәһәннәм газабына ташлаячак...

Ә солдатка алыну исә ул трагедияне бик табигый сәбәп белән юк итә... Бу икенең, ягъни солдатка китү белән куылып чыгуның, Зөләйха абыстайга бирәчәк тәэсире, әлбәттә, бер дәрәҗәдә булмаячак.

Солдатлык бер боларга гына килгән бәла түгел. Анда бөтен ил белән. Ул тагы язмыш эше дә. Дәхи, анда китү бервакыт кайту өмитен җуймый, – ә бит үзеңнең кадерле һәм җаныңнан якын угылыңны туган-үскән йортыннан үз атасы шулай итеп куып чыгаруы, Ходай сакласын, – бу бит әллә нинди авыр, башыңа да сыйдырып булмый...

Зыя анасын һәр хәлдә шул икенең берен күрергә мәхкүм[2] дип ышана, үзенчә, солдатлыкның анага бирәчәк газабы теге хәлдән җиңелрәк булыр кебек тә таба иде. Шул якны өске бер караш белән уйлаганда, бу эләгүнең бер зарарсыз ягы да бар кебек чыгара иде.

Ләкин үзе буңа ышанмый иде, шуңа күрә бичара ананы бу ике авырлыкның һәр

---

[1] *Тәклифат* – көчләп кушулар, мәҗбүр итүләр

[2] *Мәхкүм* – хөкем ителгән

икесеннән коткару ягына чара эзли иде. Һәм шуның өчен ул бәлаләр, ул дарулар вә ул һушсызлыкларны күтәрергә мәҗбүр булган иде.

Алынып кайткач, авылда үткәргән унсигез көн аның бу соңгы юлы хаклы икәнен ачык күрсәттеләр.

Үз көне, үз рәхәте ягыннан караганда, артык исе китәргә ярамаган шикелле күренгән бу алынуның анасына биргән тәэсирен күрү аның теге «сәхәрсез руза» тоту, агулану кебек мәгънәсезлекләрен гүя мәгъзур[1] итеп чыгаралар, гүя аны аклыйлар иде. Зыя буны уйлый да теге Җаббар муллага ни диярга аптырый иде.

«Җүләрнең җүләре шул! Менә ул җүләргә адәм җанындагы газап вә изтыйрабны[2] күрә алырлык кабилият бирергә дә шул олуг йөрәкле ананың күзләренә тик бер генә мәртәбә каратырга иде! Андагы җәһәннәмне күреп, ул, бәлки, бераз инсафка да килер иде!»

13

Зөләйха абыстай, ятагына кереп бераз торгач, бик әһәмиятсез һәм бөтенләй чит булган нәрсәләр хакында Зыяга берничә сөаль бирде дә, җавапка каршы бик зур мәгънә тапкан адәм сыман:

– Ә... алай икән, – диде.

Шуның белән тынды.

Зыя, яңадан акрын гына торып, ай шәүләсендә хат яза башлаганда, аның лампасы сүнгән, ул яктан һичбер тавыш-тын килми иде.

Ята-ята, егетнең башына Фәхри белән Фатыйма бикәгә каршы тору тугрысында бик мөһим төсле тоелган әллә ничаклы нәрсәләр – планнар, табигый җаваплар, чаралар килгән иде, аның бу мәктүбе дә шул хакта иде.

Язып тәмам итте дә, мөмкин кадәр белдермәскә тырышып, аны теге карт имәнгә кыстырып керде.

Бу вакыт Мәрьямнең бүлмәсендә дә ут күренми иде.

«Димәк, яттылар!»

Ул, яңадан урынына ятып, йокыга китеп беттем генә дигәндә, баягы егетләр шаулашып авылның үрге очына таба уздылар. Гыйльман һаман җырлый, музыка туктаусыз уйный иде.

Егетләр ерагайды, җыр ишетелми башлады, музыка да акрынлый-акрынлый барып, гүя ерак сахрага, ниһаясез фәзага китеп, аннан каядыр ашты; шуның эзе, уңае белән агып, Зыя да үзеннән югалды, онытылды...

14

Таң яктысы белән бергә Зыялар өендә янә хәрәкәт башланды. Иң әүвәл

---

[1] *Мәгъзур* – гафу итәрлек, кичерерлек.

[2] *Изтыйраб* – борчылу, кайгыру

кузгалучы – Зөләйха абыстай иде. Ул урыныннан торды да, туры аш өенә чыгып, хезмәтче хатынны уятты һәм аңа ниләрдер пешерергә, хәзерләргә кушып, үзе озатачак угылының әйберләрен барлый, юл ярагын карый башлады.

Зыя, яткан җиреннән баш калкытып, дивардагы сәгатьне карады да, вакыт бик аз калганын күреп, тиз генә торды һәм, ашыга-ашыга киенеп, юынып, кичә бетерә алмаган эшенә – үзе белән алачак әйберләрне сумкасына иплəп тутырырга тотынды.

Ана белән угыл гүя бер-берләрен онытканнар иде: нә бусы, нә тегесе ләм-мим дип авыз да ачмады, бер-беренә һичбер турыда мөрәҗәгать тә итешмәделәр.

Кеше кайбер вакыт йөргән хәлдә төш күрә яисә, йокыда улдыгы хәлдә, тора, йөри, әллә ниләр кыйла...

Зөләйха абыстай да бүген шуңа охшаш бер халәттә иде. Аңарда нәшат[1] калмаган, аның җаны кайгыдан талган, йөрәге озак һәм туктаусыз янудан арыган булырга тиеш ки, ул бүген һәммә нәрсәне еракта кебек, төтен эчендә сыман күрә, үтә авыр хәсрәт яки ерак бер сәфәр бар кебек тә тоймый, – Хода белсен, нинди вакыт, нинди хәл дә, нинди хәрәкәт!

Җәләл тыштан тын вә тыныч, хәтта уяулы-йокылы бер халәттә кебек күренсә дә, аның эчендә үзенә дә ачык билгеләнеп бетмәгән бер куәт кайный, нидер сыеша алмый, бәреп чыгарга итә шикелле иде.

Ул хатынына теге яхшы букча белән яхшы казаки, яна җилән, постау чалбар кебек берничә кием куярга әйтте дә Зыяга кичәге сүзен тәкрар итте:

– Зыя, син анаңа карама, ул хафалы кеше, юл ярагыңны, алачак әйберләреңне үзең барла, үзең тутыр! – Үзе тышка чыкмый гына тәһарәт алды да урта ишеккә эленгән зур ак сөлге белән битен сөртә башлады:

– Иннә әнзалнa фи ләйләтел кадер ... Ләйләтел кадри хәеруммин әлфи шәһр...[2]

– Син, син! Кара әле, намаз вакыты кергәнме икән?

Абыстай машина кебек җавап бирде:

– Кергәндер инде, кергәндер...

– Зыя, тәһарәтең бармы?

– Бар, алдым!

– Булса, азан әйт! Намаз укып алыйк, соңга калабыз, юкса!

Абыстай чигеп эшләнгән зур чобар намазлыкны алып бирде. Зыя шуны кыйблага каратып җәйде дә азан әйтте, соңра, атасының уң ягыннан торып,

---

[1] *Нәшат* – шат кыяфәт.

[2] *Иннә әнзалнa фи ләйләтел кадер ... Ләйләтел кадри хәеруммин әлфи шәһр* – Без аны (Коръәнне) Кадер кичендә иңдердек... Кадер киче – мең айдан да хәерлерәк. (Коръәннән “Кадер” (97) сүрәсе, 1 нче һәм 3 нче аятләр).

намаз ниятләде.

Абыстай, пич буена сөялгән хәлдә, боларга карап каткан иде. Беренче колак кагудан алып, актык сәламгәчә шул торыштан кузгалмады.

Балалар йоклыйлар иде. Җәләл анларны уятмаска кушты.

Ул арада теге яктан нечкә генә тавыш белән:

– Абыстай, самавыр кайнады! – дип эндәштеләр. Идәнгә җәелгән келәмнәр өстенә чәй хәзерләнде, әсбаб килде, ашамлыклар куелды. Мулла, теге якта йөргән хатынга йорттагы ялчыны чакырырга кушып, үзе табынның иң түренә «бисмилла...» дип утырды да хәзер генә табадан төшкән коймакны капкалый башлады. Зыя, аның артыннан Зөләйха абыстай утырып, ул чәй ясарга тотынды.

Чәй авыр вә акрын эчелде. Мәҗлестә әллә нинди авыр сөкүт[1] хөкем сөрә иде. Гүя телләр багланган, сүзләр онытылган, зиһеннәр әллә нинди ят галәмгә китеп югалганнар иде.

Хәзрәтнең дә башка вакытларда өзлексез эшли торган сүз тегермәне бүген туктаган – бармый да, тартмый да иде.

Тик тыштан үзенә әллә ничаклы суыклар, карлар ияртkән ялчының килеп керүе генә мәҗлесне бу авыр сөкүттән коткара алды.

– Мулла бабай, мине чакырдыңмы син?

– Сине чакырдым! – диде дә, санап чыгарылган кебек өзек, исәпле сүзләр вә кискен тавыш илә ялчыга әмерләр бирә башлады: – Зур чана чыгарылганмы? Безгә җигеләсе атлар кыргычланганмы? Озын чыбыркының элмәге юнәтелгәнме?..

Егет һәммә сөальгә сүз һәм ишарә белән «бар да эшләнгән...» дип җавап бирә барды. Җәләл дәвам итте;

– Бар, яңадан кыргычла, ял, койрыкларын иплә дә шул зур кара белән кашка җирәнне зур чанага җик! Мин кичә буяттырып алган идем, шул ике камытны кидер, теге ике кыңгыраулы зур дуга keләттәдер, шуның белән җигәрсең! Аңладыңмы?

Егет «аңладым» дип башын селекте дә чыга башлады. Мулла тагы туктатты:

– Бар, хәзер үк Зарифны чакырып кил! Мин аңа безгә кучер булып барырсың дигән идем, хәзер килсен, тиз булсын дип әйтте, диң!

Ялчы, «ярар, ярар» дип, тагын чыга башлаган иде, Җәләлнең дәвам иткәнен күргәч, кире борылды.

– ...Без киткәч, абыстаңа утынын, суын керт, малларыңа ашарга сал, сукмакларны көрә дә ике белән Югары тугайга печәнгә барып кил!.. Йортны

---

[1] *Сөкүт* – тынлык, эндәшмәү

ташлама; имчәк баласы түгелсең, атлаган саен өеңә кайтып йөрмә! Мин Садыйк картка да күз-колак булырга әйттем; төндә үлек кебек ятма; ул-бу булмасын; бер-ике мәртәбә чыгып әйлән: бу арада авылга бүре бик килә, кичә түбән очта Вәлиулла картның ун сарыгы белән ике кәҗәсен яралап чыккан. Ходай кушмаган эш булмас, шунда да аң булырга кирәк. Төнлек өчен этне дә бәйләвеннән ычкындырсаң ярый! Ишеттеңме?
– Ишеттем, хәзрәт, ишеттем!
Егет чыгарга дип ачкан ишектән озын буйлы, үткен кыяфәтле, тун, чикмән кигән ир уртасы бер адәм килеп керде.
– Әссәламегаләйкем! Соңга калдым дип котым очты... Кая, мулла абзый, безгә җигә башларга да вакыттыр инде? Яктырып килә... Камытлар кайда?..
– Өлгерербез; берәр чынаяк чәй эчеп ал! Малай анда чыгара торыр.
Зариф, келәмне түргә таба кайтарып, чабаталы аякларын ишеккә таба сузып, уңайсыз гына, кырын гына бер рәвештә утырды да,коймак белән кыздырманы җимерә башлады. Яшьтән боларда малай булып та, болай да күп йөргәнгә, абыстай аңардан качмый иде. Алды-артлы ике чынаяк чәй ясап бирде; кучер исә, авыз пешүнең ни икәнен белмәгән адәм сыман, кызу-кызу эчте дә: «Булдым... Аллаһы әкбәр», – дип чыгып китте.
Болар ничектер абыстайны бик аз гына җиңеләйттеләр. Ул, телгә килеп, иренә сөаль бирде:
– Әй, син кая чаклы озатасың? Калага гынамы?
– Әйе!
Аннан соң угылына таба әйләнде:
– Балам, Зыя, иренмә берүк, юлдан да, баргач та күп итеп хатлар яз... Ни хәлдә генә йөри икән дип, мин монда ут җотып торам бит...
– Ярар, әни, ярар, язармын. Син, әни, юкка борчылма: адәм башы югала торган җир түгел бит ул...
Зыя сүзен бетерә алмады, абыстай тавышына буылып елады да җибәрде:
– Алла үзе сакласын инде, балам... Әллә нигә күңелем бик авыр күрә шул!.. Язмыштыр инде, язмыштыр, мин күрәсене кем күрсен!
Җәләл тәрәзәгә карады да кинәт, сискәнеп киткән адәм сыман:
– А... яктырып беткән икән... Соңга калмасак ярар иде! Тизрәк булырга кирәк, – дип, урыныннан сикереп торды.
Аның артыннан ана белән угыл да, чынаякларын каплап, аякка бастылар. Йортта халык йөргәне күренә, әллә нинди тавышлар чыга, кыңгырау да, «хәзер китәбез» дигән кебек, чаңылдап куя иде.
Җәләл белән Зыя ашыгып-ашыгып киенә башладылар. Берничә карт кереп:

«Җә, мәхдүм, исән-сау йөреп кайт инде, шатлык белән күрешергә насыйб булсын !.. дип, Зыя белән күрешеп чыктылар. Өйнең теге ягында хатыннар җыелган иде. Берничә карчык, Зыя янына килеп, елау, кызгану илә тулган тавышлары белән хәер-дога кыйлдылар, исән-сау йөреп кайтуын теләделәр. Егет анларга сәдака биреп, рәхмәт укыды, фатихаларын эстәде дә:

– Менә күрерсез, Алла боерса, тоелмый да калыр, гомер үтәр, мин кайтып килермен, – диде.

Карчыклар, күзләрендәге яшьне җиңнәре белән сөртә-сөртә:

– Сез шулай дисез дә бит, монда калганнарга авыр шул, балам, әллә ниләр булыр кебек тоела! – диештеләр.

Абыстай һаман өнме-төшме икәнен аера алмаган сыман йөри, үзе йомшарганнан-йомшара бара иде. Кемдер ишекне ачты да, үзе өйгә керми генә:

– Атлар җигелде! – дип кычкырды.

Буны ишетү белән, хатын-кыз арасында кузгалу, әле анда, әле монда йөгерү башланды; кемнәрдер пыш-пыш елыйлар да иде. Зөләйха абыстай исә, йөрәге шу итеп китеп, нидер жимерелеп, менә хәзер һәлакәт килә дигән минуттагы сыман бер халәттә калды... Үзе йомшарганнан-йомшара бара иде.

Хәзрәт авыр, басынкы булып, йөзендә ачу катыш тәэсир балкый иде. Чите камалы тирән бүрекне башына кырын салып, өстенә биек якалы зур кара толып киеп, күк төсле болан перчатканы сул кулына алды да:

– Җә, булдыңызмы? – диде.

Теге якта тагы кузгалыш, аптыраш, тагы пыш-пыш елау башланды; Зыя да, каракүл бүреге белән зур якалы кара толыбын киеп:

– Булдык! – диде.

Хәзрәт сәфәр догасына хәзерләнде; Зөләйха абыстай биргән кечкенә мендәрне идәнгә салды да, үзе авыр вә мөтәэссир[1] хәлдә кыйблага таба юнәлеп, шул мендәргә тезләнде. Зыя да кечек бер нәрсә салып, идәнгә кыйблага йөз белән тезләнде, һәммә кеше «әттәхият»кә утырган сыман бер хәлдә калды, һичкем һичбер төрле тавыш чыгармый, һәммәнең йөзе мөтәэссир, күпләрнең күзендә яшь ялтырый; һәммәсе китәчәк мөсафыйр хакында олуг Тәңредән теләк телиләр, күңелдән дога кыйлалар иде.

Шул хәлдә ике минут чамасы калдылар. Соңра мулла, ишетелер-ишетелмәс итеп, бер аятьме, догамы укып китте дә амингә кул күтәрде. Башкаларның һәммәсе аңа иярделәр.

Дога тәмам булып, аякка калыкканда, өй эче халык, бигрәк тә хатыннар белән тулган иде. Кемнәрдер ишек төбенә рәтләп тезелгән багажларны – мендәр,

---

[1] *Мөтәэссир* – кайгыдан иза чигүче, тирән тәэсирләнгән

сумка кебек юл әйберләрен алып чыкты. Аның артыннан Җәләл дә:

– Нәрсә кала күрмәсен! – дип, тышка таба атлады.

Зыя, күлмәк җиңнәре белән күз яшьләрен туктаусыз сөртмәктә һәм кызгану катыш елау илә нидер теләмәктә булган карчыкларга сәдака биреп, догаларын үтенде дә өйдәгеләрнең һәммәсе белән күрешә башлады.

Бу вакыт ана ни булганын, кая таба атлаганын аера алырлык мәртәбәдән үткән иде.

Дөнья кузгаламы, һәммә нәрсәләр урыннарыннан күчәме? Әллә өн, әллә төш? – бер Хода үзе белсен!

Гүя аның аяк баскан җире каядыр түбәнгә, астка таба китә дә, шунда әллә ни була... Гүя күк вә кояш үзләренең табигый халәтләрендә калалар да, тик җир шары, әллә нинди томан эчендә улдыгы хәлдә, бер үзе, чыгырыннан чыккан сыман, әллә нинди белемсез вә караңгы һавиягә[1] таба авыша бара, авыша бара, авыша бара...

Фатыйма бикә белән Зыя аның ике як култыгыннан алдылар да сакин[2] вә басынкы бер хәлдә чыгу ягына юнәлделәр.

15

Таң белән бергә Мәрьям дә баш күтәргән иде. Бу вакыт әле башкалар йоклый, бикә исә күптән ахирәтенә киткән. Туташ, әллә кая китәсе адәм кебек, тышкы киемнәренәчә киенде дә башындагы чуалчык планнары белән газап чигә башлады: йөз төрле сылтау, мең төрле план бар. Ләкин кайсын гына гамәлгә куярга уйласаң да, нидер тыя, нидер аның имкянсызлыгын[3] күрсәтә, куәтен ала...

«Ходаем, бу чынмыни?.. Шулай ук «ул» китәмени?»

Әнә, юлчылар чана чыгара... Әнә, теге ике матур атны яхшы камытлар белән шул чаналарга җигә дә башлыйлар... Әнә, җигеп бетеп, ишек турысына да китерделәр... Әнә, әллә нинди баһадир сыман Җәләл хәзрәт килеп чыкты. Ахрысы, ялчыларның эшен яратмыйдыр, дуганы сугып, камыт бауларын тартып карый да:

– Үзең карап җиткермәсәң, булмый шул! Гомергә ат җигә белмиләр, – дип сукрана...

Чананың кучерлегенә чикмән салдылар, эченә әллә нинди кисәк-кисәк әйберләр тутыралар, артына хәтфә келәм салындырып, эчкә тутырылган әйберләрнең өстенә ак тышлы ике мендәр куйдылар... Хәзрәт, боларның да нәрсәсендер

[1] *Һавия* – упкын.

[2] *Сакин* – сөйләшмичә, бер-беренә эндәшмичә.

[3] *Имкянсызлыгын* – булдыра алмавын

яратмыйча, яңадан туздырып, үзе теләгәнчә төзәттерде.

«Ходаем, бу ни эш?.. Өнме-төшме? Шулай ук «ул» китәмени соң?»

Китә, күрәсең, китә... Әнә: «Мәхдүмне озатып калыйк», – дип, капкадан халык агыла. Әнә, Җәләл мулланың йорт эче кешеләр белән тула... Арада канфит[1] алырга килгән балалар да, зуррак егетләр дә бар. Ир уртасы адәмнәр дә күп. Картлар да бар... Берничәсе чалма белән үк: күрәсең, иртә намазына барышлый кергәннәрдер... Менә, Ходаем, кояш чыкмаган, көн тумаган, ниндидер караңгылы-яктылы бер вакыт, ә монда атлар җигелгән, мәхдүмне озатучы халык белән Җәләлнең йорты тулган... Бу нихәл бу, Илаһым!.. Өнме, төшме?.. Әнә, атлар чыдаша алмый, баскан җирләрендә түзә алмый торалар, гүя йөрәкләре ашкына, гүя әллә кемне тизрәк алып китәргә ашыгалар... Әнә, кыңгырау да: «Тиз булыңыз, китәбез...» – дигән сыман, тавыш бирә тора... Бу ни эш бу, Илаһым?!

Әнә ишек киң итеп ачылды... Бу кем?.. «Ул» бугай! «Ул» бугай! Зиһен шөбһәле күрә, ләкин йөрәк сизә: бу – «ул». Әнә «ул» анасының кулын үбеп күреште Дә чанага таба килә башлады. Атлар: «Тизрәк!» – дигән сыман, бер мәртәбә ашкынып, кыңгырау: «Китәбез!» – дигән шикелле, бер мәртәбә тавыш биреп куйды... Әнә, әллә кемнәр, әллә нинди картлар, ят кешеләр аның тирәсен сырып алдылар да:

– Сау бул, мәхдүм! Исән-сау йөреп кайтырга язсын! – дип, кул алышалар...

Ходаем, син кайда, мәрхәмәтең кай җирдә? Мине шул курешүчеләрнең бере кыйлсаң ни була, Илаһым!.. Атлар түзә алмый тора, чана вә капка тирәсендә ирләр, өй вә ишек буенда хатыннар, тулышып, нидәндер буталыша, селкенә башладылар... Әнә, теге баһадир чанага утырды; әнә, Зариф та кучерлеккә сикереп менде... Йа Ходай, хатыннар арасыннан кемдер елап җибәрде... Анасы бугай... йа Ходай, бу нихәл, өнме, төшме?.. Атлар кузгалды, чана түрендә ике адәм утырган,- берсе – «ул». Кемдер «аның» белән тагы исәнләште; халык шаулый, кыңгырау: «Без киттек!» – ди; халык диңгезе капкага, аннан урамга таба агыла... Әнә, Зариф, дилбегәне ипләп: «На-а!» – гына дигән иде, атлар очтылар. Кемдер авыр, мөтәәссир, ләкин үтемле тавыш белән кычкырып азан әйтә башлый. Тавышы нинди һәйбәт: «Аллаһы әкбәр, Аллаһы әкбәр... әлех». Әнә кемнәрдер, бүрекләрен кулларына алып, мөсафыйрларга селтиләр, гүя: «Сау булыңыз!..» – диләр. Әнә, яшен кебек атылган атлар тиз арада чатка җитте. Әнә, борылдылар да. Аһ, Илаһым, хуҗам, «ул» кемгәдер, – әлбәттә, моңа булыр, – актык мәртәбә борылып карап, баш селкергә өлгерә алмады, чана икенче урамга кереп, күздән югалды... Ходаем, кәрим, бу нихәл соң, өнме,

---

[1] *Канфит* - конфета

төшме?..

VI

1

«...Белмим, белмим, валлаһи, бернәрсә дә белмим: ничек ул эшләр булды да, ничек итеп мин бу хәлгә – түбәнгә төшә алдым?.. Мин ни белән дә булса сихерләндемме? Әллә ул көннәрдә башымны югалтып, гакылымнан язып йөрдемме?..

Менә хәзер уйлыйм да исем китә: беләсең бит, Фәхри дигәннең тик исемен ишетсәм, йөзем чытыла, тәнем чымырдый, кашларым җыерыла башлый иде. Хатын булып аста яту түгел, хәтта аның ерактан күренеше белән дә минем эчемә салкын йөгерә торган иде.

Ходаем, дөньяда бу чаклы да уйланмаган, көтелмәгән эшләр булып куяр икән! Бунда әллә нинди, адәм белми торган, серен, хикмәтен аңлау мөмкин булмаган ноктalar бардыр. Юкса, мин, мин, үз ирегем, үз саулыгым вә башымның үз куәте бар чагында бундый хәлгә төшмәс идем... Ходай белә, бу бәхетсезлектә иблиснең үз бармагы, газазилнең соңгы мәһарәтләре[1] эш иткән, шулар мине китереп каптырган булыр... Юкса, юкса, аналар сүзе, әллә кемнәр вәгазе, фәләннәр хәйләсе түгел, Аллаһның үз әмере дә минем йөрәгемне тыңлата алмас иде...

Әйт, зинһар, әллә болар бар да төш кенәме, әллә Фәхри дә юк, мин аңа кияүгә дә бармаганмын, – болар бар да йокы хыяляте яисә авыр саташулар гынамы? Белмим, валлаһи, бернәрсә дә белмим!

Син киттең – менә шуның белән бергә минем аңым үзгәрдеме, башыма икенче ми, күкрәгемә башка йөрәк куйдылармы, әллә хәтерем югалдымы? Ни дә булеа булды, мин дөньяны икенче төрле күрә башладым. Гүя тирә-ягымдагыларда, үземдә һәммә нәрсәне үзгәртеп җибәргән, әүвәлгеләр белән булган барлык мөнәсәбәтләрне өзгән, бик озак йокыдан, ниһаясез озын төннән яңа уйганган кебек бер халәт хис иттем. Гүя дөньяда матур да калмады, ямьсез дә бетте; усал да юк, яхшы да юк, дустлар да юк, дошман да юк, ярату-яратмау үзе дә юк; гүя тойгы вә мөнәсәбәт бетте дә, шуның илә бергә һәммә нәрсә бер төслегә әйләнде.

Әни кем? Мин аны яратаммы, юкмы? Аның сүзләренә ни мәртәбәдә куәт бирергә кирәк?

Фәхри нинди адәм? Ул мине кочаклап, куенына алса, ни булыр?

Менә бу сөальләр минем башыма да килмәде, килсә дә, «белмим, бар да бер!»дән башка җавап булмас иде. Һәм чынлап та бар да бер иде. Мин, чынлап

[1] *Мәһарәт* – осталык.

ук та, әүвәлге мөнәсәбәтләрнең барын онытып, йөрәгемнең әүвәлге тойгылары ниндидер бер явыз кул белән юк ителгән иде.

Ә син бу вакыт әллә кайда идең! Шөбһәсез, мин башка нәрсәләрем белән сине дә, сиңа булган мөнәсәбәтне дә югалткан идем. Хәзер дә ачык хәтерли алмыйм: әллә өнемдә, әллә төшемдә мин сине күргәли торган идем. Ләкин бер дә әүвәлге кебек түгел идең, кыяфәтең дә, мөгамәләң дә башка иде: җә кайгылы күзләрең белән ерак бер җирдән миңа озак карап тора идең дә, шелтәнеме, өмитсезлекнеме аңлаткан рәвеш белән кул селкеп китә идең; җә булмаса, караңгы төндә, ерак тау башында торган сыман булып, әллә кайда, күз аермас, тавыш ишетмәс җирдә караңгы пәрдә аша караган кебек кенә күренә идең дә, акрын гына артка чигенеп, Ходай белсен, ниндидер киң, ерак булган мөбһәм[1] хыял дөньясына кереп югала идең.

Ачык белмим, бу хәл күпме дәвам иткәндер. Синең әүвәлге ике мәктүбең килгәндә, мин әле шул уяулы-йокылы халәттә, шул саташуда идем. Хатларыңны укыдым бугай. Ләкин элекке заманнардагы кебек күз яше катыш шатлык бер дә булмады. Мин аны җүнләп аңламадым да бугай... Гомумән, миңа дөнья әллә бар иде, әллә юк иде. Әллә тагы бөтен нәрсә юкка чыгып, анларны тик төштә генә күрә, яки әүвәлдә күргән эшләр хыял күгемдә, хәтеремдә генә урала иде...

Бу афәтләрне тудырган иблис мәлгуньнең каһәрле бармагы талды, явыз кулның сихри куәте төгәнде булырга тиеш ки, бер таңда миңа гаҗәб бер могҗиза булды: белмим, шунча көннәр дәвам иткән исереклектән айныдым, белмим, төн йокысыннан уяндым, – ни дә булса булды, мин таң сызылып килгән вакытта үземне уянган кебек тойдым. Карыйм, үзебезнең кунак бүлмәсе: артык зиннәтләнгән; иң соңгы мода белән җыештырылып, аңкып торырлык мәртәбәдә хуш ис илә бөркетелгән; артык зур тантаналы көннәрдә генә кузгатыла торган зур лампа бик аз гына басылган; бүлмәдә якты катыш караңгы – хыялый бер төс. Гомеремдә беренче мәртәбә күргән сыман, боларның һәммәсенә ярым тәгаҗҗеб вә ярым хәйрәт белән күз йөртеп чыгып, уемны үземә таба китерсәм, шаша калдым, исем дә китте, гакылым да бетте – ни күзем белән күрим: минем караватымда минем белән бер түшәктә арыслан мыеклы, зур гәүдәле бер адәм ята! Ул үзенең итле вә калын беләкләре белән мине күкрәгенә кыскан да гәүдәсен гәүдәмә тәмам, тәмам урап алган. Бер минутта гакылдан шашып, урынымнан сикереп тора яздым.

Уйгандым, уйгандым, инде чыннан уйгандым! Ходаем, ни күрим, ничек итеп бу каһәреңә түзим? Бу – кем? Бу – кем? Аһ, башым әйләнә, күңелем болгана,

---

[1] *Мөбһәм* – шикле, билгесез.

йөрәгем ярылырга бара, ни диим, ничек аңлыйм, бу – ул иде!! Бу, – аһ, явыз, Фәхри иде!!

Белмим, яшен сукты, белмим, тагы артыграк уйганып, мин кичәгеләрне, үткәннәрне уйлый башладым... Чынлап та, нидер булды бугай... Гүя туй диделәр, гүя миннән ризалык та сорадылар... Гүя кешеләр белән бергә мин дә көлдем, шатландым, хәтта Фәхри белән күрешүемне, аңа кул биреп, сөйләшүемне, аның белән икәү калуымызны да бераз хәтерлим. Ләкин ачык белә алмыйм: ул өнемдә булдымы, әллә төш идеме?

Ни булса булгандыр, – анлар, бәлки, төштер дә. Ләкин хәзергесе хәкыйкать иде: сызылып таң атканда, караңгы катыш яктылы, хыялый төсле бүлмәдә, мамык мендәрләр өстендә мин Фәхринең куенында идем!

Шул вакыт, шул халәт мине уйгатты; ләкин... ләкин, газизем, кашки мин уйганмасам, кашки мин синең китүең яшене белән сугылудан килгән шул аңсызлыкта, шул исереклектә гомергә калган булсам, үз хәятымның шундый авыр трагедиясен хис итми кичергән булыр идем! Ләкин, ләкин яшен үткән, тәэсире беткән иде, мин дә шул каһәрнең куенында идем!

Акрын гына тордым да ул бүлмәдән чыктым.

Кая барыйм?

Күңелем үземнең бүлмәмә, кызлык гомеремне үткәргән, сине сагынып, синең өчен күз яшь түгеп, газап эчендә сәгадәт тапкан, һәрбер ноктасыннан сиңа булган гыйшыкымның төсе күренеп торган мөкаддәс хәрәмемә килдем. Дөнья тын, өй караңгы, һәммә кешеләр, туй шатлыгыннан арып, рәхәт вә тыныч йокыдалар иде.

Бүлмәмдә һичкем юк иде. Барып керү белән, аптырый калдым: гүя мин ничә айлар монда булганым юк иде; гүя хәзер генә кердем; гүя ул мине ни өчендер тәгъзия итте[1]; гүя андагы һәммә нәрсәләр миңа кызганып карадылар...

Мин гүя бу тәгъзияне, бу кызгануны аңладым да, язмышның биргән авыр трагедиясенә тәкать тота алмыйча, уйларга, теләргә өлгермәстән, ни эшләгәнемне белмичә үк, түрдәге караватыма атылып, шундагы мендәргә йөзтүбән егылдым...

Эчемнән нидер ташыды, җаныма нидер артык авыр сукты, мин дә сабырымны, тәкатемне җуеп, күземнән яшь дәрьясы китте. Озак, бик озак агладым.

Ләкин башка вакыттагы кебек бу күз яше үзе белән бергә минем йөрәгемдәге кайгыны чыгарып түкмәде, җаныма җиңеллек, күңелемә җуаныч бирмәде, – бу яшь, бу яшь дәрьясы авыр иде, салкын иде; моның һәрбер тамчысы үзе белән бергә җанның әллә нинди назик вә яшерен җирләрен өзеп, йөрәкне агулап ала

---

[1] *Тәгъзия итте* – тынычландырды, юатты

иде...

Аһ, газиз, белсәң, ул минутлар нинди авыр иде!

Син ирсең; шуңа күрә минем ул минутта ниләр хис кыйлганымны һичбер төрле аңлап җитә алмаячаксың. Мин ул трагедиядән элек үзем дә аны уйлаганым юк иде.

Мин айныдым, ләкин инде син белгән, син сөйгән назлы туташ, назлы Мәрьям түгел идем. Мин йөрәгемнең хаине идем. Мин хәзер, – аһ, әйтергә авыр, – хатын идем. Мин хәятымнан, дөньялык сәгадәтемнән мең вә йөз мең мәртәбә кадерле күргән асылымнан аерылган идем. Борын уйласам да, хәзер артык ачык тоям ки, безнең өчен, үзеңнең дөнья бәһасыннан югары тотып килгән җәүһәреңне жаның сөйгән, йөрәгең аңа гыйшык белән тулган бер адәмгә бүләк итү – бу бөтен кяинатка[1] хуҗалыктан кыйммәтле һәм ахирәт вә җәннәт мәртәбәләреннән гали булган бер сәгадәт, бер бәхет икән... Моны башкалар белә алмый, моны минем язмышым белән уртак булган йөрәкләр генә, алар да, минем кебек, шул кыйммәтле, шул бәһасыз кодсиятне бер кабихтән, бер каһәрдән таптатканның соңында гына тоялар...

Мин шул газапта янган минутта кайдандыр колагыма бер тавыш ишетелде:

– Кем бу?.. Кем бар монда?.. Мәрьям, синме?.. Бу ни эш, бу ни эш?!

Күтәрелеп карасам, каршымда әни тора.

Ул кунаклык киемдә, мәһабәт кыяфәттә булып, йөзендә ниһаясе булмаган хәйрәт вә тәгаҗҗеб балкый иде.

Ахрысы, ни дияргә белмәде, аптыравыннан катты да калды.

Мин дә үземә хуҗалыгымны югалттым. Әллә нәрсә кыйласым килдеме, әллә, юкса, һичбер төрле үлчәүгә сыя алмаслык бер сүз әйтеп, үземнең хәзерге хәлемне тәгъбир итәсем килдеме, – ни дә булса гадәттән югары бер арзу[2], бер ташкынлы теләгем бар иде. Ләкин әнинең хәйрәт вә мәгъюблек[3] илә тулган күз карашы минем куәтемне бетерде булса кирәк, – һичбер сүзгә телем бармады, үземнән мең вә йөз мең мәртәбә өстен булган бер ят тәэсир илә, үземне үзем белмичә үк, урынымнан сикереп тордым да идәнгә – әнинең каршысына тезләнеп, колларча олуг нияз[4] белән аның кулларына сарылдым...

Шул хәлдә бик аз гына вакыт үтте.

Бер минуттан гыйбарәт аз бер заман безгә бик күп нәрсә сөйләде, сүзсез-нисез әни мине аңлады. Ахры, артык сөкүт итәргә[5] тәкате калмагандыр, миңа аның

---

[1] *Кяинат* – дөнья, галәм.

[2] *Арзу* – теләк, омтылыш

[3] *Мәгъюб* – гаепле.

[4] *Нияз* – ялыну, ялвару.

[5] *Сөкүт итәргә* – дәшми калырга

бөтенләй ят һәм бөтенләй икенче төрле тоелган тавышы ишетелде:
– Чү, бәгырем! Чү, кызым, гакыллым! Миннән түгел, мин бит көчләмәдем, үзең риза булдың, миңа барыбер дидең, балам! Мин ни эшлим? Мин бит синең бәхетеңне телим!
Артык ни дияргә мөмкин? һәм хаҗәте дә бар идеме?
Телләр багланды. Ул, шелтәгә дә, вәгазь вә игътизарга[1] да үзендә куәт тапмыйча, мине кулбашларымнан тартып торгызды да, караватка китереп, янына утыртты.
Белмим, терек идек, белмим, шул авыр сөкүтнең сөйләгән эчке фаҗигасе безнең һәр икебезне җанлы үлек хәленә китергән иде. Шуннан соң ни булганын яза алмыйм, без икебез дә, бигрәк тә әни, яшен суккан адәмгә охшаш бер хәлдә катып калдык: нә елау мөмкин иде, нә башкача бер җан, бер жуаныч табарга юл бар иде!

2

Мәрьям яңлышмый һәм арттырмый да.
Вакыйгда да ул минутның бикәгә тәэсире яшен сукканнан да ничә өлеш артык булды. Ул, кызы хакында корып килгән планыннан тууы мөмкин булган тәмсез-лекләр хакында мең төрле ихтималят йөртсә дә, һичбер хәлдә буны зиһененә дә китерә алмаган иде:
– Имеш, кызың зөфаф кичәсендә, киявен ташлап, караңгы бер бүлмәдә ялгызы елап утырсын!
Бикә өчен бу фаҗига – артык ят, артык күңелсез һәм, булыр дип уйларга түгел, төштә дә күрмәслек бер мәгънәсезлек иде.
Һәрбер ана шикелле, ул да кызын аңлыйм, аның эчендәгесен үтә күрәм дип уйлый вә шуның буенча эш кыйлырга тырыша иде.
Ул кала кызы; мирза нәселеннән; аның тамырларында шул икедән килгән кан кайный; һәм шуның тәэсире белән ул гомер барынча үзенең бердәнбер баласын, кызын, «кара халык пычрагы»на батырмаска тырышты. Утыз ел буена димләп тә, ирен калага күчәргә күндерә алмагач, ичмаса балам бу җәһәннәмнән котылсын дип, Мәрьямне гимназиягә бирергә иҗтиһад кыйлган иде. Язмыш бу теләгенә каршы баргач, ул, чыннан да, Мәрьям хакында, бу да, күрәсең, авылга батып кала инде дип курка башлаган иде.
Ул табигате белән һәр эшне үзе теләгәнчә генә булдырырга теләсә дә, шуңа күрә кызының бәхетле булуы өчен тик үзе тарафыннан күргәзелгән юллардан гына бару тиеш дип белсә дә, гамәлдә аны бөтенләй үк кертеп бетә алмый, никадәрле яратмаса да, җәбер вә көчлек белән Мәрьямне үзе теләгән

[1] *Игътизар* – каршы килү, риза булмау.

рамкаларга салырга батырлык итми иде. Бу эш гүя аны «кара халык» мәртәбәсенә төшерәчәк иде.

Ул Зыя белән Мәрьямнең мөнәсәбәтен бик яшьтән үк сизде, кызына белдерергә килештермәсә дә, үз эченнән бу мөнәсәбәткә бик зур бәхетсезлек дип карый иде. Буны уйлый башласа, ул Мәрьямне үз ирегә, үз теләге белән әллә нинди төпсез һәм караңгы чокырга, мәҗбүри булган бер һәлакәткә таба акрын гына төшеп барган кебек тоя иде, һәм шул хәлгә тик Гәрәйнең каршылыгы сәбәп дип ышана иде:

«Хәрап була, бичарам, хәрап була! Бар да шуннан, бар да аны калага укырга җибәрмәүдән! Анда барып, гимназиягә керсә, башка кешеләр күрер, башка адәмнәргә катышыр иде! Дустлыгы да икенче төрле кешеләр белән булыр иде! Ул вакыт мондагыларга әйләнеп тә карамас, менә дөнья үзеннән-үзе мин теләгәнгә барып чыгар иде! Бер ул түгел, без барымыз да, бөтен нәселемез белән шулай: ул безгә, миңа тарткан; безгә теләсә кемне генә булса да сөям дип йөрергә фарыз төсле! Ул да шулай, бичараң... Ни эшлим соң, Ходайның язмышы шулдыр инде...»

Ул шулай карый иде, ләкин, «кара халыктагы кебек», кызының ул мөнәсәбәтенә ачыктан-ачык көрәш игълан итәргә бер дә генә килештерми иде.

Зыяның мәдрәсә ташлаулары, «урыслашуы», әллә нинди киенеп йөрүләре, халык телендә аны гел икенче якка тартып сөйләүләре бикәнең теге зур кайгысына бераз җиңеллек бирәләр иде:

«Кем белә, бәлки, аталары кебек булып калмас, бәлки, безнең кеше булыр, ихтимал, калага да урнашыр...»

Зыяның соңгы еллардагы эшләре аның бу өмитен куәтли төшеп, тик Собраниедән имтихан кыйлынып чыгуы гына аның җанын бик дулкынландырды:

«Илаһым, хуҗам, алма агачыннан ерак китәме соң, бу да шул булыр, ахры!»

Ул башта Зыяның солдаттан калуын теләде, китсә кайгырыр кебек тойды; ләкин аның алынганын ишетү бер минутка авыр хәсрәт кебек күренсә дә, ул, тиз арада башын җыеп, өстеннән әллә нинди бер авырлыкның төшкәнен хис иткәндәй, хәзер генә иркенләп тын алгандай булды, гүя: «Шөкер, котылдым!» – диде.

Ул кызында да шундый хәл булыр дип уйлаган иде.

Вакыйган, ул хакта шөбһә итәргә юл бармы?

Ул бит гакылсыз түгел, ул үзенең кем кызы, кемнең бердәнбер кадерле туташы икәнен белергә тиеш һәм белә дә... Шулай булгач, ул, ничаклы авыр булса да, моннан соң Зыяга хатын булу уен башыннан чыгарыр... Һәм табигый дә...

Имеш, сары чикмәнле мужик егетләре белән китеп, анда бәрәңге ашап, ике тиенлек чуаш ефрейторларының итеген тазартып йөргән бер бичараны, аңа кияүгә барам дип, ничә ел көт! Бу мөмкинме?.. Әлбәттә, юк; Мәрьям ул дәрәҗәдә йомшак та түгел, уйсыз да түгел...

Ана шулай дип ышана һәм инде моннан соң Зыя дигән нәрсә онытылып, аның урынына Фәхри утырырга тиеш таба иде. Кызы да шул эшне табигый күрер дип белә иде.

Зыяның алыну хәбәрен ишеткәндә Мәрьямнең ул дәрәҗәдә мөтәәссир булуы бикәнең уйлаганына каршы кебек күренсә дә ул моңа җиңелмәде.

«Яшь күңел бит, тиз генә оныта алмый... Ләкин аның гакылы җиңәргә тиеш», – дип, Зыяны Фәхригә алмаштыру карарында сабит[1] калды.

3

Һәм ул үзе буны бик табигый күрә, муаффәкыять илә тәмам итәргә мөмкин дә булыр дип уйлый иде:

«Фәхринең ни җире килми? Аның кай төше Зыядан ким? Буйга-сынга Зыядан шәп; төскә чибәр; Кара урман халкының төшенә дә кермәслек мәртәбәдә яхшы, калача, мода белән киенә; зур йөри, үзен эре тота; һәр җирдә аны мактыйлар, югары күрәләр; үзе каланыкы, җитмәсә мирза; тагы кирәк булса, ак кул – үзенең ак хезмәтендә көненә ике-өч сәгать утыра да аннан ары буш; дөрест, үзсүзлерәк, диләр, катырак мөгамәләле дип сөйлиләр, ләкин ни эшләргә? Бәндә бәндә булыр инде! Андый гына хан кызында да була, диләр...»

Фатыйма бикәнең анасы белән Фәхринең анасының анасы бертуган. Фәхринең анасы Гөлсем бикә белән Фатыйма арасында башкача да дустлык зур иде. Шунлыктан Фәхри бик яшьтән үк бу йортка катышты, үзе калада торса да, Гәрәй мирзаларга килеп-китеп йөри иде. Ул тәүфыйксыз түгел, урыны да яхшы, тагы менәчәк, диләр; берничә сыйныфлык рәсми мәктәптә укышы да бар. Ул үзе, урынга кереп, инде аякка бастым дигән көннән алып ук Мәрьямгә уен утыртып куйган һәм, бер көн килеп, аны соратыр да хатынлыкка алыр хыялына бик нык бирелгән иде. Ләкин туташ гомергә аңа якынлаша алмады. Ул бала вакытта ук аңардан кача, аның әллә нинди кибереннән, үзен каты, салкын һәм югары тотарга, баш булырга теләвеннән вә бөтен торышыннан җаны-тәне белән чиркана – аның хакында утның суга мөнәсәбәте кебек бер хәл тоя иде. Ул бала чакта моны турыдан-туры балаларча белдергән кебек, зурая төшкәч, туташларга ягышлы бер мөгамәлә белән: «Зинһар, миңа тамгыңны[2] сузма!» – дигәнне һәрбер адымда аңлата бара иде.

---

[1] *Сабит* – нык, туры.

[2] *Тамгы* – өмет, нәфес.

Бикә боларның барын сизеп йөри вә барысына да: «Илаһым, ни генә кыйлыйм соң!» – дип эченнән уфтана иде. Бер фәләк аңа бер куәт бирсә, ул җә кызының йөрәген алыштырыр да Фәхригә бәйләр иде; җә Мәрьямнең күңелен баглый торган йомшак, сөйкемле табигатен, Зыяның әллә нинди карашларын-фәлән Фәхригә алып бирер иде. Ләкин андый куәт юк. Чарасыз, Ходаның язмышына риза буласың.

Мәсьәләнең ничек барышын Фәхри дә анлый иде. Шуңа күрә дә ул, Зыя алынгач, юк йомышны бар итеп, унсигез көндә ике мәртәбә боларга килеп китте һәм һәр ике сәфәрендә, ачык әйтмәсә дә, Мәрьям хәзер минеке дигәнне аңлатырга тырышты.

Бикә, моны ачык сизеп, эченнән генә: «Бәлки шулай да булыр», – ди иде һәм кызының олуг бәхетенә ирешү юлында кискә булып яткан Зыяның язмыш кулы илә алып ташлануына чыннан куана иде...

Ул инде хәзер кызын калага, ак кул мирзага бирү, шулай итеп, аны бу җәһәннәмнән коткару хыялы белән җенләнә иде. «Анлар урынлашыр, тора башлар, шуннан соң үзем дә күчәрем», – ди иде.

Дөрест, ул Фәхринең табигатен аңлый, аның хакында бервакыт Мәрьямнең әллә нинди бер чиркану белән: «Җенем сөйми, Илаһым, шул хәерсезне! Таш йөрәктер ул, Илаһым! Ни дип искәнгән була!» – дигән сүзенең бик үк хаксыз түгел икәнен һәм ул озын буйлы, мөтәкәббир кыяфәтле ак кул мирзаның, Мәрьям туташтан бигрәк, Гәрәйдән калган зур өйләргә, хисапсыз җир-суларга күзе төшкәнен – аның Мәрьям аркылы шул дәүләтне күргәнлеген вә шуңа омтылганлыгын тоя иде. Ләкин бу тойгы аны Фәхридән биздерми, ул: «Ни эшләмәк кирәк, ул дәүләтне кабергә алып китеп булмый, ул кемгә дә булса барыбер калачак бит!» – дип җуана иде.

Шул уйлар, шул тойгылар белән бикә үзенең карарында дәвам итте:

«Зыяны Фәхригә алыштырырга тиеш!»

Ләкин Мәрьямгә ничек бу эшне аңлатырга кирәк? «Кара халыктагы кебек», кызыңны ачыктан-ачык көчләү бикәгә, Гәрәй мирза хатынына, бер дә генә дә килешми инде. Ничек кенә булса да, бик гади, бик табигый юллар табып, Мәрьям Фәхринең кочагына, һичкем көчләми, үзе барып керерлек булсын иде!

Зыя алынган көннән башлап ана белән кызның эчендә шул мәсьәлә хакында туктаусыз хәрәкәт, дулкын башланды: Мәрьям Фәхринең «искәнеп йөрүен» күптән белсә дә, анасы аның ягын куәтләр дип яңлыш кына да уйлый алмый иде, ләкин теге усал караш аның бу уеның хата икәнен белдерде; ул хәзер бикәнең, тыштан әйтә алмаса да, күңеле белән Фәхригә ауганын ачык күрде: «Димәк, башкача өмит бетте, эш көрәшүгә калды...»

Озын төннәрдә, йокысыз караңгы кичәләрдә Мәрьямнең хыялы бу көрәш өчен мең төрле план хәзерли иде.

...Башта, әлбәттә, каты бәрелергә тиеш тапмый, аны булдыра алуына да ышанмый. Юк, алай ярамый, иң әүвәл яхшылык белән керешергә, аналык йөрәген кузгатырга кирәк... Менә бер аулак кына җиргә чакырыр да анасына үз йөрәген ачып бирер: үзенең Зыяны сөйгәнлеген, аның белән йөрешүләрен, кавышуларын, хатларын, вәгъдәләрен – һичберен калдырмый сөйләп чыгар да дөньяның бар бәхете аның белән генә була икәнен, аңардан аерсалар, дөнья вә хәят җәһәннәмгә әйләнәчәк икәнен аңлатыр... Ана кеше, буны ишеткәч, әлбәттә, теге Фәхригә бирү уеннан кайтыр, чөнки ул «кара халыктагы кебек» көчләүне үзе дә теләми... Әгәр дә кайтмаса, һаман шул уенда дәвам итсә – шунда ни эшләр? Анасы турыдан-туры: «Ул чикмәнле солдатыңны ташла! Мин ана, минем сүземне тыңла!» – дисә, ни кыйлыр? Билгеле, тагы сөйләр, тагы елар, ялыныр, ялварыр; шулар белән дә булмаса, иң каты чарага тотыныр: «Әнкәй, син теләсәң ни эшлә: кулыңнан килсә, мине көчлә, мине сат, ләкин шуны онытма: ул эшләр була калса, мин үземә хуҗалыкны өстемә ала алмыйм... Бер афәт, бер бәхетсезлек чыкса, миңа үпкәләмә!» – дияр...

Ялгыз чакларда, йокысыз озын төннәрдә ул шулай уйлый иде һәм, анасы белән талашу күренешләрен хыялында ясап, ул вакытта үзен ничек каһарманча тотарга икәнен уйлап, әйтәчәк сүзләрен җөмләсе, тәртибе белән хәзерләп бетеп куя иде. Дөрест, кеше янына барса, анасы белән очрашса, аны әллә нәрсә җиңә дә, ул әүвәл уйлаганын онытып, тәртип кыйлган җөмләләре тарала, сүзләре хәтереннән чыга иде; ләкин бу аның өмитен өзми, вакыты җиткәч, батырлык табылыр, куәте җитәр, уйлаганын эшләр һәм әйтер дип ышана вә шул сәгатькә, шул көрәшкә туктаусыз хәзерләнеп килә, туктаусыз шуны уйлый һәм көтә иде.

Кызының җанында башланган бу дулкынны бикә дә сизә иде. Ләкин ул бунардан күп курыкмый, бу хәзергә генә, әүвәлге дустлыкның ялкыны сүнеп беткәнче . генә; менә бераз көннәр үтәр, йөрәк талыр, шуннан соң һәр эш үз юлы белән китәр, тик аны кыздырырга, ачуландырырга гына ярамый дип уйлый иде. Һәм, шул ноктадан карап, кызы белән ул авыр мәсьәлә хакында һичбер сүз кузгатмаска, кузгатырлык юл да бирмәскә лазем тапты.

Ул үзенең кызын хәзерге хәлендә төптән янып, ялкынланып та, дөнья йөзенә бәреп чыга алмый яткан вулканга охшата иде. Гүя аның эчендә ут тулы куәт кайный; ләкин өсте калын катлаулар белән капланган, ул шуны бәреп чыга алмый; тыштан кагылмасалар, ул шул көе дә калыр, ничаклы куәтле булса да, тышка бәреп чыга алмас, шуның өчен дә кагылудан бик сакланырга кирәк...

Уйланмыйчарак ычкындырылган бер сүз аналык куәтен, аналык хөкемен

оныттырырлык иң гади бер мөгамәлә Мәрьямнең эчендәге вулканын тышка бәреп чыгаруы бик ихтимал. Бикә, моны бик ачык сизгәнгә, мөмкин кадәрле иркәлек вә йомшаклык белән җиңәргә, теге утның чыгуына сәбәп бирмәскә тырышты. Икенче яктан, үзенең соң куәтен сарыф итеп, дөньяның астын-өсткә бутау, Зыяны, Фәхрине – барыбер ич кебек ясап күрсәтү юлына хезмәт өчен мең төрле планнар төзеде.

Зыяны авызга алмаска, яңлыш исеме чыкса, аңа бер кара тап ташлап, үзен әллә кая, хыял дөньясына, мәңге әүвәлге Зыя була алмас җиргә китеп югалганлыгын Мәрьямнең хыялына китерергә; бер-ике мәртәбә сөйкемле һәм бик җылы кыяфәттә күренгән соң, Фәхрине дә беразга юк итәргә; ләкин һәрбер адымда әүвәлгесен батырып, чумдырып, соңгыны күтәрә, якынайта барырга; аннан соң калага алып барып, һичнәрсәне уйламаслык, бар дөньяны оныттырлык итеп, кунакта, шау-шу вә халык эчендә кайнатырга; үзенең каладагы дуст кызлары, иптәшләре, бигрәк тә теге, адәмнең йөрәген аралый торган килен бикәләр белән, җиңгәчиләре белән буталдырырга – ничек тә күңелен икенче дөнья вә икенче галәмгә алып китерергә... әллә ниләр, әллә ниләр... әллә ниләр кыйлырга! Шулай иттереп, һичкем катышмаган, көчләмәгән, гүя үзеннән-үзе барып чыккан кебек итеп, туташны Фәхри куенына салырга... Аннан соңгысын Ходა белә... Яшь күңел бер җилкенер дә утырыр... Яшь чакта һәркемдә андый эшләр булгалый...

4

Фатыйма бикәнең планы уйлаганыннан да муаффәкыятьлерәк чыкты.

Кайбер вакыт эшләр һәммәсе бер нәтиҗәгә карап агалар. Монда да шундый хәл булды.

Язмыш, ананың ярдәменә җитешеп, Фатыйма бикә, «кара халыктагы кебек» турыдан-туры көчләргә мәҗбүр булмыйча ук, үз дигәненә иреште, тик планының ахырына ялгаган өмите генә юкка чыкты. Ул «яшь күңел бер җилкенер дә утырыр» дип уйлаган иде, ләкин яңлышты.

Аның, Фәхригә биреп, бәхетле ясарга теләгән Мәрьяме үзенең Зыясына язган икенче хатында ук: «Белмим, валлаһи, бернәрсә белмим!» – дип башлый да авыр сүзләр белән үзенең хәйрәтен[1], изтыйрабын[2] тасвирга керешә иде:

«...Мин, – ди, – хәзер аның хатыны. Туйлар булды. Кияүләп йөрде... Менә аның йортына килеп тора башлаганыма да ике ай тула инде...

Безнең тормышыбыз начар түгел. Байлыгы ару, өе, җиһазы да шәп кенә. Теге,

---

[1]*Хәйрәтен* – аптыравын.

[2]*Изтыйрабын* – көенү-газаплануын.

синең белән беренче кавышкан бакча хәтереңдәме? Безнең йорт шуның нәкъ каршысында гына... Беләсең, ул бит мирза кисәге. Җитмәсә, хөкүмәт хезмәтендә – түрә дә. Ул мине качырмый; ләкин аның мөстәбидлегенә[1] исең дә китәр, гакылың да бетәр... Минем ялгызымны һичкая чыгармый, үзе белән дә бик сирәк алып йөри... Кичә генә җиңгәчи килгән иде, шул Фәхринең алдында ук: «Менә, Илаһым, кара халык кебек, хатыныңны бикләп тотарга итәсеңме әллә?» – дип көлгән иде. Ул, каһәр, күзен дә йоммый: «Бикләр идем, җиңгәчи, бик бикләр идем: мин бит аны бик яратам, шуңа күрә аның йөзен башка һичбер адәми затка күрсәтмәс идем... Ләкин...» – ди.

Миңа әле артык кыен да түгел кебек. Билгеле, минем аны ярата алу ихтималым мәңге юк. Яңа тормыш, яңа хәлләр булганга, көннәрем бертөрле, сизелми генә үтәләр инде. Әмма кичләр, төннәр бик авыр... Сәгать кичке алты булдисә, бакчада музыка башлана. Минем кебек үк хатыннар, туташлар, җаннарын бирер дәрәҗәдә сөйгән шикелле тоелган ирләрнең, егетләрнең кулына мөхиббанә[2] яталар да, берәүдән дә курыкмыйча, бөтен дөньяга: «Күрегез, без нинди бәхетле», – дигән сыман гөлдердәшеп, бакчага киләләр... Менә шуны күрү миңа авыр алямле...[3] Мин моннан мөзтәриб[4] булам, боларның бәхетенә кызыгам... Шул вакыт Фәхри кайтып, үзенең гадәтенчә, мине җанлы курчак кебек шаярта башласа, ачу вә әрнүемнән әлләниләрне өзгәлән ташларлык мәртәбәгә җитәм. Аның һәр нәрсәсе, һәрбер хәрәкәте миңа салкынлык бирә, аның эчендә гүя боз диңгезе бар. Аның үзе дә, сүзе дә, йөзе вә күзе дә миңа әллә нинди авыр суыкны аңдыралар... Менә шул вакыт бер Ходай үзе генә түзем бирсен!

Мондый тойгы белән үткәрелгән кичәләр, төннәрнең бер сәгате миңа бер ел тоела... Авыр, авыр, бик авыр.,, Җанга авыр, йөрәкне сызлата; әллә нинди бәхетләр, югалган өмитләр исемә төшеп, дөньяда миннән дә бәхетсез адәм юктыр төсле хис итәм... Ләкин шул авыр минутларда мине бер нәрсә җуата: кемдер миңа бу бәхетсезлекнең вакытлы икәнен сөйли.

Шуннан минем үземне мәзлум[5] итеп хис кыйлуым югала; минем йөрәгемдә дошманлык белән бергә өмит вә гайрәт тә кузгала... Шул вакыт, шул караңгы төндә әллә кемнең каршысына барып та, мин аңа бәхет бирә алмавым, аңардан үчемне алмый калмавым һәм бу көннәрнең санаулы гына булуы, минем Фәхригә курчак булуым вакытлы гына бер газап икәнчелеге хакында Алла

[1] *Мөстәбидлек* – рәхимсезлек, деспотлык.
[2] *Мөхиббанә* – иркәләнеп, сөелеп.
[3] *Алямле* – җәфалы, газаплы.
[4] *Мөзтәриб* – кайгылы, борчылулы.
[5] *Мәзлум - кыерсытылган*

белән, Кәгъбә белән ант эчәсем, моны бөтен дөньяга каршы игълан итәсем килә... Һәм үзем шуны бик куәтле рәвештә хис тә итәм: гүя мин Фәхрине бәхетле ясамаячакмын, гүя минем аның читлегендә ябылуым вакытлы гына булачак.

Без яңарак әниләргә кунакка барып кайттык... Ничектер авыр һәм кызганыч булды... Шул аз заман эчендә үзем бик үзгәргәнмен, ахры... Кыз чагымда кешегә әйтергә түгел, үз алдымда уйларга да оялган эшләр хәзер минем телемнән, корьән сүзе кебек, җиңел һәм табигый чыга... Әнигә бар серемне ачтым: «Мин бәхетсез, мин бәхетсез», – дидем. Ул үзен гаепле хис итә, ләкин: «Ни эшлим соң, бәгырем, мин көчләмәдем, үзең миңа барыбер, дидең... Хакның язмышы шулдыр инде», – ди... Ул хәзер синең хакта тагы үзгәргән, берничә мәртәбә сагынып сөйләде, ахирәт апайга да: «Хат язсаң, миннән сәлам куярга онытма!» – дип кат-кат әйтә...

Халыкның «җенем сөйми» дигән сүзен беләсеңме? Әниләргә барып кайткач, мин Фәхригә булган суыклыгымны, читлегемне бигрәк арттырдым... Аңа мөнәсәбәтемне тәгъбирдә шуңа башка сүз таба алмыйм: «Җенем сөйми шул каһәрне!!»

Ләкин ышан, бу вакытлы бер эш; көне килер, мин бу тормышны бәреп ташлармын һәм дөньяга да, Фәхригә дә үземнең кем икәнемне күрсәтермен; мин хәзер назлы туташ Мәрьям түгел, мин, бу падлисның[1] астында яту белән ниһаясез кыйммәт булган һәм кызлык вөҗданың белән үз сөйгәнеңә генә бүләк итәргә тиеш дип хис ителгән надир кодсиятемне[2] югалтсам да, бу авыр фаҗига миннән бер пәрдәне алды, минем көчемне, каһарманлыгымны каплап торган бер мәгънәви диварны җимерде... Мин хәзер үзем уйлаганнан артыгын эшли алам...»

5

Фәхригә җиңелмәгән, үзенең нинди дә булса бер сүзе, бер мөгамәләсе белән аның киберен, хакимиятен сындырган чакларда язса, Мәрьямнең Зыяга җибәрелгән озын хатлары шундый өмитләр, шундый каһарманлык дәртләре белән тулган буладыр иде. Мондый мәктүбләрендә башка ничаклы авырлыклар тасвир ителсә дә, нәтиҗәдә «менә, менә бер көн килер дә, ул Фәхрине йөзтүбән җибәрер һәм үзе җан сөйгәненең кочагына атылыр» өмите балкый иде.

Ләкин һәрвакыт алай булмый иде.

Менә, ничек тә булса, Фәхри Мәрьямнең күңелен калдырсын; аны, үз

[1] *Падлис* – (подлец) – адәм актыгы
[2] *Надир кодсиятемне* –бердән-бер изге сафлыгымны

иштиһасы[1] өчен ясалган бер курчак итеп шаяртсын; тагы ачык итеп, аның «түшәк өчен» генә кирәклеген белдерсен – шул вакыт каһарман ханымның гайрәте сүнә, өмите, үзенә ышанычы бетә; ул тагы авыр көннәреннән, ниһаясез изтирабларыннан, мәңгегә бәхетсезлеккә мәхкүм булуыннан фөрьяд кыйла; Зыяга язган мәктүбләрендә шул хакта елау белән, күз яше белән тутыра иде... Гүя бәхет агачы мәңгегә корыган, канаты сынган; гүя ул язмышның кызганмас кулы белән үзенең өмит җәннәтеннән алынып, әллә кая түбәнгә, кара, караңгы һәм мәңге чыга алмаслык булган төпсез җәһәннәмгә, бәхетсезлек диңгезенә ташланган... Ул инде өмит белән дә жуана алмый, бәхет тә көтми... Тик үткән көннәрне вә артта калган хатирәләрне уйлау вә шулар хакында күз яше түгү белән генә кичәнә...

6

Зыя өч-дүрт ай карарсыз, билгесез бер хәлдә йөрде!

«Ни эшләргә, ничек мәкабәлә итәргә?[2]»

Ул өч катлы, меңләгән солдатлы, бөтенләй башка тормышлы, мөмтаз[3] канунлы булган казармага ябылу, өстенә соры шинель, аягына зур башлы тупас итек кию, кәбестә ашау һәм «шагом марш» уңаена атларга өйрәнү бәрабәренә, җитмәсә, тагы шундый тиз арада җаннары берләшеп, дөньяда һичбер нәрсә аера алмас кебек хис кыйлган Мәрьямен мәңгегә югалтырмын дип яңлыш кына да зиһененә кертмәгән иде.

Ә дөньялар мондый булып китте.

Хәзер Мәрьям ерак. Аның үзен күрергә мөмкин түгел... Булса, хатларын укырга да, шулар аркылы аның сурәтләрен хыялында ясарга гына имкян бар. Һәрбер мәктүб аңа әллә ничә төрле хыял вә үзгәреш бирә...

Мәрьям: «Үзгәрдем, мин хәзер хатын булдым!» – дип язса, бу Зыяда әллә нинди бер тәэсир калдыра. Гүя ул, җиргә төшеп, нур вә чәчәктән ясалган адәм сыйфатына кергән фәрештәнең, назик[4] вә назлы туташның, хәзер буе бераз кыскарган, билләре калынайган, күкрәге калкып, бите, теге таныш әфитсәрнең хадимәсенеке кебек, киңәеп, тулып киткәндер шикелле... Хәзер аның белән әүвәлгечә хыялый гыйшык сүзләрен сөйләү килешмәс тә кебек...

Теге изтыйраб, өмитсез вә күз яше белән тулган мәктүбләр исә тагы икенче төрле күренеш бирәләр... Мәрьям хәзер әүвәлгедән дә артык назик һәм хыялый күренә, аның йөзендә нindидер моң катыш трагедия әсәре, бөтен торышында

---

[1] *Иштиһа* – теләк, аппетит.
[2] *Мөкабәлә итү* – кабул итү.
[3] *Мөмтаз* - махсус
[4] *Назик* – нәфис.

фаҗигый бер матурлык балкый... Аның күзләре, ул зур, матур кара күзләре, бөтен дөньяга «юк, булмады, өмит бетте» изтирабы аркылы карыйлар...
Зыя айлар буенча шул ике сурәтне үзенең хыял күгендә бер калкып, бер югалып торган йолдызлар сыман йөртте. Аның рухының төбендә, бик тирән бер җирендә, Мәрьямне вафасыз дип шелтә итәргә һәм йөрәгенең әллә нинди назик вә яшерен бер ноктасында ул сөеклесенә үпкәләүгә охшаш бер хәрәкәт, бер тойгы булса да, бу әле бик зәгыйфь вә бик көчсез иде. Ул тойгы егетне җиңә алмый иде. Зыя да, язмышны гаепләп, Мәрьямнең хатларын җавапсыз калдырмый иде.
Ләкин бик кыска бер хәбәр теге хәлсез үпкәгә берьюлы куәт бирде.
Зыяның бер иптәше бар иде, ул, моңа бер хат язып, сүз арасында шуны да кыстырган: «...Беләсеңдер, сезнең авылның теге Мәрьям туташ безнең каланың бер мирзага кияүгә барды бит... Аны бик мактыйлар иде. Кичә үз күзем белән күрдем... Чынлап та, бик гаҗәб нәрсә икән, шундый хатының булу чыннан да зур бәхет, иптәш... Никах килешкән, ахры, – тагы да матураеп, хатынлык нәфасәте[1] артып киткән... Сөешеп кавышканнар булырга кирәк, иренең кулына тәмам яткан да көлә-көлә нидер сөйләп бара...»
Зыяны гүя яшен сукты. Ул, агулы хәбәрне укып бетәргә дә тәкать тота алмыйча, урыныннан сикереп торды да, берьюлы катып ташка әйләнгән яки үзе шуны теләгән сыман, эченнән ташкан дулкынга чыдый алмый, идән буена кызу-кызу атларга кереште:
«Ах, вафасыз! Ах, вафасыз! Ах, хаин, ах, хаин! Өзәргә, өзәргә! Аның белән мөнәсәбәтне аңдырган[2] һәммә нәрсәдән мәңгегә өзелергә! Хатларын ут җотсын! Рәсемнәре көлгә әйләнсен! Хыялымда сурәте калмасын! Исемен телгә алу түгел, хәтерем дә онытсын! Бетсен, барлыгы бетсен, аны хәтерләткән барлык нәрсә дөньядан үтсен!!»

7

Була шундый халәтләр: кайвакыт берәүне чын күңелдән сөясең, аны күрү, аның белән сөйләшү сиңа зур бәхет була; аерылсаң, аны сагынасың, аның хакында уйлау, аның белән мөнәсәбәтеңне кемгә дә булса сөйләү сиңа күңел шатлыгы, җан рәхәте бирә; аның сиңа мөнәсәбәтен дә нәкъ синең аңа дустлыгың кебек тоясың – сөясең, сөям дип ышанасың. Менә шул вакыт ул сөйгәнең тарафыннан башка һәркем илтифатсыз үтәрлек дәрәҗәдә гади булган бер эш күрәсең, ничек тә ул синең дустлыкны тәкъдир итеп җиткерергә теләмәгәнне аңлаткан бер хәл тоясың да, аңа хәтерең кала, үпкәлисең, тыш яктан аңа кара йөз күрсәтеп, бөтен

[1] *Нәфасәт* – гүзәллек, күркәмлек
[2] *Аңдырган* – саклаган, хәтерләткән.

мөгамәләңдә суык пәрдә эчендә күренергә тели башлыйсың... Бу вакыт син эчтән янасың, аның белән әүвәлгедәй дустлык бәхетендә йөзәргә күңелең тели. Ләкин нидер тыя, нидер тыш яктан караңгы һәм салкын булырга көчли, чөнки синең хәтерең калган. Артык самими, артык күңелдән дуст булган адәмнәр арасында гына була алган бу хәл тышкы мөгамәләдә ачуга, дошманлыкка җитәргә мөмкин, ләкин син эчтән һаман янасың, аны һаман сөясең, үзең көчләнеп карасаң да, күңелең аны сөюдән туктамый...

Менә бу – адәмнең бер-беренә каршы булган ике ут эчендә януы димәктер. Теге хәбәр Зыяны да шундый утка салды, һәм ул шул көннән алып Мәрьямнең хатларына җавап бирмәс булды.

Ул һаман эчтән яна, аның күңеле һаман да Мәрьямнән якын, аңардан сөйкемле бер кыяфәт тапмый иде. Ләкин тышкы күренештә сөюдән, күңел теләгеннән галибиятле[1] булган икенче бер куәт аны заһири[2] мөгамәләдә суыклык, хәтта мәңгегә өзелгәнлек сурәте бирергә мәҗбүр итә иде.

8

Бу хәл байтакка барды. Мәрьям ни диярgә, ни кыйлырга белми иде. Башта борынгы шикелле озын мәктүбләрен еш-еш язгаласа да, бара торгач, аның да каны суынып, хәтере калып китә дә, унар-унбишәр көн бер хәреф язмый, ул да үзен ике ут арасында хис итә башлый иде. Ләкин шул ике ут эчендә янган минутта ул әллә нинди бер тәэсир белән Зыя кашында үзенең гаепле икәнен, ул кодси[3] мөнәсәбәтнең өзелүенә үзе сәбәп булганлыгын хис итә дә, хәтер калуын һәм тышкы суыклыкны бер якка ыргытып,, күңеленә җиңелә; яңадан, үзе белешмичә үк, сөйгәне алдында мәктүб аркылы еларга, күз-яшь түгәргә, теге мәлгуньне каһәрләргә, ул авыр көннәрне тудырган явыз куәтне әрләргә, ләгънәтләргә тотына иде.

Беркөн ул шундый минут тәэсире белән таң вакытында Зыяга бик озын мәктүб язып, иртәнге почта белән җибәрә куйды. Шул көнне аңа Нәгыймә апасы килгән иде. Аны озату белән бүлмәсенә бикләнде дә, бер-ике минутта гына дәхи икенче бер мәктүб сызгалап, кичке почтага өлгертү уе белән, хадимәне бик ашыгыч салып кайтырга чаптырды.

«Газизем!

Иптәшең Кәримгә җибәргән хатың белән рәсемеңне, Нәгыймә апай аркылы алдырып, укыдым, күрдем. Читләргә язылган мәктүбтә генә булса да минем исемемне зикер итүең күңелемдә өмит вә шатлыкка охшаш бер тәэсир

---

[1] *Галибиятле* – өстен, югары.
[2] *Заһири* - тышкы
[3] *Кодси* – изге, гөнаһсыз

калдырды... Ни әйтергә, ни дияргә белмим, синең йөрәгеңне борын аңлап бетә алмаганмын дип, әле хәйран калам: димәк, син бәхетсез түгелсең, димәк, син кысык казармада да шаярып хат язарлык кәеф таба аласың... Рәсемеңне күрү белән, үземне онытып, бик озак шуңа карап, катып калдым... Апа әйтә: «Зыя бер дә үзгәрмәгән», – ди... Мин бернәрсә дә аера алмыйм, бер карасам, тик киемең генә алмашынган, үзең нәкъ әүвәлгечә кебек күрәм, икенче карасам, бөтенләй икенче кеше булгансың шикелле тоям... . Апа синең үзгәрмәвең хакындагы сүзен әйтеп бетерми, минем күзләремә карый; мин аның кызганган сыман карашын аңлыйм, шунда нидәндер күңелем йомшарып, күземә яшь килә... Апаның сүзе, бәлки, дөресттер, бәлки, син бер дә үзгәрмәгәнсеңдер. Көзгегә карыйм да үземне дә «нәкъ әүвәлге хәлдә» табам, миндә күп үзгәреш юк, тик йөземне каплаган үлем аклыгы катыш хәятсыз сарылык пәрдәсе калынаеп, яңакларым суырылган, күзләрем әллә кая эчкә баткан да, бөтен кыяфәтем ниндидер бер өмитсезлек төсе алган...

Мин хатынмын, ничаклы сөйсәм, үземне синең алдыңда ничаклы гаепле итеп хис кыйлсам да, сөюемә, туктаусыз аккан күз яшьләремә каршы авыр таш катылыгы, боз салкынлыгы күрсәм, куркам ки, нәфесем җиңмәгәе, шәйтанлык үз дигәнен кыйлмагае иде! Гыйшык илаһи күңелемә сыймый ташкан, үзем гарешкә ашкан минутларда мин рәхмәтле Тәңредән тик шуны сорыйм...

Рәсемемне җибәрдем. Унлаган мәктүбләремә каршы бер җавабыңны кызганмазсың дип өмит итәм... Бервакыт: «Синең сөюең алдында ташлар да эрер», – дигән идең, аптырыйм, син, ахры, таштан да катысың...»

Бу кыска хатны җавапсыз калдырырга Зыя үзендә куәт тапмады, җиңелде.

«Мөхтәрәм Мәрьям ханым!

Арамызда булып кичкән дустлык хөрмәтенә Сезгә мәктүб язмак булып, кулыма каләм алдым... Ләкин ни язарга? Ни язарга?! Күңел буш, йөрәк тын; ул әүвәлге кебек сукмый, – белмим, куәтле бер тәэсир белән ташка әверелгән, белмим, артык янудан көлгә әйләнгән...

Борын, кулга каләм алу белән, хиссият ташып китә, бармаклар хәрефне тезеп өлгерә алмый иде... Агалар, бергә мине дә агызалар иде...

Ләкин менә хәзер анларның берсе дә килми, килгәннәрен язарга каләмем карыша... Күңел буш, йөрәк тын – анда үлем тынлыгы... Менә шул сүзләрне язу үзе үк авыр... Мин Тәңренең үз ирадәсе[1] белән беркетелгән ике җан арасында бунча еллар дәвам иткән мөкаддәс мөнәсәбәтнең, безнең ул самими дустлыгымызның ахыры бундый авыр һәм күңелсез бер кыяфәт алыр дип

[1] *Ирадә* – теләк, ихтыяр.

яңлыш кына да уйлый алмаган идем... Мин кызганам һәм тәәссеф итәм...[1] Ләкин ни эшләргә? Ни эшләргә? Мин моны теләмәгән дә, көтмәгән дә идем. Табигатьтә бездән өстен куәтләр бар, күрәсең...

Яңлышасыз, мин бәхетле түгел һәм була да алмаячакмын... Хәят авыр, алдым караңгы, өмитләр алдады, инде башка юк; тик үткән гомер күгендә ялтырамакта булган бәхет йолдызларын тамаша илә генә бераз җуаныч табарга мөмкин...

Була вакытлар, төн килә, җир йөзен сөкунәт[2] вә серрият[3] каплый; шәһәр тына, казарма үзенең авыр вә тирән йокысына бата... Мин акрын гына яткан җиремнән торам, бинаның бакчага караган тәрәзәсе төбенә килеп утырам да, күңелем белән тышның тын вә куе караңгылыгы эченә китеп, югалып, авыр вә тирән уйга чумам...

Китәм артка, хатирәләр дөньясына! Сез әле назик вә хәссас табигатьле[4] туташсыз; хәятыңыз, гыйшык нурына чолганып, шул дәрәҗәдә матур күренә ки, карасаң, күзләр камаша... Дөнья тын, караңгы... Бераздан ай калка... Без икәү генә йә шелдерәп аккан бер су буенда, зифа таллар, матур чәчәкләр уртасында, табигатьнең яшел келәме өстендә утырамыз... Яисә, айлы кичәдә, зур бакчаның бер читендә, ялгыз гына күзгә-күз карашып, кул кысышып, юлыгамыз да күңелләремезнең иң эчке вә иң мөкаддәс серләрен сайрый башлыймыз...

Уем шул ноктага җиткәч, йөрәгем суга, эчемне ут ала, мин яңадан илаһиләнәм; эчемдәге иблислек җиңелен, мәләкүтият[5] куәт ала, җаныма әүвәлге тойгылар солтанәт итә башлый; мин шул вакыт, Сезнең алдыңызга тезләнеп, гафу үтенәсем, кулларыңызны кысып, туйганчы ул матур күзләреңезгә карарга хак аласым, рәд кыйлсагыз[6], ялынасым, ялварасым килә...

Ләкин, ләкин бу караңгы гомеремдә ялтырап калган бер минут, пакь вә илаһи булган бер дулкын гына булып кала... Мин тагы үзгәрәм, тагы йөрәгем суына, эчем туңа, тагы катам, бетәм; үземне тагы кысык казармада, Сезне – Фәхринең куенында күрәм... Шуның белән бар да бетә, Сезгә таба дустлык сорап сузылган кул, акрын гына тартып алынып, кире кесәмә салына. Яза башлаган булсам, бармаклар туктый, каләм төшеп китә; ни эшләремне белмичә, башымны селкеп, тешләремне кысам да, барлык хатирәтне юк итеп, ачуым

---

[1] *Тәәссеф итү* - үкенү
[2] *Сөкунәт* - тынлык
[3] *Серрият* – серлелек.
[4] *Хәссас табигатьле* – сизгер күңелле
[5] *Мәләкүтият* – сафлык-пакьлек.
[6] *Рәд кыйлу* – кире кагу

белән туңам, катам... Аннан соң мин – таш, йә мәңге эремәслек боз...
Ләкин... ләкин күңелемнең самими булган бер арзуын яшерергә куәтем җитми: мин Сезне гомеремдә тагы бер мәртәбә, тик бер генә мәртәбә күрсәм иде дә, бер генә, тик бер генә сәгатькә юлыгып, яңадан мәңге очрашмаска кул кысышып аерылсам иде дим!

Борынгы дустыңыз *Зыя.*

Казарма. Төн.»

9

Зөләйха абыстай бик тиз айнып җитә алмады. Дөнья томан эчендә кебек, кайбер вакыт боларның һәммәсе дә төш кенәдер шикелле, аныңниндидер бер кыйммәтле нәрсәсе югалган, хәятында әллә нинди бер зур бушлык ачылган бугай; ләкин ул аның өчен янып, өзелеп кайгырмый хәзер... Авыр кебек, зур хәсрәт бар кебек... Әллә тагы юк тамы?..
Улыннан еш-еш хатлар килде. Ул берсендә: «Бүген солдат киеме киендем», – дип язган, икенчесендә: «Бисмиллаһи, уенга чыктым», – дигән. Башкаларында да шундый хәбәрләр... Абыстай угылын икенче дөньяда күрә, ләкин аның һәрбер нәрсәне ярым уенга тартып язуы аны яхшы ук мәртәбәдә җуата иде.
Күрше хатыннары керәләр дә, абыстай өчен һичбер вакыт ялыктырмый торган мәузугдан сүз башлап:
– Нихәл, абыстай? Мәхдүмнән хат-хәбәр бармы?- – диләр.
Сөаль бирелеп бетми, ул, күтәрелеп китеп, җиңел мөтәәссир вә шатлыклы тавыш белән сөйли башлый:
– Аллага шөкер, киленкәем, Аллага шөкер! Һаман Шатлыклы хәбәрләр генә килеп тора... Кичә генә хат килде, харап озын язган... Уенга да өйрәндем, дигән, әфисәрләр дә үземне бик яраталар, дигән... Бер дә, дигән, кыенлык күрмим, дигән... Мине, дигән, кара эшкә кушмыйлар, мулла дип кенә йөртәләр, дигән... Аның бер шәкерт иптәше һаман китаплар җибәреп тора икән... Гәзитә дә алдырам, дигән... Минем өчен, дигән, бер дә кайгырмаңыз, мин бик һәйбәт торам, дигән... Алла боерса, кунакка да кайтып килермен, дигән...
Шуннан соң китә сүз, китә әңгәмәләр!
Ләкин хәзрәт бөтенләй икенче халәткә керде.
Ул гүя ачу белән катты; гүя ачудан туңды. Хәзер аз сөйли, уен-көлкегә бер дә якынламый. Кешеләр белән каты вә салкын мөгамәлә кыйла. Үзен ерак, югары, киберле тота. Угылларын һәрничек телгә алмаска тырыша. Ул борын тирә-якның могътәбәрләренә[1] йөрергә, анларны үзенә чакырырга бик ярата, һәрхәлдә бик хәрәкәтле, үзгәрешле рәвештә гомер үткәрә иде. Хәзер аны да куйды. Үзе

[1] *Могътәбәр* - хөрмәтле

йөрми, икенчеләрне дә чакырмый. Зөләйха абыстайның булсын, башкаларның булсын, күп сөальләренә сөкүт[1] белән җавап бирә. Сөйләсә, ачуланып, кыска һәм каты итеп сөйли. Зыядан хат килү-килмәү аңа барыбер төсле. Анларны җүнләп укымый: «Ни язган?» – ди дә куя. Акча сораса, җибәртә, ләкин үзе һичбер мәктүб язмый, сәлам куярга да сирәк әйтә.

Ул, Зыяның алынган хәбәрен ишеткәч, ике арадагы җеп өзелде кебек тойса да, озатып кайтып, юлдан язган бер-ике хатын укыгач, яңадан бераз өмит бар кебек, ул солдаттан кайтыр да атасының угылы булыр кебек хис итә башлаган иде. Ләкин соңгы мәктүбләре тагы начар тәэсир итте. Хосусән бер иптәшенә язган хаты бигрәк тә өмитсез иде. Анда булачак ахун илә булачак мөдәрриснең исе дә юк, ул һаман үзенең әллә нинди планнарыннан, музыка мәктәпләреннән, нинди көйләр өйрәнүеннән, ул хакта ниләр уйлавыннан бәхәс итеп, ничаклы көчләсәң дә, анда Җәләл теләгән адәм аслан күренми иде. Болар аңа тагы авыр тәэсир итеп, Зыяга мәңгегә кул селкергә мәҗбүр итмешләр иде.

Сабирны әйтәсе дә юк инде. Ул атасының вәгазь һәм шелтәсенә, анасының ялваруларына карамыйча, һаман үз дигәне белән бара:

– Мин, – ди, – авылны яратам. Мин шунда, үз атым, үз сукам белән иген чәчеп, үз башыма торасым килә, – ди...

Зыя алынгач, Җәләл үзенең остазбикәсеннән: «Бала, җә син ни уйлыйсың: без картайдык, энең солдатка алынды. Дөнья бар. Туганнарың бар. Гомергә дөнья гизәрсеңмени? Күп йөрдең, инде шәэненә мөнасиб[2] бер җиргә урынлашырга да вакыт бит...» – дип, зур угылына хат яздырган иде: теге туры гына, аңлаешлы гына бер мәктүб белән үзенең әүвәлге сүзләрен тәкрар итте.

Хәзрәт ачуланганын белдермәде, кызмады, тик:

– Этнең эт инде ул! Этнең адәм булганын кайчан күргәнең бар! – диде. Аның өстенә эчке бер әрнү белән: – Җүләрне чәчеп үстермиләр, диләр, менә мин ул җүләрләрне үзем чәчеп үстердем, – дип кушты.

10

Кыш, аның артыннан яз белән җәй бер-бер артлы килеп кичтеләр. Август үтеп, сентябрь дә керде. Табигать саргая, кошлар кыйбла якка карап оча башлады.

Бу ел игеннәр бик уңган булса да, көннәр коры булу сәбәпле, ялан эше үз вакытында тәмам булды.

Җәйнең туктаусыз хезмәте бик ардырмыш исә дә, халыкның күңеле күтәренке, йөзе шат иде. Чөнки:

– Тамак тук, ындырлар тулы!

---

[1] *Сөкүт* - эндәшмәү

[2] *Шәэненә мөнасиб* – теләгенә туры килә торган

Җәләл бу ел гадәттәгедән күбрәк тә чәчтергән иде. Яхшы эшләтүе, җирләренең яңалыгы сәбәпле, аныкылар тагы да башкача уңдылар. Бигрәк тә, башкорт җиренә чирәм ачтырып чәчкән бер ун дисәтинә ашлыгы адәм әйтеп, адәм ышанмаслык мәртәбәдә буйга да үскән, башка да (башакка да) искиткеч дәрәҗәдә утырган иде.

Ул бу ел кечек угылларын да, ялчыларын да уракка йөртмәде. Дисәтинәләп урырга да бирмәде, гомерендә беренче мәртәбә уларак, урак машиналары алдырып, оста урыслар яллады да шуның белән аз көн эчендә игенен бетертте.

Ул, гадәттә бик моктәсид[1] кеше булып, ашлыкны кыш көне әвен белән сугуда әллә ничаклы файда күрә:

– Саламы да яхшы була, сукканда малың кибәгенә, башагына да рәхәтләнә, – ди иде.

Бу ел исә ничектер аны уйламады, һәммә игенен ялан уртасындагы бер зур калку чирәмгә җыйдырды да, күрше баярдан зур машина китертеп, берничә көн эчендә барлыгын суктырып, ашлыгын өсәккә ташытты, саламын бик зур эскерт итеп шул җиргә өйдерде дә, мал-фәлән кагылмасын өчен, тирәсен киртәләтеп куйды.

Базар бәһалары яхшы иде. Халыккача бишәр, унар йөк белән берничә мәртәбә калага да озатты.

Халык, мулланың бу хәлләренә гаҗәпләнеп: «Буңа ни булган бу ел?» – дип карыйлар иде.

Шулар белән бергә, аның хакында төрле хәбәрләр дә чыга башлады: берәүләр, йорт-җирен сатып, калага күчә имеш, диләр; икенчеләр, анда мәрхүм... хәзрәтнең остазбикәсе Фәризәне икенче хатынга алып, шуның урынына мулла булырга уйлый имеш, дип тә арттырдылар. Ләкин болар гел авызда гына йөри, күбрәк яман телләр тарафыннан гына сөйләнә иде. Вакыйгда исә, хәзрәтнең бик еш калага иген озатуы белән атна саен диярлек яхшы ат җиктереп, шәп киенеп, каядыр югалуы гына бар иде. Сентябрь ахырларына таба шуңа охшаш дәхи берничә эше булып кичте.

Аның борыннан да атлары бик яхшы, арба вә ызбруе бик шәп иде. Күрше баярның нәрсәләре сатылганын ишеткәч, атын җиктереп чапты да, ни уй белән-дер, шуннан җигүле көенчә, бик әгъля көймә, ызбруй белән том-кара ике ат алып кайтты. Моның төпкесе тирә-якта атаклы булган бер юрга иде.

Халык аңа аптыраганнан-аптырый бара иде.

Шуннан озак үтмәде, аның бөтен йортын төзәттерергә, биналарның күбен тимер белән яптырып, яшелгә буятырга уйлаганлыгы, шуның өчен әллә кайдан

[1] *Моктәсид* – саклап торучан, сакчыл.

тимерләр, бүрәнәләр, осталар, буяучылар сөйләшеп йөргәнлеге ишетелде.

Менә шул хәбәрдән ун көн үткән соң, ул бик ашыгыч кына калага барып кайтты да, чәй эчеп, бераз хәл алгач, гомерендә беренче мәртәбә Зөләйха абыстайны кулыннан алып, хәтта бераз йомшаклык, дустлык йөзе белән:

– Син! Эшеңне бетер дә минем янга чык әле! – диде.

Остазбикә, озын-озак бураннар, ниһаясез каты суыклардан соң кинәт кенә май аеның иркәле кояшы алдына барып чыккан адәм кебек хис итеп, шатланыргамы, куркыргамы белмичә, тиз-тиз генә эшләрен тәмамлады да өмит вә шөбһә эчендә ире янына чыкты.

Ул һаман йомшак, ачык вә җиңел кыяфәттә иде. Бик мөһим бер нәрсә сыман сүз башлап, мәсьәләне тәфсил итеп бирде.

Каланың... мулла вафат булган. Аның кырык яшьләрдә угылы, унсигездә кызы бар икән. Байлыгы да бик зур, ди. Янында иптәш мулласы булса да, халык, бер белән генә канәгатьләнмичә, мәрхүмнең урынына янәдән мулла сайлаячаклар, ди. Ләкин бик ашыкмыйлар икән... Хәзер мәрхүмнең кызына төрле яктан яучы килә башлаган. Садыйк хәлфә дә сораткан, Габдрахман мулла да сүз салган. Кәрим бай да башкода җибәргән. Ләкин кызның анасы боларны бер сүз белән кире кайтарган. Ул: «Үз янымда торырлык, мәрхүмнең кыйлганнарын булдырырлык бер адәм булсын иде!» – дип әйтә, ди.

Моны Җәләлнең колагына төшергәннәр. Ул айлар буенча читләп-читләп сорашкан да, эшнең чамасын аңлап җиткәч, Мөхәммәт бай аркылы мәрхүмнең угылы белән күрешеп, якынлашкан. Ул Җәләлне күптән белә икән. Сабирны да ишеткән икән... Моның белән өмитле генә сөйләшкән. Ләкин башка сүз булмаган. Өч көннән соң, Мөхәммәт бай иң әүвәл мәрхүмнең угылын, аннан соң җәмәгатен күреп, бик озак сөйләшкән дә, тәмам килешеп, вәгъдә алган: «Анлар мәрхүмнең кызы Заһидәне Сабирга бирергә ризалар... Теләсә, бабасы урынына мулла да итәмез... Бөтен мәхаллә безнең кулда... Башкодалары могътәбәр кеше булсын, күп кичекмәсен!» – дигәннәр.

Хәзрәт сүзен бетерде дә абыстайга җитди, ләкин йомшак рәвештә бер сөаль аңлатып карады. Зөләйха остазбикә, берьюлы дөнья үзгәргән кебек хис итеп, ни дияргә белмәде, каушады, бөтен эче белән шатлык вә өмит катыш дулкынланды да:

– Ни диим, әй! Ходаның биргән бер рәхмәте икән... Алла үзе генә ярдәм бирсен... Күңеленә миһербан салсын иде, – диде.

Хәзрәт күп сузмады, тагы берничә төрле күренештә бу эшнең мөһимлеген бәян кыйлды:

– Ул – кала җире, зур җир! Мәрхүм үзе бик могтәбәр кеше иде. Җәмәгате белән

зур угылы бөтен каланы тотып торалар... Анда, бердән, байлык бар... Икенчедән, мулла да, ахун да булу – берни түгел...

Һәм шул көн кич үк, хәзрәтнең имля кыйлуы[1] буенча, абыстай Сабирга бик озын хат язып, мәсьәләне бөтен тәфсиле белән аңлатты да: «Бик тиз җавап яз һәм, мөмкин кадәрле кичекми, үзең дә кайт!» – диде.

Бу вакыйгадән соң хәзрәт ачылды. Хәтта уен-көлкеләр сөйләп, абыстай белән дә юк-бардан әңгәмә суга, кечек угылларын да шаярта башлады. Абыстай да, алдындагы томан вә караңгылык эчендә бер бәхет йолдызы ялтыраган кебек, менә-менә бер могҗиза чыга да аны бер мәсгудиять[2] кочаклап ала кебек тоя, бәгъзан өмит вә шөбһә эчендә йөзә, хәтта нидәндер кинәт кенә куркып та, каушап та китә иде.

Һәр икесе киләчәк бер бәхеттән шатлык көтәләр, һәр икесе, бер могҗиза чыгып, авыр, караңгы Хәятларының икенчегә әйләнәчәген өмит итәләр иде.

Менә берничә көннән «ярый» хәбәре килер. Аннан үзе кайтыр. Менә бервакыт туйлар, муллалыклар булыр... Анлар, угылларының шундый яхшы җиргә урынлашуын күреп, һәр икесе бәхетле булырлар!

Моның кире ягын уйларга да юк. Сабир ул дәрәҗәдә гакылсыз түгел: имеш, шундый кызны, шундый байлыкны, шундый куәтне кабул кыйлмасын. Мөмкинме соң? Ул бит җүләр түгел!..

Ун көннән соң Сабирның җавабы килде. Ул бик кыска иде:

«Гафу итеңез! Ул эш миннән булмый!!»

Бу кирелектән хәзрәт мөҗәссәм[3] ачуга әйләнеп, йөзе кара көйде, теле бағланды, күзләре бөтен дөньядагы ачу вә дошманлыкны җыйган кебек карый башладылар. Башка сүз тапмады:

– Булмасаң, кадалып кит! Чукынып җан бир! Җаның җәһәннәмгә!! – диде.

Һәм шуның белән ул, Сабирның исемен телгә алуны үзенә хәрам итеп, угылларына да, дөньясына да берьюлы кул селекте... Ул сүзне, уен-көлкене тагы онытып, өйдәгеләр өчен тагы авыр көннәр туды. Абыстай ни дияргә белми, баласын гаепләргә дә, гаепләмәскә дә аптырый. Үзе бу хәлне сизгән кебек, аның рәд кыйлырын белеп тә, иренә әйтергә генә батырлык итә алмаган кебек тоя... Мулласының кара йөзе, суык, каты мөгамәләсе аңа яңа эш түгел; ул, көннәр, төннәр эченә җыеп, түзеп килә дә, бу гөнаһсыз хәленчә газап күрүнең сәбәбен башкача тәгъбир итә алмагач: «Ни эшлим, ни генә кыйлыйм соң, Илаһым! Язмышым шулдыр инде! Әллә нинди гөнаһ шомлыкларым бардыр...

[1] *Имля кыйлу* – әйтеп яздыру.
[2] *Мәсгудиять* – бәхетле булу тойгысы.
[3] *Мөҗәссәм* – җаны-тәне белән.

Мин күрәсене кем күрсен соң!» – дип, озак, авыр, фаҗигый аглый...

Кечкенә балаларга тагы авыр. Анлар аталарының кыяфәтеннән, йөзеннән үк куркалар, аның янына барсалар, әллә нидән каушап, суыклыктан туңып, катып калалар. Шуңа күрә аналарына сыеналар. Ләкин аның янында да авыр. Аның күзләре талып, кызганычланып карыйлар. Йөзендә, хәзер елап җибәрергә торган кебек, бер тәәссер күренә...

Бу вакыйгадан соң хәзрәт планнарын онытты, йорт төзәттерү, биналарның башын яптыру, яшелгә буяту дигәнне дә телгә алмый башлады. Үзе көннәр, төннәр каядыр китеп югала; кайбер вакыт атналарча кайтмый йөри иде.

Һәр киткәндә бик күп акча бетерә, күп сәфәрдә берәр мөһим нәрсәсе дә урлана, кайтканда үзе һәрвакыт диярлек исерек була иде. Кайтса, мәсҗедкә йөрми; чыкса, җомгага чыга, ашка чакыручыларга да «бара алмый, авыру» диярга куша иде.

Мулла өйдә вакытта зарури эше булмаган һичкем аның янына чыкмый, чыкса да, каушап, аяк очы белән генә басып йөри иде. Кычкырын сөйләшү, көлешү дигәннең эзе дә калмады.

Гүя өйдә һәркемнең котын очырып, җанын бармак очына китергән, катылыгы, суыклыгы белән йөрәкләрне туңдырган бер явыз куәт, бер кара көч хөкем сөрә иде!

11

Шуның өстенә дәхи берничә нәрсә кушылды.

Җәләл берәүнең янып үлгән дигән хәбәре чыккан баласын күмгән иде. Зыяны солдатка алдырган Хәйри тоткан да: «Үлеп җитмәгәнне күмде», – дипме, әллә: «Әҗәле табигыйсез үлгән баланы докторга күрсәтмәде», – дипме, мулла өстеннән шикаять кыйлган. Дәгъвасына шаһитлар да тапкан.

Әгәр дә бунын сүзе сабит[1] булса, Җәләл үзе өчен бик күңелле булып бетмәвен сизә иде.

Чүп өстенә чүмәлә дигән кебек, икенче яктан тагы бер җәрәхәт ачылып тора.

Җәләл теге Сабирның кирелеге белән җенләнеп йөргән көннәрнең берендә һәм иң ачулы вакытта, авылның могътәбәрләреннән Гайни карт килеп, туй үткәргәнче генә дип, илле сум акча сораган иде. Ә аның әле әүвәлге бурычы йөз тәңкәгә якын булып, ул аның процентын да түләп җитмәгән иде. Муллага ачу өстенә ачу чыкты да Гайнине: «Әүвәлге бурычың да түләмәгән, сиңа тагы нинди акча?.. Китер әүвәлге бурычыңны... Векселеңнең вакыты чыкты», – дип, эт урынына сүгеп җибәрде. Картның кәефе кырылып, Хәйригә барып сөйләгән дә, аның ярдәме белән кайдандыр акча табып, мулладан векселен алып киткән.

[1] *Сабит* – нык, туры

Ул ишектән чыкканда: «Бирермен әле кирәгеңне!» – дип мыгырдаганын ишетүчеләр дә булган...

Җәләл борыннан ук бик артык аек адәм булмаса да, бердән, байлыгы, куәте, икенчедән, авылның тешлеләре белән бергә буталуы, анларның икътисадый җәһәтеннән муллага бәйләнеп беткән булулары сәбәпле, артыннан өрсәләр дә, гамәли бернәрсә чыгара алмыйлар. Ләкин берсе башлаганда кушылучылар табылуы бик ихтимал иде.

Гайни, мулладан чыккан да, Хәйри белән утырып, каядыр чапкан, киңәшкән һәм эшне әйләндереп тә чыгарган. Менә сиңа бүләк: башта Гайни уларак, мәхәлләнең утыз адәме кул куеп, Духовное собраниегә[1], белмим, тагы кая: «Муллабыз көн-төн эчә, намазга килми, мәҗлесләремездә булмый, җомгалар калдыра», – дип гариза биргәннәр...

Бала мәсьәләсенең хәбәре көне белән Җәләлгә ирешсә дә, бу утызныкы ничектер яшерелгән; мулла аны унбиш көн үткәч кенә ишетте; ләкин күп әһәмият бирмәде; җә ни булыр тагы дип, баштагы авыр вә билгесез мәсьәләләре белән чуала бирде. Бу арада авың хыялында гел тауны тауга бәрү, җирне күккә сугу, дөньяның күчәрен икенче якка бору кебек гел зур, гел гадәттән тыш олуг булган эшләр генә йөри иде.

Йортлар, биналар төзәттерү планы тагы аның теленә алынды. Әллә нинди зур, шәп иттереп мунча эшләтүне дә сөйли башлады. Ул арада булмады, беркемгә киңәшмичә, сәбәбен дә белдермичә, теге яңа алган пар Караны, җигүле көенчә, сатып та җибәрде. Ник саттың, дигәч, кирәге юк, ди.

Аннан да гаҗәбе – аның тарафыннан корылганголәма мәҗлесе иде.

Ул кунак-төшем тугрысында зур тотыну, шәп сыйлау, авылның бөтен халкын диярлек җыеп, олуг ашлар ясау белән данлыклы булса да, чит авыл халкын чакыру гадәте юк иде.

Ни уй беләндер, әле шундый бер эш кормак булган.

Ничә айлар ашаткан симез бияне сугымга суйдырды, каладан мең төрле сыйлар, ашамлыклар алдырды, атналар буенча хәзерләндерде дә, бик зур голәма мәҗлесе ясады.

Бу хәкыйкатән дә зур иде, миселсез[2] иде. Монда каланың зур муллалары булган кебек, Кара урманнан илле чакрым ераклыктагы Галим ишан да махсус атлар җибәреп алдырылган; тирә-якның зур ахуннарыннан, атаклы муллаларыннан, могътәбәр байларыннан һичкем калдырылмаган иде. Мәҗлестә коръән уку өчен, шәп тавышы, яхшы мәкамнәре белән бик күп җирләргә даны киткән

---

[1] *Духовное собрание* – Диния нәзарәте (мөселманнарда югары дини органы).
[2] *Миселсез* – моңа кадәр булмаган дәрәҗәдә.

мәшһүр Габдулла карине дә үз алдына адәм вә ат җибәреп китертелгән иде. Халыкның күплеге, җыелган адәмнәрнең шәэнлелеге искиткеч дәрәҗәдә булган кебек, мулланың хәзерләнүе, сые, кунаклавы да тирә-якның колагы ишетмәгән, күзе күрмәгән бер мәртәбәдә иде.

Күп кешеләр моңа шаштылар. Аптырамаган кеше калмады. Ул көндә Кара урман тын вә тыныч авыллыктан чыгып, туктаусыз атлар йөреп, калакуллар[1] шаңгырап, хисапсыз халык кайнап торган бер пайтәхет хәленә килде. Мәсҗедләр гомерләрендә күрмәгән зур ишаннар, калын байлар, медальле ахуннар белән, әллә нинди чобар киемнәр, кызыллы-сарылы чапаннар, бохари зур чалмалар белән тулып, Габдулла каринең тавышыннан хәйран булды, һәммәсе Җәләлгә тәхсин[2] әйттеләр, аның мондый зур һиммәтенә[3], ата-баба кыйла алмаган бер эш күрсәтүенә хәйрәтләрен бәян кыйлдылар... Чын мәгънәсе белән тантана, чыннан бер шәүкәт вә шанлы[4] көн булды.

Җәләл күтәрелде, менә яңа, үзенең җаны риза булырлык, күңеле канәгатьләнерлек бер эш кыйлганлыгын сизгән кебек бер хәлдә йөрде... Моны ни өчен кыйлганлыгын ул үзе дә ачык белми иде. Ләкин кирәк таба, зур эшенә эченнән бәйрәм итә иде.

Бу муллага яхшы тәэсир итеп, аның йөзе тагы ачылды, мөгамәләсендәге әүвәлге суыклык вә катылык, белмим, тагы каядыр китте; ул җиңел йөри, уен-көлкеләр сөйли, юк-бар эшләргә катышып шаяра башлады.

Ләкин бу озакка бармады.

Шул бәйрәмнең өченче көнендә, өйләдән чыгып, бала-чагасы, җәмәгате белән аш мәҗлесенә генә утырган иде, үзе ачык кына, балалар вә абыстай да шат кына, җиңел генәләр иде.

Ишектән бер малай йөгереп керде дә:

– Мулла бабай, сезгә әллә кем килгән, Зариф ахун бар дип әйтеңез, ди, – дип кычкырды.

Ашны икенче якка күчерделәр. Балалар белән абыстай чыкты. Ахунга «рәхим итегез!» дияргә кушып, бер угылын каршы җибәрде. Үзе, бик тиз генә кәләпүшен алыштырып, яхшы казакисен киеп алды.

Ишек ачылды, аннан, чалма-чапанын киеп, медальләрен күкрәгенә тезгән бер ахун килеп керде. Ул гадәттә уен-көлкеле, беркатлы адәм булса да, бу көн бик җитди һәм рәсми күренә иде.

– Әссәламегаләйкем!

---

[1] *Калакул* – (колокол) - кыңгырау

[2] *Тәхсин* – яхшы дип мактау, рәхмәт.

[3] *Һиммәт* – яхшылык, юмартлык.

[4] *Шәүкәт вә шанлы* – шөһрәт һәм данлы

– Вәгаләйкемәссәлам! Әйдүк, рәхим итегез, хуш киләсез...
Ахун утырды, ләкин өстен чишенмәде. Җәләл башта кыстаса да, тегенең әллә нинди бер җитдият, бер рәсмият белән карышканын күргәч, бернәрсә бар кебек тоеп, үз тарафыннан бик аз гына салкынлык, ераклык пәрдәсе күрсәтергә тиеш тапты.
Бу – Җәләлгә якын адәм булып, кирәгендә акча да алгалый, ярдәмгә мөрәҗәгать итә торган иде. Үзе яшьрәк тә, ул өченче көнге мәҗлеснең түрендә булып, моның нигъмәтен ашаган, шәэнен күргән, башкалардан да уздыра төшеп, һиммәте өчен тәхсин кыйлган иде. Җитмәсә, халыктан калып, махсус адәмнәр өчен генә корылган соңгы чәй мәҗлесендә дә булган иде.
Борын Җәләл аңа, югарыдан карап, ераграк, суыграк мөгамәлә белән йөрсә дә, һәр җирдә аның ахунлыгыннан көлсә дә, теге шәүкәтле мәҗлес аның мөнәсәбәтен үзгәрткән – якын вә дуст кебек ясаган иде. Шул тәэсир белән ул бүген Зарифка аерым илтифат күрсәтмәкче, кунак кыйлмакчы иде.
Ахунның җитдияте, рәсмияте аны берьюлы суындырды, ул эченнән генә: «Ни кыйланган була үзе тагы, бичара!» – дип уйлады да теге яктагыларга: «Чәй әзерләгез!»» – дип кычкырды.
Ләкин кунак чәйне дә рәд кыйлды:
– Юк, кирәкми, мин чәй эчә тормыйм. Мин башка бер йомыш белән – Собрание тарафыннан үземә тапшырылган бер әмер белән килдем...
Ахун сүзен бетерә алмады, Җәләл, берьюлы үзгәреп, йөзеннән дустлык илтифатын югалтты; күкрәгеν, бөтен торышын киберле бер кыяфәткә китереп турылатты; шуннан, мохатибның[1] өстенә күз салып, аның чалма-чапаннан, җитмәсә, медальләр белән үк икәнен күрде дә, бунардан тагы суынып, кимсетүле бер тавыш белән авыз ачты:
– Ни дисең?.. Ни дисең? Собрание йомышы димсең?
Зариф тагы бераз җитдиләнә төште дә, үзенә дә, Җәләлгә дә ят булган бер тавыш белән, ни өчен килгәнлеген сөйләргә тотынды.
Хәйринең дә, мәхәлләнең дә шикаяте Собраниегә ирешкән. Бу хакта анда төрле сүз булса да, бәгъзе бер мөнәсәбәтләр тәэсире белән, эшне зурга җибәрмәскә, үзара бетерергә карар биргәннәр: мәсҗедкә бармау, җомгага чыкмау кебек эшләрнең моннан соң булмавы тиеш идеке хакында тәнбиһ итәргә[2]; шикаятьнамәдә күргәзелеп, имамнар өчен аслан килешмәгән начар эшләргә катышудан тыелу белән вәгазь иттерергә; һәм шул хакта аңардан вәгъдә вә тәүбәне рәсми рәвештә алдырырга тиеш тапканнар. Шул эшләрне башкаруны

[1] *Мохатибның* – сөйләүченең.
[2] *Тәнһип итү* - кисәтү

Зариф ахунга тапшырганнар. Ул да, рәсми ахун сыйфаты белән, Собраниенең рәсми вәкаләтен алып, өстенә йөкләтелгән мөһим эшне үтәү өчен Җәләлгә килгән...

Кунак сүзен бетерергә өлгермәде, Җәләлнең йөзе каралды, күзенә ачу чыгып, куллары калтырый башлады, һәм эченә сыя алмый ташып барган ачу вә хәкарәт берьюлы бәреп чыгарга якынлады. Шулай да ул, үзен көчлек белән тыярга тырышып, «Алла» дигәч тә сугып егу ярамас кебек тойды:

– Димәк, сез шул әмер буенча килдеңез?

– Әйе! Әйе! Собраниенең вәкаләте белән аның тапшырган тәнбиһен иҗра итәргә[1] килдем... Вәгазь вә тәнбиһ шәригъдә мәмдух[2] эш бит!..

Ул тагьш сүзен бетерә алмады, Җәләлнең эчендәге ачу ташкыны бәреп чыгып, калтыраган тавыш белән сүзләрне өзә-өзә, ләкин һәрберен артык каты вә артык кискен рәвештә чыгарып, ата башладылар.

– Ни дисең?! Ни дисең?! Мине вәгазьләргә, миңа тәнбиһ ясарга килдем дисеңме? Шулай дисеңме?!

Ахун, үз куәтен сакларга тырышып:

– Ник кызасың? Собрание тапшыргач, мин ник килмим!.. – дип авыз ачкан иде, мулла, тагы кызып, җенләнеп, урыныннан сикереп торды да, Зарифның каршысына басып, ут чәчәргә тотынды:

– Әйтче, зинһар, син кем, син кем?! Син ни йөзең белән мине вәгазьләргә дип капкамнан керәсең дә шул сүзне ничек оялмый әйтә аласың? Ничек шуңа телең бара?! Син кем соң? Әйт шуны, син кем? Синең эчкәнеңне кем белми? Син бит минем шиша[3] төбемне ялый торган адәм! Мин Собрание әһелләренең каюсы белән эчмәгән? Элек үз артларын тазартсыннар, аннан соң мине вәгазьләтерләр... Оят бит, адәм хурлыгы бит. Тәнбиһ итәргә, вәгазь кыйлырга фараз итәләр, җитмәсә, шундый җебегән авызны җибәрәләр! Әй! җыен адәм актыклары!

Мулла, ахун белән беррәттән, Собрание әгъзаларын берәм-берәм эт урынына хәкарәтләп[4], аналары, бабалары белән сүгеп чыкты да, Зарифның күзенә карап:

– Җә, тәнбиһеңне ник кыйлмыйсың инде? – дип, хәкарәтләп көлде.

Ахун яхшы вә могътәбәр адәм булса да, юаш вә басынкы табигатьле иде. Мулланың мондый котыруы аңа бер дә көтелмәгән эш иде. Аның күз алды томанланып китте. Берничә мәртәбә авыз ачып:

– Ник ул чаклы акырасың?.. Илченең ни гаебе бар?.. Собрание кушкач, мин

---

[1] *Иҗра итү* – тормышка ашыру.
[2] *Шәригъдә мәмдух эш* – шәригатьтә мактаулы эш.
[3] *Шиша* - шешә
[4] *Хәкарәт* – сүгү, хурлау

килдем... Ул чаклы җикеренергә хатының юк бит монда... Мин синең малаең да түгел, – ди башлаган иде, болар Җәләлне тагы яман тилерттеләр:

– Лыгырдама дим, шул... нны! Миңа Собрание ничә тиен дә, үзең ничә тиен!! Син чалмаң, медалең белән бергә минем хатынымның кисеп ташлаган тырнагына да тормыйсың! Мин сине малайлыкка да ялламыйм! Беләсең килсә, менә кем син минем каршымда!!

Бу тәгъбир Җәләлгә охшады булса кирәк, ул, берәр секунд туктап, урамга карап алды да, тагы әүвәлгедән дә яман ачу вә хәкарәт белән шуны тәкрар итте:

– Мин сине малайлыкка да ялламыйм... Син зур чалмаң, сары медалең белән бергә минем хатынымның кисеп ташлаган тырнагына да тормыйсың! Менә син кем! Атаң, бабаңнан ишетмәгәнеңне миннән ишет...

Җәләл сүзен тәмам итә алмады, ахун, кызып китеп, мулланың каршысына килде дә:

– Син ни сөйлисең?! Син ни сөйлисең?! Ишеттеңезме, бу бит чалманы хурлый, бу медальне хурлый!! Беләмсең, моның өчен сиңа ни булыр? – дип кычкырып җибәрде.

Ул чак җөмләсен тәмам итте, мулла, тагы яман җенләнеп, аңа сул кулы белән ишекне күрсәтеп:

– Миңамы? Миңа ни булыр дисеңме? Бичара, ни кыйла алырсың?.. Бар, теләгәнеңне кыйлырсың анда, түлке хәзер күз алдымнан югал, бар, бар, чыгып кит, син этне күзем күрмәсен, бар, югал, күземә күренмә!! – дип, өстенә акырды да аяк тибеп куа башлады: – Ай, сабакы![1] Ай, көчек! Адәм хурлыгы бит, җир ярылса, оятыңнан җиргә керерсең бит!!

12

Указ... Указ... Указ... Указ!

Беләмсез, аның өчен бу ни тора иде? Бу – аның өчен һәрнәрсә, һәрнәрсә, һәрнәрсә иде! Мохит вә гомер һәр минутта, һәр адымда моны аның колагына тукып тордылар. Ул бишектә чакта анасы, үзенең әлли-бәллие белән бергә, аның мулла булуын, указ алуын теләп көйләде. Ул аягына басып йөри башлагач, һәрбер кунак, һәрбер якын адәм аны кочаклап сөя иде дә, зур булыр, мулла булыр, указ алыр дип, маңлаеннан үбә, рәхмәт диячәк җирдә: «Зур үс, мулла бул!» – ди иде. «Зур үсеп», мәдрәсәгә баргач, ул андагы биш йөзләгән шәкертнең һәммәсе озын төннәрдә, караңгы кичәләрдә, юрган астына күмелеп, киләчәктә мулла булуын, указ алуын мең төрле буяуларда, матур күренешләрдә хыял кыйлмакта, шуның белән җуанмакта, шуны үзенә гайәи әмәл[2] итеп

---

[1] *Сабакы* – (собака) - эт

[2] *Гайәи әмәл* – иң югары идеал.

тотмакта икәнен ачык күрде. Бервакыт хәлфә булу, аннан соң һәйбәт урын табып, указ алу – анларның киләчәк көненең хыял күгендә караңгы кичәдә бер ялгызы ялтырамакта булган йолдыз кебек тора, шул тарта, шул бәхтиярлык бирә иде. Илгә кайткач, ул мохитта хәят баскычларының иң югаргысына тик указ гына мендерә ала димәкне игътикад кына түгел, кан булып ук урнашкан тапты вә үзе дә шуны бик ачык хис итте.

Аның юлында ни генә кыйлмыйлар, ни генә фида итмиләр иде! Аның өчен кемнәр дустына дошман булмый, кемнәр берәүгә нахак бәла якмый; кемнәр, гөнаһка батып, ришвәтләр биреп, намус сатмый иде.

Башка вакытта аның алдында тапканын белдерергә теләмәсәләр дә, бер-бер афәт чыгып, кулдан указ ычкыну ихтималы якынайса, анлар, диңгезнең ниһаясез куәтле дулкыны астында кечек көймәдә калып та, менә, менә бер минут үтә дә һәлак булам дип торган адәмнең кыяфәтенә керәләр, шул «каза»дан аман-исән котылу өчен иң актыккы чараларга ябышалар иде. Ул үзе дә, бөтен бер илгә баш иткән, кая барса да, аксакалларны алдында баш иеп, кул кушырып тордырган, һәр җирдә түр, һәркайда кадер вә хөрмәт белән, мәшәкатьсез генә дәүләт тә бирдергән шул куәтне, шул саргайган кәгазьне аңламый түгел, бик аңлый иде. Аның юлында ул да башкалардан ким түгел иде. Шуның өчен дә, бервакыт ундүрт яшьлек кызга никах укыганлыгы өчен указының китүе ихтималлангач, ул, дөньясын онытып, йокысын калдырып, ашын, җәмәгатен ташлап, шәрекътән[1] гаребкә[2], җәнүбтән[3] шимальгә[4] чапкан, әллә нинди түбәнлекләр күтәргән, ат арытып, мал түгеп, – җан алып, җан бирер дәрәҗәдә йөргән һәм шулай итү аркасында гына да указны исән-сау алып кала алган иде.

Ләкин... ләкин бер минут килде дә, аның башы әйләнде, күзен кан басты; шуннан ул эченнән куәтле ташкын кебек күтәрелгән ачу вә хурлану тәэсире белән указны төкереп, ташлады, – теге ахунны куып чыгару белән бергә, ул үзен указдан язган хисап итте. Ләкин, иң гаҗәбе, ул бик аз гына да кызгану, үкенү хис итмәде. Гүя бу эш җә табигый иде, җә мәҗбүри иде. Гүя ул шундый бер хәлне әүвәлдән дә көтеп йөри иде... Сабир булса, анаулай[5] йөри, Зыядан да өмит калмады... Җитмәсә, мужик, дуңгыз җилкәләр дә эт кебек ырылдый башладылар... Әдәм хурлыгына калдырып, әллә нинди җебегән бичаралар, вәгазьлим, тәнбиһ итәм дип, авызын күтәреп килә. Инде әүвәлгечә атлар,

---

[1] *Шәрекъ* – көнчыгыш.
[2] *Гареб* – көнбатыш.
[3] *Җәнүб* – көньяк.
[4] *Шималь* – төньяк.
[5] *Анаулай* – әнә ничек.

ызбруйлар белән дә күп маташып булмый... Бу ел башлап уйлап караган эшләре дә канәгатьләндермиләр. Нидер җитми, тулмый... Ни дә булса, боларга бөтенләй башка һәм бөтенләй икенче төстә, зур тавышлы, зур кыяфәтле бер эш кирәк иде... Ул шул халәтнең тәэсире белән җәйдән бирле, берен башлап, берен ташлап, кая барып кагылырга белми йөргән кебек булуы, башка һәркемнән бигрәк, Зөләйха абыстайны гаҗәпләндерде. Ул иренең бу хәрәкәтләрен әллә нинди бер куркыныч әйләнмәгә алып барган төсле хис итә дә, моны башкача һичбер төрле аңлый алмагач: «Ни булды соң моңа, Ходаем? Әллә җеннәре кузгалдымы югыйсә??» – ди иде.

13

Мулла, эшне беткәнгә хисап итеп, ахун белән булган сәхнәнең икенче көнендә иртәнге чәйне генә эчте дә «Мәхкәмәи шәргыя»гә [19*] үзенең указын һәм муллалыгын ташлаганлыгы хакында “игламнамә”[1] язып, күп акча, яхшы кием, яхшы ат белән каядыр чыгып китте.

Мулла кая барачагын әйтмәгән иде. Абыстай иң әүвәл, эчәргә киткәндер, дип уйлады һәм шул уе белән ут эчендә көнне үткәреп, әлбәттә, исерек булыр, халык күзенә генә эләкмәсә ярар иде инде, дип елап-елап, төн буена башын мендәргә куймый чыкты.

Мулласының эчүе абыстайга яңа эш түгел. Аның исереп, сасып, пычранып кайтуы гына тагы бер хәл. Ул гомер буена бик күп күргәнгә, боларга, Ходай язмышыдыр инде, мин күрәсене кем күрсен, дип бер елый да бетә; болар ул чаклы авыр тоелмыйлар. Ләкин... ләкин мулласы шул исерек хәлендә көндез халык алдында кайтса да аны ил белсә, яисә фәлән җирдә, фәлән рәвештә ята иде, дип, аны берәр кеше китерсә – менә шул чакта абыстайның күзендә дөнья җәһәннәмгә әйләнә, менә шул вакыт ул тик бер нәрсә өчен, тик шул илнең, халыкның күзе Җәләлнең исерек хәлен күрмәсен, күрсә дә, онытсын өчен, белмим, ни нәрсәсен кызганыр, нинди кыйммәтдар асылын корбан кыйлмас иде! Ул мулласының кызуына, урынсыз тиргәвенә, хәятта булган һәрбер муаффәкыятьсезлеге. уңгае белән аны газапка салуына күнгән, гадәтләнгән иде. Шулай ук башка авырлыкларга да гади күз белән карый башлаган иде. Ләкин мулласының исерек кыяфәттә халык күзенә төшүе вә шуннан аның хакында авыр, куркыныч ил гайбәтенең башлануы – Зөләйханың хәятының иң караңгы, иң авыр бер төше иде.

Шуңа күрә дә мулласының эчеп кайтуы ихтималы булган сәфәр көннәре аның өчен авыр бер фаҗига була торган иде. Ул мондый көннәрдә көндезен өйдә кеше тотмый, күршедән-фәләннән килсәләр, тиз үк чыгара, үзе бертуктаусыз

[1] *Игъламнамә* – белдерү, аңлатма.

авылның Җәләл кайтачак очына карый тора; бер атлы күренсә, шулмы, түгелме дип, килеп җиткәнче җаны чыга; шул да кебек була, исерек төсле дә күренә, бер карасаң, янында берничә адәм дә бар кебек тоела... Абыстайның баскан җире каядыр китә, шуа, дөньясы әйләнә, йөрәге ярылырга җитә... Үзе бер самавырын ача, бер капкага, бер тәрәзәгә килә... Шулай итеп, теге атлы килеп җитә – ул җә бер базарчы, җә бер урыс була.

Көн үтә. Мулла һаман юк. Ләкин абыстай бераз гына тынычлана инде. Чөнки караңгы төн аның мулласының исереклеген явыз күзләрдән яшерәчәк.

Шул хәлдә Зөләйха абыстай өч тәүлек үткәрде, өч көн көндезен авыр бер изтыйрабта[1], төннәрен йокысыз, урам як тәрәзәләрдән беренең янагына сөялгән хәлдә, бер үзен онытып, хыял дөньясына югалып, бер елап кичерде. Дүртенче көнне таң вакытында Җәләл кайтып керде.

Аның аты арыган, эштән чыккан, ут йоткан кебек, эчләре суырылып, кара тиргә төшкән, аякларын чак атлап килә иде. Мулла үзе исә шул дәрәҗәдә исерек иде ки, теле көрмәкләнгән – бер сүз сөйләргә хәле калмаган, аягына басарлык куәте дә беткән иде. Габи[2] ат, бәлки кайда булса да адашып калыр, кайта алмас иде. Чөнки мулла нә юл белерлек, нә дилбегә тотып, атны идарә кыйлырлык иде! Ләкин зур Кара мондыйны күп күргән, хуҗасыз арбаларны күп ташыган иде. Абыстай үзе, урамның уртасына ук чыгып, атны җитәкләп алып керде дә өйнең нәкъ бусагасына китереп туктатты.

Мулла артык исереклегеннән үз аягы белән керә алмады, аны абыстай күтәреп алып диярлек кертте. Аның изелүе актык чиккә җиткән иде. Зөләйха аның киемнәрен салдырып беткәнче дә түзмәде, идәнгә егылган көенчә гырылдый башлады. Аның битен, башын сөрткәләп, җәюле урынга салып чыкканда, ат өй яныннан китеп, бакчаның капкасына борыны белән барып төртелгән иде. Абыстай, серне ялчыга белдермәс өчен, үзе тугарып бәйләде дә арбадагы нәрсәләрне карый башлады, һәрвакыттагы шикелле әле дә аның күңеленә шул килде: «Менә Ходаның хикмәте! Үзе берни белми, аягына баса алмый, теле сөйләми – ничек соң бу әйберләрен алдыртмый?..»

14

Хәзрәт шул көнне төштән соң гына уянды. Мунча ягулы, аш хәзер иде. Йокыдан торганда кәефе начар булса да, болардан соң, табигый, гади хәлгә килде.

Ул киткәч, Зыя белән Сабирдан хат килгән иде. Чәй янында абыстай анларны бирде. Ләкин мулла укымады, башын аска игән хәлдә: «Ни язганнар?» – дип

---

[1] *Изтыйраб* - борчылу
[2] *Габи* – аңгыра, җүнсез.

сорау белән генә канәгатьләнде...
Абыстай үз кулына алды да укып чыкты.
Мулланың йөзенә тиз арада тагы ачу калыкты:
– Сәламнәре дә кирәкми, үзләре дә! Алар минем кадеремне белмәсә, мине ата итмәсә, мин дә ялына торган кеше түгел... Мин гомеремдә кешедән бер кыл чаклы нәрсә алганым, ярдәм күргәнем юк... Әлхәмделиллаһ, бар да бар, бар да патшаныкы кебек... Мин кешегә ялына торган адәм түгел... Мин кыйлганмын һәм кыйлырмын...
Абыстай бәхәс итмәде, җавап та бирмәде, һәм мөмкин дә күрми иде. Чөнки мулланың сүзе кызып та, тиргәнеп вә ачуланып та түгел, бәлки әллә нинди ят һәм яңа бер тавыш белән, әллә нинди хаклы, бик хаклы шелтә сыман чыга иде.
Чәй ахырына таба Зөләйха ике кечек угылын мәдрәсәгә җибәрер вакыт җиткәнлеге хакында сүз кузгаткан иде, Җәләл аңа да салкын карады:
– Җә, кая ашыгалар, барырлар әле! Хатынының дәлилләре, теге ике угылның болардан кечкенә чакта ук зур мәдрәсәгә баруы хакындагы сүзләре дә хәзрәткә тәэсир итмәде:
– Җә, кая ашыгалар, барырлар әле!
Ул артык сүз әйтмәде, ләкин эчендә икенче бер казыя[1] бар иде: «Җә, кая ашыгалар; барсалар, күрше авылның берәр мәктәбенә барып ятырлар әле. Тегеләреннән ни чыкты... Укысалар да, барыбер мөдәррис тә булмыйлар, ахунлыкны да алмыйлар. Аталык әрәм... Иҗтиһад әрәм...»
Башында калган шул сүзләр артыннан аның зур угыллары, анларны укытырга дип җан атып йөрүләре; кеше күрсеннәр, үзләрен күрсәтсеннәр дип, һәркайда олуг адәмнәрдә, бөек мәҗлесләрдә булдыруы; анларга ничаклы акча түгүе; анларны ничек һәр җирдә күтәрергә тырышулары; аннан соң Зыяның хезмәттән котылуы өчен, Сабирга кала хәзрәтенең кызын алу турысында, рәхәтен, йокысын калдырып, малын түгеп, ничаклы мәшәкатьләр чигеп, башын авырттырып йөрүләре; шул мәшәкатьләр, шул рәхәтсезлекләр, шул иҗтиһад вә хезмәтләр бәрабәренә ул ике баланың ата теләгенә шул рәвешле мокабәлә[2] итүләре – берәм-берәм Җәләлнең зиһененнән кичте, һәрбере авыр, һәрбере агулы һәм чәнчеп ала иде. Хатирә актык ноктага, шул иҗтиһадлар соңында Зыя белән Сабирның моңа хәзерге мөнәсәбәтенә килеп җиткәч, карт күңел түзмәде, күзләрдән берәр бөртек яшь чал сакал буенча мөлдерәп китте.
Болар – кайгыдан, үкенүдән түгел, бәлки карт күңелнең рәнҗү белән әрнү һәм шелтә катыш бер тәэсиреннән иде.

---

[1] *Казыя* – мәсьәлә.
[2] *Мокабәлә* – каршылык.

Шуның артыннан ул көндә ахун белән булган сәхнә, аның сәбәпләре, шикаятьләр һәм указны ташлаулар, бер-бер артлы авыр күренеш белән аның күз алдына килеп, изә башлаганнар иде. Ләкин ул җиңелмәде, күзен бакчадагы зур имәнгә кадалган хәленнән алды да, чынаягын каплап, урыныннан торды:
– Яңа тимер арбаны майласыннар да йолдыз кашканы кечкенә камыт белән җиксеннәр... Миңа акчадан ике кәгазьне куй... Букчага кирәк киемнәрне тутыр!.. Теге документ та онытылмасын...
Ун минуттан мулланың һәммә боерыгы җиренә җиткерелеп, җигүле ат та ишек төбенә килеп туктады. Ул үзе дә киенеп булган иде. Абыстайга һәм ялчыларга, фәләнне фәлән, фәләнне төгән кыйлыңыз дип, берничә төрле әмер бирде. «Мин падишаһ; миндә кешенең ни эше бар!» дигән бер кыяфәт белән киберле генә бер сыйфатта утырды да кыйблага карап юнәлде...

15

Җәләлнең бу сәфәре бик озак булды. Ул ундүрт көн тулып, унбишенчегә китте дигәндә кайтты. Көндез; тәмам аек хәлдә. Янында зур угылы Сабир да бар иде. Балалар моны күргәч, аталарын онытып: «Абзый кайтты, абзый кайтты!» – дип, Сабирның муенына асылдылар.
Зөләйха абыстай шаша калды, ул күзләренә ышанмый иде. Бу – өнме, төшме? Йа Ходай, бу нихәл? Моңа шатланыргамы, әллә куркыргамы? Балаларның шатлыгына, сикерүләренә чама да юк. Бу хәлнең төш түгеллегенә, күзләренең алдамавына ышанып җиткәч, баласын күрү тәэсиреннән бераз айный төшкәч, абыстай да бу көннең махсус җибәрелгән бәйрәм икәнен, зур шатлык бар икәнен тоя башлаган иде. Угылы белән иренең бер-беренә боздай салкын торганнарын, боларның һәр икесе, гомумән, әллә нинди авыр вә фаҗигый бер хәл астында шикелле йөргәннәрен күргәч, ул тагы аптырый төште, аның шатлыгы тагы югалып, курку белән куаныч арасында калды.
Хәзрәт калада, башка эшләрен башкарып, үзенең авыр карарына килгәч, тоткан да Сабирга: «Мин хаҗга китәм. Тиз кайтып җит!» – дип телеграм биргән. Тегеннән: «Ярар!» – дип җавап килгән. Һәм, атасы ерак сәфәрнең кирәк-ярагын вә башка эшләрен бетергәнче, Сабир поезд белән калага килеп тә төшкән. Анда очрашканнар да бергә кайтканнар.
Менә эшнең бөтен тарихы шул.
Сабир шуны сөйләп биргәч, абыстайның йөзе агарды; иреннәре үз алдына, нindидер бер мәртәбә генә кыймылдап, күгәрделәр, күзләре әллә нинди бер изтыйраб катыш хәйрәт белән тулып, тәрәзә аша ерак күккә кадалдылар. Ул җә һуштан язачак, җә акырып елап җибәрәчәк иде, тик мулласының авыр кыяфәт, салкын вә караңгы йөз белән ишектән килеп керүе генә аны тыеп калды.

Абыстай ни әйткәнен үзе дә җүнләп белмидер иде бугай, ишектән Җәләлнең кереп җитүен көтмичә үк, әллә нинди, артык түбәнсетелгән, артык хурландырылган йөрәктән чыккан сыман әрнүле вә ачулы тавыш белән кычкырып җибәрде:
– Син ни эшлисең, Илаһым?! Мин синең кемең соң? Әлләниләр уйлый, әллә ниләргә ният кыйла... Миңа, ичмаса хәтер өчен дә: «Шулай итмәкчемен!» – дип авыз ачмый... Илаһым, базарга бару түгел ләбаса... Хаҗга китәсең ди бит?!
Мулла, һичкемгә карамыйча, илтифат итмичә генә, авызыннан бернәрсә аткан кебек кенә, берничә сүз ташлады:
– Барсам, ни була ди... Теләдем – бетте. Китәм дә барам... Мин гомердә кеше белән эш иткәнем юк...
– Соң, Илаһым, барсаң барыр идең... Мин койрыгыңа ябышмас идем... Ул бит базарга барып кайту түгел... Кеше анда да җәмәгате, бала-чагасы белән киңәшә... Яхшымы, начармы, мин синең утыз еллар бергә торган хатының. Күңел өчен бер сүз әйтер идең... Мин алты баланың анасы...
Абыстай эченнән ташып килгән дулкынга түзмәде: аның бугазы тыгылды, тавышы үзгәреп, үз сүзенә үзе буылып, күз яше туфанына тотылып калды.
– Әйтче зинһар, сиңа кем тигән! Минем эшем беткән. Билетым алынган. Юлдашлар хәзерләнгән. Елыйсы да юк... Кайгырасы да юк... Балалар анасы булсаң, бар да үзеңә кала... Үзеңә булсыннар...
Баштан бирле һични аңламый аптырап торган балалар, берьюлы кычкырып еглап, аталарының кулына, муенына килеп асылдылар. Абыстай күз яшенә буыла-буыла ниләрдер сөйләде дә тынды.
Мәсьәлә карар бирелгән. Беткән. Җәләл иртәгә, иртәнге намазны укыгач, сәфәргә чыга. Абыстай артык сүз кузгатмады, елап арыган, күз яше белән хәлдән тайган адәм сыман, иренең юл ярагын хәзерли бирде. Хәзрәт борын гади генә эшләрдә дә көн элек сөйләп, алай итсәм ничек, болай кыйлсам ничек дип уйлашкан булып йөри, мин фәләнчә эшне ният итәм бит әле, дип сөйләп йөри торган иде.
Бу тугрыда исә үз теленнән һичкемгә әйтмәде, картларга да хәбәр иттермәде. «Теләдем – бетте, вәссәлам!» Башка адәмнәрнең хаҗга барачагы берәр ел әүвәл мәгълүм булып, ул көнне зур бәйрәм кебек каршы алалар. Булачак хаҗины озатырга бетен авыл җыела; аның белән елашып, кочаклашып күрешәләр; һәммәсе сәдакалар бирәләр... Юл уңаендагы авылларда да аны каршылыйлар, кунаклыйлар, елашалар, кочаклашып күрешәләр, ду килеп, бөтен авыл кузгалып озаталар иде. Җәләлдә, бәлки, артык та булыр иде, ләкин ул нә сөйләде, нә хәбәр итте, нә күрешергә теләде!

Белгәннәр, белеп, килеп күрештеләр, аптыраштылар; елаучылар да булды. Белмәгәннәр, азактан ишетеп, хәйран булырга калдылар.

Көн, аның артыннан төн килеп кичте. Вакыт керү белән, азанны көтмичә үк намаз укылды да, караңгылы-яктылы чакта Җәләл озак сәфәргә юнәлде, – хаҗга, Кәгъбәгә!

16

Атасын поездга утыртып, үзенең төшкән номерына кайткач, Сабир энесенә хат язды:

«Зыя туган!

Атайны хәзер генә Хиҗазга озаттым. Хаҗ кыйлам, ди. Ләкин мин икенче төрле карыйм. Бу хаҗга китү түгел – бу аның хәят трагедиясенең актык пәрдәсе. Моңа син дә сәбәп, мин дә сәбәп; бигрәк аның үз табигате сәбәп; заман вә әхваль сәбәп... Сиңа ничек күренәдер, мин бу эшкә үзенә бертөрле булган самоубийство[1] дип карыйм, һәм мин атайның хәят трагедиясе-комедиясенең бу рәвешле барып чыгуын бик табигый күрәм... Аны кайтыр дип тә уйламыйм. Мин аның белән күп сөйләштем...»

17

Бер дә көтелмәгән, һичбер вакыт зиһененә яңлыш кына да кереп чыкмаган, шуның белән бергә, ялтыраган яшен кебек бик тиз генә килеп кичеп тә, аның хәятында әллә ничаклы үзгәреш биргән бу сәфәр абыстайны әллә нинди бер халәттә калдырды. Ул, ни эшләргә аптырап, гүя үз йөрәгеннән үзе сорады:

– Кайгырыргамы, еларгамы? Шатланырга, әллә юкса, бәйрәм итәргәме?

Җавап бик тиз бирелмәде.

Аңа авыр да кебек, бу эш аның хәятын әүвәлгедән әллә ничә өлеш каралтыр, аның бәхетсезлеген тагы да арттырыр кебек. Менә ул бар иде – яманмы, яхшымы ир иде. Ир хакы – Алла хакы, дигәннәр. Ул аны яхшылап үти алдымы? Ай, бик шөбһәле шул! Китаплар аны бик зур күрсәтә... Ир хакын үтәмәгән хатыннарның тәмугта күрәчәк авыр газаплары да бик куркыныч рәвештә тасвир ителгән...

«Илаһым, мин шулкадәр бәхетсезмени?.. Ике көнлек дөнья өчен тәмуг газабына мөстәхикъ[2] булып калдыммыни?.. Раббым, хуҗам!»

Авыр уйлар вә тирән шөбһәләр белән газапланган минутларда бу дәһшәт аның җанын тетрәтсә дә, гади вә табигый хәлгә кайткач, ул тагы ике катлана, тагы теге курку янында аның киресе булган бер куәт урын ала иде.

Болай гөнаһлы, бик гөнаһлы кебек, ир хакын үти алмады кебек. Шуның өчен

[1] *Самоубийство* – үз-үзеңне үтерү

[2] *Мөстәхикъ* – лаеклы.

аны мәңгелек газап көтәдер кебек... Ләкин вөжданының яшерен бер ноктасы йөрәгенең төбеннән, әллә кай җиреннән килгән эчке бер тойгы икенче нәрсә сөйлиләр, – болар тәэсире белән ул җуаныч таба, үзен аклаячак юллар күрә, ничек тә мөбһәмлек[1] вә томан эченнән аглаган йөрәген җуатачак, вөждани мәсьүлияттән коткарачак бер нур, бер өмит сизә...

Үткән һәрбер сәгать, һәрбер көн бу икенче тойгыны куәтли төшеп, абыстайның йөрәге тына, ир хакы куркынычы үзенең тәэсирен югалта бара иде.

18

Башкалар адәм ышанмасны сөйләмә дисәләр дә, Сабир үзенең «ул кайтмый» игътихатында нык торды һәм, анасын-фәләнен бераз җуаткач, инде утырырга вакыт дип, сызганып эшкә тотынды. Йортта мал-туар күп, иген-таруга байлык исә дә, акча калмаган, өстәвенә Җәләл йорт-җирне дә китәр алдыннан рәһенгә[2] салган иде. Сабирның үзендә бераз акча бар иде, аның өстенә, ел әйләнәсенә – яңа ашлыкка җитәрлеген чамалап калдырып, артык игенне сатты да иң әүвәл йорт-җирне рәһеннән чыгарды.

– Утыргач, нык утырырга һәм ояңны үзеңнеке итәргә тиеш! – ди.

Икенче мәсьәлә – өйләнү иде.

Ул моны берәүдән дә яшермәде. Анасына турыдан-туры сүз ачып:

– Җә, әни, миңа таза беләкле бер кыз табыйк. Без аның белән эшләрбез... Син намазыңны укып, тәсбихеңне тартып утырырсың, – дип шаярды.

Беркөн базарга барганда Җаббар мулла белән очрашкан иде. Ул башта, дөнья күргән, күпне белгән адәм дип, Сабирдан тартыныбрак торса да, моның һәр турыда ачыктан-ачык бәргәнен күргәч, берьюлы үзенең Җаббарлыгына төште дә, табам, үзем табам, дип, бөтен тирә-якның кызларын сөйли башлады. Боларның өстенә теге яшерен шагыйрь Кәрим мәхдүм дә килеп кереп, мәсьәлә тагы куерды.

Җаббар тирә-якның шәп кызларын саный тора, шагыйрь исә аның һәр сүзенә каршы бара иде.

– Менә безнең авылның Садыйк кызы бар. Таза, матур, уңган кыз. Җиһаз дигәнең исәпсез... Атасы тирә-якның бае. Кызымны укыган адәмгә бирер идем дип җан ата. Мал-туар, йорт-җир синекеннән бер дә ким түгел, – ди Җаббар...

Шагыйрь аңа сөйләп бетәргә дә бирми:

– Менә таптың кыз! Әлифне таяк дип белми. Атасының байлыгы белән ни кыйласың... Ул үзе бик ашкынган нәрсә дә бугай. Сабир әфәндегә бит тән белән бит кенә кирәкмидер, мал да матлуб түгелдер... Җаны да, йөрәге дә, аң вә

---

[1] *Мөбһәмлек* – билгесезлек.

[2] *Рәһен* – заклад, залог.

белеме дә булырга тиештер...
Сабир шагыйрьне бүлә:
– Юк, туган! Мин башкачарак карыйм. Дөрест, мин мал эзләмим, иптәш эзлим, кыз эзлим... Ләкин мин укуына һичбер әһәмият бирмим. Әлифне таяк дип, вауны чукмар дип белми икән – минем өчен ул бернәрсә дә түгел. Миңа иң мөһим нокта – аның табигате. Ул тере булсын, артык җанлы булсын, мин үзем дә авыр, басынкы кеше. Хатыным да шулай булса, безне җир күтәрә алмас... Шуңа күрә, очып торсын, үләм дип аска карап йөрмәсен, хәятлы, хәят дәртле булсын. Фәгъгаль[1] булсын... Шул сыйфатлары табылып, укымаган булса – минем өчен ул бигрәк мөнасиб. Ул зат укымаган, димәк – яратылышы, табигате, табигый нәфасәтләре[2] үз хәленчә, бөтен көенчә калган; тышкы тәэсирләр белән, кешедән, китаптан алган сүзләр белән бозылмаган димәктер... Бу – гаҗәиб табигать булырга тиеш. Мин, мөмкин булса, гыйлем вә мәдәният дигәннең төсен дә күрмәгән, уку вә китап дигәннең исен дә иснәмәгән бәдәви[3] кызлары эченнән шундый бер табигатьне сайлап алыр идем... Аннан соң, әллә нинди назик хисле, шагыйрь кыяфәтле булсын дигән теләгем дә юк. Чөнки мин гыйшык эзләмим... Ул күрер күзгә чибәр, таза, табигый гакыллы булса, шуның өстенә баягы сыйфатлары да кушылса, минем дигәнем булды.
– Ләкин шул җәһәт бар: берәүгә ошаган икенчегә ярамаска мөмкин.
– А... анысы бик бар. Мин, хур кызы дип мактасаңыз да, сезнең коры сүзеңез буенча башкода җибәрү ихтималым юк... Мин аны үзем күрергә тиеш. Аннан соң, аның табигате үзем теләгәнчә икәнен белү өчен, аның хәятында булган бераз вакыйгаларны ишетергә кирәк. Минем дәгъвам бар, кыйлган кылыкларыннан беразын сөйләсәләр, шуннан мин аның табигатен үтә күрермен, җанына керермен дип ышанам.
Бу эш хакында Җаббар үз өстенә йөкләтелгән бер фарыз шикелле итеп тырышты. Ул Сабир белән борыннан ук таныш булса да, әле бигрәк якынаеп китеп, бер аңа килә, бер үзенә алып китә, шулай итеп, ду китерә иде. Күп сүздән, күп кыздан соң кемдер теге Госман мулланың икенче балдызы Камиләне искә төшергән иде.
– Ә, менә таптың... Менә таптың... Башта ук ничек гакылга килмәгән ул, – дип, Җаббар тиз үк эләктереп алды да: – Озын буйлы, таза тәнле, кара туткыл йөзле, зур кара күзле, төрек борынлы; бик дәртле, бик уенчак. Сүзгә бик шәп, биюгә

---

[1] *Фәгъгаль* – эшлекле, актив.
[2] *Нәфасәт* – гүзәллек, матурлык
[3] *Бәдәви* – күчмә тормыш белән яшәүче, культурасыз кеше.

авылда беренче, – дип, аны тәүсыйф итәргә[1] кереште һәм аның күп егетләр тарафыннан, хатының булса, өстеңә менеп атланыр ул, дип сөйләнгәнен батырлыгына, куәт вә ныклыгына дәлил итеп зикер итте.

Сабир, аның хакында бераз сүз ишеткәч үк, куәтле бер мәел[2] сизеп, хәтта: «Бетте, шуны алам!» – дип эченнән уйлап та куйды. Ләкин бөтен ягын өйрәнеп бетү өчен һаман сөйләндерде. Җаббарның һәрбер сүзе Камиләнең хәятыннан яңа сәхифәләр ача бара, баета бара; боларның һәркаюсы Сабирны ныграк тарта баралар иде. Хосусан бер хәрәкәте бигрәк мөмтаз[3] тоелды.

Уку бабында ул үзенең апасы Фатыйма белән бөтенләй кара-каршы табигатьтә булган. Ул әүвәл, абыстайга сабакка барырга мотлак карышып, елап, бармаган. Берничә ел шулай үткән. Уникеләргә килгәч, әллә нинди тәэсир белән көчләнеп, бер кыш йөргән икән. Анда да укымаган, кызлар белән шаярып, матур китап тоткычлары ясап тик гомерен үткәргән, һәм шунда бер нәрсә алмыйча, бер хәреф тә башына кертмичә, хәтем итеп[4], ничаклы көчләсәләр дә, артык укырга якын да килмәгән. Апасы белән аны да кызлар мәктәбенә җибәрергә уйлаганнар икән, ул бәйләп илтсәңез дә бармыйм дип каршы торган.

– Булмас, атакай гынам, булмас дигәч булмас... Китап укыйм дип, энә очы кебек нәрсәләр белән чокынып утырыр хәлем юк... Булмас дигәч булмас, яратмыйм мин шундый юк нәрсә белән чемченеп утыруны! – дигән.

Моңа каршы Сабир ышанырга да, ышанмаска да белмәде:

– А... чыннан да гаҗәиб нәрсә икән... Бу факт үзе генә дә ул кызның табигате, куәте хакында бик күп нәрсә сөйли. Әйтергә мөмкин, артык тәгърифкә[5] хаҗәт тә юк. Мин озак уйламыйм, ул кыз-арыслан белән күрештерә дә алсагыз, мин карар бирәм.

Бу соңгы шартны китерү Госманга тапшырылган иде. Ул бер дә мәшәкатьсез үк булдырды.

Ул Камиләне үзенә утырмага дип алып килде дә, билгеле бер вакытны үзенең хатынын каядыр озатып, башкаларны да тараткалап, шул сәгатьтә Сабирга килергә кушты.

Камилә теге вакыттан соң бик тиз үсеп тә, җитеп тә, башкаланып та киткән иде, җизнәсенең Сабир белән күрештерү хакындагы планына бер дә исе китмәде:

– Ник күрешмәскә? Теге вакытта мин аның энесеннән качкан идем... Анда мин бала идем... Хәзер нигә күрешмәскә? Тулке кеше генә белмәсен... Кара берүк,

---

[1] *Тәүсыйф итү* – сыйфатлау.
[2] *Мәел* - теләк
[3] *Мөмтаз* – шәп, аерылып торган
[4] *Хәтем итү* – тәмамлау.
[5] *Тәгъриф* – сөйләү, аңлату.

үзеңнән башка бирәү дә белмәсен, – диде.

19

Эшләр уйлаганнан да тизрәк китеп, егет яратты, кыз риза булды, ата-аналар да каршы бармады, – шулай итеп, Камилә Сабирның кочагына атылды.

Рәсми сүз җибәрүнең башында ук Сабир: «Мин ел буенча кияүләп йөри алмам. Туйдан соң бер барып кайтырмын да икенчесендә йортка китерермен, мин ялгыз кеше...» – дип әйттергән вә шуны шарт кыйлган иде.

Камиләнең ата-аналары, ил җоласын кыйлмый ярамас, күп вакыт юк бит, йортына алуны җәйгә кичектерсен иде, дип карасалар да, Сабир якын килмәде; тегеләр дә, башка һәммә турыда килешеп беткәч, бер моның өчен генә эшне бозарга теләмәделәр. Кыз үзе дә: «Ерак җир түгел ич. Сагынып үлмәм әле», – дигәч, «Җә, ил сүзе бетмәс, сөйләр-сөйләр дә, арыгач туктар», – дип, Аллага тапшырдылар.

Туй үткәнгә егерме көн булды дигәндә, Камилә Җәләл мулланың йортына килен булып төште.

Менә ул вакытта: «Мин соң анда, әллә нинди егетләр янына чыгып, сынымны күрсәтеп йөримме!» – дигән Камилә, хәзер шул егетнең йортында, ак беләген сызганып, яулыгын артка бәйләп, алъяпкыч ябып, эшләп йөри.

Аңа яшь килен диләр. Ләкин күпләр бу сүзнең аңа килеп бетмәгәнен ачык күрә. Сабир, юк мәшәкать дип, бөркәнчек (кушъяулык) ябындырмый. Камилә дә, бөтен ил гадәтенә каршы барганлыгын илтифатка алмыйча, иренең сүзенә шатлана гына...

Аннан да бигрәк, ул үзенең сүзе, торышы белән дә бер дә яшь киленнәргә охшамый. Әйтерсең, шул авылда, шул йортта туып, шунда үскән – шул дәрәҗәдә иркен кыйлана. Җүнләп качмый, өлкәннәр бар дими, үз дигәнен кыйлып, юк-бар сүз белән көлдереп, шаярып йөри... Ул булган җирдә уен, көлке, каһкаһә[1] күтәрелә, уңганлыгын, шәплеген, чибәрлеген һәммәсе тасдыйк[2] итсә, һәммәсе ул як белән мактасалар да, югарыгы эшләрен һичкем килештерми... Бирәүләр: «Килеп җитмәгән – йортка баш булган», – диләр. Икенчеләр: «Зөләйха абыстайның башына менеп утырыр бу явыз», – диләр. «Гомумән, яшь килен булгач яшь киленнәрчә булырга иде, берьюлы ул чаклы сикермәскә иде», – диләр. Абыстай үзе киленнән бик мәмнүн, аны бик ярата: «Башка каенаналар кебек гыйфрит булмам, үз балам итәрмен», – дип, аркасыннан гына кагып йөртә. Ләкин кайбер вакыт килененең артык иркен, артык уенчак кыйлануыннан да, пошаланып кына:

---

[1] *Каһкаһә* – кычкырып көлү.
[2] *Тасдыйк итү* – раслау, дөрес дип табу

– Балам, Сабир, безнең Камиләбез артык җиңел, артык җиңел лә! – дип куя. Ләкин шуннан үтми, аның хакында башкача әйтергә сүз дә тапмый...

Сабир бигрәк мәмнүн. Ул, гомергә үлек булган бу йортка тик Камилә аркасында гына җан керде, аның килүеннән соң гына да өйләрендә хәят башланды, дип уйлый һәм шулай хис итә.

Ул үзе дә бик эшчән булып китте. Аягына озын кунычлы пима (киез итек), өстенә, билен бәйләп, кыска тун, башына җонлы тышлы тирән бүрек, кулларына ике катлап зур күн бияләй кия дә чын бер йорт хуҗасы кебек булып эшләп йөри.

Бу хәлләргә карап, ана тагы аптырый башлый... Болар чынмы? Әллә төш кенәме? Ул соң шундый бәхеткә ирешә алдымыни? Ул Сабир кайтыр да хатыны белән аның алдында йөрер, мин шул бәхетле көнне күрермен өмитеннән тәмам аерылган иде. Шуңа күрә бу көннәр аңа артык көтелмәгән иде.

Шул бәхетләр тәэсире белән аның башлары әйләнгән булырга тиеш ки, ул угылының намазга бармавын һәм өйдә укымавын да күрмәс һәм аның әллә нинди машинист урыс кебек киенеп йөрүләренә дә сүз әйтмәс булган иде. Тик әллә нинди шатлык вә дустлык минутларында гына, ярым шелтә вә ярым иркәләү катыштырып:

– Куйчы, балам! Кайдан тапкансың шул җыен койрыксыз киемнәреңне! – дип куйса куя; ул да коры бер сүздән гыйбарәт булып, һичбер вакыт кабат тәкрар ителми, аңа гамәли нәтиҗә дә өстәлми иде.

Дусты Зыялар гаиләсендә тиз арада булып алган мондый зур үзгәрешләрне ишеткәч, түзә алмады, Мәрьям дә, иренең карышуына карамыйча, атна-ун көнгә дип, Кара урманга кайтты. Яшь килен Камилә белән махсус танышты, якынлашты. Бу йортка төшкән яшь килен аңа кызыгумы, кызганумы, әллә нинди бер тәэсир бирә иде. Камилә белән сөйләшә-сөйләшә, кайбер вакыт авыр мөтәэссир[1] хәлдә кайтып китә иде. Хәтта берничә мәртәбә бик юктан гына күзләре яшәргәнен һәм, шул ук минутта анасы өенә кайтып, үзенең кызлыгы үткән бүлмәсенә бикләнеп, бик озак елаганын сөйлиләр...

## 20

Майның соңгы көннәре иде.

Рәттән ике тәүлек яңгыр явып, бүген иртә белән бигрәк котырган, урамнар ап-ак суга әйләнеп, аяк атларга да хәл калмаган иде; тик менә төштән соң гына көн ачылып, болытлар таралды; кояш, зур бер шатлыкка каршы булган кебек, көлеп карый башлады, һавада дым катыш бер ләтафәт бар. Бөтен шәһәрдә агач вә

---

[1] *Мөтәэссир* – кайгы-хәсрәткә төшкән

үләннәрдән, чәчәкләрдән күтәрелгән бер тәмле, тик яшенле яңгыр соңында, җылы кояшлы һаваларда гына була торган һәйбәт ис аңкый. Гүя бу минутларда табигать бәйрәм итә, баглы күңелләр дә аңа кушылалар. Яңгырдан качып, тар, кысык биналарга, дивар эчләренә бикләнгән кала халкы, бу минутларны ганимәт белеп[1], киенде, ясанды да зур урамнарга, өлкән бакчаларга агылды. Озак яңгырдан, каты сагындырудан соң матур йөзен ачкан, кояшның нурларын киң күкрәгендә иркәләп уйнаткан сыман күренгән тигез, шома Идел өсте төрле төстәге көймәләр белән чобарланды. Анда өздереп музыка уйныйлар, монда матур тавыш белән җырлыйлар, тегендә – эчке шатлык. Чын бәйрәм куанычы белән рәхәтләнеп көлешәләр – һәр җирдә җанлылык, һәр җирдә хәят вә бәйрәм.
Мәрьям, чәен эчеп бетермичә үк стаканын каплады да мамык шәлен иңенә салып, өйләренең бакчага караган тәрәзәсе төбенә килеп утырды.
Бакчаның агачларыннан куәтле бер ис аңкый; халык – ирләр, хатыннар, яшьләр, парлап-парлап, шунда агылалар; музыка башка вакытта булмый торган бер тәэсир белән моңлана, нидер сөйли, каядыр чакыра, ниндидер үткән көннәрне үзенә хас бер тел белән хикәят итеп, әллә нинди вакытларны искә төшерә, кемнедер сагындыра иде.
Яшь ханым шәлен, урындыгын ипләп бетерергә өлгерә алмады, берәү, ишектән кереп, сиздермәс өчен аяк очы белән генә басып килде дә ике кулы белән арт яктан аның күзләрен каплады. Мәрьям, бу билгесез адәмне тану өчен, кулы белән аның беләкләрен, йөзен капшый башлады.
– Белдем, белдем, Нәгыймә апа, син икәнсең... Теге һаман кулларын алмый.
– Җә, дим, апа... Таныдым бит, җибәр инде... Ансыз да йөрәгем бик ярсып тора, җә берәр сүз әйттерерсең...
Нәгыймә кулларын алды да, урындык тартып, Мәрьямнең каршысына утырды.
– Җә, сөйлә! Авылда ниләр күрдең, ниләр бетердең?
Мәрьям теләр-теләмәс сөйләргә кереште: Фатыйма бикә сәламәт икән. Сәлам әйткән, алдагы числода үзе кунакка килмәкче... Бакчалары шәбәйгән, яшәргән... Бу ел тагы әллә нинди гөлләр утырткannar. Зөләйха абыстай бик шат гомер итә. Яшь киленне бик мактыйлар, ләкин артык үткен, артык кыю диләр икән. Сабир, билен бәйләп, беләкләрен сызганып, иген эшенә, баерга тотынган; көлеп, мин алпавыт булам, дип әйтәдер, ди икән... Аларнын атасы Җәләлдән бер дә хат юк, ди. Аның белән бергә киткән хаҗилар, бездән: «Минем зиярәт кыйласы җирләрем, нәзерләрем бар», – дип калган иде, дип әйтәләр, ди...
Нәгыймә кинәт кенә Мәрьямнең сүзен бүлде:
– Әй, шуны әйтим әле: мин бүген бик яман төш күрдем дә, әллә берәр хәл

[1] *Ганимәт белеп* – файдаданып, бәхет дип санап.

булдымы икән, булса, хат язар әле дип, почтадан, «Мәрьям Чалишевага до востребования хат юкмы?» – дип барып сорадым. Берсе, бар, дип алып бирә башлаган иде, икенче бер явызы килде дә, мине баштанаяк карап: «Ә, юк, ярамый... Мин аны таныйм... Сез ул түгел, бездә алай бирелми», – дип, кире салып куйды. Бирсә, күп булса бер тиргәр, бер үпкәләр дә бетәр, дип ачмакчы идем. Гөнаһ шомлык, бирмәде. Син калага ни вакыт кайттың? Ул хатны барып ала алдыңмы?

Мәрьям, бераз кызарып, апасының күзләренә карап, әүвәл елмайды, соңра, авыр сулап, җавап бирде:

– Алмаган кая, шунда ук алдым... Юл буена, әлбәттә, бардыр инде дип, ашкынып килгән идем. Калага керүгә, йортка кайтмастан, кучерга тугры почтага тотарга куштым... Алдым, берсе ябык, берсе ачык ике хат бар иде. Икесе дә аңардан.

«Аңардан»ны әйткәндә Мәрьям тагы кызарды.

– Җә, уналты яшьлек кыз кебек нигә кызарган буласың инде... Мин көчләмәдем, үзең бит барын да сөйләдең. Хатларын укы әле, ул, гөнаһ шомлык, бигрәк матур яза бит. Тик аның кайбер сүзләрен аңлап кына булмый... – Нәгыймә берәр минут сөкүт[1] итте дә кинәт кенә тагы башлады: – Әй, кара әле! Теге өч айлап туктап торганның соңында, әллә ничек үпкәләп, хәтер калган кебек итеп, бер хат язган иде бит. Шунысы аның актыгы төсле иде... Сез шуннан соң тагы ничек килештегез? Хәзер тагы әүвәлгечә яза башлады бит. Шуны һаман сорыйм дим дә онытам...

Мәрьям тагы бөтен күкрәген тутырып һәм авыр итеп сулады да апасының күзләренә карады:

– Булды инде, апа, анда әллә ниләр булды... Мин аны сиңа хәзер сөйләп бирә алмыйм. Сөйли дә белмим, сүз дә тапмыйм. Икенчедән, аларны куйыйк әле, анда минем ярама агу була торган күп эшләр бар...

Бераз авыр, табигый булган сөкүттән соң Нәгыймә тагы шул мәүзугны алды:

– Алайса, хәзергесен сөйлә, хатларын укы! Яратам шул егетне! Синең аркылы мин дә гашыйк булмасам ярар иде... Әллә ничек, шуның исеме үк йөрәккә бертөрле якын тоела...

– Әй, апа, син белмисең әле... Ул синең белән минем күргән адәмнәргә бер дә генә охшамый шул! Аның белән бергә утырсаң, сүзен ишетсәң, йөрәген белсәң, Ходаем, бәндә түгел, фәрештәнең үзе түзмәс.

– Беләм, Мәрьям, бик беләм. Утырганым булмаса да, синең аркылы беләм; рәсеме, хатлары белән беләм... Тик мин аптырыйм: ничек син бу хәлгә

[1] *Сөкүт итү* – эндәшми тору

тешәрлек мәртәбәдә йомшак булдың?.. Адәм әйтеп адәм ышанмаслык бер эш! Мәрьямнең, йөзе, берьюлы үзгәреп, әллә нинди авыр вә фаҗигый сыйфатка керде дә үз ирегендә булмаган бер ят тавыш белән кычкырып җибәрде:

– Куйчы, Илаһым, шул сүзеңне! Мең мәртәбә, йөз мең мәртәбә әйттем бит мин сиңа бу һәлакәтнең мине үз тырнагына ничек алганын! Анда мин башка идем... Әллә нинди сихерләргә җиңелдем... Хәзер булса, дөньяның җыен хәйләкәрләре, барлык шәйтан вә иблисләре бергә җыелып тозак корсалар да, мин битләренә генә төкерер: «Бәндә эшенә җиңелү түгел, Алла үзе төшеп әмер кыйлса да, мин, йөрәгемә каршы бара алмыйм, җанымны ал, үземне тәмугта сугар, – ризамын, ләкин бу тәклифеңне[1] куй!» гына дияр идем.

Нәгыймәнең дә йөзенә икенче төс чыкты.

– Юк, Мәрьям, син ачуланма: мин аптыраганнан гына әйтәм... Хатларыңны укытмыйсыңмыни?

Мәрьям як-ягына каранды, торып, ишекне элде дә, күлмәкләренең әллә нинди эчке вә яшерен җиреннән ике хат чыгарып укый башлады.

Һәр ике мәктүб бик дустанә язылган, һәр икесе баштанаяк сөю, сагыну аңкытып торалар иде. Шуның белән бәрабәр, аның соңгы хатларының күбендә булган кебек, бу икесендә дә газап вә изтыйраб[2] күп урын алган иде. Ул, күп нәрсәдән бәхәс итеп, җанының әллә кай җирләрен ачып бирә, андагы бәхет вә газапларны бербер сөйли: язмышы, хәяты хакында әллә нинди дулкыннар, карарсызлыклар, изтыйраблар вә шулар белән янәшә үк булган сәгадәтләр хакында фөрьяд[3] кыйла.

«Белмим, газизем, белмим... Ни дияргә дә аптырыйм, мин әллә бик зур бәхетлемен; әллә Ходаның ниһаясез мәртәбәдә бәхетсез бәндәсе, язмышның артык каһәрле колымын. Миндә ничектер газап белән сәгадәт бергә, бер минутта җыела ала. Минем хәятым – җәһәннәм белән җәннәтнең һәр икесен үзендә җыйган, берләштергән...

Беләсең, мине «музыка тилесе», диләр. Чыннан шулаймындыр. Гомерем буена шуны эзләдем. Үземне белә башлаганнан бирле шуның өчен газап чигәм. Беренче сиңа табынсам, икенче – музыкага! Синең бирдегең мәсгудиятле минутлардан башка, мин тагы аның аһәңе белән дә сәгадәт табам... Күп газап биргән шул афәт миңа иң бөек ләззәтләр, кыйммәтле секундлар да һибә[4] итә. Ләкин... ләкин монда бик авыр бер җәһәт бар... Мин башкалар тарафыннан уйналган музыкага, теләсә кем, теләсә нинди зур мәһарәт белән, теләсә ничек

[1] *Тәклиф* – көчләү, мәҗбүриләү.
[2] *Изтыйраб* – көенү, борчылу
[3] *Фөрьяд кыйлу* – аһ-зар итү
[4] *Һибә* – бүләк.

кенә уйнаса да, һичбер вакыт канәгатьләнә алмыйм. Ул яхшы да була, тәэсир дә итә, ләкин минем ноктама җиткерә алмый. Менә үзем уйнарым, музыка сәнгатендә башка һичкем ирешмәгән бер серне ачарым – шул һәм теге ноктага ирештерер; шул минем музыка дигәннән көткәнемне тәмамы белән бирер кебек тоям... Һәм шуны булдырырлык куәт үземдә бар төсле. Менә, менә шуңа җитәм төсле. Мәдрәсәне ташлап, башым-аягым белән музыкага чумган; әнә синең белән теге шәһәр бакчасында музыка астында беренче мәртәбә кавышкан заманнарымызда мин шул серне табарга якынлашкан; менә-менә әллә нәрсә генә кирәк тә һәм шул үз алдына килеп чыга да, мин теге ноктага ирешәм; шул минем җанымны, бер минуты бөтен кяинатка торырлык ләззәткәме, бәхет вә сәгадәткәме тутырыр шикелле иде... Ни диим, әйтергә телем бармый, шуннан бирле тырышам, янам, шуннан бирле газап эчендәмен; шул ноктага җитә алмау үз сәнгатемнән үзем канәгать итә алмау, эзләгәнемне таба алмау җәһәннәмендә янамын... Булыр төсле... Менә, менә ирешелә төсле. Ләкин юк, булмый, табылмый. Күп тырышам. Нәзари вә гамәли күп нәрсә өйрәнәм. Начар да димиләр... Ләкин нидер җитми, нидер тулмый...

Була төннәр, башка һичбер иштиһа[1], һичбер теләк, һичбер дәрт аңа тиңләшергә мөмкин булмаслык мәртәбәдә бер музыка теләге, музыка дәрте бөтен рухыңны каплап ала. Дөнья тын, караңгы... Һәммә җан иясе тирән йокыда... Шул вакыт акрын гына торасың да, эчке дәрттән үз алдына калтырап барган кулларыңа мәңгелек дустың скрипкаңны алып, җай гына, сак кына сызып җибәрәсең... Артык бернәрсә калмый, шуның белән дигәнең тәгәлләнде: дөнья бетте, җир-күк каядыр югалды; үзең онытылдың... Йөрәгең ни беләндер тулып ташты; җаның гарешкәме, Тәңренең үз тәҗәлласы[2] каршысынамы очты... Беттең, беттең... беттең...

Ләкин бу – минутлар гына була. Бераздан син тагы җиргә төшәсең, тагы үзеңнең тәнеңне, кулыңдагы скрипкаңны тоясың. Җаның эчеңә сыймый, йөрәгең, читлектәге кош кебек, нидәндер тарсына... Син тагы айнып, теге җитешмәгәнлек ачысын татый башлыйсың. Тагы эчеңдәге дәртне кандырырлык сәнгатьле була алмавыңны, кулың йөрәгең чаклы музыкалы яратылмавын сизәсен. Тагы газап катыш сәгадәт; тагы сәгадәт эчендә газап, җәннәт эчендә җәһәннәм... Хәятымның бу фаҗигасе соңгы вакытларда бигрәк ачы, бигрәк үткен хис ителә башлады.

Шулар мине авыр бер изтыйрабка китереп чумдыра: мин, дим, җә иртә, җә соң – һәрхәлдә вакытсыз туганмын... Җә булмаса, бу мохиткә, бу сәнгать белмәс

---

[1] *Иштиһа* - теләк

[2] *Тәҗәлла* – нурлы чагылыш.

тупас табигатьләр эченә яңлыш ташланганмын... Ничек кенә булса да, табигать мине хәлык кыйлганда[1], бер гайре табигыйлек, бер мантыйксызлык кыйлган булыр, дип аптырый башлыйм... Әллә булырмы икән?.. Әллә минем сәнгатем бервакыт эчемдәге дәртне канәгатьләндерерлек мәртәбәгә җитәр, мин теге серне табармын, теге ноктага ирешерменме икән?.. Әллә минем кулымның йөрәгем, җаным эзләгән бөек ләззәтне бирә алырлык көне алдамы икән әле?.. Белмим, ни дияргә белмим...»

Шул җиргә җиткәч, кемдер ишекне шакылдатты. Мәрьям бик ашыгычлык белән хатларын эчкә тыкты да ишеккә барды: анда зур мыеклы бер урыс килгән икән, Адамашевның квартиры шулмы дип сорый. Хатын ачуыннан кулын селекте дә, юк, монда түгел, әнә янәшә йортта дип, ишекне яңадан элде.

Нәгыймә әллә нинди бер тавыш белән:

– Фу, ләгънәт, әдәмне бүлдереп йөри... Җә, укып бет инде... – диде.

Мәрьям тагы башлады.

«. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Ләкин, ләкин бернәрсә мине җуата. Бер һәдиясе өчен мин язмышның барлык мәгънәсезлекләрен гафу итә алам. Ул һәдия дә – син һәм сиңа булган мәхәббәтем.

Менә шуның өчен мин Тәңрегә мең ел сәҗдә итәргә үземне бурычлы саныйм; шуның өчен аны гадил[2], дим, гали[3], дим.

Дөньяда ничә җан булса, шунча йөрәк, шунча табигать бар; һәм шунча теләк вә әмәл бар. Берәү берне, берәү икенчене эзли. Һәммә кешенең һәммә теләге табигый, һәммә эше хак вә тугры. Шуңа күрә дә һичкем һичбер төрле теләге, һичбер төрле әмәле өчен гаепле дә түгел, мәсьүл ителергә дә ярамый... Чөнки – табигый. Алла мине сөяр өчен яраткан, йөрәгемә сөю җәүһәрен куйган. Шуңа күрә сөюне теләү, аны бер рухани зарурат итеп хис кыйлу – миңа табигый.

Әгәр дә мин моның белән генә калдырылган булсам, хәятым бер трагедиядән гыйбарәт булыр иде – Тәңрегә артык зур голүвиятен[4] күрсәтергә ни өчендер лазем булган да, ул мине сөючән табигатем, сөю җәүһәре булган йөрәгем белән синең юлыңа куйган. Сиңа очрап, йөрәгемдәге бөтен гыйшкымны сиңа хәсер итәргә[5], синең алдыңда сәҗдә кыйлырга имкян биргән; моның белән дә калмыйча, минем табигатьле адәмнәр өчен, дөнья вә кяинатны бер якка ташлап, ихтыяр итү лазем һәм табигый булган икенче бер бөек бәхет – сөелү сәгадәте дә

---

[1] *Хәлык кыйлу* – барлыкка китерү, тудыру.
[2] *Гадил* – дөрес хөкем итүче.
[3] *Гали* – бөек, олуг
[4] *Голүвият* - бөеклек
[5] *Хәсер итәргә* - багышларга.

хәзерләгән.

Менә бу минем хәятымның нурлы ягы, бу җәннәте!

Болар булгач, боларның барлыгын тоя алгач, мин язмышыма үпкәләргә үземдәге хакны югалта башлыйм... Минем хәятым ни белән тәмам булыр? Мин тагы ниләр күрермен? Анысы минем өчен икенче дәрәҗәдә эш... Мин хәзер үкенмим – дөньяга килдем һәм яшим. Чөнки сөям һәм сөеләм. Моның нәтиҗәсе мөһим түгел, чөнки бу – үзе нәтиҗә, үзе максат, үзе гая[1].

Мин, бәлки, калган гомеремнең барын газапта, барын кайгыда кичерермен... Бәлки, шул сөю үзе үк минем эчемдә зур җәһәннәмнәр ягар. Ләкин ни генә булмасын, һәммәсе икенче дәрәҗәдә – синең бер сүзең, бер карашың боларның барын юк итә.

Без, бәлки, күрешә алмабыз; без, бәлки, мәңгегә аерылганбыздыр. Ләкин без табигатемез теләгендә яшәдек, без мәхәббәт илаһысына самими гыйбадәтебезне вакытында самимият белән үтәдек.

Хәзерге хәятның мең газабын ул үткән көннәрнең иң гади бер хатирәсе юкка чыгара ала... Шуларның һәммәсе белән бәрабәр, әле мин өмитсез дә түгелмен, киләчәк көннәрнең, берендә синен белән кавышу сәгадәте минем хыял күгемдә туктаусыз ялтырамактадыр...»

Кемдер тагы ишек какты. Мәрьям дә, «инде бетте» дип, хатларын эчкә үк салды да барып ишекне ачты. Анда хадимә бар икән.

– Сучы хатыны килгән, акча сорый, – ди. Ханым, йөзен чытып, авыр гына сулады да:

– Бар, иртәгә иртүк килер, хәзер бер дә вагым юк, дип әйтә, диң, – диде.

Үзе, тагы баягы урынына килеп утырып, бакчага карый башлады.

Анда халык һаман тулы; музыка һаман моңланып, нидер сөйли, каядыр чакыра, кем хакындадыр хикәят кыйла иде... Көн яхшы ук караңгыланганга, зур-зур электрик шарлары да ягылган – аерым бер нур, аерым бер сер бар кебек тоелмакта иде.

Авыр вә мозтариб[2] кыяфәт белән бераз сөкүт кыйлганнан соң, йөрәгенең әллә кай җиреннән килгән бер тавыш белән Нәгыймә сүз кузгатты:

– Әй, сиңа да шулаймы? Мин аның хатларын аңлап бетә алмыйм...

– И... апа! Алай булырга кая? Сүзләрен мин аңлап бетә алмыйм, ләкин аның ни әйтергә теләгәнен мин, аңлыйм гына түгел, җаным, йөрәгем белән үк сизәм... Анлар минем әллә кай җирләремә төшеп утыралар...



[1] *Гая* – иң соңы, чик.

[2] *Мозтариб* – борчылулы.

Мәрьямнәр белән бер йорт эчендә зур гына бер татар бае тора иде. Шул җитмеш[*] алты яшендә булган хәлдә, бу ел яз вафат булып, варисы намына тик бердәнбер хатыны калды. Аның исеме – Нәфисә. Яше егерме дүртенчедә. Кыскарак буйлы, калку күкрәкле, симез һәм тулы тәнле, кызыл йөзле булган бу ханым хакында ире бар чакта да әллә нинди хыялый романнар сөйлиләр; явыз телләр аны «тутырган тавык» дип атыйлар; бер этәч егерме тавыкка җитсә дә, Нәфисә бер үзенә егерме ирсез туя алмый, фәлән-төгән, дип һәм, зур, таза гәүдәле, симез вә куәтле ирләр күрсә, күзен ала алмый, шуңа карый да исе китеп кала, дип тә гайбәтлиләр иде.

Борыннан анларның Мәрьямнәр гаиләсе белән һичбер төрле мөнәсәбәте булмаса да, ирен күмеп кайтканның икенче көнендә үк, мәхкәмә эшләренә гаид ниндидер бер йомыш тапкан булып, керде дә башта Мәрьям аркылы, аннан ары, кача-кача гына маташкан булып, үзе үк Фәхри белән сөйләште.

Һәм шул – ике арадагы мөнәсәбәт нигезенә беренче таш булып калды.

Мәрьям өйдә чакларда, Фәхринең аның белән мөнәсәбәте булу ихтималын аңлаткан һичбер нәрсә дә күренмәсә дә, китеп, берничә көн йөреп кайтса, усал телләр әллә нинди гайбәтләр хәзерләп куйган була иде.

Бу барышта ун көннәр үк торып кайтканга, гайбәтләр тагы күбәйгән; инде явыз телләр генә түгел, ышанмау мөмкин булмаган адәмнәр дә, җирәнә-җирәнә, әллә ниләр сөйлиләр иде.

Нәфисә, мактану өченме, ир белән хатынның арасын ныграк бозу өченме, белмим, нидәндер берничә «дустларына», «сер итеп кенә», Фәхринең игътирафларын[1] да сөйләп ташлаган; ул гүя: «Минем Мәрьямдә хатынлык аз, ул хатын була белми...» – ди икән.

Хадимә, күзен дә йоммыйча, бай абый әйтергә кушмаган иде, мин әйтте димәгез, ул бу ун төннең һичберендә өйдә кунмады, дип кычкырып тора...

Нәгыймә дә, халык авызындагы байтак нәрсәне риваять кылганның соңында, Фәхринең карсак кына хатын белән караңгы кичәдә ябулы кимәгә утырып каядыр китүе кебек берничә вакыйганы, приказчигыбыз күргән, дип, сөйләде.

Боларның һичбере ни өчендер Мәрьямнең исен дә китәрмәде, ачуын да китермәде. Нәгыймә апасының сүзенә каршы: «Танытырмын әле мин аңа Мәрьямнең хатынлыгын!» – дип кенә куйды.

Ул үзендә бик аз гына да әрнү һәм көнләшү кебек нәрсә хис итмәде, шулай да эченнән: «Болай калдырмам мин аны!» – дип, кискен рәвештә карар бирде. Фәхри теләсә кем белән йөрсен, теләсә биш Нәфисә белән мөнәсәбәт ясасын,

---

[*] Авторда – *«йитмеш».*

[1] *Игътираф* – кимчелек.

Мәрьямгә бер тиенлек әһәмияте юк. Чөнки аңа Фәхри – җиде ятларның ятрагыдыр. Ләкин бу эш – тавыш чыгарырга уңгайлы сылтау. Шул мөнәсәбәт белән, үзен гомергә бәхетсез ясаган каһәрдән үчен алырга юл ачыла... Шуңа күрә ул «калдырмам мин моны!» ди... Моны ничек башлар, ничек тавыш чыгарыр, үч алуы нидән гыйбарәт булыр – бу хакта Мәрьямнең планы юк иде һәм кирәк тә тапмый иде.

Гүя ул кайта да, моның тарафыннан сүз башлана. Шунда бу аның пычрагын битенә бәрә. Ни дә булса бер явыз, куркыныч булган эш кыйла...

Нәгыймә, күрешергә дип кенә кергән идем, абау, бик озак торып китәм, дип чыгып китте. Мәрьям озакламый кузгалып та әллә нинди бер афәт чыгарырлык булган өермә алдындагы сыман бер халәттә калды.

Бу вакыт сәгать унберенче иде.

22

Хәзер нинди йөз бирергә?.. Нинди төстә булса да, бер-бер тәэсирме, әллә илтифатсызлыкмы күрсәтергә? Шул сөаль Мәрьямнең башына килеп: «Тукта, ишекләрне бикләтим, шәмнәрне сүндерим дә үзем бүлмәмә ябылып ятыйм... Теге кайтса, ишек ачарга да үзем чыкмыйм, каршы да алмыйм, хәтта тормыйм, исәнләшмим дә... Әллә алай итмимме? Әллә юкса, аның бөтен серен беләм, ләкин ул ни генә кыйлса да, минем өчен барыбер икәнен аңлатырлык бер кыяфәт биримме?.. Әлбәттә, шулай кирәк – менә гөнаһ шомлык, кайдан килгән ул теге караңгы йөз күрсәтү, бикләнү уе! Алай кыйлансам бит, мин аңа үпкәләгән булып күренәчәкмен... Гүя теге хәбәрләрне ишетеп хәтерем калган. Гүя, мин аны көнләшәм булып чыга... Ходай үзе сакласын!.. Мин, мин аңа белдерергә тиешлемен ки, ул бер түгел, егерме Нәфисә белән йөрсә дә, минем өчен барыбер. Чөнки ул миңа бөтенләй ят; ирем булса да, җиде ятларның да ятрагы. Мин моны аңа белдерергә, шуңа күрә мәсхәрә катыш истиһза[1] илә хәкарәтләү[2] катыш илтифатсызлык күрсәтергә кирәк...» – дип уйлап өлгерә алмады, кемнеңдер тыш яктан сирәк, ләкин куәтле адымнар белән ишеккә таба якынайганы беленде, һәм, ишек ачылып, авыр, салмак, бераз һавалы йөреш белән Фәхри килеп керде. Аның өстендә җәйге пальто, кулында таяк, башында яһүд каракүл бүреге иде.

Әүвәлге күренештә Мәрьямгә аның буе бераз озынайган, гәүдәсе тагы да ныграк турылана, күкрәге, әүвәлгедән дә артык алгарак чыгып, киңәя, куәтләнә төшкән сыман тоелды. Болардан да элек күзгә чалынган җире – аның сакАлларының бик ялтыратып кырылган, мыегының бер дә иренми төзәтелгән

[1] *Истиһза* – көлү, ирония.
[2] *Хәкарәт* – хурлау.

икәнчелеге булды. Гомумән, аның бөтен торышы бик тырышлык белән ясанганлыкны аңлаталар кебек иде.

Урыныннан кузгалыр-кузгалмас бер рәвештә, йокы арасында сыман күренеп, иң әүвәл Мәрьям сүз башлады:

– Кем дип торам – син икәнсең!

Фәхри бүреге белән таягын урынлаштырды да, урындык алып, Мәрьямнең янынарак килеп утырды һәм, күрсәткән илтифаты ясамадан гына икәнен белдерердәй тавыш белән:

– А, кунак, исәнме? Сау кайттыңмы? Сине җибәрерлек бар икән... Өч көнгә дип китеп, ун тәүлек йөрисең... Сагынып беттем үзеңне! – дип, Мәрьямне кочагына алмак булды.

Ләкин хатын, аны бик илтифатсызча кире этәреп:

– Куй әле, зинһар... Бик арыганмын... Үзем дә тәннәремне күтәрә алмыйм, – диде дә, хадимәне чакырып, кайнаган самавыры булса, теге бүлмәгә хәзерләргә кушты.

– Фәхри, син эчәсеңме?

– Ният юк түгел... Только мин бакчага барырбызмы дигән идем. Бүген «Татарин» белән Борис көрәшә. Кайткан булсаң, сине дә алып чыгармын дип уйлаган идем... Андагылар ни хәлдә соң? Әби исәнме?

– Бар да исәннәр, сәлам әйттеләр.

Мәрьямнең илтифатсызрак кыйланганын күргәч, Фәхри сүзне ярым көлке чыгар дип уйлаган якка тартмак булды:

– Җәләл мулланың теге дурагы әле дә шулай йөриме икән?

Мәрьям аптырый калды:

– Кемне әйтәсең? Сабирнымы?

– Башка кем булсын!

– Ул ни эшләп дурак булсын, ди... Ни дигән сүзең ул «дурак»! Ул синең белән миннән мең мәртәбә гакыллырак әле, җаным. Әллә син үзеңчә ялтыраган штиблет киеп, галстук бәйләп йөрмәгәч тә, дурак була дип беләсеңме? Кызык икән!

– Җә, якламачы шул вәхшиеңне! Мин аны дурак кына димим, примерный чудак дим.

– Таптың сүз! Сезнең мирзаларда гына инде гакыл1 Кайдан җыелган гакыл чишмәләре!

Фәхри һаман туктамады:

– Әй, кара әле, раст сүзме, шул «интеллигент», белми-күрми, бер тиле кызга өйләнгән, диләр?

– Сөйләмәче Ходай язмаганны! Күргәнме, юкмы – анысы икенче эш. Әмма торуларын күрсәң, исең китәр... Пар сандугач кебек сайрашып кына яшиләр... Ә син үзең ничек өйләндең соң?
– Белмим, ничектер бит. Мәрьямнән сорарга кирәк.
– Син, җаным, урман артындагын тикшергәнче, танау астындагын күр! Кешене сөйләгәнче, үзеңне бел!
– Ник белмим, ди, бик яхшы беләм.
– Беләсең, бик беләсең!.. Әйттерерсең әллә ни!
Мәрьям, йөзен берьюлы үзгәртеп, тавышын йомшатты да, бөтенләй башка бер мәсьәләгә кергән кыяфәт алып:
– Әй, онытып торам икән әле: бая синең теге Нәфисәң кергән иде. Минем кайтканымны белмәгәндер, ахры, асраудан бик җентекләп-җентекләп сине сорады. Мин икенче бүлмәдә идем, асрау кыз аны, «катаниегә барам дигән иде, ни вакытта кайтырын әйтмәде», дип җибәрде... Син күрдеңме әле аны, эзләп, интегеп йөрмәсен, бичара... – диде.
Фәхри буен турылатты, йөзенә әллә нинди хәйрәт[1] вә тәгаҗҗеп[2] катыш бер салкынлык чыгарды:
– Әйтче, зинһар, син ни сөйлисең?.. Нинди Нәфисә ул? Уеныңмы, чыныңмы? Шаяртырга мин бала түгел бит!
Ул арада теге яктан хадимә килеп:
– Әзерләдем!.. Абыстай, мин ятыйммы инде? – диде.
– Ярый, бар ят!
Мәрьям, иренең култыгыннан алды да:
– Җә, син тагы бик тиз кызып китмә әле... Әйдә чәй эчәргә чыгыйк, – дип, икесе бергә аш бүлмәсенә чыктылар.
Утырып җитмәс борын, Фәхри баягы тавыш, баягы кыяфәт белән тагы шул сүзне тәкрар нтте:
– Син ни сөйлисең, Мәрьям? Шаяртырга мин бала түгел, кем ул – «минем Нәфисәм»?
Мәрьям, иренен сүзенә колак салмаган шикелле күренеп:
– Шул Гайни гомер буена чәй өстәлен хәзерли белмәде, – диде дә самавырын өстәлнең икенче башына этәрде, патнус вә ашамлыкларны якынрак тартып, зур шарлы, биек аяклы өлкән лампаны үз янына таба куйды.
Үзе ике стаканга чәй ясады да, берсен ире алдына таба этәреп, урынына утырды, йөзе, кыйланышы, сүзе һәм тавышы – бар да бик илтифатсыз, бик гади

[1] *Хәйрәт* - аптырау
[2] *Тәгаҗҗеп* - гаҗәпләнү

хәлдә күренәләр иде.

– Мин эш белән буталып тыңлый алмый калдым. Ни дигән идең әле син, Фәхри? Кем ул – «минем Нәфисәм», дисеңме?

– Шулай дим!

Мәрьям йөзеннән вә бөтен кыяфәтеннән шаяру төсен берьюлы югалтты вә уң кулының шәһадәт бармагы[1] һәм күз карашы белән Нәфисәләрнең өе җәһәтенә ишарә кыйлды:

– Инде белдеңме?

Һәр икесе эчтән һәм тыштан тиз вә куәтле рәвештә үзгәрә башладылар.

– Мәрьям, син уйлап сөйлә!

– Уйнарга бер дә генә дәртем юк, җаный. Уйлап, бик уйлап сөйлим!

– Уйласаң, минем башыма тай типкән дип беләсеңмени – әллә кем мещанның калдыгы артыннан өстерәлергә!

– Белмим, кем типкәндер, тайдырмы, аттырмы? Анысын үзең беләсең! Һәрхәлдә, исән баш булганда, үзенең мирзалыгы белән һәрбер адымда мактанып йөрүче Фәхригә андый «әллә кем мещанның калдыгы артыннан өстерәлергә» бик килешеп бетмәс иде... Бардыр бер хәл!

– Тагы әйтәм, уйлап сөйлә, Мәрьям!

Мәрьямнең тавышы ирексез ачы, кискен вә куәтле бер рәвешкә керде:

– Куйчы, пажалуйста, шул сүзеңне! Артык туры тидеме әллә! Торасың да, «уйлап, уйлап», дисең! Синең белән уйнап торасым бик килми – уйлап, бик уйлап сөйләшәм! «Кем ул – минем Нәфисәм?» – дип үзең сорадың, мин әйттем. Аның өчен ник ул чаклы...

Мәрьям сүзен бетерә алмады, Фәхри, эченә сыя алмый ташып барган ачу тәэсире белән, бер кузгалып, бер утырып, яман тавыш белән акырып җибәрде:

– Әйт, зинһар, куясыңмы шул сүзеңне, юкмы? Нинди Нәфисә бар да, нинди өстерәлү бар? Бу нинди хатыннар әкияте бу? Шунда, мужиклар арасына кайтып, бер-ике көн торып килсә, бөтенләй эштән чыга!.. Кайдан тапкан Нәфисәсен дә, кайдан өстерәлүен чыгарган! Менә әкият!! Менә әкият!!!

Мәрьямнең йөзенә үлем аклыгы чыгып, иреннәре калтырый, күзләрендә ялкын уйный башлады. Ничектер ят һәм әллә кайдан төптән, ут арасыннан килгән, шуның белән бәрабәр түбәнсетү катыш истиһзаны[2] белдергән төсле бер тавыш белән һаваны калтыратып ярды:

– Нинди Нәфисә бар да, нинди өстерәлү бар дисеңме? Мине белми йөри дисеңме?.. Мин киткәч, ун көн буена кайларда, кемнең куенында йокладың?..

---

[1] *Шәһадәт бармак* – имән бармак.

[2] *Истиһза* - ялвару

«Эрмитаж»ның алтмыш беренче номерына караңгы юл белән кемне керттең?.. Анда өч тәүлек кем белән яттың?.. Шимбә көн кич сәгать ун ярымда, Собор чиркәвенең аргы ягындагы бакча каршысындагы тыкрыкта нинди карсак хатын белән ябулы кимәгә утырып киттең? Тагымы?.. Тагы: «Минем Мәрьямнең хатынлыгы аз, ул хатын була белми!» – дип кемгә сөйләдең?

Теге, пычак белән чәнчелгән кебек, сикереп торды да:

– Хуш, Нәфисә белән булдым! Аңа сөйләдем! Инде ни дисең? Инде ни кыйла аласың? – дип, хәкарәтле тавыш белән җикеренеп, Мәрьям өстенә килә башлады.

Яшь ханымның йөзендәге үлем аклыгы артты, иреннәре тагы яман калтырый, күзендә тагы яшен ялтырый башлады... Ул, өстенә таба җикеренеп килгән Фәхринең тәэсире белән үзе сизмичә үк, бераз артка таба атлады да һәр икесенә дә ят һәм өмитсез тоелган бер тавыш белән:

– Инде ни кыйласың дисеңме?.. Инде минем өскә җикеренеп киләсеңме, падлис! – дип кычкырып бетә алмады, кул астында гына торган зур лампаны яшен тизлеге белән үк кулына эләктерде дә: – Менә ни кыйлам, менә ни кыйлам, падлис!! – дип, Фәхринең башына төзәп атты...

Кул яңлышмады, лампа туры мирзаның битенә барып бәрелде дә, шары белән куыгы ватылып, теге гәүдәсе белән артка таба кайшалдыгыннан, керосин әүвәл аның өстенә, аннан идәнгә түгелеп, аңа ут кабынып, Фәхри дөрләп яна башлады; идәннән дә гөлт итеп ялкын күтәрелде.

Аптыраш... Тавыш... Каушау... Кая барырга, ни кыйлырга белмәү... Кабалану... Буталу...

Бер минутта өйнең эчен тәмам ут алды. Ләкин, искиткеч хәл, Мәрьям бик тиз искә килде дә, йөгереп барып, урам тәрәзәне ачты һәм, бөтен дөньяга һәлакәт килеп, һәммә кешегә актык секунд җиткән икәнчелегеннән фөрьяд кылгандай ачы тавыш белән:

– Янабыз!.. Янабыз!.. Янабыз!.. Тизрәк булыгыз!.. Янабыз! – дип акырып җибәрде.

Дөнья уянды. Күбесе ятак киемнәре өстенә бер җилән йә пальто салган ирләр, хатыннар агыла башлады. Өй тирәсе һәм эче халык белән тулып, ата угылны, ана кызны белмәслек бер ашкыну белән йөгерергә, булышырга, әллә ни эшләргә – кабаланырга, чабарга тотындылар...

Ул арада янгынчылар да килеп җитте.

Ут артык зурга китә алмады. Фәхриләр квартирының эче күп әйбере белән бергә янып эштән чыккан иде. Тыш ягы исән калды, башкаларга күчәргә ирек бирелмәде.

Фәхрине шунда ук шифаханәгә озаттылар.

Аның хәяты өчен куркыныч күренмәсә дә, ут үз дигәнен кыйлган – аның йөзе һәм кулбашлары яхшы ук янган иде.

Башкалар белмәде. Мәрьямнең юк-бар белән мактанасы килми иде. Фәхри исә, хатынын махсус чакыртып алды да:

– Булачак эш булды инде. Анысы икебезнең арада өзелер. Үз кашыңда иң кадерле булган нәрсә намыннан үтенәм: син бу казаның сәбәбен хәзергә һичкемгә белдермә; «ул, урындыкка басып, шкафтан әйбер эзли иде, аягы таеп китте дә, лампа өстенә ауды, шуннан ут чыкты», диң, – диде.

Мәрьям «ярар» диде.

Бичараң, халыкның «хатыныннан кыйналган...» дигән гайбәтеннән курка, күрәсең!

## VII

### 1

Зәңгәр чишмә буен берьюлы өч фәлякәт[1] сукты: һәм шулар тәэсире белән аның халкында да өч мәузугъда[2] әллә ничаклы әкиятләр, гайбәтләр туды.

Теге, карамалы Сафый шәкертнең агасы Сәлим атылып үлгән. Фаҗига ил телендә шул рәвешле тәфсил кыйлына: егет берничә көннәр, бик зур хафага төшкән адәм сынлы, гел уйланып, борчылып йөргән. Ашау-эчүенең дә җүнләп рәте булмаган, кешеләр белән дә рәтләп сөйләшмәгән. Аның бу хәлен күреп, Җаббар мулла:

– Сәлим, сиңа ни булды? Балтасын суга төшергән урыс кебек, гел кайгыңа батып йөрисең? – дип шаяртырга уйлаган икән, ул аңа бик пычрак, бик агулы бер сүз генә әйткән дә артык авыз да ачмаган. Беркөнне көн буена бүлмәсенә бикләнеп, һичберәүне янына кертми үткәргән дә авыр, караңгы һәм ямьсез көзге төндә, һичкемгә әйтмичә, тау ягына ялгызы гына чыгып киткән һәм шуннан ул юк та булган...

Аны төн көткәннәр, иртә көткәннәр – юк, һаман юк та юк... Сәлим югалган дип, тирә-якка хәбәрләр таралган... Эзли башлаганнар... Шуннан ике көн үткәч, таш кисүчеләр тауда бер мәет күргәнлекләрен, ләкин вакыт кич булу сәбәпле, кем икәнен таный алмаганлыкларын старостага хәбәр иткәннәр... Җыелып барган халык...

Ни күрсеннәр? Теге мәет – Сәлим булып чыккан. Өстендәге барлык киеме үзендә, һәммә әгъзасы сәламәт, ди. Башта, моны кем вә ничек үтерде икән дип, бик аптырашканнар икән, кесәсеннән кечкенә генә бер кәгазь чыккан. Анда шул

---

[1] *Фәлякәт* – бәхетсезлек, афәт.

[2] *Мәузугъ* – тема, проблема.

сүзләр язулы ди:

«Берәрсе үтереп ташлагандыр дип, юкка гөнаһлы булмаңыз, алтатарны үзем корып, чигәмә үзем төзим... Минем өчен, әлбәттә, кайгырмазсыз, чөнки мин күптән үлек идем...»

Халык шаша калган. «Бу ни эш, бу ни эш?» – дип, күз, колакларына ышанмас булганнар, һәм бу хактагы авыр хәбәр тиз арада бөтен Зәңгәр чишмә буена яшен тизлеге белән таралып, алты яшьлек баладан алтмыш яшьлек картларгача булган һәммә кешене хәйранга калдырган. Ни дияргә, ничек аңларга белмиләр, ди...

Мәрхүмнең анасы, угылының гәүдәсен күрү белән, акырып елап җибәреп, өстенә егылган да һушыннан язган... Әй, балам, әй, бәгырем, нинди генә гөнаһ шомлыкларым булды икән дип, көн-төн аглыйдыр, ди.

Балалар ул хакта бер сүз ишетүгә йөзләре агара, күзләренә үлем куркусы чыга да, тыннары киселә, телләре баглана. Карчыклар:

– Яхшы атаның, яхшы ананың баласы иде. Хак язмышы шулайдыр инде, – дип, мәрхүмнең мөртәт китүенә кайгыралар.

Картлар да салкын карый алмый. Хәтта Ярми карт та, ак сакалын уң кулы белән тотып, башын чайкый да хатирәсендәге тарихи дөньясын ачып сала:

– Менә, балалар, моны да күрер көнебез бар икән... Яшем сиксәнгә җитеп, бу эшне күрү түгел, ишеткәнем дә юк иде: имеш, бер мөселман тиктән-тик үзенә кул озайтып, мөртәт китсен... Андый эш кяфер җәмәгатендә булгалый торган, без яшь чакта Әндри дигән урыс боярының унҗиде яшьлек кызы агу кабып үлгән дип сөйлиләр иде... Нindидер эшкә эләккән бер чуашның аркан белән асылып үлгәнен үзебез дә күргән идек... Ул инде кяфер җәмәгатеннән була торган эш, аңа барыбер җәһәннәм, шуңа күрә ул бер кайгы күрсә, атыла, суела башлый... Әмма... әмма бер мөэмин-мөселман бәндәнең тиктән-тик үзенә кул озайтып, нәгузе биллаһи[1], имансыз үтүен (беләмсез, балалар, китап бит анларны мөртәт китә, ди...) ата-бабадан күрү түгел, ишеткән дә юк иде...

Күренеп торган бер сәбәбе булмау халыкны тагы аптырата:

– Кеше бит, – диләр, – ачка үлә башлый, каторга[2] китә – анда да түзә. Әмма моның атасы бай, дөньясы төгәл, кирәге хәзер... Бер эшкә эләкмәгән, фәлән итмәгән... Ходай белә, Ходай белә – ләүхелмәхфузда[3] язылганны җуеп булмый дигәннәре шулдыр инде...

Ләкин теге, тирә-якның иң иске имамы булган Галим хәзрәт аз гына да кызгану

---

[1] *Нәгузе биллаһи* – Алла сакласын.
[2] *Катор – (*каторга) - сөрген
[3] *Ләүхелмәхфуз* – язмыш китабы.

әсәре күрсәтми:

– Хәерсез эшнең ахыры да хәерсез була, дигән китаплар... Сәләфне[1] сүгеп, дөнья күчәрен икенче якка борамыз, халык тормышындагы авырлыкны бетерәмез, дип йөргән булган иде... Бетердең менә... Бар да шуның бәласе, бар да юкны уйлап йөрүнең афәте, – ди.

Бу фәлакәт Зәңгәр чишмә буендагы яшьләргә, яңаларга да бер кара тап сыман булып тоелды. Галим хәзрәтләр, Сәлимнең мөртәт китүе белән шул «дөньяны төзәтергә йөрүчелек» арасында бер галяка[2] бар төсле итеп сөйли, соңгылар үзләре дә ни дияргә аптырый.

Яшерен шагыйрь Кәрим мәхдүм белән Госман бу көннәрдә үзләрен бик авыру вә бөтенләй эчке фаҗига тәэсирендә кебек хис иттеләр. Телләре белән әйтергә батырлык итә алмасалар да, анлар Сәлим хакында . шундый бер хәлнең булуы табигый кебек тоялар. Гүя аның теге елларда үзен, шәхсиятен онытып, үз дөньясын ташлап, башы-аягы белән «мәсләгем» дигән юлына чумуы һәм дә ул көннәрдән бераз заман үткәч, дөнья басылгач, байтак дәверләр кичергәч, шул ук Сәлимнең «хезмәт» дигән «мәсләк вә халык» дигән сүзләрне үзе авызга алу түгел, кешедән ишеткәндә дә каш җыерып, кул селкеп, икенче якка таба борылып китүләре белән хәзерге фәлакәте – кара, караңгы һәм ямьсез көзге төндә ялгызы тауга барып, тыныч кына хәяттан китүе арасында табигый бер бәйләнеш бар иде. Гүя бу шулай булмый мөмкин түгел иде...

Аның кесәсеннән чыккан теге кәгазь дә гүя егетләрнең бу шөбһәләрен куәтли иде:

«Минем өчен, әлбәттә, кайгырмазсыз... Чөнки мин күптән үлек идем».

Борын бик салкын йөргән шагыйрь бу фаҗигадән соң Сәлимгә якынлык вә ихтирам тоя башлады, һәм аның теге язуын хатирә дәфтәренә күчереп алды да шуның астына үзе язып куйды:

«Син, «күптән үлек идем», дисең. Кайчаннан, нинди дәверләр соңында? Теге, хәятта бердәнбер максат итеп, шуның кодсияте алдында даимән табынмакта булган иман вә идеалыңны югалткан көннән бирлеме?»

2

Үзенең һиммәт вә мәртәбәсе һәм зур торуы белән тирә-якның ханы дәрәҗәсендә яшәгән мәрхүм Гәрәй мирзаның кызы Мәрьям туташ бик кечкенәдән үк халыкның диккатенә төшеп, аның дөньяга беленерлек булган һәрбер адымы, һәрбер хәрәкәте ил теленә керә – җә гайбәткә, җә мактауга сәбәп

---

[1] *Сәләф* – борынгылар, «изгеләр».

[2] *Галяка* – бәйләнеш, мөнәсәбәт

була иде. Кияүгә чыккач, халык әкияте аны бигрәк еш үзенә мәузугъ[1] итеп ала башлады. Ничектер, аның ирен яратмау мәсьәләсе дә таралган.

Җәләл мулланың солдаттагы угылы белән хат языша имеш, дигән хәбәре дә чыккан... Соңга таба Фәхринең Нәфисәгә мөнәсәбәте дә, әллә нинди «Әлфе ләйлә» буяулары белән эшләнеп, кызыклы әкиятләр тудырган иде... Бу хакларда төрле кеше төрлене сөйли: берәү гаепли, берәү кызгана, икенче бере Фәхрине сүгә иде. Ләкин Мәрьямнең язмышының актык пәрдәсе ачылгач, иң явыз телләр дә гайбәткә куәт тапмады – һәммә кеше аны беравыздан кызганып сөйли башладылар.

Теге янгын казасыннан соң Мәрьям, котылдым инде, ара өзелде, дип уйлаган иде. Ул, ире яңадан бергә тору хакында авыз да ачмас, дип хөкем итеп куйган иде. Ләкин болар яңлыш булып чыкты. Фәхри шифаханәгә алынган минутыннан башлап ни өчендер бу вакыйгага бер дә исе китмәгән төсле, аңа бик гади караган кебек күренде, һәм терелеп, йөри алырлык булгач та, Фатыйма бикәгә килеп, аның васиталыгын[2] үтенде, Нәгыймә апаны да эшкә катыштырды. Алар Мәрьямгә сөйләп, аның шартларына Фәхрине дә ризалатып, ир белән хатынны тагы берләштерделәр.

Тагы бертөрле генә, салкын гына, рәхәт тә, кайгы да күрми генә көннәр кичә башлады. Ләкин ханым эченнән бик тарсына, бик ашкына, тик һичбер сылтау булмаганга, чарасыздан гына тыныч гомер сөргән кебек йөри иде.

Яңадан берләшеп, берәр ай чамасы торгач булса кирәк, моңарчы тын вә рәхәт килгән мохитны кинәт кенә дулкынландырып җибәргән бер фаҗига баш күтәрде: Фәхри бер тәүлек югалып торган иде, таң вакытында аны үз йортының азбары артында үлек хәлендә таптылар, һичбер җирендә пычак, мылтык эзе күренми. Кан әсәре дә юк. Докторлар, агу белән үлгән, диделәр.

– Кем агулаган?

Менә бу – зур бер мәсьәлә булып китте. Берәүләр, мәрхүм, күптән түгел карта уйнап, бик күп акча оттырган, бурычка баткан, җитмәсә, берничә урында шәэнен[3] югалткан иде, шуның кайгысыннан үзе агу эчкәндер, диләр. Кайбер кешеләр, ул, Нәфисәне ташлап, икенче бер хатын белән йөри башлаган иде, әүвәлге шуңа үч алу өчен агу биргәндер, дип шөбһәләнәләр. Фәхринең якыннары исә, үз күзләре белән күргән кебек, җинаятьне Мәрьямгә каплыйлар:

– Сәгать төнге уникегәчә Фәхри бездә булды. Шат вә ачык иде. Без аны йортынача озата да бардык. Ул безнең күз алдыбызда өенә керде, – диләр.

---

[1] *Мәүзугъ* - тема

[2] *Васиталыгын* - арадашлыгын

[3] *Шәэнен* - дәрәҗәсен

Кайдандыр шаһитләр табып, Фәхринең тәнендәге агуның ише Мәрьямдә дә булганлыгын дәгъва кыйлалар...

Башка берничә шөбһәле адәмнәр белән бергә Мәрьям дә зинданга алынды. Вакытында бу көтелмәгән эшне кызу гына сөйләп тә, Сәлим фәлякәте белән тәмам онытканнар иде. Бу соңгы өчен ничә айлар кайгырып, телләр арыгач, Мәрьямнәрнең эше окружной судта тиздән карала икән дигән хәбәр тагы яшен тизлеге белән бөтен тирә-якка таралып китте.

– Судта ни булыр, судта ни булыр?

Халык моны сабырсызлык белән көтә, каладан кайткан адәмнәрнең һәрберен: «Бикәнең кызы хакында ни хәбәр?» – дип сырып алалар иде.

Хөкем ачык ишектә булып, җыелган халыкның исәбе-саны юк иде, ди. Шул тирә авылларыннан Каргалының Кәрим бай үзенең хатыны Зарифә белән шул көннәрдә калада булып, судка кергәннәр икән. Дөньяда булган һәрбер вакыйганы, үзенең кыйммәтле хатирәсе кебек, һәр җирдә һәркемгә сөйләп йөрергә ярата торган бу ханым үзенең судтан .алган тәәссераты белән бетен Зәңгәр чишмә буен тутырып ташлады:

– Йа, Ходай, – ди, – ни күрәбез инде дип, әллә ничә катлы бик озын бер таш пулатка барып кердек. Күрсәң исең китәр; ул озын-озын баскычлар, ул эрелеваклы бүлмәләр, дисеңме. Тулып кына ята инде... Ялгызың керсәң, кая барырга да белмәссең, ничек чыгарга да аптырарсың – башың әйләнер дә калыр... Бераз менгәч, бик зур бер залга барып кердек. Менә зур инде, Илаһым, эчендә ат чабыштырырсың. Шуның иң түрендә бер калкурак җире бар. Анда әллә нинди бик озын, бик киң бер өстәл тора. Аның өсте зәңгәр постау белән ябылган да, шунда әллә нинди кәгазьләр, каралар, каләмнәр ята...

Өстәлнең тирә-ягында күтәрмәле утыргычлар тезелеп киткән... Залның бирерәк якларында да бик, бик күп урындыклар, артлы эскәмияләр тора. Мин, йа Ходай, берсе бәйләнмәсә генә ярар иде, кире кумасалар гына ярар иде, дип, котым очып барам. Ирнең ир бит... Бер дә шикләнми генә барды да шундагы артлы эскәмияләрнең бер җиренә утырды. Мин дә аның янына сыендым...

Менә бервакыт халык агыла, халык агыла башлады, әйтерсең инде бөтен дөнья монда җыелды. Эскәмияләр, утыргычлар бар да тулды; сыймаганнар аягүрә басалар... Менә бервакыт әллә нинди түрәләр, кылычлы солдатлар кайнаша башлады; берсе керә, берсе чыга... Халык дигәнең һаман агыла, һаман агыла; урысы да калмаган, татары да...

Менә бервакыт теге калку җирдәге өстәлнең янына әллә нинди киемле, сары төймәле адәмнәр җыела башлады... Кайберләре шундагы сыгылмалы урындыкларга арка терәп утыралар да тәмәке тарталар...

Менә бер мәлне (вакытны) усал гына кыяфәтле бер адәм бер кечкенә генә сары нәрсәне алды да берничә мәртәбә шыңгырдатып куйды... Зал тынды... Сүз, тавыш берьюлы бетеп китте...

Шул вакыт, залның сул ягындагы бер ишек ачылды да, әллә нинди бер марҗа килеп чыкты... Аяк битенә төшеп тора торган озын бернәрсә кигән. Ул ап-ак, ак киндер кебек. Башына да шундый нәрсә ураган... Үзенең яныннан кылычларын ачкан ике солдат бара... Менә бервакыт килә-килә шул марҗа безнең турыбызга якынайды... Карасам, шул таныш кебек, үз кешебез кебек булып калды да, ныграк карасам, һушым да китте, гакылым да бетте, ни күзең белән күрәсең: шул марҗа дигәнем – үзебезнең Мәрьям икән...

Ни эшләгәнемне белмәдем, урынымнан сикереп торып, «җаным, Мәрьямем, синме?» дип, акырып елап, муенына асыла яздым... Ирем, ни эшлисең, ди... Ул безне үтеп киткәч, тәнемә эсселе-суыклы су коелган кебек булды... Шуннан акрын гына барды да, – анда гаеплеләр өчен аерым урын бар икән, – шуңа җиткәч, безгә таба борылды... Әй, Ходаем, әй, Раббым, хуҗам! Адәм бу чаклы да үзгәрсә үзгәрер икән...

Йөзе ап-ак, ак дигәндә дә әллә нинди үлем агы. Әллә ничек үлгән адәмнеке төсле. Яңаклары, тиресе итенә ябешеп, эчкә утлыгып кергән. Күзләре әүвәлгедән дә зураеп, кап-кара булып киткән дә әллә кая төпкә, эчкә киткән. Күзендә, йөзендә, Ходай белсен, әллә нинди һәлакәт, әллә нинди газап күргән адәмнеке кебек, авыр да, кызганыч та бер төс бар. Карасаң, еларга да җибәрергә... Баштанаяк уралган ак нәрсәсе аны хәзер генә кәфенен өстерәп кабердән чыккан шикелле күрсәтәләр... Ике як чигәсеннән кап-кара чәче чыгып тора, шулар да авырайталар... Мәрьямнең күренүе белән бөтен халык коелды да төште... Ул һичкемгә күтәрелеп карамады, әллә нинди бер һәлакәт астындагы адәм кебек, акрын, салмак адымнар белән теге гаеплеләр урындыгына килде дә, әллә ничек шунда сеңгән кебек булды. Бераз торгач, теге өстәл тирәсендәге түрәләрнең әле берсе, әле икенчесе аякка басып, әллә ниләр сөйләргә, гаеплеләрне торгызып сөйләтергә тотындылар. Гуаһлардан[1] сорыйлар. Ирем кайбер сүзләрне миңа, үзебезчәгә авыштырып, әйтә тора. Бик озак шулай маташтылар, кычкырыштылар. Берничә мәртәбә туктатып, үзләре теге якка чыгып, бераз торып та керделәр.

Без инде, йа Ходай, ни генә ишетәбез, дип торабыз. Мин, котылгач ук, Мәрьямне барып кочакларга уйлыйм... Шулай бик озак талаштылар, кычкырыштылар; теге түрәләрнең беразы тагы каядыр, икенче бүлмәләргә таба киттеләр. Инде бусында бик озак торып килделәр... Без тагы сабырсызлык

---

[1] *Гуаһ* – шаһит.

белән күтәбез:

– Йа Ходай, ни генә була? – дибез.

Бар да яңадан урыннарына утырды. Халык та, мәхшәрдәге кебек, курку катыш бер тынлык белән теге өстәлдәгеләргә таба карап катты... Менә тагы баягы усал йөзле адәм, акрын гына кузгалып аягына басты да берничә мәртәбә кыңгыравын чыңылдатты. Зал тынды. Йа Ходай, үләбезме, дип торам... Бер-ике мәртәбә тамак кырды, өзеп-өзеп кенә бернәрсә сөйләде. Ирем миңа үзебезчә әйтте. Мин ни эшләгәнемне белмичә, акырып җибәрә яздым.

– Йа Ходай, йа Ходай, бу ни һәлакәт – Мәрьямгә алты ел катр, ди...

Минем башым әйләнде, кайда утырганымны белми, әллә кая ашкына башладым... Теге адәм сүзен бетерә алмады, Мәрьям, кәфеннәрен өстерәп, аягүрә басты, ике кулы белән кинәт кенә башын кысып, әллә нинди авыр, үтә кызганыч тавыш белән:

– Аһ, нахак! Аһ, нахак!! – дип, фөрьяд кыйлып, йөрәкләрне үтә кисәрлек бер аваз белән кычкырып елап җибәрде дә эскәмиясенә йөзтүбән егылды... Аның белән бергә бөтен зал да аглый башлады. Мин ни эшләгәнемне белмим, «Мәрьям, Мәрьям, җаным», дип аңа таба барырга омтылам икән...

Зарифә бу фаҗигане урыны чыккан саен һаман яңа дәрт белән сөйли, тасвираты актык нокталарга җиткәч, һәр сөйләүдә тавышы үзгәрә, күзе яшәрә дә, яулыгы белән сөртә башлый; аны тыңлаучы хатыннарның да күбе еламый кала алмый иде. Шул хәлне бергәләп сөйләшәләр, елашалар да ахырдан Фатыйма бикәне кызгану белән тәмам итәләр иде:

– Бичара, бигрәк гакыллы, бигрәк зирәк, сөйкемле иде... Анасына күек булыр өчен генә туган, күрәсең...

Картлар да салкын карый алмый:

– Мөэмин-мөселман бәндәгә түгел, дин дошманыңа да язмасын, әйтергә ансат бит, нахактан алты ел катор, нахактан алты ел катор!

3

Мәрьямнең фәлякәте бераз онытыла төшеп тә, ерак вә салкын Себернең каһәрле каторыннан язган өченче мәктүбе тәэсире белән Зәңгәр чишмә буе хатыннары телендә яңадан бик нык кызганыла, кайгыртыла башлаган бер заманда, Зыя мәхдүм хәятының соң пәрдәсе ачылып, халыкның зиһен вә теле аның тарафына юнәлде.

Зыя солдатлык хезмәтенең өченче елында авылына кунакка кайткан иде. Бирелгән мөддәте – кырык көне тулып иртәгә китәм дип торганда, Госман мулла, мәҗлес ясап, бөтен гаиләләре белән боларны да чакырган иде. Зөләйха абыстай, кәефем юк дип, бармады. Яшьләрнең исә һичбер манигъләры юк иде.

Сабир, хатыны Камилә белән икесенә бер ат җигеп, Зыя мәхдүм Кәрим янына утырып, көндезге сәгать уникедә шунда юнәлделәр.

Чакырылган кешеләрнең күбе килмәгән. Шунлыктан мәҗлес бик хосусый гына, үзара гына бер җыелыш шәкеленә керде. Ят адәмнән һичкем юк – барлыгы Җаббар мулла, мәрхүм Сәлимнең энесе Сафый шәкерт, яшерен шагыйрь Кәрим мәхдүм, Сабирлар өчәү, авылның учителе, тагы шундый тирә-якның яшьләреннән берничә егет тә бер мөгаллимә.

Госманның хатыны мәҗлескә чыкмады да, күренмәде дә. Чаршау артында, боларга биреләчәк аш-суны хәзерләп йөргән чагында, Сабир, аңа берничә мәртәбә бәйләнеп:

– Җә, Асылбикә, ник мәҗлестән качасың? Камилә синең сеңелең булса да, утыра бит, – дип караса да, ул үзенең чаршавы артыннан бик кыска гына рәвештә:

– Көчләмәгез, булмый миннән, – җавабы илә каршы баруында дәвам итте һәм чыкмады, күренмәде.

Госманның сые шәп, хөрмәте зур иде. Мәҗлес яхшы һәм күңелле иде. Кунакларның кәефе аннан да яхшы иде.

Табынның мәркәзе – башыннан ахырынача Камилә булды. Ул үзе табынчылык итә, аш сала, чәй ясый, шуның белән бергә, йөзендәге матур елмаюын бер дә җибәрмичә, үзенең ачык, саф тавышы белән әллә ниләр сөйли, әллә кемнәрдән көлә, әллә кемнәрне гайбәт кыйла иде. Аның тәэсирендә башкалар да үзләрен бик җиңел, бик иркен хис иттеләр. Сабир күп сөйләми; ләкин ул да ачык, шат булып, хатынының күзеннән күзен ала алмый утыра иде. Арада Госман, теге Зыяның каралып йөргән чакларындагы әңгәмәне хәтергә алып:

– Исеңдәме, балдыз, ул вакыт «Казан шәкертен күрәсем килә...» дип, минем муеныма асылган идең... Менә күр инде, ул каршыңда утыра, – дип көлгән иде.

Камилә башта бер генә секундка бик аз гына кызарды да, тиз арада, тагы үз көймәсенә утырып, ул заманның хатирәти дәрьясына йөзеп китте – ваклап, тәмләп һәм мөгаллимәне кызартырлык мәртәбәдә тәфсилләп, әүвәл шул хактагы, соңра бөтен кызлык дәверендәге кызыкларын сөйләп ташлады.

Мәҗлеснең шундый күңелле барган чагында, арадан кемдер бүген каторда җәһәннәм газабында яшәмәктә булган Мәрьям ханымның күләгәсен монда китергән – аны кызганып телгә алган иде. Шуның белән, гүя мәҗлеснең күген кара болыт каплап, шатлык кояшы әллә кая яшеренде дә, һәммәнең йөрәгенә авыр бер фаҗига тәэсире төшеп, күкрәкләрдән ирексез «у-уһ!» – дип бер авыр сулыш күтәрелде; һәм шуның уты тышка чыгып, Камиләнең теле бағланды, бөтен торышына кара кәфен капланды; Зыя, кара көеп, эченә батты; башкалар

да мөтәэссир булдылар – мәҗлес берьюлы матәмле[1] кыяфәт алды. . Ходай белә, җыелышның дәвамы ни сурәттә булыр иде, тик Җаббар мулланың бетмәс-төкәнмәс шаянлык таланты гына мәҗлесне бу авырлыктан чыгара алды...

Ул, башта берничә җиргә кагылып та, ялгызы гына, зур муаффәкыять казана алмагач, ахырдан килеп, Камиләгә бәйләнде:

– Синең, – ди, – Камилә ханым, иманың юк... Үзең дә имансыз, ирең дә имансыз. Син нәмәхрәмгә йөзеңне күрсәтәсең – ул хәрам. Хиҗаб[2] фарыз – син аны да тотмыйсың. Чит ирләр белән бер мәҗлестә көлешеп утырасың...

Хатын тиз арада тагы җиңеләеп китте:

– Ә, алай икән! Әллә син мине дә, үзеңнең Бәдәркәең кебек, башым белән капчыкка тыгып йөртер идеңме?

– Әлбәттә, шулай кирәк иде, мөселман булсаң, шәригатьне тот. Әле бит син үзең дә шулай йөри идең... Тик менә бу явыз, Сабир гына сине харап итте... Белмәдем бит, валлаһи, белмәдем, белгән булсам, мәңге димләмәгән булыр идем...

Аш вә чәй җыелып алынган соң, Сабирның тәклифе буенча[3] учитель Зариф үзенең өеннән скрипкәсен алдырды. Халык бер мәртәбә тышка, бакчага таба йөреп керде дә, туйган корсак белән, төрлесе төрле җиргә җирләштеләр.

Госман, өстәлдәге скрипкәне күреп:

– Халык лыгырдаса лыгырдый бирер, әйдәгез, егетләр, сыздырыгыз! – диде.

Башта уенны учитель алды. Куллары зарарсыз иде. Мәҗлес ялыкмый гына тыңлады.

Соңра, мина җитәр дип, учитель скрипкәсен Зыяга бирде.

Кайберәүләр кузгала башлаган, Госман, тышка чыкмак булып, ишеккә килгән иде. Егет яткан җиреннән торып, идәндәге утыргычка аркасын терәп, аягын аяк өстенә куеп, уенны тарта башлагач, һәммәсе тынды. Госман да кире чигенде. Гүя сөкүнәт[4] фәрештәсе бүлмәдән аша үтеп, музыкага башка һәммәнең хәрәкәт күәсен бетерде... Телләр сөйләүне онытты, күзләр кая караганын белмәс, тәннәр кайда утырганын сизмәс булды. Йөзләргә әллә нинди моң катыш җитдият чыкты.

Зыя һаман уйный иде.

Ахыр, Камилә түзә алмады, әллә нине яшерергә теләгән, гаепсез мәгъюб[5] кебек, йөзен каплап урыныннан торды да:

---

[1] *Матәмле*– кайгылы.
[2] *Хаҗиб фарыз* – йөзеңне ирләргә күрсәтмәскә кирәк.
[3] *Тәклифе буенча* – үтенече буенча
[4] *Сөкүнәт* - тынлык
[5] *Мәгъюб* - гаепле

– Әй, Раббым, хуҗам! Шул мәхдүмҗан уйный башласа, йөрәкләрем әллә ни эшли... Килендәшем Мәрьям исемә төшә дә җаннарым өзелә... Ул, бичараң, бервакыт озын төн буена, елап-елап, аның уйнавын сөйләгән иде, – дип, теге якка, апасы янына атылып чыгып китте... Һәм шуның артыннан ук ниндидер бер чалмалы карт:
– Әй, балалар, һич булмаса, азан әйткәндә генә туктаңыз инде, – дип, урам як тәрәзәдән кычкырып үтте.
Көй тәмам иде. Шул минутта Зыяның да, куллары сүтелеп, скрипкәсе тезенә төште. Авыр, басынкы кыяфәттә, зиһеннәре белән әллә нинди хыял галәменә китеп югалган вә музыка тәэсире дәрьясына чумган рәвештә, берничә минут торган соң, халык тагы кузгала башлады. Зиһеннәр җир йөзенә, адәмнең башына төшеп, телләр яңадан чишелде.
Госманның йорты мәсҗед белән янәшә. Икенде-ахшам вакыты булганга, анда хәзер әһле иман гыйбадәт кыйлалар. Шул хәлне игътибарга алып, скрипкәне кабаттан кулга тотарга, әлбәттә, мөмкинлек күрмәделәр.
Камилә бу якка чыкмады. Халыкның бер бүлеге, сәкегә кырын төшкән хәлдә, төрле баптан гәп сугарга тотындылар. Зыя белән шагыйрь исә, өйнең икенче читендә үк булган киң караватка килеп, кырын яттылар.
Һәр икесе авыр, һәр икесе җитди иде.
Кәрим мәхдүм сүз башлады:
– Иптәш, синең музыкаң таш йөрәкләрне дә тетрәтә – анысында сүз юк. Ләкин үзеңә тәэсире тагы куәтлерәк булырга тиеш... Кулыңа скрипкәңне алып, бер-ике минут уйнагач ук, синең бөтен кыяфәтең шул дәрәҗәдә үзгәрә, йөзеңә һәм күзеңә шундый бер төс чыга ки, сине ул вакыт Зыя дип танымаска ук мөмкин була...
Сүз, мотлак музыкага, аның әһәмиятенә, тәэсиренәг аннан хәят мәсьәләләренә күчеп, Зыя тагы үзенең җаны газап катыш сәгадәт эчендә йөзгәнен, аның хәяты, җәннәт белән, җәһәннәмне бергә җыеп, җәннәт эчендә җәһәннәм хис кыйлганын әллә нинди бәхет катыш бер әрнү белән сөйләргә кереште. Ахырдан хосусый үз музыкасына килде. Ул аңа бер афәт тә кебек, чөнки хәят юлында аның аркылы ничаклы газаплар күргән. Шул ук вакытта ул аңа бөтен сәгадәтенең мәркәзе дә булып китә. Чөнки башка һичнәрсә бирә алмаячак бәхетле минутларны тик ул гына бирә алган...
Ирексез тагы эченә кереп, ул шул музыка юлында үзе теләгән ноктага ирешә алмау, кулы, йөрәге чаклы музыкант булып хәлык кыйлынмау[1] һәм үзенең тойгысы эстәгән дәрәҗәдә сәнгате мөкәммәл була алмау – гомумән шул юлдагы

---

[1] *Хәлык кыйлынмау* – яратылмау.

авыр канәгатьсезлеге газабына чумды. Инде бу вакыт ул каршысындагы адәмгә чынлап та җәннәт эчендә җәһәннәм газабын чигүче бер шәһит кебек күренә башлаган иде.

Халыкның берсе чыкты, берсе керде. Кемдер таралырга вакыт дип сөйли, аңа каршы Госман белән Җаббар мулла, вакытны сатып алмаган бит, ник ашыгырга, дип дәлилләр торгыза башлады...

Зыя белән Кәрим исә һаман шул урында, шул мәзугда бер-бер артлы игътирафларын[1], өмит вә әмәлләрен[2] ачмакталар иде. Һәр икесенең дә йөзләре ни булган боларга диярлек мәртәбәдә үзгәргән иде.

Шагыйрьнең кат-кат вә туктаусыз сөалена каршы Зыя, тагы җитдирәк кыяфәт белән сөйли башлап:

– Алгы якта, иптәш, кешегә әйтергә түгел, табигый үлчәү белән караганда, үземә үзем игътираф итәргә дә куркыныч тоелган әмәлләр бар. Агам мине хыялыйсың ди, бу әмәлләрең бар да тәҗрибәсез яшь йөрәкнең гарешкә менәргә ашкынуы кабиленнән бер хәл генә, ди. Бәлки, шулайдыр, бәлки, мин читләргә авыру яки хыялый күренәмдер. Ләкин эчемдә ни барын Тәңре белә, минем әмәлем ни мәртәбәдә ерак һәм зур булса, иманым шул дәрәҗәдә куәтле. Мин кулыма музыка коралы алып уйный башласам, шул минутта гүя эчем бөтен татарлык куәтен үзенә җыя... Шул вакыт мин, бәлки, хыялыйлыгымнандыр, язмыш уң биреп, гомер вафа итсә[3], музыкам белән татарның аслы рухын уйгатырым, күгәргән йөрәген сафларым һәм аның авыр язмышына бер үзгәреш бирермен, томанлы вә караңгы хәятына бер нур тудырырмын кебек хис итә башлыйм да алгы көнемнең күгендә ялтыраган өмит йолдызының... – диде дә, сүзен бетерә алмыйча, кинәт хәлсезләнеп, артындагы мендәргә чалкан сузылып төште.

Кәрим мәхдүм, ни булганын аңлап, башка иптәшләренә фөрьяд итәргә[4] өлгерә алмады, авыру әллә нинди ят тавыш белән:

– Аллаһ... Аллаһ... Аллаһ, башым... йөрәгем... Беттем... – дигән кебек берничә сүз чыгарды да артык тереклек галәмәте күрсәтмәде.

Башкалар урыннарыннан сикереп торып аның янына җыелышканда, Зыяда җан әсәре калмаган – тыны киселеп, теле бәгланган; кул вә аяклары ике якка җибәрелгән, йөзе үлем аклыгы белән капланып, күзләреннән хәят очкан иде.

Докторлар, йөрәген фалиҗ[5] суккан, диделәр.

---

[1] *Игътирафларын* – үзенең кимчелекләрен тану

[2] *Әмәлләрен* – теләк-омтылышларын

[3] *Вафа итсә* – мөмкинлек бирсә

[4] *Фөрьяд итәргә* - кычкырырга

[5] *Фалиҗ* – паралич.

Үлем адәмне гүя пакъли; гүя хәятта кылган барлык гөнаһларны юып ташлый. Элек "Зыя мәхдүм" диләр, шул исем әйтелүгә мөэмин күңелле бәндәләр изге сәләф[1] юлыннан аерылган бер гөнаһкяр адәмне тәхаттыр итәләр[2], яхшы нәселдән килеп, яхшы анадан туган бер мәхдүмнең андый, һәрбер иманлы кешене нәгүзе биллаһи[3] дидертерлек, көфериятка вә ярамас эшләргә буялуын, башка һичбер төрле аңлата алмагач, Хакның язмышы шулдыр инде дип, кызгану катыш кайгыру тоялар иде.

Явыз дошманның кабахәт гамәле аркасында солдатка эләгүе мәхдүмнең исеме белән багланган байтак каралыкларны оныттырса да бөтенләй бетерә алмаган иде.

Үлем килде. Шуның белән бергә Зыяның барлык гөнаһлары кодрәт кулы белән юылды, ул ак вә пакъ булып калды.

Үлемнең алуы аны саф бер намус итеп калдырган кебек, аның кинәтлеге коддеси бер кәмаләт[4] тә бирде. Гүя һәммә явызлыклары гафу кыйлынды гына түгел, ул инде изге җаннар зөмрәсенә[5] ашты.

Әһле иман, бигрәк тә саф күңелле голяма аның әйтәчәк җөмләсен дә бетерә алмыйча "Алла... Алла..." дигән сүз белән дөньядан үтүен ишетәләр дә хакыйкый тәэсир белән кул күтәреп тәгъзия укыйлар:

- Иннә лиллаһи иннә иләйһи раҗигун!..[6]

Һәм шуның артыннан ук, бер дә риясыз рәвештә аның хакында сүз башлап:

Шәригать мәҗанин[7] үлүчеләрне шәһидләрдән саный... Китаплар ул бәхетле бәндәләрне сөаль вә хисапсыз тугры оҗмахка китә, ди... Аллаһы Тәгалә барча мөэмин мөселманга шуны насыйп итсен, дип шәһадәт вә җәннәтлелек белән хөкем кыйлалар... Халыкка бу бик яхшы тәэсир итә...

Ул хәятында теләсә кем булсын, аның үлүе – Зәңгәр чишмә буе өчен изге нәселдән килгән кадерле мәхдүмнең зыягысы[8] хисап ителә... Ул инде шәһадәт таҗын киеп шәһидләр җөмләсенә керде.

Тирә як тиз арада шул тәэсиргә килеп, аның, докторлар карамагыннан чыгып, авылына кайтарылганчы үткән көннәрендә шуннан башка нәрсә сөйләмәделәр. Халык арасында әллә нинди әкиятләр дә туып өлгерде. Гүя, анасы әүвәлге

---

[1] *Сәләф – ата-баба (элеккеләр)*

[2] *Тәхаттыр итәләр* – искә төшерәләр

[3] *Нәгузе биллаһи* – Алла сакласын

[4] *Коддеси бер кәмаләт* – изге бер рәвеш.

[5] *Зөмрә* - төркем

[6] *Иннә лиллаһи иннә иләйһи раҗигун!..* – "Чынлап та, без Аллаһныкы һәм аңа әйләнеп кайтачакбыз!", Коръәннән, "Бәкарә" сүрәсе, 156 аять.

[7] *Мәҗанин* – хыялый булып.

[8] *Зыягысы* – үлеме (аны югалту)

көнне аның үлүе хакында төш күргән, имеш. Гүя, ул үзе дә алдагы көнне үзенең хәятының аз калганлыгын аңлаткан, имеш. Гүя, ул үлеп, докторлар тарафыннан ярылгач, ничә көннәр яткач та, төсе үзгәрмәгән, йөзеннән иман нуры балкып торган, имеш...

Картлар хәзер аны кызганып сөйли башладылар:

- Юлда очраса, ерактан сәлам биреп исәнләшә, олуглап күрешә торган иде... Мәсҗедкә барса, аның Коръән укуын күңел теләп тора, ул укыса еламый түзеп тора алмый торган идек... Яхшы җаннар бу дөньяда аш яши шул... диләр.

Җеназасы җомга көнгә тугры килде. Җәмәгать бик күп иде. Күпләр, Фазыл ишаннан соң бу чаклы халык җыелган җеназа булганы юк иде, диештеләр.

Кара урманнан ир яратылып йөрерлек куәте булган һичбер адәм калмаган кебек, чит авыллардан да бик күп халык килгән иде. Кәрамәтле нәсел белән кадерле остазбикә һәм кызганыч язмышлы Җәләл мулла кебек газиз җаннарның авыр күләгәсе җеназаның өстеннән бара; җәмәгать исә, гүя моны хис кыйлып, олуг бер зыягъ күрә[1] иде.

Җеназаны алып чыкканда көн аяз, һава тын, күк ачык, кояш көлә, чәчәкләр елмая – табигать зур шатлык белән бәйрәм итә иде. Ләкин халык басынкы иде. Нидәндер телләр аз сөйли, күзләр авыр, кайгырып карый. Йөзләр гүя көлүне мәңгегә онытканнар. Гомумән матәмле бер кыяфәт.

Гүя халык, кара кәфенгә уралып, үзе икенче дөньяга бара...

Каберстанга җитеп, дәфен мәрасименә[2] керешкәч, табигать үзгәрде, кояш баешы ягыннан кара болыт чыгып, киң вә ачык күкне тиз арада каплый башлады... Кояш яшеренде, һавага яңгыр җиле исе керде. Фәза[3] югалып, җирнең түбәсе катлаулы-катлаулы, кара, караңгы һәм авыр болытлардан гыйбарәт булып калды.

Гүя бөтен дөнья кара кәфенгә уралды.

Дин вә гадәт буенча тиешле булган айиннәр (мәрасим) тәмам булып, киң мәйданны кара болыт шикелле каплап алган авыр җәмәгать аякка баса башлагач, Сабир бик тнз генә күтәрелде дә:

– Җәмәгать! Иптәше Кәрим мәхдүм бөрадәр мәрхүм хакында бер-ике генә сүз әйтмәкче: кузгалмавыңызны үтенәм! – диде.

Бу – яңа эш иде. Гадәттә бар нәрсә түгел иде. Ләкин халык, ни эшләячәген белмичә үк, кире җиргә тезләнде.

Йөзе вә кыяфәте танылмас мәртәбәдә үзгәргән шагыйрь, авыр кузгалып,

---

[1] *Зыягъ* – югалту, һәлакәт.
[2] *Дәфен мәрасиме* – күмү эше (җирләү церемониясе).
[3] *Фәза* – күктәге(һавадагы) бушлык.

халыкның уртасына басты да ят вә мөтәәссир тавыш белән мәрсиясен[1] укый башлады:

«Яшибез үлмәк өчен. Үлем һәр даим безнең баш өстебездә йөри. Хәятның һичбер секунды безне караңгы үлем дөньясына җибәрми калдыра алу куәтенә малик түгел... Без бүген терек, өмит саклыйбыз, әмәлләр белән башымыз тулы. Ләкин, кем белә, бәлки иртәгә, хәтта бүген, менә шушы минутта ук безне үлем алыр да өмитләр юкка чыгар, әмәлләр үзең белән бергә кабергә керер. Моңа иманыбыз камил, чөнки беләбез: бу – Илаһның үзгәрмәс кануны.

...Без – җир йөзенең мөсафирләребез: әзәлияттән килеп әбәдияткә[2] китәбез... Безнең гомеребез чикле; безнең насыйбымыз үлчәүле; шулар төгәнә[3] – без дә үлемгә тапшырылабыз... Хәят бик мөхтәлиф[4]. Шул үлемнең калганнарга тәэсирен дә төрлеләндерә. Синең хәятыңның гомум өчен кыйммәте ни дәрәҗәдә булса, үлемең өчен аӘмәлнлар да шул мәртәбәдә фөрьяд күтәрер, шулкадәр мөтәхәссир[5] булыр... Күзләребездәге яшьне сөртә-сөртә, хәзер генә караңгы гүргә куйдыгымыз Зыя мәхдүм – ул пакь вөҗдан, ул гали намус та – шундый, аглап кәффарәте[6] табылмаячак надирләрдән[7] берәү иде... Моны без, аңардан мәңгегә аерылгач, бигрәк ачык хис кыйлабыз...

Ул, яшим, ди иде. Яшәве гомум өчен иде. Ул «алгы көненең күгендә өмит йолдызының ялтыравын...» күрә вә бөтен вөҗүде белән шуңа таба ашкына иде... Аның җаны бөек әмәлләр[8] белән тулы булып, күңелендәге:

– Язмыш уң биреп, гомер вафа итсә, шул халыкның авыр көненә бер үзгәреш бирермен, томанлы вә караңгы хәятына бер нур тудырырмын!.. – дигән өмите тышка бәреп чыгарга якынлаша иде.

Ул Ходаның мөмтаз колы, халыкның махсус сәнгате иде. Табигать аны Тәңренең аерым бер бәндәсе итеп яратмыш улмалы ки, ул, үзе белмичә үк, шул мәгъбүденә[9] табына, шуңа нияз кыйлып[10], һәрбер адымда аңа якынаю голүвиятен[11] эсти иде...

Шул бөек мәгъбүдкә, адәм тәкатенә сыя алмаслык мәртәбәдә гали һәм самими

---

[1] *Мәрсия* – гүр нотыгы (үлгән кешенең яхшы якларын искә алып сөйләнгән сүз яки шигырь).

[2] *Әзәлияттән килеп әбәдияткә* – башлангычы булмаган мәңгелектән килеп ахыры булмаган мәңгелеккә.

[3] *Төгәнә* – бетә, тәмамлана

[4] *Мөхтәлиф* – каршылыклы.

[5] *Мөтәхәссир* – хәсрәтләнгән.

[6] *Кәффарәт* – яхшы эшләре белән аңа торырлык.

[7] *Надир* – сирәк очрый торган кеше.

[8] *Әмәл* – өмет, ышаныч.

[9] *Мәгъбүд* – табыну объкты, биредә: Тәңре мәгънәсендә.

[10] *Нияз кыйлып* – ялварып.

[11] *Голувиятен* - бөеклеген

булган бер гыйбадәт иҗат кыйлмак – хәятта аның бердәнбер идеалы иде...
...Ләкин, ләкин язмыш каршы китте, гомер вафа итмәде; шәфкатьсез дәһернең[1], асыл корбаннарны тиз алу золымы буенча, бөек әмәлләре, гали өмитләре белән бәрабәр тар вә караңгы кабер ул газизне дә җотты...
– Аһ, үлем! Аһ, фани әмәлләр... Зәваллы[2] өмитләр!!
Сезнең өчен кояш каплансын; табигать кара кәфенгә уралып, матәм тотсын; мөтәәссир[3] күңелләрдән күтәрелгән фөрьяд вә фәган илә җиде кат күк җимерелеп, агланган күз яшьләреннән җир йөзен туфан бассын – күңелем кинә[4] сабырсыздыр...
Ялгыз... Ялгыз бер җуаныч бар:
– «Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун!»[5]
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кояш батты... Кара кызыл ут белән ялкынланган шәфәкъ тә сүнеп бара. Матәм сурәтле җәмәгатьнең авыр вә басынкы кузгалыш белән таралышканына да бераз булып килә инде... Бик аз гына җил исә – яфраклар шыбырдый; күк йөзен каплап алган авыр, кара болытлар, белмим, каядыр акрын, ләкин куәт белән кузгалалар... Дөнья куе караңгылык эченә җотылырга якын...
Мәрхүмгә иман тәлкыйне[6] өчен калган карт мулла, тирән моракабәгә[7] охшаш бер хәлдән соң, акрын гына күтәрелде дә, мәетнең баш очына кадалган яшел таягын кулына алып, тамчыларга торган яңгырдан саклану өчен, ак җиләненең арткы чабуын тискәре ягы белән башына каплап, тыныч йөрәк белән кайтырга юнәлде...
Инде зыярат үзенең иске вә яңа каберләре, кемнең кайчан вә ничәдә вафат булганын сөйләмәктә булган ташлары, белмим, калганнарны юатып[*], белмим, киткәннәргә иман теләп, сабыр гына зикердә утырган карт агачлары белән-ялгыз калды...
Табигать исә гүя шуны гына көтә иде... Кинәт җил котырды. Күк күкрәп, яшен яшьни, күк, нindидер бер дәһшәтне каршылаган кебек, караңгылык эчендә куркыныч ут белән уйный; әллә кайда әллә нинди таулар, ташлар җимергән, ниһаясез галәмнәрнең астын өсткә китергән кебек, кемгәдер ачуыннан бөтен

---

[1] *Дәһер* – матди дөнья.
[2] *Зәваллы* – югалган.
[3] *Мөтәәссир* – кайгы-хәсрәткә чумган
[4] *Кинә* – һаман да.
[5] *«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун!»* - “Чынлап та без Аллаһныкы һәм аңа әйләнеп кайтачакбыз!”. Коръәннән “Бәкарә” сүрәсе 156 нчы аять.
[6] *Иман тәлкыйне* – мәрхүмнең исенә төшерү өчен иман уку.
[*] Юатып – авторда: *“җуатып”*
[7] *Моракабә* – уй.

кяинатны бер минутта юк итәргә янагандай дәһшәт белән тавышлый башлады... Бер минут үтә, күк тагы үзенең мөдһиш[1] тынлыгы эченә тала... Инде кабер өстендәге карт имән төн җиле белән шауларга тотына... Ул кемнедер шелтәли, ни нәрсә хакындадыр сөйли... Әлбәттә, куркыныч хакында... дәһернең кызганычсызлыгы тугрысындадыр... Тагы бер-ике минут үтә – тагы куркыныч куәт белән яшен яшьни, дәһшәтле күк күкри дә, кызу, куәтле һәм җилле яңгыр җир йөзен басып китә...

1912, май, Казан.

[1] *Мөһдиш* – куркыныч.